АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**Институт языка, литературы и искусства
имени Г. Ибрагимова**

# ЛЕКСИКОЛОГИЯ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

В трех томах

III том

Вторая часть

Казань
2018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
**Г. Ибраһимов исемендәге**
**Тел, әдәбият һәм сәнгать институты**

# ТАТАР ЛЕКСИКОЛОГИЯСЕ

Өч томда

III том

Икенче кисәк

Казан
2018

**УДК 811.512.145´373**
**ББК 81.2Тат-3**
**Т 23**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен
һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы
кысаларында басыла

**Проект җитәкчесе** – филол. фән. докт., проф. **М.З. Зәкиев**

**Фәнни редактор** – филол. фән. докт., проф. **Г.Р. Галиуллина**

**Рецензент –** филол. фән. докт. **Ф.С. Баязитова**

**Т 23** **Татар лексикологиясе:** өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – Т. III. 2 кис.– 464 б.
ISBN 978-5-93091-353-8

«Татар лексикологиясе»нең өченче томы икенче кисәге татар лексикографиясенең тарихын һәм сүзлекләрнең төрләрен өйрәнүгә багышлана. Әлеге хезмәт – татар фәнендә беренче тәҗрибә. Биредә үзәк мәсьәләләр итеп татар лексикографиясе фәненең методологик нигезе, традицияләре һәм казанышлары, бүгенге халәте һәм үсеш тенденцияләре алынды.

Басма тел белгечләренә, аспирантларга, студентларга һәм татар әдәби теле белән кызыксынган киң катлам укучыларга тәкъдим ителә.

**УДК 811.512.145´373**
**ББК 81.2Тат-3**

**ISBN 978-5-93091-353-8**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2018

# КЕРЕШ

Татар теленең сүзлек байлыгы, тарих катламнарын узып, бүгенге халәтебезгә зур мирас буларак килеп ирешкән. Телебезнең байлыгы, мәгънәви тирәнлеге, мәгълүмати мөмкинлекләре, мәдәни катламнары турында сүз алып барганда, беренче чиратта аның лексикасы тупланган чыганаклар, сүзлекләр күзаллана. Ерак гасырларда кулланылган лексик байлыкның бүгенге көнгә кадәр килеп җитүе дә сүзлекләр хисабына барган. Телебезнең үсеше дәвамында барлыкка килгән үзгәрешләрне, сүзлек составының баю, тулылыну юлларын ачыклаганда да, сүзлекләрнең роле әйтеп бетергесез зур.

Татар теле бу яктан горурланырлык мираска ия, чөнки телебезнең лексикографик фонды үткән тарихыбызда да, бүгенге чорда да күпләргә үрнәк булырлык байлыкны берләштерә. Татар сүзләренең сүзлекләргә теркәлеп, беркетелеп калуы бик борынгы заманнарга карый, һәм аларда теркәлеп калган берәмлекләр дә шактый төрле. Халыкның сүзлекләрдә теркәлеп калган җанлы сөйләм теле, диалект һәм сөйләшләрдә кулланыла торган лексик берәмлекләр, тотрыклы әйтелмәләр, башка төр лексика телнең сүзлек составын төрле яклап өйрәнүдә алыштыргысыз роль башкаралар. Шунлыктан сүзлек фондының, турыдын-туры вазифасыннан тыш, халыкның тарихын, мәдәни мирасын, милли психологиясен өйрәнүдә дә әһәмияте зур.

Үзенең үсеш дәверендә татар лексикографиясе төрле этапларны үтеп, аларның һәркайсына хас үзенчәлекләр булу, лексикографик материалның төрле һәм күпкырлы булуы әлеге мирасны бергә туплап, комплексы өйрәнүне таләп итә. Шулай ук сүзлек

эшенең җитди үсеше тупланган тәҗрибәне барлап, яңа лексикографик проектларны тормышка ашыру ихтыяҗын барлыкка китерә. Бу җәһәттән өчтомлы «Татар лексикологиясе» хезмәтенең өченче томын ике өлештән тәкъдим итү мәсьәләсе килеп туды. Аның беренче өлеше татар ономастикасына багышланса, икенче өлеше исә хәзерге татар тел белемендә зур үсешкә ирешкән һәм гаять җитди казанышлары булган лексикография фәненә багышлана.

Әлеге томны эшләү барышында, татар лексикографиясе фәненең традицияләре, методологик нигезе, фәнни мәктәпләрнең нәтиҗәләре һәм гомуми лексикографиянең үсеш тенденцияләре үзәккә алынды.

Әлеге проектның җитәкчесе – академик М.З. Зәкиев, фәнни редакторы – филология фәннәре докторы, профессор Г.Р. Галиуллина. Хезмәтнең концептуаль төзелеше филология фәннәре докторы, профессор К.Р. Галиуллин тарафыннан эшләнде.

Хезмәт өч гомуми бүлектән тора: беренче бүлектә лексикография фәненең теоретик мәсьәләләре карала. «Лексикографиянең статусы һәм башка фәннәр белән бәйләнеше», «Сүзлек төзү этаплары һәм принциплары» бүлекчәләренең авторы – филология фәннәре кандидаты Ә.К. Булатова. «Сүзлекләрнең хәзерге җәмгыятьтәге роле һәм урыны», «Лексикография фәненең төп төшенчәләре» бүлекчәләре филология фәннәре кандидаты А.Я. Хөсәенова тарафыннан башкарылды. «Татар теле сүзлекләренең типологиясе һәм структурасы» бүлекчәсен филология фәннәре кандидаты, доцент Р.Н. Кәримуллина, филология фәннәре докторы, профессор К.Р. Галиуллин язды (филология фәннәре кандидаты, доцент Р.К. Сәгъдиева тәрҗемәсендә).

Икенче бүлек татар лексикографиясенең тарихына, үсеш этапларын тасвирлауга багышлана. Башлангыч чор сүзлекләренә багышланган бүлекчәнең авторы – филология фәннәре кандидаты, доцент Х.Х. Кузьмина; «XIX гасыр сүзлекләре» өлешен филология фәннәре докторы, профессор Ә.Ш. Юсупова башкарды; «XX гасыр башы сүзлекләре»н – филология фәннәре кандидаты, доцент Р.С. Нурмөхәммәтова, «XX гасырның 20–40 нчы еллар сүзлекләре» бүлекчәсен – филология фәннәре докторы, профессор К.М. Миңнуллин

һәм филология фәннәре кандидаты Э.И. Сафина, «XX гасырның 50–80 нче еллар сүзлекләре» һәм «XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы сүзлекләре» бүлекчәләрен филология фәннәре кандидаты М.З. Вәлиева язды.

Өченче бүлектә татар сүзлекләренең төрләре анализлана. Бу бүлектәге материалларның авторлары: филология фәннәре кандидаты Ф.Г. Гаффарова («Аңлатмалы сүзлекләр» һәм «Терминологик сүзлекләр» бүлекчәләре), филология фәннәре кандидаты И.И. Сабитова («Ортологик сүзлекләр»), филология фәннәре кандидаты А.Я. Хөсәенова («Диалектологик сүзлекләр»), филология фәннәре кандидаты Р.Т. Сәфәров («Этимологик сүзлекләр. Алынмалар сүзлекләре»), филология фәннәре докторы, профессор Г.Р. Галиуллина («Ономастик сүзлекләр»), филология фәннәре докторы, профессор Ф.С. Хәкимҗанов («Фразеологик сүзлекләр»), һәм филология фәннәре кандидаты Э.И. Сафина («Сүзлекләрнең башка төрләре»). Кереш һәм йомгак өлешләренең авторы – Г.Р. Галиуллина.

Хезмәт ахырында татар сүзлекләренең хронологик белешмәлеге урнаштырыла.

Белешмәлекне төзегәндә, К.М. Миңнуллин, Р. Н. Вәлиуллин («Татар теле – сүзлекләрдә: [1801-1998 гг.]»), Р.Н. Кәримуллина, К.Р. Галиуллиннарның («Татарская лингвография: словари татарского языка 1951-2008 годов») хезмәтләре файдаланылды.

Татар лексикографиясе казанышларын туплаган әлеге хезмәт, татар тел белеменең үткәнен күрсәтү белән бергә, хәзерге торышын һәм киләчәктә үсеш юнәлешләрен ачыклауда да үз өлешен кертер дип ышанабыз.

# ТАТАР ЛЕКСИКОГРАФИЯСЕ ФӘНЕНӘ КЕРЕШ

## § 1. Лексикографиянең статусы һәм башка фәннәр белән бәйләнеше

*Лексикография* – чагыштырмача яңа термин. Ул берничә мәгънәгә ия: лексикография – 1) сүзлекләр төзү теориясе һәм практикасын өйрәнә торган тел гыйлеме тармагы; 2) сүзлек төзү эше; 3) басылып чыккан сүзлекләр тупламасы [2016-РТ_лингв: 80].

Бүгенге көндә лексикография статусы турында төрле фикерләр яшәп килә. Мәсәлән, В.Д. Табанакова билгеләвенчә, немец, француз һәм инглиз телле лингвистик сүзлекләрдә *лексикография* төшенчәсе практик эшчәнлек буларак билгеләнә (Табанакова, 2001: 11).

Чит ил галимнәре (мәсәлән, Ф. Гоув, Г.Э. Виганд, С. Аткинс, М. Рандел) лексикографияне фән буларак кабул итмиләр һәм теоретик лексикография юк дип дәлиллиләр. Шулай да соңгы елларда лексикографиянең теоретик статуслы булуы турындагы фикер өстенлек итә. Мәсәлән, Р. Хартман һәм Г. Джеймс лексикографик хезмәтләрендә, лексикография «сүзлекләр һәм белешмә басмалар белән бәйле профессиональ эшчәнлек һәм фәнни өлкә» дип бирелә. Ул *лексикографик практика*, ягъни сүзлекләр төзү, һәм *лексикографик теория* – сүзлекләрне тикшерү өлешләреннән тора. Беренчесе – сүзлекләрнең коммерция басмалары белән, икенчесе лингвистика өлкәсендәге фәнни тикшеренүләр белән бәйле (Хартман, 2002: 85).

Төшенчә аңлатмасыннан күренгәнчә, инглиз телле лексикографиядә коммерция сүзлекләре һәм фәнни сүзлекләр төшенчәсе капма-каршы куела. Әлеге сүзлекләрне төзү юллары сизелерлек

дәрәҗәдә аерыла. Коммерция сүзлекләрен төзегәндә, зур урынны маркетинг тикшеренүләр алып тора (Дамбуев, 2011: 17). Безнең илдәгә лексикография фәнендә маркетингны тикшеренүләр Европа лексикографиясендәге кебек зур урын бирелми.

Лексикографиягә карата башка төрле фикер дә бар. Мәсәлән, бер төркем галимнәр лексикографияне мөстәкыйль фән өлкәсе дип саныйлар. Аның үз өйрәнү предметы (төрле типтагы сүзлекләр), үз фәнни һәм методологик принциплары, махсус теоретик проблематикасы барлыгын дәлиллиләр. Беренче булып бу фикерне Л.В. Щерба алга чыгара (Щерба, 1974: 308). Шул вакыттан алып ватан тел белемендә, лексикография, сүзлекләр төзү практикасы гына түгел, теоретик фәнни тармак дип санала башлый.

Лексикография лексикология, семантика, стилистика, этимология, фонология һ.б. белән тыгыз бәйләнештә. Лексикография үзе лингвистиканың үсешенә йогынты ясый дип әйтеп була. Ул «универсаль методологик фән» вазифасын башкара (Дубичинский, 2009: 9).

Сүзлекләрсез математика, биология, информатика, культурология кебек башка фәннәрдә тикшеренүләр мөмкин түгел, сүзлекләр күпчелек фәнни тармакларның төп, программ чыганаклары дип таныла. Шуның өчен бүген чит ил һәм ватан лингвистлары лексикографиянең «синтетик» фән булуын исбатлыйлар.

Лексикография өлкәсендә күренекле белгеч В.В. Морковкин *сүзлек лексикологиясе* төшенчәсен кертергә тәкъдим итә. Аның максаты – тел берәмлекләрен гамәли лексикографик эшкәртү өчен оптималь шартлар тудырган лингвистик төшенчәләр һәм категорияләр белән эш итү. Сүзлек лексикологиясенең төп үзенчәлеге булып сүз турындагы фәннең ясалма рәвештә төрле аерым тармакларга бүленешен кире кагу һәм лексик берәмлекләрнең фонетик, морфологик, семантик, сүзьясалыш һәм башка үзенчәлекләрен бер урында һәм бер лексикографик караштан тикшерү тора (Морковин, 2001).

Лексикография лингвистик мәгълүматларны кулланучылар өчен турыдан-туры юнәлтелү белән аерыла. Аның ярдәмендә лингвистик мәгълүмат халыкка җиткерелә.

Лексикографик практика үсеше берничә юнәлештә бара: зур лексикографик проектлар оештырыла, шул проектлар кысаларында күләмле лексик массивлы сүзлекләр булдырыла; аерым тел кат-

ламнарын тасвирлаган сүзлекләр саны арта; төрле кулланучылар кызыксынуын исәпкә алган сүзлекләр эшләнә (төрле юнәлештәге уку сүзлекләре, күләмле ике телле сүзлекләр). Лингвистика фәненең казанышларын гәүдәләндергән, принципиаль яңа сүзлекләр дә барлыкка килә. Мәсәлән, Ю.Д. Асперсян тәкъдим иткән актив сүзлек (Асперсян, 2014: 5). Актив сүзлекләр беренче чиратта, потенциаль кулланучыны билгеле бер телдә үз текстларын дөрес төзү өчен кирәк булган бар нәрсә белән дә тәэмин итү өчен эшләнә. Бу ноктадан караганда, сүзлектәге сүзләр саны күпкә азрак та булырга мөмкин. Шул ук вакытта һәр сүз турында мәгълүмат мөмкин кадәр тулы булырга тиеш (Сафаров, 2020:15).

Хәзерге лексикографлар сүзлекләр төзү белән генә шөгыльләнми, лексикография фәненең теоретик нигезләрен дә тикшерә, өйрәнә. Сүзлек, сүзлекче фәнни эшчәнлегенең уникаль объекты буларак, җәмгыятьнең рухи тормышында аерым урын алып тора. Халыкның иҗтимагый-мәдәни торышын бәяләгәндә, төп факторларның берсе булып милли әдәби телнең академик аңлатмалы сүзлеге булу санала, чөнки ул башка лексикографик хезмәтләр өчен нигез функциясен үти.

Бүген халыкның мәдәни мирасын аңлап җиткерүдә сүзлекләрнең йогынтысы сизелә. Лексикографиянең казанышларын барлык фәннәр дә куллана, чөнки терминнарның семантик аңлатмасы – фән аппаратының иң мөһим өлеше. Сүзлек мәкаләсенең һәрбер өлеше зур эксперименталь эшчәнлек нәтиҗәсе булып тора. Нинди дә булса сүзлек төзегәндә, абруйлы чыганаклар файдаланыла, мәсәлән, моңа кадәр булган сүзлекләр, сүзлек картотекалары, лингвистик экспериментлар, электрон мәгълүмат базалары һ.б.

Лексикографиянең ике төре – гамәли һәм теоретик лексикография аерыла. *Гамәли лексикографиянең* төп функциясе: 1) телне өйрәтү, 2) туган телне тасвирлау (аңлатмалы сүзлекләр), 3) телара аралашу (икетелле сүзлекләр), 4) телнең сүзлек составын фәнни яктан өйрәнү (этимологик, тарихи сүзлекләр). *Теоретик лексикографиянең* төп функциясе: 1) сүзлекләрнең типларын билгеләү, 2) сүзләрне туплау, алар турында мәгълүмат бирү принципларын билгеләү (Галиуллина, 2013: 107–108).

Лексикография сүзне аның барлык үзлекләре җыелмасында бирә, шул сәбәпле, сүзлек тел өлкәсендәге уникаль һәм алыштырылмас әсбап кына түгел, фәнни тикшеренүләрнең мөһим коралы

булып тора. Бүгенге көндә лексикографлар булган лингвистик белемнәрнең барлык аспектларын да сүзлек формасына гәүдәләндерергә омтыла, шуңа күрә яңа сүзлекләрдә тасвирлау объекты булып сүзләр генә түгел, башка тел берәмлекләре дә тора.

«Кеше һәм сүзлек» диалогы коммуникатив һәм таныпбелүнең мөһим формасын тәшкил итә. Шул ук вакытта сүзлек кулланучыларның төп өч төркемендә (тел вәкилләре (нигездә укучылар), чит телне өйрәнүчеләр, телчеләр) дә диалог барышында принципиаль төрле мәсьәләләр барлыкка килә.

Белем бирү өлкәсендә сүзлекләрнең роле бик мөһим. Тел белемендә *уку лексикографиясе* актив үсеш ала. В.Г. Гак, аның үсеше турында фикер йортеп, болай яза: «Һәр сүзлек – иң беренче чиратта дидактик, ягъни уку өчен төзелгән әсәр. Сүзлек тәгъбирләренең анализы, сүзлек материалларының тасвирланган дөньяга мөнәсәбәт үзенчәлекләре, сүзлеккә хас хәбәр төрләре сүзлекнең дидактик жанрына караганын һәм аңа педагогик сөйләм үзенчәлекләре хас икәнен күрсәтә» (Гак, 1978:12).

Татар лексикографиясендә сүзлекләрнең күп төрләре тәкъдим ителгән, ләкин җәмгыятьнең гомуми *лексикографик культура* дәрәҗәсе түбән булып кала. Күпчелек уникаль сүзлекләр, аз тираж белән чыгу сәбәпле, киң катлам кулланучыларга барып җитми. Күп кенә нәшер ителгән, яңадан басылып чыккан сүзлекләр һәм сүзлекчәләр кибет киштәләрендә бар, ләкин алар еш кына сатылып алынмый калалар, чөнки укытучыларда да, укучыларда да сүзлекләр белән файдалану күнекмәләре формалашмаган. *Лексикографик компетенция* (танып белү һәм коммуникатив мәсьәләләрне чишү өчен сүзлеккә мөрәҗәгать итү кирәклеген аңлау, төре һәм жанрын истә тотып, кирәкле лексикографик басма сайлый белү, сүзлек текстын кабул итә белү һәм сүзлектән сүз турында кирәкле мәгълүмат таба белү, төрле сүзлекләрне чагыштыра белү) булмау сүзлекне яхшы сыйфатта кулланырга, аның бөтен мөмкинлекләрен кузалларга мөмкинлек бирми (Козывер, Черняк, 2015: 12–15).

Җәмгыять культурасы күрсәткечләренең берсе буларак, лексикографик культураны тәрбияләргә кирәк, һәм бу эшне мәктәптән үк башлау зарур.

*«Лексикография»* төшенчәсенең иерархик аңлатмасын В.В. Морковкин түбәндәгечә тәкъдим итә: «*Лексикография теориясе* («лексикография» төшенчәсенең күләмен, эчтәлеген һәм

структурасын билгеләү; сүзлек лексикологиясе; сүзлек төрләре һәм жанрлары турында; сүзлек өлешләре һәм параметрлары турында; лексикографик конструкцияләү турында; беренчел сүзлек материаллары, ягъни картотекалар; сүзлек эшен планлаштыру һәм оештыру турында өйрәтмәләр); *лексикография тарихы* ( сүзлекләр тарихы; типик лексикографик проблемалар чишү тарихы); *практик лексикография* (сүзлекләр һәм башка сүзлек тибындагы әсәрләр төзү; сүзлек материалларын җыю һәм саклау)» (Морковин, 1987: 41).

Лексикография фәнни генә түгел, ул киң иҗтимагый әһәмияткә дә ия. Ул телне өйрәнә торган лингвистика фәне һәм телне өйрәнү белән кызыксынучы җәмгыятьне тоташтыру вазифасын үти.

Лингвистик сүзлекләр мөһим иҗтимагый функция башкара. Бер яктан, алар төрле халык вәкилләренә бер-берсен яхшырак белергә ярдәм итә. Икенче яктан, андый сүзлекләрдә төзелү вакытына кадәр җыелган теге яки бу халыкның, җәмгыятьнең барлык белемнәре туплана.

Лексикография берничә мөстәкыйль тармакка бүленә, аның һәрберсенең үз фәнни аппараты, сүзлекләрнең эчке типологиясе, сүзлек төзү методлары, картотекалары һәм мәгълүмат базалары бар. Бүгенге көн лексикографиясендә гомум лексикография (һәр сүзлеккә хас сыйфатларны өйрәнә торган тармак) һәм лексикографиянең хосусый бүлекләрен (укыту, терминологик, ономастик һ.б.) аерып була. *Гомуми лексикография* типология ярдәмендә барлык сүзлекләр өчен уртак булган (ягъни статистик өстенлек иткән) сыйфатларны билгеләргә, шулай ук сүзлекләрне куллану һәм аларның функцияләренең гомуми закончалыкларын тикшерергә тиеш. *Хосусый лексикография* билгеле төр сүзлекләрнең эчке төзелешен һәм аны төзү методларын, шул төр сүзлекләрнең тарихын, шул төр сүзлекләрнең адресатын һәм ни өчен кирәклеген өйрәнгән тармаклардан торырга тиеш дип исәпләнә (Дамбуев, 2011: 20).

Тел белемендә берничә төр хосусый лексикография аерыла. *Бер телле лексикография* (аңлатмалы сүзлекләр, мәсәлән, Татар теленең аңлатмалы сүзлеге [2005-Т_аңлат].), *икетелле сүзлекләр* (тәрҗемәле сүзлекләре, мәсәлән [2016-РТ_лингв]), *укыту лексикографиясе* (тел өйрәнү өчен сүзлекләр: Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге. [2013-Т_аңлат_мәкт].), *фәнни-техник лексикография* (терминологик сүзлекләр: [2015-АРТ_компьют.]).

Бүгенге көндә сүзлекләр эшендә актив рәвештә яңа лексикографик технологияләр кулланыла. Традицион сүзлекләрнең электрон версияләреннән тыш, электрон сүзлекләр дә чыга. Төрле тел мәгълүмат базалары кергән тел машина фондлары төзелә. Шулар нигезендә лексикографиянең яңа тармагы – *корпус лексикографиясе* барлыкка килә. Корпус лексикографиясе – булган мәгълүматларны анализлау, саклау һәм эшкәртү өчен даими рәвештә компьютерларны кулланып, текст һәм акустик корпуслар нигезендә телне өйрәнү тармагы. Татар телендә, мәсәлән, татар теленең «Туган тел» корпусы, «Татар теленең язма корпусы», «Татар матур әдәбияты корпусы» проектлары эшләнгән.

Заманча лексикографиянең компьютерлаштыру белән бәйләнгән икенче тармагы – *киберлексикография*, ягъни текст белән эшләү өчен, сүзлекләрне төзү өчен, Интернет куллану (Карр, 1997: 209–221).

Татар лексикографиясенең бай тарихы һәм берничә гасыр буе күп галимнәр тикшеренүчеләр һәм тел белгечләре тарафыннан җыелган кыйммәтле мирасы бар. Төрки-татар тел белеме, шул исәптән татар лексикографиясе өлкәсендәге гамәли һәм фундаменталь тикшеренүләр нигезендә барлыкка килгән фәнни потенциалны киңәйтү, тирәнәйтү һәм эзлекле реальләштерү ярдәмендә милли лексикографиянең хәзерге көндәге дәрәҗәсе тәэмин ителә.

Шуның белән беррәттән, тормыш гомум технологияләштерү юнәлешендә үсеш ала. Массакүләм компьютерлаштыру, электрон мәгълүмат базалары, төрле каталоглар, информацион-эзләү ресурслары булдыру һәм куллану, тәрҗемә, сөйләм аеру һәм синтезлау өчен программалар эшләү шартларында профессиональ лексикографик эшчәнлекнең мөһимлеге арта бара. Бу өлкәдә яңа буын электрон сүзлек продукциясен күп максатлы, полифункциональ, интерактив сүзлекләр булдыру бурычына өстенлек бирелә. Мондый сүзлекләр минималь көч кую белән бер чыганактан киң тематик диапазондагы максимум кирәкле мәгълүмат бирергә тиеш. Шундый типтагы сүзлекләрне заманча гаджетлар ярдәмендә куллану мөмкинлеге, аларны традицион сүзлекләрдән уңайлырак һәм популярлырак ясый, ләкин бу – традицион лексикографиянең үсешенә сизелерлек йогынты ясамый. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Гамәли семиотика институты һәм Татарстан

Республикасы Фәннәр академиясе белән хезмәттәшлек итә торган башка оешмалар катнашында татар телен интернет челтәре аша популярлаштыру максатыннан эшләнгән Татар теленең зур электрон тупланмасы «TATZET» платформасы актив кулланышта. Татар теле сүзлекләренең электрон фонды (аңлатмалы, тәрҗемә, терминологик һ.б. сүзлекләр); татар матур әдәбияты корпусы (татар язучылары әсәрләрен, аерым фольклор жанрлары текстларын, башка телләрдән татарчага тәрҗемә ителгән матур әдәбият үрнәкләрен үз эченә ала); «Туган тел» татар гомумтел корпусы (күләме – 150 миллионнан артык әдәби кулланышта булган татар сүзе); Татарстан Республикасы топонимнарының электрон каталогы (3920 географик атаманы үз эченә алган комплекслы сүзлек); татар сөйләме синтезаторы (персональ компьютерда язылган текстны тавыш белән әйтү мөмкинлеген тудыручы проект); Microsoft Office, Microsoft Windows, Android, iOS операцион системалары өчен татарча локализация пакетлары һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан эшләнгән башка проектларны үз эченә ала.

Лексикографик практикага компьютер технологияләрен кертүгә зур роль бирелә, һәм бу милли лексикография үсеше өчен, төрле типтагы зур күләмле электрон лексиконнар, интерактив уку сүзлекләрен һ.б. фәнни продукцияне әзерләргә шартлар һәм мөмкинлекләр тудыра.

Хәзерге татар лексикографиясендә җитди фәнни эшләр алып барыла, һәм алар якын киләчәктә тел семантикасының лексикографик интерпритациясе мөминлекләрен камилләштерүдә алга китергә ярдәм итәчәк. Булган тәҗрибәдән күренгәнчә, әлеге максатка ирешү өчен иң эффектив юл – лингвистлар һәм программистларның тырышлыгын берләштерү һәм бу процесска массакүләм укучыларны да җәлеп итү.

### § 2. Сүзлекләрнең хәзерге җәмгыятьтәге роле һәм урыны

Сүзлекләр халык мәдәниятен, тарихи үсешен аңлау һәм кабул итүдә мөһим урын алып торалар. Дөньяда меңнәрчә төрле сүзлекләр яшәп килә, алар киң катлам укучы һәм махсус белгечләрнең ихтыяҗларына җавап бирә.

Лексикографиянең төп өйрәнү объекты саналган сүзлек билгеле бер тәртиптә тупланган һәм төрле аңлатмалар бирелгән сүзләр җыелмасы буларак билгеләнә [2016_РТ_лингв: 157–158; 2001-Т_тел гыйлеме: 64, 1976-Р_лингв: 396]. Сүзлек – сүзләрне (морфема, сүзтезмә, идиома һәм башка төр тәгъбирләрне) җыеп, алфавит тәртибе белән яки башкача урнаштырып, аларга тиешле аңлатмалар (тәрҗемәләр, кулланылыш үзенчәлекләре һ.б.) яисә нинди дә булса төшенчәләр, әйберләр, аерым шәхесләр хакында мәгълүмат биргән белешмәлек. Лексиколог һәм сүзлекләр авторы Г.Әхәтов сүзлекне «сүзләр исемлеге» дип атый (Әхәтов, 1995: 88). К.Р. Галиуллин сүзлек термины урынына «лингварий» төшенчәсен тәкъдим итә, һәм лингварийны «аерым бер тәртип буенча тупланган тел берәмлекләренең (сүзләр, морфемалар, сүзтезмәләр һ.б.) җыелмасы», – дип билгели (Галиуллин, 1994: 125).

Сүзлек телнең билгеле бер чордагы торышын, сүз байлыгын чагылдыра торган лексикографик чыганак булып тора. Анда халыкның, телнең үсеш-үзгәреш эволюциясе һәм аерым бер дәвергә хас сүзләр мирасы теркәлә.

Телнең сүзлек составы – гасырлар буенча тудырылган зур байлык. «Телнең лексик-семантик системасы дип үзара мөнәсәбәттә яшәгән һәм тулы бер бөтен хасил иткән лексик берәмлекләр җыелмасын атыйлар» (Татар теленең лексикологиясе, 2015, Т.I.: 79). Ул үзара аралашуда көн саен кулланыла торган лексик берәмлекләрне, тормыштагы үсеш-үзгәрешләрне үзендә чагылдыра. Шуңа күрә, иҗтимагый тормыш үзгәргән саен, сүзлек составы даими рәвештә тулыланып үсеш кичерә.

Ф.Ә. Ганиев: «Лексика – хәрәкәттәге ачык система, анда яңа берәмлекләр барлыкка килә, кайберләре акрынлап төшә бара. Әмма ул һәр этап өчен, тел эволюциясенең һәр чорында үзенә бер бөтен тәшкил итә», – дип белдерә (Ганиев, 2001: 3).

Кешелек дөньясында сүзлекләрнең әһәмияте гаять зур. Гасырлар буе халык иҗат иткән сүз хәзинәсен җыеп калдыру, аны яшь буынга дөрес җиткерү, көндәлек тормышта дөрес кулланырга өйрәтү лексикографик хезмәтнең төп бурычларыннан санала. Сүзлекләр дөнья турында күзаллауларны, тел буенча белемнәрне теркәү, системалаштыру, туплау, саклау һәм киләчәк буыннарга тапшыру макстатыннан чыгып төзелә.

Лексикографик хезмәт буларак, сүзлек түбәндәге функцияләрне башкара:

- телне, аның тарихын һәм хәзерге торышын фәнни яктан өйрәнә;
- тел белеме буенча белемнәрне системалаштыра;
- туган тел нормаларын өйрәнә;
- язма һәм сөйләм теленең кагыйдәләрен чагылдыра;
- алынма сүзләр, аңлашылмый торган сүзләр һәм искергән сүзләрне аңлата;
- телара аралашу һәм тәрҗемә практикасын сүзләр (төшенчәләр) белән тәэмин итә;
- чит телне өйрәтә, өйрәнә торган телдә сөйләшүче халыкның мәдәнияте һәм тарихи үткәне белән таныштыра;
- телдә барган үзгәрешләрне фаразлый.

Сүзлекләрне без «тарих елъязмасы» дип тә атый алыр идек. Милли мәдәниятнең бер өлеше буларак, сүзлекләргә кергән лексик берәмлекләрдә халык тормышының төрле яклары чагылыш таба, тарихи үсеш үзенчәлекләре сүзләр, төшенчәләр аркылы беркетелә.

Сүзлекләр «халыкларның үзара аралашуы, тормыш-көнкүреш казанышларын уртаклашуы, башка халыкларның мәдәниятен белергә омтылуы алар телендәге аерымлыкларны, җитештерелгән һәм базарга чыга торган төрле әйберләрнең, эшләнмәләрнең исем-атамаларын да белү зарурлыгын тудырган. Бу бигрәк тә чит, әлегә таныш булмаган халыклар белән очрашканда, алар белән аралашуны җайга салу өчен кирәк булган» [Миңнуллин, Сәфәров, 2019: 8].

Сүзлекләрнең күпсанлы төрләре билгеле. Барлык төр сүзлекләрен ике төркемгә бүләләр: энциклопедик һәм филологик сүзлекләр.

Энциклопедик сүзлекләрдә төшенчәләргә аңлатма бирелә, алар турында карашлар, гипотезалар, фикер каршылыклары чагылдырыла, төшенчәләрне белдергән күренешләр, әйберләр, вакыйгалар, күренекле шәхесләр турында информация китерелә. Энциклопедик сүзлекләрнең 2 төре аерыла: 1) җәмгыять тормышы һәм фәннең төрле тармакларыннан системага салынган мәгълүматларны чагылдыра торган универсаль сүзлекләр һәм 2) фәннең аерым тармагы турында системага салынган мәгълүматларны бирә торган махсус сүзлекләр.

Филологик сүзлекләрдә сүзләр алфавит тәртибендә туплана, аларның мәгънә, лексик-грамматик, стилистик һ.б. үзенчәлекләре күрсәтелә. Эчтәлеге, максаты, сүзлек шәрехнамәләренең төзелеше, нинди телдә язылуына карап, филологик сүзлекләр түбәндәге төрләргә бүленә: 1) тәрҗемәи, 2) бер тел сүзлекләре. Аларның төренә бәйле вазифалары да төрле була. Әйтик, телара сүзлекләр сәүдәгәрлек, сәяхәтчеләр өчен ярдәмлек, белешмәлек буларак хезмәт итә. Төрле илләр, өлкәләр белән сату иткәндә, яисә таныш булмаган җирләргә сәяхәт, сәфәр кылганда, җирле халыкларның телләрен аңлау, алар белән аралашу өчен, әлбәттә, махсус сүзлекләрдән файдалану ихтыяҗы, зарурилыгы туа.

Бер тел сүзлекләре, үз чиратында, берничә төргә аерылып, мөһим функцияләр башкара: 1) аңлатмалы сүзлекләрдә сүзнең мәгънәсе, кулланылышы, грамматик, фонетик һәм стилистик үзенчәлекләре күрсәтелә; 2) алынмалар сүзлеге теге яки бу телгә икенче телдән кереп урнашкан сүзләрне туплый; 3) синонимнар сүзлегендә телнең синонимик байлыгы бирелә; 4) этимологик сүзлекләрдә сүзнең килеп чыгышы ачыклана; 5) диалекталь сүзлекләрдә телнең аерым диалектларында кулланылган сүзләр туплана, әдәби телдәге варианты бирелә; 6) фразеологик сүзлекләр телдә кулланылышта йөри торган тотрыклы әйтелмәләрне аңлата; 7) орфографик сүзлекләрдә телдәге сүзләрнең дөрес язылышы күрсәтелә; 8) терминнар сүзлегендә телдә кулланыла торган терминнарга аңлатма бирелә; 9) ономастик сүзлекләрдә, максатына карап, төрле ялгызлык исемнәре, аларның мәгънәләре, килеп чыгышлары күрсәтелә (Галиуллина, 2013: 108).

Уку-укытуда сүзлекләрнең әһәмияте бәхәссез. Нинди дә булса өлкәдә белем алганда, кеше махсус белешмәлекләрдән файдалана. Мәктәптә белем алу дәверендә, бала аерым төшенчә, сүзләрне аңламаска мөмкин. Ярдәмгә сүзлекләр килә. Алар мәктәп укытучылары һәм укучылары, югары һәм һөнәри белем бирү уку йортлары студенлары өчен белешмәлек ролен үти, ягъни сүзлек гамәли кулланма вазифасында була. Укучылар сүзлекләр аркылы телнең киң кулланылышта йөргән актуаль лексикасы, фразеологиясе, укыту предметларының төп төшенчәләре, терминнары белән танышалар. Шул рәвешле, сүзлек укучыга телне өйрәнү-өйрәтү, туган телне үзләштерүдә белемен тирәнәйтү өчен мәгълүмат алу чыганагы дип карала. Татар теле белемендә мондый төр сүзлекләр-

не төзү тарихы һәм тәҗрибә зур, мәсәлән, соңгы еларда чыккан «Татар теленең мәктәп өчен аңлатмалы сүзлеге» [ 2013-Т_аңлат].

Сүзлекләр телне өйрәнергә теләүчеләр өчен кулланма буларак файдаланыла. Чит халыкның мәдәниятен өйрәнү, ул сөйләшә торган тел реалийлары, күренешләре белән якыннан танышу вакытында, сүзлекләр белән эшлиләр, аңлашылмый торган сүзләргә аңлатма, тәрҗемә-эквивалентларын табалар, сүзнең әйтелеш һәм язылыш үзенчәлекләрен үзләштерәләр. Чит телне үзләштергәндә, эквивалентсыз лексиканы өйрәнеп була, лексиконда китерелгән мисал-иллюстрацияләр сүзне урынлы һәм дөрес кулланырга өйрәтә, сүзлек чит телдә язылган әдәбият белән танышуда алыштыргысыз әсбап була.

Бу уңайдан шуны да искәртеп китү урынлы булыр: сүзлекчеләр, ягъни лексикографлар эшчәнлеге, тулаем әйләнә-тирә мохит, вакыт һәм аерым бер катлам укучылары ихтыяҗларына юнәлдерелгән була. Хезмәттән файдаланучының яшь үзенчәлекләре, компетенция дәрәҗәсе, һөнәри һәм тел буенча әзерлеклеге истә тотыла, димәк, кулланучы укый алырлык материал тәкъдим ителә.

Һөнәрләре ягыннан киң катлам аудитория белән эшләүче матбугат, радио, телевидение хезмәткәрләре, тәрҗемәчеләр дә шулай ук сүзлекләрдән белешмә буларак файдалана. Мәгълүматны тулы һәм аңлаешлы итеп җиткерү максатыннан, чыгыш ясаганда дөрес һәм аһәңле, сүзләрне урынлы куллану алар өчен бик мөһим.

Иҗтимагый күренеш буларак, сүзлек идеологиядән аерылгысыз. Ул социумда, җәмгыятьтә яшәп килүче иҗтимагый, сыйнфый, кастаара концептларның системасыннан гыйбарәт. Тел берәмлекләренең дефинициясе, форма, урынны һ.б. кулланылышы җәмгыятьнең мәдәни һәм идеологик кагыйдәләренә таяна. Ж.П. Сеген фикеренчә, «Җәмгыять үзенең сүзлек составы белән идарә итә» [Дубичинский, 2008: 33]. Шул рәвешле, сүзлек «идеологик корал» булып та тора.

Матур, төзек сөйләшү кешенең мәдәниятлелеге һәм белемлелеге хакында сөйли. Сүзлек запасы бай булу кешенең югары интеллектуаль үсеше турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә, җәмгыять әлеге бай телле кешене шулай ук акыллы һәм укымышлы шәхес, эрудит буларак кабул итә. Бу исә тормышта үз урынын табуны җиңеләйтә, хезмәт яисә иҗади эшчәнлектә югары үрләргә ирешүнең бер юлы булып тора.

Дөрес сөйләм күнекмәләрен булдыру өчен, әлбәттә, кеше лексиконының бай булуы мәҗбүри. Шуны да искәртү зарури: лексемаларны дөрес һәм урынлы куллану да мөһим. Статистика буенча, киң таралган телләрдә, нигездә, 500 мең сүз дип каралган. Шул ук вакытта укымышлы саналган кеше бары 10 меңгә якын сүзне генә белә ала дип исәпләнә. Үзенең лексиконнында булмаган сүзләрне ул төрле махсус белешмәлек, сүзлекләргә, энциклопедияләргә мөрәҗәгать итү аркылы табарга мөмкин. Мәсәлән, татар теленең 1977–1981 елларда дөнья күргән өч томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә – 52 мең баш сүз, 6 меңгә якын фразеологик берәмлек; 2007 елгы ике томлы «Татарча-русча сүзлек»тә – 56 мең баш сүз; 2015–2021 елларда төзелгән алты томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә чама белән 70 меңгә якын баш сүз, 10 меңнән артык фразеологик берәмлек теркәлгән. Хәзерге көндә әлеге сүзлекләр татар теленең иң тулы сүзлекләре булып санала.

Кешенең акылы күп күләмдәге мәгълүматны үз эченә сыйдырып бетерә алмый, шунлыктан һәр кеше үзенең гомерендә сүзлекләрдән файдалана. Сүзлекләр уку һәм алардан файдалану сөйләм культурасын үстерә. Алар һәр аерым кешенең сүзлек запасын баета, тел нормалары белән таныштыра, урынсыз кулланылыштан саклый, грамматик-орфоэпик хаталарны булдырмауда ярдәм итә. Алар телне өйрәнүнең киң мөмкинлекләрен ача һәм логик фикерләүнең үсешен тәэмин итә. Белемнәре төрле дәрәҗәдә булган киң катлам укучылары сүзлекләрдә кызыклы һәм файдалы мәгълүмат таба ала: сүзнең мәгънәләрен аңлату, аның сөйләмдәге урынын күрсәтү, дөрес кулланылышын билгеләү, сүзне телнең функциональ стильләре белән бәйләү, укучыга сүзнең грамматик кулланылыш үзенчәлекләрен күрсәтү, аның килеп чыгышын билгеләү, башка телләрдәге эквивалент-тәрҗемәләрен барлау һ.б.

Хәзерге яшәү рәвеше, тормыш темпы һәм мәгълүматның чиксезлеккә омтылган күләме сүзлектән җыйнаклык, оперативлык һәм файдалану уңайлыгын таләп итә. Шул ук вакытта мәгълүматның да максималь рәвештә бай булуын күзаллый. Күп очракларда китап сүзлекләрне электрон, Интернет сүзлекләр алмаштыра. Мәсәлән, Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һә сәнгать институты хезмәткәрләре төзегән ике томлы Татарча-русча һәм Русча-татарча сүзлекләрнең гади электрон версияләре дөньякүләм билгеле ABBYY компаниясенең күптелле лексикографик проектында —

ABBYY Lingvo сүзлегендә чагылыш таба [URL: http://tatar. com. ru/e-slovar.php].

Шулай ук татар теленең «Сүзлекләрнең электрон фонды»-на аерым тукталу кирәк. Анда Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында алдагы елларда төзелгән, республика нәшриятлары, шулай ук сүзлекләрнең авторлары тәкъдим иткән белешмәлекләр берләштерелгән. Фондта төрле типтагы: аңлатмалы, ике һәм күп телле, гомуми, аерым өлкәләргә багышланган, төрле аспектларны яктырткан сүзлекләр урын ала. Фондның чыганаклары сүз турында төрле мәгълүмат табу мөмкинлеген бирә (дөрес язылышы һәм әйтелеше, басымы, грамматик үзенчәлекләре, мәгънәсе, синонимнары, килеп чыгышы, фразеологизмнарда һәм сүз тезмәләрендә кулланышы һ.б.). Әлеге тупланма татар телен куллану, өйрәнү һәм тикшеренүне мәгълүмати тәэмин итү мөмкинлекләрен киңәйтә [https://suzlek.antat.ru/about.html].

Телнең үсеше һәм үзгәреше даими күренеш булганлыктан, сүзлек – вакытлы феномен. Ул телне аерым бер үсеш чорында гына терки, телдә яңа барлыкка килгән лексик берәмлекләр лексикографик хезмәтләргә бераз чигерелеп кертелә. Сүзлекләр һәрдаим яңартылып торсалар да, алар сүзлек составында яңа гына барлыкка килгән үзгәрешләрне чагылдырмый. Кулланылучы зур күләмле сүзлекләрдә телнең барлык сүзләре керә дип күзаллый, әмма бу чынбарлыкка туры килми. Сүзлекне шартлы рәвештә генә тулы тел хәзинәсене дип атап була.

Сүзлекне, үзенә күрә иҗтимагый киңәшче вазифасын үтәп, сүз кулланылышы, аерым чикләр эчендәге телнең торышын тәртипкә салучы аерым бер структур берәмлек дип тә карап була.

Адресатка юнәлдерелгән булу – хәзерге лексикографиянең төп принципларыннан берсе. Сүзлекләр халыкның цивилизация дәрәҗәсен, иҗтимагый тормыш темпын, милләтнең фәлсәфи, сәяси, дини, фәнни үзаңының үсешен тасвирлый. Шул ук вакытта сүзлек – «мәдәни» хезмәт, анда аерым бер тарихи үсеш этабындагы җәмгыятьнең үсеш казанашларын чагылдырыла.

Шулай итеп, сүзлек һәм белешмәлекләр – кешелек тормышының аерылгысыз юлдашлары. Алар белем алуда ярдәм итә, дөньяны танып белү мөмкинлекләрен киңәйтүдә, тел культурысын үстерүдә әһәмиятләре гаять зур.

## § 3. Лексикография фәненең төп төшенчәләре

XX гасыр ахырына лексикография – сүзлек төзүнең теориясе һәм практикасы буларак кабул ителә. Теоретик лексикография сүзлекләр типологиясен һәм сүзлек элементлары һәм структурасы турында тикшеренүләрне үз эченә ала. Бүгенге көндә лексикографиянең терминологик аппараты формалашу этабы дәвам итә, түбәндәге лексикографик терминнар инде киң таралышта: сүзлекнең микроструктрасы һәм макроструктурасы, сүзлек метателе, уң як, сул як, сүзлек билгеләмәсе, сүзлек төре һ.б. Лексикографиянең үз терминнары булуы, лексикографиянең фән буларак үсеше турында сөйли (Табанакова, 2001: 16). Лексикография теориясендә сүзлекләр функциясе (укыту, белешмә бирү, системалаштыру, норматив), лексикографик тасвирлау принциплары (адресатка нисбәтлелек һәм юнәлдерү, стандартлык, гадилек, тулылык, файдалылык һ.б.) формалаштырылган.

Теоретик лексикография сүзлекнең макроструктурасы (лексика сайлау, сүзлек күләме һәм характеры, материалның урнашу принциплары) һәм микроструктурасы (сүзлек мәкаләсенең структурасы, сүзлек билгеләмәсе төре, сүз турында төрле мәгълүматларның үзара бәйләнеше, тел иллюстрацияләрнең төре һ.б.), сүзлекләр типологиясе булдыру һәм лексикография тарихына бәйле мәсьәләләр җыелмасын үз эченә ала.

Сүзлекнең төп берәмлеге *мегастуктура* – сүзлекнең исеме, кереш өлеше; сүзлек корпусы – сүзлек мәкаләләр җыелмасы, нигездә, алар сүзлекнең 90% тирәсен тәшкил итә; кушымталар – сүзлек белән куллану кагыйдәләре, кыскартмалар исемлеге, төп һәм ярдәмче күрсәткечләр.

*Макроструктура* сүзлек корпусын оештыру, сүзлек мәкаләсенең урнашу тәртибен билгели (сүзлек, аның сул өлеше, сүзлек мәкаләсе).

*Микроструктура* – бер сүзлек мәкаләсе эчендә булган мәгълүматлар җыелмасы (сүзлек мәкаләсе структурасы). Сүзлек мәкаләсе һәрвакыт түбәндәге өлешләрне үз эченә ала:

– баш сүз (*сул як*);
– баш берәмлекне аңлаткан, аның төп үзенчәлекләрен тасвирлаган текст, ул төрле зоналар белән тәкъдим ителә (*уң як*).

Нигездә, барлык структур өлешләр дә сүзлек метателе сорауларына бәйле. *Сүзлек метателе* – төшенчәләр һәм аларны атаган терминнар системасы, алар ярдәмендә сүзлек, аның структурасы һәм эчтәлеге тасвирлана һәм анализлана.

Лексикографиянең төп төшенчәсе *сүзлек* (*лөгать*) – билгеле бер тәртиптә тупланган һәм төрле аңлатмалар бирелгән сүзләр җыелмасы.

К.Р. Галиуллин хәзерге тел белеме өлкәсендә «лексикография» терминына да яңача карау зарурлыгы бар дип билгели. Моңарчы бу терминны куллану шик тудырмады, чөнки лексикографик чыганаклар объекты, кагыйдә буларак, сүз булган. Ләкин лингвистика үсеше белән бәйле рәвештә сүзлек тасвирламасының аерым объектлары морфемалар, сүздән зуррак берәмлекләр (фразеологизмнар, паремияләр һ.б.) була, шуның нәтиҗәсендә киңрәк эчтәлекле яңа ыруглык төшенчә кирәклеге туа.

Мондый термин булып «*лингвография*» тәкъдим ителә. *Лингвографияне* тел белеменең тел белешмәләрен – лингварийларны төзү теориясе һәм практикасы белән шөгыльләнә торган дисциплинарара өлкәсе буларак билгеләргә мөмкин.

Шуңа бәйле рәвештә, бигрәк тә теоретик тикшеренүләрдә лингвографиянең төп терминын яңадан карау зарурлыгы туа. «Сүзлек» терминының эчке формасы тасвирлау объекты белән каршылыкка керә. «Сүзлек» термины нәкъ менә лексеманы тасвирлый торган тел белешмәсе буларак аңлана, ә тасвирлау объекты башка тел берәмлекләре яки морфемалар булган тел белешмәләре өчен әдәбиятта «фраз[ем]арь», «морфемарь» кебек атамалар барлыкка килергә мөмкин. Шуңа бәйле рәвештә бу терминнарны гомумиләштерүче термин-гиперонимда ихтыяҗ туа. Гомумиләштерелгән термин буларак, «лингварий» төшенчәсен кулланырга мөмкин. *Лингварий* (*лингварь*) – кулланучыга тел берәмлекләренең (сүз, морфем, сүзтезмәләр һ.б.) тәртипкә китерелгән җыелмасын һәм аларның характеристикаларын яисә тәрҗемә эквивалентын бирә торган белешмә (Галиуллин, 1995: 10).

XX гасырның 80 нче еллар икенче яртысында Казан университетында барлыкка килгән «лингвография» термины татар лексикографиясе өлкәсендә билгеле бер дәрәҗәдә таралыш тапты. Терминны тәкъдим итүче авторлар татар лексикографиясе эшчәнлеге лексикографик юнәлештән лингвографик этапка күчте: XX гасыр-

ның икенче яртысында сүзләр генә түгел, ә хәтта морфемалар, шулай ук лексик берәмлекләр тасвирланган шактый күп кенә тел белешмәлекләре барлыкка килде дигән фикердә торалар. Мисал буларак, морфемографик (мәсәлән, «Татар әдәби теленең сүзьясалыш калыпларының сүзлеге» [84-ТР_словообр_Гат.] ), фразеографик [57-Т_фраз_Зал.; 59-РТ_фраз_Бур.; 80-РТ_фраз_Байр.; 08-РАНТурТ_фраз һ.б.], паремиогра¬фик [59-Т_посл(59-67)_Исан_1] кебек һ.б. шундый тел белешмә китапларының төрләрен китерәләр (Татарская лингвография, 2011: 3).

Телдәге барлык сүзләрне туплаган сүзлек, аерым телнең тулы сүзлеге *тезаурус* дип атала. Әлеге терминның икенче мәгънәсе «сүзләргә төрле яклап, мөмкин булганча тулы характеристика бирә торган сүзлек» [2016-РТ_лингв: 157-158].

Лексикография теориясендә: сүзләрне сайлап алу һәм идиоматик куллануны җиңеләйтә торган лексикографик ярдәмлек *актив сүзлек* [2016-РТ_лингв:13].

Гадәттә сүзлек ул – аерым китап, ләкин ул дәреслеккә яки уку әсбабына кушымта булырга мөмкин. Беренче сүзлекләр нәкъ шундый булган. Мәсәлән, Ваһапов Г.А. Үз – үзеңне өйрәткеч (Татарлар русча һәм руслар татарча сөйләшергә. 5-нче басма. – Казан, 1871. – 60 б.) әсбабы. Аның төп өлеше рус-татар сүзлегеннән тора.

Сүзлекнең төп берәмлеге – *вокабула***,** ягъни сүзлектә тасвирлана торган сүз. Сүз мәкаләсенең бу беренче компоненты төрле атамалар белән билгеләнә: баш сүз, баш берәмлек, вокабула, реестр сүзе. Татарча сүзлекләрдән берничә мисал:

**САФЬЯН** → (сафьян – кожа) → сәхтиян; нәфис күн; кәҗә күн [1999-Т_синон: 83 ].

**ӘЛҮН** *каз.ар*. әлүчә (алыча) [2009-Т_диал.: 81] .

Лексеманың шартлы рәвештә төп саналган, гадәттә сүзлекләрдә теркәлгән формасы – **лемма**. Мәсәлән, фигыльне төрле сүзлектә төрле формада бирү күзәтелә.

Төп юнәлештәге (*-у/-ү*) исем фигыль формасы:

**САПЛАМЛАУ** *ф*. Саплам-саплам итеп аеру (җепне) [2019-аңлат_V:62].

Фигыльнең -ырга/-ергә (-рга/-ргә) инфинитив формасында бирелә:

**укырга** гл. 1) *в разн. знач*. читать / read; (*лекции*) give, deliver; (*наставления кому-л*.) lecture *smb*.; 2) учиться, обучаться / study,

learn; 3) *с именами сущ. образует слож. гл. со знач.* накликать, превозносить / call; *ләгънәт* ~ проклинать / (*призывать проклятие*) call down curses; *рәхмәт* ~ благодарить / call thanks, shower praises [2014-ТРА:361].

Гадәттә, һәр сүзлек мәкаләсендә бер генә вокабула тасвирлана. Әмма бу барлык типтагы сүзлекләр өчен дә дөрес түгел (мәсәлән, оялы типтагы кайбер сүзлекләрдә сүзлек мәкаләсенә тамырдаш сүзләр һәм семантик яктан якын сүзләр төркеме кертелә; синонимнар һәм антонимнар сүзлекләрендә сүзлек мәкаләсе үз эченә бөтен синонимик рәтне яки антонимик парын ала). Мәсәлән:

**САУБУЛЛАШУ – КАРШЫЛАУ**** прощаться – встречать [2015-Т_омон_антон: 41].

**САБЫРСЫЗ** → (нетерпеливый, несдержанный) → түземсез; тынычсыз; чыдамсыз; тынгысыз; тәкатьсез; биссабыр [1999-Т_синон: 81].

Шуңа да карамастан бары тик бер сүз генә мәкаләдә төп санала. Ул шартлы (башлангыч) сүзлек формасында бирелә.

Сүзлек күләмен вокабуллар җыелмасы (исемлеге) тәшкил итә. Гадәттә, сүзлекнең күләме турында мәгълүмат аның титул битендә яки аннотациясендә китерелә Мәсәлән, «Русча-татарча география сүзлег»енең күләме якынча 4000 термин, төшенчә һәм атаманы үз эченә ала [2017-РТ_геогр].

*Сүзлекнең күләме* – томлар саны түгел, ә сүзлектә тасвирлана торган берәмлекләр саны. Ул төрле тел берәмлекләреннән торырга мөмкин:

– Фонемалар – соңгы вакытта киң кулланышта, бу сөйләмнең автоматик белеп алу (аеру) эшләре белән бәйле.
– Морфемалар (алкушымчалар, тамырлар, кушымчалар) – морфема сүзлекләре, грамматик, сүзьясагыч сүзлекләр өчен. Мәсәлән, «Словарь словообразовательных элементов современного татарского литературного языка» [84-ТР_словообр.].
– Лексемалар («нигез формадагы» сүзләр) – бу критерий буенча күпчелек сүзлекләр төзелгән: аңлатмалы, орфографик һ.б. Әлеге төркемгә мисал итеп «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н атарга мөмкин [2005-Т_аңлат].
– Сүзформалары (билгеле сандагы, килештәге сүзләр) – грамматик сүзлекләр, рифма сүзлекләре өчен. Татар лексикогра-

фиясендә, мәсәлән, Әхтәмов М.Х. Татар теленең грамматика сүзлеге [2004-Т_грамм] басылып чыга.

– Сүзтезмәләр (берничә үзара бәйләнгән сүзләр) – фразеологик, идиомалар, клишелар сүзлекләре өчен. Мәсәлән, Ф.С. Сафиуллина тарафыннан төзелгән «Татарча-русча фразелогик сүзлек» [2001-ТР_фраз].

Сүзлекнең төп структур берәмлеге – *сүзлек мәкаләсе*. Тел берәмлегеннән яки берәмлекләр төркеменнән (сүз, сүзләр оясы, морфема, аңлатмалар, мисаллар, фразеологик берәмлекләр) торган, баш сүз белән башланган аерым текст һәм аның тасвирламасы [2018-аңлат_VI:15]. Бу сүзлекнең чагыштырмача автоном бүлеге.

Сүзлектә аңлатма бирелә яки тәрҗемә ителә торган барлык баш сүзләр тупланмасы, шул сүзләрнең исемлеге *лөгатьлек (сүзлекчә)* дип атала. [2019-аңлат_V:59].

Кайбер сүзлекләрдә, мәсәлән, орфографик сүзлектә сүзлек мәкаләсе баш сүз белән чикләнә:

**төркемчеле | к**, -ге [2010-офограф: 255].

Мондый сүзлекләр *бер яклы* дип атала. Күпчелек сүзлекләрдә җентекле яки күп төрле мәгълүмат бирелә, ул мәгълүмат лингвистик комментарий дип атала. *Лингвистик комментарий* – сүз тасвирламасының теге яки бу аспекты (дөрес язу, әйтелеш, куллану, килеп чыгышы һ.б.). Бу *ике яклы* сүзлекләр, чөнки сүзлек мәкаләсе структурасында ике як: *сул* (баш сүз) һәм *уң* (лингвистик мәгълүмат). Уң як өлеше – беренче чиратта, сүзгә аңлатма бирү.

Сүзләрнең лексик мәгънәсен аңлатуның традицион, гасырлар буе барлыкка килгән ысуллары бар, яки сүзлек дефиницияләре. Мәгънәне ачыклау процессын һәм аның нәтиҗәсен билгеләгән түбәндәге терминнарны кулланалар: «аңлатма», «дефиниция», «тәрҗемә эквивалент». *Аңлатма* тел берәмлегенең мәгънәсен дөнья картинасы карашыннан аңлата һәм, нигездә, филологик сүзлекләр өчен хас. Мисал итеп аңлатмалы сүзлектән өземтә китерик:

**ГЫЙЛЕМ** *и. гар.* **1.** 1) Белем. *Син гыйлем тупла, наданлыктан уян, Ахирәт көнне надан – эттән яман.* Г. Утыз-Имәни. *Ганасыйрны әсир иткән табигать, Булып мозтар, гыйлемгә кыйлды бигать.* Дәрдемәнд. *Укымышлы кеше – Кол Шәриф мәдрәсәсендә гыйлем алган.* Р. Мостафин

2) Фән, белем тармагы, фән өлкәсе. *Нитәк ки гыйлем укып, остаздан фатихасыз чыккан кеше файда күрмидер.* К. Насыйри. *Монда мин гыйльме тыйб әһелләренә бер-ике кәлимә сүз юлладым.* Ф. Латыйфи. *Мәдрәсәнең бер еллык «галия» бүлегендә укучылар, дин гыйлемен үзләштереп, имам-мөдәррислеккә әзерләнделәр.* Казан утлары [2016-аңлат_ II:121].

*Дефиниция* – төшенчәнең логик билгеләмәсе, аның эчтәлеген һәм үзенчәлекләрен билгеләү. Гадәттә, дефиниция – логик категория, һәм ул энциклопедик, терминологик сүзлекләргә хас. Мәсәлән, «Русча-татарча астронимия терминнары сүзлеге»:

**Магнитные бури** магнит давыллары (*Җир магнит кыры көчәнешлелегенең, гадәттәге тәүлеклек салмак үзгәртеп торуыннан тыш, Кояштагы процессларга бәйле рәвештә, кинәт кенә тәртипсез үзгәреше*) [1974-РТ_астр: 29].

*Тәрҗемә эквивалентлары* – икетелле һәм күптелле сүзлекләрдә аңлатма һәм дефиниция буларак кулланылган тел берәмлеге. Мәсәлән:

**төнге** *прил.* ночной / night; nightly ~ **лампа** ночник / night-lamp; ~ **смена** ночная смена / night shift [2018-ТИ:215].

Гадәттәгечә, түбәндәге аңлату ысуллары кулланыла:

1. *Тасвирлама*. Иң тулы аңлатма ысулы. Сүзнең мәгънәсен чынбарлыктагы объектны тасвирлап аңлатып бирү – *ыруг* төшенчәсен (гиперсема) кертү һәм дифференциаль үзенчәлекләрне (гипосема) ачу юлы белән аңлату. Аңлатмалы сүзлекләрдә сүзләрнең мәгънәсе һәм мәгънә төсмерләре күпчелек очракта кыскача аңлатма бирү юлы белән ачыклана. Мәсәлән:

**ҖАМАЯК** *и*. Төрле зурлыкта һәм тирәнлектә булган тоткасыз савыт. *Карчыкның кулыннан агач җамаягы төшеп китеп, ат аягы астына тәгәрәде.* М.Галәү. *Ахырда түзмәде Хәдичә апа, бер җамаяк җылы сөт күтәреп, чирәм үскән ишегалдына барып керде.* М.Маликова [2016-аңлат_ II:268].

Әлеге аңлатма ысулының бер төре – *сүз ясалыш аңлатма*, ул ясалма сүзләр өчен кулланыла. Мәсәлән:

**ӘЙЛӘНЕШ** *и*. 1) Берәр нәрсә тирәсендә яки йомык әйләнә буенча хәрәкәт. --- *алар [тәрәзә рамнары], кояш әйләнеше буенча, һәр сәгатьтә остаханәне тигез яктыртып тора иде.* Р.Мирхәйдәров. *Самолёт шәһәр өстеннән бер әйләнеш ясап алды.* Г.Аху-

нов. *Бал кортлары тәбрик әйләнеше ясады.* Г.Хәсәнов... [2015-Т_аңлат_ I:315].

2. Кыска сүзлекләрдә җыйнаграк аңлату ысулын кулланалар, мәсәлән, *синонимик ысулны*, ягъни синонимнар сайлап алу ярдәмендә: («яхшы →(хороший) → хуш; әйбәт; һәйбәт; шәп; ару; ярыйсы» [1999-Т_синон: 124]). Мондый аңлатмалар бигрәк тә нинди дә булса берәр стилистик төсмере булган (диалекталь, искергән һ.б.) сүзнең яки алынма сүзләрнең мәгънәсен ачу өчен кулланыла. Мәсәлән, «**ӘШТЕР-ӨШТЕР** *рәв. сөйл.* Ашыгып, аннан-моннан, өстән-өстән генә...» [2015-аңлат_I: 15].

3. Сүзнең мәгънәсе урынына башка сүзлек сүзенә, ягъни аның аерым мәгънәсенә (гадәттә, ниндидер билге ярдәмендә) сылтама бирелергә мөмкин. Бу *сылтамалы ысул*. Мәгънәләрнең мотивлаштыручы һәм мотивлашкан бәйләнешләрен саклаган сүзнең билгеле бер категориягә караганлыгын күрсәтеп торган дефиниция. Әлеге ысул сүзләр лексик мәгънәләре белән аерылмаганда кулланыла, мәсәлән, «**АРАЛАНУ** ф. 1) *төш.юн.* к. аралау...» [2005-Т_аңлат:44].

Сүзлекнең уң як өлешен тәшкил иткән компонентлар: лексикографик тамгалар һәм иллюстрацияләр.

Лексикографик мәгълүматның күп төрләре *тамга (билге, помета)* рәвешендә бирелә. *Тамга* – сүзлектәге берәмлекләре турында мәгълүматларны киңәйтү һәм тирәнәйтү өчен, кыскартылган аңлатмаларның билгеле системасын кулланган лексикографик ысул. Берничә төр лексикографик тамгалар аерыла:

Сүз төркеменә, грамматик формага, төрләнеш үзенчәлекләренә һ.б. *грамматик тамга*. Мәсәлән:

**КӨЯЗ** *сф.* **1.** 1) ... **2.** ис. мәгъ. Купшы киенгән кеше. Көяз туңмас, *калтырар.* Әйтем. **3.** *рәв. мәгъ.* Купшы итеп. *К. киенгән егет...* [2005-Т_аңлат: 325].

2. Сүз мәгънәсе үзенчәлегенә күрсәткән *семантик тамга*. Мәсәлән, «**АЛТЫН** *и.* ... 5) күч. Алтын төсле, ялтырап торган ачык сары төстәге; алтынсыман...» [2015-аңлат_I: 152].

3. Сүзнең стилистик төсмерләренә *стилистик тамга* (мәсәлән, *сөйл.* – сөйләм телендә, *кит.* – китап телендә, *гади с.* – гади сөйләм):

**мәрсия** *сущ. книжн. лит.* элегия (стихотворение, посвящённое чьей-л. памяти) [2007-ТР: 31].

4. Сүзнең экспрессив-эмоциональ төсмерен күрсәткән *экспрессив тамга* (әйтик, *ирон*. – ироник мәгънәдә, *шаярт*. – шаярту сүзе, *ирк*. – иркәләү сүзе һ.б.) Мәсәлән:

**ЕГЕТЛӘН│Ү** (-ә) *фг. ирон.* 1) Егетләргә (1 мәгъ.) охшарга тырышу, егетләрчә кылану (яшүсмерләр турында). Аларның уллары егетләнә башлады; ... [2013-Т_аңлат: 99].

*Тарихи тамгалар* куллану динамикасына яки сүзне куллануның тарихи перспективасына күрсәтәләр (мәсәлән, «искер.» яки «яңа»). Мисал итеп, этимологик сүзлек мәкаләсен китерергә мөмкин:

**АГЛА-У** иск. «плакать» ~ бор. төрки (ДТС: 21) *aγïla*- id.; *aγï* – елау тавышы, к. **Ыгы-зыгы.** К. **Ела-у.** [2015-Т_этим: 74].

*Функциональ тамгалар* сүзнең куллану өлкәсен күрсәтәләр. Гадәттә, кулланышы территориаль яктан чикләнгән яки һөнәри сүзләр өчен. Мәсәлән,

**Барәкәаллаһ** بارك الله *гыйб.* 1) *дини* Алла мөбарәк кылсын. 2) Бик шәп, яхшы, егет! *Һай, барәкәаллаһ, бик яхшы булган.* (К. Нас.) [2018-ГРТ_алынм: 74].

Баш сүзнең сүзьсалыш мөмкинлекләренә күрсәтмәләр сүзнең мәгълүмәти мөмкинлекләрен киңәйтә. Баш сүз белән сүзьсалыш бәйләнештә булган тамырдаш лексемлар төркеме бирелгән сүзлек мәкаләсенең өлеше *сүзьсалыш оясы* дип атала. Оялар баш сүзнең деривацион мөмкинлекләрен күрсәтә, гадәттә, бу аспект сүзьсалыш сүзлекләрдәге тикшеренүләр объекты була. Мәсәлән, Сабитова И. И. Татар теленең сүзьясалыш сүзлеге: «кеше» тематик төркеменә караган лексика:

11. **КЕНДЕК** *и. анат.*

кендек-**ле** *с.*

кендек-**сез** *с.*

кендек әби+**с**-*е и.*

кендек ба*в*-ы *и. анат.* [у//в] [2015-Т_сүзъяс: 56].

Сүзлеккә *этимологик белешмәләр* баш берәмлекнең тарихи чыганакларын: тышкы формаль яктан һәм семантик килеп чыгышын ачыклар өчен кертелә. Мәсәлән, Р.Г. Әхмәтьяновның ике томлык «Татар теленең этимологик сүзлеге» [2015-Т_этим]. Сүзлектә барлыгы 10300 чамасы сүзнең килеп чыгышы аңлатылган. Теркәлгән сүзләрнең зур күпчелеген төрки тамырлы берәмлекләр һәм татар теленең диалекталь лексикасы тәшкил итә.

Лексикографик иллюстрацияләрнең кирәклеге күпсанлы сүзлек әсәрләре ярдәмендә күп тапкыр дәлилләнә. Иллюстратив мисаллар (сүзтезмәләр, җөмләләр һ.б.) тексттан өзек буларак баш берәмлекне контекста күрсәтәләр, һәм төп ике функцияне үтиләр: 1) баш сүзнең мәгънәсен ачыклыйлар, аерылар; 2) тел берәмлеге семантизациясен тулыландырган, иллюстрацион дәллиләр китерәләр. Гадәттә, лексикографик иллюстрацияләр өчен кыскалык һәм төгәллек таләпләре куела.

Сүзлектәге *иллюстрацияләр* – сүзне контекстта, сөйләмдә кулланылышын күрсәтү. Иллюстрация өчен китерелгән миссаллар, күбесенчә, татар телендә басылган матур әдәбияттан, иҗтимагый-сәяси, публицисик, фәнни популяр, фольклор әсәрләреннән, дәреслекләрдән һәм вакытлы матбугаттан алына.

*Иллюстрация* төрләре:

Гыйбәрәләр, әлеге сүзтезмә өчен типик сүзтезмәләр. Мәсәлән, «**АК** I сф. **1.** 1) Кар, сөт, акбур төсе; *киресе* кара. *Ак кәгазь. Ак кар. Ак яулык. Ак чәчәк*; ... » [2005-Т_аңлат: 28].

Ясалма контекст, автор тарафыннан уйлап табылган тезмәләр. «АБАЙСЫЗ рәв. Сөйл. Саксызлык, гәмьсезлек күрсәтеп, хафасыз: таркау. Абайсыз бәреп төшерү» [2015-Т_аңлат_I: 22].

Цитаталар (гадәттә, нәфис әдәбияттан). Мәсәлән:

**БЕР ДӘ КИЛМӘГӘН ҖИРЕ ЮК** Бик чибәр, сылу, буесыны, бар җире дә килешле дигәннән. Хатын-кызлар чибәрлеге хакында. Йөзе-бите, буе-сыны дисеңме, бер генә дә килмәгән җире юк иде аның. Ә. Еники [1989-Т_фраз:161].

Мәкальләр һәм әйтемнәр. Мәсәлән:

**ВЫРЫХ** [рус. ворох] *тмн.*, *лмб.*, *кузн.* җилгәрмәгән ашлык өеме (ворох зерна). Вата нинди вырыхлар выргыттык. – *лмб.* Ындырдан вырыхлар чыгаралар. – *кузн.* Кеше вырыхын себерә, үзенекен йел алмый (мәкаль). – *тмн.* [2009-Т_диал: 150].

Лексикография терминологиясенең әһәмияте лексикография тарихын, төрле сүзлекләрнең барлыкка килү сәбәпләрен, аларның классификациясен, сүзлек структурасын һәм сүзлек мәкаләсен аңлау өчен кирәк.

## § 4. Татар теле сүзлекләренең типологиясе һәм структурасы

Хәзерге сүзлек эшчәнлеге лексикографиянең теоретик һәм гамәли тәҗрибәсен төрле яклап аңлауга, кулланылышта йөргән лексикографик чыганакларны системалы рәвештә анализлауга, һәм шуның нигезендә сүзлекләрне камилләштерү өчен тәкъдимнәр, алардагы кимчелекләрне бетерү һәм төзәтү ысулларын һәм юлларын эшләүгә шактый кискен ихтыяҗ кичерә.

Әлеге процесста сүзлекләрнең типологиясе мөһим урынны алып тора. Хәзерге лексикография үсешендә сүзлек типологияләренең киңәюенә һәм дифференциациясенә китерә торган тенденция күзгә ташлана.

Сүзлекләрнең типологиясе – аларның төрле билгеләренә нигезләнгән лексикографик чыганакларның классификациясе. Тел белешмәлекләренең типологиясенә багышланган хезмәтләрдә күпсанлы төркемләү тәкъдим ителгән (Апажев, 1971; Денисов, 1977; Дубичинский, 2009; Козырев, 2004; Цывин, 1978; Шимчук, 2003, 2009; Щерба, 1974 һ.б.). Алар барысы да төрле дифференциаль билгеләр нигезендә төзелгәннәр. Аларның кайберләренә тукталып китик.

Рус лексикографиясендә типология мәсьәләсенә беренчеләрдән булып Л.В. Щерба туктала һәм алты капма-каршылыкка нигезләнгән классификация тәкъдим итә: 1) академик – белешмәлек, 2) энциклопедик – гомуми, 3) thesaurus – гадәти, 4) гадәти – идеологик, 5) аңлатмалы – тәрҗемәи, 6) тарихи булмаган – тарихи (Щерба 1974).

1978 елда А.М. Цывин сигез классификация схемасыннан торган, сүзлекләрнең универсаль, тирәнтен һәм алга таба киң җәелеш табарлык классификация системасын төзергә омтыла.

1) Сүзлекләрнең уң һәм сул як тәңгәллеге. Сүзлекләр берьяклы (орфоэпик, орфографик һ.б.), шулай ук икеяклы (тәрҗемәи һәм тәрҗемәи булмаган) була.

2) Баш берәмлекләрнең урнашу ысулы. Алфавит рәвешендә төзелгән һәм алфавит тәртибендә булмаган (тематик) сүзлекләр аерылып чыгарыла.

3) Баш берәмлекләрнең составы. Лексикон (ул үз эчендә глоссарий һәм морфемарийга бүленә) һәм фразарий капма-каршы куела.

4) Баш берәмлекләрнең сайлап алыну үзенчәлеге. Тезауруслар һәм атезауруслар капма-каршы куела.

5) Тасвирлана торган объект. Гомуми һәм хосусый сүзлекләр аерылып чыгарыла.

6) Тарихи вакыйгаларның чагылышы. Синхрон һәм диахрон сүзлекләрне атарга мөмкин.

7) Максат һәм бурыч. Уку-укыту сүзлекләре һәм сүзлек-белешмәлекләр капма-каршы куеп карала.

8) Баш берәмлекләрнең ялгызлык исемнәренә яисә күмәк исемнәренә каравы (Цывин, 1978).

А.М. Цывин кебек үк В.М. Лейчик та терминологик сүзлекләрнең классификациясен аермалы билгеләренә таянып тәкъдим итә: 1) тематик яктан яктырту (күптармаклы, тармаклы, тартармаклы); 2) сул һәм уң өлешләренең эчтәлеге; 3) лексиканы тәртипкә китерү ысулы; 4) сүзлекнең максаты (функциясе) һәм бурычы; 5) телләрнең бирелеше; 6) яңалык (Лейчик ,1988: 41).

В.В. Морковкин сүзлекнең адресациясенә һәм андагы тел материалын тикшерү ысулына юнәлдерелгән таксономик үзенчәлеккә ия булган сүзлек төрен аерып чыгара. «Сүзлекләрнең тәкъдим ителгән стимул бирә торган типологиясе үзара «нәрсә», «ничек» һәм «кем өчен» принцибы буенча төзелгән өч классификацияне берләштерүне күз алдында тота» (Морковкин, 1988: 130–132).

В.В. Дубичинский, кулланылышта булган төремләүләрне берләштереп, сүзлекләрнең күпланлы (күпмаксатлы) һәм күптөрлелеген истә тотып, гомумиләштерелгән типология тәкъдим итә. Ул түбәндәге сыйфатларга нигезләнгән: 1) тасвирлана торган берәмлекләрнең күләме, 2) бөтен лексиканы бергә туплау, 3) күләм, 4) мәгълүматны тиешле тәртипкә китерү һәм детальләштерү, 5) функциональ юнәлеш, 6) лексик материалны тәкъдим итү тәртибе, 7) мәдәнурологик караш, 8) комплекслы сүзлекләр, 9) уку-укыту сүзлекләре (Дубичинский, 2009: 69–71).

Икетелле лексикографиядә В.П. Берков сүзлекләрнең түбәндәге үзенчәлекләрен аерып чыгара, һәм, әлеге билгеләренә бәйле, тел белешмәлекләренең төрләрен санап китә:1) күләм (кыска, уртача, зур); 2) гомуми (гомумтел, махсус булмаган) һәм махсус (билгеле бер тармакка караган, терминологик, фразеологик, канатлы гыйбарәләр сүзлеге һ.б.); 3) дифференциаль (диалектологик, тәрҗемә-

ченең ялган дуслары сүзлекләре һ.б.); 4) рәсемле (иллюстрацияле, визуаль) (Берков, 2004: 11-14).

«Сүзлекләрне тәртиткә салганда, еш кына бер-берсен инкяр итми торган күп төрле үзенчәлекләргә таянырга туры килә, шуңа күрә теге яки бу сүзлек бер үк вакытта төрле билгеләргә ия булырга мөмкин» (Шимчук, 2003: 36).

Татар телендәге тел сүзлекләрнең төрле нигезләмәләргә таянган типологиясен карап үтик.

- Тасвирлана торган материалның урнашу тәртибенә бәйле:

1) *алфавит* тәртибендә төзелгән сүзлекләр. Аларда баш сүзләр алфавит (формаль) тәртибендә урнаштырылган. Татар лексикографиясендәге күпчелек сүзлекләр нәкъ менә әлеге төргә, турыдан-туры алфавит тәртибендә төзелгән сүзлекләрнең төркемчәләренә карый. Соңгы хәрефне истә тотып баш сүзләр кире сүз тәртибендәге (инверсион) сүзлекләрдә [99-Т_кире_*Әхт.*; 06-Т_Җәлил_*Гал.*], шулай ук татар лексикографиясендә әлегә булмаган рифмалар сүзлегендә урын алган (Җәлил һәм Тукай компьютер фонды кысаларында М. Җәлил һәм Г. Тукай рифмаларының сүзлеген төзү эше алып барыла);

2) *тематик* (яисә идеографик сүзлекләр). Аларда баш сүзләр тематик якынлыкны исәпкә алып төркемнәргә туплана [1959-Т_мәк_темат_*Исән*_1; 1991-РТ_фраз_темат_уку_*Байр.*; 1994-АРТ_темат_фраз; 1994-РТ_загс_темат.; 1995-РТ_мәдән_темат.; 1999-РТ_соц/эш_уку_темат.; 2001-РТФ_алынм_темат_*Хаб.*; 2005-Т_диал_идеогр_1(1,2)] һ.б. Алар арасында һәм тематик (к., мәсәлән, [1989-РТ_темат_*Саф.*]) һәм төркем эчендәге берәмлекләр алфавит тәртибендә урнаштырыла торган тематик-алфавит сүзлекләр дә бар (к., мәсәлән, [98-РТ_сәүдә_темат.]);

3) *билгеле бер өяга тупланган.* Алар арасында алфавитлы-оя яисә оя формалаштыру элементлары белән алфавит тәртибендәгеләр бар [1997-РТ; 98-РТ_библ.; 1998-РТ_физ/тәрб.; 2007-ТР_тамыр һ.б.];

4) *ешлык буенча төзелгән.* Татар лексикографиясендә ешлык буенча төзелгән татар теле сүзлеге юк. Анализ ясала торган белешмәлекләр арасында тел берәмлекләренең ешлык күрсәткече, билгеле бер дәрәҗәдә, М.Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» теле сүзлегендә күзәтелә (к. [2006-Т_Җәлил_*Гал.*; 2006-Т_Җәлил]).

• **Тасвирлау берәмлекләренә (объектына) бәйле:**

1) *хәрефләр сүзлеге* (әлеге төргә әлифбалар керә);

2) *иҗекләр сүзлеге* (компьютер эшкәртмәләрендә файдаланыла);

3) *морфемалар сүзлеге* («Хәзерге татар әдәби теленең сүз ясагыч элементлар сүзлеге» [1984-ТР_сүзяс_*Гат.*]);

4) *сүзләр сүзлеге* (татар теленең күпчелек сүзлекләре әлеге төргә карый);

5) *сүзтезмә,* шул исәптән тотрыклы берәмлекләр (фразеологизмнар) сүзлеге; мәсәлән «Русча-татарча сүзтезмәләр сүзлеге» [1998-РТ_сүзтезм_*Агиш*_1; 2001-РТ_сүзтезм_уку_*Агиш*_1]; «Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре» [1957-Т_фраз_*Җәл.*], «Русча-татарча фразеологик сүзлек» [1959-РТ_фраз_*Бор.*], «В.И. Ленин сөйләмендәге русча-татарча фразеологик сүзлек» [1980-РТ_фраз_*Байр.*] һ.б.;

6) *җөмләләр, фразалар сүзлеге.* Аңа сөйләүлекләр, кыска күләмле тел белешмәлекләре, мәкаль һәм әйтемнәр сүзлеге керә (к., мәсәлән, [1959-Т_мәкаль_*Исән*_1]). Әлеге төр шулай ук лексик минимумнарда, «ЗАГС һәм ритуаль хезмәт күрсәтү хезмәткәрләре өчен русча-татарча кыска сүзлек» [1994-РТ_загс.], «Җәмәгать туклану оешмасы хезмәткәрләре өчен русча-татарча кыска сүзлек» [1995-РТ_җәм/тукл.], «Музыкаль оешмаларда эшләүче хезмәткәрләр өчен русча-татарча кыска сүзлек» [1997-РТ_музык.] һ.б. шундый кечкенә күләмле сүзлекләрдә фразалар сүзлеге рәвешендә чагылыш таба.

• **Лексикографик чыганакларда тәкъдим ителгән телләрнең саны белән бәйле:**

1) *бертелле;* XX гасырның икенче яртысы – XXI гасырның башында татар лексикографиясендә 47[1] сүзлек теркәлгән [2000-Т_фраз_*Исән.*; 01-Т_абстр_*Хаб.*; 2001-Т_фраз_*Исән.*; 2002-Т_орфогр.; 2002-Т_энц.; 2003-Т_орфогр_*Газ.*; 2003-Т_фәлсәф_*Ган.*; 2004-Т_орфогр.-орфоэп.; 2005-Т_антон_*Саф.* һ.б.];

2) *икетелле;* барлыгы 189 сүзлек; аларның күпчелеген түбәндәге тел белешмәлекләре алып тора:

[1] Монда һәм алга таба 1951–2008 елларда басылган сүзлекләр саны китерелә. Аларга күптомлы белешмәлекләрнең аерым томнары һәм кабаттан бастырылган хезмәтләрнең саны керми.

а) *русча-татарча* – барлыгы 137[2] сүзлек [1953-РТ_геогр_*Дус.*; 1953-РТ_тел бел; 1955-РТ_мәкт_*Газ*; 2000-РТ; 2000-РТ_биохим_*Якуп.*; 2000-РТ_хәрби; 2000-РТ_*Ган.*; 2000-РТ_техн.; 2000-РТ_физиол.; 2000-РТ_хим.; 2000-РТ_икът.,төзел_*Сафиул.*; 01-РТ һ.б.];

ә) *татарча-русча* – барлыгы 49 сүзлек [1998-ТР_тел бел_*Саф.*; 1999-ТР_син_*Хан.*; 1999-ТР_уку-укыту_*Хар.*; 1999-ТР_кесә_*Юнал.*; 2000-ТР_уку-укыту_*Ган.*; 2000-ТР_Р_дини; 2001-ТР_абстр_*Хаб*_а; 2001-ТР_абстр_*Хаб*_б; 2001-ТР_алынм., диал_*Минг.*; 2001-ТР_тарих.-этим_*Әхм.*; 2001-ТР_фраз_*Саф.*; 2001-ТР_тел бел_*Сал.* һ.б.]; моннан тыш, татарча-төрекчә [1997-ТТөр], төрекчә-татарча [1998-ТөрТ] һәм инглизчә-татарча сүзлекләр дә тәкъдим ителә [2007-ИТ];

3) *күптелле сүзлекләр;* аларда (татар һәм рус өлешләреннән тыш) инглиз, алман, гарәп, фарсы һ.б. телләрнең материалы китерелә. Андый сүзлекләр барлыгы 33 [1997-АБашРТ_*Гар.*; 1998-РБашТТурГарФарсВенг_*Гар.*; 1998-РТИ_иллюстр; 1999-АТР_уку_*Арс*; 1999-ЛатРТ_анатом.; 2000-АТР_информ.; 2001-РТФ_алынм_темат_*Хаб.*; 2001-РТФ_*Хаб.*; 2002-ТРЛат_үсем.; 2004-НРТ_сәнг_*Хәйр.*; 2006-АТР_информ_аңлат; 2006-РНТ_сынам_*Фат.*; 2006-ТАР_менедж_*Гар.*; 2006-ТАР_менедж_*Гар.*; 2007-АРТ_эшл.лекс.; 2007-НРТ_инвект_*Файз.*; 2008-РАНТөрТ_фраз һ.б.].

Күргәнебезчә, иң зур өлешне икетелле сүзлекләр алып тора. Аларны исә түбәндәгечә төркемләргә мөмкин:

- **Юнәлешенә бәйле:**

1) *бер юнәлештәге* (яисә моноскопик), аларга югарыда саналган икетелле сүзлекләр керә;

2) *ике юнәлештәге* (яисә бископик; лексикографик жаргонда «тегендә-монда» сүзлеге дип йөртелә); мәсәлән, бер басма рәвешендә нәшер ителгән татарча-русча, русча-татарча сүзлекләр. Соңгы елларда мондый төр сүзлекләрне бастыру киң таралды. Тикшерү объекты итеп алынган чорда татар лексикографиясендә 26 бископик сүзлек басылган [2001-РТ_ТР_*Хар.*; 2001-ТР_РТ_*Саф.*; 2002-РТ_ТР_уку_*Юнал*; 2003-ТР_РТ_антон_*Саф.*; 2004-РТ_ТР_ветерин.; 2007-ТР_РТ_*Саф.*; 2008-ТР_РТ_мәкт.; 2008-ТР_РТ_мәкт_*Саф*; 1972-РТ_ТР_физик.; 1996-РТ_ТР_биол_1 һ.б.].

---

[2] Шуларның 81е терминологик сүзлек. Терминологик сүзлекләр хакындагы тулырак мәгълүмат белән алга таба таныша аласыз.

- **Адресатларга юнәлтелгән булуына бәйле:**

1) *бер дирекциональле* (бер адрестка ия булган); мәсәлән, мәктәпләр өчен русча-татарча сүзлек, «сүзлек татар урта мәктәбе укучыларына, шулай ук рус телендә белем бирә торган оешмаларның татар төркемнәрендә белем алучылар өчен дә тәкъдим ителә» (аннотацияне к. [1989-РТ_мәкт_*Мах*]);

2) *ике дирекциональле* (ике адрестка ия булган); мәсәлән, «Русча-татарча тематик сүзлек», гадәттә, «рус һәм татар теленнән үз белемнәрен камилләштерергә теләүчеләр» өчен тәкъдим ителә (к. [1989-РТ_темат_*Саф.*]). Мондый төр сүзлекләрнең киң таралышы гамәли якка бәйле (белешмәлекне төзүгә чыгымнар чагыштырмача аз китә).

- **Максатына (юнәлешенә) бәйле:**

1) гомуми (русча-татарча [1955-РТ_1; 1971-РТ; 1997-РТ; 2001-РТ һ.б.], татарча-русча [1966-ТР; 04-ТР; 2007-ТР_1 һ.б.];

2) уку-укыту [1957-РТ_уку_5кл.; 1957-РТ_уку_6кл.; 1957-РТ_уку_7кл.; 1989-РТ_уку_*Мах.*; 1996-Т_орфогр_мәкт_*Нур.*; 1998-РТ_ТР_иллюстр_уку _*Саф.*; 1999-АТР_уку_*Арс.* һ.б.].

Уку-укыту сүзлекләре арасыннан түбәндәгеләрне билгеләргә мөмкин:

1) *актив* (продуктив, сөйләмне үстерү өчен);

2) *пассив* (рецептив, сөйләмне кабул итү өчен); телне өйрәтүчеләргә («Балалар өчен русча-татарча рәсемле сүзлек: (башлангыч сыйныф укытучылары һәм балалар бакчалары тәрбиячеләре өчен методик кулланма)» [1998-РТ_ТР_иллюстр_уку_*Саф.*]) һәм телне өйрәнүчеләргә. Әлеге тел белешмәлегенең бер төре итеп мәктәп сүзлекләрен билгеләп үтәргә була [1955-РТ_мәкт_*Газ.*; 1960-РТ_мәкт_5кл.; 1960-РТ_мәкт_6кл.; 1960-РТ_мәкт_7кл.; 1970-НРТ_мәкт_*Фаз.*; 1972-РТ_биол_мәкт.; 1989-РТ_мәкт_*Мах.* һ.б.].

Укыту әсбапларына мөнәсәбәте ягыннан:

1) *бәйле булмаган* сүзлекләр; татар теленең тикшерелә торган күпчелек тел белешмәлекләре әлеге төргә карый;

2) *бәйле булган* сүзлекләр; алар билгеле бер уку-укыту комплексы эченә урнаша. Татар лексикографиясендәге әлеге сүзлекләр рәтенә чираттагылар керә [1960-РТ_мәкт_5кл.; 1960-РТ_мәкт_6кл.; 1960-РТ_мәкт_7кл.; 1973-РТ_мәкт_6кл.; 1984-РТ_мәкт_4кл.; 1986-РТ_мәкт_6кл.; 2008-ТР_РТ_мәкт_*Саф*; 1998-ТР_мәкт_1,2кл_*Лит*_1].

• **Татар лексикографиясендәге берәмлекләрне сайлап алуга бәйле:**

1) *гомуми* сүзлекләр, ягъни лексиканың барлык төркемнәрен үз эченә алган сүзлекләр. Татар лексикографиясендәге әлеге төргә аңлатмалы [мәсәлән, 1977-1981-Т_аңлат_1-3; 2005-Т_аңлат һ.б.] һәм орфографик [2005-Т_орфогр. һ.б.] сүзлекләрне кертергә мөмкин.

2) *аерым бер төркем берәмлекләрен тасвирлаган* сүзлекләр; алар татар теле составындагы гомуми уртак билгеләргә ия булган билгеле бер төркем берәмлекләрен сурәтлиләр. Тасвирлана торган берәмлекләр түбәндәгеләрне берләштерә ала:

а) кулланылыш өлкәсе һәм үзенчәлеге, статусы

– ***терминологик сүзлекләр*** [2004-РТ_нефтепром.; 2008-РТ_охр.тр,с/х.; 2008-РТ_агроэкол. һ.б.],

– ***эшлекле лексика сүзлеге*** [2001-РТ_эшл.лекс_*Тимер.*; 2007-АРТ_эшл.лекс.],

– ***инвектив лексика сүзлекләре*** [2007-НРТ_инвект_*Файз.*; 2007-ТР_инвек_Файз.],

– ***ономастик сүзлекләр*** [1981-Т_антропон_*Сат.*, 1984-Т_гидр_*Гар*_1; 1992-Т_микротоп_*Гар*_1; 1998-ТР_антропон_*Сат.*; 1998-РТ_топон. һ.б.];

ә) барлыкка килүе

– ***алынмалар сүзлеге*** [1965-ТР_алынм_Хам.; 1993-ТР_алынм_*Мәх*_1; 1994-ГФТ_алынм_Зәйн.; 2001-ТР_алынм, диал_*Минг.*; 2001-РТФ_алынм_темат_*Хаб.*; 2003-ТР_алынм, диал_*Минг.*; 2006-Т_ТР_алынм_*Саф.*; 2006-РТ_алынм_Хус.],

– т***амырдаш сүзләр сүзлеге*** [2007-ТР_тамырд.];

б) чыганак

– ***аерым әсәр яисә әсәрләр җыентыгы сүзлеге*** [2006-Т_Җәлил_*Гал.*; 2006-Т_Җәлил],

– ***автор сүзлеге***; мәсәлән, Г.Тукайның шигърият теле сүзлеге [ТС 2009; ТС 2010];

в) тарихи яссылыкта

– ***искергән лексика сүзлеге*** [2003-ТР_алынм, диал_*Минг.],*

– **неологизмнар сүзлеге** [2014-РТ_лекс.]*;*

г) берәмлекләр системасы эчендә билгеле бер мөнәсәбәткә бәйле;

– ***синонимнар сүзлеге*** [1962-Т_син_аңлат_*Хан.*; 1999-ТР_син_*Хан.*],

– ***антонимнар сүзлеге*** [1997-ТР_антон_*Саф.*; 2003-ТР_РТ_антон_*Саф.*; 2005-Т_антон_*Саф.*],

– ***омонимнар сүзлеге*** [1997-ТР_омон_мәк_*Саф.*; 2004-ТР_омон_аңлат_*Хак.*].

- **Тәкъдим ителгән билгеләренә бәйле:**

1) *күп аспектлы* (комплекслы) сүзлекләр; алар баш берәмлекләрне төрле яклап тасвирлыйлар. Әлеге төргә иң беренче чиратта аңлатмалы сүзлек туры килә, к., аерым алганда, татар теленең аңлатмалы сүзлеге [2005-Т_аңлат], чөнки анда баш берәмлеккә караган иң күп тасвирлама тәкъдим ителгән.

2) *аспектлы* сүзлекләр; аларның бурычы – тел берәмлегенең теге яки бу үзенчәлеген характерлау, бәян итү. Татар лексикографиясендә әлеге төргә түбәндәгеләр керә:

***грамматик сүзлекләр*** [2004-Т_грам],

***орфографик сүзлек*** [1983-Т_орфогр.; 1996-Т_орфогр_мәк_*Нур.*; 02-Т_орфогр.; 2003-Т_орфогр_*Газ.*; 2005-Т_орфогр],

***орфоэпик сүзлек*** [1995-Т_орфоэп_*Сал.*; 2004-Т_орфогр.-орфоэп.],

*этимологик сүзлекләр* [2001-ТР_тарих.-этим_*Әхм.*; 2005-Т_этим_*Әхм*_1].

Сүзлекләрнең кайбер төрләре татар телендә әлегә юк.

- **Күләменә бәйле** татар лексикографиясендә гадәти зур, уртача һәм кечкенә тел белешмәлекләрен санарга мөмкин. Билгеле булганча, әлеге бүленеш шартлы.

*Зур күләмле* сүзлекләргә татар лексикографиясендәге 1) бер телле сүзлекләрне – [2005-Т_аңлат; 1977-1981_Т_аңлат]; 2) ике-телле сүзлекләрне – [1955-РТ_1; 1966-ТР; 1971-РТ; 1997-РТ; 2001-РТ; 04-ТР; 07-ТР_1] кертергә була.

*Уртача күләмлеләр* – [1953-Т_диал_2; 1955-РТ_мәкт_*Газ.*; 1957-Т_фраз_*Җәл.*; 1959-Т_мәк_*Исән*_1; 1965-ТР_алынм_*Хам.* һ.б.];

*Кечкенә күләмлеләр* – [1993-РТ_тарих; 1995-РТ_мәдән.; 1995-РТ_җәм/тукл.; 1995-РТ_а/хуж.; 1995-РТ_сәүдә; 1995-РТ_ижт/сәяси; 1995-РТ_музык.; 1997-РТ_бел/бирү; 1997-РТ_таб/сакл.; 1997-ТР_мәд_мәк_*Хар.*; 1998-РТ_сәүдә; 1998-РТ_медиц_*Мин.*; 1999-РТ_бизнес.; 1999-РТ_соц/эш_уку. һ.б.].

• **Сүзлек составының тулылыгына бәйле:**

1) *тулы* сүзлекләр; алар барлык тел берәмлекләрен (тезауруслар) үз эченә ала. Билгеле булганча, җанлы сөйләм өчен тезаурус-сүзлек төзү мөмкин түгел диярлек, ләкин лексикография тарихында андый омтылышлар булганлыгы мәгълүм (к., мәсәлән, В.И. Даль тарафыннан төзелгән «Толковый словарь живого великорусского языка»).

2) *дифференциаль* сүзлекләр (атезауруслар). Бирегә диалектологик сүзлекләрне [1953-Т_диал_2; 1969-ТР_диал.; 2005-Т_диал_идеогр_1(1) һ.б.] кертергә мөмкин.

• **Тел берәмлекләрен тасвирлау характерына бәйле:**

1) *күрсәтмәле* сүзлекләр, аларда мәгълүмат гади генә тел берәмлекләренә таянып яисә үрнәк мисаллар ярдәмендә хәбәр ителә. Әлеге төргә орфографик (к. югарыда), антоним [1997-ТР_антон_*Саф.*; 2003-ТР_РТ_антон_*Саф.*; 2005-Т_антон_*Саф.*], синоним [1962-Т_син_аңлат_Хан.] һ.б. сүзлекләр керә;

2) *аңлата торган* аңлатмалы сүзлекләр, аларда мәгълүмат аңлатмалар, аныклагычлар ярдәмендә җиткерелә. Аларга мисал итеп аңлатмалы [1977-Т_аңлат_1; 2005-Т_аңлат һ.б.] һәм диалектологик [1953-Т_диал_2 һ.б.] сүзлекләрне санарга мөмкин.

• **Визуаль элементларның булуы яисә булмавына бәйле:**

1) *рәсемле* (яисә картиналы) сүзлекләр; алар төрле иллюстратив материалны (рәсемнәрне, фотографияләрне һ.б.) үз эченә ала [1998-РТА_иллюстр_*Асад.*; 1998-РТ_ТР_иллюстр_уку_*Саф.*];

2) *рәсемсез* сүзлекләр, аларда рәсемнәр булмый. Күпчелек татарча тел белешмәлекләре нәкъ менә әлеге төргә карый.

• **Вакыт билгеләренә бәйле:**

1) *диахроник* (тарихи). Хәзерге татар лексикографиясендә туры мәгънәсендә әлеге төр юк.

2) *синхроник* (хәзерге заманга караган). Хәзерге татар теленең күпчелек сүзлекләре әлеге төргә туры килә.

• **Мәгълүматның нинди форматта бирелүенә бәйле:**

1) *кәгазь* (традицион);

2) *электрон* (CD-вариантлары, Интернет-вариантлары һ.б.). Әлеге төргә 2008-2009 елларда төзелгән русча-татарча, татарча-русча компьютер сүзлекне, үз эченә 150 000 (75000 – русча-татарча сүзлек җирлегендә, 75000 – татарча-русча сүзлек нигезендә) баш сүзне туплаган «КАМУС» исеме астындагы универсаль сүзлекне,

Казан университеты порталындагы «Казан лексикографик фонд» (http://www.klf.kpfu.ru) бүлегенә эленгән М.Җәлил һәм Г.Тукай әсәрләре сүзлекләренең интернет-вариантларын, моннан тыш Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе порталында урнашкан «Сүзлекләрнең электрон фонды» (http://www.suzlek.antat.ru) составындагы татар теле сүзлекләренең электрон версияләрен кертергә мөмкин.

- **Яшәеш формасы, ысулы белән бәйле:**

1) *автоном* (аерым китап итеп басылганнар);

2) *кушымта* (нинди дә булса басма хезмәтнең бер өлеше булып тора).

Шулай итеп, типологик һәм структур яктан караганда, татар теле сүзлекләренең төрле булулары күренә.

## § 5. Сүзлек төзү этаплары һәм принциплары

Һәр сүзлек үз концепциясенә ия, икенче төрле әйткәндә, аның максаты, күләме, шәрехнамәләренең төзелеше һәм гомумтеоретик принциплары билгеләнгән була.

Тел берәмлекләренең сүзлектәге бирелеш принциплары фәнни-аналитик гамәлләрнең таләпләреннән чыгып билгеләнә. Барлык төр сүзлекләр өчен уртак булган түбәндәге лексикографик принципларны аерып чыгарырга мөмкин:

1. Лексикографик хезмәтләрнең дәвамлылыгы. Яңа сүзлекләр, белешмәлекләр булдырганда, телдә яшәп килгән лексикографик традицияләргә таянып эш итәләр. Алдан төзелгән сүзлекләр яңа хезмәтнең чыганагы ролен башкаралар, алардагы күпчелек берәмлекләр яңа лөгатьнең нигезен тәшкил итәләр, тел материалы тагын да баетылып, өстәлеп, тәгаенләп бирелергә мөмкин.

2. Сүзлек төзегәндә, субъектив факторлар йогынтысын исәптә тоту. Лексикографиядә индивидуаль-стилистик күрсәткечне исәпкә алмау мөмкин түгел: һәр сүзлекче, сүзлек төзү дәвамында, үзенең шәхси белем-тәҗрибәсеннән чыгып эшли. Лексикограф, бер яктан, сүзлек авторы булса, икенче яктан, ул телне уртача белүче, шул телдә сөйләшүче кеше буларак кабул ителә. Димәк, лексикографик хезмәттә субъектив белемнәр белән объектив күзаллау берлектә килә. Сүзлектә авторның үз карашлары, аерым төшенчә, лексик берәмлекне үзенчә аңлавы чагылмый калмый. Гадәттә,

сүзлек коллектив хезмәт булганлыктан, аның аерым өлешләрендә материалны тәкъдим итү ягыннан бераз аерымлыклар күзәтелүе дә ихтимал. Мәсәлән, күпмәгънәле лексик берәмлекләрне теркәгәндә, сүзлекче аерым тарихи үсеш дәвамында барлыкка килгән семаларны хронологик тәртиптә, яисә гомумкулланышта булган лексик-семантик вариантларны күрсәтеп, соңыннан сирәк кулланылган мәгънәләрне бирү юлын үзе хәл итә. Димәк, сүзлекнең сыйфаты аны төзүче галимнең һөнәри компетенциясенә һәм телне тоемлавына турыдан-туры бәйле була.

3. Аерым бер аудиториягә юнәлдерелү. Һәр сүзлеккә үзенең укучысына кайсы яктан файдалы булуы ягыннан бәя бирелә. Әлеге төр фәнни хезмәт «иҗтимагый заказ» буларак кабул ителә, ягъни ул «сатып алучы, заказчының» нинди дә булса ихтыяҗларына җавап бирергә тиеш. Мәсәлән, түбәндәгене ихтыяҗларны аерып чыгарырга мөмкин:

а) сүзне беренче тапкыр очратканда, аның мәгънәсен белергә омтылу. Мәсәлән, аерым контекстта *алма* сүзен очратканда, әлеге лексеманың нинди төшенчә, предметны белдерүен төшенергә телибез;

ә) сүзнең нинди дә булса өлкәгә караганлыгын, аның нәрсә аңлатканшыгын белү теләге. *Алма* сүзе аерым конкрет предметны белдерүен ачыклап, аның алмагачының җимеше икәнлеген ачыклыйбыз;

б) аерым лексик берәмлекнең нәрсә аңлатуын белеп, әлеге предметның (күренешнең) ни рәвештә булуын күзаллау ихтыяҗы. Алмагач җимешенең нинди булуын күзаллыйбыз, образ тудырабыз;

в) сүзнең төп мәгънәсен белеп, аның турында тулырак мәгълүмат туплау. Сүзнең төп мәгънәсе ‘алмагач җимеше’, шулай ук әлеге лексеманың тагын берничә лексик-семантик варианты яшәп килә. Ул шулай ук ‘күзнең түгәрәк рәвешендәге урта өлеше, үзәге’ мәгънәсендә дә файдаланыла. Телнең үсеш дәвамында, сүз шулай ук ‘хайваннарның тиресендәге төп төс өслегендә ак яки кара, күгелҗем һ.б. түгәрәк тап барлыкка китергән йон төкләре’ семасын да аңлата башлый. Шулай ук сөйләм телендә ‘алмагач’ мәгънәсендә дә кулланыла. Контексттан чыгып, шулай ук ‘сөйгәнем, кадерле кешем’ мәгънәсендәге эндәшү сүзе буларак та кулланыла;

г) сүзне тагын нинди лексема белән алмаштырып булуын ачыклау. Контекстта *алма* сүзен *алмагач җимеше* синонимы белән алмаштырырга мөмкин;

д) сүзнең капма-каршы мәгънәсен белергә теләү;

е) сүзнең килеп чыгышы, этимологиясе белән кызыксыну. *Алма* лексемасы һинд-европа телләреннән *alma* 'әче' сүзеннән килеп чыккан дип карала;

ж) лексик берәмлекнең нинди тематик төркемгә керүен ачыклау. *Алма* сүзен җиләк-җимеш атамалары тематик төркеменә кертәбез;

ж) сүзне текста очратып, аның дөрес әйтелешен белү. *Алма* сүзенең басымы икенче иҗеккә төшә, беренче иҗектәге *а* олаштырылып әйтелә: [а$^{о}$ лма'];

з) сүзне әйткәндә, аның язылышта ничек бирелүен ачыклау. *Алма* сүзе ничек ишетелә, шулай языла;

и) лексеманың төрләнешен беләсе килү, аның грамматик үзенчәлекләрен тәгаенләү;

й) аерым төшенчәләр белдерә торган сүзне эзләп табу ихтыяҗлары һ.б.

4. Лексик байлыкның бирелеше һәм сайланып алынуында нормалылык. Сүзлек беренче чиратта әдәби тел норма һәм кагыйдәләренә нигезләнә (аерым төр хезмәтләрне, мәсәлән, диалекталь, жаргон, сленг һ.б. кулланылышы чикләнгән берәмлекләр сүзлекләрен исәпкә алмаганда). Сүзлек үзе тел кагыйдәләрен булдырмый, ул әлеге кагыйдәләргә таянып эш итә, ягъни теоретик белемнәрне гамәли яктан файдалана.

Шул ук вакытта түбәндәгене искәртеп китү урынлы. Әдәби телдә, халык үзаңында яшәп килә торган аерым реалийларны чагылдыра алырлык сүзләр булмаска да мөмкин, әлбәттә, әдәби тел берәмлекләреннән тыш, бу очракта кулланылышы чикләнгән лексемалар да (мәсәлән, диалектизмнар, этнографизмнар) да китерелергә мөмкин. Терминологик пландагы сүзлекләрдә күпчелек сүзләрнең кулланылышы чикләнгән.

5. Лексикографик хезмәтнең теоретик һәм гамәли күппланлылыгы. Телнең сүзлек составын фәнни анализлаганда, барыбер нинди дә булса аспектлар тиешенчә каралмый, нинди дә булса бер як игътибардан читтә калырга мөмкин. Әлбәттә, бөтен критерийларга, таләпләргә дә җавап бирерлек лексикографик хезмәт булмый, шулай да галимнәр универсаль сүзлеккә омтылалар.

Барлык төр сүзлекләр өчен уртак күренешләр, ягъни лексикографик универсалийләр бар. Аларга түбәндәгеләрне кертеп була: 1) сүзлекчә, лөгатьлек (сүзлекнең сул як өлеше); 2) баш сүз (вокабула, лемма); 3) аңлатма, дефиниция, тәрҗемә эквиваленты (сүзлекнең уң як өлеше); 4) сүзлектә бирелгән тел материалының системалы рәвештә булуы; 5) нормалылыгы / тел берәмлекләренең, аерым чикләнгән лексик катламның бирелеше; 6) сүзлек материалының билгеләнгән тәртиптә (алфавит тәртибе, кире тәртип, идеографик бирелеш) тәкъдим ителүе һ.б.

Сүзлек төзүнең түбәндәге этапларын бүлеп чыгарырга мөмкин.

Беренче этапта лексикография фәненең үткәне, хәзерге торышы белән танышу сорала. Бу үз чиратында инде дөнья күргән сүзлекләргә анализ бирү, теоретик чыганаклар белән эш итү, сүзлек юнәлдерелгән адресатның ихтыяҗларын ачыклау һ.б.ны күздә тота. Әлеге мәгълүматлардан чыгып, төзүче яңа сүзлеккә куела торган таләпләрне булдыра: сүзлекнең макроструктурасы һәм микроструктурасының макетын оештыра. Шулай ук лексикограф кайсы чыганаклардан файдалануны билгеләргә тиеш. Әлеге чыганакларга язма яисә сөйләмә текстларны, төрле белешмәлек-ярдәмлекләр, алда нәшер ителгән сүзлекләрне кертеп карарга мөмкин.

Икенче этапта лөгатьлек, сүзлекчә төзелә. Сүзлекнең лөгатьлеген төзү, сүзләр сайлау – аеруча әһәмиятле мәсьәлә. Телдә яшәп килгән барлык сүзләрне туплап, җыеп бирү мөмкин эш түгел. Лөгатьлеккә, гадәттә, гомумкулланылышта булган актуаль сүзләр (сүзтезмәләр, сүзформалар һ.б.) алына, күп очракта филологик сүзлекләрдә әлеге берәмлекләр алфавит тәртибендә китерелә. Шушы этапта берәмлекләр сайлаганда, полисемия белән омонимия арасындагы чикләр, лексиклашкан формаларның мөстәкыйль сүз булып китүләре, сүзнең нинди формада бирелеше һ.б. мәсьәләләр хәл ителә.

Бер генә сүзлек төзү эше эмпирик базасыз булмый, шунлыктан бу этапта беренчел картотека төзелә. Сүзлекнең лексикографик тәгъбирендә алда чыккан сүзлекләр, картотекалар чагылыш таба. Әйбәт һәм җентекләп тупланган картотека, әлбәттә, лексиконда китерелә торган иллюстрация мисалларының сыйфатын арттыра һәм сүзлек мәкаләсен баета.

Чираттагы этапта сүзлекнең проекты, аның белән эшләү рәвеше билгеләнә. Бу этапта сүзлек нинди тәртиптә бирелү күрсәтелә.

Материалның урнаштыру тәртибен ачыклау – бик мөһим мәсьәлә. Күп очракта филологик сүзлекләрдә алфавит тәртибе кулланыла, алга таба материал белән эшләүнең иң кулай һәм уңайлы варианты буларак санала. Кайбер вакытта сүзләр ояларга бүлеп бирелә (гнездование), ягъни аерым үзара бәйләнгән (тамырдаш, мәгънәдәш) сүзләрне бергә берләштерү рәвешендә була. Аеруча этимологик һәм сүзьясалышы сүзлекләре өчен мондый структура уңайлы. Мәсәлән, «Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге»ннән бер мисал китерик:

**ЕЛГА** (-га; -дан; -сы) *ис.* Башыннан алып койган җиренә кадәр үзе салган үзәнлек ярлары арасында ага торган, шактый зурлыктагы табигый су агымы. *Елга аша күпер салу* [] **Елга каракошы** Карчыга кошлар семьялыгыннан, чөйсыман кыска ак койрыклы, күбесенчә балык, куян ише вак җан ияләре белән туклана торган күчмә кош. **Елга күбәләкләре** *зоол.* Төкле канатлылар семьялыгыннан, тышкы кыяфәте белән көя күбәләкләренә охшаган, суда үрчеп, корыда яши торган бөҗәк; *русчасы*: **ручейник**. **Елга үләне** *бот.* Су кәбестәчәләре семьялыгыннан, вак чәчәкле, озын сабаклы, яфраклары өлешчә су астында, өлешчә су өстендә булган су үсемлеге; *русчасы*: **рдест** [2013-Т_аңлат: 100].

Кире, идеографик сүзлекләрдә махсус тәртип – систематика принцибы нигезендә урнаштыру каралган, ягъни лексик берәмлекләр ярдәмендә белдерелгән төшенчәләр логик эзлеклелектә классификацияләнә. «Материалы к идеографическому словарю диалектов татарского языка» сүзлеген мисал буларак биреп була [2005-Т_идеогр]. Биредә китерелгән материал тематик төркемнәргә аерылып бирелә, тематик төркем эчендә ваграк семантик төркемчә китерелә, әлеге төркемчә эчендә генә алфавит тәртибе саклана.

Соңыннан сүзлекне төзү һәм редакцияләү этабы килә. Сүзлек төзүгә керешкәндә, лексикограф махсус мәсьәләләрне хәл итәргә тиеш: лексиконның форматы, күләме, сүзлек мәкаләсенең составы, тел берәмлеге хакында төрле мәгълүматның бирелеше (этимологик, энциклопедик, семантик, грамматик, сүзьясалышы, стилистик, иллюстратив һәм башка төр информация) һ.б.

Сүзлекнең кереш өлешендә аның концепциясе аңлатыла. Шул ук вакытта укучы, файдаланучы өчен сүзлек белән эшләү тәртибе яисә инструкция булуы мөмкин. Гадәттә, сүз башында әлеге лек-

сиконның үзенчәлекләре, составы, төзелешенең техник бизәлеше тәгаенләнә, сүзлек мәкаләләренең структурасы ачыклана.

Аерым төр сүзлекләр шулай ук төзүчеләр тарафыннан теоретик нигезләмәләр дә кертелә, кайбер очракта сүзлектә лингвистик терминнар сүзлекчәсе дә урын ала.

Шулай ук, гадәттә, икетелле (күптелле) сүзлекләрдә тәрҗемә ителә торган телнең фонетик һәм грамматик структурасының кагыйдәләре, яки әлеге телнең грамматик теориясенә кыскача күзәтү китерелергә мөмкин.

Күп кенә сүзлекләрдә кулланылган фәнни әдәбият исемлеге һәм иллюстратив мисалларның чыганагы аерым исемлек белән күрсәтелә.

Сүзлек мәкаләсе хезмәтнең структурасы нигезендә формалаштырыла, тулаем әлеге мәкаләләр җыелмасы сүзлекнең макроструктурасын тәшкил итә.

Сүзлек мәкаләсе сүзлекнең төп структур берәмлеге, баш сүз (вокабула) һәм аның аңлатмасыннан гыйбарәт. Иллюстрация буларак, төрле типтагы сүзлекләрдән үрнәк китерик:

**АЛМА** «яблоко» < гом. кыпч., уйг., угыз. һ.б. *алма//elma* > мар. *алма, олма,* чув. *алма, улма, улми,* удм. *улмо* ~ коми. *үлме,* венг. *alma* id. ~ бор. төрки *almïla* > монг. *альмына* > *альман* id. Бор. төрки яңгыраш бор. һинд-евр. (яки лат. гына) *abella* «алмагач; алма» сүзеннән килә (Pokorny I: 3), шуннан да фин. *omena* «алма». Федотов II: 278, ССТМЯ I: 33.

Алманың культуралы төрләрен һинд-европалылар үстерә башлаган булса кирәк.

Дерив.: **алмалы, алмасыз; алмалык, алмалаш-у** «алма кебек булу» [2015-Т_этим_I: 93].

**Ярмо** – кыса, камыт [1963-РТ_тех:214].

**сухожилие** *с* сеңер [1963-РТ: 603].

Аның һәрбер өлеше бер-берсенә бәйле һәм буйсынган була. Традицион сүзлекләрдә иң минималь структур берәмлеге лемма сүзлек мәкаләсенең исеме булып тора: әлеге сүзне аңлау өчен, сүзлек мәкаләсе белән тулысынча танышып чыгарга кирәк. Баш сүз, гадәттә, ноль формада китерелә (фигыльләр инфинитив яисә исем фигыль формасында бирелә). Аның турында фонетик мәгълүмат китерелергә мөмкин, гадәттә, басымы күрсәтелгән була, аерым очракларда транскрипция урын ала, электрон сүзлекләрдә та-

вышлы әйтелеше дә бирелә (аларда махсус аваз синтезаторы һәм әйтелеше кертелгән махсус программасы була).

Аннан соң грамматик мәгълүмат китерелә, сүзнең нинди сүз төркеме, сан, килеш белән төрләнеше, башка сүзләр белән ярашу үзенчәлекләре күрсәтелергә мөмкин. Сүзлек материалны җыйнак һәм анык формада булуны исәпкә алып, еш кына әлеге грамматик мәгълүмат шартлы кыскартылмалар ярдәмендә күрсәтелә. Әлеге шартлы кыскартылмаларның исемлеген һәм тәгъбирләрен махсус рәвештә булырга тиеш.

Һәрбер лексеманың функиональ-стилистик кулланылыш үзенчәлеген дә истән чыгарырга ярамый, шунлыктан грамматик күрсәткечләрдән соң тамгалар ярдәмендә стилистик билгеләр дә бирелә. Алар сүзнең нинди стильдә кулланылуын, аның стилистик төсмерен тәгаенлиләр.

Соңыннан сүзенең шәрехнамәсе урын ала. Ул аңлатма яисә тәрҗемә рәвешендә, тәрҗемә булганда шулай ук башлангыч форма китерелә. Кайбер сүзлекләрдә уң яктагы аңлатма булмаска да мөмкин, мәсәлән, ортологик сүзлекләрдә, күп очракта баш сүз һәм аның грамматик характеристикасы гына грамматик тамгалары белән бирелергә дә мөмкин. Синоним сүзлекләрендә – сул якта синонимик рәт, антонимнар сүзлегендә антонимик рәт китерелә. Ешлык сүзлекләрендә кулланылыш ешлыгы күрсәтелә. Берничә мисал тәкъдим ителә:

**компью'тер** *сущ. спец.* компьютер (*электронная вычислительная машина*); *~га кертелгән программа* программа, внесённая в компьютер; *судно белән идарә итү ~ы* компьютер, управляющий судном [2007-ТР_I: 603 ]

бәялә/ү, үе [2010-Т_орфог: 48].

**КӨЙМӘ** → (лодка, челн, шлюпка,ялик) → каек; кимә; кәмә [1999-Т_синон: 60].

**Балкып йөрү** – шатланып, шатлыгын йөзенә чыгарып йөрү. Ул бөтенләй **балкып йөри башлады**. Ф. Хөсни [ 1982-Т_фраз: 27].

Аңлатма өлештән соң, гадәттә, иллюстратив мисаллар бирелә. Һәр узуаль семага аерым мисал тәкъдим ителергә мөмкин. Иллюстрация рәвешендә җөмләләр, кайбер очракта берничә җөмлә, ирекле сүзтезмәләр урын ала, телара сүзлекләрдә эквивалент тәрҗемәләре китерелә. Сүзлектә шулай ук фразеологизмнар, тотрыклы сүзтезмәләр, идиомалар да күрсәтелергә мөмкин. Шулай

ук сүзлек мәкаләсе кысасында сүзнең синонимнары, антонимнары һ.б. бирелә ала, омонимнар, гадәттә, аерым мәкалә тәшкил итә. Оялап бирелгән материалда лексеманың тамырдаш сүзләре, дериватлары шул ук сүзлек мәкаләсе эчендә бирелә, аларның һәрберсенең үз шәрехләмәсе була. Гадәттә, сүзлекләрдә китерелгән мисаллар матур әдәбият, публицистика, фәнни-популяр чыганаклардан алына. Соңгы елларда интернет заманында тел корпусларына нигезләнеп туплана. Бүгенге көндә татар теленең өч корпусы эшләп килә. Корпуста сүз, аның формасы, конструкциясен тиз табып алу мөмкинлеге бар. Әлеге материаллар лексикографның хезмәтен берничә тапкыр җиңеләйтә.

Рәсемле сүзлекләрдә сүзлек мәкаләсе иллюстрация рәвешендә бирелгән рәсемнән, фотосурәттән, график схемадан башланып китәргә мөмкин. Ишарәләр сүзлегендә башта ишарәнең рәсеме, аннан соң аның аңлатмасы, әлеге ишарә вакытында катнашкан органнарның торышы билгеләнә.

Мәсәлән, бу төркемгә Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисованың «Рәсемле татарча-русча тематик сүзлеге»н кертергә мөмкин [2017-РТ_тем].

Алдагы этапта сүзлек өлешләре бергә тупланып, махсус форматка салына, сүзлек версткалана һәм китап бастырыла (яки электрон ресурска кертелә). Шул рәвешле, сүзлек үзенең адресатына тәкъдим ителә.

Сүзлек төзү эше әлеге этап белән генә төгәлләнми, алга таба яңа басмалар әзерләү өчен өстәмәләр кертү, төгәлсезлек һәм хаталарны төзәтү эше башлана.

Югарыдан күренгәнчә, сүзлек төзү күләмле материал белән эш итүне күздә тота, шунлыктан һәр этабы нииндидер дәрәҗәдә автоматлашкан булуны күзаллый һәм катлаулы максатлар хәл ителешен тәэмин итә. Сүзлек, – эш нәтиҗәсе буларак, югары әзерлекле белгечләр тарафыннан башкарыла торган, гадәттә, коллектив хезмәт. Аеруча әһәмиятлесе – сүзлек төзегәндә, баштан алып ахырына кадәр тулы эзлеклелек саклануы зарури, бердәй принципка нигезләнү мөһим. Шуны да искәртү кирәк: һәр этапка бәйле рәвештә махсус шартлар тудырылган (заманча технологияләрдән, элек басылып чыккан сүзлекләр, фәнни әдәбият белән эшләү мөмкинлеге, вакыт ягыннан чикләрнең киңлегә һ.б.) булырга тиеш.

# ТАТАР ЛЕКСИКОГРАФИЯСЕ ТАРИХЫ

## § 6. Башлангыч чор сүзлекләре

Билгеле булганча, төрки халыклар элек-электән сәүдә белән шөгыльләнгәннәр, төрле илләргә сәяхәт иткәннәр, яуга чыкканнар. Яңа илләр ачу, моңа кадәр билгеле булмаган яңа җирләр, анда яшәгән халыклар белән элемтә урнаштыру өчен, башка телләрне өйрәнү таләп ителгән. Тылмачлар – тәрҗемәчеләр арту белән беррәттән, сүзлекләр төзү эше дә алга китә. Тылмачлар телнең сөйләмә шәкелен үзләштерсә, сүзлекләр төзү турыдан-туры язма тел барлыкка килү һәм таралу, кулъязма китаплар язылу белән бәйле. Иң борынгы сүзлекләр тарихының башлангычын текст читендәге глоссалар – аңлашылмаган сүзләргә шәрехнамә-комментарийлар язылу белән бәйлиләр. Гло́сса (бор. грек. γλῶσσα «тел», «сөйләм») – китаптагы (тексттагы) аңлашылмаган сүзнең яки чит тел сүзенең өстенә, астына яки текст читенә язылган аңлатма, шәрех. Мондый глоссаларның иң борынгылары б.э.к. III меңьеллык уртасында Шумер дәүләтендә, б.э.к. III–II меңьеллыклар чигендә Кытайда, б.э.к. V–IV гасырларда борынгы Грециядә Гомер шигърияттен өйрәнгәндә язылган дип исәпләнелә (Языкознание. Большой энциклопедический словарь, 2000: 107).

Монотеистик диннәр барлыкка килгәннән соң, дин тарату максатыннан, миссионерлар дини китаплардагы аңлашылмаган сүзләргә глоссалар язганнар. Әлеге глоссалар соңрак аерым сүзлекчә рәвешен алган.

Төрки халыклар тарихында иң беренче сүзлек-белешмә булып Мәхмүд Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» хезмәте санала. Ул XI гасырда – 1072–1074 (кайбер мәгълүматлар буенча 1072–1083)

елларда төзелгән. Ике тел (төрки-гарәп телләре) сүзлеге буларак төзелсә дә, аны гади сүзлек дип кенә атап булмый хезмәтнең энциклопедик сыйфатта булуын барлык белгечләр дә раслый (Махмуд ал-Кашгари..., 2005: 3). Башка сүзлекләрдән борынгылыгы белән дә, тел материалы белән дә аерылып торганга, без әлеге хезмәткә киңрәк тукталырбыз.

XX гасыр башында рун язулы истәлекләргә һәм шуңа бәйле рәвештә төрки телләргә игътибар арткач, «Диване лөгатет-төрк» сүзлеге дөньякүләм дан казана. Беренче тапкыр ул 1915–1917 елларда Төркиянең Истанбул шәһәрендә Килисли Мөгаллим Рифгать Билге тарафыннан бастырылып чыгарыла. 1928 елда алман галиме Карл Броккельман, әлеге басмага нигезләнеп, «Урта төрки тел сүзлеге» хезмәтен яза. 1939–1941 елларда Бесим Аталай Төркиядә әлеге сүзлекнең төрек теленә тәрҗемәсен һәм соңрак кулъязманың индексацияләнгән факсимилесын бастыра. СССРда исә 1960–1963 елларда Үзбәкстанда Солих Муталлибов тарафыннан эшләнелгән тәрҗемә дөнья күргәннән соң, сүзлеккә игътибар башлана, 1969 елда аның шактый өлеше «Борынгы төрки сүзлек»кә кертелә. «Диване лөгатет-төрк» хезмәте яки аның материаллары Бөекбританиядә (1972), Кытайда (1981–1984), Америка Кушма Штатларында (1982–1984), Төркиядә (1990), Казахстанда (1997, 2005), Россиядә (2010) басыла, сүзлекнең электрон форматы Төркиянең Türk Dil Kurumu порталында урнаштырылган [http://yazmalar.tdk.org.tr], ә кулъязмасы исә Истанбулның Милли китапханәсендә (Millet Kutuphanesi) саклана.

«Диване лөгатет-төрк» сүзлеген өйрәнүгә өлеш керткән галимнәр шактый. Төрле елларда әлеге хезмәтне К. Брокельманн (1918), Г. Бергштрессер (1921), Ф. Хоммел (1923), В.В. Бартольд (1921), Б. Чобанзаде (1926), П.К. Жузе (1926), Җ. Вәлиди (1927), А. Фитратат (1927), М.Ф. Көпрюлюзадә (1930), А.З. Вәлиди (1932), В. Тоган (1932), А. Геррманн (1935), И.И. Умняков (1940), В.И. Беляев (1939), Б. Аталай (1939, 1941), А.Н. Кононов (1973), О. Прицак (1950), С.Е. Малов (1951), А. Бомбачи (1956), С. Ахаллы (1958), С.К. Ибраһимов (1959), В.С. Храковский (1959), С. Муталлибов (1960–1963), И.В. Стеблева (1972), А.Н. Кононов (1973), Р. Дэнкофф һәм Дж. Келли (1982–1985), Х. Короглы (1988), Р. Эрмерс (1999), В.Х. Хаков (1999, 2003), И. Хавеншилд (2003), М. Биран (2001), Ю.А. Зуев (2002), З.М. Ауэзова (2005), А.Р. Ру-

стамов (2010), И.В. Кормушин (2010) һ.б. тикшергәннәр. Моннан тыш, борынгы һәм урта гасыр ядкярләрен өйрәнгән һәрбер галим диярлек сүзлеккә мөрәҗәгать иткән, язма истәлекләрнең телен Мәхмүд Кашгарый сүзлеге белән чагыштырып өйрәнгән. Сүзлек төрек, алман, инглиз, үзбәк, уйгур, казах, рус телләренә тәрҗемә ителгән. Рус теленә беренче тулы тәрҗемәсе гарәп, фарсы, төрек телләре белгече, көнчыгыш әдәбиятын өйрәнүче күренекле галим Зифа-Алуа Ауэзова тарафыннан эшләнелгән һәм Казахстанда бастырылган (2005). Биредә без аның хезмәтендә [Махмуд ал-Кашгари, 2005] күрсәтелгән мәгълүматларга таяндык. 2010 елда «Көнчыгыш язма истәлекләре» сериясендә Россия фәннәр академиясе тарафыннан академик И.В. Кормушинның кереш сүзе белән һәм аның редакторлыгында «Диване лөгатет-төрк» сүзлегенең 1 нче томы, 2016 елда 2 нче томы рус теленә тәрҗемә итеп чыгарыла.

«Диване лөгатет-төрк» сүзлеге безнең көннәргә бердәнбер күчермә кулъязма вариантта килеп җиткән (оригинал сакланмаган). Ул 239 × 165 мм үлчәмдәге 319 кәгазьдән тора, аңарда XX гасырда тамгаланган 638 бит бар. Һәрбер биттә гарәп язуының нәсех шәкеле белән 17 юл язылган, текстта хәрәкәләр очрый, алар төрле чорларда редакторлар тарафыннан куелган булырга мөмкин. Текстның соңгы битендәге колофонга таянып, Мәхмүд Кашгари үзенең хезмәтен һиҗри ел исәбе белән 466 елда (милади 1074) тәмамлаган, ә табылган кулъязма ике гасыр соңрак – 664 (1266) елларда күчерелгән дип әйтергә нигез бар. Күчерүченең исеме дә билгеле – Мөхәммәд ибн Әбү Бәкр ибн Әбү-әл-Фатыйх әс-Савый, соңрак – әд-Дәмәшк. Кереш өлешендә хезмәтнең Габбас династиясе хәлифе Әбү Касыйм Габдулла ибн Мөхәммәт әл-Муктадыйга багышлануы, төрки халыкларның даны мәңгелек кыйммәт буларак тарихта калсын өчен язылуы турында әйтелә [Махмуд ал-Кашгари, 2005: 13–16].

Сүзлектә авторның үзе турында да шактый мәгълүмат табарга мөмкин. Кашгари Мәхмүд ибн әл-Хөсәйен ибн Мөхәммәд (1029–1038 елларда туган булырга мөмкин) – затлы, бай әмирләр нәселеннән (Омельян Прицак аның 992 елда Бохараны яулап алган Бограхан нәселеннән булу мөмкинлеген күрсәтә), белемле, сугыш алымнарын өйрәнгән («иң оста сөңге ыргытучы»), әтисе – Кыргызстанның Ыссык Күл янында урнашкан Барсган шәһәреннән, үзе соңрак Карахани төркиләренең мәркәзе булган

Кашгар шәһәренә килеп тупланган. Сүзлекне төркиләр яшәгән төрле урыннарны йөреп чыкканнан соң төзүе турында әйтә: «Мин аларның (төркиләрнең) шәһәр һәм далаларын йөреп чыктым, шигырьләрен һәм сөйләмнәрен белдем: төрки, төрекмән-угыз, җикил, йағма, кыргыз... *(тәрҗемә безнеке. – Кузьмина Х.Х.)*». Сүзлектә 41 сөйләш атамасыннан (кабилә теленнән?) мисаллар күрсәтелгән: *арғу, бәҗәнәк, баласағун, барсған, булғар, югары һәм түбән сыйн, җикил, җумул, йабақу, йағма, йәҗүҗ, йэмәк, йасмил, қай, қарлуқ, қыйрқыйз, кәнҗәк, қашғар, қыпчақ, қуҗа, мәҗүҗ, огуз, сыйн, сайрам, суварин, суғдақ, таңут, татар, тубут, түркмән, түркмән-қарлуқ, тухси, түрки, уғрақ, уҗ, уйғур, утлуқ, хақаниййя, хутан, согыд, түркмән-огуз* (Махмуд ал-Кашгари, 2005: 1269–1270). Үзбәк галиме Мәхмүт Равшанов мәкаләсендә исә сүзлектә 70 кабилә, халык, ил атамалары китерелгән дигән мәгълүмат бар: *ава (жава), алқа, араб, арамут, арғу, афшар, эзгиш, эжму, элка булақ, бажат, бажундур, барсған, басмил, башғирт, бектили, бэженак (бэженг), булақ, булғар, жабарқа (япония), жувалдар, жумул, жабақу, жазғир, жамақ, жаруқ, жаруқлуғ, жасмил, жағма, жэпни, игдар, қаж, қажиғ, қара болуқ, қарлуқ, қиниқ, қирқиз, қифчақ, оғрақ, кэнжак, кўчат, огуз, рус, салғур, сувар, суқақ (огуз), суғдақ, тат-тат (уйгур һәм башка мөселманнар), тат, татар, тат тавғач (фарсы, төрки, уйгурлар), тэжик, тэнгут, тугар, тутирқа, тухси, тубут, турк, туркман, уйғур, ундлуғ, уч, уғрақ, фарс, халач, хотан, чаруқ, чигил, чумул* (http://www.zpu-journal.ru/e-zpu/2012/2/Ravshanov_Comparative-Historical-Lexicography). Башка чыганакларда да бу атамаларның чагылганын исәпкә алсак, чыннан да, Мәхмүд Кашгарыйның тел материалы бик зур территорияне үз эченә алган булуы күренә.

Сүзлек шул вакыттагы гарәп теле сүзлекләре традициясендә төзелгән. Кереш өлешендәге мактау-догалар, хәлифкә багышлау, аларның ритмлы проза белән язылуы да гарәп йогынтысының көчле булуы турында сөйли. Белгечләр хезмәтне шул чордагы сакланып калган гарәп сүзлекләре белән чагыштырып чыккач, аның төрки чыгышлы автор Әбү Ибраһим Исхак ибн Ибраһим әл-Фәрабиның «Диван әл-әдәб фи бәййан лөгат әл-гарәб» («Гарәп әдәби теле җыентыгы») сүзлегенә нигезләнеп төзелгән булуын раслыйлар (Махмуд ал-Кашгари, 2005: 36).

«Диване лөгатет-төрк» сүзлеге эчтәлеккә бәйле исем бирелгән 8 китаптан (бүлектән) тора:

1. «Хәмзә»дән башланган сүзләр китабы (сузык авазларга башланган сүзләр җыелмасы (*ат, ит, ут һ.б.*)).

2. «Дөрес» сүзләр китабы (в, й, хәмзә тартыклары кермәгән, икеләтелмәгән тартык авазлардан торган сүзләр җыелмасы (*шат, қашуқ, сикир һ.б.*)).

3. «Икеләтелгән» тартыклы сүзләр китабы (*қақ, сақақ, бититте, җырлатты һ.б.*).

4. «Дөрес» сүзләргә охшаган сүзләр китабы (й тартыгына башланган сүзләр (*йат, йәстү, йәси һ.б.*)).

5. «Көчсез» аваз уртада килгән сүзләр китабы (сүз уртасында сузыклар яисә дифтонглар килгән сүзләр *(сөт, таш, тайак һ.б.* )).

6. «Көчсез» аваз сүз ахырында килгән сүзләр китабы (сүз ахырында сузыклар яисә дифтонглар килгән сүзләр (*бити, саҗу, қурдай-, башла- һ.б.*)).

7. Борын авазлары кергән сүзләр китабы (*таң, тәңри, қуңур, биринҗ, сиңирлә- һ.б.*)).

8. Тоташ ике тартыктан торган сүзләр китабы (ике тартыгы хәрәкә белән аерылмаган (иҗек ясалмаган) сүзләр (*илдруқ, түркмән, тарт, қызарт- һ.б.*) [Махмуд ал-Кашгари, 2005: 53–1081].

Соңгы ике китапта төрки телләрнең гарәп теленнән аермалы булган үзенчәлекләре чагылган, калганнары исә шул вакыттагы гарәп теле сүзлекләрендә сүзләрне урнаштыру шәкелендә төзелгәннәр. Хезмәтнең 18 нче битендә Мәхмүд Кашгари төрки телләрнең грамматикасыннан да «Китабу җәваһир ән-нәхү фи лөгат әт-төрк» («Төрки телләр нәхүе (грамматикасы) җәүһәрләре китабы») исемле зур хезмәт язуы турында искәртеп үтә, ләкин, кызганыч ки, әлеге хезмәт безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән.

Кашгарый еш кына төрки тел үзенчәлекләрен гарәп теле мисаллары белән чагыштырып бара. Шул ук вакытта сүзлекнең зур өлешендә сүзләрнең мәгънәви кулланылышын төрки фольклор үрнәкләре мисалларында аңлата, чөнки кереш өлештә үк инде моны ул үзмаксат итеп куя: «Мин аңа (сүзлеккә) төрки халыклар сөйләшкәндә, мөрәҗәгать иткәндә әйтә торган, берсеннән берсенә җиткерә торган шигырьләр; кайгыда да, шатлыкта да зирәк сүзләр буларак яңгыраган мәкальләр чәчтем» (ДЛТ, 2005: 5–6). Төрки тел материалын Мәхмүд Кашгари гарәп теленә тәрҗемә итеп бара.

Шул рәвешле, 6727 сүз һәм аларга иллюстратив тел материалы (шигырьләр, җырулар, мәкаль-әйтемнәр, канатлы сүзләр) бирелә.

Төрки телләрне тасвирлаганда, автор аларның кайсы шивәгә каравын күрсәтә. Үзе чыгышы белән Кашгардан (әтисе Баласагун шәһәреннән) булганга, аның өчен көнчыгыш төрки шивәләр якынрак: иң затлы төрки тел буларак, Мәхмүд Кашгари хаканлы (карахани династиясе) шивәсен билгели, чөнки бу тел чит телләр йогынтысына бирелмәгән, алынмалар аз. Төрки телләрнең сыйфатын күрсәткәндә, дә ул аларны үз теле белән чагыштырып бара, аның өчен карахани (хаканлы) теле үрнәк нигез тел булып тора, шуннан чыгып, ул телләрне «дөрес һәм дөрес булмаган», «чиста һәм чиста булмаган» телләргә аера. Телнең чисталыгы ул – фарсы алынмаларыннан азат булуы, дөреслеге – хаканлы теленә якын булуы. Димәк, Кашгарый классификациясендә төрки телләр ике зур төркемгә – сафлыгын югалтмаган көнчыгыш төрки телләргә һәм фарсы теле йогынтысы нәтиҗәсендә үзгәрешләр кичергән көнбатыш төрки телләргә бүленә.

Икенче билге – төрки телләрнең фонетик-морфологик күрсәткечләре. Мәхмүд Кашгари [з~й~d, б~м, з~с, р~л, қ~к, ғ~0 һ.б.] аваз тәңгәллекләрен күрсәтә һәм шулар буенча төрки телләрне бер-берсеннән аера.

Шул рәвешле, Мәхмүд Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» хезмәте гади сүзлек кенә түгел, XI гасыр төрки телләренең фонетик-грамматик белешмәлеге дә, тарихы, географиясе, халык авыз иҗаты, рухи мирасы буенча энциклопедия дә булып тора. Кызганыч ки, әлеге энциклопедик сүзлек татар теленә мөнәсәбәтле рәвештә бүгенге көнгә кадәр тикшерелмәгән.

Төрки телләр тарихын өйрәнүдә әһәмиятле урын алып торган тагы бер сүзлек – «Кодекс Куманикус» турында әйтергә кирәк. Урта гасырларда Алтайдан Дунайга, Мисырга кадәр сузылган җирләрдә куәтле төрки кабиләләр берләшмәсе – Дәшти Кыпчак яшәве мәгълүм. Әлеге кабиләләрнең тел үзенчәлекләре борынгы гарәп, фарсы, грек, латин, рус теленә караган истәлекләрдә теркәлеп калган. Шундыйларның берсе – XIII гасыр ахыры – XIV гасыр башында төзелгән «Alfabetum Persicum, Comanicum et Latinum Anonymi scriptum Anno 1303. Die 11 Julii», тарихта «Codex Cumanicus» («Коман мәҗмугасы») исеме астында билгеле ядкяр. Сүзлек 1303 елның 1 июлендә тәмамланган (күчереп язу бер-

кадәр соңрак булырга мөмкин). Язылу урыны билгеле түгел, ихтимал ватаны буларак, Кырым яки Венгрия территориясен, Сарай шәһәрен күрсәтәләр. Галимнәр: «Сүзлек миссионерлар тарафыннан Алтын Урдада дәүләт теле булган кыпчак телен өйрәнү һәм христиан динен тарату өчен төзелгән», – дип фаразлый (Гаркавец, 2006: 65). Безнең көннәргә әлеге 82 табаклы кулъязма ике өлештә – итальян һәм алман (немец) телләрендә килеп җиткән, аның бердәнбер күчермәсе Венециянең Изге Марк китапханәсе фондларында саклана. Итальян өлешендә (1–110 битләрдә) латин-фарсы-коман телләре сүзлеге, алман өлешендә (111–164 битләрдә) коман-алман сүзлеге һәм текстлар урнаштырылган. Текст латин язуында бирелә, латин өлешендә кыпчак теле *comanicum, chomanicho* (коман) дип аталган, ә төрки текстта ул *tatarče, tatar til* дип күрсәтелгән. Димәк, әлеге сүзлектә коман, кыпчак, татар сүзләре синонимнар буларак кулланылган.

Беренче өлеш латин телендә язылган кереш һәм өч баганага бүленгән өч тел сүзлеген – латин-фарсы-кыпчак (коман) телләрендәге 2680 сүзне үз эченә ала (200 латин сүзенең тәрҗемәсе бирелмәгән). Алман телендәге өлеше тәртипкә салынмаган, төрле язу рәвеше белән язылган, ул кыпчак-алман һәм кыпчак-латин сүзлеგеннән тора. Биредә шулай ук кыпчак телендә христиан текстлары, латин текстларының кыпчак теленә тәрҗемәсе һәм, киресенчә, кыпчак теленнән латин теленә тәрҗемә текстлар бирелә. Ике өлештә дә кыпчак теленә караган грамматик материал – фигыльләрнең төрләнеш үзенчәлекләре, алмашлыклар, исемнәр турында мәгълүмат китерелгән (Гаркавец, 1987: 34).

«Codex Cumanicus» сүзлеге беренче тапкыр Якоб Филипп Томасини тарафыннан тасвирланган. Ул әлеге кулъязманың Венеция китапханәсенә Яңарыш чоры шагыйре Франческо Петрарка тарафыннан бүләк ителгәне турында хәбәр итә (Гаркавец, 2006: 65). 1826 елда сүзлек турында Россия фәннәр академиясенең элеккеге экстраординар академигы Генрих Юлиус Клапрот язып чыга һәм ике елдан соң аерым өлешләрен бастыруга ирешә. Сүзлекнең хәзерге атамасын («Codex Cumanicus»ны) 1880 елда Венгрия галиме Геза Куун фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә һәм, сүзлекне өйрәнеп, аны тулысынча бастырып чыгара. Әлеге язма истәлекне өйрәнүгә В.В. Радлов (1887), Вильям Банг (1910, 1925), Кааре Грёнбек (1936, 1942), Аннемари фон Габен (1959; 1964), Владимир Дрим-

ба (1973), А.Н. Самойлович (1924), С.Е. Малов (1930) һ.б. зур өлеш керткән. Соңгы елларда әлеге ядкярне өйрәнү белән күренекле украин чыгышлы казах тюркологы Александр Гаркавец шөгыльләнә [http://www.qypchaq.unesco.kz]. Татар теленә мөнәсәбәтле рәвештә «Codex Cumanicus» сүзлеге татар теле һәм әдәбияты тарихы, диалектология буенча язылган хезмәтләрдә әлеге сүзлек чагыштырма материал буларак кулланыла (В.Х. Хаков, Ф.Ш. Нуриева, Л.Т. Мәхмүтова, Ш. Ш. Абилов һ.б.). «Codex Cumanicus» теленең татар теленә якын булуы турында шулай ук А. Габэн, Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин, Ф.Ш. Нуриева һ.б. язып үтәләр (Абдуллин, 1974: 167).

«Codex Cumanicus» сүзлегендә җанлы сөйләм теле үзенчәлекләре урын алган. Александр Гаркавец билгеләвенчә, «Латин теленнән тәрҗемә ителгән дога һәм дини гимн текстлары төрки тел чисталыгы белән таң калдыралар» (Гаркавец, 2006: 67). Сүзлектән алынган мисаллар, чыннан да, татар теленә бик якын: «Мән сизенеп әйтер идем сезгә Тәңре сүзен, тел белмәем, тылмач юк...», «Качан аны таш белән ташлар иде, ул әйтер иде: югары бакып күрегез, Мән күрермен кем, күк ачылыптыр...», *oymac* (уймак), *bus* (боз), *urluk* (орлык), *cun* (көн), *cüydurumen* (көйдерермен), *köz* (күз), *kerek* (кирәк), *kir* (кер), *tav* (тау), *sav* (сау), *baursak* (баурсак), *habar* (хәбәр), *haram* (хәрәм), *teqirman* (тегермән) һ.б. В.В. Радловның «Коман мәҗмугасы» турындагы фикерләрен берничә хезмәтендә Л.Т. Мәхмүтова да дәвам итә. Мәсәлән, «Татарский язык в его отношении к древнеписьменному памятнику Codex Cumanicus по данным лексики» исемле хезмәтендә ул В.В. Радловның коман-алман сүзлегенә кертелгән 2223 сүзнең 1781е (80%ы) татар телендә дә кулланылуын раслый, шуларның күпчелеге борынгы төрки сүзләр булуын ассызыклый. Моңардан башка сүзлектә гарәп һәм фарсы сүзләренең, шулай ук берничә славян һәм грек телләреннән кергән сүзләр булуын билгеләп үтә. Шул ук вакытта гарәп һәм фарсы сүзләренең күпчелеге татар телендә дә кулланышта булуы турында да яза (Махмутова, 1982: 68).

Төрки телләрнең лексикографиясе тарихында әһәмиятле урынны мәмлүк Мисырында XIII–XIV гасырларда төзелгән сүзлек-глоссарийлар, грамматикалар алып тора. Якынча бер сәяси-мәдәни вакытта, охшаш тел ситуациясендә һәм якын территориядә төзелгәнгә күрә, аларны, берләштереп, мәмлүк-кыпчак

язма истәлекләре рәтендә карарга мөмкин. Татар галиме Рәмил Фәнәви улы Исламов: «Мәмлүк-кыпчак Мисырында тел өйрәтү буенча эчтәлекләре һәм төзелешләре төрле булган җиде сүзлек һәм грамматика китабы барлыкка килгән», – дип әйтә (Исламов, 1998:142). Шундыйлардан Җамалетдин бине Мөһаннаның «Китаб-и мәҗмуг-у тәрҗеман төрки вә гаҗәми вә моголи вә фарси» («Төрки, монгол, фарсы телләренең тәрҗемә мәҗмугасы»), Җамалетдин Әбү Мөхәммәд Габдуллаһ әт-Төрки исемле авторның «Китаб-у булгат әл-муштак фи лөгат әт-түрк вә әл-кыфчак» («Төрки һәм кыпчак телләрен белү теләген канәгатьләндерә торган китап»), атаклы гарәп галиме Асиретдин әбү Хәййан әл-Андалусыйның «Китаб әл-идрак ли-лисан әл-әтрак» («Төрки телләрне аңлата торган китап») хезмәте, авторы билгесез «Китаб әт-төхфәт әз-зәкиййә фи-л-лөгат ит-төркиййә» («Төрки телләр өчен кадерле бүләк») сүзлеге, шулай ук авторы билгесез «Әл-кавагыйн әл-куллия ли-дабт әл-лөгат әт-төркиййя» («Төрки телне куллану өчен кагыйдәләр әсбабы») сүзлеген күрсәтергә мөмкин.

Озак вакытлар авторы билгесез саналган «Китаб-и мәҗмуг-у тәрҗеман төрки вә гаҗәми вә магули вә фарси» – мәмлүк Мисырында төзелгән ике тел сүзлеге [Улаков, 2001: 17]. Биредә кыпчак (команн) теленең беркадәр угыз элементларын алган көнбатыш варианты чагылган. Кульязманың Хәлил бине Мөхәммәд бине Йосыф әл-Кунави тарафыннан күчерелгән варианты (76 бит) Голландиянең Лейден университеты китапханәсендә саклана. Әлеге кульязмада төрки-гарәп сүзлегеннән соң монгол-фарсы һәм гарәп-монгол сүзлеге дә урнаштырылган. Сүзлекнең кульязмасы 1875 елда Санкт-Петербург Фәннәр академиясе академигы Виктор Романович Розен тарафыннан табыла («Les manuscrits arabes de l'Institut des langues orientales» (СПб., 1877)). 1894 елда сүзлекне күренекле голландияле галим Мартин Теодор Хаустма алман телендә дөньяга чыгара (Ein tiirkisch..., 1894).

Россиядә сүзлек беренче тапкыр П.М. Мелиоранский тарафыннан докторлык диссертациясе объекты буларак өйрәнелә һәм бастырыла (Мелиоранский, 1900). 1919 елда төрек галиме Килисли Мөгаллим Рифгать Билге Истанбулда Җамалетдин ибне Мөһаннаның «Китаби хөллийәт үл-инсан вә хөлбат ул-лисан» («Кешеләрнең бизәге, телнең ширбәтлеге китабы») кульязмасын таба һәм 1921 елда аны бастыра, бу кульязмада «Китаб-и мәҗ-

муг-у тәрҗеман төрки вә гаҗами вә моголи вә фарси» сүзлеге элек табылганнарына караганда тулырак һәм яхшырак сакланган икәнен күрсәтә. Әлеге басма турында 1926 елда Россиядә Шәрек Белгечләре коллегиясендә С.Е. Малов чыгыш ясый һәм сүзлекнең авторы ибне Мөһанна булуы турында хәбәр итә, тел материалы турында мәгълүмат бирә. «Китаб-и мәҗмуг-у тәрҗеман төрки вә гаҗәми вә магули вә фарси» сүзлеген кандидатлык диссертациясе темасы буларак үзбәк галиме А. Юнысов (1973), докторлык диссертациясе темасы буларак А.К. Курышҗанов (1973) тикшергәннәр, Э.В. Севортян (1962), Н.Н. Баскаков (1951), азәрбайҗан галимәсе З. Мөхәмәдова (1967), Ә.Н. Нәҗип (1965, 1989) һ.б. аерым аспектларына тукталганнар. Татар галиме В.Х. Хаков хезмәтләрендә дә сүзлеккә аңлатма һәм мисаллар бирелә (Хаков, 1977: 60).

Мартин Хаустма сүзләренә караганда, сүзлек 1245 елда Мисыр яки Сүрия территориясендә төзелгән булырга тиеш (Ein tiirkisch..., 1894). Әмир Нәҗип әлеге сүзлекнең Мисырга мәмлүкләр килгәнче үк төзелгән булуын күрсәтә (Наджип, 1989). Хезмәт 1260 ка якын сүзне үз эченә ала, аларның җитмешкә якынында «төрекмән» (угыз) тамгасы күрсәтелгән, калганнары кыпчак сүзе буларак аңлашыла. В.Х. Хаков билгеләвенчә, сүзлекнең тел үзенчәлекләре татар теленә бик якын тора [Хаков, 2003: 49], әмма бу сүзлек тә татар теленә мөнәсәбәтле рәвештә җентекле тикшерелмәгән.

Урта гасырларда төзелгән тагы бер күркәм сүзлек – Җамалетдин Әбү Мөхәммәд Габдуллаһ әт-Төрки исемле авторның «Китаб-у булгат әл-муштак фи лөгат әт-түрк вә әл-кыфчак» («Төрки һәм кыпчак телләрен белү теләген канәгатьләндерә торган китап») дип аталган ике тел (гарәп-кыпчак) сүзлегенең кулъязмасы бүгенге көндә Франциянең Париж шәһәре Милли китапханәсендә саклана. Бу сүзлекне өйрәнүче галимнәрдән 1938 елда кулъязманың фотокүчермәсе белән бер өлешен нәшер иткән, соңрак факсимилесын һәм транскрипциясен бастырган караим чыгышлы атаклы поляк галиме А.А. Зайончковскийны (Zajączkowski, 1954, 1958), күренекле тюркологлар Ә.Н. Нажип (Наджип, 1989), Э.И. Фазылов (1971), Н.Н. Баскаков (1960), А.Н. Щербак (1961) һ.б.ны күрсәтергә мөмкин. А.А. Зайончковский фикеренчә, кулъязмада сүзлекнең төзелү елы күрсәтелмәгән, әмма аны якынча XIV гасыр урталарында мәмлүк Мисырында төзелгән дип уйларга нигез бар.

Хезмәтне татар теленә мөнәсәбәтле тикшерүче Г.Р. Гайнетдинова кулъязманың беренче битендә Әбү Бәкер исемле кешенең һиҗри ел исәбе белән 855 (1451) тамгасы барлыгын әйтә [Гайнетдинова, 2004:10]. Димәк, кулъязма XV гасырдан да соңрак төзелмәгән. Үзбәк галимәсе Ш.А. Фәйзуллаева Җамалетдин әт-Төрки сүзлеге буенча фәнни диссертация яклый (Файзуллаева, 1969).

«Китаб-у булгат әл-муштак фи лөгат әт-түрк вә әл-кыфчак» сүзлеге кулъязмасы 71 кәгазьдән, 166 биттән тора (Гайнутдинова, 2004: 10). Сүзләр зигзаг рәвешендә өч колонка буларак төзелгәннәр, гарәп телендәге текст кара төс белән, ә төрки сүзләр кызыл төс белән язылган. Әмир Нәҗип күрсәтүенчә, кулъязмада «кыпчак сүзләренә караганда, төрекмән-угыз сүзләре күбрәк» (Наджип, 1965: 10), шуңа күрә сүзлекне саф кыпчак язма истәлеге дип атарга һәм борынгы кыпчак формаларын реконструкцияләү өчен куллану өчен җирлек аз (Улаков, 2001: 20).

Атаклы гарәп галиме Асиреддин әбү-Хәййан әл-Андалусыйның «Китаб әл-идрак ли-лисан әл-әтрак» («Төрки телләрне аңлата торган китап») хезмәте 1312 елда Каһирәдә тәмамланган һәм безнең көннәргә кадәр ике кулъязма күчермәдә килеп җитеп, Истанбул шәһәрендә саклана. Чыгышы белән Испаниянең Андалус (Гренада) шәһәреннән булган авторның тулы исеме – Әбү Хәййан Асиреддин Мөхәммәд ибне Йосыф ибне Гали ибне Йосыф ибне Хәййанән-Нифзи әл-Барбари әл-Җаййани әл-Гарнатый әл-Андалусый (1256–1344) – гарәп илләрендә танылган ислам дине һәм шәригать белгече, фәлсәфәче, тарихчы, филолог, шагыйрь; гарәп, фарсы, төрек, хәбәши (эфиоп) телләрендә язылган күп томлы 65 хезмәт авторы (шуларның унбише безнең көннәргә кадәр килеп җиткән). Автор кереш өлешендә сүзлекне төзүен болай тасвирлый: «Мин сүзләрне телне яхшы белгән һәр кеше авызыннан язып алдым. Аларны үземчә бер тәртипкә китердем. Грамматика кагыйдәләрен төзегәндә, башка бер хезмәткә таянмадым, үзем күргәнчә, үзем аңлаганча яздым. Изге максат, яхшы ниятне күздә тоттым. Сүзләрне туплау барышында хуш исләр аңкып торган гүзәл бакчаның һәр төрле агачларыннан татлы җимеш җыеп йөргәндәй, бик рәхәтләндем, җаныма җай табып, күп файда күрдем. Диңгез төпкеленә чумып, энҗе-мәрҗәнны армый-талмый эзләп, тау кадәр күтәрдем дә билгеле бер телнең асыл табигатен аңлауда беренче урынга ия булдым. Шуңа күрә хезмәтемне «Төрки телләрне аңлата

торган китап» дип атадым (*казахчадан тәрҗемә безнеке*. – К.Х.) (https://kk.wikipedia.org/wiki/Китаб_әл-Идрак_ли-Лисан_әл-Атрак).

Әбү Хәййан сүзлегендә 3500ләп сүз тупланган, аларның күбесенә кайсы шивәдән икәнлеген күрсәтә торган билгеләмәләр (кыпчак, төрекмән, төрки, болгар, татар, токсюба, уйгур һәм төркстан) бирелгән. Телгә алынган сигез этностан *болгар* сүзе дип, өч сүз күрсәтелә: *азак, изи, узу*. Татар сүзе буларак, *чәрчә* (перепёлка) сүзе китерелгән (Расулова, 1969, 119). В.Х. Хаков билгеләвенчә, «Әсәрнең теле бүгенге татар теленә бик якын. «Китаб әл-идрак»та теркәлгән сүзләр, фонетик-грамматик үзенчәлекләр 1245 елда иҗат ителгән «Төркичә вә гарәпчә сүзлек», 1303 елда язып тәгәлләнгән («Кодекс Куманикус») һәм шул чорда язылган башка әсәрләр теленә якынлыгы белән аерылып торалар. Әбү Хәййан әсәрендә мәмлүк төркиләренең лексикасыннан, фонетика һәм грамматикасыннан күп мәгълүмат бирелә» (Хаков, 2003: 67). Мәсәлән, *бай, ау, эз, су, ир, ат, кат, таш, башак, агу, алын (маңгай), йазуқ, карындаш, елдырым* һ.б.

Урта гасыр сүзлекләре арасында авторы билгесез «Китаб əттөхфәт әз-зәкиййә фи-л-лөгат ит-төркиййә» («Төрки телләр өчен кадерле бүләк») сүзлеге һәм шулай ук авторы билгесез «Әл-кавагыйн әл-куллия ли-дабт әл-лөгат әт-төркиййя» («Төрки телне куллану өчен кагыйдәләр әсбабы») сүзлекләре аерым урын тоталар. «Китаб әт-төхфәт әз-зәкиййә фи-л-лөгат ит-төркиййә» 1426 елда Мисырда яки Сүриядә төзелгән булырга мөмкин, чөнки әлеге хезмәттә гарәп теленең Сирия сөйләше үзенчәлекләре чагылыш таба. Сүзлекнең өч меңгә якын сүз һәм грамматик белешмәлек тупланган күчермәсе Төркиянең Истанбул шәһәренең Баязид китапханәсендә саклана. Әлеге ядкярнең фән дөньясында мәгълүм булуына һәм өйрәнелүенә тюркологлар Э. Фазылов, М. Күпрелезадә, А.А. Зайончковский, Ә.Н. Нәҗип, С. Мөталлибов, Т. Арынов һ.б. өлеш кертә. Казан университеты доценты А.Х. Нуриева, сүзлекне хәзерге татар әдәби теле белән чагыштырып, кызыклы гына нәтиҗә ясый. Аның тикшеренүләреннән күренгәнчә, тәңгәллек, нигездә 70% (Исламов, 1998: 135).

«Әл-кавагыйн әл-куллия ли-дабт әл-лөгат әт-төркиййя» сүзлегенең бердәнбер күчермәсе Истанбулдагы Сөләймания китапханәсендә саклана. «Әл-кавагыйн әл-куллия...» М.Т. Хоустма, Н.Н. Баскаков, Э. Севортян, Ә.Н. Нәҗип, А.А. Курышҗанов һ.б.

хезмәтләрендә өйрәнелә. Төрек галиме Рәджәп Топарлы хезмәтләрендә сүзлектәге 764 сүзнең 686сы төрки (91%), 35е фарсы (4,6 %), 18 е гарәпчә (2,4 %), калган 15 сүз гарәпчә-фарсыча-төркичә аралаш (1,9 %) икәне күрсәтелә (Исламов, 1998: 138).

Әдәбият галиме Р.Ф. Исламов билгеләвенчә, урта гасыр мәмлүк кыпчаклары телен чагылдырган, «Әд-дөррәтел-музыйа фил-лөгатет-төркийә» дип аталган ике сүзлек барлыгы тюркологиядә күптәннән мәгълүм. Алар Истанбулдагы Тупкалы музеенда саклана, А.А. Зайончковский 1963 елда Италиядә гыйльми сәфәр вакытында табып алган. Галимнең билгеләвенчә, һәм эчтәлеге, һәм эшләнеше ягыннан бу чыганак мәмлүкләр дәверендә төзелүендә шик калдырмый, кыпчак теле буенча материалга бай (Исламов, 1998: 139).

Шул рәвешле, Алтын Урда чорында, дәүләт теле буларак кыпчак телен өйрәнү өчен, бик күп сүзлекләр төзелүе мәгълүм. Аларның күбесе бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән һәм, төрки телләр тарихын, диалектология һәм лексикологиясен өйрәнү өчен, кыйммәтле чыганак булып тора.

Казан ханлыгы чорыннан (1438–1552 еллар) сакланып калган татар язма истәлекләре сан ягыннан күп түгел (аларның Казанны яулап алу вакытында яндырылган, юкка чыгарылган булуы ихтимал), ярлыклар һәм сату-алу, метрика кенәгәләре архивка соңрак беркетелгәннәр. Алар арасында төп урынны матур әдәбият һәм дидактика әсәрләре алып тора, сүзлекләр төзелсә дә, бүгенге көнгә кадәр килеп җитмәгән, яки аларны архивлардан эзләп табу – киләчәк эше. Әлбәттә, бу чорда төп игътибар Казан – Мәскәү арасындагы каршылыкка юнәлгән, шуңа күрә рус-татар, татар-рус ике тел сүзлекләре төзелгән булырга тиеш, бу табигый. Рус галиме, библиограф, энциклопедист П.К. Симони хезмәтләрендә кайбер мәгълүмат табарга мөмкин (Симони, 1908). Мәсәлән, иске рус-татар сүзлекләре шәкелендә язылган «Се татарский язык» һәм грек теле сүзлегендә урын алган «Толкование языка Половецкаго. Первые по половецки, а опосля русски» язмаларын күрсәтергә мөмкин (Левичкин, 2018: 32). «Се татарский язык» сүзлекчәсендә барысы 27 сүз, 6 фраза һәм 18 сан атамасы теркәлгән. Бу сүзлекчә Новгород шәһәренең София соборы китапханәсендә XV–XVI гасырларга караган җыентыкта сакланган. 1559 елда изгеләр тормышын ай көннәренә бүлеп тасвирлаган «Четьи-Миней» кулъязмасында

урын алган «Толкование языка Половецкаго. Первые по половецки, а опосля русски» сүзлекчәсендә барысы 17 сүз бирелә (Симони, 1908). Әлеге сүзлекчәләр татар лексикографиясе тарихына мөнәсәбәтле рәвештә тикшерелмәгән.

1581 елда Бәйрәм Хаҗи Булат 10 меңнән артык сүздән торган «Гарәпчә-төркичә сүзлек» төзи. Казан университеты китапханәсендә генә сакланып калган 296 битле әлеге кулъязмада хәзерге татар телендә кулланыла торган сүзләрне дә күрергә була (Татар лексикологиясе, 2015: 16).

Алда әйтелгәнчә, Казан ханлыгы рус дәүләте составында яши башлаганнан соң (XVI гасырның икенче яртысыннан соң), рус телендә язылган күп санлы ярлыклар һәм рәсми эш кәгазьләре туплана. Материаллар арасында рус теленә кереп киткән татар сүзләрен очратырга мөмкин *(чюлан, чардак, ясак һ.б.)*. Бу документларны фәнни әйләнешкә кертү, компьютер текстотекасында гамәлгә кую өчен, Казан университеты профессоры К.Р. Галиуллин җитәкчелегендәге төркем эшли (Э.А. Исламова, А.Р. Гизатуллина, Р.Р. Шакирова һ.б.). Бүгенге көндә «Казан төбәге» («Казанский край») проектының эш нәтиҗәсе буларак, XVI–XVII гасыр чыганакларын үз эченә туплаган электрон каталог барлыкка килгән, әлеге чорга караган 781 рус телле документ, эшкәртелеп, электрон форматка күчерелгән (http://www.klf.kpfu.ru/kazan/index.php).

XVII гасырга караган беренче басма грамматика – Иероним Мегизерның «Institutiones linguae Turcicae libri quatuor» хезмәтен күрсәтергә мөмкин. Әлеге хезмәт 1612 елда Лейпцигта латин телендә дөнья күргән. Хезмәт 2012 елда Казанда Ф.Ш. Нуриева, М.М. Петрова, М.М. Сөнгатуллиналарның кереш сүз һәм аңлатмалары белән басыла. Эчтәлеге белән грамматик сыйфатта булса да, биредә шушы чорга караган һәм алман, итальян, латин телләренә тәрҗемә ителгән төрки тел материалы белән танышырга мөмкин (Мегизер, 2012).

XVII–XVIII гасырга караган сүзлекләрне җентекле рәвештә күренекле тел галиме, шагыйрь, педагог Мостафа Ногман тикшерә [Ногман, 1969]; аның русча-татарча сүзлекләр тарихы турындагы белешмәләрен Ф.С. Сафиуллина үзенең лексикология буенча язылган хезмәтләрендә куллана (Сафиуллина, 1999).

Мостафа Ногман әйтүенчә, XV–XVII гасырларга караган тел материаллары рус галиме П.К. Симонинын «Памятники старин-

ной русской лексикографии по рукописям XV–XVII веков» (1908) хезмәтендә урын ала. Монда славян хәрефләре белән язылган кырыкка якын татар сүзе һәм тәгъбирләре, алфавит тәртибендә урнаштырылып, русча аңлатып бирелгән [Ногман, 1969: 26]. «Сборник рукописей конца XVII и начала XVIII века» исемле икенче кулъязма җыентык эчендә тагын бер аңлатмалы сүзлекчә бар. Ул «Наука языку турскому» дип атала һәм 15 битлек кулъязмадан тора. Гамәли максатны күздә тотып эшләнгән бу сүзлек сәүдә һәм көнкүрешкә караган өч йөзгә якын иң кирәкле рус сүзләрен үз эченә ала, аларга татарча аңлатма бирелә. Сүзлекнең лөгатьлеге һәм татарча тәрҗемәләре борынгы славян хәрефләре белән язылган. Автор сүзләрне «турский», «по-персидски», «по-татарской речи» бүлекләренә аерып күрсәтә. Сүзлекнең төзү урыны, авторы билгесез, шулай да бер нәрсә ачык: бу сүзлек татарлар арасында сату-алу эшләренә якын кеше тарафыннан төзелгән булса кирәк. Сүзлектә көнкүреш атамалары һәм аралашуда кирәкле җанлы сөйләм элементлары алынган, шулай ук ашамлык, мал-туар, кием-салым, йорт җиһазлары, төрле кыйммәтле ташлар һәм материалларның татарча атамалары бирелгән.

XVII—XVIII гасырларда дәүләтара мөнәсәбәтләрдә дә татар теле кулланыла. Рус дәүләте мәнфәгатьләрен яклау өчен дә, татарча белә торган чиновниклар, хәрби кадрлар әзерләү кирәк була. Инде бу вакытларда ук җирле телләрне өйрәнә торган мәктәпләр ачыла. Мәсәлән, 1730 еллар ахырында тарихчы галим, дәүләт эшлеклесе В.Н. Татищев, русларга татар һәм калмык телләрен укыту өчен, махсус мәктәп ача, сүзлекләр төзү эшен оештыра. Сенатка язган докладларының берсендә ул Россиядә яшәүче халыкларның телләре буенча чагыштырма «Лексикон» төзергә тәкъдим итә һәм үзе шул эшне җитәкли башлый. Төрле өлкәләрдән төрле күләмдәге русча-татарча сүзлекчәләр рәвешендә җаваплар алына, һәм алар хәзер дә Фәннәр академиясенең Петербург бүлегендә саклана. Шулар арасында Сембер, Казан, Тобол татарларының да сүзлекчәләре бар. Аларда лөгатьлекләре бер-берсенә охшаш 600 сүз теркәлгән. Русча-татарча-калмыкча сүзлек 1740 елларда өлешчә әзер була. Аны төзүче П.И. Рычков үзенә ярдәмгә җирле ахун Мәхмүт Габдрахмановны чакыра, һәм бу укымышлы ахун рус аңлатмаларын татарчага тәрҗемә итү эшен башкара. Кызганычка

каршы, бу кулъязма сүзлек «А», «Б», «В» хәрефләреннән соң тукталып калган (Ногман, 1969: 31–32).

Шушы ук Самара татар-калмык мәктәбе укучылары өчен әзерләнгән икенче бер хезмәт турында да бер-ике сүз әйтергә кирәк. Аны төзүче М. Котельников исемле кеше элек Оренбургта яшәгән, В.Н. Татищев һәм П.И. Рычков белән таныш булган һәм, бәлки, китапны алар кушуы белән дә эшләгәндер. Кулъязма 71 биттән тора. Һәр биттә 3 графа: беренчесендә – рус җөмләсе, икенчесендә – аның татарча тәрҗемәсе, өченчесендә татарча җөмләнең рус хәрефе белән транскрипциясе бирелгән. Бу – татар сүзләрен дөрес әйтү өчен зур ярдәмлек булган (Сафиуллина, 1999: 185).

1769 елда Екатерина II татар телен яхшы белгән чиновниклар әзерләү теләге белән татар теле укыту өчен, Казан губернаторына гимназия каршында махсус класс оештыру турында боерык бирә. Бу гимназиядә татар телен укыту белән Сәгыйть Хәлфин һәм аның уллары шөгыльләнә: 60 ел дәвамында бу эш буыннан-буынга күчеп килә. Татар телен өйрәнүгә булган ихтыяҗ яңадан-яңа сүзлекчәләр, кулланма материаллар таләп итә. Дәреслекләр дә төзелә башлый. Сәгыйть Хәлфин 1778 елда «Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов» исемле китап яза, һәм ул татар телен укыту буенча төзелгән беренче басма дәреслек дип санала. Гимназиядә күпьеллык укыту тәҗрибәсенә таянып, Сәгыйть Хәлфин 1785 елда «Татарский словарь в пользу обучающихся при Казанских гимназиях юношества татарскому языку» дип аталган ике томлык татарча-русча сүзлек төзи. Сүзлекнең өч нөсхә күчермәсе бар. Төп нөсхәсе Казан дәүләт университетының сирәк китаплар бүлегендә саклана. Сүзлектә башта рус сүзләре, аннан рус хәрефләре белән язылган татарча сүзләр бирелә. Шул ук сүзләр гарәпчә язылышта да күрсәтелә. Ике томлык сүзлеккә 23 меңнән артык сүз кергән. Хезмәт үзенең системалы булуы, рус сүзләренең мәгънәләрен тулырак, төгәлрәк күрсәтүе белән аерылып тора. Әлеге сүзлек «дәүләт идарәләрендә эшләүче чиновникларга турыдан-туры кулланма итеп әзерләнә һәм гимназия директоры аны князь Потемкинга бүләк итеп җибәрә. Потемкин исә ул чакта Таврия губернасы (элекке Кырым ханлыгы) белән идарә итә» (Ногман, 1969: 17).

Сәгыйть Хәлфин сүзлеге татар лексикографиясенең иң әһәмиятле казанышларының берсе булып санала.

1733 елда Россия фәннәр академиясе, җирле халыкларны өйрәнү өчен, махсус экспедицияләр оештыра. Шулардан Г.Ф. Миллер җитәкчелегендәгесе Казан губернасында, Урал, Себер якларында була. Ул үзе белән әзер лөгатьлек алып барып, җирле телләрнең кыскача глоссарийларын төзи. 1733 елда төзелгән бер сүзлекне Г.Ф. Миллер Сенатка җибәрә. Сүзлек рус теленнән башка 7 тел сүзләрен үз эченә ала: анда татар, чирмеш (мари), чуваш, вотяк (удмурт), мордва, пермяк һәм зырян телләрендәге билгеле бер сүзләр теркәлгән. Бу сүзлек 1758–1759 елларда беренче тапкыр немец телендә басылып чыга һәм «Россия тарихын өйрәнү өчен татар телен дә белү кирәк» дигән гыйльми максат белән төзелгән сүзлекләрнең башлангычы була (Ногман, 1969: 19).

XVIII гасырның икенче яртысында, аеруча Екатерина II патшалык иткән елларда, җирле халыкларның телләрен өйрәнү эше бик нык активлаша. Россиянең күренекле телчеләре күп телләрнең чагыштырмалы сүзлеген төзү белән кызыксына башлыйлар. 1785 елда Түбән Новгород шәһәрендәге духовная семинария епископы Дамаскин русча-татарча-чувашча-мордвача-марича сүзлек бастырып чыгара, бу эш аңа Екатерина II тарафыннан йөкләтелгән була. Екатерина II сүзлекләр төзүне бик хуплый, үзе дә әлеге эшкә актив катнаша. Төрле өлкәләрдән күп материал килә һәм бу материал «Сравнительные словари всех языков и наречий, собранные десницею всевысочайшей особы. Отделение первое. Содержащие в себе европейские и азиатские языки. СПб., ч. I – 1787; ч. II – 1789» исеме астында басылып чыга. Тел гыйлемендә әлеге сүзлекне Паллас сүзлеге дип атау гадәткә кергән. Бу сүзлектә татар теле, «Казан татар теле», «Мишәр теле», «Тобол татар теле» дип, өч төркемгә бүлеп күрсәтелгән (Ногман, 1969: 19).

Югарыда аталган русча-татарча сүзлек һәм сүзлекчәләр төзүнең ныклы иҗтимагый-тарихи җирлеге булган һәм алар шул дәвернең икътисади һәм сәяси таләпләренә җавап буларак барлыкка килгәннәр. Мостафа Ногман бу чордагы русча-татарча сүзлекләрнең төзелү максатын түбәндәгечә билгели: 1) татар телен өйрәнеп, рус һәм татар халкы арасындагы сәүдә-икъдисади бәйләнешләрне ныгыту; 2) рус дәүләтенең җирле идарәләрендә эшләргә татарча белгән чиновниклар әзерләүне тизләтү; 3) Россия тарихын өйрәнгәндә, татар телендә язылган тарихи чыганаклардан файдалана алу; 4) самодержавиенең христианлаштыру политикасын

уздырганда, татар телен белгән миссионерлар хәзерләү (Ногман, 1969: 17). Сафиуллина Ф.С., боларга өстәп, тагын русча-татарча сүзлекләр, кулланмалар төзүдә патша самодержавиесенең көнчыгыш халыкларын буйсындыру, колониаль омтылышларын зурайту максатлары да чагылуын ассызыклый (Сафиуллина, 1999: 190).

Шул рәвешле, татар лексикографиясенең башлангыч чор сүзлекләре тарихын берничә этапка бүләргә мөмкин:

1. Борынгы төрки сүзлекләр төзелү чоры (XI–XIII гасырлар);
2. Кыпчак-коман сүзлекләре төзелү чоры (XIV–XV гасырлар);
3. Русча-татарча (яки татарча-русча) сүзлекләр төзелә башлау чоры (XVI–XVIII гасырлар).

Әлеге сүзлекләр арасында ике тел (тәрҗемә) сүзлекләре өстенлек итә. Димәк, иң беренче чиратта төрки сүзлекләр төзелү сәбәбе – сәүдә һәм иҗтимагый аралашу мөнәсәбәтләрен җайга салу. Дин тарату максатында миссионерлар өчен, тылмачлар өчен, белем алу, телләрне өйрәнү өчен дә төзелгән сүзлекләр булуы табигый.

## § 7. XIX гасыр сүзлекләре

XIX гасырда татар әдәби теле тарихында гаять күп яңарыш һәм үзгәрешләр була. Бу – телебез үсешендә бик бай, гаять үзенчәлекле, катлаулы чор. Телдәге үзгәрешләргә иҗтимагый мөнәсәбәтләр, милли күтәрелеш, җәмгыятьтәге тарихи вакыйгалар тәэсир итә. Әдәби телне халыкның җанлы сөйләм теленә якынайту һәм шул нигездә нормалаштыру мәсьәләсе куела. Яңа чор әдәби телнең эшкәртелүен, норматив грамматикаларның төзелүен, сүзлек хәзинәсен һәм тел байлыгын барлауны таләп итә.

XIX гасыр татар әдәби теленең иҗтимагый функцияләре киңәя, җанлы сөйләмгә нигезләнгән хәлдә, ул бөтенләй яңа юнәлештә үсә башлый. Гасырлар буе килгән традицион язма тел сөйләм теле үзенчәлекләре белән тыгыз рәвештә кушыла бара (Хаков, 1993: 10–13).

Россиядә татар телен өйрәнүгә ихтыяҗ арткannан-арта. 1803 елда Россия Фәннәр академиясендә гуманитар бүлек яңадан торгызыла. Мәскәү, Казан, Харьков университетларында көнчыгыш телләре кафедралары ачыла. 1812 елдан татар теле Казан университетының уку программасына кертелә һәм укытучы итеп Ибраһим Хәлфин билгеләнә. Шулай ук университетның татар –

төрек телләре кафедрасында А. Казем-Бек, И.Н. Березин, М. Мәхмүтов эшли.

XIX гасырда төрле типтагы уку йортларында татар теле фән буларак укытыла башлый. Тобол, Томск, Оренбург, Саратов, Әстерхан, Ставрополь, Симферополь гимназияләрендә татар теле барлык милләт вәкилләренә дә өйрәтелә.

Патша Россиясенең көнчыгыш сәясәте татар телен белгән тәрҗемәчеләр, канцелярия хезмәткәрләре булуны таләп итә. Якын Көнчыгыш илләреннән килгән делегацияләрне Россия буйлап татарча белгән тәрҗемәчеләр озатып йөри. Оренбургтагы Неплюев кадет корпусы укытучысы М. Бекчурин, мәсәлән, шушы өлкәдәге тырыш хезмәте өчен патша Россиясенең югары бүләкләренә, орден-медальләргә лаек була.

XIX гасырда Россия территориясендә киң җәелгән миссионерлык хәрәкәте дә татар телен белүне сорый. Казан рухани академиясендә һәм семинариядә А. Троянский, Н. Ильминский, Е. Малов татар теленнән дәрес бирәләр, укыту тәҗрибәсенә таянып дәреслекләр, грамматикалар, сүзлекләр төзиләр.

Рус һәм татар халкы арасында үзара сәүдә-икътисади, иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни бәйләнешләрнең яшәп килүе дә һәр ике телгә ихтыяҗ тудыра. Шул сәбәпле ике тел байлыгын туплаган сүзлекләр дөнья күрә башлый.

Иң күп таралган сүзлекләрдән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләрне күрсәтергә кирәк. Мондый сүзлекләрнең күпләп чыгуының төп сәбәпләре итеп түбәндәгеләрне атарга мөмкин: XVI гасырда рус дәүләте составына керү, рус әдәбияты һәм мәдәнияте белән якыннан танышу, руслар белән аралашу өчен уртак тел зарурлыгы, татар телен өйрәнеп, рус һәм татар халкы арасында сәүдә-икътисади бәйләнешләрне ныгыту, рус дәүләтенең җирле идарәләрендә эшләргә татарча белгән чиновниклар әзерләү, Россия тарихын өйрәнгәндә, татар телендә язылган тарихи чыганаклардан файдалана алу, самодержавиенең христианлаштыру сәясәтен уздырганда, татар телен белгән миссионерлар әзерләү һ.б. Бу сәбәпләр XIX гасырда ике телле сүзлекләрнең барлыкка килүенә җирлек булып торалар.

Шулай итеп, бу чорда дөнья күргән сүзлекләр, нигездә, ике-телле, ягъни татарча-русча я русча-татарча. Болай булуның сәбәпләре итеп шул чордагы сәясәт, әдәби-мәдәни вазгыять һәм Казан

тюркология мәктәбенең бу юнәлештә зур эш алып баруын әйтергә кирәк. Бу вакыт аралыгында унөч тәрҗемәи, бер аңлатмалы, бер терминологик сүзлек дөнья күрә. Бу сүзлекләр галимнәр, укытучы-практиклар, дин эшлеклеләре тарафыннан төзелә, һәм алар барысы да бу хезмәтләрендә үзләренең эш практикаларын чагылдыра.

И. Гигановның **«Слова коренные, нужнейшие к сведению для обучения татарскому языку, собранные в Тобольской главной школе учителем татарского языка И. Гигановым и Юртовскими муллами свидетельствованные»** (СПб, 1801. – 75 с.) сүзлеге авторның татар грамматикасына кушымта рәвешендә тәкъдим ителә. Сүзлектә урын алган 1800 лексик берәмлек төрле тематик төркемнәргә бүленеп бирелгән. Төркемнәрнең исемнәре рус телендә генә тәкъдим ителгән: «Область и его части с принадлежностями», «Дом и его части», «Разные вещи», «Конский прибор», «Вещи принадлежащие к одеянию», «Школа со школьными пособиями», «О стихиях и других естественных вещах», «О человеке, его возрастах и его частях», «О родстве», «О различных состояниях людей», «Месяцы с зодиакальными созвездиями», «О промыслах», «О животных», «О рыбах», «О деревьях и плодах», «О птицах», «О насекомых», «Об огородных растениях», «О луговой зелени» «О камнях и металлах», «Об именах встречающихся в других книгах», «О времени», «О добродетелях и пророках», «Имена означающие качества».

Сүзлектә сүзләрнең бирелеше бик гади. Башта гарәп графикасында татар сүзе, икенче баганада шул чорда кабул ителгән орфографик нормаларга буйсындырылып, сүзнең кирилл хәрефләре белән язылышы һәм өченче баганада – рус сүзе. Мәсәлән,

دروازه дарваза городскія ворота (с. 1)

اوچ уцъ конецъ (с. 2)

Сүзлектә теркәлгән лексик берәмлекләрнең бер өлешен Себер татарлары, ягъни көнчыгыш диалект вәкилләре теленә генә хас булган сүзләр тәшкил итә. Теркәлгән сүзләрнең күбесе телебездә хәзер дә актив кулланыла, ләкин алар көнчыгыш диалектларга хас булган фонетик закончалыкларга буйсынган рәвештә биреләләр. Алар арасында ашамлык атамаларын, тормыш-көнкүреш предметларын, табигать күренешләрен белдерә торган сүзләр бар. Мәсәлән, ياصدوغاج *ястугачъ* (с. 7) колак мендәре, кечкенә мендәр

дигәнне белдерә (Тумашева, 1992: 72), سرة *сәртә* (с. 14) кыздырып, аш өстенә салынган май (Тумашева,1992: 168) мәгънәсендә кулланыла.

И. Гигановның 75 биттән торган сүзлеге – XIX гасыр башында дөнья күргән беренче ике телле сүзлек. Төзелеше ягыннан ул XVIII гасыр кулъязма сүзлекләренә һәм сөйләүлекләренә бик якын. Моңа төп дәлил итеп сүзлекнең тематик принципта төзелүен һәм хезмәттә телдә иң актив кулланылышта булган берәмлекләрнең генә теркәлүен күрсәтергә була.

Гомумән алганда, И. Гигановның тел белеме өлкәсендәге хезмәтләре үз вакытында татар телен өйрәнү өчен гаять файдалы кулланмалар булып саналган. Алар төрки телләрне өйрәнүдә мөһим урын били. Хәзерге вакытта исә әлеге хезмәтләр шул чор теленең лексик составын өйрәнү, бигрәк тә көнчыгыш диалектларны тикшерү өчен бай чыганак булып торалар.

И. Гигановның икенче сүзлеге **«Словарь российско-татарский, собранный Тобольском главном народном училище учителем татарского языка И. Гигановым и муллами Юртовскими»** дип атала. Ул 1804 елда Санкт-Петербургта басылган. Сүзлек 672 биттән гыйбарәт. Рус сүзләренә сүзгә-сүз җыйнак һәм аңлаешлы тәрҗемә бирелгән. Сүзлекнең төзелеше безнең заманда камилләшкән сүзлек төзү принципларына якын тора. Сүзләр рус алфавиты тәртибендә урнаштырылып, күп очракта бу тәртип сүзнең беренче хәрефенә генә түгел, аннан соң килгәннәренә дә карый. Сүзлекнең һәр битендә сүзләр өч графага бүленгән. Беренчесендә, алфавит тәртибен саклап, рус сүзе бирелә; икенчесендә, әйтелеш дөреслеген сакларга тырышып, рус хәрефләре белән сүзнең татарча укылышы язылә; өченче графада гарәп графикасында татар сүзе китерелә:

Аллебарда *айбалта* ائبالطا (с. 3)

Алтынъ *учъ теинькикъ* اوچ تينلک (с. 3)

Аптека *дару ханясъ* داروخاناسى (с .4)

Ныклы алфавит тәртибе авторның сүзлек төзү принциплары белән якыннан таныш булуы турында сөйли. Ул сүзлек белән кулланучылар өчен дә билгеле бер уңайлылык бирә. Кайбер очракта бирелгән сүздән соң бер тамырдан ясалган, яисә мәгънәдәш сүзләр күрсәтелә. Бу вакытта алфавит тәртибе бозыла. Мондый алым

сүзлек белән эшләүне җиңеләйтә һәм татар теле лексикасын тиз истә калдыруда зур роль уйный.

«Словарь Российско-татарский» хезмәтендәге лексик байлыкның төп өлешен шул чор татар халык сөйләм һәм язма теленә хас булган, шулай ук Себер татарлары сөйләмендә кулланыла торган сүзләр тәшкил итә. Шулардан бер өлеш хәзерге татар әдәби теленең һәм көнчыгыш диалектының сүзлек фондына керәләр.

И. Гиганов сүзлекләре лексик берәмлекләрнең күләме ягыннан, структур яктан бер-берсеннән аерылып торалар. Беренче сүзлек телне башлап өйрәнүчеләр өчен төзелгән булса, икенче сүзлек академик басма рәвешендә эшләнгән. Тагын шуны да ассызыкларга кирәк, И.Гигановның сүзлекләре диалектологик сүзлекләрнең башлангычы булып саналалар. Соңрак алар үрнәгендә татар теленең яңа диалектологик сүзлекләре дөнья күргән.

А. Троянскийның татар лексикографиясенә керткән өлеше бик зур, ләкин бүгенге көнгә кадәр галимнең гаять күләмле сүзлеге тиешенчә тикшерелмәгән һәм үзенә лаеклы бәяне алмаган. Хезмәтнең исеме – **«Словарь татарского языка и некоторыхъ употребительныхъ въ немъ реченій арабскихъ и персидскихъ, собранный трудами и тщаніемъ учителя татарского языка въ Казанской семинаріи священника Александра Троянского и напечатанный съ дозволенія комиссіи духовныхъ училищъ»**. Беренче томы 1833 елда Казан университеты типографиясендә дөнья күрә чыга. Ул 629 биттән тора, анда якынча 6490 сүз теркәлгән. Ә икенче томы 1835 елда басыла, ул 340 биттән гыйбарәт. Бу томда якынча 3400 сүз бар. Сүзлекнең форматы – 26*25.

Сүзлекне бастыруга рөхсәт 1829 елның 31 декабрендә бирелә. Беренче биттә мондый юллар бар: «По журналу Комиссіи Духовныхъ училищъ 31-го декабря 1829 года состоявшемуся, печатать дозволяется для употребленія въ подведомоственныхъ оной Комиссіи учебныхъ заведеніяхъ. Казанской Семинарій Ректоръ, Архимандритъ и Кавалеръ Ѳеофанъ».

Сүзлекнең төзелешенә, структурасына килгәндә, бу – алфавит тәртибендә төзелгән татарча-русча сүзлек. Сүзләрнең фонетик вариантлары аерым лексик берәмлек буларак теркәлгәннәр.

اتچ Пътухъ, пътелъ, кочатъ (т.1, с.6)

اتش Огонь, (пер. сл.) (т.1, с.6)

وله ن Трава, мурава, зелень (т.1, с.131 ),

اوي Дом, изба, покой (т.1, с.139),

اويرمه Вихарь, буря, сильный ветер (т.1,с.139)

ايسلي Душистый, вонючий, угарный, или: имеющий запах, дух, вонь, угар ( с.153).

Географик атамаларны, милләт атамаларын теркәү сүзлекне тагын да кызыклырак итә. Бу атамалар укучының дөньяга карашын киңәйтә, аның белемен арттыра. Хәзерге телдә бары рус варианты гына кулланылган географик атамаларның гарәп-фарсы, төрки вариантлары теркәлү сүзлекнең кыйммәтен тагын да күтәрә.

А.Троянскийның татарча-русча сүзлеге башка милләт вәкилләрен татар теленә өйрәтү максатын күздә тотып төзелгән. Бу – татар сүзләрен рус теленә тәрҗемә итүдә ачык чагыла. Татарча бирелгән һәр сүзнең рус телендәге тәрҗемәсе, тәрҗемәнең барлык синонимнары, вариантлары бирелә.

Автор сүзләрнең килеп чыгышына да игътибар итә һәм һәр сүзнең кайсы телдән керүен күрсәтеп бара. Мәсәлән, сүзләр янында «араб.», «перс» дигән искәрмәләр бар. Мисал өчен, پيشه *пишә* (перс.) – рукоделье, художество (с.259), تحسين *тәхсин*[1] (араб.) – хвала, похвала, одобрение (с.281), تفراج *тәфәррежс* (араб.) – веселье, забава, утешение, восхищение, увеселение (с.331), تفرق *тәфәррык* (араб.) – развод, разведение, разлука, отдел, отделение (с.331), چشم *чишм* (перс.) – глаз (с.467), اته ش *атәш* ( перс.) – огонь (с.9), جفت *җефет* (араб.) – жена, супруга (с.401). Автор татар телендә пассив булган, сирәк кулланылган алынмаларны гына аерып күрсәтә. Шул рәвешле, беренче томда – 374 гарәп, 162 фарсы сүзе, икенче томда 283 гарәп, 23 фарсы сүзе бирелә. Ләкин сүзлектә теркәлгән гарәп-фарсы алынмалары моның белән генә чикләнми.

Автор кайбер сүзләр янына җәяләр эчендә «трава», «дерево», «платье», «плод», «зверек», «растение», «рыба», «болезень», «грамматический термин» дип, сүзләрнең лексик мәгънәсен ачып бара, кайсы тематик төркемгә мөнәсәбәтле булуларын күрсәтеп үтә. Ләкин бу искәрмәләр һәрвакытта да куелмый. Автор укучы өчен бик үк таныш булмаган, пассиврак кулланылган сүзләрне шулай билгеләгәндер дип гөман кылырга мөмкин.

---

[1] А.Троянский сүзлегендә гарәп алынмалары диокритик билгеләр белән тәкъдим ителә. Техник сәбәпләр аркасында бу билгеләр текстта күрсәтелми.

Сүзлектә фигыльләр *-мак* формасында теркәлгәннәр. Төрле юнәлешләрдәге фигыльләр аерым берәмлек итеп күрсәтелгәннәр. Берничә мисал китереп үтик: جرطماق *җыртмак* – драть, раздирать, разодрать, изодрать, рвать, разорвать, изорвать (с.393); جرطدرماق *җыртдырмак* – велеть драть, раздирать, изодрать, рвать, разрывать, разорвать, изорвать (с.393); جرطشماق *җыртышмак* – взаимно с кем драть, раздирать, издирать (с.393); جرطلماق *җыртылмак* – драться, раздираться, изодраться, рваться, разрываться, разорваться, изорваться, или быть раздираему, издираему, разрываему (с.394).

Сүзлек турында гомуми нәтиҗә ясап әйткәндә, А. Троянский сүзлегенең XIX гасырның беренче яртысында дөнья күргән иң зур татарча-русча сүзлек булуын искәртү зарур. Ул алда каралган И. Гиганов сүзлекләреннән лексик берәмлекләрнең составы, байлыгы белән аерылып тора. Анда 22 меңнән артык сүз һәм сүз формасы туплана. Сүзләр тормышның торле өлкәләренә карый һәм һәр сүзнең синонимнары, диалекталь вариантлары аерым сүзлек мәкаләсе итеп формалаштырыла. Бу искиткеч зур лексик байлык аерым монографик өйрәнүгә лаек.

С. Кукляшевның **«Словарь къ татарской хрестоматии»** хезмәте 1859 елда Казан университеты типографиясендә дөнья күрә. Сүзлекне бастырып чыгарырга цензор И. Готвальд рөхсәт бирә. Титул битендә «Печать дозваляется съ темъ, чтобы по напечатаніі представлено было въ цензурный Комитетъ указанное число экземпляровъ. Казань, 19 мая 1859 г.» дип язылган. Хәзерге вакытта сүзлекнең берничә нөсхәсе Казан дәүләт университеты китапханәсенең сирәк китаплар бүлегендә Готвальд фондында саклана.

С. Кукляшевның хрестоматиясе һәм аңа кушымта итеп төзелгән сүзлеге иң беренче чиратта татар булмаган укучыларга адресланган. Сүзлекнең максаты — хрестоматиядә урын алган һәр сүзгә, ягъни 3546 лексик берәмлеккә русча аңлатма бирү, аңлату, тәрҗемә итү.

Сүзлек алфавит тәртибендә төзелә: башта гарәп шрифты белән язылган татар сүзләре теркәлә һәм каршысында русча тәрҗемәсе дә бирелә. С. Кукляшев сүзләргә аңлатмаларны, контекстка нисбәтле рәвештә, мөмкин кадәр тулырак бирергә омтыла:

*а.* امر әмер – приказаніе (с.14)

بالچق балчык – грязь, глина (с.23)

*а*. امان аман – безопасность, миръ, пощада, покой (с.14)
ومچ умач – мучной бульонъ (с.19)
دلدل дөлдел – конь Алія, 4 арабскаго халифа (с.49)
Сүзлекнең форматы – 16*22.

Шунысы мөһим: С. Кукляшев А.Троянский үрнәгендә шартлы билгеләр ярдәмендә гарәп, фарсы, кыргыз (казах), иске татар һәм төрек сүзләрен дә билгеләп бара (а. – значить арабския слова, п. – персид, к. – киргизския, т. – турецкая или старотатарские слова, вышедшые из употребления, с. – значитъ слово составленныя из арабских или персидских слов с прибавлением на конце оных татарскихъ частицъ или глаголов). Әгәр дә башка сүзлекләрдә татарча сүзләр я хәрәкәләр, я янәшәдә рус хәрефләре белән бирелгән булса, бу сүзлектә исә андый хәл күзәтелми. Шуның нәтиҗәсендә аерым сүзләрне уку авырая, аларны төрлечә уку ихтималлыгы туа.

Сүзлек бик үзенчәлекле. Бу хезмәттә С. Кукляшев хрестоматиясендә урын алган текстлардагы лексик берәмлекләр сүзлек формасына китерелеп, тәрҗемә ителгән. Монда телдә актив кулланылышта булган сүзләрне дә, шулай ук кулланылышы чикле, пассив булган берәмлекләрне дә күрергә мөмкин.

Хрестоматиядәге төрки-татар телендә язылган үрнәкләр дә бар. Ләкин, нигездә, текстлар гарәп, фарсы теленнән тәрҗемә ителгән һәм шуңа күрә сүзлектә гарәп һәм фарсы сүзләре аеруча күп.

Сүзлек иң беренче чиратта рус яки башка милләт вәкиле өчен төзелгән, шуңа күрә сүзләрне тәрҗемә итү алымнары аеруча игътибарга лаек. Сүзгә-сүз, ягъни эквивалент тәрҗемә сүзлектә төп урынны алып тора: امر *әмер* – приказание (с.14), بوري *бүре* – волкъ (с.26), بلبل *былбыл* – соловей (с.26). Ләкин автор сүзнең бер тәрҗемәсе белән генә чикләнеп калмый, булган синонимнарны да теркәп бара. Мәсәлән: ايمام *имам* – имам, мулла, священник (с.14), امان *аман* – безопасность, мир, пощада, покой (с.14 ), انط *ант* – присяга, клятва (14 с.). Бу алым бер телдәге сүзнең мәгънәсен икенче тел вәкиле өчен тулырак, төгәлрәк аңлату мөмкинлеген ача.

Автор кайбер сүзләргә аңлатмалар, иллюстрацияләр бирә. Бу сүзләр – я халык атамасы, я дини термин, я милли үзенчәлеккә ия берәмлек. Мәсәлән, ومچ *умач* – мучной бульон (с.19 ), دلدل *дөлдел* – конь Алия, 4 арабского халифа (49 с.), صور بازاري *сур* базары – базаръ, торгъ сурками в мае месяце при г. Оренбурге (с.62).

С. Кукляшев сүзлеге бу чорда дөнья күргән сүзлекләрдән үзенең эчтәлеге белән аерыла. Сүзлекнең төзелү максаты да төгәл билгеләнә. Ул хрестоматиягә кушымта итеп төзелә, шуңа күрә сүзләр составы бик үзенчәлекле. Сүзлектә хрестоматияләрдә урын алган хикәяләрдәге сүзләр генә теркәлә һәм шул сүзләргә аңлатма бирелә.

Сүзлек, бер яктан, текстларны аңларга, төшенергә мөмкинлек бирсә, икенче яктан, тел һәм лексикография тарихын өйрәнүдә мөһим чыганак булып тора. Кызганычка каршы, практикада һәм лингвистик тикшеренүләрдә бу сүзлек әле бөтенләй диярлек искә алынмый.

XIX гасырның икенче яртысында дөнья күргән ике телле сүзлекләр арасында Л.З. Будагов сүзлеге аеруча кызыклы. Башка сүзлекләрдән ул үзенең үзенчәлекле сүзләр җыелмасы, татар сүзләре белән беррәттән төрек сүзләренең күп булуы, А. Нәваи, Бабур, Абу-л-Гази әсәрләренә, төрки телләрнең шәрык сүзлекләренә (аңлатмалы, тәрҗемә), төрки-европа сүзлекләренә, төрки-фольклор язмаларына нигезләнүе белән аерыла.

Л.З. Будаговның гыйльми хезмәтләре арасында заман сынауларына бирешмәгән, төрки лексикография тарихында тирән эз калдырган **«Сравнительный словарь турецко-татарскихъ наречій, съ включеніемъ употребительнейшихъ словъ арабскихъ и персидскихъ и съ переводомъ на русскій языкъ составилъ ЛАЗАРЬ БУДАГОВЪ доцентъ восточного факультета С.-П. Университета и драгоманъ V-го класса при Азіятском департаменте»** («Төрек-татар телләренең чагыштырмалы сүзлеге... ») – тел белеме өлкәсендә аеруча әһәмиятле. Бу хезмәт әлегә кадәр фәнни әйләнешкә кермәгән, гаять кызыклы лексикологик материал туплаган булуга карамастан, аның турында мәкаләләр, монографияләр язылмаган.

Бу сүзлекне Л.Будагов бик озак төзи. 1864 елның 8 гыйнварында факультет укытучыларына ул сүзлекнең структурасын, сүзләр составын аңлата. Төрки телләрдән сүзлеккә казан, кыргыз (казах), тобол, башкорт, чагатай, төрек, кырым, ногай, азәрбайҗан телләре сүзләре керү турында әйтә.

Сүзләрнең урнашу тәртибе казан татарларында кулланыла торган алфавит тәртибендә булуын ассызыклый, чөнки автор бу алфа-

витны гамәли яктан иң алга киткән әлифба дип саный (Усманов, 1980: С.101–102).

Сүзлек 1869–1871 елларда дөнья күрә. Ул Мәскәү шәһәренең Армән тыкрыгы, 2 йортта урнашкан Фәннәр Академиясе Азия халыклары институтының көнчыгыш әдәбияты нәшриятында әзерләнә, Санкт-Петербург император Фәннәр Академиясе типографиясендә басылып чыга. Тиражы зур түгел – бары 1500 данә. Күләменә килгәндә, бу сүзлек – XIX гасырда чыккан иң зур сүзлекләрнең берсе: I том 800 биттән тора, 17*26 форматлы, II том 415 биттән тора. Ике томда барлыгы 25 200 лексик берәмлек теркәлгән. Сүзлекнең титул битендә автор үзе турында да мәгълүмат биреп үтә. Ул үзен Санкт-Петербург университеты доценты, Азия департаментының бишенче класс драгоманы дип күрсәтә. Титул битендә автор турында шундый белешмә бирү XIX гасырда шактый киң таралган күренеш була.

Сүзлекнең күләме һәм лексик составы төрки тел материалына – татар һәм башка төрки телләргә нигезләнгән булуы белән билгеләнә.

Сүзлектә шулай ук гомумтөрки һәм арадаш лексика да урын алган. Бу бигрәк тә барлык төрки телләр өчен уртак булган берәмлекләргә багышланган сүзлек мәкаләләрендә чагылыш таба. Мәсәлән: *bas* ‘голова’ (с. 225–228); *ajaq* ‹нога› (с.174–175); *ajtmaq* «сказать, говорить› (с.178–179). Л. Будагов диалекталь һәм гади сөйләм сүзләрен дә сүзлектә шактый күп теркәгән һәм бу сүзләргә багышланган «провинц.» или «простом.» дигән билгеләр куйган. Мәсәлән: «тур. *bisrak* (провинц.) – одногорбый верблюд» (с. 258); «тур. *bobrek, bogrek* (простон.) *bowrek* почка» (с. 272), «тат. *mant* пчельник (у приволжских татар селения Тархан; у других татар это слово неизвестно)» (с. 673). Кайбер очракларда, «хатын-кыз теле» берәмлекләре дип, төрки телләрдә кулланыла торган аерым сүзләр теркәлгән. Мәсәлән: «кир. *kobogen* детки, ребятушки (старушечье слово)» (с. 142); *manya cirik* «бранное выражение кумыкских женщин» (с. 198).

Сүзләргә аңлатма биргәндә, Л. Будагов эзлекле рәвештә «Wort und Sache» дип аталган методикага нигезләнә, ягъни сүзләрне аңлатканда, сүз белдергән предмет һәм төшенчә турында мәгълүмат бирә. Шуңа нисбәтле рәвештә, Л.З. Будагов сүзлеге төрки

халыкларның иҗтимагый-сәяси, мәдәни тормышын, көнкүрешен чагылдырган энциклопедиягә әйләнә.

Сүзлекнең керешендә автор әлеге хезмәтнең максатын аңлатып үтә. Китапның укучыларга, чиновникларга, сәүдәгәрләргә адреслануын һәм шуңа күрә бары тик иң актив сүзләрне генә туплавын искәртә.

Сүзлекнең күләме һәм сүзләр составы ике төрки тел материалын чагыштырып бирү белән дә бәйле. хезмәттә гомумтөрки сүзләр зур урын алып торалар. Бу төркемгә караган берәмлекләрнең сүзлек мәкаләләре шактый күләмле итеп эшләнгән.

Будагов сүзлегендә диалекталь һәм гади сөйләм сүзләре дә шактый теркәлгән, алар янына автор «провинц.», «гади», «хатын-кыз теленнән» дигән билгеләр куеп барган.

Китапның күләмле булуының тагын бер сәбәбе – авторның икеләтелгән максаты. Беренчедән, бу фәнни сүзлек булса, икенчедән, ул студентлар өчен уку әсбабы ролен үтәгән, чөнки сүзлектә әдәби ядкярләрдә урын алган сүзләр һәм тезмәләр теркәлгән.

Хезмәттәге сүзләр гарәп графикасында һәм гарәп алфавиты тәртибендә бирелә. Ләкин һәр сүзнең рус хәрефләре белән транскрипциясе күрсәтелә.

Мәсәлән, *тос.* قاباق 1) затворъ, забор на межъ (чтобы чужой скотъ не ходелъ), 2) = قاباق ( с.2 ).

Бу, әлбәттә, тел өйрәнүченең эшен күпкә җиңеләйтә. Л. Будагов моның белән генә чикләнми, ул да, югарыда күрсәтелгән авторлар кебек, сүзләрнең килеп чыгышына игътибар итә, сүзләр янына аларның кайсы телдән керүләрен дә искәртеп үтә. Моның өчен махсус кыскартылмалардан файдалана: а.=арабское, алт.=алтайскаго, баш.=башкирскаго, бух.=бухарскаго, каз.=казанскаго, кир.=киргизскаго, п.=персидскаго, тур.=турецкое. Бу күренеш сүзлек белән эшләүне җиңеләйтә һәм аның үзкыйммәтен тагын да арттыра.

Л.З. Будаговның «Сравнительный словарь турецко-татарских наречий...» хезмәтендә китерелгән сүзләр гаять күп һәм алар төрле өлкәләргә карый. Сүзлектәге сүзләрне туганлык атамалары, ашамлык, үсемлек исемнәре, кием-салым, тукыма, савыт-саба, эш кораллары, предметлар, географик атамалар һ.б. тематик төркемнәргә берләштерергә була.

Сүзлекнең тагын бер мөһим ягы итеп анда теркәлгән мәкаль-әйтемнәрне күрсәтергә була. Алар арасында хәзер кулланылыштан төшеп калган мәкаль-әйтемнәр дә бар: *Җаман катын үлсә, түшәк җаңарыр, җакшы катын үлсә – баш каңгырыр.* (каз. II т., с.19)

Югарыда әйтелгәннәргә нәтиҗә ясап, сүзлекнең түбәндәге мөһим үзенчәлекләрен билгеләргә кирәк: күп кенә сүзләр этимологик чыгышлары ягыннан аңлатыла (күп очракта бик уңышлы); терминнарда (административ, хокукый, фәнни, дини һ.б.) еш кына тиешле чыганак һәм әдәбиятка сылтамалар белән кыскача аңлатмалар китерелә; географик атамалар, төрки эпос һәм фольклор геройлары исемлеге, тормыш чынбарлыклары һәм төрки халыкларның гореф-гадәтләрен белдергән кайбер сүзләр, кагыйдә буларак, кыскача аңлатмалар белән тәэмин ителә. Бу мәгълүматлар сүзлекне аңлатмалы, этимологик һәм өлешчә энциклопедик сүзлекләргә хас әһәмиятле үзенчәлекләр белән баеталар. Шушы чыганакларга нигезләнгән Л.З. Будагов сүзлеге борынгы төрки әдәбиятны һәм тарихи әсәрләрне укыганда бик яхшы ярдәмче була ала.

XIX гасыр ахырында миссионерлар җәмгыяте тарафыннан христиан динен пропагандалаган китаплар бастырыла. Рус булмаган халыкларга христиан дине тәгълиматларын өйрәтү шул халыкның милли телен яхшы белүне таләп итә. Шул максаттан христиан миссионерлары төрле телләрне, шул исәптән татар телен дә бик җентекләп үзләштерәләр. Җәмгыять ике телле сүзлекләр бастырып чыгара башлый. Шушы басмалар арасында Н. Остроумовның 1876 нчы елда чыккан «Первый опыт словаря Остроумова народно-татарского языка по выговору крещеных татар Казанской губернии», һәм 1892 елда дөнья күргән «Татарско-русский словарь» исемлехезмәтләре бар.

Н. Остроумов – йөзләгән басма хезмәтләр авторы. Алар арасында **«Первый опыт словаря Н. Остроумова народно-татарского языка по выговору крещеных татар Казанской губернии» (1876) һәм «Татарско-русский словарь»** (1892) аеруча игътибарга лаек.

Беренче сүзлек (1876) Казан император университеты типографиясендә басыла һәм керәшен мәктәпләре өчен файдалы кулланма итеп тәкъдим ителә. Бу сүзлек 145 биттән гыйбарәт. Кереш өлешендә татар теленең тарихы, грамматикасы, фонетика һәм морфологиясе турында тулы мәгълүмат бирелә.

Н.П. Остроумовның 1892 нче елда чыккан «Татарско-русский словарь» китабын миссионерлар җәмгыяте сүзлеге дип йөрткәннәр. Сүзлек өч кеше: Н. Ильминский, Н. Остроумов һәм А. Воскресенский тарафыннан төзелгән. Ләкин беренче булып бу эшне Н. Остроумов башлый. Ул сүзләрне туплый, терки, ә Н. Ильминский сүзлекне бастыра, А. Воскресенский Н. Ильминскийның ярдәмчесе була һәм аның эшен дәвам итә. Бу хезмәт 244 биттән гыйбарәт, барлыгы 1710 сүзне берләштерә.

Н.П. Остроумовның һәр сүзлегенә аерым тукталып үтик. 1876 елда дөнья күргән сүзлек лексик яктан бик бай. 1892 елда чыккан сүзлектән аермалы буларак, монда искергән, диалектларда гына сакланган, яисә бөтенләй сөйләм теленнән төшеп калган сүзләр күбрәк урын алган. Алда каралган сүзлекләрдән аермалы буларак, Н. Остроумов хезмәтләре бары тик кирилл графикасында гына язылган, ә сүзләр рус алфавиты тәртибендә урнаштырылган. Бу сүзлекләрне төзегәндә, Н. Остроумов төп максат итеп әлеге хезмәтләр ярдәмендә татар халкын христиан дине белән таныштыруны куя. Бу китаплар миссионерлык максатларын тормышка ашыру һәм миссионерлар мәнфәгатен яктырту белән беррәттән, рус халкына татар телен өйрәтүдә зур эш башкаралар. Бу сүзлекләр чыгуда, миссионерләр теләгеннән тыш, җәмгыяви ихтыяҗ да төп урынны алып тора.

Н.П. Остроумовның 1876 нчы елда чыккан хезмәте «сүзлек» дип аталса да, ул үз эченә татар халкы тарихы, татар теле, мөселманнар, миссионерлар турындагы бай материалны ала. Моннан тыш, Н. Остроумов сүзләрне фонетик, морфологик яктан яктан анализларга тырыша. Авазлар күчешен, авазларның бер-берсенә ничек тәэсир итүен, иренләшү-иренләшмәү, аваз өстәлү, кыскартулар үрнәкләрен ачык мисаллар белән күрсә. Мәсәлән: *сапля* – цапля (б. 21), бу – *быу* (б.61), китер – *килтер* (б. 90) һ.б.

Морфологик яктан тикшергәндә, Н.Остроумов күбрәк фигыльләргә игътибар итә, ләкин фигыльләрне теркәүдә бертөрлелек сакланмый, мәсәлән: *булмыш* (б.61), *әйтештер* (б. 58).

Н.Остроумовның 1892 елгы сүзлегенең төзелешенә килгәндә, хезмәтнең кереш өлеше бик кыска язылган. Анда бары тик татар хәрефләренең язылыш тәртибе һәм тыныш билгеләре турында гына берникадәр мәгълүмат бирелгән. Ләкин төп өлеше, ягъни сүзлек – лексиканың байлыгы, сөйләшләрнең төрлелеге, искергән

сүзләрнең, гарәп-фарсы алынмаларының аз булуы белән аерылып тора.

Н.П. Остроумовның 1892 елда дөнья күргән хезмәтендә түбәндәге аңлатма бирелә:

I. а) сүзләрдә рус хәрефләренең кулланылышы;
ә) басым;
б) татар сүзләренең әйтелеше.

II. Татар теленең этимологиясе:
а) сузыкларның яңгыраш закончалыгы;
ә) тартыкларның яңгыраш закончалыгы;
б) кушымчалар;
в) исемнәр, сыйфатларның һ.б. зат, сан, заман белән төрләнеше;
г) фигыльләрнең килеш белән төрләнеше;
д) фигыль – сүз төркеме буларак;
е) җөмләдә сүзләр кулланылышы.

III. а) Рус хәрефләренең тәртибе;
ә) русча-татарча сүзлек;
б) туганлык терминнары таблицасы.

Н. Остроумов, сүзлекләрендә диалекталь, искергән, алынма сүзләр дә бар. Алар арасында иң зур урынны керәшен сөйләшләренә хас диалекталь лексика тәшкил итә. Диалекталь лексика проблемасы – искиткеч кызыклы, мавыктыргыч һәм тарихи яктан бик мөһим мәсьәлә. Бу мәсьәлә үзенә аерым игътибар итүне сорый.

Н. Остроумов сүзлеге алдагы сүзлекләрдән гадилеге, җиңеллеге белән аерыла. Сүзлек, нигездә, халыкның җанлы сөйләменә тыяна. Шул сәбәпле, югарыда билгеләгәнчә, сүзлектә диалекталь берәмлекләр шактый зур урын алып тора.

Татар теленең бай тарихи язма әдәбиятында сүзләрнең искергән мәгънәләрен күп табарга мөмкин. Безнең телебездә югалган мәгънәләр кайбер башка төрки телләрдә яисә диалектларда, сөйләшләрдә яши. Н.Остроумов сүзлекләреннән иллегә якын искергән лексик берәмлек бар. Бу сүзләр иҗтимагый-тарихи шартларның үсүе-үзгәрүе нәтиҗәсендә актив кулланылыштан төшеп калганнар һәм шул чорга караган сүзлекләрдә генә теркәлгәннәр.

«К. Насыйриның **«Татарча-русча лөгать китабы»** 1859 елда ук төзелә башлый. Ләкин басылып чыгуы ни өчендер соңарган»

(Хангилдин, 1948: 80 ). Бу сүзлекнең дөнья күрүендә китап сәүдәсе белән шөгыльләнүче Фәтхулла Хәмидулла улы Амашевның ярдәме зур була. Китап 1878 елда басылып чыга. Сүзлек иң беренче чиратта ике максатны күз уңында тота: ул татарларга рус теле, русларга татар телен өйрәтүдә куллану өчен әһәмиятле гамәли кулланма хезмәтен үти. Күләме – 120 бит, ул үз эченә 2923 сүзне ала. Хәзерге чорда галимнәр һәм укытучы-практиклар әйтүенчә, 1500–3000 сүз теге яки бу телдә иркен аралашу өчен җитәрлек лексик база санала. К. Насыйри, үзенең укыту тәҗрибәсеннән чыгып, әлеге фикерне инде 120 ел элек дәлилләгән була. «Татарча-русча лөгать»нең керешендә К. Насыйри татар һәм рус телләре фонетикасы турында кыскача мәгълүмат бирә. Кереш өлештә «Рус азбукасында хәрәкәткә йөри торган хәрефләр», «Слоглар», «Ударение бәянында» исемле бүлекләр булу шул турыда сөйли. «Урысның берничә төрле гласный хәрефләре өчен бары үземезнең шул өч хәрефемезне истигъмаль кылмак кирәк, әмма бу мөмкин түгел», – ди К. Насыйри. Рус телендә хәрефләрнең ике төрле, ягъни баш (зур) һәм юл (вак) хәрефләре булуын, сулдан-уңга язылуын да искәртеп үтә. Бу ике телдә иҗек һәм басымның уртак һәм үзенчәлекле якларын билгели. Басымның татар телендә, гадәттә, сүз ахырында, ә рус телендә төрле иҗектә килә алуын һәм басымга карап мәгънә үзгәрүен ассызыклый: «Аларның бәгъзе кәлимәләре бар, бер рәвешле языла, әмма ударениесенә карап, мәгънәгә даләләт кыйладыр. Мондаен хосусларда алар ударение галәмәтен куймакны зарур күрәләр. Мәсәлән: *газаб* – мука, *он* – мука». Керешнең соңгы өлешендә «урыс хәрефләренең кайсы хәрефләр бәрабәренә әйтелүе» дип, алфавит тәкъдим ителә. Автор укучыга сүзлекнең кереш өлеше белән танышырга һәм анда әйтелгән фикерләргә игътибар итәргә кирәклеген искәртә: «Бу лөгать китабындан бер файда хасил итим дигән адәм ошбу безнең язылмыш мөкаддимәмезне мөтәләга кыйлып (укып), үз галәмәтләренең вадигын (куелышын) белсеннәр» (Насыйри, 1878: 3). Күргәнебезчә, галим тарафыннан бик акыллы һәм үтемле кереш сүз язылган. Ул – татар телен өйрәнергә теләүчеләргә бик файдалы методик ярдәм хезмәтен үти.

Бу сүзлек үзенең төзелеш принциплары белән хәзерге сүзлекләргә бик якын. Анда сүзләр алфавит тәртибендә урнаштырыла. Сүзләр дүрт баганага бүленә: беренче баганада – гарәп алфавиты тәртибендә, гарәп графикасында татарча сүз; икенчесендә – сүзнең рус хәрефләре белән транслитерациясе, ягъни рус

хәрефләре белән язылган татар сүзе; өченче баганада – сүзнең русчага тәрҗемәсе; дүртенче баганада рус сүзләр гарәп хәрефләре белән бирелә. Әлеге алым XIX гасырда киң кулланылышта була, бу чорда дөнья күргән татар теле үзөйрәткечләрендә дә чагылыш таба. Монда галимнәр тел өйрәнүчеләр өчен ике телнең фонетик мөмкинлекләрен, әйтелеш һәм язылыш үзенчәлекләрен бирергә тырышканнар. Әлбәттә, бу алым телне җиңелрәк үзләштерергә ярдәм иткән.

К. Насыйриның 1892 елда дөнья күргән русча-татарча сүзлеге XIX гасырның икенче яртысында төзелгән сүзлекләр арасында аеруча күренекле лексикографик хезмәтләрдән санала. Сүзлекнең тулы атамасы – «Рус хоруфы һиҗасы үзрө мөрәттәб лөгать китабы» = «Полный русско-татарский словарь с дополнением из иностранных слов, употребляемых в русском языке как научные термины». Ул 264 биттән гыйбарәт һәм иң күләмле сүзлекләрнең берсе буларак билгеле.

Күренекле тел белгече В. Хангилдин билгеләвенчә, «К. Насыйри бу сүзлекне турыдан-туры татарларга рус теле өйрәтү өчен белешмәлек, кулланма итеп төзегән» (Хангилдин, 1948: 82). «Русча өйрәнүчеләргә бераз нәсыйхәт» исемле кереш сүзендә автор бу хезмәтенең 35 еллык эш тәҗрибәсе икәнлеген әйтә, «бу вакытка кадәр бездә тел өйрәнү юк иде», – ди. Рус телен өйрәнүгә карата киңәшләр бирә, дүрт таләпне шарт итеп куя: 1) аерым сүзләрне белү, аларны, җиләк җыйганда үзең дә сизмәстән, чиләк тутырган шикелле, әкрен-әкрен үзләштерү; 2)авазларның әйтелешен белү; 3) өйрәнелә торган телнең морфология Һәм синтаксисын белү. «Телне конвертларда адрес язу өчен генә өйрәнергә ярамый, чөнки мондый максаттан чыгып өйрәнүчеләр бервакытта да теләкләренә ирешә алмыйлар», – ди К. Насыйри һәм телне өйрәнүнең чагыштырма метод базасына корылган булырга тиешлеген дә әйтеп уза; 4) рус префиксларының үзенчәлекләрен исәпкә алу (Насыри, 1892: 3-5). Автор тарафыннан бирелгән бу тәкъдим-киңәшләр бүгенге көн өчен дә актуаль яңгырый.

Сүзлеккә шул чор рус әдәби телендә кулланылган рус сүзләре, шулай ук алынмалар теркәлгән. Бу турыда автор үзе хезмәтенең титул битендә әйтә: «Рус кәлимәләренең мәгънәсе тәфсыйлән бәян кылынып, хәрфе җәрле (предлог, приставкалы) фигыльләр дә, вә дәхи һәрбер хәрфе җәрнең мәүзугы ләһ (үзенә хас) мәгънәләре дә

тәфсыйлән бәян кылынды. Янә рус кәлимәләреннән башка рус телендә мөстәгъмәл булучы әҗнәби лөгатьләр (чит тел сүзләре), рус телендәге фөнүне шәтта истыйлахлары (төрле фәннәргә караган атамалар) – күбрәк чит тел сүзләредер, зикер кылынды».

Сүзлекнең төзелеш методикасына килгәндә, автор үз хезмәтендә төрле алымнарны куллана. Сүзләргә тәрҗемә ясаганда, туры тәрҗемә, синонимнар белән тәрҗемә итү һәм аңлату юлы белән сүзләргә шәрехләү алымы киң файдаланылган. Кайбер урыннарда сүзлек аңлатмалы сүзлеккә охшап китә. Әлбәттә, сүзләрнең эквивалент тәрҗемәсенә меңләгән мисаллар китерергә мөмкин, мәсәлән, аистъ –له لك لقلق (с. 5), барсъ – قبلاق (с.7) һ.б.

Күп очракларда эквивалент тәрҗемә һәм синонимнар белән тәрҗемә алымы килеп керә. Синонимик рәттә татар сүзләре белән бергә гарәп-фарсы алынмалары да теркәлеп бара. Моңа мисал итеп түбәндәге сүзләрне күрсәтә алабыз: армия – لشكر عسكر(с. 6), арбузъ – بطيخ خفر خربو زه قار بو ز (с. 6)

Аңлату юлы белән бирелгән берәмлекләр сүзлеккә теркәлгән рус я европа сүзләрен татар укучысына тирәнтен аңлау мөмкинлеген бирә. Мәсәлән, аллея – اعاج ارا سنداعي يءللار(с. 5), ампутация – ادمنهرنك بر اعضاسى كيسوب الؤ (с. 5), актер – ثماشا حانه ده اوينا وحي تاش صاوث وحولماق كبك نهرسه كرننك طشندا بىا لا سيمان نرسهدر (с. 5), глазурь – (с. 30), акробатъ – ارقان اوستونده اوينا و جى (с. 5).

Үзенчәлекле терминнар, татар теле өчен чит атамалар гарәп-фарсы алынмалары я аңлату юлы белән тәрҗемә ителәләр. Кайбер очракларда ике юл бергә кушыла. Мәсәлән, атом – ذرب جزئ لا يثجزي, барбарис – عببر نار يس بر باريس, архитектор – مهندس معمر

«Русча-татарча» сүзлеккә 18 меңгә якын берәмлек алынган. Лөгатьлектә сүзләр рус алфавиты тәртибендә урнаштырылып, шул чор орфографиясе белән язылган. Тәрҗемә өлешендәге сүзләр гарәп графикасында бирелгән. Китапның соңгы битендә һәр хәреф буенча сүзләрнең башланган бит санын күрсәткән таблица урнаштырылган. Шулай итеп, К. Насыйри сүзлекнең техник төзелешен дә заманындагы алдынгы үрнәкләр нигезендә, рус сүзлекләре төзелеше кебек формалаштырган.

«Русча-татарча сүзлек»нең ахырында К. Насыйри «Әлфаз әҗнәбия», ягъни «Чит сүзләр» исемле баш астында рус теленә башка телләрдән кергән сүзләр һәм терминнар сүзлекчәсе урнаштыра. Бирердә *артиллерия, антропология, барометр* кебек 1700 гә

якын иҗтимагый-сәяси, фәнни-техник терминнар урын ала. Рус телендәге бу алынмаларга татар телендә аңлатмалар бирү, тәрҗемә итү сүзлекнең кыйммәтен тагын да арттыра һәм бу күренеш үз чоры өчен зур яңалык булып тора.

XIX гасырда төрки халыкларның телләрен, фольклорын һәм этнографиясен өйрәнүдә православ миссионерлар зур роль уйнаганнар. Христиан рухани уку йортларының татар теле укытучылары да әлеге хәрәкәт тарафдарлары булганнар. Алар камил татар теле дип керәшен сөйләшләрен санаганнар һәм шул шивәләрдә дәрес биргәннәр, татар телен шул җирлектә өйрәткәннәр.

Православ миссионерлар татар лексикографиясе өлкәсендә дә зур эз калдырганнар. Миссионерлар җәмгыяте төзегән **«Краткий татарско-русский словарь с прибавлением некоторых славянских слов с татарским переводом»** сүзлеге биш тапкыр басылып чыга (Казань, 1880. – 55 с.; 1882. – 55 с.; 1886. – 96 с.; 1888. – 96 с.; 1891. – 96 с.), ләкин алар өйрәнелмәгән, теркәлгән лексик берәмлекләр тикшерелмәгән.

Сүзлекнең ике басмасы М.А. Гладышева, 1886 елда чыкканы М.А. Чиркова типографиясендә басыла, ә соңгы ике басманың типографиясе күрсәтелми.

Алда әйтелгәнчә, сүзлекнең биш басмасы дөнья күрә. Аларның форматы – 10 х 17,5, структур яктан тематик принципка нигезләнеп төзелгән. Өч басма бер-берсеннән аерылмый, дүртенче, бишенче басмаларның күләме зуррак. Авторлар соңгы басмаларга яңа сүзләр, яңа тематик төркемнәр, грамматик материал өстиләр.

1880 елда М.А.Гладышева типографиясендә басылып чыккан **«Краткiй татарско-русскiй словарь съ прибавленiемъ некоторыхъ славянскихъ словъ съ татарскимъ переводомъ»** сүзлегенә киңрәк тукталырбыз.

Сүзлек 55 биттән тора, тематик принципка нигезләнеп төзелгән, барлыгы 43 төркем, шулар кысасында 983 сүз теркәлгән.

Төркемнәрнең исемнәре татарча һәм русча бирелгән: *ишек алдындагы каралдылар – строенiя на дворе, ашамлыклар – съедобное, жорт кошлары – домашнiя прицы, сугыш кораллары – оружiя, кейемняр – одежды, агач атлары – названiя деревьевъ, доньа жаклары – страны света, багыт – время, акча исабе – денежный счетъ, улчяуляр – весы, буйга улчяу – меры протяженiя, сыйык нястяне улчяу – меры жидкости, ой – домъ, ой эчендяге*

*настяляр – вещи въ доме, жимешляр – плоды, гомбяляр–грибы, куренмей торган нястяляр – предметы отвлеченные, уйынчыклар – игрушки, чиркяу айберляре – церковныя вещи, укыту нястяляре – учебныя вещи, тешлей торган ыуак жяннекляр – насекомыя, кейекляр – звери, жирянгеч жяннекляр – гады, жорт терлекларе – домашнія животныя, эчемнекляр – напитки, кеше тяненен саннары – состав человеческаго тела, ындырдагы нястяляр – вещи на гумне, кыр кошлары – дикія птица, урман кошлары – лесныя птица, ауадагы нястяляр – предметы небесные, бакча – огородъ, мунча – баня, жир – земля, тосляр – цвета, балчык эчендяге нярсяляр – металлы, ташлар – камни, нястянен ничеклеге – качества, ден сюзляре – слова веры, балта остасынын кораллары – плотничьи инструменты, тимерче – кузнецъ, ашлыклар – хлеба, улямняр – растенія, кыйлану сюзляре – глаголы*[2]. Бу сүзлекләрне төзүчеләр Казан университеты профессоры миссионер Николай Ильминский алфавитын кулланып эш иткәннәр.

Сүзлектә төрле сөйләшләргә хас булган диалекталь берәмлекләр дә бар, ләкин алар күп түгел: *бистяр – полотенце* (с.6), *туйра – дубнякъ* (с.7) *эт бороно – шиповникъ* (с.8) һ.б.

Сүзлектә урын алган лексик берәмлекләр арасында рус алынмалары шактый күп. Аларның күбесе татар теленең фонетик закончалыкларына буйсынган, телдә эквивалентлы булмаган берәмлекләр, мәсәлән, *клят – клеть* (с.3), *прянник – пряник* ( с.4), *эштей – щи* (с.4) һ.б.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, бу сүзлек тел өйрәнүчеләр өчен бик уңайлы булган, чөнки авторлар икенче телгә өйрәтүнең бөтен нечкәлекләрен белеп эш иткәннәр. Көндәлек аралашу өчен кирәкле иң актив берәмлекләрне генә туплау, аларны тематик төркемнәргә аерып бирү, телгә хас фонетик закончалыкларын язуда чагылдырырга тырышу, тәрҗемә иткәндә, нигездә, эквивалентлар белән эшләү аларның тәҗрибәле, оста лексикограф булулары турында сөйли.

Ш. Рәхмәтуллин (Шиһабетдин Габделгазиз ) татарларны рус теленә өйрәтүгә дә үзеннән өлеш кертә. Ул сүзлекләр, үзөйрәткечләр авторы буларак та билгеле. Аның ике сүзлеге безгә мәгълүм.

Ш. Рәхмәтуллинның Ш. Габделгазиз исеме белән басылган **«Татар теленнән русчага һәм урыс теленнән татарчага тәрҗемә лөгать яки словарь»** исемле хезмәте 1893 елда Казан

[2] Сүзләрнең язылышы нәкъ сүзлектәгечә бирелде.

университеты табгыханәсендә басыла. Китап 15х23 см форматта, 72 битле. Сүзлекнең исеме русча да бирелгән: «Перевод съ татарскаго на русский языкъ или словарь». Исеменнән соң: «Бу тәрҗемәдә һәр затны җенесе вә нәүгысы илә аерым фасылларда бәян кылынгандыр, таки бер мәгълүм нәрсәнең исемени белмәк ирадә кылындыкта дәфгатән табу асан булсын өчен» дип куелган. 1892 елның 28 гыйнварында Санкт-Петербург цензурасы сүзлекне бастырып чыгарырга рөхсәт бирә. Сүзлекнең авторы Шиһабетдин Габделгазиз дип күрсәтелгән.

Сүзлек, алда әйтелгәнчә, аерым өлешләрдән тора. 40 бүлектә 1781 сүз тупланган, алар түбәндәге тематик төркемнәргә берләшә: «Адәм тәненең әгъзалары», «Кардәш-ыругларның исемнәре», «Кеше», «Киемнәр», «Ашамлыклар», «Үсемлекләр», «Хайваннар» һ. б. Сүзлектә алфавит тәртибе сакланмаган, һәр тематик төркемдә мәгънәләре охшаш, тамырдаш сүзләр янәшә урнашкан.

Сүзләр гарәп һәм рус хәрефләре белән язылган. Битнең сулъяк яртысында татар сүзе, уң ягында рус сүзе гарәп һәм рус хәрефләре белән күрсәтелгән.

Сүзлек ахырында «Җөмләләр һәм өзекләр» китерелгән. Бу җөмләләр гадидән катлаулана барып бирелгән. Алар арасында үгет-нәсыйхәт характерындагы әйтемнәр, философларның сүзләре бар. Хезмәтнең ахырында мәкальләр тәрҗемә ителгән.

Күләме ягыннан зур булмаган әлеге сүзлеккә бай лексик материал теркәлгән. Автор бары тик сөйләмдә актив кулланыла торган берәмлекләрне генә бирергә тырышкан. Сүзлек һәрьяктан да XIX гасырда дөнья күргән күпсанлы татар теле үзөйрәткечләренә бик якын. Бу ягы белән ул башка сүзлекләрдән аерылып тора.

Сүзләрне тематик төркемчәләргә бүлеп урнаштыру тел өйрәнүчеләрнең хезмәтен күпкә җиңеләйткән. Сүз төркемнәренә игътибар итү, аларга хас грамматик категорияләрне мисалларда гына күрсәтү Ш. Габделгазизнең чит тел өйрәтү методикасын яхшы белүе турында сөйли.

1894 елда А. Воскресенский **«Русско-татарский словарь»** китабын бастырып чыгара. Сүзлек 374 биттән тора, кереш сүз юк. Бары тик рус хәрефләренең урнашу тәртибе, ягъни рус алфавиты гына күрсәтелә. А.Воскресенскийның әлеге сүзлеге керәшен-татар мәктәпләрендә кулланыла торган төрле пособиеләрдәге сүзләрдән

һәм Казан губернасының керәшен авылларыннан җыеп кайткан сүзләрдән төзелә.

А. Воскресенский сүзлеге искиткеч тулы, төгәл итеп эшләнгән. Автор рус сүзләренең татар телендәге эквивалентларын табарга тырыша. Даими рәвештә булмаса да, сүзләрнең кулланылыш даирәсен күрсәтеп китә. Мәсәлән: Агнецъ (ц.сл.) *бярян, Алла бяряне. Агнецъ непороченный монсоз бярян, пасха бяряне* (с. 1), *бабка (игральная кость) кузна* (с. 3).

А. Воскресенский сүзләрнең тәрҗемәләрен бирү белән генә чикләнми, күп очракта ул сүзнең куллану мөмкинлекләрен күрсәтә, сүзтезмәләр составында сүзнең урынын билгели: *деньги – акча* (*вообще*), тянкя (*серебряныя*, которыя назыв. также и комош акча). *Бумажныя* деньги кагаз акча. *Золотыя* деньги алтын акча. *Деньжонки* акча-мокча, акча асяре. За деньги продать *акчага сат* (с. 53).

Сүзлекнең тагын бер үзенчәлекле ягы – сүзләргә аңлатма биреп тәрҗемә итү: *касса – касса* (акча сала торган төш) (с. 101), *налогъ – налогъ* (айбер очен казнага тюляу) (с. 143), *профессоръ – профессоръ* (Академия белян Университетта ойрятеуче) (с. 259), *вакса – вакса* (итек чистарта торган нястя) (с. 17). Мисаллардан күренгәнчә, бу ысул татар телендә рус сүзләренә туры килә торган эквивалент булмаган очракларда кулланыла.

А. Воскресенский сүзлеген үзенең составы ягыннан Н.Остроумов сүзлекләренә бик якын. Бу уртаклыкны автор үзе дә күрсәтә, чөнки аларның максатлары, бурычлары бер була. Ләкин сүзлекләр беренче телләре белән аерылалар. Н. Остроумов сүзлекләре татарча-русча итеп төзелгән булса, А.Воскресенский беренче тел итеп рус телен ала. Аңлатма бирү алымнары ике сүзлектә дә бер типта эшләнгән, сүзләрнең бирелү рәвеше дә бер үк төрле, тәрҗемә ителергә тиешле берәмлек калын хәрефләр белән тәкъдим ителә.

1894 елда Казан Император Университеты типографиясендә Е. Неклюдовның **«Словарь-самоучитель 1500 татарских слов»** хезмәте басылып чыга. Бу кулланма татар телен үзлегеннән өйрәнүчеләргә адресланган. Автор аны бигрәк тә Себер төбәгендә яшәүчеләр өчен дип ассызыклый. Сүзлек-үзөйрәткечкә 1500 сүз теркәлгән. Алар рус алфавиты тәртибендә урнаштырылган. Сүзләр башта русча бирелә, татар теленә тәрҗемә ителә һәм гарәп графикасына транслитерация ясала:

*Бог – Алла, Тәңре, Худай*

*Бровь – каш*

*Бабушка – эбий, улкун ана* (с.8)

Кулланма кесә сүзлеге форматында төзелгән. Автор аны Себер җирлегендә сәүдә эшләрендә ярдәмче булсын дип эшли. Татар теленең төрки халыклар белән аралашуда кирәклеген сүзлекнең кереш мәкаләсендә аңлатып китә.

Хезмәтнең ахырында кушымта формасында һинд саннары таблицасы бирелә. Бу саннар рус һәм татар теленә тәрҗемә итеп күрсәтелә.

1894 елда К. Насыйри **«Гөлзар вә чәмәнзар»**га аерым сүзлек китабы бастыра. Бирелә 313 үсемлекнең русча, татарча атамалары күрсәтелгән. Безнең төбәктә үскән 192 дару үләненә аңлатма бирелә. Китап Октябрь революциясенә кадәр татар халкы арасында бик популяр була. Аның 1903 елда кабаттан басылуы да шуны дәлилли.

Бу хезмәттә ботаника һәм медицинага караган күптөрле терминнар урын алган. Төп терминнар татарча, русча һәм латинча китерелә:

*Гөлбәдран –рябинка –tanacetum* (23);

*Үги ана яфрагы – мать и мачеха – tussitago* (22);

*Тимер үлән – железняк аптечный – verda officinalis* (27);

*Мәтрүшкә – душица обыкновенная – origanum vulgare* (26) һ.б.

Кайбер очракларда үләннәрнең гарәпчә исемнәре дә күрсәтелә: *ишәк колагы – живокость аптечный – symphutum officinale – әзән әл-химар, гарәпчә* (31), *бөтнек үләне – мята – mentha – нәгнәг* (31) һ.б.

Кайчакта төп термин гарәпчә бирелеп, аңа татарча тәңгәллекләр китерелә: *гаттас – гатәсә үләне, ягъни төчкерек уты* (22) һ.б.

Татар телендә әзер исемнәре булмаган төшенчәләрне биргәндә, К. Насыйри тәрҗемә методы һәм калькалаштыру алымнарыннан файдалана: *ангелика – фәрештә уты* (29), *ааронова борода – һарун сакалы* (57), *меңъяфрак – тысячилистник* (21), *красавица маргаритка – гүзәл гаурәт* (55) һ.б.

Каюм Насыйриның «Гөлзар вә чәмәнзар» хезмәтендә рус алынмалары да чагылыш таба. Бу берәмлекләр арасында *миндаль, керән, кәбестә* кебек берәмлекләр бар.

Китапның ахырында үләннәрнең гарәпчә-татарча исемлеге теркәлгән, нинди авырулардан кулланылуы турында мәгълүмат бирелгән.

Каюм Насыйриның **«Ләһҗәи татари»** сүзлеге – ике томлы хезмәт. Беренче томы – 1895, ә икенче томы 1896 елларда Казан университеты типолитографиясендә басылган. Беренче өлеше, «ا» (әлиф), «ص» (сад) хәрефләрен үз эченә алып – 226, икенче өлеше, «ض» (зад), «ی » (йай) хәрефләрен үз эченә алып, 107 биттән тора. Сүзлеккә ун мең ярым чамасы лексик берәмлек беркетелгән. Алар арасында сүзтезмәләр һәм фразеологик берәмлекләр дә бар. Автор аларга семантик-грамматик һәм этимологик аңлатмалар бирә. Генетик яктан караганда, төп өлешне төрки-татар сүзләре тәшкил итә, гарәп-фарсы алынмалары да сүзлектә теркәлгән. Сүзлек үзенә язма һәм сөйләм теленә хас тел үрнәкләрен берләштерә, шул чорда киң кулланылышта булган тел байлыгын чагылдыра.

«Ләһҗәи татари» да сүзләрнең мәгънәләре төрле юллар белән аңлатыла. Монда сүзләрнең синонимнарын бирү, күпмәгънәлелекне күрсәтү – барысы да кулланыла.

Сүзләр гарәп алфавиты тәртибендә 33 хәреф астына урнаштырылган. Сүзлектә һәр сүз аерым мәкалә итеп формалаштырылган. К. Насыйри баштагы берничә хәрефкә аның исеме, нинди санга туры килүе, алфавиттагы урыны, яңгырашы турында белешмә бирә, ә калган хәрефләрнең нинди санга туры килүен генә күрсәтә.

«Ләһҗәи татари» сүзлегендә мөстәкыйль сүзләр дә, ярдәмлекләрдә чагылыш таба. Аларның лөгатьлеккә теркәлү тәртибе, нигездә, татар теленең өч томлы аңлатмалы сүзлеге кагыйдәләренә туры килә. Автор аерым лексик берәмлекләр итеп төрле аффикс һәм кисәкчәләрне дә лөгатьлеккә урнаштырган. Сүзлекләрнең күпчелегенә К. Насыйри грамматик характеристика бирә, ягъни кайсы сүз төркеменә караганлыгын, грамматик мәгънәсен искәртеп бара. Бу – хәзерге көн сүзлекләр төзүдә кулланылган принцип.

Каюм Насыйриның «Ләһҗәи татари» сүзлеге – татар лексикографиясендә беренче аңлатмалы сүзлек буларак зур кыйммәткә ия булган язма истәлек. Әлеге сүзлек турында җентекле анализ хезмәтнең 12 нче бүлекчәсендә бирелгәнлектән, монда гомуми күзәтү белән чикләнәбез.

XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр арасында төрле максатларда чыгып төзелгән төрле

күләмле хезмәтләр бар. Кайбер сүзлекләр уку әсбапларына ярдәмлек, тел өйрәнүчеләргә кулланма итеп эшләнгән булсалар, икенчеләре зур күләмле энциклопедик характердагы ике телле сүзлекләр булып торалар. Алар, нигездә, әдәби тел материалына таянып төзелгәннәр, ләкин шул ук вакытта татар теленең төрле сөйләшләренә нигезләнгән, диалектологик сүзлек дип аталырлык хезмәтләр дә бар.

Гомумән алганда, XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр телебезнең бер гасырлык лексик мирасын туплаган бик кыйммәтле хәзинә булып торалар. Аларны өйрәнү, сүзлекләргә теркәлгән сүзләрне лингвистик яктан тикшерү, алар ярдәмендә телебезнең сүзлек составының бер гасырлык үсешен, хәрәкәтен күзәтү татар теленең лексикология фәненә, тарихи лексикологиягә бик зур өлеш кертер дип уйлыйбыз.

## § 8. XX гасыр башы сүзлекләре (1900–1918 еллар)

Татар лексикографиясенең XIX йөздәге уңышлы тәҗрибәсе XX гасырда тагы да колачлырак төс ала. Төрле сәяси вакыйгаларга, иҗтимагый һәм мәдәни үзгәрешләргә бай булган XX гасыр башында татар сүзлекләре тарихы тагы да байый, бу елларда татар теленә мөнәсәбәтле дүрт дистәгә якын сүзлек дөнья күрә. Алар арасында татарча-русча, русча-татарча, терминологик һәм тематик, орфографик, берничә тел сүзлекләре һ.б. бар.

Бу хезмәтләр төрле авторлар тарафыннан, төрле урыннарда төзелгәннәр, шуңа күрә алар бер-берсен кабатламый, теркәлгән сүзләрнең саны да төрлечә, хәтта бер үк авторның төрле елларда басылган бер исемдәге хезмәте дә берникадәр аерыла, алар вакыт сынавын үтә-үтә камилләшкән, кулланучыга яраклаштырылган.

XX йөз башы – татар халкы, аның мәдәнияте, мәгарифе өчен гаять җаваплы, катлаулы чор. Бу елларда татарлар башлыча гарәп графикасын куллана, әмма язудагы төрлелекләр лексикографиягә дә тәэсир итми калмаган. Чөнки бу чыганаклар үз чорларында орфографик нормаларны тәртипкә салуда әһәмиятле роль уйнаганнар.

### Мирсәет Юнысов сүзлекләре

Чистай шәһәр мәдрәсәсенең рус теле укытучысы **М. Юнысов** төзегән **«Татарско-русскій словарь наиболѣе употребительныхъ словъ и выраженій»** сүзлеге ике гасыр чигендә (1900 ел) басыла.

Сүзлекнең күләме зур түгел – 114 бит. Бу хезмәттә 5 мең чамасы татар сүзен русчага тәрҗемә итү күздә тотыла. Лөгатьлек сүзләре гарәп алфавитына якын тәртиптә урнашалар (рус алфавиты тәртибе сакланмаган): А, Э, Б, Т, С, Дж, Х, Д, З, Р, Ш... Әлифба тәртибе (шулай әйтергә яраса) сүздәге беренче авазда гына исәпкә алынган. Эчтәлектә аерым авазларга башланган сүзләрнең кайсы битләрдә урын алуы күрсәтелгән (мисал өчен, Г – 71–73, Ф – 73–73, К – 74–89, Л – 89–89, М – 90–93 һ.б.). Китап рус телле укучыларга атап төзелгән булса кирәк, сүзлекнең татарча өлеше дә, русчасы да кириллицада бирелә. М. Юнысов татар теленең үзенчәлекле авазлары өчен кайбер өстәмә тамгалар да куллана: ӱ – [ү], ӧ – [ө], Ĥ – [ң], дж тезмәсе [җ] авазын белдерә һ.б. Шул рәвешчә, М. Юнысов татар сүзләренең яңгырашын рус хәрефләре белән төгәл чагылдырырга тырыша: *эбій* – бабушка, *элякь* – сплетня (15), *бльмяу* – незнаніе (33), *таджь* – вѣнецъ, *тӧшляну* – грёза (43), *сӧĤге* – рогатина, копье (53), *джилга* – рѣчка (57), *мясхяря* – срамъ, *мяĤгелекь* – вѣчность (93), *юрю* – хожденіе (106), *ӱлям* **(***ӱлянь***)** – трава (111), *ӧрлекь* – перекладина (114) һ.б.

Фигыльләр **-***мак/-мәк* формасында теркәлгән: *эрчемякь* [әрчемәк] – чистить (18), *бтрмякь* [бетермәк] – кончать (25), *слтямякь* [селтәмәк] – махать (51), *мазасызланмакъ* – беспокоиться (92) һ.б. Лөгатьлектә кайбер фигыльләрнең юклык формалары да урын ала: *аирмамакъ* [аермамак] – не разлучить (14), *башланмаганъ* – неочатой (33), *сыналмаганъ* – неиспытанный, *суглмаганъ* [сугылмаган] – небитый (49) һ.б. Сүзлектә аналитик төзелешле фигыльләр дә шактый. Алар русчага алкушымчалы (приставкалы) фигыльләр белән тәрҗемә ителәләр: *алштрыбъ алмакъ* – вымѣнить (11), *эрбь бетмякь* – растаять, *эшлябь алмакъ* – заработать (17), *ктӧбь тормакъ* – поджидаться (88), *ильтебь джиткзмякь* – доводить (98) һ.б.

Сүзлектә сүзгә-сүз тәрҗемә өстенлек итә, бу аның телне башлап өйрәнүчеләр өчен төзелүен күрсәтә: *ата-ана* – родители (5), *эйбрь* – вещь (19), *бакръ* – медь, *блан* – лось (32), *тярязя* – окно (43), *гярябя* – янтарь (73) һ.б.

Сүзлектә сыйфатларның өч род күрсәткече дә бирелә: *ару* (пакъ) – чистый, ая, ое (8), *бай* – богатый, ая, ое (27), *тозлы* – соленый, ая, ое (35), *джлы* – теплый, ая, ое (59), *кзылъ* – красный, ая, ое (78) һ.б.

Билге белдерә торган сүзләрнең кайбер дәрәҗә формаларын бирү сүзлекнең үзенчәлекләреннән санала ала: *аксылъ* – беловатый

(9), *ачерякь* – горше, кислѣе (15), *эрерякь* – крупнѣе (16), *экренрякь* – тише (19), *бикь начаръ* – очень дурной (23), *бигаять джумартъ* – чрезвычайно щедрый (29) һ.б.

Татар телендә род категориясе булмау тәрҗемәле сүзлекләрдә үзенә бертөрле кыенлыклар китереп чыгара. Бу мәсьәләне М. Юнысов түбәндәгечә аңлата: ир һәм хатын җенесен белдергән төшенчәләр янында *ир, хатын* сүзләрен куллана. Мәсәлән: *алдакчы ирь, алдакчы хатынъ* (7), *тгюче ирь, тгюче хатынъ* (34), *сатучы ирь, сатучы хатынъ* (52) һ.б. Хайван, кош-корт белән бәйле очракларда *ана, ата* сүзләре дә җенесләрне аеру вазифасын башкарган: *ана аю* (8), *ана бүре* (10), *ана казъ, ата казъ* (13), *ата кюркя, ана арсланъ, ана ишякь* (14) һ.б.

Күп мәгънәле сүзләр, омонимнар кайбер очракларда махсус билге (нокталы өтер) белән аерылган: *блязекь* – пясть руки; браслеты (33), *джазу* – разгибаніе; лишеніе (57) һ.б. Шулай ук сүзнең төрле мәгънәләре санап кына кителгән очраклар да бар: *трма* – грабли, борона, рѣдька (42), *сугышъ* – война, драка (51), *шырпы* – спичка, заноза (70) этажъ һ.б. Омонимнарның аерым сүз мәкаләсе булып теркәлгәннәре сирәк: *сафъ* – чистый, *сафъ* – рядъ (55). Сүзләрдәге рәвеш һәм сыйфат мәгънәләре тәрҗемәдә аерып күрсәтелгән: *кюЙелле* – весело, веселый (80), *вакытсыз* – безвременно; безвременный (94), *яхшы* – хорошо; хорошій (104), *юнь* – дешево; дешевый (108) һ.б.

Фразеологизмнар сүзлектә аерым сүзлек мәкаләсе итеп теркәлгәннәр: *ачыкъ аузъ* – ротозѣй, розиня (6), *акылданъ таймакъ* – съ ума спятиться (10), *эчь поша* – сердце ноетъ (17), *гакылданъ язмакъ* – ума лишиться (73), *кюзгя чалынмакъ* – броситься въ глаза, *кюздя кашъ кöтмякь* – ждать очи не смыкаючи (85), *ись китмякь* – пасть въ обморокъ (97) һ.б. Тотрыклы тезмәләр белән беррәттән ирекле сүзтезмәләр дә аерым сүзлек мәкаләсен тәшкил итәләр: *ачъ тормакъ* – голодать (5), *астка джяймякь* – подстилать (11), *ачы суукъ тӧнь* – морозная ночь (12), *балыкъ тотмакъ* – рыбу ловить (21), *кчкеня чилякь* – ведерка (85), *иртянге сӧть* – утреннѣе молоко (96) һ.б.

Бу хезмәт 1906 елда тагын бер кат басыла. Икенче басмада бераз үзгәрешләр дә бар.

1. Ул бу юлы татарларга атап төзелгән булырга тиеш, чөнки татар сүзләре башта гарәп хәрефләре белән язылган, аннары ки-

риллицада транскрипция бирелгән, соңыннан тәрҗемә вариантлары теркәлгән: آغا – *агъа – старший брат* (19), جيلس – *джиләс – прохладно* (94) һ.б.

2. Беренче басмада сүзлекнең бары тик русча исеме генә булса, икенчесендә ул аның татарча исемен дә тышлыкка чыгарган: «Иң истәгъмәл кыйлына торган сүзләрнең татарский-русский ыславаре»

ايك استعمال قيلنا تورغا ن سوزلرنك تاتارسكى- روسكى اصلاوارى .

3. Лөгатьлек бу басмада гарәп алфавитына нигезләнгән татар әлифбасы нигезендә төзелгән. Әмма алфавит тәртибе шулай ук сүзнең беренче авазында гына сакланган.

4. Сүзлекнең күләме бераз артса да (164 бит), сүзләрнең саны шулай ук калган, чөнки китапның бер битендә бер генә багана сүз бирелгән. Татар сүзләрен ике графикада бирү дә урынны күп алган булса кирәк.

5. Кириллицада татар авазларын чагылдыру өчен, автор бу сүзлектә дә өстәмә тамгалар кулланган: ő – ө; ä – ә; ŏ – рус сүзләрендәге **о** авазын белдерә һ.б.

6. Татар сүзләренең рус хәрефләре белән бирелешендә дә кайбер үзенчәлекләр бар: сүзләрнең калынлыгы яки нечкәлеге беренче басмада сүз ахырындагы *ъ*, *ь* билгеләре белән белдерелсә, икенче басмада тартыкларның да калынлыгы рус хәрефләре белән язылышта аерым күрсәтелеп барылган. Мәсәлән: *къ* – قارا *къара* – черный (133); قالن къалын – толстый; قل къŏл – рабъ (134), قش къŏш – птица (135) һ.б.

7. Гарәп телендә калын тартыкларны белдерә торган хәрефләр белән язылган сүзләрдә тартыкларның калынлыгы да транскрипциядә чагылдырылган: خ– *хъ:* خق *хъакъ* – цѣна (99), خاطا *хъата* – ошибка (100); ص— *съ*: صاران съаран – скупой, صلى съоло – овесъ (117), ط - *тъ*: طون тъун – шуба (125), طوب тъуб – мячъ, мячикъ (127); غ – *гъ*: عقل гъакыл – умъ (131) һ.б.

8. Калын сүзләр ахырында ъ билгесе куелган, ә нечкә сүзләр транскрипциясендә *ь* тамгасы икенче басмада юк. Сүзлекнең бу басмасында башка аерымлыклар күзәтелми, лөгатьлектәге сүзләр дә шул ук.

**Орфографик сүзлекләр**

Орфографик сүзлекләр төзелә башлау язуга оешканлык, бердәмлек кертү максатыннан булган.

XX гасыр башында (1901 ел) М. Иманаевның рус-татар, башкорт мәктәпләре һәм мәктәп-мәдрәсәләр каршында эшләүче рус класслары өчен төзелгән «Русское слово» уку китабының II кисәгенә русча-татарча орфографик сүзлеге дөнья күрә. Күләме шул чор татар сүзлекләренә хас булганча зур түгел, 46 бит. Исеменә караганда, бу хезмәт сүзләрнең дөрес язылышын күз уңында тотарга тиеш булса да, нигездә, бу – русча-татарча аңлатмалы, тәрҗемәле сүзлек. Анда якынча 2000 сүз урын алган. Сүзлекнең русча өлеше дә, татарча ягы да рус хәрефләре белән, рус алфавиты тәртибен саклап бирелгән, татар сүзләрендә өстәмә тамгалар кулланылган (ä, ö, ÿ, ů һ.б), рус сүзләрендә басым күрсәтеп барылган. Сүзгә-сүз тәрҗемә өстенлек итә: *крапива – кычытхан, серебро – кӧмӧш*; фигыльләр -мак/-мәк формасында бирелгән, лөгатьлек ягында җәя эчендә күп кенә грамматик күрсәткечләре урын алган: отдыхать (-хаю -ешь -ютъ, -халъ -ли, -хай -хайте) – *жьал итмäк*; сыйфатларда род кушымчалары күрсәтелгән: розовый (-ая -ое) – ал (тöс) һ.б.

Гарәп язуына нигезләнгән чын мәгънәсендәге орфографик сүзлек Казандагы Харитон бабай көтебханәсендә 1914 нче елда басыла. «Кыскача татар нәхүе илә орфографический словарь» дип аталган бу хезмәтнең авторлары күрсәтелмәгән.

Исеменнән үк аңлашылганча, китапның бер өлеше татар теленең синтаксисына (16 бит) багышлана, ә икенче өлеше (20 бит) орфографик сүзлекчәне тәшкил итә, анда 3000 ләп сүзнең дөрес язылышы бирелә. «Татарча авыр сүзләр өчен орфографический словарь» ибтидаи (башлангыч) мәктәп укучылары өчен төзелгән. Сүзләр гарәп язуы нигезендә татар алфавиты тәртибендә тупланганнар. Сүзлекчәдә теркәлгән сүзләрнең күпчелеген алынма сүзләр тәшкил итә. Моның шулай булуы табигый, чөнки башлангыч мәктәп укучылары өчен чит телдән кергән сүзнең язылышын истә калдыру берникадәр авырлык тудыра.

Гарәп-фарсы телләреннән кергән сүзләр сүзлектә бик күп, һәм алар график принцип белән язылганнар: اختلاف ихтилаф, اختار ихтар, استعداد истигдад, بيكار бикәр, اسلا аслан, اول әүвәл, دعا дога, دعوا дәгъва, دقيقه дәкыйка, دليل дәлил һ.б.

Рус теленнән алынган сүзләрне язуда фонетик принцип өстенлек итә, шул сәбәпле алар түбәндәге рәвешләр алганнар: افتامابيل афтамабил (автомобиль), بانكروت банкрут, بالكوت балкун, اوچيتل учител, اوچيليشچا училишча һ.б.

Татар сүзләренең язылышында түбәндәге үзенчәлекләр күренә:

1. Сүзләр, нигездә, фонетик принцип белән ишетелгәнчә язылалар: اوچنچی өченче, تیلگه ن тилгән, اوقوچی укучы, اوقوتوچی укытучы, یمه ن имән һ.б.

2. Ирен гармониясе язуда чагылыш таба: بوروچ бороч, بوزوق бозок, تورکوم төркөм, بولوت болот, بورکوت бөркөт, سولوك сөлөк, سوروم сөрөм һ.б.

3. Кушымчаларда хәзерге «т» урынына «д» ( د) хәрефе языла: استدا астда, اتدئ атды, اداشدرو адашдыру, باسدرماق басдырмак, تومشدان тумышдан һ.б.

4. Исем фигыльнең *-у/-ү* формасы белән беррәттән -мак/-мәк кушымчалысы да очрый: اسلماق асылмак, اتنماق атынмак, اغزماق агызмак, ئرلا ما ك эрләмәк һ.б.

5. Сүз ахырында «п» авазы «б» ( ب ) хәрефе белән бирелгән: اوچلاب учлаб, اونارلاب унарлаб, ايلتوب илтүб, باروب баруб, بيشلا ب бишләб һ.б.

6. Сүз башында «җ» авазы – «й», «й» авазы «җ» белән чиратташа: جوكا җүкә (юкә), جوگان җөгән (йөгән), جالان җылан (елан); يبتو йебетү (җебетү) һ.б.

7. Иске татар теле үзенчәлекләре чагылыш тапкан: بوغداي богдай, اوغل угыл, اوغلان углан, اوشانداق ушандак, اياقسو аяксу, اڭقئ аңкы һ.б.

8. Сүз уртасындагы *ы, э* авазлары, кушымчадагы сузыклар язуда күрсәтелмәгән һ.б.

Бу хезмәт – гарәп хәрефләренә нигезләнгән орфографик сүзлекләрнең беренчесе. Ул башлангыч мәктәп укучылары өчен кирәкле кулланма булгандыр. Гарәп алфавиты нигезендә татарча язу системасына азмы-күпме тотрыклылык, бердәмлек бирергә омтылу авторны әлеге хезмәтне язуга этәргеч ясаган булырга тиеш.

**Галимҗан Баруди сүзлеге**

Гарәп, фарсы телләре гасырлар буе татар теленә көчле тәэсир итеп килгәннәр. Бу хәл аерым сүзлек материалларында гына түгел, тәрҗемәле сүзлекләрдә чыганак итеп алынган телләрдә дә күренә. Мисал өчен, 1893 елда Г. Баруди «Лөгате сөлляса зөбан өч тел» исемендә гарәпчә, фарсыча, төркичә (татарча) сүзлек төзеп бастыра. Китап Г. Барудиның кереш сүзе белән ачыла. Һәр бит 6 баганага бүленгән, икешәр багана гарәп, фарсы, төрки (татар) сүзләре би-

релгән, гарәп графикасы гына кулланыла. Сүзлек тематик принципта төзелә, үз эченә ике дистәдән артык тематик төркемне ала: кеше әгъзаларының атлары (*баш, колак, күз* һ.б.), кеше төрләренең атлары (*ир, хатын, ата* һ.б.), хайван горуһлары (*ат, сыгыр, тай* һ.б.), сулар вә аңа мөнасыйб шәйләр (*су, дингез, күл* һ.б.), күк нәрсәләре һәм вакытлар (*күк, йир, кояш, ай* һ.б.), кием вә өй җиһазлары (өй, тәрәзә, кылыч һ.б.), ашау вә йемешләр (*богдай, арпа, дөге* һ.б.), рәвешләр (*олуг, кечек, озын* һ.б.) кебек төркемнәрдә сүзләр башта гарәпчә бирелә, аннары аларның фарсы һәм татар телләренә тәрҗемәләре китерелә. «Кагыйдәләр бабы»нда кайбер кагыйдәләр белән таныштырыла. Мисал өчен, «Масдар: бер эшкә дәләләт итүче сүздер. Фарсы масдарының ахырында «تن» «دن» улур, төрки масдарының ахырында مک якә مق «улур» (20) һ.б.

Сүзлекнең 1897, 1902, 1907, 1911, 1916 елларда берничә басмасы дөнья күрә, алар бер-берсеннән күләмнәре һәм материалның бирелеше белән аерылмый, барысы да 40 бит сүзлектән гыйбарәт.

### Хәбирә бинте Габделкави Насыйрия сүзлеге

«Фарсы-гарәби һәм төрки лөгате» дип аталган әлеге сүзлек Казанда 1902 елда басыла. 15,5х25 см форматлы. Китапның һәр бите өч баганага бүленгән, гарәп хәрефләренә нигезләнгән фарсы әлифбасы кулланыла, һәр хәреф аерып бирелә ( فصل الالف, فصل ابا  һ.б.), әмма хәреф эчендә алфавит тәртибе сакланмый. Чыганак тел – фарсы теле, сүзләр фарсычадан гарәп һәи төрки (татар) телләренә тәрҗемә ителәләр. Төрки графасында аңлатмалы тәрҗемәләр дә очрый: ارج – озын муенлы кош (5), دایه – бала тәрбияләүче хатын (43). Төп сүздән соң шул сүзгә бәйле сүзтезмәләр китерелгән сүзлек мәкаләләре дә очрый: су – салкын су, кое суы, кар суы, эссе су, исле су, кайнар су, салкын су һ.б. (3).

91 битлек әлеге хезмәттә 1800 чамасы фарсы сүзе ике телгә тәрҗемә итеп бирелгән.

### Каюм Насыйри сүзлекләре

К. Насыйриның «Рус хоруфы һиҗасы үзрә мөрәттәб лөгать китабы» = «Полный русско-татарский словарь с дополнением из иностранных слов, употребляемых в русском языке как научные термины» беренче тапкыр 1892 елда басылып чыга. XX гасыр башында аның тагын ике басмасы (1904, 1911) дөнья күрә.

Күләмнәре беренче басмадан аерылмый. Әлеге сүзлек турында алдагы бүлекчәдә тулы мәгълүмат бирелә.

**Православие Миссионерлары җәмгыяте тарафыннан төзелгән сүзлекләр**

«Кыскача русча-татарча сүзлек» 1904 елда Тобольск шәһәрендә басыла һәм «Тобольск губернасы татарлары сөйләшенә нигезләнә» дип белдерелә. Басмага кереш сүз өлешендә татар телендә басымның һәрвакыт соңгы иҗектә булуына игътибар итәргә кушыла, сүзлектә кулланылган рус алфавитына өстәмә ҥ тамгасының н һәм г кушылмасы икәне, борын авазы булуы турында әйтелә.

Сүзлек 5нче биттән башлана, тематик принципта эшләнгән. Барлыгы 42 тематик төркем, төркем исемнәренең кайберләре татарчага тәрҗемә ителми генә бирелә: Богъ, Человѣкъ, Родство, Занятия, Пища = Аш, Напитки = Сусын, Плоды = Емешляр, Деревья = Агацлар, Вещи в доме = Өй эцендәге нярсяляр һ.б. Төркемнәрдә сүзләр саны төрлечә, иң зур төркем сыйфатлар һәм фигыльләр. Фигыльләр *-мак/-мяк, -у/-ү, күбрәк -галы/-гяле* формасында бирелә. Сүзләрдә әдәби тел белән чагыштырганда ц-лаштыру (сани – *цана* (24), чекушка – *цой* (24), молотила – *шабагацъ* (25), пестрый – *цыбаръ* (40) һ.б.), б авазының п белән чиратлашуы (свояк – *паца* (9); кобыла – *пія, пайтал* (25); теленок – *пысау* (25); бык – *пыга* (25); медь – *пагыръ* (32) һ.б.) кебек себер татарлары теленә хас фонетик үзенчәлекләр күзәтелә.

Нигездә сүзгә-сүз тәрҗемә өстенлек итә, ара-тирә синонимнар белән бирү очраклары да күзәтелә: качели – цянгелця, бау типкец (30), радость – куаныцъ, шатлыкъ (40), бесстыдный – оятсысъ, питсес (41) һ.б.

«Славянча-татарча сүзлек» 1911 елда басыла һәм «пособіе къ чтенію св. Евангелія, Часослова и Псалтири» буларак тәкъдим ителә. Кечкенә форматлы 147 битлек китап. Барлыгы 2000 нән артык сүз теркәлә. Сүзлек 3 биттән башлана, лөгатьлек ягы да, татарча өлеше дә кириллицада бирелә. Лөгатьлек өлеше чиркәү славян телендә, язуда бик күп иске тамгалар бар, һәр сүзнең басымы күрсәтеп барыла. Тәрҗемә өлешендә сүзгә-сүз тәрҗемә дә, синонимнар белән тәрҗемә итү дә, аңлатмалар бирү дә очрый: *глад – ачлык* (25), *дворъ – ишек алды, жорт* (29), *лоно – кюкряк, куйын* (54), *начатки – алданырак житкян жимешляр, ашлыклар* (57) һ.б. Кайбер очракларда иллюстратив материал китерелә һәм татарчага

тәрҗемә ителә. Изге китапларга сылтамалар да (кыскартылмалар формасында) биреп барыла: *Лук. 22,41* (13), *Псал. 105,28* (12), *Мө. 18,10* (23), *Мат. 27,46* (22) һ.б., әмма әлеге кыскартылмаларның аңлатмалары бирелми.

**М.-Садыйк Иманколый сүзлекләре**

1909 елда Казанда М.-С. Иманколыйның «Тәрҗеман руси вә фарси вә төрки» дип аталган хезмәте дөнья күрә. Китапның тышлыгында ук «Перевод самоучитель» дип күрсәтелгән, ягъни – бу русча, фарсыча һәм төркичә үзөйрәткеч. Һәр бит өч баганага бүлеп бирелгән, беренче баганада – русча, икенчесендә – төркичә (татарча), өченчесендә фарсыча материаллар. Һәр баганада сүзләр, сүзтезмә һәм җөмләләр кириллицада да, гарәп хәрефләре белән дә языла. Мәсәлән, руси: богъ بوغ; төрки: тенгрей تنكري ; фарси: худай خداى (5); руси: письмо پيصما, төрки: хатъ خاط (6) һ.б. Берникадәр сүзләрдән соң шушы берәмлекләр кергән гыйбарәләр китерелә, алар да баганалап, ике графикада бирелә: *Я читаю книгу и пишу письмо. Мянъ китабъ укимянъ гам хатъ язамянъ. Мянъ китабъ миханемъ хамъ хатъ минависемъ* (10). Сүзләр берникадәр тематика буенча туплана. Мисал өчен, 5–9 битләрдә дин, уку-укыту белән бәйле сүзләр, 9-10 битләрдә шул сүзләр белән аерым гыйбарәләр тәкъдим ителә; 11–12 битләрдә – вакыт, атна көннәре, 13–15 битләрдә – җөмләләр һ.б. Шул рәвешчә туганлык атамалары, зат алмашлыклары, фигыльләр (*-мак/-мәк* формасында) һ.б. тематик төркемнәргә мисаллар теркәлә.

1913, 1917 елларда үзөйрәткечнең тагын ике басмасы нәшер ителә.

**С. Рахманколый сүзлекләре**

С. Рахманколый һәм Г. Кәрамның «Русча-татарча мөкәммәл лөгать» сүзлеге 1911 елда И.Н. Харитонов типографиясендә Әхмәд Гәрәй Хәсәнов булышлыгы белән дөнья күрә. Күләме 624 бит булган бу хезмәттә 25 меңләп рус сүзен татарчага тәрҗемә итү күздә тотыла. Сүзлекнең һәр бите икегә бүленгән, анда ике багана рус сүзләре, ике багана татарчага тәрҗемә бирелгән.

Авторлар лөгатьлекне В. Даль сүзлегенә нигезләнеп төзиләр. Сүзләр рус алфавиты нигезендә урнаштырыла, лөгатьлек ягында сүзләрнең грамматик үзенчәлекләре (сүзнең кайсы сүз төркеменә каравы, исемнәрнең роды, күплек сан формасы, фигыльләрнең виды, юнәлеше һ.б.), басымы күрсәтелә.

Сүзлекнең татарча өлеше сүзгә-сүз тәрҗемә белән дә, аңлатма бирү юлы белән дә бирелгән. Шулай да тәрҗемәдә сүзләрне синонимнар аша аңлату төп принцип икәне күренә: *атаман – башлык, рәис, атаман* (14), *балкон – балкон, сәндерә, бала ханә* (17), *бисер – мәрҗән, сәйлән, энҗе, ләэлөә* (32), *доверие – ышану, инабәт, табшыру* (127), *звать – атамак, чакырмак, дәшмәк, өндәмәк, дәгъвәт итмәк* (177), *элегантный – матур, зифа, латыйф* (601) һ.б. Синонимик рәтләр шактый тулы, тәрҗемә синонимнары арасында рус алынмалары сирәк очрый, гарәп-фарсы сүзләре һәм аларга нигезләнеп ясалган сүзләр зур урын алып тора.

Бу хезмәт татарлар арасында популяр була һәм 1920 нче елда (С. Рахманколый вафат булгач), тулыландырылып, 35 мең сүз белән яңадан бастырыла.

С. Рахманколыйның 1913 елда чыккан «Татарча-русча лөгать» китабында 10 000 чамасы татар сүзе русчага тәрҗемә ителгән. Сүзлекнең лөгатьлеген автор, 1911 елда Г. Кәрам белән бергә төзегән русча-татарча сүзлеге картотекасыннан файдаланып, үзе төзегән булырга тиеш. Болай уйлау өчен берничә сәбәп бар: 1) моңа кадәр татар сүзләрен бу күләмдә туплап биргән тәрҗемәле сүзлек юк; 2) сүзлек үзенә күрә татар теленең синонимнар сүзлеге вазифасын да башкара. Лөгатьлек ягында синонимнар бирү элегрәк чыккан сүзлекләрдә күзәтелми; 3) русча-татарча сүзлектә татар ягында синонимнар шулай ук күп. Әйләндереп куйганда, татарча-русча сүзлектә лөгатьлек ягында да синонимнар килеп чыга: *гора – тау, таг (1911: 109), тау, таг – гора, холм (1913: 138); дождь – ягмур, яңгыр (1911: 128), ягмур, яңгыр – дождь (1913: 102); душа – җан, рух, нәфес (1911: 138), җан, рух – дух, душа (1913: 78) һ.б.* Шулай булгач, С. Рахманколыйның татарча-русча сүзлек лөгатьлеген үз көче белән төзү өчен белеме дә, тәҗрибәсе дә, материалы да җитәрлек булган дияргә нигез бар.

1915 елда С. Рахманколыйның «Русча-татарча кесә лөгате» дип аталган сүзлеге дөнья күрә. Ул 280 биттән гыйбарәт, анда 10 000 чамасы рус сүзенә татарча аңлатма бирелә. Бу сүзлек белән С. Рахманколый татар лексикографиясенә бер яңалык алып килә: беренче булып кесә сүзлеге төзеп бастыра. Дөрес, рус лексикографиясендә мондый сүзлекләр булган. Лексикография казанышлары, сүзлек төзү эшләре белән даими кызыксынып торган С. Рахманколый аларга игътибар итми кала алмаган, билгеле, һәм ул бу алым-

ны татар сүзлекчеләре арасында беренчеләрдән булып гамәлгә керткән.

**Н.Ф. Катанов сүзлеге**

Н.Ф. Катановның «Краткій татарско-русскій словарь» хезмәте 1912 елда басыла. Ул М.Ф. Кәримовның «Тарихе әнбия» («Пәйгамбәрләр тарихы») дәреслегенең 1нче кисәге күләмендә Казан рухани академиясе миссионерлык бүлегенең I, II курс студентлары өчен төзелә.

Китапның баштагы 23 бите татар тел белеме буенча теоретик мәгълүматтан гыйбарәт. Анда Казан-татар сөйләшенең төп фонетик үзенчәлекләре тасвирлана, татар теле авазлары башка төрки телләрдәге авазлар белән чагыштырыла.

Сүзлек өлеше 265 биттән гыйбарәт. Лөгатьлектә барлыгы өч меңгә якын сүз теркәлгән. Хезмәт XX йөз башында галимнәр һәм миссионерлар кулланган транскрипцияләр таблицасы белән ачыла. Һәрбер сүз гарәп хәрефләре белән язылганнан соң ике транскрипциядә дә, гыйльми һәм миссионерлык транскрипцияләре туры килгән очракта, берсендә генә бирелә.

Сүзлек гарәп алфавиты тәртибендә төзелә. Башта сүз татарча языла, аннан – транскрипцияләр, соңыннан мөмкин булган тәрҗемә вариантлары китерелә: ارپا *арпа* – ячмень (18), ارو *ару* – чистый, здоровый, хорошій (25), الى *äле* – теперь (53), بارى бары – то что есть, все наличное (80), سنه сäнä – годъ (136), شولاى шулай – такъ, такимъ образомъ (141), طات тат – вкусъ, сладость (149) һ.б.

Сүзлектә гарәп-фарсы алынмалары шактый. Алардан тыш, *төрек, грек, чыгытай, рус* дигән тамгалар белән билгеләнгән сүзләр дә очрый. Мәсәлән,

- ابت *äбäт* (1), الماس *алмасъ* (50), انيس *анисъ* (56),پراواصلاونى *прауаслауный (96),* خرستيان *христианъ* (123), قوماندا *куманда* (181), ماتور *матур* (195) сүзләрен һ.б. автор рус теленнән кергән дип саный. *Матур* сүзе «матерый» дигән сүздән килеп чыккан дип күрсәтелә (195).
- ابتدايى *ибтидаи* (1), احاطه *ихата* (10), احمر *ахмар*, اخر *ахыр*, اخرتахирäт (11), بركت бäрäкäт (85), بيان бäян (92), تاريخ тарих (97), حال хäл (116) һ.б. сүзләр гарәпнеке дип тамгалана.
- برابر *бäрабәр* (85), بها *бäһа* (89) پريشان *пäришан* (97),حكمدار *хөкөмдар* (120), حانه *ханä* (122), دوچار *дучар* (127) һ.б.

сүзләр фарсы теленнән дип билгеләнә. Алынма берәмлекләр арасында алар зур күпчелекне тәшкил итәләр.

- «төрек» (турец.) тамгасы белән теркәлгән сүзләр аерым игътибарга лаек: اوستون *öстöн* – превосходящій, победитель (63), اوزره *ÿзäрä* = татар. *буенча* (63), ایدلمك *äдiл* = татар. *ителмәк* (72), دکز *дäӊiз* = татар. *диңгез* (127), دوه *дäвä* = татар. *дөя* (128), شويله *шöйлä* = татар. *шулай* (141), طوقز докуз = татар. *тугыз* (157), کبی *kiбi* = татар. *кебек* (183) һ.б.

Фигыльләр *-мак/-мәк* формасы белән бирелә, әмма транскрипциядә бу кушымча никтер төшеп кала һәм фигыль тамыр рәвешен ала: اتالمق атал – получать, имѣть имя, названіе…(3), ارمق ар – утомлять, уставать (24), ارمك эре – таять, плавиться (26), اوازلانمق авазлан – браниться, ворчать (57), باشلامق башла – начинать (81), تلامك теләә – просить, желать (101), سورمك сöр – гнать, вести (жизнь) (137) һ.б.

Лөгатьлектә урын алган берәмлекләрдә *җ*-ләштерү күренеше дә, й-ләштерү дә бар. Мәсәлән: یابالاق *җабалак* – сова (217), یابق *җабык* – тощій, худощавый (218), یات *җат* – чужой (219), یارق *җарык* – щель, трещина, расщелина (221); یب *жеб* – нитка, веревочка (235), یایه *жяя* – лук для стрѣльбы (235), یای *жяй* – лѣто (234), ییزنی *жизней* – муж старшей сестры (256), ییتز *җитез* – проворный (256) һ.б. Гыйльми транскрипциядә й-ләштерү, ә миссионерлык транскрипциясендә ж-ләштерү өстенлек итә.

Сүзлекнең русча өлешендә сүзгә-сүз тәрҗемә дә, синонимнар белән тәрҗемә итү дә, сирәк булса да аңлату юлы да очрый: اتاو *атау* – островъ, курганъ въ степи (4), اچيتقى *ачыткы* – квасъ (10), اد *ад* – имя, названіе (12), ارم *äрем* – полынь (трава), اعا *ага* – старшій братъ; اعارتوچى *агартучы* – бѣлильщикъ (35), الما алма – яблоко; ایسکی *иске* – древній, ветхій, старый, обветшалый (75), خسته *хаста* – тяжко больной (123), قارا *кара* – черный, чернила (169), موك *моң* – печаль, унынiе, скорбь (205) һ.б.

Ясалма сүзләрнең тамырлары да күрсәтеп барылган: اتاسز *атасыз* – не имеющий отца – отъ *ата* (3), ازانچى *азанчы* – … отъ *азан* (15), ارولق *арулык* – … отъ *ару* (25), اقسل *аксыл* – … отъ *ак* (39), بولوچى *булучы* – … отъ *булу* (91), تمسز *тäмсез* – … отъ *тәм* (102), روحانى *рухани* – … отъ *рух* (131) һ.б.

Бер үк сүзлек мәкаләсендә төп сүз кергән сүзтезмәләр дә очрый: ارا *ара* – аларның арасында (16), ارچيغچ *арчыгыч* – теш ар-

чыгыч (21), اغاچ *агач* – агач сабы, алма агачы (35), اهميت *ähämijjät* – әһәмият бирмиләр (57), ايمان *иман* – иманга килделәр (78),تللى *телле* – татлы телле (102), روش *рäўш* – шул рәвештә (131), تارتمق *тартмак* – баш тартып (151), قايغورمق *кайгырмак* – бала юклыкка кайгырган (173), هر *häр* – һәр сәгатьтә, һәр йирдә, һәр качан, һәр тарафтан, һәр икесе (213) һ.б.

**Габбас Сәйфуллин сүзлекләре**

Габбас Сәйфуллинның «Кечек лөгать» сүзлеге 1912 елда «Милләт» нәшриятында дөнья күрә. 116 битлек әлеге хезмәттә «Әдәбиятымызда очрый торган гарәп, фарсы һәм европа телләреннән кергән» сүзләр туплап бирелгән.

1917 елда «Өмет» нәшрияты Габбас Сәйфуллинның «Мәктәп лөгате» сүзлеген бастыра. Кечкенә форматлы 135 битлек бу сүзлектә 4300 тирәсе гарәп сүзе урын ала, аларга татарча аңлатма китерелә. Ягъни бу – гарәпчә-татарча сүзлек. Хезмәттә тупланган сүзләр тормышның төрле өлкәләренә карый: уку-укыту, табигать күренешләре, хайваннар дөньясы, дини сүзләр, туганлык терминнары, сыйфатлар, фигыльләр һ.б.

Автор бер телдән икенче телгә сүзгә-сүз тәрҗемәне максат итеп куймаган, сүзлектә андый очраклар күп түгел, нигездә, сүзләр җентекләп аңлатылган: شارط – *берәр эшне эшләүдән элек эшләнүе тиешле нәрсә* (64) һ.б. Тәрҗемә ягында гарәп-фарсы алынмалары бик күп очрый. Сүзләр гарәп сүзлекләрендәге кебек оялап түгел, алфавит тәртибендә урнаштырылган.

«Мәктәп лөгате» сүзлеге төзелешенең гадилеге, эшләү өчен җайлы булуы, татарчага аңлаешлы тәрҗемәләре белән игътибарны җәлеп итә. 1918 елда ул тагын бер кат басыла.

**И.П. Березгин сүзлеге**

И.П. Березгинның «Словарь татарскаго языка съ начертаніем словъ русскіми буквами, съ повтореніем ихъ по-татарски и съ переводомъ на русскій языкъ» хезмәте 1914 елда Уральскида басыла. Китап шактый зур форматлы, 253 биттән гыйбарәт. Аның лөгатьлеге 14 000 чамасы сүзне сыйдырган. Сүзлек өлешенә кадәр берничә таблица урнаштырыла: гарәп һәм рус алфавитларын чагыштырып биргән таблица (б.IV), сан исемнәре (б.V), унике айлык кыргыз ел циклы (б.V), ай исемнәре, атна көннәре таблицасы (б.VI). Сүзлек өлешендә һәр бит урталай бүленә, татар сүзләре һәм

аларның тәрҗемәләре ике багана итеп урнаштырыла. Сүзлекнең исеменнән үк аңлашылганча, татар сүзләре башта рус, аннан гарәп хәрефләре белән языла, соңыннан тәрҗемә вариантлары китерелә. Тәрҗемәләрдә синонимнар да очрый. Алдагы сүзлекләрдәге кебек, бу хезмәттә дә алынмаларның чыганагы билгеләнгән. Мәсәлән: *армиган* ارمغان(пер) – даръ, подарокъ, награда; *арнэб* ارنب (ар) – заяцъ (15); *афтаба* افتابه (пер) – кувшинъ, умывальникъ; *ахыян* اخيان (ар) – времѣна (19); *багар* بهار (пер) – весна (21); *бадрай* بدراى (пер) – дающій дурные совѣты (23); *габын* غبن (ар) – обманъ въ продаже (48); *гылтан* غلطان (пер) – круглый, вся круглая вещь; *гым* غم (ар) – печаль, горѣ, забота (49); *далю* دلو (ар) – месяцъ январь, созвездіе Водолей (51); *дизман* دزمان (пер) – большой, круглый, колоссальный (53); *жаля* ژاله (пер) – роса, градъ, инѣй (57); *мина* مينا (пер) – эмаль (123); салим ساليم (ар) – здоровый (141); *тырыш* ترش (пер) – кислый, соленый, угрюмый, суроватый (187) һ.б.

Фигыльләр *-мак/-мәк* формасында теркәлгән: *бульдрмек* بلدرمك- разорить (40), *мактамак* ماقتامق – хвалить, восхвалять (121), *сагмак* صاومق – доить (139), *ялунмак* يالونمق – просить, упрашивать, докучать (248) һ.б. Бу сүзлектә фигыльләрнең зат-сан белән төрләнгән формалары да урын алган. Мәсәлән: *адасти* اداستى – заблудился, *адастим* اداستيم – я заблудился, *адастың* اداستنك – ты заблудился (3); *куткар* قوتقار , куткарди قوتقاردى , куткардм قوتقاردم (111); *сынди* صندى , *сындр* صندر, *сындрамсың* صندرامسن (153); *яздрма* يازدرما, *яздым* يازديم , *язма* يازما , *язмасын* يازماسن (246) һ.б.

Сүзлекнең лөгатьлегендәге кайбер сүзләр башка сүзлекләрдә күзәтелми: *агуун* اغوون – куропатка (2); *азарламак* ازارلامق – бранить; *азай* ازاى – не очень хорошій (3); *алак* الاق – грабеж (8); *антари* انتارى – камзолъ (12); *аркач* ارقاچ – склонъ или подошва горы (14); *аякмак* اياقمق – встать на ноги, научиться ходить (о детях); *бабир* بابير – очень старый (20); *байгач* بايعاچ – дерево (23); *мешин* مشين – обезьяна (123); *тарнау* تارناو – водопроводъ, каналъ (165); *туткал* طوتقال – клей (184); *тушан* طوشان – заяцъ (185); *ушкат* اوشقات – кустарникъ (207); *чалаган* چالاعان – крапива (219) һ.б. Кайбер сүзләр иске татар телендәгечә теркәлгән: *сагау* صاغاو – заика, картавый; *саг* صاغ – здоровый, живой, трезвый (139); *саускан* صاوصقان – сорока (145); *тарбака* طارباقا – черепаха (164); *тиш* تيش – развяжи, распутай (173); *тупук* طوپوق – лодыжка (182); *чанача* جناجه – мизинец (220) һ. б.

Лөгатьлектәге бер төркем сүзләрнең аерым мәгънәләре генә татар телендә сакланган (алар курсив белән бирелә): тирсак ترساك– *локоть*, аршинъ; уголъ, мысь (173), тургай طورغاى – воробей, скворецъ, *жаворонокъ* (182); уймак اويماق – *наперстокъ*; гробъ; оладьи; ссадить, осапить ( 194) һ.б.

Сүзлектәге кайбер берәмлекләр казакъ, кыргыз, төрек телләрендә сакланып калган: *айдин* ايدين – свѣтъ, блескъ, свѣтъ луны (5), кыргызча *айдың* – 1) лунный свет, 2) лучезарность; айкай ايقاى – крикъ, шумъ (5), кыргыз телендә *айгай* = *айкай* – громкий тревожный крик; *алакан* الاقان – ладонь (8), кыргыз телендә дә шул ук мәгънәне белдерә; *суганак* صوغاناق – обжорливый (147), кыргызча *сугалак* – жадный, ненасытный, прожорливый; *аил* ايل – подпруга; женщина, жена (5) сүзенең «женщина» мәгънәсе казакъ телендә бар; *акэ* اكه – отецъ, папа (8), казакъча *отец* – әке, ата; *апата* اپاتا– недѣля (12), казакъ телендә *неделя* – апта; тыкуль طقول – пень; огарокъ; корень рога (186), *огарок* казакъчага *тукыл* дип тәрҗемә ителә; анафур انافور – водоворотъ (11) төрек телендә дә шул мәгънәдә сакланган anafor; *аништа* انيشته – зять, мужъ сестры (12), төрекчә зять – enişte (муж сестры); *коку* قوقو – запахъ (101), төрекчә kokax – koku – запах; *кумшу* قومشو – соседъ (106), төрекчә сосед – komşu һ.б.

Сүзлеккә теркәлгән лексик материал бик бай, аны, төрки телләрнең лексикасын чагыштырып өйрәнгәндә, фактик материал буларак кулланырга мөмкин.

**Һ. Максуди сүзлеге**

Һади Максудиның «Гарәбият» дип аталган хезмәте (1915) махсус әдәбиятта гарәпчә-татарча сүзлек һәм аларның әдәбиятта кулланылуы турында кагыйдәләр буларак тәкъдим ителә. 112 битлек бу китапта гарәп теленең төзелешенә һәм язуына караган күп кенә кагыйдәләр (гарәп хәрефләре, мәд хәрефләр, тәшдидле хәрефләр, һәмзәнең төрлечә язылуы, хәмзә һә әлиф, гарәби сүзләрдә хәрефләр саны, асыл вә кушма хәрефләр һ.б.) тупланган һәм алар мисаллар ярдәмендә аңлатылган. Мисаллар гарәп теленнән булганлыктан, һәр мисал татарчага да тәрҗемә итеп бирелгән. Тәрҗемәләр сүз янында да ( مدح мактау (10), اعلام белдерү (11)), сүзнең астына да язылган:

| | |
|---|---|
| علم | بيع |
| белү | сату (17) һ.б. |

Китаптагы кагыйдәләргә китерелгән мисалларның тәрҗемә ителүен күздә тотып кына, аны икетелле сүзлек буларак карарга мөмкин.

**Сәяси сүзлекләр**

Шәйхгаттар Абзгилдинның «Лөгать русчадан татарчага» дип аталган иҗтимагый-сәяси терминнарның татарчага аңлатмаларыннан гыйбарәт булган хезмәте 1907 елда Оренбургтагы «Дин вә мәгыйшәт» нәшриятында дөнья күрә. Китап бите бүленми, лөгатьлек тәрҗемәдән аерылып тормый, тоташ итеп бирелә. Рус сүзләре шул чор алфавиты тәртибендә китерелә, соңыннан шул сүз гарәп хәрефләре белән языла, аннары гарәп хәрефләре белән татарча аңлатыла: аудиторія – آوديتوريه аудтория дәресханә ягъни дәрес һәм вәгазь тыңлый торган урын (2); килограмъ – كيلاغرام француз үлчәве ике ярым кадактыр (19) һ.б. Интернациональ терминнар гына түгел, рус сүзләре дә, күп очракта тәрҗемә ителмичә генә, гарәп хәрефләре белән бирелә: санкционировать – سانكتسيانيروايت (34); трудящій – ترودە شچي (37) һ.б. 42 битлек элеге сүзлектә 200гә якын термин теркәлгән.

1918 елда татар дөньясы берьюлы ике сәяси сүзлек кабул итеп ала. Алар, икесе ике автор тарафыннан төзелеп, төрле җирләрдә басылалар. XX гасыр башында җәмгыятьтә барган иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр мондый сүзлекләргә ихтыяҗ тудырган булса кирәк.

Г. Габидовның «Русча-татарча сәяси лөгать» хезмәте Оренбург шәһәренең «Яңа вакыт» нәшриятында басыла. Сүзлек 48 биттән гыйбарәт, формасы, күләме шул чор терминологик сүзлекләреннән әллә ни аерылмый. Хезмәттә барлыгы 300дән артык сүз теркәлгән һәм һәрбер терминга татарча аңлатма китерелә. Сүзлектә ике төрле шрифт кулланыла: рус сүзләре – кириллицада һәм гарәп хәрефләре белән, татарча аңлатмалар шулай ук гарәп графикасында бирелә. Сүзлек рус алфавиты нигезендә, хәрефләргә аерылмыйча тоташ итеп төзелә.

Автор сүзгә-сүз тәрҗемә белән мавыкмый. Аның максаты сәяси терминнарның асылын гади халыкка җиткерү булгандыр. Мәсәлән, *узурпатор – хакимиятне көчләп үз кулына алучы* (41), *формализм – законга чын мәгънәсе ягыннан карамыйча, рәсми яктан караганда гына тырышучылык* (44) һ.б.

Сүзлектә тупланган сүзләр иҗтимагый тормышның төрле өлкәләренә карыйлар: дәүләт төзелеше, хакимияткә караган сүзләр,

иҗтимагый-сәяси партияләр эшчәнлеген чагылдырган берәмлекләр, икътисад, сәүдәгә нисбәтле терминнар, суд, хокук саклау, хәрби өлкәләрне чагылдырган сүзләр һ.б.

Икенче сәяси сүзлекне Г. Камал төзи. Ул «Кесә өчен русча-татарча мөкәммәл сәяси лөгать» дип атала. Аны Казандагы «Өмет» нәшрияты бастыра. Ул кечкенә форматлы (8,5х13 см), бүгенге сувенир китапларны хәтерләтә. Үзенә 600дән артык сүзне сыйдырган, 139 биттән тора.

Сүзләр рус алфавиты нигезендә, хәрефләргә бүлеп-бүлеп теркәлгән. Сүзлектә шулай ук ике төрле язу (кириллица, гарәп) кулланылган. Бу хезмәт тә аңлатмалы сүзлек итеп төзелгән. Теркәлгән сүзләрнең тематикасы шактый киң: монда, Г. Габидов сүзлегендә күзәтелгән төркемнәрдән тыш, уку-укыту, мәгариф өлкәләренә, матбугат, әдәбиятка караган сүзләр, чит илләрдәге иҗтимагый-сәяси үзенчәлекләрне чагылдырган берәмлекләр, акча, озынлык үлчәмнәре һ.б. да урын алган.

Шул рәвешчә, XX гасыр башы – татар лексикографиясе тарихында зур әһәмияткә ия чор. Бу елларда XIX гасырда тупланган тәҗрибәне кабул итеп, аны лаеклы дәвам итү лексикография алдына куелган иң төп максат була. Әлеге дәвердә басылган сүзлекләрне лексикографик тәҗрибәсе, үзе алынган өлкәдә белемле авторлар төзегәне игътибарга лаек. Аларда гасыр башында җәмгыятьтә барган үзгәрешләр объектив рәвештә чагылыш тапкан; татар халкының тарихына, гореф-гадәтләренә, мәдәниятенә һ.б. өлкәләргә караган төшенчәләр теркәлгән; һәр сүзлек, күләме мөмкинлек биргән кадәр, үз чорындагы татар теленең актив сүзләрен туплаган.

Сүзлекләрнең төзелү принциплары хәзерге замандагы сүзлек төзү принципларына якын тора. Бу хезмәтләрне хронологик эзлеклелектә, системалы рәвештә тикшереп чыгу шуны күрсәтте: әлеге сүзлекләр тел фактларын туплау, аларны лексикографик эшкәртү җәһәтеннән елдан-ел камилләшә барганнар.

## § 9. XX гасырның 20-40 нчы еллар сүзлекләре

Тарихтан билгеле булганча, 1920 елларда халкыбыз өчен үсеш-үзгәрешләргә бай чор башлана. Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелү татар теленә бәйле уңай үсешкә китерә, телебез, әдәбиятыбыз, мәдәниятебезне яңа бас-

кычларга күтәрер өчен мөмкинлекләр ача. Татарларның дәүләтле булуга ирешүендә киләчәккә зур өметләр баглап, туган телнең байлыгын барлау һәм теркәү юнәлешендә тагын да күбрәк эшләргә, яңа идеяләрне тормышка ашырырга этәргеч бирә.

1921 елның июнендә Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты һәм халык Комиссарлары Советы тарафыннан «Республикадагы совет учреждениеләрендә эш башкарганда татар телен куллану турында» декрет кабул ителә. Әлеге Декрет карары татар теленә бәйләнешле күп вакыйгаларның башлангычы булып тора: татар теле курслары ачыла, татар телен документлар теле итеп файдалану тагын да киңрәк колач белән тормышка ашырыла башлый. Татар теленең дәүләт теле буларак кулланылышка керүе республикада яшәүче башка милләт вәкилләренә дә татар телен өйрәтү мәсьәләсен көн тәртибенә куя. Казанда оешкан Гыйльми үзәк һәм аның каршындагы «Татар телен гамәлгә ашыру» комиссиясенең, тел белеме юнәлешенең максатчан эшчәнлеге нәтиҗәсендә фән өлкәсендәге үсеш, татар телендә белем бирүнең киң колач җәюе күзәтелә. Нәтиҗәдә русча-татарча, татарча-русча һәм терминологик сүзлекләр төзү, төрле тармакларга караган терминнарны татарчага тәрҗемә итү зарурлыгы туа, ашыгыч рәвештә һәр юнәлештә кызу эш башлана. Әлеге максат белән төзелгән авыл хуҗалыгы (1924), сәяси (1925), хәрби (1926) һ.б. терминнар сүзлекләре, Һ.Максудиның «Фәнни камус» исемле энциклопедик сүзлеге (1927) дөнья күрә, 1927 елда «Татарча-русча сүзлек», 1929 елда 32 мең рус сүзенең тәрҗемәсен биргән һәм татарча өлеше гарәп хәрефләре белән язылган «Русча-татарча яңа лөгать» басыла. 1938 елда, татар язуы кирилл графикасы нигезенә күчерелгәч, «Русча-татарча сүзлек»нең яңа варианты чыга.

Башка елларда төзелгән сүзлекләр бер-берсеннән, гадәттә, төрләре, принциплары, лөгатьлекләре белән аерылып торсалар, 1920–1940 ел сүзлекләре нинди шрифтта басылулары белән дә үзенчәлекле, чөнки уку-язуыбызга зур йогынты ясаган латинга күчү чоры нәкъ менә әлеге вакыт аралыгына туры килә. Билгеле булганча, 1927 елда яңалифкә күчү турында карар кабул ителә. Урта һәм югары мәктәпләр шул елдан ук латин хәрефләре нигезендә уку-язуны башларга, ә яңа уку елыннан инде барлык мәктәпләр дә яңалифкә күчеп бетәргә тиеш була. Әлбәттә, яңа орфография кагыйдәләрен эшләп, яңа таләпләргә туры килерлек орфографик

сүзлек төзү өчен галимнәргә бик аз вакыт бирелә. Берничә ел эчендә шактый камилләшеп җитсә дә, латин язуы вакытлыча гына хезмәт итә. 1939 елдан соң татарлар кириллицада укый һәм яза башлый.

Билгеле инде, шрифт алмашынган саен, яңа сүзлекләргә ихтыяҗ туган.

Латин графикасы кабул ителгәч, сүзлекчеләр гарәп шрифтындагы сүзлекләрне яңалифтә бастырырга, ә кирилл алфавитына күчкәч, ашыгыч рәвештә кирилл хәрефләрендә русча-татарча сүзлекләр чыгарырга мәҗбүр булган. Җитмәсә, шрифт алмашыну аркасында туган төрле техник кыенлыклар да аларның эшен катлауландырып торган. Бу хакта 1920–1940 елларда басылган сүзлекләрнең һәрберсендә дә диярлек телгә алына.

Сүз алып барыла торган чорда төзелгән сүзлекләрнең 1928 елга кадәр басылганнары – гарәп, аннан соңгылары – латин һәм 1939 елдан соң басылганнары кирилл хәрефләре белән язылган. Тулы күзаллау булсын өчен, һәрбер сүзлеккә хронология тәртибендә үз тематик төркемнәрендә кыскача күзәтү ясалыр.

**Тәрҗемә (русча-татарча, татарча-русча) сүзлекләр**

Тәрҗемәле сүзлекләр төзү эше Октябрь инкыйлабыннан соңгы чорда тагын да тирәнрәк фәнни нигездә дәвам итә. Билгеле, монда үткән дәвердәге татар лексикографиясенең бай традицияләре киң файдаланыла. Гомумән, чорына бәйсез рәвештә кайсы төр сүзлекләрнең аеруча актуаль булуы турында фикер йөрткәндә, икетелле сүзлекләрнең алгырак планда торуы күзгә ташлана. Чөнки, халыкларның үзара аралашуы өчен дә, чит телләрне өйрәнгән вакытта да, бер телдәге сүзнең мәгънәсен икенче телгә мөмкин кадәр тулы, төгәл итеп күчерү өчен, беренче чиратта тәрҗемәле сүзлекләр кирәк. Шуңа 1920–1940 еллар аралыгында иң беренче басылып чыккан лексикографик чыганакның икетелле (тәрҗемә) сүзлек булуы да гаҗәп тоелмый. Тәрҗемәле сүзлекләрдән, күрсәтелгән чорда, нигездә, русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләр эшләнә. Русча-татарча сүзлекләр җиде булса, татарча-русча сүзлекләр чагыштырмача азрак – ике генә. Иң элек русча-татарча сүзлекләргә тукталырбыз.

Алдагы параграфларда элеккерәк чорда төзелгән тәрҗемәле сүзлекләр турында сүз алып барганда, бу төр хезмәтләрнең иң күренеклеләре арасында С. Рахманкулов белән Г. Карамның 1911 елда

чыккан «Русча-татарча мөкәммәл лөгать» («Полный русско-татарский словарь с указанием ударений и грамматических свойств каждого языка, со включением иностранных слов, вошедших в употребление в русском языке») сүзлеге дә каралган иде. Күзәтү ясала торган чор нәкъ менә әлеге сүзлекнең 1920 елда кабат дөнья күргән икенче басмасы белән башланып китә. 680 битлек әлеге сүзлекнең татарча ягы гарәп шрифтында бирелгән. Сүзләрнең басымы, кайбер грамматик үзенчәлекләре күрсәтелү хезмәтнең кыйммәтен тагын да арттыра [1920-РТ_(2) (г)].

**па́морозъ** یازغی قراو *[язгы кырау]*

**размениваться** آلشدرلو *[алыштырылу]*

**переспевать** آرتق پشو *[артык пешү]*

1929 елда 32000 гә якын сүзне үз эченә алган зур күләмле «Русча-татарча яңа лөгать» басылып чыга. Сүзлектә рус һәм чит тел сүзләренә, яңа атамаларга, кыскартылмаларга шактый урын бирелә (1929-РТ (г)).

**Сма́ковать** تەملەو *[тәмләү]*

**Оче́рчивать** سزغالاو *[сызгалау]*

**Ва́та** مامق *[мамык]*

1938 елда Г. Нугайбәк, Ф. Әмирханов, М. Корбанов, С. Фәйзуллин төзегән һәм шулай ук 32 000 нән артык сүзне үз эченә алган «Русча-татарча сүзлек» басылып чыккан. Татарчасы латинда бирелгән әлеге хезмәтнең кереш өлешендә «Бу сүзлек үзенең характеры белән русча сүзләрнең татарча мәгънәләрен бирү белән чикләнергә тиеш иде. Ләкин татар телендә әле энциклопедик һәм политик сүзлекләр булмавын исәпкә алып, кайбер сүзләргә кыскача аңлатмалар да бирелде», – диелгән [1938-РТ].

**Взборонить** – tьrmalap сьqu, tьrmalap betery [тырмалап чыгу, тырмалап бетерү]

**Изъян** – 1) zian, zarar; 2) kimcelek, çiteşşezlek, qəjep [1) зыян, зарар; 2) кимчелек, җитешсезлек, гаеп]

**Взвеситься** – ylcәну [үлчәнү]

1939 елда башлангыч мәктәпләр өчен «Русча-татарча сүзлек» эшләнә (төзүчеләре: Г. Нугайбәк, М. Корбангалиев, М. Гыймадиев). Сүзлекнең төп өлешен башлангыч мәктәпләр өчен чыгарылган рус теле дәреслекләрендәге сүзләр тәшкил итә. Монда исемнәр һәм сыйфатлар берлек санда, баш килештә, фигыльләр инфинитив формасында бирелгән. Тагын шунысы әһәмиятле : сүзлектә кайбер

грамматик, орфографик үзенчәлекләрне күрсәтеп, зат, сан һ.б. га бәйле тамгалар куелган. Алынма терминнарга җәя эчендә кыскача аңлатма бирелгән сүзлек мәкаләләре дә очрый. Сүзлек кириллицада [1939-РТ_мәкт].

**аза́рт** – азарт, комар, кызып китү

**аре́нда** – аренда (күчми торган нәрсәдән, мәсәлән: җирдән, складтан, хак түләп, вакытлы рәвештә файдалану)

**вы́хватить** (б. вр. я выхвачу, мы выхватим) – тартып алу, эләктереп йолкып чыгару

1940 елда шактый күләмле хезмәт – Г. Нугайбәк, Ф. Әмирханов, М. Корбанов, С. Фәйзуллин төзегән «Русча-татарча сүзлек» дөнья күрә. 33 000 нән артык сүзне үз эченә алган икенче басма, 1938 елда басылган беренче басма нигезендә эшләнеп һәм тулыландырылып, кириллицада бирелгән [1940-РТ_(2)].

**жема́нный** – кыстатучан, кылanучан, назлы

**всход** – чыгу, калку; шыту, тишелеп чыгу

**бузун** – 1) суы корып утырып калган тоз (күлләрдә); 2) җәнҗалчы

**двоить** – 1) икегә яру; икегә аеру; 2) икенче кат сөрү (җирне)

1941 елда шул ук сүзлекнең өченче басмасы чыга. Рус телен өйрәнүчеләргә, укытучыларга, киң катлау укучыларга тәкъдим ителгән яңа басма 40 000 нән артык сүзне үз эченә ала.

Рус телендәге сүзнең тулы мәгънәсен бирә алырлык сүз булганда, сүзлектә татарча тәрҗемәләр бер генә сүз белән бирелгән, ә андый сүз яки термин булмаган очракларда якынча мәгънәләре китерелгән. Шулай ук, интернациональ сүзләрнең һәм фән-техникага кагылышлы терминнарның бик популярлашып җитмәгәннәренә, димәк, халыкка яхшы таныш булмаганнарына кыскача аңлатмалар да бар [1941-РТ_(3)].

**абзац** – абзац: 1) кызыл юл (язуда, китапта); 2) кызыл юл башында ачык калган урын; 3) бер кызыл юл башыннан икенчесенә кадәр булган текст

**вспылить** – кинәт ачулану, кызу

**железистый** – 1) бизле (*анат*); 2) тимерле, химик составына тимер катнашкан

1948 елда башлангыч мәктәпләр өчен «Русча-татарча сүзлек» дөнья күрә. Рус телен чит тел буларак өйрәнә торган татар балаларына һәм киң катлау укучыларга рус телендәге текстларны

мөстәкыйль рәвештә укыганда ярдәмлек буларак чыгарылган бу сүзлектә 6000 гә якын сүз һәм сүзтезмә урын алган. Төзүчеләре: Р. Газизов һәм М. Гыймадиев. Кереш сүздә «Бу сүзлекнең словнигы татар башлангыч мәктәпләре өчен төзелгән рус теле дәреслекләрен һәм дәрестән тыш уку өчен чыгарылган әкиятләр, мәсәлләр, хикәяләр нигезендә төзелде. Сүзлектә сүзләрнең тәрҗемәләре генә бирелмичә, грамматик формалары да китерелә» диелгән [1948-РТ_мәкт].

**Вся́чески** – һәртөрле юллар белән, ничек кенә булса да

**Обма́н** – алдау, алдалау, ялган, ялганлау

**Ли́стик** – яфракчык, кечкенә яфрак

Игътибар итсәк, 1920 елдан алып 1950 елга кадәр русча-татарча сүзлекләрнең һаман саен яңалары төзелеп һәм булганнары кабат нәшер ителеп торган. Барлыгы җиде русча-татарча сүзлек басылу – әлеге еллар өчен чагыштырмача зур күрсәткеч. Бу, әлбәттә, XX гасырның беренче яртысында татар теле белән кызыксыну көчәюгә, аны уку-укытуга зур игътибар бирелүгә, туган телгә ихтыяҗ артуга бәйле.

Ә тәрҗемәле сүзлекләрнең татарча-русча төрен 1927 елда гарәп графикасында басылган «Татарча-урысча сүзлек» башлап җибәрә. М. Корбангалиев, Р. Газизов, И. Кулиев төзегән бу сүзлек шактый күләмле. Ул 15 000 гә якын сүзне туплаган. Әлеге сүзлекнең алдагы елларда басылган татарча-русча сүзлекләрдән төп аермасы шунда : авторлар элеккеге сүзлекләрдә очрый торган бик иске һәм дини сүзләрне төшереп калдырып, 1917 ел инкыйлабыннан соң актив кулланыла башлаган интернациональ сүзләргә шактый урын биргәннәр. Фигыльләр төп формада күрсәтелә. Әлеге хезмәт сүзлек ахырында кушымта буларак татар грамматикасыннан кыскача белешмә китерелүе белән үзенчәлекле. [1927-ТР (г)].

**Цапля** چلەن [челән]

**Бисер** سەيلەن [сәйлән]

1931 елда әлеге сүзлекнең икенче басмасы дөнья күрә. Латин язуы кабул ителгән булу сәбәпле, анысы, билгеле инде, яңалифтә. Сүзлекнең ничек эшләнүе турында кереш өлешендә болай диелгән: «Советлар союзындагы төрек-татар халыклары күп йөз еллар урыс халкы белән бергә яшәгәнлектән «Урысча-татарча сүзлек» һәр ике халык өчен бер-берсенең телен өйрәнү ягыннан иң кирәкле ярдәмче булырга тиеш булса да, әлегә кадәр татар китап

мәйданында бу бушлык тутырылмый тора иде. Моннан 15 еллар элек мәрхүм Солтан Рахманкулов тарафыннан төзелгән «Татарча-урысча лөгать» исемендә бер сүзлек «Сабах» көтепханәсе тарафыннан басылган булса да, бердән аз сүзне эченә алуы, икенчедән, беренче тәҗрибә булганга күрә, байтак җитешсез булуы, өченчедән, басылган нөсхәләре әллә кайчан таралып беткән булу сәбәпле, татарча-урысча сүзлек төзү мәсьәләсе Татарстанда моннан 3–4 еллар элек үк кузгатылган иде.

Менә шул теләк бүген үтәлә. Без бу сүзлек белән укучыларда, укытучыларда һәм көндәлек тормышта файдаланырга теләгән һәммә кешеләргә ярдәм итәргә телибез.

...Татарча-урысча сүзлек төзүдә төп нигез татар теленең тулы сүзлеге булырга тиеш булса да, ул нәрсә әлегә кадәр бездә эшләнмәгән. Җамал Вәлиди тарафыннан төзелгән «Татар теленең тулы сүзлеге»нең беренче бүлеге (барысы 4 бүлектә, 100 табаклар күләмендә булуы уйланыла) яңа гына басылып ята. Шуңа күрә безгә бу «Татарча-урысча сүзлек»не төзегәндә төп татар сүзләрен дә үзебезгә төзергә туры килде. Шуңа күрә анда кайсыбер үзенчәлекләр һәм, бик ихтимал, кайсыбер җитешсезлекләр дә булуы мөмкин» [1931-ТР (л)].

Беренче басмасындагы кебек, сүзлектә фигыльләр башта төп формада бирелә, аннары квадрат җәяләр эчендә исем фигыль формасы китерелә. Әйтергә кирәк, бу фигыльләрне төп фигыль формасында күрсәтү белән исем фигыль формасында бирү арасында үзенә күрә бер компромисс була. Җ. Вәлиди сүзлекләрендә кулланылган әлеге алым, ягъни татар лексикографиясендәге яңалык – фигыльләрне исем фигыль формасында теркәү – икетелле сүзлекләр арасында нәкъ менә әлеге хезмәттән башлана.

Фигыльләрнең бирелеше түбәндәгечә:

**aqrnna [u]** – замедляться, утиха́ть, затиха́ть, ме́длить, мешкать

**aqla [u]** – 1) обели́ть; 2) опра́вдывать, оправдать

Хезмәт ахырында кушымта буларак бирелгән грамматик белешмә сүзлекнең кыйммәтен тагын да арттыра. Анда татар теле морфологиясе нигезләре, сүз ясалышы кагыйдәләре, үрнәкләре, сүз төркемнәре турында мәгълүматлар һ.б. урын алган [1931-ТР (л)].

**abctraksiə** [абстракция] – абстракция

**caq** *[чак]* – 1) аккуратный, нормальный, умеренный; 2) дурной, плохой, дрянной; 3) время, мера времени, пора; чуть

**kəjfse**z *[кәефсез]* – настроенный дурно, в плохом настроении духа, нездоровый, невеселый, скучный

**cɷꞁьş** *[чыгыш]* – 1) выступление, выход; 2) расход; 3) умолот; 4) происхождение; 5) восход.

Әлеге татарча-русча сүзлекләр Р.С. Нурмөхәммәтованың кандидатлык диссертациясендә җентекләп тикшерелгән, анализланган. Алар мисалында автор XX гасырның беренче яртысында татар әдәби теле үсешенең төп тенденцияләрен билгели, бәя бирә.

Татарча-русча сүзлекләр мисалында XX гасырның беренче яртысында татар әдәби теле үсешенең төп тенденцияләрен билгеләүгә багышланган  кандидатлык диссертациясендә Р.С. Нурмөхәммәтова әлеге ике сүзлекне җентекләп тикшергән, анализлаган. Хезмәттә сүзлекләр турында тагын да күбрәк мәгълүмат һәм сүзлек мәкаләләренә мисаллар табарга була.

Күзәтү ясалган русча-татарча һәм татарча русча сүзлекләр тәрҗемәле сүзлекләр төзү юнәлешен шактый үстергән, алга җибәргән дияргә мөмкин. Мисаллардан күренгәнчә, бу елларда төзелгән сүзлекләр лөгатьлекләренең шактый бай булуы белән аерылып тора. Аларда татар теленең үз сүзләре, гарәп-фарсы алынмалары, рус һәм рус теле аша чит телләрдән кергән сүзләр урын алган, терминнарның мөмкин кадәр төгәл тәрҗемәләре китерелгән. Шул ук вакытта тәрҗемәсез генә теркәлгән алынмалар да күп очрый. Иң мөһиме – ул елларда актив кулланылган сүзләрне, терминнарны теркәгән бу сүзлекләр татар телен өйрәнү өчен бай һәм гаять мөһим чыганак ролен үтәгәннәр.

**Терминологик сүзлекләр**

1920–1950елларда төрле өлкәләргә караган терминнарны туплаган 19 сүзлек басылган. Игътибар итсәк, терминологик сүзлекләр төзүнең фәнни нигезләре дә 1920  елларда эшләнә башлый. Казанда Гыйльми үзәк оешып, аның каршында «Татар телен гамәлгә ашыру комиссиясе» эшчәнлеге башлангач, терминологик сүзлекләр бастыру аеруча җанланып китә. Бу елларда татар теленең дәүләт теле буларак гамәлгә куелуы аның кулланылыш даирәсен тагын да киңәйтә, мәктәпләрдә һәм уку йортларында ана телен укытуга күбрәк вакыт һәм игътибар бирелә башлау сүзлекләргә булган ихтыяҗны тагын да арттыра. Төрле

өлкәләргә караган терминологияне туплау, системага салу эше көнүзәк мәсьәләгә әйләнә, тармак терминологиясен үстерү юнәлешендә зур эшләр башлана. Болар барысы да татар лексикографиясенең үсеп китүенә, аеруча билгеле бер тармак терминнарын туплаган сүзлекләрнең күпләп басыла башлавына этәргеч булалар. Нәтиҗәдә 1920–1940 елларда математика, физика, химия, юриспруденция һ.б. фәннәргә кагылышлы терминнарны туплаган сүзлекләр дөнья күрә. Димәк, махсус үзәк оештыру сүзлекләр төзү эшен киңәйтергә, аны фәнни нигезгә куярга реаль мөмкинлекләр ачкан дияргә тулы нигез бар.

Нинди максат белән һәм нинди принципларга таянып төзелүләренә карап, гадәттә, терминологик сүзлекләр берничә төргә бүленә. Мисал өчен, тармак терминологиясен туплаган сүзлекләр икетелле, күптелле, аңлатмалы, энциклопедик һ.б. булырга мөмкиннәр.

1920 еллардан соң басыла башлаган терминологик сүзлекләрнең барысы да диярлек икетелле сүзлекләр. Төгәлрәк итеп әйтсәк, аларның күпчелеге русча-татарча. Бу исә теге яки бу өлкә терминологиясе үсеш алып килә торган чорда терминнарның нәкъ менә татарчасын белү актуаль булуны, терминнарның тәрҗемәсен булдыру эше алгы планга чыгуны аңлата. Шунлыктан ел саен диярлек төрле тармакка, өлкәгә караган русча-татарча терминологик сүзлекләр төзелә торган. Әлеге төр терминологик сүзлекләрдән тыш, бу чорда берничә аңлатмалы һәм бер күптелле терминологик сүзлек басылган. Хронология тәртибендә аларның һәрберсенә тукталып үтәрбез.

1920 – 1940 елларда дөнья күргән терминологик сүзлекләрнең беренчесе – «Авыл хуҗалыгы истилахлары». Ул 1924 елда басылган [1924-РТ_а/хуж].

Тарихтан билгеле булганча, 1921 елның ахырында «Татарстан җир эшләре халык комиссариаты»ның нәшрият бүлеге каршында терминология комиссиясе төзелеп, аңа татар телендә авыл хуҗалыгы терминнарын чыгару вазифасы йөкләтелгән була. Сүзлек әлеге истилах комиссиясе тарафыннан төзелгән 2000 гә якын атаманы туплап чыгарылган.

Сүзлектә терминнарның күбесе рус теленнән татарчага тәрҗемә ителгән, тәрҗемә итеп булмаган очракта, рус яки интер-

националь сүзләр кулланылган. Сүзлек ике телле. Татарчасы гарәп хәрефләре белән бирелгән.

**Участок** بولمتك *[бүлемтек]*

**Фирма** فيرما *[фирма]*

**Орошение** سوعارو *[сугару]*.

1925 елда «Сәяси лөгать» дөнья күрә. Г. Нигъмәти, М. Мөхәммәдов, С.Шәрәфетдинов төзегән бу сүзлеккә 2000 гә якын сүз кертелгән. Хезмәттә төп урын сәяси терминнарга бирелсә дә, анда күпмедер дәрәҗәдә икътисадка, тарихка кагылышлы сүзләр дә урын алган. «Сәяси лөгать» тулысынча гарәп графикасында [1925-Т_сәяси (г)].

مانارحيست – دەولەت ئيدارەسى رەوشينڭ مانارحييەلى بولوون ياقلاوچى كشى *[монархист (манархист дип язылган. – авт. иск.) – дәүләт идарәсе рәвешенең монархияле булуын яклаучы кеше]*

ماكلير– ياوچى، ئاراچى *[маклер – яучы, арачы]*

1926 елда «Кыскача русча-татарча сугыш сүзләре тылмачы» басылып чыга. Якынча 1700 сүзне берләштергән әлеге хезмәт ике төрле максатны күз уңында тотып төзелгән. Беренче максат – уставларны татарчага тәрҗемә итү белән шөгыльләнүчеләр өчен хәрби терминнарны системага салу. Икенчесе – хәрби хезмәттәге татар егетләрен устав белән таныштыру, аларга винтовка, пулемёт өлешләрен һ.б. аңлату барышында, рус командирлары терминнарны татар телендәге варианты аша аңлата, төшендерә алсын өчен, атамаларның төгәл тәрҗемәләрен булдыру. Уңайлылык өчен сүзлектәге терминнар бер үк вакытта гарәп хәрефләре белән дә, кирилл хәрефләре белән дә язылган. Сүзләр өч баганада тәкъдим ителә. Беренче баганада – рус телендә, икенчедә – татар телендә (гарәп язуында), өченчедә татар атамасы рус хәрефләре белән язылган (“татарское название русскими буквами”). Татар авазларын төгәл белдерү өчен рус телендәге хәрефләр генә җитмәгәнлектән, төзүчеләр кайбер сүзләрне транскрипциядә бирә. Моның өчен өстәмә ä, ö, q хәрефләре кулланыла. Бу хакта сүзлекнең керешендә дә тәфсилләп аңлатыла [1926-РТ_хәрби (г, л)].

**Закраина** زاكراايينا) چيت) Чит

**Ружьё** ملتق Мöлтöq [мылтык]

**Караул** قاراول Qараул [караул]

Кайбер сүзләрдән соң җәя эчендә кыскача аңлатма да китерелә:

**Залп** زالپ (بر نیچه توب یه ملتقدان بر یولیُ ئاتو) Залп *[берничә туп я мылтыктан берьюлы ату]*

1927 елда «РСФСР кодексларында очрый торган атамалар лөгатьчәсе» басылып чыга. Ул шулай ук кечкенә русча-татарча сүзлектән гыйбарәт. Якынча мең сүзне үз эченә алган бу сүзлекчә юристлар, хокук белгечләренә тәкъдим ителә.

Билгеле инде, татар телен судларда куллану өчен, аның системага салынган терминологиясе булырга тиеш. Рус теленнән аермалы буларак, татар теле бер яктан гарәп-фарсы, икенче яктан Европа телләреннән кергән терминнар белән чуарланган. Ә терминнарны урынлы кулланам дисәң, татар теленең үз сүзләре белән алынма сүзләрнең чикләре, мәгънәләре төгәл билгеләнгән булырга тиеш. Әлеге сүзлек РСФСР кодексларына кергән сүзләрне туплап, аларның тәрҗемәләрен бирү , хокук белгечләренә һ.б.га ярдәм итү, терминнарны куллануда әлегә кадәр очрый торган төрлелекне һәм ялгыш бирелешләрне, хаталарны бетерү максатыннан эшләнгән. Сүзлекнең татар ягы гарәп графикасында [1927-РТ_юрид (г)].

**Взлом** واتو *[вату]*

**Истязание** جافالاو *[җәфалау]*

**Самоуплотнение** تعزلانو *[тыгызлану]*

1927 елда кечкенә күләмле, барлыгы 10 биттән гыйбарәт «Физика атамалары» сүзлеге чыга. Зур форматка язылган каты тышлыктагы әлеге сүзлек кульязманы хәтерләтә. Физика өлкәсендә эшләүчеләргә, укытучыларга һәм киң катлау укучыларга тәкъдим ителгән хезмәттә Татарстан мәгариф халык комиссариаты гыйльми үзәге каршындагы фәнни атамаларны җыю комиссиясе тарафыннан барланган төп терминнар һәм киң кулланыла торган физика атамалары китерелә. Татарча сүзләр гарәп язуында бирелгән (1927-РТ_физ (г)).

ИЗОБРАЖЕНИЕ شەولە *[шәүлә]*

ИСПАРЕНИЕ بولانو *[булану]*

СКОРОСТЬ تیزلک *[тизлек]*

СИФОН سیفون *[сифон]*

1929 елда «Медицинадан татарча атамалар: Нормаль анатомия атамалары» исемле сүзлек басылып чыга. Медицина терминнары сүзлегенең әлеге беренче кисәге якынча 1200 чамасы атаманы туплаган. Аны төзүдә «Татарстанны өйрәнү җәмгыяте»нең 1928 елда оешкан медицина секциясе һәм университетта эшләп кил-

гән атамаларны барлау һәм системалаштыру түгәрәге дә катнашкан. Әлеге хезмәт 1920–1940 еллар аралыгында басылган икенче күптелле сүзлек булып санала ала. Терминнар латинча, русча һәм татарча бирелгән. Татарчасы латинда, җәя эчендә кирилл хәрефләрендә язылган варианты да бар [1929-ЛРТ_анат].

**Sanguis** – кровь – qan *[кан]*

**Faux** – зев – tamaq *[тамак]*

«Атамалар сүзлеге» сериясеннән 1931 елда «Авыл хуҗалыгы һәм урманчылык атамалары» (XI кисәк) сүзлеге дөнья күрә. Ул беренче тапкыр авыл хуҗалыгы һәм урманчылык өлкәсендә эшләүчеләргә тәкъдим ителсә дә, шул ук вакытта киң катлау укучылар өчен дә гаять актуаль сүзлекләрнең берсе булып тора. Сүзлекнең татарча өлеше латин язуында [1931-РТ_а/хуҗ, урман (л)].

Брюква Gərənkə *[гәрәнкә]*

Боярышник Dylənə *[дүләнә]*

Иней Bəs [*бәс]*

Шул ук елда Г. Вәлитов төзегән «Химия атамалары. Анорганик кушылмаларның яңа номенклатурасы» басыла. Лексикографик принципларга таянып төзелгән сүзлекләрдән шактый аерылып тора торган әлеге хезмәт укучыларга химия атамаларын һәм химиягә кагылышлы мәгълүматны татар телендә җиткерү максатын күздә тотып эшләнгән белешмәлек кебек кабул ителә. Ул «Элементларның интернациональ һәм татарча атамалары: химия формулаларын уку тәртибе», «Беренче тәртиптәге кушылмалар номенклатурасы», «Икеле-тозлар һәм комплекс кушылмалар номенклатурасы» һ.б. бүлекләрдән гыйбарәт [1931-Т_хим (л)].

K CN – kali sianidь *[калий цианиды]*

Hg2O – TrekɵmeŞ oksidь *[терекөмеш оксиды]*

1931 елда дөнья күргән «Урысча, латинча һәм татарча атамалар сүзлеге: Кеше морфологиясе (анатомия, гистология)» исемле сүзлектә якынча 1700 атама урын алган. Сүзлекнең күптелле булуы аның исемендә дә чагыла.

Верхняя челюсть Maxilla Ɵske teş qaznasь *[өске теш казнасы]*

Височная кость Os temporal Cigə sɵjəge *[чигә сөяге]*

Надколенная чашка Patella Tez qarqaсь *[тез капкачы]*

Билгеле булганча, 1920–1940 елларда халык арасында актив рәвештә санитария пропагандасы алып барылган, «Кызыл хаҗ» түгәрәкләре, санитария курслары эшләп килгән. Сүзлек әлеге эшчән-

лекне оештыручы, алып баручы медицина хезмәткәрләренә ярдәм итүне күздә тотып башкарылган. Казан дәүләт медицина институты хезмәткәрләре төзегән бу сүзлекнең керешендә болай диелгән: «Атамаларны төзү техникасына килгәндә, анатомия атамалары стеклографиядә латинча-урысча-татарча тәртиптә җыелган булсалар да, биредә урысча-латинча-татарча тәртибенә күчерелделәр һәм анатомиянең төп бүлекләре буенча әлифбага салындылар. Гәрчә бу халыкара латинча анатомия терминнарын кулланырга күнеккән белгечләр һәм студентлар өчен җыентыктан файдалануны кыенлаштырса да, икенче яктан, югарыда сөйләнгән нияткә туры китереп, киң массага файдаланырга, ярдәмләшергә һәм тәнкыйтькә катнашырга мөмкинлек бирә» [1931-РЛТ_анат, гист (л)].

Шул ук елны «Урысча-татарча атамалар сүзлеге» сериясенең беренче кисәге буларак, физика, математика, астрономия терминнарын туплаган сүзлек дөнья күрә. Әлеге сүзлектә 4400 дән артык атама китерелгән. Аның төп нигезен Татарстан гыйльми үзәге тарафыннан стеклографиядә бастырылган материаллар тәшкил итә. Русча-татарча итеп эшләнгән әлеге сүзлекнең татарчасы латин хәрефләре белән бирелгән.

Аберрация Abirratsia [аберрация]

Момент силы Køc momintь [көч моменты]

Многочлен Kyp buьnnar [күп буыннар]

Төгәл фәннәрдән иң актуаль терминнарны туплаган бу хезмәт укытучылар, югары сыйныф укучылары һәм студентлар өчен бик кирәкле чыганак ролен үтәгән [1931-РТ_физ, матем, астр_(л)].

1934 елда 4000 нән артык сүздән торган русча-татарча «Химия терминнары» сүзлеге басылып чыга. Ул, татар телендәге фәнни химия терминнарын бергә туплау, системага салу һәм рус теленә тәрҗемә итүне күздә тотып, Казан дәүләт университеты каршындагы химия терминнары комиссиясе биргән материалларга нигезләнеп төзелгән. Сүзлекнең татарчасы латин графикасында [1934-РТ_хим (л)].

**Альбумин яичный** – Jomьrqa al'buminь *[йомырка альбумины]*

**Вещество простое** – Gadi maddə *[гади маддә]*

Терминология өлкәсендәге хезмәтләрне баетып, 1935 елда «Табигыять һәм биология терминнары» (төзүчеләре: М, Корбан, М. Сафин, Җ. Сәгъди, Н. Асманов, Н. Шәфиев, С.Саттаров) сүзлеге дөнья күрә [1935-РТ_биол (л)].

**Абиогенез** – Abiogenez (terek bulmaqannan tereklek jaralu) *[терек булмаганнан тереклек яралу]*

**Дерево тутовое** – Tut aqaсь *[тут агачы]*

**Наряд брачный** – Qavьşu qupşьlьqь *[кавышу купшылыгы]*

Шул ук елны, математикага кагылышлы төп терминнарны үз эченә алган «Элементар математика терминнары җыентыгы: алгебра, арифметика, геометрия, тригонометрия» (төзүчеләре: Х. Халиков, И. Алексеев, З. Ишаев) басылып чыга [1935-РТ_матем (л)].

Неравенство – Tiqezsezlek

Пятиугольник – Bişpocmaq

Точная мера – Tөqəl ylcəv

Удвоение – Ikeləty

1939 елда «Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге» (авторлары: Г. Кадыйров, М. Корбан, Т. Курамшин һ.б.) төзелә. Сүзлектә авыл хуҗалыгында очрый һәм кулланыла торган терминнар төп урынны алып тора. Биредә үсемлек, кош-корт, хайван атамалары да шактый бирелгән [1939-РТ_а/хуж (л)].

**Аборигенный скот** – çirle terlek, urьndaqь terlek *[җирле терлек, урындагы терлек]*

**Колесо** – təgərməc; kөpcək *[тәгәрмәч; көпчәк]*

**Трамбовка** – tөjgecləv; tөjy; tөjgec *[төйгечләү; төю; төйгеч]*

Аерым очракларда сүзлектә урын алган кайбер терминнарга җәя эчендә аңлатма да китерелгән.

Мәсәлән: **Автол** – aftol (nefttən alьna həm maŞina өleŞləren majlav өcen qullanьla torqan maj) *[нефтьтән алына һәм машина өлешләрен майлау өчен кулланыла торган май]*

**Автомат** – aftomat (mexanizm xərəkəte belən, bilgele ber eŞne yzennən yze baŞqara torqan apparat) *[механизм хәрәкәте белән, билгеле бер эшне үзеннән-үзе башкара торган аппарат]*

Мисаллардан күренгәнчә, аңлатмалары шактый киң. Димәк, русча-татарча дип исемләнгән әлеге сүзлекне эшләгәндә, өлешчә аңлатмалы сүзлек төзү принциплары да кулланылган.

Шул ук елда «Физика һәм метеорология терминнары» басылып чыга (төзүчеләре: М. Галиев, Х. Мөштәри, Х. Хөснуллин). Сүзлектә башта физика, аннары метеорология терминнары китерелә. Керештә күрсәтелгәнчә, дәреслекләрдә кулланылып килгән физика терминнары Татарстан мәгариф халык комиссариатының

тәкъдиме белән тәртипкә китерелгән, системалаштырылган. Татар терминнары латин графикасында (1939-РТ_физ, метеорол (л)).

**Зуммер** – zummer *[зуммер]*

**Лупа** – lupa *[лупа]*

**Поплавок** – qalqavьc *[калкавыч]*

Игътибар итсәк, моңа кадәр икетелле терминологик сүзлекләрнең барысы да русча-татарча иде. Ә менә 1941 елда дөнья күргән «Политик-экономик терминнар (русча-татарча, татарча-русча)» сүзлеге, исеменнән үк күренгәнчә, ике яклы тәрҗемәдән гыйбарәт. Ф. Махиянов, Г. Шәфиев, Г. Нугайбәк төзегән бу хезмәт ике яклы, аның яртысы – русча-татарча, яртысы – татарча-русча (1941-РТ+ТР_сәяси, икът). Мисал өчен, русчадан тәрҗемә ителгән ягы:

**Лавировать** – боргалану, лавировать итү

**Манифест** – манифест

**Машинно-тракторная станция (МТС)** – машина-трактор станциясе (МТС)

Икенче ягында башта татар телендәге терминнар китерелә:

**Авыл хуҗалыгы налогы** – сельскохозяйственный налог

**Стихиянең хөкем сөрүе** – господство стихии

**Табигый байлык** – естественное богатство, природное богатство

1943 елда Ф.Х. Фәйзуллин төзегән «Кыскача русча-татарча сүзлек (командирларга ярдәмче)» басылып чыга. Ул, рус телен бик яхшы белмәгән хәрби хезмәттәге татар егетләрен укытканда ярдәмлек буларак, Совет армиясе коралллы көчләренең командирлар составы өчен тәкъдим ителгән. (1943-РТ)

И. Алексеев һәм Х. Халиков төзегән «Русча-татарча математик терминнар сүзлеге» 1949 елда басыла. Сүзлектә интернациональ һәм рус теленнән кергән терминнар үзгәрешсез бирелә. Терминнар сүзгә-сүз тәрҗемә ителә; анда элементар математика, аның методикасы, югары алгебра, анализ, аналитик геометрия, ихтималлык теориясе терминнары һ.б. китерелгән. Шунысы да игътибарга лаек: сүзлектә элек кулланыла торган терминнарның күбесе яңалары белән алыштырылган. Мәсәлән: геометрическое тело – геометрик җисем (геометрик гәүдә түгел), переменный – үзгәрешле (үзгәрмәле түгел), сторона – як (кыр түгел) һ.б. Башка төр терминологик сүзлекләрдәге кебек үк, интернациональ харак-

тердагы терминнар үзгәртелмичә бирелгән (коэффициент, функция, периметр, медиана һ.б.). Сүзлек үз вакыты өчен шактый тулы, мәгълүматлы чыганак булып саналган, терминнарның күплеге һәм төрлелеге белән аерылып торган [1949-РТ_матем].

**дро́бное число́** – вакланмалы сан

**едини́ца длины́** – дуга берәмлеге

М.С. Галиев эшләгән «Русча-татарча физика һәм геофизика терминнары сүзлеге» 1949 елда чыккан. Сүзлектә физика һәм техника өлкәсеннән урта мәктәп дәреслекләренә һәм фәнни-популяр китапларга кергән 4000 чамасы термин теркәлгән. Сүзлектән файдалануны җиңеләйтү максатыннан, автор физика һәм геофизика терминнарын аерым биргән. Сүзлек беренче чиратта мәктәп укытучылары һәм укучылар өчен төзелгәнлектән, терминнарның дөрес әйтелешен, укылышын булдыру өчен, аларның һәммәсенә басым куелган. Бу – кулланучылар өчен сүзлекнең тагын бер уңай ягы. Хезмәт, һичшиксез, үз чоры өчен шактый актуаль саналган һәм физика терминнарын системага салуга зур бер адым булып торган. (1949-РТ_физ, геофиз)

**изосте́ра** – изостера

**зерни́стость** – бөртеклелек

Хезмәтләргә ясалган кыскача күзәтү терминологик сүзлекләрнең күплеген һәм төрлелеген күрсәтә. 1920 елдан 1950 елга кадәр барлыгы 18 сүзлек басылган. Аларның бер өлеше – русча-татарча сүзлекләр һәм бу исемнәрендә үк чагыла (мәсәлән, «Кыскача русча-татарча сугыш сүзләре тылмачы», «Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге»). Икенчеләре – шулай ук төре, бирелеше буенча тәрҗемә, ягъни русча-татарча сүзлекләр, тик бу хезмәтнең исеменә чыгарылмаган («Авыл хуҗалыгы истилахлары», «Физика атамалары», «Авыл хуҗалыгы һәм урманчылык атамалары» һ.б.). Моннан тыш, терминологик сүзлекләр арасында бер русча-татарча, татарча-русча сүзлек, ике күптелле, бер аңлатмалы сүзлек бар. Һичшиксез, аларның һәммәсе үз вакыты өчен зур чыганак ролен үтәгән. Шул чорның актив кулланылыштагы терминнарын системага салып, туплап тәкъдим иткән әлеге хезмәтләр бүгенге көндә дә актуальлекләрен югалтмыйлар. Тармак терминологиясен өйрәнүчеләр, тел белгечләре, сүзлекчеләр аларга бик еш мөрәҗәгать итәләр, үз хезмәтләрендә кулланалар.

**Аңлатмалы сүзлекләр**

Билгеле инде, бай лексикасы һәм сүзлекләр төзү тәҗрибәсе булган телдә генә аңлатмалы сүзлекләр төзелә ала. Теге яки бу телдә лексикография фәненең нинди дәрәҗәдә үскән булуын нәкъ менә аңлатмалы сүзлекләр аша бәяләп буладыр. Ә бу елларда татарча өч аңлатмалы сүзлек басылу бик әйбәт күрсәткечләрдән санала.

Татар телендә аңлатмалы сүзлек төзү кебек катлаулы һәм искиткеч җаваплы өлкәдә беренче тәҗрибәне күренекле галим К. Насыйри башкарган булса, икенче аңлатмалы сүзлек зур галим, әдәбият һәм тел белгече Җ. Вәлиди тарафыннан төзелгән. «Татар теленең тулы сүзлеге» дип аталган хезмәтнең беренче кисәге 1927 елда, икенче кисәге 1929 елда басылып чыга.

Телнең ул вакыттагы үсеше-үзгәреше турында хезмәтенең сүз башында Җ. Вәлиди болай дип яза: «Каюм Насыйриның соңгы елларында һәм аннан соң берничә еллар буена бездә, «Тәрҗеман» тәэсире белән гомуми төрекчелек фикере шактый көч алып, яңа туган каләмнәребезнең күбесе госманлыча дип әйтерлек яки шуңа тартым тел белән яза башладылар. Ләкин 1905 ел революциясенең төртеше белән мәйдан алган зур мәдәни һәм әдәби хәрәкәт телебезне акрынлап үзенең табигый эзенә тартып, башта «гомуми төрекчә» белән яза башлаган каләмнәрне дә бөтенләй яки берникадәр татарлашырга мәҗбүр итте. Бу инде Каюм Насыйрига таба чигеш дигән сүз иде. Ләкин, шуның белән бергә, инде «Ләһҗәи татари» иясенең теленә караганда күп эшләнгән, күп баеган, бигрәк тә дөресе эшләнеп, баеп бара торган тел туа иде» [1927-Т_аңлат_1/1 (г)].

«Татар теленең тулы сүзлеге»нең беренче кисәге А–Ә, У–Ү, Ы–Е, О–Ө, И, Б хәрефләренә башланган сүзләрне үз эченә ала. Сүзлектә якынча 5200 сүз һәм төшенчә бирелә. Анда һәр сүзнең мәгънәсе аңлатыла һәм аларга мисаллар китерелә, кайбер очракта сүзләрнең русча тәрҗемәләре дә бирелә. Сүзлекнең 1929 елда дөнья күргән икенче кисәгендә Б-П, Т хәрефләренә башланган 7300 дән артык сүз урын алган. (1929-Т_аңлат_1/2 (г))

تاچ (ئم.)- سییق بالچق یاکی تۇكرك كبك نەرسەنڭ قاتیُ نەرسەگە كیلب تۇشووندەگُگە ئوحشاشلیُ تاوشنیُ ئاڭلاتا

*[**тач** (ым.) – сыек балчык яки төкерек кебек нәрсәнең каты нәрсәгә килеп төшүендәгегә охшашлы тавышны аңлата]*

تاریحچُ - تاریح تیکشُروچیُ، تاریح عالیمیُ، یازوچُسیُ - مؤئەرریح

*[**тарихчы** – тарих тикшерүче, тарих галиме, язучысы – мөәррих]*

Җ. Вәлидинең татар теленең сүзлек байлыгын төгәл фәнни принципларга нигезләнеп яктырткан әлеге хезмәте ул чор өчен бик мөһимнәрдән саналган һәм алдагы елларда татар лексикографиясе нигезләнә алырлык лаеклы чыганак ролен үтәгән. Галим лексикографиянең теоретик нигезләрен эшләүгә дә зур хезмәт куя – беренче тапкыр сүзләрнең лексик һәм грамматик мәгънәләрен аеруны тәкъдим итә, фигыльләрнең *-у* га беткән бирелешен кертә һ.б. Фәнни эзләнүләренең нәтиҗәсен һәм теоретик ачышларын автор үзенең сүзлекләрендә дә чагылдырырга омтылган. Тик мәгълүм сәбәпләр аркасында әлеге хезмәт басылып бетмичә кала. 1932 елда Җ. Вәлидине, халык арасында милли идеяләр таратуда гаепләп, биш елга хөкем итәләр. «Яңа әлифба кертү – милли мәдәният өчен чын фаҗига, чөнки бу – традицияләрнең тулысынча өзелүе дигән сүз. Бөтен халык кинәт кенә, бер мизгел эчендә наданга әверелә», – дигән була ул вакытта Җ. Вәлиди. Әлеге фикерне тел галиме Ш. Асылгәрәев дә куәтли: «Без бүген дә әнә шул мизгел алып килгән фаҗигане тоеп яшибез. Әби-бабаларыбыз, зыялыларыбыз, шул исәптән, Җ. Вәлиди мирасын өйрәнүгә дә гаҗиз без, чөнки язу (хәреф) танымыйбыз. Бу – татар халкының зур фаҗигасе. Гарәп хәрефен латинга, латинны кириллицага алыштыру безнең барыбызны да, дөресрәге, татар халкының берничә буынын мәңьеллык мирасыбыздан аерды. Җ. Вәлиди үз чорында моның дөрес гамәл булмавын аңлап, сиксән ике зыялы мөрәҗәгатенә кушыла, алфавит алыштыруга каршы чыга, бу фикерен ул төрмә шартларында да үзгәртми» [Вәлидов: 2007; 11–12].

1928 елда «Газета укучылар өчен кесә сүзлеге» басылып чыга (төзүчесе – М. Гали). Хезмәт тулысынча гарәп графикасында. «Газета-журналларда гади укучыларга аңлау читен булган сүзләрнең күп булуын истә тотып, хәзерге вакытта бездә иң күп тарала торган «Крестьян газеты» үзенең укучыларына карата газета-журналларда иң күп очрый торган сүзләрне җыеп «Крестьян газеты сүзлеге» исеме белән китап рәвешендә басып барган иде. Ләкин, һәрбер кеше «Крестьян газеты» алып бармаганлыктан һәм алганнарының да берничә айлар буена аны җыеп бара алулары шөбһәле булганлыктан, шул сүзлек яңадан төзәтелеп һәм берникадәр сүзләр арт-

тырылып аерым китап итеп бастырылды», – диелә аның керешендә. (1928-Т (г))
ئانارحيزم – ميلكنى هەم دەولەتنى ئينكار ئيتوچى هەم شوڭار قارشى كوُرەشوچُلەرنڭ توُتقان يوللارى

*[**Анархизм** – милекне һәм дәүләтне инкяр итүче һәм шуңар каршы көрәшүчеләрнең тоткан юллары]*

پراشينييه ـ عاريزا، ئوتُنچ

*[**Прашиния** (прошение) – гариза, үтенеч]*

XX гасыр башында төзелгән аңлатмалы сүзлекнең тагын бер үрнәге –1929 елда басылган «Керәшеннәргә татар-гарәп сүзләрен аңлатыр өчен сүзлек» (авторы – Г. Биляев). Өч меңданәдә бастырылган әлеге сүзлек барлыгы 31 биттән генә гыйбарәт булса да, анда 600 дән артык сүз тупланган. Автор фикеренчә, «татар теленә кергән күп кенә гарәп һәм татарның әдәби сүзләрен аңламау, белмәү керәшеннәрне төп татар культурасына, татар әдәбиятына якынлаштыруда, бөтенләй берләштерү теләген тормышка үткәрүдә зур гына комачаулык булып яши». Сүзлек, әлеге «комачаулык»ны бетерү максатыннан, керәшеннәргә ярдәмлек буларак төзелгән. 1929-Т (л)).

Mərkəz – yzək (центр) *[мәркәз – үзәк (центр)]*

Rəsmi – zakunca (официальный) *[рәсми – законча (официальный)]*

Мисаллар әлеге сүзлекнең гадәти аңлатмалы сүзлекләрдән шактый аерылып торуын күрсәтә. Автор теге яки бу сүзгә тулы аңлатма бирүне максат итеп куймаган, ә аларны синонимнары яки якын мәгънәдәге башка сүзләр аша аңлаткан. Шул ук вакытта җәяләр эчендә атамаларның тәрҗемәләре дә күрсәтеп барыла. Хезмәттә синонимнар сүзлеге һәм татарча-русча сүзлек төзү принциплары кулланылган, шуңа күрә ул әлеге төр сүзлекләрне, дөресрәге, аларның кушылмасын хәтерләтә. Тик исемендә дә «татар-гарәп сүзләрен аңлатыр өчен сүзлек» диелгәнлектән, без аны, авторның максатыннан читләшмичә, аңлатмалы сүзлекләр рәтендә карыйбыз.

Димәк, алда сүз алып барыла торган чор аңлатмалы сүзлекләргә шактый бай. Алар арасында иң әһәмиятлесе һәм саллысы Җ. Вәлиди төзегән һәм, кызганычка каршы, тулысынча басылып өлгерә алмаган «Татар теленең тулы сүзлеге». Аның белән чагыштырганда калган икесе – «Газета укучылар өчен кесә сүзлеге» һәм «Керәшеннәргә татар-гарәп сүзләрен аңлатыр өчен сүзлек»

чагыштырмача тыйнаграк, чөнки алар билгеле бер кулланучыларны һәм максатларны күздә тотып башкарылганнар.

**Орфографик сүзлекләр**

1920 – 1940 еллар аралыгында җиде орфографик сүзлек дөнья күргән. Тарихка күз салсак, татар телендәге орфографик сүзлекнең беренче үрнәкләре 1901, 1914 елларда төзелгән. Һәм шуннан соң басылган, ягъни өченче орфографик сүзлек әлеге чорга туры килә. 1920–1940 елларда орфографик сүзлекләрнең шулай күп һәм еш чыгарылуы, һичшиксез, берничә тапкыр шрифт алышынуга да бәйле.

Бу чорда төзелгән орфографик сүзлекнең беренчесе – 1927 елда Гыйбад Алпаров төзегән «Татар теленең имла сүзлеге». Ул 12 000 нән артык сүзне үз эченә ала. «Телнең имла кагыйдәләре әлегәчә эшләнеп бетмәү сәбәпле, сүзлек тулы камиллеккә дәгъва кылмый», – ди автор [1927-Т_орфогр (г)]. Гарәп шрифтындагы әлеге хезмәткә кушымта итеп «Калынлык билгесе куела торган төп сүзләр», «Сүз башында «җ» белән язылган сүзләр», «Үзгәрешле кушымчалар имласы» кебек белешмә мәгълүмат китерелгән.

جايق *[Җаек]*
تيين *[тиен]*
جەديد *[җәдид]*
جاناش *[җанаш]*

Икенче орфографик сүзлек И. Рәми исеме белән бәйле. Ул төзегән «Имла сүзлеге» 1928 елда басыла. Әлеге сүзлеккә дә 12 000 нән артык сүз кергән. Татарча сүзләрнең латин графикасы нигезендә дөрес язылышын бирә торган һәм ашыгыч рәвештә, бик кыска вакыт аралыгында эшләнгән бу сүзлек үз вакыты өчен гаять актуаль һәм мөһим чыганак булган.

almacь *[алмачы]*
almaş-tilməş *[алмаш-тилмәш]*
analь-qьzlь *[аналы-кызлы]*

Латин графикасына күчүгә мөнәсәбәтле шау-шулы елларда басылган сүзлекнең керешендә болай диелгән: «Яңалиф-искәлиф бәхәсләре чорында (1926 ел) «иске мирас» мәсьәләсе күтәрелгән иде. Искечеләр: «яңалифкә күчү – иске әдәби мирасны юкка чыгару булачак» диделәр. Аларның бу зур аргументларына вакытында җаваплар бирелгән иде инде. Бу урында безгә иске мирасның,

имлә тармагынча булган «байлыкларына» кыскача тукталырга туры килә.

Бөтен СССРдагы татар яңалифчеләренең беренче съезды (28 ел, гыйнвар) күпме генә көч, хезмәт салынмасын, беренче чиратта «Яңалифнең имла сүзлеге»н һәм шуның артыннан ук «яңалифнең имла сүзлеге» эшләргә дип карар ясаган иде. Шул карарны үтәү юлында күптән түгел генә «Имла нигезләре» басылып чыкты, инде карарның калган яртысын үтәү юлында шушы китапны мәйданга куябыз.

Съезд тарафыннан эшләнеп бетмичә, Яңалифнең метод комиссиясенә калдырылган *j-ç* мәсьәләләре әле бөтенләй чишелеп бетмәде. Сүз башындагы *ç* ләр мәсьәләсен кырт кистереп карарга техника ягыннан мөмкинлек булмады, билгесез бер вакытта иске хәлендә калдырылды» [1928-Т_орфогр (л)]. И. Рәми һәм И. Кули төзегән «Татар теленең орфография сүзлеге» 1930 елда басыла. Ул моңа кадәр булган орфографик сүзлекләр үрнәгендә эшләнгән һәм шулай ук латин графикасында [1930-Т_орфогр (л)].

abьz *[абыз]*

bilbau *[билбау]*

quanьc *[куаныч]*

1933 елда Ш. Абай төзегән «Орфографик сүзлекчә: «о», «е» хәрефләре булган интернациональ һәм халыкара сүзләр» исемле кечкенә сүзлек басыла. Анда татар теленең орфографик принциплары һәм интернациональ сүзләрне язу кагыйдәләре китерелгән. Сүзлекчә беренче чиратта «о» һәм «е» авазлары кергән халыкара сүзләрнең дөрес язылышы турында белешмә буларак төзелгән. Кушымта буларак бирелгән «Сузык аваз-хәрефләр», «Тартык аваз-хәрефләр», «Сүз һәм кушымчалар» исемле кечкенә бүлекчәләрдә сүзләрнең язылышына кагылышлы кайбер кагыйдәләр һәм мәгълүматлар китерелгән.

Игътибар итсәк, ц хәрефе ике хәреф белән – ts бирелә: protses [процесс], akatsiə [акация], aksiə [акция], funksiə [функция]. Щ хәрефе язылган урыннарда бер үк иҗектә килгәндә «ş» (borş, tovariş), ике авазга бүленеп әйтелгәндә «şc» языла: (şci, şcotka). Җ авазы ç хәрефе белән күрсәтелә: çançal [жанжал], çədit [җәдит] [1933-Т_орфогр_алынм (л)] һ.б.

epos *[эпос]*

farfor *[фарфор]*

aksiə *[акция]*
adres *[адрес]*

1934 елда алынма сүзләрнең дөрес язылышына багышланган тагын бер хезмәт – «Татар әдәби телендәге интернациональ сүзләрнең орфография сүзлеге» басыла (төзүчесе – И. Рәмиев). Сүзлекнең басылу елына килгәндә, аның 1934 елда чыгарга тиеш булып та, бары 1935 елда гына дөнья күргән булуы да ихтимал. Чөнки, эчендәге мәгълүматларда 1934 ел күрсәтелгән булса да, сүзлекнең тышлыгына 1935 ел датасы куелган [1934-Т_орфогр_алынм (л)].

**Başnə** *[башня]*
**Memuar** *[мемуар]*
**Ragu** *[рагу]*

1941 елда басылган «Татар әдәби теленең орфография сүзлеге»нең төзүчеләре – М. Гыймадиев, Х. Хисмәтуллин, К. Хәмзин, Х.Шамкин, Р. Хәкимова. Әлеге сүзлеккә 7000 нән артык сүз тупланган. Бу сүзлек, татар язуын яңа алфавитка күчергәннән соң, татар әдәби теленең рус графикасы нигезендә төзелгән беренче орфография сүзлеге булып тора. Сүзлектә татар әдәби телендә очрый торган сүзләрнең күбесе, бигрәк тә язылышлары ягыннан кыен булганнары алына. Хезмәтнең кереш өлешендә Татарстан АССР Югары Советы президиумының «Татар язуын латин алфавитыннан рус графикасы нигезендәге алфавитка күчерү турында» һәм «Татар әдәби теленең төп орфография кагыйдәләрен аныкландыру турында»гы указлары китерелә [1941-Т_орфогр].

Каләм
Кама́ (җәнлек), Ка́ма тамагы (р.)
Каймак – каймагы

1948 елда тагын бер хезмәт – Х. Хисмәтуллин һәм М. Гыймадиев төзегән орфографик сүзлек басылып чыга. 1941 елгы басмасындагы кебек, әлеге сүзлектә дә Татарстан АССР Югары Советы президиумының алфавит турындагы указлары бирелгән. «Татар әдәби теленең алфавиты һәм орфографиясе» дип аталган бүлекчәдә алфавит һәм орфография принциплары, кайбер төрләндергеч кушымчаларның язылышлары һ.б. китерелә.

Баю – баюы
Гаделлек – гаделлеге
Ма́сса
Вестибю́ль – вестибюльне – вестибюле

Мисаллардан күренгәнчә, кушымча ялганганда сүзнең ничек үзгәрүе дә күрсәтелгән, басымнар да куелган [1948-Т_орфогр].

Шулай итеп, 1920–1940 еллар аралыгында җиде орфографик сүзлек басылган. Башка чорлар белән чагыштырганда бу шактый күп һәм моңа, билгеле инде, татар язуының берничә тапкыр үзгәреш кичерүе дә йогынты ясамый калмаган.

**Энциклопедик сүзлек**

1920 елдан алып 1950 елга кадәр бары бер генә энциклопедик сүзлек басылып чыккан. Күренекле тел галиме, җәмәгать эшлеклесе Һ. Максуди төзегән һәм «Фәнни камус. Русча-гарәпчә һәм төркичә фәнни мәҗмугалар буенча тәгъриф кылынган фәнни, әдәби вә синагый истилахлар камусы» дип аталган ул сүзлек 1927 елда дөнья күргән.

Энциклопедик сүзлек буларак тәкъдим ителгән әлеге чыганак 10 000 фәнни истилахны үз эченә ала. Сүзлекнең төзелеше турында кереш өлешендә болай диелгән: «Бу китапта сүзләрнең һәрберсен бер-берсен искә төшерерлек дәрәҗәдә мантыйкый бер мөнәсәбәт буенча янәшә китерергә ни кадәр тырышылса да, әлбәттә, бу беренче басмада һәр баб та теләгәнчә булып бетмәгәндер. Бу китапта истилахларның русчалары янына, шәрык милләтләрендә һәнүз йөртелә торган гарәпчәләре белән бергә, рәсмиләшкән татарчалары да язылдылар. Гарәпчә-татарча каршылыклары булмаганнары русча гына кылып тәгъриф кылындылар. Һәр сүзнең русча язылышы рус хәрефләре илә күрсәтелде» [1927-РТ_энц (г)].

Мистификация میستیفیکاتسییئ (گر، لات) نەرسە هەم ئشکە حییانەت وە ئالداو قاتشدئرو

*[**мистификация** (гр, лат.) нәрсә һәм эшкә хыянәт вә алдау катыштыру]*

Типический تیپیچسکی بر تیپکە حاس، شول بر تیپدەگنە بولا تۇرعان

*[**типический** бер типка хас, бер типта гына була торган]*

Мисаллардан күренгәнчә, сүзлек мәкаләләре бүгенге көндә басыла торган заманча энциклопедик сүзлекләрнекеннән шактый аерыла, мондый төр сүзлек төзү принципларына туры килеп бетми һәм күбрәк аңлатмалы сүзлекне хәтерләтә. Шул ук вакытта «Фәнни камус. Русча-гарәпчә һәм төркичә фәнни мәҗмугалар буенча тәгъриф кылынган фәнни, әдәби вә синагый истилахлар камусы» татар телендә 1950 елга кадәр төзелгән бердәнбер энциклопедик сүзлек булып санала һәм, беренче тәҗрибә буларак, һичшиксез,

зур игътибарга лаек. «Фәнни камус...» үзеннән соң төзелә торган мондый төр сүзлекләр өчен үрнәк булып торган һәм галимнәрне, тел белгечләрен җитди лексикографик хезмәтләргә алынырга рухландырган.

**Диалектологик сүзлек**

1921 елда Гыйльми үзәк оешудан соң башланган уңай үсеш-үзгәрешләр, 1939 елда Татарстан Совнаркомы каршында Тел һәм әдәбият институты ачылу, бер төркем сүзлекчеләрне туплаган тел бүлеге барлыкка килү лексикография юнәлешендә тагын да киңрәк планда эш җәелдерү өчен мөмкинлекләр бирә. Тәрҗемәле, терминологик, аңлатмалы, энциклопедик сүзлекләр рәтен дәвам итеп, 1920–1940 елларда татар лексикографиясе тагын бер төр сүзлеккә байый.

Сүз алып барыла торган чор диалектологик сүзлекләр төзелә башлау, дөресрәге, беренче диалектологик сүзлек төзелү белән тарихка кереп калган. Җирле сөйләшләрне тирәнтен өйрәнү, туплау, чагыштыру эшенә керешү, беренчедән, тел белеменең үсешен, икенчедән, телчеләрнең, диалектологларның җитлеккән, өлгергән, саллы хезмәтләр язарга әзер булуын күрсәтә.

1948 елда дөнья күргән «Диалектологик сүзлек» «татар теле диалектларын өйрәнү юлында беренче тәҗрибә» буларак тәкъдим ителә. Аны Л. Җәләй, Х. Шабанов, А. Камский, С. Әмиров кебек танылган галимнәр төзегән.

Хезмәттә татар теленең барлык диалектларында кулланыла торган сүзләр урын алган [1948-Т_диал_I].

Бит яулыгы (Акт.) – сөлге

Иләсә (Бард.) – бияләй

Кумырык (Гәй.) – аю баланы (бузина)

Мисаллардан күренгәнчә, сүзлеккә беренче чиратта көндәлек тормышта кулланыла торган предметлар һәм әйләнә-тирәдә кешегә иң еш очрый торган әйберләрнең (үсемлек, хайван, кош, киемсалым, савыт-саба, көндәлек кирәк-яраклары һ.б.) атамалары кертелгән. Диалектизмнарны билгеләүнең критерийлары, диалектологик сүзлек төзүнең төп принциплары тулысынча эшләнеп бетмәгән булса да, сүзлек беренче тәҗрибә буларак шактый кыйммәтле.

Билгеле инде, җирле сөйләшләргә хас киң кулланыштагы лексика күпмедер дәрәҗәдә моңа кадәр төзелгән сүзлекләргә дә кертелгән иде. Беренче татар сүзлекләренең аерым сөйләшләргә ни-

гезләнеп төзелгән булуы да мәгълүм. Соңрак чорда эшләнгән лексикографик чыганаклар да, мисал өчен, И. Гиганов сүзлеге (1804) себер диалектларының сүз байлыгын үз эченә алган, Н. Остроумов (1876, 1892), А. Воскресенский (1894) сүзлекләре керәшен татарлары сөйләшләре лексикасына нигезләнеп төзелгән һ.б. Алар телебезнең билгеле бер чорга хас җанлы телен чагылдыралар, шул чорның тормыш-көнкүреше турында бай мәгълүмат бирәләр.

Ә лексикографик принципларны күздә тотып диалекталь сүзләрне яктан тикшерү өчен гаять әһәмиятле чыганак булып торган «Диалектологик махсус бер сүзлеккә туплаган һәм татар телен, татар мәдәниятен тарихи сүзлек»не җирле сөйләш лексикасын чагылдыра торган сүзлекләр сериясен башлап җибәргән, әлеге юнәлешкә юл ачкан хезмәт дияргә мөмкин. Бу чынлап та шулай, чөнки 1950 еллардан соң татар теленең төрле сөйләшләренә хас сүзләрне, атамаларны туплаган сүзлекләр еш басыла башлый.

Күзәтү ясалган лексикографик чыганаклар 1920–1940 елларда сүзлек төзү эшенә зур игътибар бирелү хакында сөйли. Бу чорда барлыгы 41 сүзлек басылган һәм алар арасында 19 терминологик, 7 русча-татарча, 2 татарча-русча, 7 орфографик, 4 аңлатмалы, 1 энциклопедик, 1 диалектологик сүзлек бар. Бу елларда русча-татарча сүзлекләрнең аеруча актуаль булуы күренә: хәтта терминологик сүзлекләрнең дә күпчелеге русча-татарча. Сүзлекләрнең бер өлеше гарәп һәм латин графикасында. Бары тик 1939 елдан соң төзелгәннәре генә кирилл графикасында басылган. Тулы күзаллау булсын өчен, сүзлек мәкаләләре чыганактагыча, шул ук шрифтта бирелде.

Ассызыклап шуны әйтергә кирәк: шрифт алмашынулар сүзлекчеләр өчен шактый кыенлык тудырса да, 1920–1940 елларда татар лексикографиясенең һәр аерым тармагы даими эзлеклелек белән үсә барган. Әлеге чор, бер яктан, күзәтү ясалган терминологик, тәрҗемә, аңлатмалы һәм орфографик сүзлекләрдә татар теленең сүз байлыгы елдан-ел тулырак чагылуы, аларның тулылана, камилләшә баруы белән әһәмиятле булса, икенче яктан, тәүге диалектологик һәм энциклопедик сүзлекләр басылу белән игътибарга лаек. Шуңа да ул киләсе еллар лексикографиясе өчен үрнәк була алырлык, тарихка кереп калырлык продуктив чорлардан санала.

## § 10. XX гасырның 50–80 нче еллар сүзлекләре

Татар теле бай лексикографик традицияләргә ия. Халкыбыз тарихында сүзлек төзү эше XVIII–XIX гасырларга ук барып тоташа. Татар лексикографиясе узган чорларда ук төрки телләр арасында алдынгы урынны алып тора, ләкин чын-чынлап XX гасырның 50–80 нче елларында киң үсеш ала.

1950–1980 елларда Татарстан Республикасы иҗтимагый-иктисади яктан үсеш кичерә. Илдә барган яңа төзелешләр, фәндәге яңа ачышлар татар тел белеменең дә яңа этапка чыгуына китерә. Узган гасыр урталарыннан башлап татар теленең грамматик төзелеше, туган телдә белем бирү, әдәби нормаларны эшләү һ.б. мәсьәләләр комплекслы тикшерелә башлый. Бу беренче чиратта Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты эшчәнлеге белән бәйле була. 1939 елда ук институтта башка тел галимнәре белән бергә лексикографлар төркемен дә үз эченә алган тел бүлеге ачыла. Биредә Нәки Исәнбәт, Гаяз Ишмөхәммәтов, Касыйм Хәмзин, Хәмит Мөштәри кебек күренекле галимнәр хезмәт куя. 1958 елда лексикографлар төркеме аерым сектор булып эшли башлый. Бу елларда лексикографларны туплап, аларның эш юнәлешләрен билгеләүдә зур көч куйган галимнәрнең берсе Г.С. Әмиров була. Аның җитәкчелегендә лексикография бүлеге ике зур юнәлештә эш башлый: 1) Татарча-русча сүзлек төзү; 2) Татар теленең аңлатмалы сүзлеген булдыру. Киләчәктә зур уңышларга китерәчәк әлеге хезмәтләрне тиешле югарылыкта башкару максатыннан, лексикография секторын киңәйтәләр, яңа хезмәткәрләр алалар. Алар арасында соңрак зур галим булып танылучы М.Г. Мөхәммәдиев, Г.Х. Ахунҗанов, Ф.А. Ганиев, И.А. Абдуллин да була. Сектор тарафыннан югарыда телгә алынган сүзлекләрне төзү принципларын билгеләү, аларга төгәллек кертү өчен, даими эшләп килүче фәнни семинар да оештырыла.

Шул рәвешчә, биредә эшләүче галимнәрнең тырышлыгы белән халкыбызның лексик һәм әдәби хәзинәсе төрле яклап тирәнтен тикшерелә, фәнни хезмәтләр языла, татар теленең сүз байлыгын туплаган сүзлекләр бер-бер артлы дөнья күрә. Шушы елларда галимнәр тарафыннан җитмешкә якын сүзлек чыга. Бу елларда басылган сүзлекләрнең түбәндәге төрләрен күрсәтергә мөмкин: а) аңлатмалы сүзлекләр; б) тәрҗемәи сүзлекләр; в) диалектологик

сүзлекләр; г) фразеологик сүзлекләр; д) терминологик сүзлекләр; е) орфографик сүзлекләр; ж) синонимик сүзлекләр һ.б.

**«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге».** 1950 – 1980 елларда татар лексикографиясенең иң зур казанышы булып өч томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» [1977-1981_Т_аңлат_I-III] тора. Ул 1977–1981 елларда СССР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институты тел галимнәре тарафыннан төзеп бастырыла. Сүзлекне төзүдә И.А. Абдуллин, М.Г. Мөхәммәдиев, Ф.Ә. Ганиев, Г.Х. Ахунҗанов, Р.Г. Әхмәтҗанов, Ш.С. Ханбикова, Ф.М. Газизова, С.Б. Вахитова, Р.К. Рәхимова, Л.Р. Гайнанова, Л.Т. Мәхмүтова, К.С. Сабиров кебек күренекле галимнәр катнаша. Сүзлекнең төп бурычы – татар әдәби теленең XIX гасырның ахырыннан алып хәзерге көнгә кадәр гомумкулланылышта булган лексик һәм фразеологик байлыгын туплап бирү; сүзләрнең мәгънәләрен һәм мәгънә төсмерләрен ачу, аларга грамматик-стилистик характеристика бирү, кулланылыш үзенчәлекләрен күрсәтү.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» төрки дөньяда галимнәр һәм халык тарафыннан югары бәяләнә, татар әдәби теленең иң тулы сүзлек хәзинәсе буларак таныла. Мәсәлән, әлеге сүзлекнең беренче томына карата язылган бәяләмәләрнең берсендә болай диелгән: «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» практик яктан гына түгел, ә бәлки чын фәнни әһәмияткә дә ия. Иҗади интеллигенциянең, нәшрият-редакцияләр, тел-әдәбият укытучылары, киң катлау укучыларның сорауларын канәгатьләндерү белән бергә, сүзлек материалларын полисемия һәм омонимнар, алынмалар, икетеллелек, фразеология, тарихи лексикология, татар әдәби теле үсеше кебек проблемаларны өйрәнгәндә киң файдаланырга мөмкин» [Зәкиев, Сафиуллина, 1978: 80]. Ул татар әдәби теле, сөйләм культурасы өчен кыйммәтле хезмәт булып тора. Әлеге сүзлек тел галимнәре, укытучылар, нәшрият хезмәткәрләре, иҗат кешеләре, киң катлау укучылар өчен чын фәнни әһәмияткә ия. Вакытлы матбугатта, фәнни җыентык-журналларда әлеге сүзлекне яктырткан күпсанлы мәкаләләрнең дөнья күрүе дә аның тюркологик лексикография өлкәсендә зур казаныш булуы хакында сөйли.

**Тәрҗемәи сүзлекләр**

1950–1980 елларда тәрҗемәи сүзлекләр төзү эше аеруча камилләшә, тармаклары киңәя. Бу юнәлештә әлеге сүзлекләр сыйфат ягыннан да алга китәләр: лексикографиядә фәнни максатлар

гамәли әһәмият белән үрелеп бара башлый, телнең лексик байлыгын төрле яклап системага салып тасвирлап бирергә тырышалар. Әлеге үзенчәлек аеруча шушы елларда дөнья күргән тәрҗемәи сүзлекләрдә яхшы чагылыш таба. Алар бу чорда барлыгы ике басылып чыга. Тәрҗемәи сүзлекләрнең түбәндәге төркемнәрен күрсәтергә мөмкин: а) русча-татарча сүзлекләр. Бу елларда барлыгы өч төрле русча-татарча сүзлек дөнья күрә, шуның берсе дүрт том булып чыга, берсе ике тапкыр бастырыла; ә) татарча-русча сүзлекләр; барлыгы өч төрле сүзлек берәр тапкыр нәшер ителә; б) мәктәпләр өчен чыгарылган телара сүзлекләрдән бу чорда ике төрле сүзлек чыга, шуларның М.И. Мәхмүтов тарафыннан эшләнгән «Русча-татарча мәктәп сүзлеге» өч тапкыр бастырыла; г) чит тел яисә алынмалар сүзлекләреннән әлеге елларда дүрт төрле лингвистик сүзлек халыкка тәкъдим ителә.

Русча-татарча сүзлекләргә бу чорда аеруча ихтыяҗ арта. Бу беренче чиратта җәмгыятьтә иҗтимагый-икътисади шартларның үсү, милләтара мөнәсәбәтләрнең ныгуы белән бәйле була. 1955 – 1959 елларда татар галимнәре тарафыннан (Ә.М. Ахунҗанов, Р.С. Газизов, С.Г. Әмиров, Ф.С. Фасеев, Л.Т. Мәхмүтов, М.Г. Гимадеев) дүрт томлы «Русча-татарча сүзлек» төзелә һәм нәшер ителә [1955-1959-РТ_I-IV].

Сүзлектә 80 меңнән артык рус сүзе һәм тәкъбирләре теркәлгән. Шулай ук элек булган аерым кимчелекләр төзәтелгән, сүзлекләр төзүнең зур тәҗрибәсе исәпкә алынган, рус һәм татар сүзләренең күптөрле мәгънә төсмерләре мисаллар белән төгәл дәлилләнгән, сүзләрнең стилистик һәм грамматик кулланылыш үзенчәлекләре күрсәтелгән. Бу сүзлек ике телле лексикографиянең кайбер теоретик мәсьәләләрен хәл итүдә шактый алга китә: рус теленең лексик-грамматик үзенчәлекләрен, русча нисби сыйфатларны, фразеологик берәмлекләрне һ.б.ны татар телендә бирү ысуллары ачыклана. Шулай ук кайбер русча терминнарны татарча бирү мәсьәләсе хәл ителә. Мәсәлән:

**ГЛУБОКО** *нареч.* – **1.** Тирән, тирәнтен, тирән итеп, тирәндә, тирәнлектә; *глубоко вырыть яму* – тирән итеп чокыр казу; **2.** Бик нык, тирәнтен; *он его глубоко уважает* – ул аны бик нык ихтирам итә; *глубоко переживать* – бик нык кайгыру; **3**. *безл.в знач.сказ.* тирән; *здесь очень глубоко* – монда бик тирән [1955-РТ_I: 193].

Әлеге сүзлек эчтәлек ягыннан бай, техник яктан чагыштырмача камил эшләнгән. Ул алга таба яңа сүзлекләр төзү өчен база, нигез ролен үти. Әмма күләм ягыннан артык зур булганлыктан, массакүләм сүзлеккә әверелә алмый. Шул сәбәпле татар лексикографиясе алдына бер томлык тәрҗемәи сүзлекләр төзү бурычы куела.

1971 елда Р.С. Газизов, К.С. Сабирова, Л.Т. Мәхмүтова, Ә.М. Ахунҗанов һ.б. галимнәр тарафыннан «Русча-татарча сүзлек» [1971-РТ] эшләнә. Ул үз эченә 50 меңләп сүзне туплап бирә. Бу сүзлекне эшләгәндә, төзүчеләр югарыда телгә алынган дүрт томлы «Русча-татарча сүзлек»кә, С.И.Ожеговның «Словарь русского языка» (1964) сүзлегенең яңа 6 нчы басмасына нигезләнәләр. Биредә сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре мисаллар белән аңлатыла, аларның эмоциональ-экспрессив төсмерләре, дөрес язылышы һәм басымы күрсәтелгән. Сүзлек нәшрият хезмәткәрләре, газета һәм журнал редакцияләрендә эшләүчеләр, язучылар, филологлар, тәрҗемәчеләр һәм киң катлау укучылар өчен чыгарылган. Сүзлекнең төзелешен күз алдына китерү өчен, түбәндәге мисалга тукталыйк:

**БРАТЬ** *несов.* – 1. Алу; 2. Алдыру, уңышка ирешү; *он берет умом* – ул акыл белән алдыра; 3. Тоту: *бери вправо* – уңга тот (борылу турында); 4. Кабу, чиртү: *рыба плохо берет* – балык начар чиртә. ♦ **Брать верх** – өстен чыгу, өстенлек алу. **Брать на себя смелость** – батырчылык итү, җөрьәт итү. **Брать прицел** – төбәү, төзәү. **Брать начало** – башланып китү, башлану; **река Кама берет начало в Уральских горах** – Кама елгасы Урал тауларыннан башланып китә. **Брать свое** – үзенекен итү; **Жизнь берет** – тормыш үзенекен итә. **Нож не берет** – пычак кисми, үтми. **Сила не берет** – көч җитми. **Брать за горло** – якасыннан алу (мәҗбүр итү). **Брать за живое, за сердце** – нык тәэсир итү. **Брать в штыки** – штыкка алу (кискен каршылык күрсәтү). **Брать под руку** – култыклап алу. **Брать ягоды (грибы)** – җиләк (гөмбә) җыю. **Брать в оборот** – шелтәләү, кирәген бирү, арт сабагын укыту. **Тоска берет** – эч поша. **Брать курс, направление** – юл тоту, юнәлеш алу. **Брать высоту** – күтәрелү (самолет, дирижабль турында). **Брать одну сторону медали** – берьяклы гына аңлау, мәсьәләнең (эшнең) бер генә ягын күздә тоту [1971-РТ: 49].

Мондый телара сүзлекләргә ихтыяҗ зур булу сәбәпле, 1984 елда Мәскәүнең «Русский язык» нәшриятында профессор Ф.Ә. Га-

ниев редакциясендә эшләнгән «Русча-татарча сүзлек» [1984-РТ] нәшер ителә. Аны шулай ук Казан Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшләүче Ә.М. Ахунҗанов, Р.С. Газизов, Ф.Ә. Ганиев, Л.Т. Мәхмүтова, М.Г. Мөхәммәдиев, Х.Г. Агишев, Х.Н. Мөхәммәтшин, К.С. Сабирова, Ф.Х. Хәсәнов кебек галимнәр төзи. 1986 елда бу сүзлек өстәмә тираж белән янәдән бастырыла. Ул 47 меңләп сүзне туплап бирә. Мәскәү редакциясендә чыккан әлеге хезмәт рус телен өйрәнү һәм куллану, рус теленнән татарчага тәрҗемә итү, аеруча аны мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында укыту ихтыяҗларын күздә тотып төзелгән. Ул С.И. Ожеговның «Словарь русского языка» (Мәскәү, 1977) хезмәтен өлге итеп алып эшләнә. Анда рус һәм татар телләренең сүзлек хәзинәсендәге, сүзләрнең мәгънәсендәге үзгәрешләр, яңа күренешләр – барысы да исәпкә алынган. Алдагы елларда басылган сүзлекләрдән аермалы буларак, әлеге сүзлектә архаиклашкан сүзләр төшереп калдырыла, тар даирәдә генә кулланыла торган яңа сүзләр кертелә, кайбер сүзләрнең яңа мәгънә үзенчәлекләре дә күрсәтелә. Сүзлекне «Географик исемнәр» дип аталган бүлек тәгәлли. Анда рус һәм татар топонимиясенә караган ялгызлык исемнәре теркәлгән.

Татарча-русча сүзлек нәшер итү юнәлешендә дә Тел, әдәбият һәм тарих институтының лексикография секторы зур көч куя. 1950 елда Р. Газизов, Н. Исәнбәт, Г. Ишмөхәммәтов тарафыннан эшләнеп, М. Гыймадиев редакторлыгында «Татарча-русча сүзлек» басыла [1950 - ТР]. 20 меңләп сүз һәм тәгъбирләрне үз эченә алган әлеге сүзлек лексикографик практика җәһәтеннән дә яңалык алып килә: авторлар кушма сүзләргә аерым игътибар итә башлыйлар. Бу сүзлек ул чорда укытучылар, тәрҗемәчеләр, иҗат кешеләре һ.б. өчен бердәнбер күләмле лексикографик хезмәт була.

1966 елда Мәскәүнең «Советская энциклопедия» нәшриятында «Татарча-русча сүзлек» [1966 - РМ] дөнья күрә. Бу хезмәтне төзүдә күп авторлар катнаша: К.С. Абдразаков, Г.С. Әмиров, А.Ш. Әсәдуллин, Г.Х. Ахунҗанов, У.Ш. Байчура, С.Б. Вахитова, Ф.М. Газизова, Ф.А. Ганиева, Г.И. Исхаков, М.Г. Мөхәммәдиев, М.М. Османов, Ф.С. Фәсиев, Г.Г. Фәхретдинов, К.Х. Хәмзин, Ә.Ш. Хәмидуллин, Ш.С. Ханбикова. 38 мең чамасы сүз һәм тәкъбирләрне туплаган әлеге сүзлек телебезнең лексик-фразеологик байлыгын, терминологик лексиканы моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә тулырак яктырта. Биредә беренче булып татарча сүзләргә грам-

матик һәм стилистик характеристика бирү гамәлгә кертелә, ягъни татар лексикография теориясе яңа үсеш баскычына күтәрелә. Сүзлек галимнәр, филологлар, тәрҗемәчеләр, укытучылар, мәктәп укучылары, телне өйрәнүчеләр өчен озак еллар дәвамында кирәкле кулланма булып тора.

1988 елда 25 мең сүз кертелгән «Татарча-русча сүзлек» басыла [1988 - ТР]. Төзүчеләре: Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре А. Абдуллин, Ф.Ә. Ганиев, М.Г. Мөхәммәдиев, Р.А. Юналиева. Сүзлек тәрҗемәчеләр, нәшрият хезмәткәрләре, укытучылар, студентлар һәм киң катлам укучыларны күздә тотып, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нә нигезләнеп эшләнә. Сүзлекнең төп максаты – татар сүзләренең русчага дөрес һәм төгәл тәрҗемәсен бирү. Шуның белән бергә, сүзләрнең грамматик һәм мәгънәви табигатен, кайбер тотрыклы гыйбарәләрне теркәү дә күздә тотылган була. Бергә татар халкының гореф-гадәте, тормыш-көнкүреше, мәдәнияте белән бәйле төшенчәләр, фразеологик байлык та теркәлә. Кулланылышта йөрми торган лексик берәмлекләр төшеп кала, шул чорда яңа кулланылышка кергән *лавсан, кримплен, поролон, комьютер, торгынлык* һ.б. кебек яңа сүзләр өстәлгән. Гомумән, бу хезмәт сүзлек төзү эшенә күп кенә яңалыклар да кертә. Мәсәлән, биредә фигыльләр, алдагы сүзлекләрдән аермалы буларак, *-рга/-ргә* кушымчалы инфинитив формасы белән бирелә. Аннары сүзләрнең морфологик үзенчәлекләре, ягъни теге яки бу сүзнең кайсы сүз төркеменә каравы әйтелә. Хәбәрлек сүзләр аерып күрсәтелә. Тезмә сүзләр белән фразеологик әйтемнәр китерелә. Сүзнең аңлатмасы өч өлештән тору да игътибарга лаек: баш сүз һәм аның мәгънәләре бирелә, аннан тезмәләр китерелә, аннан соң фразеология теркәлә. Мәсәлән:

**ЗУР** *прил.* **1.** большой, крупный, великий. **2.** большой (взрослый, старший по возрасту в знач. сущ. *зурлар* взрослые, старшие. **3.** велик (об обуви, о головном уборе и т.п.); *зур аяклы* большеногий; *зур башлы* большеголовый; *зур гына* довольно большой; *зур гәүдәле* рослый, здоровенный, дюжий; *зур корсаклы* ушастый, *зур күзле* глазастый ♦ *зур кылану* важничать; *зурга китү* осложняться, принять серьезный оборот; *зурга җибәрү* раздуть (дело); *зурдан кубу* (күтәрелү) хватить через край [1988-РТ: 99]

Бу хезмәттә телара сүзлекләр өчен яңалык кертелүен дә искәртергә кирәк. Биредә рус һәм татар сүзләре үзара омоним бул-

ган очракларда *к, г* хәрефләре янына калынлык билгесе өстәгәннәр, ягъни тирән тел арты авазларын күрсәткәннәр: *казакъ – казак, къарта – карта* һ.б.

Сүзлек ахырында ике кушымта бирелү дә сүзлекнең әһәмиятен тагын да арттыра. Беренче кушымтада Татарстанның географик атамалары, икенчесендә татар исемнәре урын алган.

Мәктәпләр өчен тәрҗемәи сүзлекләр бу чорда басылган сүзлекләрнең тагын бер әһәмиятле төре булып тора. Җәмгыятьнең алга баруы, милли бәйләнешләрнең ныгуы, лексикага интернациональ сүзләр үтеп керү, милли мәктәпләрдә рус телләрен уку-укыту кебек мәсьәләләр мондый төр сүзлекләргә ихтыяҗның зур булуын күрсәтә. Бу чорда мәктәпләр өчен барлыгы 3 төрле телара сүзлек басыла, кабаттан бастырылуын исәпкә алсак, бу төр сүзлекләр биш тапкыр дөнья күрә.

Г. Нугайбәк, М. Корбангалиевләр кебек күренекле галимнәрнең башлангыч мәктәпләр өчен сүзлекләр төзү традициясен дәвам итеп, 1951 елда Р.С. Газизов һәм М.Г. Гыймадиев тарафыннан төзелгән «Русско-татарский словарь: для начальной и семилетной школы» сүзлеге [1951-РТ_мәкт_(1)] халыкка тәкъдим ителә һәм тиз арада таралып та бетә. 1955 елда бу сүзлек яңартылып, тулыландырылып кабаттан бастырыла [1951-РТ_мәкт_(2)].

1967 елда М.И. Мәхмүтов төзегән «Русча-татарча мәктәп сүзлеге» [1967-РТ_мәкт_(1)] нәшер ителә. Татар мәктәпләрендә рус теле укыту таләпләрен искә алып эшләнгән шактый зур күләмле әлеге сүзлек шул чорда мәктәп укытучылары, укучылар өчен гаять кирәкле кулланма була. 1975 елда әлеге «Русча-татарча мәктәп сүзлеге» [1967-РТ_мәкт_(2)] тулыландырылып кабаттан чыгарыла.

Мәктәпләр өчен төзелгән сүзлекләр чыгу дәвам итә. 1989 елда М.Мәхмүтовнең «Школьный русско-татарский словарь» сүзлегенең [1989-РТ_мәкт_(3)] өченче басмасы дөнья күрә һәм озак еллар дәвамында укытучылар һәм укучылар өчен өстәл китабы булып хезмәт итә.

Тәрҗемәи сүзлекләр арасында берничә тел сүзләрен үз эченә алган сүзлекләр дә шушы чорда күренә башлый. Тикшерелгән чорда бу төргә караган өч төрле сүзлек нәшер ителә. 1954 елда, мәсәлән, Г.Ишмөхәммәтов «Төрки, фарсы, гарәп һәм казахча, татарча, русча сүзлекчә» [1954-ТиФГКзТР] эшли. 2600 сүз кергән бу хезмәт тел галимнәре, шушы телләр белән кызыксынучылар тарафыннан көтеп алына.

1965 елда «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге» [1965-ГТР_(1)] басыла. Әлеге хезмәт аеруча зур популярлык казана. К.З. Хәмзин, М.И. Мәхмүтов, Г.Ш. Сәйфуллин тарафыннан төзелгән сүзлекнең тиз арада таралып бетүе, сирәк китаплар рәтендә йөрүе, киләчәктә кабат-кабат бастырылуы гарәп-фарсы алынмаларына бай татар телендә мондый кулланмага ихтыяҗның зур булуын тагын бер кат раслый. 854 битле бу сүзлек шул чорның бай һәм кабатланмас, күпмедер өлеше инде әйләнештән төшеп калган лексик хәзинәсе теркәлгән. Биредә гарәп сүзләренең, берникадәр аңлатмалар белән, рус һәм татар телләренә тәрҗемәсе бирелә. Сүзләр XIII йөз шагыйре Кол Галидән башлап XX гасыр әдипшагыйрьләрнең әсәрләреннән, шулай ук төрле фәнгә караган дәреслекләрдән, элекке чор вакытлы матбугатыннан чүпләп тупланган. Алынмаларга сүзгә-сүз мәгънә бирү белән беррәттән, аңлатмалы сүзлекләрдәгечә, аңлатулар һәм, кирәк, тапканда, әдәбияттан алынган мисаллар да бирелә. Мәсәлән:

**Гали I** عالى сф. 1) Бөек, өстен, олы. *Күңел югарылана әллә нинди гали хис белән.* (М.Гаф.) 2) Биек, югары, күтәренке. *Ничек гали минем урным. Түбәннәр күрәмсез ди.* (Г.Тук.) 3) Югары, дәрәҗәле. *Телим булырга мин инсане гали...* (Г.Тук.)

**Гали II** عالى сф. Кыйбат, бәһалы, югары бәяле [1965-ГТР_(1): 72].

Сүзлекнең ахырында татар теленә кергән гарәп-фарсы алынмалары, аларның фонетик үзенчәлекләре хакында мәгълүмат биргән, гарәп теленең грамматикасын яктырткан белешмә урнашу аның бәясен тагын да күтәрә. Әле бүгенге көндә дә бу сүзлек тел белгечләре, киң катлау укучылар өчен шушы юнәлештә бердәнбер һәм зур әһәмияткә ия хезмәт булып тора.

1970 елда Г.Ф. Фазлыев, Г.Ю. Курамшина тарафыннан «Школьный немецко-русско-татарский словарь» [1970-НРТ_мәкт_(1)] төзелә. Ш.Әхмәдуллин редакторлыгында чыккан 144 битлек бу сүзлек укытучылар һәм урта мәктәп укучыларын күздә тотып эшләнә. Әлеге хезмәт заман таләпләре куйган бурычларны үтәп, мәктәпләрдә инглиз, немец кебек чит телләрне уку-укыту өлкәсендә ярдәмлек булыр дигән максаттан чыгып нәшер ителә.

**Терминологик сүзлекләр**

1950 – 1980 еллар терминологик сүзлекләр басылу эше үсеш алган чор буларак та тарихка кереп кала. Мәктәпләрдә, уку йортларында ана телендә төрле фәннәр укытыла башлау, фәнни-техник

яңарышлар, халыкның мәдәнияте үсү галимнәр алдына төрле тармакларга караган терминнарны тәртипкә китерү, аларның татарча тәрҗемәләрен булдыру бурычын куя. Бер-бер артлы терминологик сүзлекләр басылып чыга башлый. Шушы елларда егермедән артык терминологик сүзлек халыкка тәкъдим ителә. Аларда сәясәт, физика, биология, математика, авыл хуҗалыгы, география, тел белеме, педагогика, психология кебек өлкәләргә караган терминнар бирелә. Иҗтимагый тормышның барлык өлкәләрен дә иңләгән ул сүзлекләр мәктәп укытучылары, укучылар, студентлар, фән белгечләре һәм киң катлау укучылар өчен кирәкле хезмәт-кулланма булып тора. Бу төр сүзлекләр үзләрендә энциклопедик һәм лингвистик сүзлекләргә хас сыйфатларның икесен дә туплый диярлек. Аларда теге яки бу термин татар теленә тәрҗемә ителеп кенә калмый, ә аңа татарча аңлатма да бирелә. Бу елларда татар телендә ике дистәләп терминологик сүзлек нәшер ителә:

«Кыскача политик сүзлек» [1950-полит]

«Русча-татарча психология һәм педагогика терминнары сүзлеге» ([1950-РТ_псих, пед]

«Русча-татарча география сүзлеге» [1953-РТ_геогр]

«Русча-татарча техник терминнар сүзлеге» [1963-РТ_техн]

«Русча-татарча математик терминнар сүзлеге» [1970-РТ_матем]

«Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге» [1971-РТ_а/хуж]

«Русча-татарча биологик терминнар сүзлеге» [1972-РТ_биол]

«Русча-татарча физика терминнары сүзлеге» [1972-РТ_физ]

«Русча-татарча астрономия терминнары сүзлеге» [1974-РТ_астр]

«Русча-татарча география терминнары сүзлеге» [1977-РТ_геогр]

«Русча-татарча химия терминнары сүзлеге» [1978-РТ_хим]

«Русча-татарча физика терминнары сүзлеге» [1981-РТ_физ]

«Русча-татарча педагогика һәм психология терминнары сүзлеге» [1985-РТ_пед, псих]

«Русча-татарча биология терминнары сүзлеге» [1985-РТ_биол]

«Тематический русско-татарский словарь» (1989) [1989-РТ_темат]

Югарыда искәртелгәнчә, телгә алынган терминологик сүзлекләр төзелешләре ягыннан төрле принципларга нигезләнеп эшләнә. Бер төрле сүзлекләрдә русча терминының татарча эквиваленты бирелә. Икенче бер сүзлекләрдә русча терминның татар

телендәге вариантын бирү белән бергә, терминга аңлатма да китерелә. Кайбер сүзлекләрдә әлеге принципларның икесе дә кушылып китә.

Бу елларда тел һәм әдәбият белеменнән басылган сүзлекләр игътибарга лаек. 1953 елда татар телендә кулланылышта йөргән тел белеме терминнарын туплап, «Тел белеме буенча терминнар һәм әйтелмәләр сүзлеге» [1953-Т_терм, әйтелмә] нәшер ителә. Тел, әдәбият, тарих институтының Ш.А. Рамазанов, М.А. Фазлуллин, Р.Ф. Шакирова, Л.Җ. Җәләй кебек күренекле галимнәре төзегән бу сүзлек тел галимнәре, мәктәп укытучылары һ.б. өчен зур ярдәмлек буларак бастырыла. 1957 елда исә әдәби терминнар хакында мәгълүмат бирә торган «Әдәбият белеме сүзлеге» [1957-Т_әдәб] дөнья күрә. Н. Гыйззәтуллин төзегән әлеге сүзлек озак еллар дәвамында мәктәп укытучылары, әдәбият галимнәренең өстәл китабы ролен үти.

Узган гасырның 50–80 нче елларында дингә зур игътибар бирелмәсә дә, ислам дине турында белешмә сүзлекләр дөнья күрә. 1978 елда Я.Г. Абдуллин, Ш.Ш. Абилов, Р.Г. Балтанов һ.б. тарафыннан язылган «Ислам дине турында белешмә-сүзлек» [1978-РТ_ислам_(1)] басыла. 1981 елда бу сүзлек, яңартылып, кабат халыкка тәкъдим ителә. Сүзлектә, нигездә, ислам диненең килеп чыгу тарихына, аның өйрәтмәләренә, төп юнәлешләренә, бу дингә бәйләнешле оешмаларга һәм тарихи шәхесләргә бәйле терминнарга аңлатма бирелә. 200 биттән торган бу белешмә үз чоры өчен дә, бүгенге көндә дә гомуми мәгълүмат бирә торган актуаль хезмәт булып тора.

**Диалектологик сүзлекләр**

Татар теленең диалектология фәне үсә, галимнәр татарлар яшәгән төбәкләргә фәнни экспедицияләргә чыга, татар диалектлары буенча материал туплый башлыйлар. Нәтиҗәдә, диалекталь лексиканы туплап, аларга аңлатма бирүне күздә тоткан диалектологик сүзлекләр бастыру ихтыяҗы туа. Шулай итеп, бу елларда татар галимнәренең тырышлыгы белән, диалектология фәненең казанышы булып, өч диалектологик сүзлек дөнья күрә. 1953 елда Л.Җәләй редакциясендә тел галимнәре Н. Борһанова, Г. Якупова төзегән «Диалектологик сүзлек» [1953-Т_диал_(2)] нәшер ителә. Ул 1948 елда Тел, әдәбият һәм тарих институты бастырган «Диалектологик сүзлек»нең тулыландырылган икенче чыгарылышы

була. 1958 елда өченче тапкыр дөнья күрә. Ул «Диалектологик сүзлек»не [1958-Т_диал_(3)] Н. Борһанова белән Л. Мәхмүтовалар төзи. Әлеге сүзлектә галимнәр диалекталь лексиканы мөмкин кадәр тулы яктыртырга тырышалар.

1969 елда исә татар теленең урта һәм көнбатыш диалектына караган сүзләрне туплаган «Татар теленең диалектологик сүзлеге» [1969-Т_диал] нәшер ителә. Ул Н.Б. Бурганова, Л.Т. Мәхмүтова, З.Р. Садыйкова, Г.К. Якуповалар тарафыннан күпсанлы экспедиция вакытында тупланган материалга һәм узган елларда басылган сүзлекләргә нигезләнеп эшләнә.

Болардан тыш, диалектолог галимнәр үзләренең фәнни хезмәтләренә дә кушымта итеп сүзлекчәләр бирә башлыйлар. Мәсәлән, күренекле галимә Д.Г. Тумашева Себер татарларының телен фонетик, грамматик, лексик аспектларда өйрәнә, өч диалектны аерып күрсәтә. Шушы юнәлеш буенча монографияләрен бастыра. 1961 елда галимәнең «Көнбатыш Себер татарлары теле. Грамматик очерк һәм сүзлек» исемле хезмәте басыла. Анда кушымта рәвешендә себер татарларының телен яктырткан диалектологик сүзлек тә урын ала.

**Орфографик сүзлекләр**

Тикшерелә торган чорда язылыштагы фикер каршылыкларын, күп кенә орфографик кимчелекләрне бетерү, кушма сүзләр, гарәп-фарсы алынмалары язылышында уртак фикерләр булмау орфографик сүзлекләр бастыру мәсьәләсен көн тәртибенә куя. Бу чорда татар тел белемендә орфография сүзлеге төзү юнәлешендә, нигездә, А.Х. Нуриева эш алып бара. Аның «Орфография сүзлег»енең [1968-Т_орфогр_(1)] беренче басмасы 1968 елда, икенче басмасы 1973 елларда [1973-Т_орфогр_(2)] дөнья күрә. 90–110 битлек әлеге сүзлекләр башлангыч мәктәп укучыларын йөздә тотып эшләнгән була. Китапта киң кулланылышта йөри торган лексик берәмлекләр туплап бирелә. 1983 елда «Татар теленең орфографик сүзлеге» [1981-Т_орфогр] басылып чыга. Аның төзүчеләре: А.Х. Нуриева, Ф.С. Фасеев, М.И. Мәхмүтов. Бу сүзлеккә шул чорда кулланылышта булган алфавит һәм орфография кагыйдәләре нигез итеп алына. Анда татар телендәге 38 меңләп сүзнең дөрес язылышы теркәлә. Сүзләрнең дөрес язылышы традицион, фонетик, морфологик, график принципларга таянып бирелә. Кайбер очракларда сүзләр язылышының берничә варианты булуы искәр-

телә. Мәсәлән, *казах һәм казакъ*. Сүзләрнең сүз төркемнәре, төрләнешенә бәйле үзенчәлекләре дә мөмкин булган кадәр күрсәтелеп барыла. Мәсәлән: кайчак (рәв.); кайчан (алм.). Сүзләр төрләнгәндә аваз үзгәргән очракта, үзгәргән формалары да бирелә: *туй-туе, кабак – кабагы* һ.б. Фигыльләр исем фигыль формасында килә, кайбер очракта инфинитив формасы да күрсәтелә: *язу, язарга (инф.)*. Фигыльләр төрләнешенең дөрес язылышы да кайбер очракларда бирелә: *бизәү, бизә, бизим, бизисең, бизәр, бизәячәк* һ.б. Исемнәрнең тартым һәм килешләр белән төрләнешендәге язылыш юнәлеш килеше мисалында аңлатыла: *герб – гербка, гербына; кәгазь – кәгазьгә, кәгазенә* һ.б. Сүзлек галимнәр, мәктәп укытучылар, киң катлау укучылары өчен кирәкле, мөһим басма булып тора.

**Фразеологик сүзлекләр**

Татар теле – фразеологиягә иң бай телләрнең берсе. Кеше сөйләмен баетуда, көчлерәк һәм үткенрәк итүдә, тулырак ачуда әһәмиятле роль уйнаган фразеологик берәмлекләрне өйрәнә башлау XIX йөзгә Каюм Насыйри хезмәтләренә барып тоташа. Галим «Ләһҗәи татар» сүзлегенә, халык телендә йөргән күпсанлы лексик берәмлекләр белән бергә, фразеологик гыйбарәләрне дә теркәп калдырган. 1950 – 1980 елларда исә тотрыклы гыйбарәләр, мәкаль-әйтемнәр тупланган алты сүзлек нәшер ителә, шуның берсе ике томлы булып чыга. Фразеологизмнарны махсус туплап, җыентык итеп чыгару 1957 елга карый. Л. Җәләй, Н. Борһанова, Л. Мәхмүтова тарафыннан төзелгән «Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре» [1957-Т_фраз, мәкаль, әйтем] җыентыгына татар теленең алты меңләп фразеологик гыйбарәләре, мәкаль һәм әйтемнәре кертелгән. Җыентык ике өлешкә бүлеп эшләнгән. Фразеологик гыйбарәләр тематик бүлекчәләргә аерып бирелә. Кайбер фразеологик берәмлекләрнең мәгънәсе мөмкин кадәр тулы аңлатыла, әдәби әсәрләрдән, халык авыз иҗатыннан китерелгән мисаллар белән дәлилләнә, хәтта синонимик вариантлары да китерелә. Хезмәтнең фәнни-практик әһәмияте шунда: биредә тупланган гыйбарәләр бер үк сүзнең күп төрле фразеологик әйтемнәр составында очравын күрсәтә. 1959 елда исә, шушы ук авторлар тарафыннан әзерләнеп, «Русча-татарча фразеологик сүзлек» [1959-РТ_фраз] нәшер ителә. Бу кечкенә күләмле сүзлек булса да, рус һәм татар телләре фразеологиясен чагыштырма планда тикшеренү буенча беренче тәҗрибә итеп кабул ителә. Сүзлектә рус теленең өч меңләп

фразеологик берәмлеге теркәлеп, шуларга татар телендәге эквиваләнтлар бирелә. Биредә татар әдәби теленең фразеологик байлыгы белән беррәттән, халыкның җанлы сөйләмендә кулланыла торган гыйбарәләр дә урын ала.

Татар фразеологиясен өйрәнүгә зур өлеш кертүчеләрдән беренче чиратта үзенең фәнни эшен лексикографик тәҗрибә белән үреп баручы Г.Х. Ахунҗановны атарга кирәк. Галим фразеологик әйтелмәләрне фәнни-теоретик яктан тикшереп, «Татар теленең идиомалары» (1972) исемле монографиясен чыгара. Фәнни хезмәт белән бергә зур күләмле «Идиомалар сүзлеге»н [1972-Т_идиом] халыкка тәкъдим итә. Сүзлеккә җанлы сөйләм, матур әдәбият, иҗтимагый-публицистик әсәрләр, фәнни басмалар һәм вакытлы матбугат битләрендә кулланыла торган идиомалар байлыгы семантик, стилистик һәм гомумлексикографик кретерийлар нигезендә туплап, системага салып китерелә. Теркәлгән идиомаларга эзлекле семантик-стилистик аңлатмалар бирелә, мисаллар белән дәлилләнә.

Татар теленең фразеологик гыйбарәләрен тикшерүгә Г.Х. Әхәтов үзеннән зур өлеш кертә. Галим 1980 елда «Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге»н [1980-Т_фраз, әйтелмә] төзеп, халыкка тәкъдим итә. 1982 елда сүзлек яңартып кабаттан бастырыла. Бу хезмәтләр татар фразеологизмнарын туплау-өйрәнү юнәлешендә тагын бер адым була. Әлеге сүзлекләрдә татар теленең кулланылышта йөри торган 2500 фразеологик тезмәсе теркәлә, аларга аңлатма китерелә, әдәби әсәрләрдән мисаллар белән тулыландырыла.

Рус һәм татар фразеологизмнарын чагыштырма планда өйрәнүгә Л.К. Бәйрәмова үзеннән зур өлеш кертә. Аның тарафыннан төзелгән «Русско-татарский фразеологический словарь языка В.И. Ленина» хезмәтендә [1980-РТ_фраз] өч меңләп фразеологик гыйбарә урын ала. Анда рус фразеологизмнарының татарча эквивалентлары, аңлатмалары китерелә. Шулай ук рус фразеологик берәмлекләрен татарчага тәрҗемә итү, фразеокалькалар барлыкка килү кебек мәсьәләргә дә урын бирелә.

Татар теленең фразеологик байлыгы тупланган иң төп хезмәтләрдән Н. Исәнбәтнең 1989–1990 елларда басылган ике томлы «Татар теленең фразеологик сүзлеге»н [1989-1990_Т_фраз] атарга кирәк. 15 меңләп фразеологик берәмлек теркәлгән сүзлектә фразеологик әйтемнәргә аңлатма бирелә, аларның байтагының килеп

чыгышы, кулланыла башлавы хакында да мәгълүмат китерелә. Диалектларда гына кулланыла торган яисә искергән фразеологизмнар да *диал., искергән* дигән искәрмәләр белән күрсәтелеп барыла. Мәсәлән:

**АГАЧ АТКА АТЛАНДЫРУ** Кешене алдау, ялганга ышандыру, алдандырып калдыру. *Кайвакыт мәҗнүн кеби көлмәс һәм шатланмас идем, Син агач ат өстенә атландыручы булмасаң.* Г.Тукай

**АГАЧ БАШМАК** *хурл.* Фикерсез, туңбаш, иярчен кеше. Кем теләсә, шул аны аягына элгән башмак кебек ияртеп, сөйрәп китә алудан.

Элек шәкертләр тышка чыгарга шундый агач табанлы башмакның теләсә кемнекен сөйрәгәннәр [1989-1990_Т_фраз: 30].

Н.Исәнбәтнең бу сүзлеге фән-әдәбият галимнәре тарафыннан югары бәяләнә, зур хезмәт булып танылa. Халкыбызның тел байлыгын туплап биргән бу хезмәт бүгенге көндә дә әйтеп бетергесез кыйммәтле һәм бай чыганак санала.

**Синонимик сүзлекләр**

Бу чорда байтак кына татар галимнәре үзләренең лексикология өлкәсендәге фәнни тикшеренүләрен лексикографик практика белән бергә үреп баралар, ягъни җыелган фактик материалларын сүзлек рәвешендә туплап бастыралар. Мәсәлән, Ш.С. Ханбикова татар теленең синонимнарын тикшергән «Татар телендә синонимнар» (1961) исемле хезмәтеннән соң «Татар телендә синонимнар сүзлеген» [1962_Т_синон] нәшер итә. 400 дән артык синонимик ояны үз эченә туплаган әлеге хезмәт татар тел белемендә беренче синонимнар сүзлеге булып санала. [1980_Т_синон] дигән хезмәте дә дөнья күрә. Галим хезмәтләрендә синонимик сүзлекләр төзү принципларын да яктырта. Хезмәттән аңлашылганча, синонимик сүзлек барлык сүз төркеменең синоним сүзләрен туплап бирә. Теге яки бу сүзнең синонимнары, ягъни бер төшенчәне аңлата торган фразеологик һәм структур берәмлекләр, сүзләр белән бер дәрәҗәдә, синонимик рәт берәмлеге буларак күрсәтелә. Гомумкулланылыштагы иң актив сүз синонимнар рәтенең доминантасы итеп алына. Ш. Ханбикова сүзлеге озак еллар дәвамында бу өлкәдә беренче һәм бердәнбер хезмәт булып йөри. «Синонимнар сүзлеге»ннән бер үрнәк китерик:

*Сәламәтлек, саулык, исәнлек, тазалык, сихәтлек.*

Организмның һәртөрле авырулардан азат булуы, чирләмәве мәгънәсен аңлаталар. Сәламәтлек һәм саулык төсмерләр белән аерылмыйлар да кебек, исәнлектә тере, исән генә булу, ә тазалыкта нык, таза булу төсмерләре бар. Сихәтлек – шул ук сәламәтлек, ләкин хәзер телдән төшеп бара.

*Аңа ишегалларыннан, баскыч төпләреннән дәшеп, сәламәтлеген сорап калалар* (Г.Бәширов).

*Хатын сөя байлыкны, ир сөя саулыкны* (мәкаль).

*Аларның балаларының исәнлекләрен, саулыкларын сораша һәм Шәрифулланың үзенә карата мактау сүзләрен кызганмый* (А. Шамов).

*Байлыкның башы – тазалык* (мәкаль) [1962_Т_синон: 121].

**Ономастик сүзлекләр**

Узган гасырның 60 нчы елларыннан башлап ономастик эзләнүләрнең чикләре киңәя, төрле фәннәргә бәйләнешле рәвештә аны өйрәнү фәнни яктан тагын да тирәнәя бара. Галимнәрнең ономастик берәмлекләрне туплаган, анализлаган фәнни хезмәтләре, шул исәптән сүзлекләр дә дөнья күрә башлый. Г.Ф. Саттаровның «Татар исемнәре сүзлеге» [1981_Т_оном] дә фәнни-теоретик хезмәтнең лексикографик практика белән үрелеп баруының нәтиҗәсе булып тора. 10 меңгә якын (төрдәшләре белән 15 меңнән артык) кеше исемен туплаган бу китапны татар кеше исемнәренең беренче аңлатмалы сүзлеге дип тә атарга мөмкин. Биредә ир-ат һәм хатын-кыз исемнәренең килеп чыгышы, мәгънә үзенчәлекләре хакында мәгълүмат бирелә. Ул – татар лексикографиясе өчен зур яңалык, аңа ихтыяҗ зур булу сәбәпле, алдагы елларда яңартып, кабат-кабат бастырыла.

1984 елда, шулай ук ономастик тикшеренүләрнең нәтиҗәсе буларак, Ф.Г. Гарипованың «Татарстан гидронимнар сүзлеге»нең [1984_Т_гидрон_I] беренче китабы нәшер ителә. Китапка кертелгән материал галимнең бу өлкәдәге фәнни эшчәнлеге, еллар дәвамында Татарстан авылларына чыккан экспедицияләре нигезендә туплана. Сүзлеккә елгалар һәм инешләр, чишмәләр, күлләр, сазлыклар дип берничә өлешкә бүленеп, 3200 чамасы елга, күл, чишмә һәм сазлык атамалары теркәлгән. Һәрбер гидронимик терминның кайсы төбәктә, районда урнашуы, нинди елга бассейнына каравы турында мәгълүмат бирелә, кайбер очракта этимологиясе дә аңлатыла. Мәсәлән:

**Әлкәй елгасы** – *Поп* елг. (5) бассейны (Кыр шынталысы а., Алексеевский р.). 1. Әлмөхәммәт исеменең варианты Әлкәйгә (Саттаров, 1981, 236) мөнәсәбәтле булуы мөмкин. 2. Татар теленең гәй. сөйләшендә *әлкәй* – «бишек» )ТТДС, 1969, 542, 385); к. *Әлкәй чишмәсе* [1984_Т_гидрон_I: 144].

Гомумән, бу ономастик сүзлекләр, милләт, киң җәмәгатьчелеккә кирәкле кулланма булудан тыш, туган тел һәм туган як тарихын өйрәнүчеләр өчен дә кыйммәтле чыганак ролен үти, практик һәм теоретик яктан зур әһәмияткә ия.

Шулай итеп, XX гасырның 50–80 нче елларында татар теленең сүзлек хәзинәсен төрле яклап яктырткан алтмыштан артык сүзлек халыкка тәкъдим ителә. Әлеге сүзлекләрне төзеп, дөньяга чыгаруда, нигездә, Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре зур көч куя. Җәмгыять ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатыннан, яңадан-яңа сүзлекләр басылу алга таба да дәвам итә. Искиткеч зур тизлек белән үзгәреп торган хәбәрдарлык шартларында сүзлекләр фән, техника, мәдәният, мәгърифәт һәм башка шундый өлкәләрдә эшләүчеләр, мәктәп укучылары, студентлар, татар теле белән кызыксынучылар өчен гаять әһәмиятле чыганак булып хезмәт итәләр.

## § 11. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы сүзлекләре

Узган гасырның 90 нчы елларында илебездә зур үзгәрешләр башлана. Татарстанда татар халкы һәм башка милләтләрнең бай милли-мәдәни мирасын саклап калу һәм үстерүгә юнәлтелгән максатчан чаралар тормышка ашырыла. Илебездә дәүләт югарылыгында милли мәсьәләләр һәм тел өлкәсендә яңа үсеш концепциясен кабул итү, аны тормышка ашыру юнәлешендә эшләү татар телен саклап калу, өйрәнү һәм үстерү өчен яхшы шартлар тудыра. Республикадагы иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышта татар теленең әһәмияте һәм кулланылыш чикләре киңәя. 1992 елда «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы закон кабул итү дә татар телен үстерү юнәлешендә җитди адым була. Анда татар теле рәсми рәвештә дәүләт теле дәрәҗәсендәге тел буларак теркәлә. Шуның нәтиҗәсендә татар теленең абруе арта, аның рәсми аралашу өлкәсендә кулланылыш даирәсе киңәя. Шулар белән бергә татар телен һәм әдәби-мәдәни мирасны барлау, фәнни ни-

гездә өйрәнү-тикшерү юнәлешендә эш башлана. Мәсәлән, 1990 елларда өч томлы «Хәзерге татар теленең академик грамматикасы», татар фольклорының татар һәм рус телләрендә җыентыклары, Г. Исхакый, Г. Ибраһимов кебек классик язучыларның күптомлыклары нәшер ителә, фәнни югарылыкта эшләнгән фундаменталь хезмәтләр басыла – болар барысы да татар теленең барлык тармакларында да зур алга китеш булуы хакында сөйли.

Шул рәвешчә, сәяси-иҗтимагый тормыш, икътисад, мәдәният өлкәсендә барган үзгәрешләр нәтиҗәсендә телнең лексик системасында яңа сүзләр барлыкка килә, чит телләрдән терминнар керә, онытылган гарәп-фарсы алынмалары яңадан телгә әйләнеп кайта. Ә бу, үз чиратында, төрле эчтәлектәге сүзлекләр эшләп чыгаруга игътибар артуга китерә. Нәтиҗәдә, бу чорда татар лексикографиясе алга китә, сыйфат һәм сан ягыннан чын-чынлап зур үсеш кичерә. Иҗтимагый тормышның төрле өлкәләрен иңләгән яңа төр сүзлекләр дөнья күрә. Бу чорда 300дән артык сүзлек басылу татар лексикографиясенең зур казанышы булып тора.

Соңрак «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында милли лексикография юнәлеше яңа максатлар куеп эш итә башлый. Ике томлы «Татар теленең татарча-русча сүзлеге», күп төрле тәрҗемәи терминологик сүзлекләр, берничә тел сүзлекләре һ.б. шушы юнәлештәге эшчәнлекнең нәтиҗәсе булып тора.

XX гасыр ахыры – XX1 йөз башында басылган сүзлекләрне барлап чыкканнан соң, сан ягыннан шуны әйтергә мөмкин: бу чорда 190 лап ике тел сүзлекләре, 81 терминологик, 8 фразеологик, 8 алынмалар сүзлеге, 7 ортологик, 6 диалектологик һ.б. төр сүзлекләр дөнья күрә.

Соңгы елларда лексикографик практикага компьютер технологияләре үтеп керде. Бу, үз чиратында, милли лексикографиянең заман таләпләренә яраклашып үсүе, төрле электрон лексиконнар, интерактив сүзлекләр һәм башка төр фәнни хезмәтләр эшләү өчен зур мөмкинлекләр бирә. ТР Фәннәр академиясенең сайтында булдырылган электрон лексикографик фонд шулай ук дәүләт программасы кысаларында тормышка ашырылган зур хезмәт булып тора.

**Энциклопедик сүзлекләр.** 1990 еллар татар лексикографиясе тарихында гына түгел, гомумән, татар халкы тарихында истәлек-

ле еллар була. Бу чорда татар халкының иҗтимагый-сәяси, милли-мәдәни яктан үсешен күрсәткән факторларның берсе «Татар энциклопедик сүзлеге» була. Аның басыла башлау тарихы Татар энциклопедия институтының оешу елларына барып тоташа. 1989 елда ул СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты составында Татар энциклопедиясе бүлеге буларак оештырыла (мөдире Ф.С. Хәкимҗанов). 1994 елда Татар энциклопедиясе институты итеп үзгәртелә. Институт эшчәнлегенең төп юнәлешләре – рус һәм татар телләрендә күптомлы Татар энциклопедиясен, шулай ук тармак энциклопедияләре һәм башка фәнни басма-белешмәлекләр әзерләү һәм нәшер итү.

«Татар энциклопедиясе сүзлеге» — Татарстан һәм татар халкының үткәне һәм бүгенгесе турында беренче универсаль белешмә басма. Энциклопедик сүзлек Татарстан Республикасы Президенты М.Ш. Шәймиев Указы нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты тарафыннан төзелгән һәм 1999 елда – рус телендә, 2002 елда татар телендә Казанда Россия Фәннәр академиясе Татар энциклопедиясе институты нәшриятендә бастырып чыгарылган.

Бүгенге көндә татар һәм рус телләрендә татар халкының телен, тарихын, күренекле шәхесләрен һ.б яктырткан энциклопедик сүзлекләр дөнья күрә:

Татарский энциклопедический словарь [1999-Р_энц],

Татар энциклопедия сүзлеге [2002-Т_энц],

Татарская энциклопедия [2002–2014-Р_I-VI],

Татар энциклопедиясе [2008–2016-Т_энц_I-V],

Татарстан: иллюстрированная энциклопедия[2013_Р_иллюстрэнц_(1)], [2015_Р_иллюстрэнц_(1)].

Энциклопедик сүзлектә татар халкының тарихы, мәдәнияте, тормышы-көнкүрешенә мөнәсәбәтле сүз-атамалар яисә шәхесләр хакында мәгълүмат бирелә, кайбер очракта башка сүзгә кайтарыла. Аңлатма бирелəсе сүзләр гадәттәгечә алвафит тәртибендә урнаштырыла. Бер үрнәк китерик:

**«МӘГЪРИФӘТ»**, атналык газета. 1925 елның 16 гыйнварыннан 12 апреленә кадәр Кеми шәһәрендә (Финляндия) татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире – Х.Хәмидулла [2014_Т_энц:79].

Бу сүзлекләр татар халкы һәм Татарстанның борынгы заманнардан алып безнең көннәргә кадәрге тарихын һәм яшәешен яктырт-

кан татар телендәге беренче фәнни универсаль басма буларак, галимнәр, киң җәмгатьчелек тарафыннан югары бәяләнә.

Энциклопедик сүзлекләрдән кызыклы һәм үзенчәлекле тагын бер сүзлекне – күренекле галим Ф.Урманчеев тарафыннан эшләнгән өч томлык «Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек» китабын атарга кирәк. Мондый төр сүзлек – татар гуманитар фәннәре тарихында беренче тәҗрибә. Автор кереш өлештә мифлар, аларның төрләре хакында шактый тулы мәгълүмат бирә. Китапта атама яки төшенчәгә, төрле чыганакларга нигезләнеп, берничә биткә сузылган, тулы-төгәл, күләмле аңлатма бирелә, һәм аңлатма ахырында әдәбият исеме дә күрсәтелә. Төрки-татар халыкларының бик борынгыдан килгән ифрат бай рухи мирасына багышланган хезмәт буларак, ул тел, әдәбият, сәнгать, халык иҗаты, этнография өлкәләрендә эшләүче галимнәр, укытучылар, югары һәм урта уку йорты студентлары, гомумән, киң катлау укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

**Аңлатмалы сүзлекләр.** XX гасыр ахыры – XXI йөз башында илдә татар фәне үсүгә уңайлы иҗтимагый-сәяси шартлар тудырылу аңлатмалы сүзлекләр төзү юнәлешен дә үстереп җибәрә. Телнең лексик байлыгын, халыкның аң-мәдәни дәрәҗәсен, иҗтимагый-көнкүреш шартларының үсешен, үткәнен һәм бүгенгесен һ.б. чагылдырган аңлатмалы сүзлекләр бер-бер артлы дөнья күрә.

Мәгълүм булганча, аңлатмалы сүзлекләрдә телнең сүзлек хәзинәсе, аларның мәгънә төрләре, грамматик характеристикасы, алар кулланылышындагы мәгънә күчешләре, туры һәм күчерелмә мәгънәләре, шул сүз катнашында ясалган фразеологизмнар, кушма сүзләр һәм башка бик күп үзенчәлекләре мөмкин кадәр тулы яктыртыла. Шуңа күрә, аңлатмалы сүзлекләр төзелсен өчен, тәҗрибәле лексикографик җирлек таләп ителә. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты әнә шундый бай җирлек ролен үти дә инде.

XX гасыр ахырында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты бер томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н [2005-Т_аңлат] төзү эшенә керешә. Сүзлек төзелеп бетсә дә, аны редакцияләү эше ул елларда бик киеренке бара, чөнки бүлек хезмәткәрләре тулысынча яңара диярлек. М. Мөхәммәдиев, И. Абдуллин, Г. Ахунҗанов, С.Вахитова кебек тәҗрибәле лексикографлар дөньядан китеп баралар. Эшкә сүзлек төзүдә тәҗрибәсе

булмаган яшь белгечләр алына. Шуңа күрә сүзлекнең аерым проблемаларына караган семинарлар оештырыла, үзара фикер алышулар еш үткәрелә. Шулай да фәнни һәм практик авырлыкларны узып, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (Казан: «Матбугат йорты» нәшрияты, 2005. – 848 б.) [2005-Т_аңлат] дөнья күрә. Сүзлекне төзүдә М.Г. Мөхәммәдиев, И.А. Абдуллин, М.Б. Хәйруллин, С.Б. Вахитова, Ф.М. Газизова, Р.Г. Әхмәтьянов, Ф.Ә. Ганиев, Г.Г. Саберова, Д.Б. Рамазанова, Р.К. Рәхимова, Ә.Х. Алеева, Л.Г. Абдрахманова, Р.Р. Абдуллина, Л.Р. Мортазина, Ф.И. Таһирова, Ф.Ф. Гаффарова кебек галимнәр катнаша. Әлеге бер томлы аңлатмалы сүзлекнең максаты түбәндәгеләрдән гыйбарәт: XX йөздә кулланылышта булган лексик һәм фразеологик берәмлекләргә, аларның мәгънәләренә дөрес аңлатма бирү; сүзләрнең кайсы сүз төркеменә каравын һәм аларның нинди стилистик төсмердә булуын дөрес билгеләү; мөмкин кадәр аларның кулланылыш даирәсен ачыклау; боларның барысын да әдәбияттән китерелгән мисаллар белән дәлилләү; кайсы телдән алынуын күрсәтү. Сүзлеккә 60 меңгә якын лексик һәм фразеологик берәмлек кертелә, шуларның 52 меңе – мөстәкыйль сүз, 6 меңгә якыны – фразеологик берәмлек. Бу сүзлеккә, татар лексикографиясендә беренче буларак, татар теленең синтетик-аналитик тел булуын исәпкә алып, билгеле бер система нигезендә тезмә фигыльләрне кертү бурычы да куела. Сүзлектә сүзнең мәгънәсе өч юл белән аңлатыла:

а) тасвирый аңлатма. Мәсәлән:

**АБАГА** *ис. бот.* Тармакланып торган челтәрсыман зур яфраклы споралы үсемлек ◊ **Абага чәчәк атканда** «Беркайчан да булмас, өметсез» мәгънәсендә [2005-Т_аңлат: 15].

б) синонимнар ярдәмендә аңлату. Мәсәлән:

**АЗГЫН** *сф.* 1) Тәрбиясез, тыңлаусыз, йөгәнсез; бик шук. *А. бала. А. күңел ачу (куч.). А.җил (куч.)*; 2) Мораль тотнаксыз, әхлаксыз, бозык, юлдан язган, азып-тотып йөрүче. *Азгынның азгыны. А. хатын-кызлар. А. холыклы кеше*; 3) Тире авыруларына тиз бирелүчән тән турында. *А. тән.* [2005-Т_аңлат: 25].

в) сүзнең мәгънәсен ачыклау өчен, аны икенче бер сүзнең мәгънәсенә җибәрү. Мәсәлән:

**БИЕМ** *ис. диал. к.* **каенана** [2005-Т_аңлат: 85].

Сүзлек ахырында кушымталар бирелү хезмәтнең дәрәҗәсен һәм фәннилеген тагын да күтәрә. Ф.Ә. Ганиевның «Татар телендә

сүзләрнең структурасы һәм ясалышы», «Татар теленең морфологиясе турында кыскача белешмә» дигән язмаларында татар телендә сүз ясалышы һәм морфологик төзелешенә кагышлы мәгълүматлар кыска, төгәл һәм аңлаешлы итеп халыкка җиткерелә. Татарстан географиясенең атамалары исемлеге И.А. Абдуллин белән Р.Р. Абдуллина тарафыннан эшләнгән кушымтада чагылыш таба. Татар халкында кеше исемнәре, аларның килеп чыгышлары, семантик-грамматик үзенчәлекләре, аларның стилистик вариантлары һәм кыскача исемлеге Р.Г. Әхмәтьяновның «Татар телендә кеше исемнәре» кушымтасында яктыртыла.

Шул рәвешчә, бүгенге көндә бу сүзлек татар телендә сөйләшүчеләр, туган телебезне өйрәнүчеләр өчен генә түгел, төрки телләрне чагыштырып өйрәнүчеләр өчен дә кулланма, тикшерү материалы була ала.

Шушы бертомлык аңлатмалы сүзлек төзүдә тупланган уңай тәҗрибәне лексикограф галимнәр бераз соңрак «Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге»н [2005-Т_мәкт_аңлат] төзүдә файдаланалар. Әлеге хезмәт Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнеп, 2013 елда дөнья күрә. Ул күләм ягыннан кыскарак, куллану өчен уңайлы итеп, мәктәпләр өчен махсус төзелә. Әлеге сүзлек, мәктәп программасы күләмендә укучыларга туган телне үзләштерү, белемнәрен тирәнәйтү өчен, ярдәмлек буларак тәкъдим ителә. Аны татар телендә гомуми мәгълүмат алу чыганагы буларак та файдаланырга мөмкин.

Шушы чорда сүзлекче галимнәр берничә томнан торырга тиешле «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» төзү эшенә керешәләр. Аның төп бурычы – татар әдәби теленең лексикологик-фразеологик байлыгын мөмкин кадәр тулырак туплап чагылдыру; гомум кулланылышта булган сүзләргә, тотрыклы берәмлекләргә, аларның мәгънәләренә, мәгънә төсмерләренә тулы һәм төгәл аңлатма бирү; сүзләрнең грамматик, стилистик билгеләрен күрсәтү, кулланылыш үзенчәлекләрен барлау, матур әдәбият, публицистикадан китерелгән мисаллар белән дәлилләү. Сүзлеккә гомум кулланылышта булган төп лексик байлык белән беррәттән, яңа кулланылышка кергән яисә озак еллардан соң янә активлашкан алынма, архаик, тарихи, диалекталь, дини һ.б. лексика да кертелә. Хезмәтнең беренче томы 2015 елда нәшер ителә, бирегә барлыгы 11 меңгә якын сүз һәм 2 меңнән артык фразеологик берәмлек кертелә. Әлеге сүзлекнең

томнары басылу әле бүгенге көндә дә дәвам итә. 2019 елда үз эченә С – Т хәрефләренә караган 13300 дән артык сүз һәм 1800 гә якын фразеологик берәмлекне алган бишенче томы нәшер ителәчек. Бу сүзлекләр киләчәктә татар халкының рухи-мәдәни мирасын, тел байлыгын чагылдыра торган бай чыганак һәм мирас ролен үтәр.

**Тәрҗемәи сүзлекләр.** XX гасыр ахырында татар теле дәүләт теле статусы дәрәҗәсен алгач, илдә аның фән теле буларак үсешенә төрле яклап тәэсир итүче экстралингвистик һәм лингвистик факторлар барлыкка килә. Республикадагы сәяси, икътисади, иҗтимагый һ.б. үзгәрешләр лексик системаның семантик-семасиологик, генетик һәм стилистик яктан үсешенә китерә. Милли яңарыш, дөньяга караш үзгәрү белән бергә лексик система да яңа лексик берәмлекләргә байый. Нәтиҗәдә, тәрҗемәи сүзлекләргә игътибар һәм ихтыяҗ арта. Телнең сүзлек байлыгы семантик мөмкинлекләре һәм лексикасында барган үзгәрешләр нәкъ менә тәрҗемәи сүзлекләрдә яхшы чагылыш таба да инде. Бу төр сүзлекләр һәм татар, һәм рус телләрен өйрәнүдә чыганак, нигез ролен дә үти алалар. Татар галимнәре тарафыннан русча-татарча, татарча-русча сүзлекләр – икесе дә кабат-кабат эшләнә, күләмле тираж белән бастырыла. Мәсәлән, Ә.М. Ахунҗанов, Р.С. Газизов, Ф.Ә. Ганиев һ.б. кебек галимнәр тарафыннан төзелгән «Русско-татарский словарь» (М: Изд-во «Рус.яз», 1991. – 734 с.) 1991 елда яңартылып, өченче кат бастырыла [1991-РТ_(3)]. Якынча 47 меңләп лексик берәмлекне туплап бирүче бу хезмәтне телче галимнәр генә түгел, ә киң катлау укучылар да көтеп ала. Соңрак 1996 елда ике төрле «Русско-татарский словарь» [1996-РТ] басыла. Беренчесе Ф.Ә. Ганиев, Ф.Ф. Гаффарова тарафыннан, икенчесе Р.А. Юналеева, Р.Р. Абдуллина кебек сүзлекче галимнәр тарафыннан төзелгән була.

1998 һәм 2002 елларда 25 меңләп сүз һәм гыйбарәне үз эченә алган «Татарча-русча сүзлек»нең (Казань: Татар.кн. изд-во, 1998, – 462 с.) яңартылган өченче [1998-ТР_(3)] һәм дүртенче басмалары [2002-Т_(4)] нәшер ителә. Ф.Ә. Ганиев редакторлыгында И.А. Абдуллин, Ф.Ә. Ганиев, М.Г. Мөхәммәдиев, Р.А. Юналеева кебек күренекле галимнәр төзегән әлеге сүзлек шул елларда басылган иң күләмле хезмәтләрнең берсе дисәк тә дөрес булыр.

1997 елда Мәскәүнең «Инсан» нәшриятында Ф.Ә. Ганиев редакциясендә «Русча-татарча сүзлек»нең [1997-РТ_аңлат_(4)] төзәтелгән дүртенче басмасы дөнья күрә. Сүзлек «Татарстан Респу-

бликасы халыкларының телләре турындагы Закон»ны тормышка ашыру юнәлешендә эшләнә. Бу сүзлектә: 1) аерым рус сүзләренең тәрҗемәләре төгәлрәк бирелгән; 2) сүзлек татар әдәби теленең лексикасын активлаштырырга, туган телнең үз чаралары һәм инде югала язган сүзләрне торгызырга ярдәм итә; 3) алынмалар кабул итүче телнең дә байлыгын тәшкил итәләр, шуңа күрә актив кулланылыштагы рус һәм Европа алынмаларын ике телдә дә бирүне төзүчеләр урынлы дип санаганнар; 4) сүзлектән аерым искергән сүзләр һәм тәгъбирләр төшеп калган.

2007 елда ике томнан торган «Татарча-русча сүзлек» (Казан: Мәгариф, 2007) [2007-ТР_I-II] дөнья күрә. Анда 56 мең сүз, 7400 фразеологик берәмлек туплап бирелә. Сүзлекне төзүдә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Г.Х. Ахунҗанов, И.А. Абдуллин, Р.Г. Әхмәтьянов, М.Г. Мөхәммәдиев һ.б. катнаша. Редакцияләү эшен исә Ш.Н. Асылгәрәев җитәкчелегендә Ф.Ф. Гаффарова, Ф.И. Таһирова, О.Н. Бятикова, А.Ф. Гайнетдинова һ.б. башкара. Сүзлеккә «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә теркәлгән лексик берәмлекләрдән тыш, милли яңарыш нәтиҗәсендә кабаттан кулланылышка кергән гарәп-фарсы алынмалары, искергән сүзләр, диалекталь лексика да урын ала. Сүз төркемнәре, фигыль формалары, фразеологик берәмлекләр, исемнәрдә изафә мәгънәсенең бирелеше һ.б. күп кенә үзенчәлекләр сүзлектә чагылыш таба, мисаллар белән дәлилләнә. Мәсәлән:

**аксакал** *сущ.* 1. старец, старейшина; аксакал *обл.*; отцы (*ед. нет*) *устар.*; патриарх; *ыруг ~лары* старейшины (патриархи, отцы) рода; *авыл ~лары* сельские старцы; *әдәбиятыбызның ~лары* патриархи литературы 1. старец, седобородный человек; аксакал *обл*; ветеран.

Татар теленә игътибар, телне өйрәнүгә кызыксыну арту куллаnыр өчен уңайлы булган кесә сүзлекләренең кирәклегенә китерә. 1996 елда Ф.С. Сафиуллина тарафыннан 6 меңләп сүзне туплаган «Карманный татарско-русский и русско-татарский словарь» (Казань: Татар.кн.изд-во, 1996. – 286 с.) [1996-ТР+РТ] эшләнә. 1997 елда бу сүзлекнең икенче тапкыр бастырылуы бу елларда, илдә барган иҗтимагый-милли үзгәрешләр, татар теленә игътибар арту нәтиҗәсендә, кесә сүзлекләренә ихтыяҗның зур булуын күрсәтә.

Гомумән, бу чорда тәрҗемәи сүзлекләрнең басылуы чын-чынлап арта. Аеруча мәктәпләр өчен татарча-русча берничә төрле сүзлек басыла:

«Татарча-русча уку-укыту сүзлеге» (Казань, 1992). Төз. Ф.Ә. Ганиев, И.А. Абдуллин, Р.Г. Гатауллина, Ф.Ю. Юсупов [1992-ТР_уку].

«Татарско-русский учебный словарь» (Казан, 1993) [1993-ТР_учеб].

«Татарча-русча сүзлек» (Казан, 1995). Төз. И.А. Абдуллин, Ф.Ә. Ганиев, М.Г. Мөхәммәдиев, Р.А. Юналеева [1995-ТР_уку].

«Мой первый татарский словарь: илл. татарско-русский словарь» (Казан, 1995). Төз. Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисова [1995-ТР_иллюстр].

«Татарско-русский словарь для начальной школы» (М.: АСТ-Пресс, 1997). Төз. А.Х. Алеева [1997-ТР_мәкт].

Кайбер очракта галимнәр мәктәп дәреслегенә кушымта рәвешендә дә сүзлекләр тәкъдим итәләр. Мәсәлән, күренекле галим Ф.С. Сафиуллина сүзлекләре аеруча игътибарга лаек. Галимнең «Базовый татарско-русский, русско-татарский словарь для школьников» (Казань: Хәтер, 1997, – 65 с.) [1997-ТР+РТ_мәкт] сүзлеге мәктәп программаларында өйрәнелергә тиешле лексик минимумны күздә тотып эшләнгән. Бирегә барлыгы 3 мең татар, 2,5 мең рус сүзләре теркәлгән.

Ф.С. Сафиуллинаның «Татарско-русский иллюстрированный словарь для детей» (Казань: Изд-во «Заман», 1998. – 151 с.) [1998-ТР_иллюстр] сүзлеге исә – мәктәпкәчә яшьтәге, башлангыч мәктәп укучылары, укытучылар өчен эшләнгән сүзлек. Ул балаларны кызыксындырырлык итеп, төсле рәсемнәр белән бастырылган, һәрбер рәсем янына аның татарча-русча атамасы язылып бара.

2006 елда Ф.С. Сафиуллина «Русско-татарский иллюстрированный словарь для детей (пособие для воспитателей детских дошкольных учреждений и учителей начальных классов)» (Казань: Изд-во «Заман», 2006) [2006-РТ_иллюстр] хезмәтен халыкка тәкъдим итә.

1998 елда Ә.Ш. Әсәдуллин белән Ф.Ә. Әсәдуллиналар тарафыннан балалар өчен «Тел ачкычы (ключ к языку) (словарь для детей с картинками): пособие для учащихся нач. классов татарской школы» (Казань: Магариф, 1998) [1998-Т_мәкт] сүзлеге дөнья күрә. Шулай ук рәсемнәр белән бастырылган әлеге китап татар һәм рус телләрен генә түгел, ә инглиз телен өйрәнүне дә максат итеп куя.

2017 елда Ф.Ф. Харисов белән Ч.М. Харисовалар тарафыннан «Иллюстрированный татарско-русский тематический словарь» (Казань: Татар. кн. изд-во, 2017) [2017-ТР_иллюстр] эшләнә. Бу сүзлек кече яшьтәге мәктәп укучыларына эшләү өчен бик җайлы, кызыктыргыч, ул шигырь, әкият, табышмак, мәкаль-әйтемнәр, өстәмә биремнәр белән баетылган.

**Берничә тел сүзлекләре.** Телара сүзлекләрдән XX гасыр ахырында кабаттан бастырылган «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»н (Казан: «Иман» нәшр., 1993. Т. I. – 448 б.; Т. II – 448 б.) [1993-ГТР_I-II_(2)] искәртергә кирәк. К.З. Хәмзин, М.И. Мәхмүтов, Г.Ш. Сәйфуллин тарафыннан төзелеп, 1965 елда дөнья күргән әлеге хезмәт аеруча зур популярлык казана. Сүзлекнең тиз арада таралып бетүен, сирәк китаплар рәтендә йөрүен искә алып, халыкның бай тарихын һәм мәдәни мирасын иске чыганаклардан өйрәнүчеләргә, борынгы татар һәм гарәп телләре белән кызыксынучыларга ярдәмлек булыр дигән максат белән, 1993 елда бу сүзлек ике өлешкә бүлеп чыгарыла. Ә 2018 елда, сорау зур булу сәбәпле, Казанның «Иман» нәшриятында бер китап итеп кабаттан нәшер ителә [2018-ГТР_(3)].

Гарәп-фарсы алынмаларын туплаган сүзлекләрдән күренекле галим Җ.Г. Зәйнуллинның «Шәрык алынмалары сүзлеге» (Казан: Мәгариф, 1994. – 143 б.) [1994-Т_алынм] дөнья күрә. Сүзлектәге алынмалар XX гасыр башында дөнья күргән татар телендәге газета-журналлардан, әдәби, тарихи, сәяси эчтәлекле китаплардан һәм бүгенге вакытлы матбугат сәхифәләреннән сайлап алына. Билгеле бер күләмдә ялгызлык исемнәренә һәм аларның мәгънәләренә дә урын бирелә. Сүзлектә алынма лексик берәмлек теркәлә һәм аның хәзерге татар әдәби телендәге мәгънәсе аңлатыла, мәгънә төсмерләре күрсәтелә яисә татарча эквивалентлы языла. Мәсәлән:

**Бадам** ф. Миндаль чикләвеге.

**Баде саба** ф. Төньяк-көнчыгыштан искән йомшак җил.

Гомумән, татар халкы тормышында гарәп-фарсы алынмалары зур әһәмияткә ия. Бу, бер яктан, татар теленең лексик байлыгының күп өлешен гарәп-фарсы алынмалары тәшкил итү белән аңлатылса, икенчедән, соңгы елларда гарәп телендә басыла торган дини китапларга игътибар көчәю дә тәэсир итә. Дини текстларны дөрес уку максатыннан сүзлекләр чыгу шуның дәлиле булып тора. Мәсәлән, 2016 елда алынмалар сүзлегеннән Тел, әдәбият һәм сән-

гать институтының яшь галиме Р. Сәфәров тарафыннан төзелгән «Дини текстларга гарәпчә-татарча сүзлек» (Казан, 2016. – 652 б.) [2016-ГТ] дөнья күрә.

Мәгълүм булганча, XX гасыр ахырында төрки халыклар белән сәяси-мәдәни багланышлар аеруча җанланып китә. Шул мөнәсәбәтләр лексикография өлкәсендә дә чагылыш таба. Мәсәлән, 1992 елда В.Имамов редакторлыгында эшләнгән «Татарча-русча-төрекчә сүзлек» (Яр Чаллы: КамАЗ, 1992. – 127 с.) [1992-ТРТк] басыла. 1997 елда «Татарча-төрекчә сүзлек» [1997-ТТк] (Казан-Мәскәү: Инсан, 1997, 496 б.) халыкка тәкъдим ителә. Ф.Ә. Ганиев, Р.Г. Әхмәтьянов, Х.Ачыкгөз тарафыннан төзелгән сүзлеккә 22 меңгә якын лексик берәмлек кертелә. Ул төрек телен өйрәнергә теләүчеләргә төпле ярдәмлек, татар телен белергә теләүчеләр өчен дә белешмә булып торыр дигән максат белән эшләнә. 1998 елда «Төрекчә-татарча сүзлек» (Казан-Мәскәү: Инсан, 1998. – 559 б.) [1998-ТкТ] дөнья күрә. 20 мең чамасы сүз һәм гыйбарәне үз эченә алган сүзлекне Р.Әхмәтьянов, Р.Мөхәмәтдинов, Ф.Нуриева, Ф.Ганиев, А. Рәхимова кебек галимнәр төзи.

Инглиз теле тормышыбызга үтеп керү чит телләрне яхшырак өйрәнү кирәклеген күрсәтә. Нәтиҗәдә мәктәпләр, уку йортлары өчен тәрҗемәи сүзлекләргә ихтыяҗ арта бара. Шуларны күздә тотып, 2014 елда «Татарча-русча-инглизчә мәктәп сүзлеге» [2014-ТРИ_мәкт] нәшер ителә. Бу өч тел материалына нигезләнеп төзелгән мәктәп сүзлекләре арасында беренче тәҗрибә булып тора. А.Ә. Тимерханов, С.Ф. Гарифуллин тарафыннан төзелгән бу сүзлек мәктәптә татар, рус һәм инглиз телләрен үзләштерүдә гамәли кулланма буларак тәкъдим ителә. Сүзлеккә барлыгы 12 мең чамасы сүз, сүзтезмә һәм меңләп тотрыклы гыйбарә кертелә. Ул татар әдәби теленең киң кулланылышта йөргән актуаль лексикасын һәм фразеологиясен үз эченә ала.

**Терминологик сүзлекләр.** XX гасыр ахырында җәмгыятьтә барган үзгәреш-яңарышлар нәтиҗәсендә, татар теленең дәүләт статусы дәрҗәсенә күтәрелүе, аның кулланылыш даирәсе киңәю, илдәге фәнни-техник алгарыш телебезгә бик күп терминнар үтеп керү һәм яңа терминнар булдыру өлкәсендә барган эшчәнлек терминологик сүзлекләр бастыру ихтыяҗын тудыра. Галимнәр тарафыннан кыска вакыт эчендә теге яки бу иҗтимагый өлкә-юнәлешкә караган иң еш кулланылышлы сүзләрне, терминнарны туплаган

лексик минимумнар эшләнә башлый. Бу елларда күп кенә алынма терминнарның татарча эквивалентларын булдыру юнәлешендә уңышлы эш алып барыла. Аннары «Татарстан халыклары телләре турында»гы Татарстан Республикасы законы игълан ителү, Татарстан Республикасы халыклары телләре турындагы Законны гамәлгә ашыру буенча Комитет оештырылу һәм Программа кабул ителү, аның каршында төрле юнәлешле комиссияләр, шул исәптән терминологик комиссия төзелү татар теле үсешенә уңай шартлар тудыра. Тел турындагы законны гамәлгә ашыру төркеме мәдәният, икътисад, авыл хуҗалыгы, фән һәм техника, гомумән, тормышның барлык өлкәләрендә дә татарча терминнар системаларын булдыру, аларны камилләштерү максатын куя. Нәтиҗәдә XX гасыр ахырында терминологик сүзлекләр төзү юнәлешендә гаять актив эш башлана. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре, башка уку йортларының галимнәре XX гасыр ахыры – XXI йөз башларында төрле фәнни юнәлешләргә караган 120 ләп терминологик сүзлек эшләп чыгаруга ирешә. Алар турында тулы мәгълүмат терминологик сүзлекләргә багышланган махсус бүлекчәдә бирелә.

Әлеге сүзлекләрнең байтагы телче-галимнәрнең, татар зыялыларының үз теләк-максатлары нәтиҗәсендә төзелгән. Кыска вакыт эчендә фән, техника, сәнгать, әдәбият, сәясәт, икътисад, мәдәният, медицина, юриспруденция һ.б. тармакларга караган сүзлекләр эшләнә һәм алар елдан-ел камилләшә бара.

Сүзлекләрдә чагылыш тапкан терминнарның бер өлеше үзебезнең милли җирлектә туган татарча атамалар белән тәрҗемә ителсә, икенче өлеше алынма сүзләрне шул телдәгечә калдыру яисә калькалаштыруга нигезләнгән. Мәсәлән, икътисад, финанс, сәнәгать, хокук, авыл хуҗалыгы атамаларын туплап бирә торган «Русско-татарский словарь экономических терминов» (Казань: Изд-во «Раннур», 1999. – 448 с.) [1999-РТ_икът] сүзлегеннән мисал китерик. Түбәндәге очракта икътисадый терминнар тулысынча татарча сүз һәм сүзтезмәләре белән күрсәтелгән яисә аңлатып кителгән:

**денонсация** 1) ğəməldən çiğaru // гамәлдән чыгару; 2) ğəməldən çiqqan dip belderü // гамәлдән чыккан дип белдерү

**национальные банкноты** milliaqçalar // милли акчалар

Түбәндәге мисалларда терминнарның чыганак телдәгечә калу яисә калькалаштырылуы күренә:

**механизатор** mexanizator // механизатор

**многоукладная экономика** küpukladliiqtisad// күп укладлы икътисад

Терминологик сүзлекләр арасында цикллап чыгып килгәннәре бар. Мәсәлән, А.Б. Халидов, А.С. Кузнецова, В.И. Гаранин һ.б. тарафыннан төзелгән «Азбука природы: Русско-татарский, татарско-русский словарь биологических терминов» [1996-2002-РТ+ТР_биол_I-VI] сүзлеге 1996 – 2001 еллар аралыгында 6 китап булып басыла. Бу сүзлекләрдә биология фәненең барлык өлкәләре дә (гөмбәләр, кошлар, җир-су хайваннары, сөйрәлүчеләр, бөҗәкләр һ.б.) чагылыш таба диярлек. Сүзлекнең керешендә теге яки бу хайван төре турында кыскача мәгълүмат бирелә. Аннары сүзлек өлеше китә. Мәсәлән, «Азбука природы: рыбы, земноводные. Пресмыкающиеся» (Казань: Магариф, 2001. – 79 б) [1996-2002-РТ+ТР_биол_VI:10] сүзлегеннән үрнәк китерик:

**АБДОМЕН** (брюшко) – корсак (хайваннарда)

**АВТОТОМИЯ** – автотомия (кайбер хайваннарның гәүдә өлешен өзеп калдыру сәләте)

**АГАМОВЫЕ** – агамалар (кәлтәләр семьялыгы).

Соңгы елларда биологик терминологиядән балык һәм кош атамаларын җентекләп тикшереп, системага биргән сүзлекләр дөнья күрде:

Татарча-русча-латинча кош атамалары сүзлеге (2018). Төз. Э.И. Сафина [2018-ТРЛ_кош];

Балык атамаларының татарча-русча-латинча аңлатмалы сүзлеге (2019). Төз. О.Н. Галимова [2019-ТРЛ_аңлатм_балык].

Халык сәнәгате, сәнгать, музыка өлкәсенә караган терминологияне яктырткан сүзлекләргә дә игътибар зур:

Русско-татарский музыкальный словарь (2007). Төз. И.Г. Алмазов, Д.Б. Рамазанова [2007-РТ_музык];

Тасвири сәнгать, архитектура һәм китап сәнгате аңлатмалары: аңлатмалы сүзлек (2011). Төз. Ф.Г. Вагапова [2011-Т_аңлат_сәнг, архит];

Татарча-русча тукучылык һәм тегүчелек атамалары сүзлеге (2018). Төз. Р.К. Рәхимова [2018-ТР_туку, тегү].

Хәрби лексиканы өйрәнү, шушы тармак белән бәйле терминнарны тикшерү, системага салу, сүзлек итеп туплап чыгару юнәлешендә дә галимнәр эш алып бара:

Русско-татарский словарь военных терминов (2000). Төз. Р.А. Мугинов [2000-РТ_хәрби];

Татарча-русча хәрби лексика сүзлеге (2017). Төз. Р.Т. Сәфәров [2017-ТР_хәрби].

Терминологик сүзлекләр төзү юнәлешендә татар лексикографиясе шактый алга китә. Кайбер фәнни тармакларда өч телгә караган сүзлекләр басыла башлый. Мәсәлән:

Краткий русско-татарский толковый словарь медицинских терминов (с эквивалентами на английском, на английском, немецком, французском и латинском языках) (1994). Төз. М.М. Миннебаев [1994-РТ_аңлатм_мед];

Толковый словарь-справочник по физике, химии и химической технологии на русском, татарском и английском языках (1995). Төз. Р.С. Сәйфуллин [1995-РТИ_аңлатм_физ, хим/технол];

Англо-русско-татарский тематический словарь: Соматическая фразеология казань (1994). Төз. Л.Я. Апакова [1994-АРТ_темат_фраз];

Англо-русско-татарский словарь физических терминов (1996). Төз. З.М. Вәгыйзова, Г.Ю. Даутов, О.Аслан [1996-АРТ_физик];

Англо-татарско-русский словарь общестроительной лексики (1996). Төз. В.И. Кафиатуллина [1996-АТР_строит];

Немецко-татарско-русский словарь общестроительной лексики (1996). Төз. В.И. Кафиатуллина [1996-НТР_строит].

2015 елда, бүгенге көндә актуальлеген исәпкә алып, «Англо-русско-татарский словарь компьютерных терминов» [2015-АРТ_компьют] сүзлеге халыкка тәкъдим ителә. А.Ә. Тимерханов, Ф.И. Таһирова, Р.Т. Сәфәров тарафыннан төзелгән әлеге сүзлеккә компьютер белән бәйләнешле 3 меңнән артык термин һәм терминологик сүзтезмә кертелә. Сүзлек шушы өлкәдә эшләүчеләр һәм киң катлау укучылар өчен чыгарыла.

2017 елда информатика фәнен үзләштерүдә ярдәмлек буларак, Л.Л. Салехова, Н.И. Батрова, А.В. Данилов төзегән «Информатика и ИКТ: русско-татарско-английский глоссарий компьютерной лексики» (Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2017. – 114 с.) [2017-РТА_инфор, ИКТ] сүзлекчәсе басыла. Китапка информатика һәм мәгъ-

лүмати-коммуникацион технологияләр өлкәсенә караган 200 ләп терминның рус, татар һәм инглиз телләрендә тәрҗемәләре бирелә, һәркайсына аңлатмалар китерелә.

**Тел һәм әдәбият терминнары сүзлекләре.** Бу чорда әдәбият һәм тел терминнарын өйрәнү, аларны туплап сүзлекләр итеп чыгаруга да галимнәр зур игътибар бирә башлый. 1990 елда күренекле әдәбият галиме А.Г. Әхмәдуллин «Әдәбият белеме сүзлеге» [1990-Т_әдәб] төзеп бастыра. Ф.С. Сафиуллина «Татарча-русча тел белеме терминнары сүзлеге» (Казан: Хәтер, 1998, 127 б.) [1998-ТР_тел/бел] нәшер итә. Анда 4500 татарча терминнар тупланып, русчага тәрҗемә итеп бирлегән. Автор терминнарны татар теле дәреслекләреннән, узган гасырлардан ук чыга килгән татар грамматикаларыннан тупланган. Сүзлектә аерым терминнар тәрҗемә ителсә дә, аларны оялап бирү прицибы сакланган:

| **Иҗек** | **Слог** |
|---|---|
| басымлы | ударный |
| басымсыз | безударный |
| ачык | открытый |
| ябык | закрытый |
| беренче | первый |
| соңгысы | последний |

2016 елда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре (О.Н. Галимова, И.И. Сабитова, Р.Р. Абдуллина, Ф.Ф. Гаффарова, Ф.И. Таһирова, Ф.К. Сәгъдиева) тарафыннан төзелгән «Лингвистик терминнарның русча-татарча аңлатмалы сүзлеге» [2016-РТ_аңлатм_лингв] дөнья күрә.

Х.Г. Агишевның «Русско-татарский словарь словосочетаний» (Казань: «Матбугат йорты», 1998. – 511) [1998-РТ_словосоч] хезмәте дә тел галимнәре, татар телен өйрәнергә һәм өйрәтергә теләүчеләр өчен зур ярдәмлек буларак басыла. Мондый төр сүзлекләр бүген дә басылуын дәвам итә.

**Кыскартылмалар сүзлеге** 2005 елда дөнья күрә. Ф.Г. Миңнуллин төзегән «Татар теленең кыскартылмалар сүзлеге» [2005-Т_кыскарт] русча-татарча өлешендә якынча 3500 берәмлек, татарча-русча өлешендә 850 ләп берәмлекне туплап бирә. Бу хезмәт татар теленең кыскартылма сүзлекләрен бирә торган бердәнбер хезмәт булып тора.

**Сүзьсалыш сүзлекләре** телнең сүзьсалыш оялары, сүзләрнең морфемаларга бүленеше кебек үзенчәлекләрне бирә. Мондый сүзлекләрдән 2007 елда А.М. Ямалтдинова тарафыннан төзелгән «Тематический русско-татарский словообразовательный словарь: на материале тематической группы «Человек. Части человеческого тела (организма)» [2007-РТ_темат_словообр_человек], 2015 елда сүзлекче галим И.Сабитованың «Татар теленең сүзьясалыш сүзлеге: «кеше» [2015-Т_сүзъяс] тематик төркеменә караган лексика» китабы нәшер ителә. Бу сүзлектә татар телендәге «кеше» сүзенә караган лексик берәмлекләр сүзьясалыш ояларына туплап бирелә. Ояларда урнашкан ясалма сүзләрнең алфавит тәртибендә аерым исемлеге дә тәкъдим ителә. Һәрбер ясалма сүз үзе урнашкан ояның нумерациясенә туры килгән индекс белән урнаштырыла. Хезмәт татар филологиясе галимнәренә, укытучыларга, студентларга, мәктәп укучыларына тәкъдим ителә һәм татар телен өйрәнергә теләүчеләр өчен дә уңайлы кулланма була ала.

**Неологизмнар сүзлеге** – яңа предмет яисә төшенчәләрне атау максатыннан сөйләмгә яңа кулланылышка кергән сүз яисә сүзтезмәләрне туплап бирүче сүзлек. 2014 елда Р.Р. Абдуллина тарафыннан төзелгән «Русча-татарча актуаль лексика сүзлеге» басыла [2014-РТ_лекс]. Анда 5500 сүз теркәлгән.

XX гасыр ахырында татар теле фән буларак та үсеш кичерә. Антоним, омоним, синоним сүзлекләр барлыкка килә.

**Антонимик сүзлекләрдән** тикшерелә торган чорда өч сүзлек дөнья күрә. Ф.С. Сафиуллина белән Л.М. Ризвановалар тарафыннан «Татарча-русча антонимнар сүзлеге» (Казан: Хәтер, 1997. – 96 б.) [1997-РТ_антон] бу өлкәдә беренче тәҗрибә була. Анда 1000 парга якын антонимнар әлифба тәртибендә тупланып бирелгән һәм русчага тәрҗемә ителгән. Антонимнарның мәгънә төрләре татар халык мәкальләре ярдәмендә раслана. Мәсәлән:

Аз — күп
Аз — мало
Күп — много

*Аз малың, күп куанычың булсын. Аз хәрәкәт, күп бәрәкәт. Ярлылыкның азы да күп. Бүре күп — ите аз. Аз булса да җитәр, күп булса да бетәр. Мең дус аз, бер дошман күп. Аз булса да, күп итеп ал.*

2003 елда «Татарча-русча, русча-татарча антонимнар сүзлеге» басылып чыга [2003-ТР+РТ_антон]. 2005 елда тагын бер төр-

ле «Антонимнар сүзлеге» халыкка тәкъдим ителә [2005-Т_антон]. Биредә 2500 антонимик пар тасвирлана, иллюстратив материал буларак, матур әдәбият әсәрләреннән һәм фольклордан мисаллар китерелә.

**Омонимик сүзлекләр** татар телендә узган гасыр ахырында гына басыла башлый. Беренче сүзлек 1997 елда чыга. Аны Ф.С. Сафиуллина, Л.М. Ризванова төзи. «Татар теленең омонимнар сүзлеге» [1997-Т_омон] дип аталган бу хезмәттә 1000 нән артык омоним теркәлә. Омонимнар русчага да тәрҗемә итеп бирелә. Әдәби телдәге лексик омонимнар күпчелекне тәшкил итсәләр дә, аерым очракларда кайбер диалекталь яисә гомум кулланылыштагы омоформалар да урын ала. Берничә мисал китерик:

ал I — алый, розовый
ал II — передняя часть
ал III — диал. хороший, прекрасный
ал IV — диал. ал тел; льстивый, сладкоязычный
ал V — бери, возьми (повел. накл., II лицо, ед.ч.)

2004 елда ике томлык «Татар теленең аңлатмалы омонимнар сүзлеге» нәшер ителә [2004-Т_омон]. Биредә 2300 омонимик оя туплап бирелә. Омонимнар рус теленә тәрҗемә ителә, аларның грамматик һәм стилистик билгеләре күрсәтелә, мәгънә үзенчәлекләре матур әдәбияттан китерелгән мисаллар белән дәлилләнә.

Синонимик сүзлекләр мәгънәдәш сүзләрне туплап бирә. Синонимнар – чын мәгънәсендә тел байлыгын билгели торган сүзләр. Аларның сүзлекләрен төзү зур әһәмияткә ия. 1999 елда Ш.Ханбикова белән Ф.Сафиуллинаның «Синонимнар сүзлеге» басыла [1999-Т_синон]. Анда 600 ләп синонимик оя туплап бирелә. Доминантасы рус теленә тәрҗемә ителә. 2014 елда шушы ук авторларның «Татар теленең синонимнар сүзлеге» [2014-Т_синон] кабаттан бастырыла. Анда 25 мең сүз, 4500 синонимик оя туплап бирелә.

**Ортологик сүзлекләр** – әдәби телнең гамәлдәге кагыйдәләрен ныгыту, тел һәм сөйләмне камилләштерү өчен хезмәт итә торган норматив сүзлекләр. Аларга орфографик һәм орфоэпик сүзлекләр керә.

Орфографик сүзлекләрдә сүзләр дөрес язылышта алвафит тәртибендә бирелә. Массакүләм мәгълүмат чараларында, басылып чыккан хезмәтләрдә, фәнни тикшеренүләрдә татар теленең орфографиясе проблемаларын хәл итүгә карашлар төрлелеге һәм шак-

тый сүзләрнең язылышында вариантлылык һәрбер чорда да яшәп килә. Дөрес язу проблемаларын тулаем берьюлы гына хәл итеп бетерү мөмкин түгел. Шуңа күрә татар теленең тулы, системалаштырылган орфографик сүзлеген булдыру — гаять мөһим һәм катлаулы мәсьәлә, һәм ул еллар дәвамында киң катлам белгечләр тырышлыгы белән хәл ителә һәм кат-кат бастырыла.

1990 елларда илдә барган үзгәртеп корулар белән бәйле вакыйгалар, татар телен үстерү, камилләштерү, аны дәүләт статусы дәрәҗәсенә күтәрү юнәлешендә барган эшчәнлек телнең эчке үсешендә дә үзгәрешләр кертә. Аннары бу елларда барган латин графикасына күчү хәрәкәте дә орфографик мәсьәләләрнең актуальләшүенә китерә. Шуларның нәтиҗәсе буларак, 1996 елда А.Х. Нуриеваның башлангыч мәктәп укучылары өчен эшләнгән «Татар теленең орфографик сүзлеге»нең 4 нче басмасы дөнья күрә [1996-Т_орфог_(4)].

Яңа гасырда телдәге лексик хәзинәне мөмкин кадәр тулы чагылдырган яңа сүзлекләр пәйда була. Мәсәлән, 2002 елда Ф.Ә. Ганиев, И.И. Сабитова тарафыннан төзелгән «Татар теленең орфографик сүзлеге» (Казан: Раннур, 2002) [2002-Т_орфог] халыкка тәкъдим ителә. Бу орфография сүзлеге гомум кабул ителгән кагыйдәләр нигезендә төзелә. Шул елларда кулланылышка кертелгән лексик берәмлекләр, татар тел белеменең үсешенә бәйләнешле яңалыклар кертелә. Сүзлектә 140079 сүз һәм сүзформасы теркәлә. Сүзләрнең сүз төркемнәре, аларның төрләнешенә бәйле үзенчәлекләре, сүзләр төрләнгәндә аваз үзгәргән очракта, үзгәргән формалары да мөмкин булган кадәр күрсәтелеп барыла.

2003 елда Ф.М. Газизова төзегән «Татар теленең латинда һәм кириллда орфография сүзлеге» басыла [2003-Т_орфог]. Бу сүзлектә кулланылыштагы орфография кагыйдәләрен исәпкә алып, укучылар, студентлар, укытучылар, нәшрият һәм газета-журнал редакциясе хезмәткәрләре өчен эшләнгән була.

2010 елда Казанда «Мәгариф» нәшриятында «Татар теленең орфографик сүзлеге» нәшер ителә [2010-Т_орфог]. Ул К.Р. Галиуллин, Р.И. Раскулова тарафыннан төзелә. Әлеге сүзлектә хәзерге татар әдәби теле лексикасының төрле катламнары якынча 43 мең сүз итеп туплап бирелә. Шулай ук басмада «Татарстан Республикасындагы торак пунктлар исемнәре» сүзлеге дә урын ала. Китапның ахырында исем һәм фигыль формаларының ясалышы

һәм язылышы турында мәгълүмат тупланган белешмәлек бирелә. Укучылар, студентлар, укытучылар, нәшрият һәм редакция хезмәткәрләре һәм, гомумән, татар теле белән кызыксынучылар өчен чыгарыла.

2017 елда исә К.Р. Галиуллин һәм Р.И. Раскулова авторлыгында эшләнгән «Татар теленең орфографик сүзлеге: Сүзлек. Морфологик-орфографик белешмәлек» (Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2017. – 423 б.) [2017-Т_орфог] халыкка тәкъдим ителә. Сүзлектә хәзерге татар теле лексикасының төрле катламнары урын ала. Сүзлеккә 46 мең чамасы сүз керә һәм анда өч миллионлап исем (22 меңнән артыграк сүз) белән фигыль (9 меңнән артык сүз) формаларының ясалышы һәм язылышы турында мәгълүмат бирелә. Сүзлек соңгы елларда кулланышка кергән лексик берәмлекләр исәбенә тулыландырыла.

Орфоэпик сүзлекләрдә сүзләрнең дөрес әйтелеше һәм сүз басымы чагылыш таба. Бу чорда татар теленең орфоэпик сүзлеге күренекле тел галиме Х.Х. Сәлимов тарафыннан эшләнә. 1995 елда аның «Татар теленең орфоэпик сүзлеге» [1995-Т_орфоэп] басыла. Әлеге белешмәлектә һәр сүзнең фонетик транскрипциясе бирелә. Басым баш сүздә түгел, ә җәяләр эчендәге транскрипциядә күрсәтелгән. 2004 елда исә «Татар теленең орфографик-орфоэпик сүзлеге» (Казан: Яңалиф, 2004. — 192 б.) [2004-Т_орфог, орфоэп] нәшер ителә. Бу сүзлек гомум кабул ителгән һәм татар теленең Академик грамматикасында тасвирланган орфография, орфоэпия кагыйдәләре нигезендә төзелә. Сүзлектә әйтелеш-язылыш арасында беркадәр аерма булган, авыррак язылышлы һәм әйтелешле 10 меңнән артык сүз теркәлә. Сүзләрнең язылышы кириллицида һәм 1999 елда кабул ителгән латин графикасында бирелә, шуннан соң гадиләштерелгән гамәли транскрипциядә сүзнең әйтелеше (авазларның әйтелеше, сүз басымы һ.б.) күрсәтелә. Сүзлек мәктәп укучылары, студентлар, татар теле укытучылары, радио-телевидение хезмәткәрләре һәм, гомумән, киң катлау укучылар өчен гамәли кулланма буларак тәкъдим ителә.

2019 елда Р.Т. Сәфәров, А.Ә. Тимерханов, О.Н. Галимовалар тарафыннан төзелгән «Татар теленең орфоэпик сүзлеге» (Казан: ТӘһСИ, 2019. – 156 б.) [2019-Т_орфоэп] нәшер ителәчәк. Сүзлек хәзерге татар теленең 4600 дән артык сүзен үз эченә ала. Аның максаты – сүзләрнең әйтелеше, басымы, аларның орфоэпик як-

тан авырлык тудыру ихтималы булган грамматик формалары турында мәгълүмат бирү. Басымның күчүен я күчмәвен, төрләнгән вакытта әйтелештә үзенчәлекле үзгәрешләр барлыкка килүен һ.б. мәсьәләләрне күз уңында тотып, сүзләрнең грамматик формалары тутырып язылган формалары тәкъдим ителә. Орфоэпик сүзлек филологлар, укытучылар, лекторлар, радио һәм телевидение дикторлары һ.б. өчен төзелә.

**Диалектологик сүзлекләр.** XX гасыр ахырында татар диалектологиясе зур үсеш чоры кичерә. Идел буе төбәкләрендә таралган сөйләшләрне өйрәнү белән бергә диалектологик атлас һәм сүзлек төзү юнәлешендә эшләр алып барыла, бай лексик материал туплана. Шул сүзлек хәзинәсен лексикографик эшкәртеп бастыруның, диалектология генә түгел, тел белеменең башка тармаклары өчен дә, аеруча тел тарихы, халык тарихы, тарихи лексикология мәсьәләләрен хәл итүдә әһәмияте зур булуны искә алып, диалектологик сүзлекләр нәшер ителә. 1993 елда «Татар теленең диалектологик сүзлеге» [1993-Т_диал_(2)] басыла. Бу 1969 елда дөнья күргән диалектологик сүзлекнең икенче китабы була. Аны Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова һәм Т.Х. Хәйретдинова төзи. Анда төп урынны татар теленең Урал тирәсендәге сөйләшләре буенча тупланган диалекталь сүзләр һәм сүзтезмәләр алып тора, ахырда татар сөйләшләре буенча белешмәлек урнаштырыла.

Д.Г. Тумашеваның «Словарь диалектов сибирских татар» (1992) сүзлегендә 4500 берәмлек теркәлгән. Бу сүзлек себер татарларының диалектын яктырту ягыннан зур әһәмияткә ия.

2005 елда «Материалы к идеографическому словарю диалектов татарского языка: в 2 т» хезмәтендә диалекталь идеографик сүзлек тә бирелә [2005-Т_диал_идеогр_I-II]. М.З. Зәкиев һәм Д.Б. Рамазанова редакторлыгында эшләнгән бу хезмәт 1969 һәм 1993 елларда басылган диалектологик сүзләргә таянып эшләнгән.

2009 елда «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге» [2009-Т_диал] басылып чыга. Бу сүзлек Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдиновалар тарафыннан төзелә. Әлеге хезмәт татар теленең барлык диалектлары буенча тупланган якынча 40 мең берәмлекне үз эченә. Анда барлык татар диалектларының лексик байлыгы чагылыш таба. Алдагы елларда басылган сүзлекләргә кертелгән лексик берәмлекләрдән тыш, бирегә соңгы

елларда даими уздырылып килгән экспедицияләр барашында тупланган материаллар да урнаштырыла. Сүзләрнең мәгънәләре татарча аңлатыла, рус теленә тәрҗемә ителә, бай иллюстратив материал белән раслана. Мәсәлән:

**АДРАСМАН** *әстер.* үлән (растение – гармала). Адрасман йағып аwыруны даwалыйлар. Адрасман, диләр, акчәчәк ата, ак чәчәктән соң йәшел түгәрәк төймә була.

Болардан тыш, теге яки бу җирлектә яшәп, шул төбәкне өйрәнеп, җирле сөйләшләрне чагылдырган сүзлекләр аерым игътибарга лаек. Мисалга, Н.Ш. Зимасовның «Барда сүзлеге (Барда татарлары сөйләшенең диалектологик сүзлеге)» (2005) [2005-Т_диал], И.Ә. Гафаровның «Мишәрләр. Тарих һәм тел» (2011, сүзлек өлеше бар) кебек хезмәтләр төбәкнең тарихын, диалекталь үзенчәлекләрен яктырту ягыннан зур әһәмияткә ия. Аннары О.И. Барышникованың «Русско-нагайбакский словарь. Нагайбакща-урысща сузлег» (2015) [2015-НТ], П.М. Минеев һәм В.А. Минееваларның «Русско-нагайбакский словарь. Нагайбакско-русский словарь. Русско-нагайбакский тематический словарь» (2017) [2017-НР+РН] сүзлекләре исә нагайбәк сөйләшенә игътибар арту хакында сөйли.

**Этимологик сүзлекләр** сүзнең килеп чыгышы хакында мәгълүмат бирә, филологиянең барча тармакларына да иң кирәкле ярдәмлек булып тора. Тарихчылар, этнографлар, сәнгатьчеләр һ.б. лар өчен дә ул – файдалы белешмә чыганагы. Киң катлам укучылар да мондый төр сүзлекләрдән татар сүзләренең тарихы хакында кызыклы мәгълүмат таба ала. Татар тел белемендә лексик берәмлекләрнең этимологиясен тикшерү юнәлешендә озак еллар буе Р.Әхмәтьянов эшли. 2001 елда галимнең «Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге» дөнья күрә. Бу хезмәт татар теленең сүзлек фондын этимологик яктан яктыртуның беренче тәҗрибәсе була. Сүзлектә татар теленең сүз нигезләренең этимологиясе аңлатыла. 2015 елда ике томнан торган «Татар теленең этимологик сүзлеге» халыкка тәкъдим ителә [2015-Т_этим_I-II]. Бу сүзлек – туган телебездәге сүзләрнең килеп чыгышын (этимологиясен), тарихын ачыклау, мәгънәләрен, кулланылыш үзенчәлекләрен тикшерүгә багышланган киң колачлы беренче хезмәт, зур гыйльми казаныш буларак, төрки-татар тарихын, татар-башкорт тел байлыгын өйрәнергә теләүче галимнәр, мәктәп һәм югары уку йортлары мөгал-

лимнәре, укучы-студентлар файдалану өчен гаять файдалы кулланма булып тора. Анда 10 меңнән артык сүзгә аңлатма бирелә. Мәсәлән:

**АТАЛ-**У «называться» – *атау* дип карала, ләкин бор. төрки телләрдә үк *ат ал-(у)* «ат, исем алу» – сүз икенче, «героик исем» тур. бара. К. Атаклы.

Хәзерге татар лексикографиясендә этимологик сүзлек мондый киң күләмдә һәм чагыштырмача тулы шәкелдә беренче тапкыр нәшер ителә. Сүзлек авторның озак еллар дәвамында алып барган фәнни тикшеренү-эзләнү нәтиҗәләрен, аның бу өлкәдәге табышларын-казанышларын чагылдыра. Сүзлектә барлыгы 10300 чамасы сүзнең килеп чыгышы аңлатылган. Теркәлгән сүзләрнең зур күпчелеген төрки тамырлы берәмлекләр һәм татар теленең диалекталь лексикасы тәшкил итә. Нигездә, фонетик яктан үзләштерелгән рус, шулай ук гарәп-фарсы алынмалары да чикләнгән күләмдә кертелгән. Сүзлек, анда тупланган тел материалын мәктәпләрдә, югары уку йортларында уку-укыту программалары кысаларында файдалану өчен шулай ук зур мөмкинлекләр бирә.

**Фразеологизмнар һәм паремиялар сүзлекләре** татар теленең тотрыклы гыйбарәләрен, мәкаль-әйтемнәрен туплап, мәгънәләрен аңлатып, кайчак башка телләргә тәрҗемә итеп бирүләре ягыннан зур әһәмияткә ия.

1991 елда Л.К. Бәйрәмова төзегән «Учебно-тематический русско-татарский фразеологический словарь» [1991-РТ_темат_фраз] басыла. Бу сүзлек «Учебный фразеологический словарь русского языка» (Быстрова Е.А., Окунева А.П., Шанский Н.М., Л., 1984) сүзлегенә нигезләнеп эшләнгән. Бирегә татар мәктәпләрендә рус теле укытуда лексик-фразеологик минимумның нигезен тәшкил итә торган 700 ләп тотрыклы гыйбарә кертелә. Аларның кулланылышы матур әдәбият әсәрләреннән китерелгән мисаллар белән дәлилләнә. Фразеологик берәмлекләр 14 бүлек һәм 95 темага бүлеп урнаштырылган. Рус телендәге фразеологик берәмлекнең мәгънәсе аңлатыла, һәм булган очракта татарча эквиваленты китерелә. Мәсәлән:

**СЕБЕ НА УМЕ** – *скрытен, хитер; төтене кыек, кыек-мыек; үз акылы үзендә. Этот человек опытный, себе на уме, не злой и не добрый, а более расчетливый; это тертый калач, который знает людей и умеет ими пользоваться.*

Сүзлек ахырында фразеологизмнарның алфавит һәм тематик күрсәткеч-белешмәсе бирелә.

2001 елда Ф.С. Сафиуллинаның «Татарча-русча фразеологик сүзлеге» (Казан: Мәгариф, 2001) [2001-ТР_фраз] басыла. Анда татар фразеологизмнарына эквивалент итеп рус фразеологизмнары тәкъдим ителә. Автор аларны татар әдәбиятының русча һәм рус әдәбиятының татарчага тәрҗемәләреннән, Н.Исәнбәтнең сүзлегеннән, җанлы сөйләмнән туплаган, русча фразеологик сүзлекләрдән дә файдаланган. Сүзлектә 16 меңнән артык фразеологик берәмлек бирелгән. Сүзлектәге фразеологизнарның күп өлешен фигыль фразеологизмнары тәшкил итә. Мондый тип сүзлекләр филологлар, тәрҗемәчеләр, редакторлар һ.б. өчен кирәкле кулланма булып тора.

2006 елда басылган «Татарча-русча идиомалар сүзлеге» дә (Казан: Алма-Лит, 2006) [2006-ТР_идиом] галимнәр, журналистлар, укытучыларга һ.б. ярдәмлек буларак эшләнгән. Ф.Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова тарафыннан төзелгән әлеге сүзлектә татар теленең киң кулланылышка ия гыйбарәләре, сирәк очрый торганнары да кертелгән. Русча төгәл эквивалентлар бирелүләре, дөрес тәрҗемә ителүләре җәһәтеннән бу хезмәт югары бәяләнергә хаклы.

Л.Р. Сәгыйдуллинаның «Татар теленең зоокомпонентлы фразеологизмнар сүзлеге» (2012) [2012-Т_ зоокомп/фраз], З.С. Кәримованың «Аяз Гыйләҗев прозасындагы фразеологизмнар сүзлеге» (2012) [2012-Т_Гыйләҗев/фраз] дә татар теленең фразеологик байлыгын бирү җәһәтеннән әһәмияткә ия.

2018 елда күренекле галим К.Р. Галиуллин татар паремияләренең дүрт төре (мәкальләр, канатлы әйтелмәләр, әйтемнәр, җор сүзләр) белән бәйле фактик материалларны системага салып, «Татар фольклоры теле: мәкальләр, канатлы әйтелмәләр, җор сүзләр һәм әйтемнәр: сүзлек» (Казан: ТӘһСИ, 2018. – 588 б.) [2018-Т_ фольк] хезмәтен бастыра. Бу гади сүзлек кенә түгел, ә татар фольклор лингвографиясендә халык иҗаты әсәрләре теленең сүзлеген тасвирлауның беренче тәҗрибәсе булып тора. Әлеге белешмәлекнең төп өлешен конкорданс, кире һәм ешлык сүзлекләре тәшкил итә.

Гомумән, татар теленең фразеологиясен, мәкаль-әйтемнәрен өйрәнү, аларның тәрҗемәи сүзлекләрен бастыру һәрчак игътибар үзәгендә була. Түбәндәге хезмәтләр шуны раслый: «Русско-англо-немецко-турецко-татарский фразеологический словарь»

(Казань: Изд-во КГУ, 2008) [2008-РАНТрТ_антон], М.М. Абдурахимов «Кыскача үзбәкчә-татарча мәкаль һәм әйтемнәр сүзлеге» (Казан: Татар. кит. нәшр., 2010) [2010-ҮзТ_мәкаль, әйтем] һ.б.

**Ономастик сүзлекләр** ялгызлык исемнәрнең килеп чыгышы, мәгънәсе, кулланылыш таләпләре хакында мәгълүмат бирә. XX гасыр ахырында ономастика фәне чын-чынлап фән булып формалашып бетә дисәк тә дөрес булыр. Татар ономастикасының аерым тармакларын тирәнтен тикшергән хезмәтләр, сүзлекләр басыла. Мәсәлән, кеше исемнәрен өйрәнү юнәлешендә Г.Ф. Саттаров зур көч куя. Галимнең 1998 елда дөнья күргән «Татар исемнәре ни сөйли?» [1998-Т_ономас] дип аталган сүзлегендә төрле чыганаклардан тупланган 15 меңгә якын (төрдәшләре белән 20 меңнән артык) татар ир-ат һәм хатын-кыз исеме туплап бирелгән. Аларның лексик мәгънәләре, этимологияләре турында мәгълүмат бирелгән.

2006 елда «Татарча-русча кеше исемнәре һәм фамилияләр сүзлеге» [2006-ТР_ономас] басылып чыга. Хезмәтнең авторлары – Г.Ф. Саттаров, Р.Г. Әхмәтьянов, Ф.Ә. Ганиев, И.А. Абдуллин, Г.С. Сабирҗанов, К.Р. Галиуллин. Сүзлек төрле дәүләт оешмаларына, паспорт һәм загс идарәләре хезмәткәрләренә кеше исеме һәм фамилияләренең дөрес язылышы буенча кулланма буларак тәкъдим ителә.

Татарстан топонимнарын, шул исәптән гидронимнарын тикшергән галимнәрдән беренче чиратта Ф.Г. Гарипованы атарга кирәк. Галим, топонимнар һәм гидронимнарны туплап, сүзлек итеп бастыру юнәлешендә дә зур көч куя. 1989 – 1990 елларда ике китап булып «Татарстан гидронимнары сүзлеге» [1989-1990-Т_гидрон_I-II] басыла. Татар топонимнары өлкәсендә алып барган фәнни эшчәнлеге нәтиҗәсендә, 1992 һәм 1993 елларда шулай ук ике китап булып – «Татарстан микротопонимнары сүзлеге» [1992-1993-Т_антон], 2010 елда «Татар топонимнары сүзлеге» басыла. Бу сүзлекләрне татар топонимиясенең казанышы дип тә атарга була.

Бу чорда аерым төбәк исемнәрен тикшергән сүзлекләр дә дөнья күрә. Мәсәлән, Г.Т. Бакиеваның «Словарь имен сибирских татар» сүзлегендә себер татарларының кеше исемнәре теркәлгән.

**Язучының сүз байлыгын туплаган сүзлекләр** – теге яки бу язучы яисә шагыйрь иҗатында кулланылган сүз байлыгын туплап, аларга аңлатма биргән комплекслы сүзлекләр. Татар әдәби тел та-

рихын, лексикологиясен өйрәнүдә бу төр сүзлекләр мөһим чыганак булып тора.

Татар телендә мондый сүзлекләр бары тик XXI гасыр башында гына эшләнә башлый. 2006 елда Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» җыентыгындагы сүз байлыгын туплаган «Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» дигән сүзлек дөнья күрә [2006-Т_Җәлил].

2009 елда Габдулла Тукай иҗатының тел байлыгын чагылдырган «Габдулла Тукай: Шигърият теле» сүзлеге басыла [2009-Т_Тукай].

З.С. Кәримованың «Аяз Гыйләҗев прозасындагы фразеологизмнар сүзлеге» дә язучының тел байлыгын туплап бирә торган сүзлекләрдән санала [2006-Т_Гыйләҗев].

**Лингвомәдәни сүзлекләр** лексик берәмлекнең лингвомәдәни компонентын тасвирлау аша илнең-халыкның тарихы, мәдәнияте хакында мәгълүмат бирә.

Шундый сүзлекләрдән 2007 елда нәшер ителгән «Миллият сүзлеге»н [2007-Т_лингвомәдәни_миллият] атарга мөмкин. А.Тимергалинның бу хезмәтендә 12000 чамасы сүз тасвиралана. 2016 – 2018 елларда А.Тимергалин бу сүзлекне тулыландырып, өч томлы итеп эшли. Ул «Миллият сүзлеге: аңлатмалы сүзлек» исеме астында нәшер ителә. Әлеге хезмәт милләт һәм дин тарихына кагылган әһәмиятле һәм кызыклы фактларны, күренекле шәхесләр турындагы мәгълүматларны, хикмәтле сүзләр һәм төрле төшенчәләргә аңлатмаларны үз эченә ала. Сүзлек әдәби-тарихи мирас буларак нәшер ителә. Ул гамәлдә йөри торган сүзлекләрдән эчтәлеге белән аерыла. Аңлатмалар мисаллар белән тулыландырылган. Биредә шулай ук заманында актив кулланылган, әдәби-гыйльми мирасыбызда сакланган төрки сүзләргә һәм фарсы алынмаларына да киң урын бирелә. Лексик берәмлек, төшенчәләр сүзлектә алфавит тәртибендә бирелә. Бу сүз яисә атама лексик, мифик, дини, тарихи күзлектән чыгып аңлатыла, нинди сүз-атама-төшенчә яки нинди шәхес булуы, кайбер очракта кайсы чорда очравы турында мәгълүмат бирелә. Мәсәлән:

*Ант* – Гомумтөрки сүз. Тунгус-маньчжурча *аң-ыт* ике туган сүзеннән (Р.Әхмәтьянов). Борынгыда ике ят кабиләнең ике кешесе кардәш булып хисапланырга вәгъдәләшү гадәтеннән. А.И. Попов борынгы «ант» сүзе – «славян һәм төрки кабиләләр союзы»

да шуннан килә дип саный // *ант-ширт* – ант (төркичәдә шерт – шарт).

«Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»ндә «ант» мәгънәсендә гарәби чыгышлы касәм сүзе теркәлгән.

Апа-тархан – VI – VIII гасырларда төрки дәүләтләрдә каһан тарафыннан бирелә торган югары хәрби титул. Мәгънәсе «өлкән тархан» дип фаразлана (борынгы төрки телдә *аба/ апа* – өлкән туган).

«Миллият сүзлеге» галимнәргә генә түгел, тел, әдәбият, тарих белән кызыксынучы һәр кеше өчен уңайлы кулланма-сүзлек булыр дигән максат белән чыгарыла.

2003 елда Р.Р. Җамалетдиновның «Этнокультурная лексика татарского языка: словарь-справочник» сүзлеге басыла. Биредә «кеше» тематикасына караган утызлап төп берәмлек тасвирлана [2003-Р_этномәд].

2015–2016 елларда ике китап булып этномәдәни лексиканы яктырткан сүзлекләр басыла: «Татар теленең этномәдәният сүзлеге» [2015-Т_этномәд], «Матди мәдәният лексикасы (кием-салым, тукымалар һәм бизәнү әйберләре атамалары) [2016-Т_матди/мәд]. Р.Җамалетдинов, Р.Нурмөхәммәтова һ.б. тарафыннан төзелгән әлеге сүзлекләрнең беренче томында ризык һәм савыт-саба атамалары бирелгән, барлыгы — 40 берәмлек. Икенче томында кием-салым һ.б. атамалар яктыртыла.

2013 елда Р. Сәгыйдуллина авторлыгында дөнья күргән «Татар лингвомәдәни концептлар сүзлеге» дә [2013-Т_концепт] шулай ук халкыбызның рухи-мәдәни дөньясы белән бәйле төшенчәләрне яктырта.

XX гасыр башында иҗтимагый тормышта барган үзгәрешләр, замана таләпләре сүзлекләрнең электрон вариантына иҗтыяҗ тудыра. Хәзерге көндә Татарстан Фәннәр Академиясе сайтында «Сүзлекләрнең электрон фонды» булдырылды. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында төзелә торган сүзлекләр ике форматта: һәм кәгазь, һәм электрон вариантта эшләнә. Электрон вариантлар «Сүзлекләрнең электрон фонды»-на урнаштырыла бара. Бүгенге көндә фондта 38 сүзлек бар. Һәр сүзлек турында кыскача белешмә бирелә: төзүче авторлары, нәшер ителү елы, сүзлек турында мәгълүмат, кереш сүзе һ.б. Әлеге фонд-

ның мөмкинлекләре шактый һәм аннан теләге булган һәркем файдалана ала.

Шул рәвешчә, XX гасыр ахыры – XXI башында чыккан сүзлекләр татар теленең лексикографик фондын яңа баскычка күтәрә. Бу чорда нәшер ителгән сүзлекләр бай һәм күпкырлы булулары белән аерылып тора: энциклопедик сүзлекләр басыла башлый, филологик сүзлекләрнең яңа төрләре барлыкка килә һ.б. Аннары бу чорда, югарыда искәртелгәнчә, сүзлекләрне куллану-файдалану мөмкинлекләре дә арта. Телебезнең байлыгы, сафлыгы нәкъ менә сүзлекләрдә чагылыш таба. Шуңа күрә укытучы, галим, журналист, телевидение хезмәткәре, сәхнә остасы, гади укучы булсынмы – һәркемгә сүзлек, тормышында бер генә тапкыр булса да, кирәк булып куя.

## ТАТАР СҮЗЛЕКЛӘРЕНЕҢ ТӨРЛӘРЕ

### § 12. Аңлатмалы сүзлекләр

Аңлатмалы сүзлекләр үзләрендә теркәлгән һәр сүзнең мәгънәсен яки мәгънәләрен аңлатып бирү максаты белән төзелә. Ике яки аннан да артык сүз ярдәмендә ясалган күп составлы атамалар (кушма һәм тезмә сүзләр) һәм фразеологизмнар да мондый төр сүзлекләрдә аңлатмалары белән урын ала. Сүзлектә сүзнең кулланылыш даирәсе күрсәтелә, гамәлдәге кагыйдәләр нигезендә һәр тел берәмлегенең грамматик һәм фонетик үзенчәлекләре нормалаштырыла. Алынма сүзләрнең бары тик шул телдә кулланылган мәгънәләре генә китерелә. Күп мәгънәле сүзләрне шәрехләгәндә, аның бөтен семантик кыры исәпкә алына. Мәгънәләрнең бирелеш тәртибе аларның әдәби телдәге кулланылыш ешлыгыннан чыгып билгеләнә, мәгънәләр арасындагы логик эзлеклелек һәм генетик бәйләнеш мөмкин кадәр сакларга тырышып урнаштырыла. Конкрет мәгънәләр абстракт мәгънәләрдән алданрак бирелә. Сүзнең күчерелмә мәгънәләре дә туры мәгънәдән соң китерелә. Аерым очракларда максатка ярашлы рәвештә әдәбиятта еш очраган диалектальь, борынгы сүзләр, кайбер сүзләрнең кулланыштан төшеп калган искергән мәгънәләре китерелергә мөмкин. Сүзлектә алынган лексик берәмлекләрне шушы рәвештә шәрехләү сүзләрнең үсеш-үзгәрешендәге тарихи эзлеклелекне күрсәтү, аның мәгънә төзелешен аңлауны җиңеләйтү максатыннан эшләнә. Шул нигездә ул әдәби телнең төп сүзлек хәзинәсен туплап чагылдыру максатын гамәлгә ашыра. Әлбәттә, тел ул иксез-чиксез дәрья кебек, аның барлык сүз байлыгын тормышның бөтен өлкәләреннән тулысынча җыеп бетерү мөмкин түгел һәм шул ук вакытта тел туктаусыз

үсеш-үзгәрештә. Шуңа күрә аңлатмалы сүзлекләр, бер яктан, тулылыкка омтылсалар, икенче яктан, үзеннән-үзе чикләнергә мәҗбүр булалар, чөнки сүзлек тел үсешенең аерым бер этабын – үзе төзелгән чорны гына чагылдырырга сәләтле.

Аңлатмалы сүзлекләр – телдәге башка сүзлекләр арасында иң мөһиме һәм иң кыйммәтлесе. Ул халыкның матди һәм рухи үсеш юнәлешләрен, яшәү рәвешен, мәдәниятлелек дәрәҗәсен, башка халыклар белән икътисади-мәдәни бәйләнешләрен аның бөтен тарихы барышында тупланган сүзләре аша күрсәтә ала, чөнки тупланган сүзлек хәзинәсе киң халык массаларының иҗтимагый эшчәнлеге, аның буыннан-буынга килгән тәҗрибәсе белән турыдан-туры бәйләнгән. Җәмгыятьтә мондый төр сүзлекләргә ихтыяҗ халыкның тел культурасы билгеле бер дәрәҗәгә ирешкәннән соң гына барлыкка килә ала. Бер яктан, шул телдә сөйләшүчеләрнең тел хәзинәсен туплап, аны нормалаштыру зарурияте җитлегергә, икенче яктан, телне лексикографик тасвирлау өчен, тиешле күләмдә сүз байлыгы тупланып җитешергә тиеш була. Милләтнең аңлатмалы сүзлеге төзелгән булу үзе үк аның югары мәдәниятькә ия булуын күрсәтә.

Татар телендә аңлатмалы сүзлекләр төзү зур тәҗрибәгә ия һәм бу төр сүзлекләр күпсанлы. Аларның кайберләре төрки халыклар арасында беренче тәҗрибә буларак тәкъдим ителгән. Хәзерге вакытта татар телендә төзелгән түбәндәге аңлатмалы сүзлекләрне күрсәтергә мөмкин:

1. Насыйри К. Ләһҗәи татари: 2 томда. – Казан: Ун-т типолитогр., 1895. – 226 б.; 1896. – 106 б.

2. Вәлиди Ж.Ж. Татар теленең тулы сүзлеге. 1–2 кисәк. – Казан: Татарстан Халык Мәгариф Комиссариаты гыйльми үзәге басмасы, 1927. – 720; 1929. – 721 б.

3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Т. I–III. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – 475 б.; 1979. – 724 б.; 1981. – 831 б.

4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / Ф.Ә. Ганиев ред. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

5. Миллият сүзлеге / Төз. А.Тимергалин. – Казан: Мәгариф, 2007. – 575 б.

6. Ганиев Ф.Ә. Тезмә фигыльләрнең аңлатмалы сүзлеге: Ике кисәктә. Беренче кисәк (А–К). – Казан: Мәгариф, 2009. – 375 б.; икенче кисәк (Л–Я). – Казан: Паравитта, 2012. – 537 б.

7. Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 510 б.

8. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: I том: А–В. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – 712 б.; II том: Г–Й. – Казан: ТӘһСИ, 2016. – 748 б.; III том: К. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – 744 б.

Татар лексикографиясендә аңлатмалы сүзлекләр төзү эше шактый бай һәм ерак тарихка ия. Беренче тапкыр татар телендә аңлатмалы тулы сүзлекне төзү идеясе Казан университетының гарәп һәм фарсы телләре белгече профессор Ф.И. Эрдман тарафыннан 1829 елда тәкъдим ителә. Ул үзе аның 12 параграфтан торган программасын эшли. Анда сүзләрне бирү тәртибе, кайсы телдән алынуы, сүзләрне сайлап алу принциплары, мәгънәләрне аңлату һәм аларга мисаллар, фразеология бирү каралган була. Программада татар сүзләрен рус һәм латин телләренә тәрҗемә итү дә күздә тотыла. Аның бу проекты университет советында уңай бәя ала, ләкин ул чорда кадрлар җитешмәү сәбәпле, бу идея тормышка аша алмый (Франц Эрдман документлары Казан университетының Н. Лобачевский исемендәге китапханәсендә, сирәк китаплар бүлегендә 4391 нче номер белән саклана). Шул рәвешле, татар теленең тулы лексикасы белән кызыксыну, аны аңлатмалы сүзлеккә туплап бирү ихтыяҗы проблемасы көн тәртибенә куелып кына кала.

Җәмгыятьтә төрле максатларда барлыкка килгән бу ихтыяҗ озак вакытлар көн таләбеннән төшми. Ниһаять, бу зур, җаваплы эшкә беренче булып үз чорының алдынгы карашлы фикер иясе, зур галим, мәгърифәтче К.Насыйри алына. Телче буларак, К. Насыйри тел гыйлеме һәм сүзлекләр төзүдә шулкадәр катлаулы һәм кирәкле эшләр башкара ки, бу өлкәдә ул кагылмаган, хезмәт күрсәтмәгән бер генә тармак та калмый. Аның татар теленең сүзлек составын өйрәнүгә багышланган әһәмиятле хезмәтләреннән берсе – «Ләһҗәи татари» ике томлык татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеге – I томы (226 б.) – 1895 елда, II томы (106 б.) 1896 елда университет типографиясендә басылып чыга. К.Насыйриның бу өлкәдәге эшчәнлеге җиңел генә бармый. Заманыннан күпкә алдынгы карашлары замандашлары тарафыннан кискен тәнкыйть ителә, кире кагыла. Кадими законнар үз көчендә булган заманда К. Насыйриның карашлары һич мөмкин булмаган эш итеп кабул ителә. «Ләһҗәи татари» сүзлегенең керешендә ул үзен бик хаклы рәвештә «татар теленең хезмәтчесе» дип атый. Бу юлда бик күп кыенлык-

лар күрергә, каршылыкларны җиңәргә туры килүен ачынып искә ала: «Татар телебезгә хезмәтчеләр була килмәгәнлек сәбәпле, татар телебез артта, бик еракта йоклап калган. Әмма татар телебезгә хезмәтче мин булыйм дип, утыз биш ел уздырдым... Төн-көн никадәр тырышсам, шулкадәр җәфа чиктем. Милләтебез халкын татар дип атасам яратмадылар, татар теле дисәм яратмадылар», – дип яза ул (Насыйри, 1974: 33).

К. Насыйри «Ләһҗәи татари» сүзлегендә татар теленең идеологик инвентарьларын, ягъни мәгънә берәмлекләрен, сүз байлыгын җыйнап тәртипкә салып бирә, хәтта күп кенә сүзләрнең этимологиясен дә ача. Анда барлыгы 10 467 сүз теркәлгән. Генетик яктан төрки-татар сүзләре сиксән процентка якын, ә гарәп, фарсы сүзләре егерме процентны тәшкил итә. Сүзләргә аңлатма бирүнең төп принцибы итеп К. Насыйри синонимнар китерү юлын сайлый. Мәс.: ***үткән*** – узган, булган – үткән кич – үткән көн – үткән гомер – үткән заман – үткән ел; ***үткәзләмәк*** – үткен итмәк, кайрамак, үткәрләмәк – үткәзләмәк морадифләре.

Аерым очракларда киңәйтелгән аңлатмалар куллана: ***олтырак*** – кәвеш, итек, ката вә гайре аяк киемнәренә җылылык вә йомшаклык өчен салырлар – киездән яки башка гыйһен заттан; ***эремәк*** – каты нәрсә сыек хәленә әверелмәк: кар эремәк – боз эремәк – май эремәк – җиз вә гайре мәгъдәннәр эремәк – тоз эремәк – шикәр эремәк.

Гарәп һәм фарсы телләреннән кергән сүзләрнең татарча мәгънәсен аңлата, татар сүзләренең гарәпчә һәм фарсыча вариантларын китерә, аларның нинди сүзтезмәләрдә кулланылуын күрсәтә: ***олуг*** – улуг, дәү, кәбир, җәсим, газыйм, өлкән.

Ул төп игътибарны телнең эчке мөмкинлекләреннән файдалануга, сүзләрнең семантикасын ачуга юнәлтә; сүзлектә бер үк сүзнең төрле мәгънәләре бирелә, галим сүзләрнең мәгънә киңлегенә, аларның мәгънәви аермаларына махсус туктала.

Үз чорының җанлы халык теле материалларын шактый тулы чагылдыруы белән сүзлек зур фәнни әһәмияткә ия. К.Насыйри тарафыннан төзелгән ике томлы «Ләһҗәи татари» телебезнең никадәр бай икәнен, куллану мөмкинлегенең киң булуын дәлилли. Төрки телләр тарихында татар телендә басылган беренче төрки аңлатмалы сүзлек булуы аның әһәмиятен тагын да арттыра төшә.

XX гасырның 20 нче елларында татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзү эше яңа бер баскычка күтәрелә. Ул татар тел галиме, тәнкыйтьче, әдәбият тарихчысы, педагог, җәмәгать эшлеклесе Җамал Вәлиди исеме белән бәйле. Җамал Вәлиди – «Татарны өйрәнү җәмгыяте»ндә Н.И. Воробьёв, В.А. Богородицкий, И.Н. Бороздин, Н.И. Ашмарин, П.М. Дульский кебек күренекле галимнәр белән иңгә-иң торып хезмәттәшлек иткән зур галим.

Җамал Вәлиди җәмгыятьтә барган һәртөрле үзгәрешләрнең беренче чиратта сөйләм телендә чагылыш табуын күрә. Телдәге үзгәрешләрнең иҗтимагый вакыйгаларга бәрабәр сикерешләр белән үсүен билгели. 1905, 1917 елгы революцияләр чоры – «мөддәте ягыннан кыска, ләкин мәгънәсе ягыннан зур булган ара» телебездә зур үзгәрешләр китереп чыгарды, ди ул. Бу үзгәрешләр язма әдәби телдә гаять дәрәҗәдә чуарлык барлыкка китерүгә сәбәпче булуын әйтә. Ул Каюм Насыйриның «Ләһҗәи татари» сүзлеге татар әдәби телен халык сөйләм теленә якынайтуда зур эш башкаруын билгеләп китә. Татар теленә «җиң сызганып хезмәт итүче бу гыйлем каһарманын монда зур хөрмәт белән искә төшереп китү – бурычыбыздыр» ди ул сүзлегенең кереш өлешендә. Каюм Насыйриның сүзлеге чыгуга кыска вакыт узса да, яңа чор әдәби телен нормалаштыру өчен, эшне татар теленең тулы сүзлеген булдырудан башлау бик мөһим дип күрсәтә галим. Ул белдергәнчә, Каюм Насыйри сүзлеге төзелгән вакытында татар теленә төрек, гарәп, фарсы телләренең йогынтысы зур була. Шул сәбәптән бу телләрдән кергән алынмаларның сүзлектә күп булуы табигый. «Каюм Насыйриның соңгы елларында һәм аннан соң берничә еллар буена бездә «Тәрҗеман» газеты тәэсире белән гомуми төрекчелек фикере шактый көч алып, яңа туган каләмнәребез күбесе госманлыча дип әйтерлек яки шуңа тартым тел белән яза башладылар» (Вәлиди, 1927: 5–7). Революцияләр чорында телнең тәрҗемәдә киң кулланылуы, әдәбиятка яңа буын каләм осталарының килүе, баштарак алар төрек теленә якын язсалар да, соңыннан гади халык теленә якынаюлары телебезне табигый эзенә кайтарды дип белдерә. Шул сәбәптән татар теленең сүзлек составында зур үзгәрешләр килеп чыкты. «Ләһҗәи татари» иясе теленә караганда, «күп эшләнгән, күп баеган, бигрәк тә дөресе, эшләнеп, баеп бара торган бер тел туа иде». Телдә рус теленнән кергән алынмалар күбәйде, язма тел халык теленә якынайды, кайбер сүзләрнең язылышында үз-

гәрешләр барлыкка килде, элек «урамча» дип саналган формалар хәзер телдә тулы гражданлык алды. Кыска вакыт эчендә тел ике дәвер теленә әверелеп калды. «Лөгать китаплары үзләре язылган дәвернең көзгесе булырга, ягъни шул вакыттагы телне күрсәтергә тиеш». Җ.Вәлиди шушы сәбәпләр дәвер ихтыяҗын чагылдыра алырлык яңа «Татар теленең тулы сүзлеге»н төзү бурычын тудыра дип дәлилли (Вәлиди, 1927: 5–7).

«Татар теленең тулы сүзлеге» буларак, ул әдәби тел белән генә чикләнмичә, «халыкта булган бөтен сүзләрне эченә алырга һәм аерым урыннарда гына сөйләнә торган сүзләрне дә калдырмаска тиеш», «... халыкның телендә булган барлык сүзләрне эченә ала торган бер хәзинә булырга тиеш», ди. Яңа чорның әдәби теле әле эшләнү дәверендә генә булу сәбәпле, телдәге барлык сүзләрнең дә сүзлектә теркәлүе әдәби тел үсеше өчен гаять әһәмиятле дип нигезли. Язма телдә хәзерге вакытта Казан һәм Казан тирәсе татарлары теле өстенлек итә дип искәртә. Әдәби тел бер урындагы сөйләшкә генә нигезләнә алмый. Аның барлык урындагы сөйләшләрне, шивәләрне дә үзендә туплавы шарт дип белдерә (Вәлиди, 1927, 9–11). «Телебезнең үсүе, бердән, татарча яңа сүзләр, формалар ясалу юлы белән барса, икенчедән, халыкара Европа сүзләрен кабул итеп үзләштерү юлы белән дә барачак». «...Европа сүзләре белән алмаштырылып ята торган кайбер гарәпчә сүзләрне дә яңа кабул ителгән көндәшләре белән берлектә сүзлеккә кертергә туры килә, чөнки әле аларның кулланыштан чынлап чыгып та җиткәннәре юк», – ди (шунда ук).

Шушы шартларда гыйльми үзәкнең фәнни эш планына «Татар теленең тулы сүзлеге»н булдыру бурычы кертелә. Сүзлекне 100 басма табак күләмендә ике томда бастыру күздә тотыла. Һәр томны ике кисәккә бүлеп чыгару карала. Шул план нигезендә сүзлекнең беренче томы 1927, 1929 елларда ике кисәк булып дөнья күрә. Беренче кисәктә «Гыйльми үзәктән» дигән кереш сүз урнаштырыла. Анда сүзлекнең төп авторы Җ. Вәлиди булуы әйтелә. Татарстан Халык Мәгариф Комиссариаты гыйльми үзәгенең бу эшкә һәм бу хезмәткә җитди әһәмият бирүе тәгъбир ителә. Сүзлекнең гыйльми дөреслеген һәм тулылыгын тәэмин итү өчен, аерым бер комиссия тикшерүе үтүе күрсәтелә. Комиссия составында Мөхетдин Корбангалиев (комиссия рәисе), доцент Габдрахман Сәгъди, доцент Гали Рәхим һ.б. булуы турында белешмә бирелә (Вәлиди, 1927, 3–4).

Басылып чыккан беренче том сүзлек гарәп графикасының өч хәрефен – *әлиф, би, ти* хәрефләрен эченә ала. Кириллицага күчерсәк, әлиф белән (татар телендә барлык сузык авазлардан) башланган *а, э-ы, у-ү, о-ө, ә, и,* би хәрефенә *б, п* һәм т хәрефенә төзелә. Барлыгы 11 719 сүз тупланып бирелә. Икенче кисәкнең кереш сүзендә моннан соң чыгачак сүзлек ч (چ) хәрефеннән башланып китәчәге һәм яңалиф нигезендә төзеләчәге әйтелә. Яңалифтә әлифба тәртибе башкача булу сәбәпле, алда чыккан өлешләрнең арада кабатлану мөмкинлеге дә искәртелә (Вәлиди, 1929, кереш сүз). Шул чордагы татар алфавиты яңалифкә күчү белән бәйле утырышларда Җ. Вәлидинең «Татар теленең тулы сүзлеге» кабат-кабат телгә алына, тикшерелә һәм һәрвакыт югары бәя бирелә.

Җ. Вәлидинең сүзлек төзү принципларына килсәк, ул – татар лексикографиясе тарихында беренче тапкыр сүзлек төзү эшен фәнни лексикографик принципларга нигезләгән автор. Иң беренче чиратта, сүзлек төзү өчен, эшне ул картотека туплау белән башлап җибәрә. Татар теленең тулы сүзлеген төзү һәм фәнни грамматикасын язу идеясе Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә татар теле мөгалиме булып торган вакытта туган иде дип искә ала ул (Вәлиди, 1927, 19). Төрле тарафлардан җыелган шәкертләр ярдәме белән шул чорда ук ул материал туплау эшенә керешә. Эшне билгеле тәртиптә эзлекле алып бару өчен, шәкертләрдән торган телне тикшерү түгәрәкләре оештыра. Ул бу түгәрәкләр эшчәнлеге белән бик күп сүзләр җыюы һәм картотеканың, нигездә, гомумхалык теленә таянуы турында әйтеп китә. Түгәрәк эшендә катнашкан шәкертләр, укып бетереп таралганнан соң да, материал җибәрүләрен дәвам иттерәләр, хәтта сугышта катнашып йөргән төбәкләреннән дә хатлар килде дип искә ала галим. Сүзлектә аерым сүзләрнең таралыш төбәкләре күрсәтелүенә караганда, аларның географиясе шактый киң: Уфа, Златоуст, Стәрле, Сарытау һ.б. Алдан татар грамматикасын язу белән мәшгуль булу сәбәпле, ул сүзлек төзү эшенә бары 1919 елда гына ныклап керешә алуы турында әйтә. Әмма аның нинди типта – тәрҗемәме яки аңлатмалымы булачагын бары 1922 елда Казанга килеп эшли башлагач кына уйладым, ди. Сүзлекне аңлатмалы итеп төзү, тупланган һәр лексик берәмлеккә аңлатмалар биреп бару максатка ярашлырак булачагын аңлап эш итә галим. Материал туплауны дәвам итү өчен, төрле якларга лингвистик экспедицияләргә чыга, мәгариф бүлекләре аша Урский өязендә, Ка-

занда, Арча кантонында, Тәтештә, Минзәлә кантонында, татарлар яшәгән башка төбәкләрдә укытучылар курслары, телне өйрәнү түгәрәкләре оештыра. Сүзлек, авторның әйтүенчә, 1925 елга китап булу дәрәҗәсенә җитешә. Татарстан Гыйльми үзәге бу эшне һәм мәдәни, һәм гыйльми яктан өлгергән дип тапты, китап итеп бастыру өчен, сүзлекне тикшерү комиссиясе әгъзалары, бигрәк тә Гали Рәхим, Гыйльми үзәк рәисе Г. Ибраһимов һәртөрле ярдәм күрсәттеләр дип рәхмәтен белдерә (Вәлиди, 1927, 19–20).

Сүзлекчәне туплаганда, галим биреләчәк сүзләрне лексик һәм грамматик мәгънәләргә бүлеп карауны шарт итеп куя. Кушма, тезмә сүзләр бирелешен җентекләп тикшерә. Ул сүзлекне төзү принцибы турында болай дип яза: «Мин башта оялау ысулы белән бик зәвыкланып, китабымны шул юл белән тәртип итәргә башласам да, бара торгач, моның төрле яктан уңайсызлыгын сизеп, ахырында механик рәвештә ныклы әлифба тәртибендә төзүне ихтыяр иттем. Моның өчен безнең телнең аерым ятышлыгы да бар: бездә бер тамырдан алынган сүзләр барыбер сүзлекнең төрле җиренә чәчелеп бетми, бертөрле хәреф белән башланганлыктан, бергәрәк җыелып тора. Шулай булса да бу сүзлектә «оя» (гнездо)лар бөтенләй юк түгел», мәс., тезмә исемнәр баш сүз оясында бирелсә, «органик рәвештә кушылып киткән» кушма сүзләр «аерым сүз итеп үзләренә тиешле урында китереләләр» ди (Вәлиди, 1927, 5–7). Сүзлекнең үзенә мөрәҗәгать итсәк, мәс.:

***тау*** (ис.) 1. җирнең күтәрелеп торган биек урыны / *ут тавы* – янар тау / *кар тау ягы; карлы тау* – түбәсеннән җәен-кышын кар бетми торган тау / *Каф тавы* – әкиятләрдә дөнья кырыендагы биек тау / *янар тау* – вулкан.

2. зурлыкка, авырлыкка киная булып йөри. – *Шул эш өстемдә тау булып тора инде.*

3. мәгъдән казу, бигрәк тә җир күмере эшләрендә урысларның горный дигән урыннарында йөртелә: *тау авыруы; тау эшчесе; тау итәге; тау башы; тау-таш; тау тезмәсе; тау-чагал; тау-чокыр; тау шуу; тау кабыргасы; тау кочаклату* – булмаслык нәрсәләр вәгъдә итү; *тау кәҗәсе; тау лаләсе; тау ястыгы.*

Югарыда китерелгән сүзлек мәкаләсеннән күренгәнчә, тезмә, парлы сүзләр һәм фразеологизм тау сүзе оясында үзләренең аңлатмалары белән урын алган. Ә кушма сүзләр алфавит тәртибендә үз урыннарында бирелгән:

***ташпулат*** (ис.) – таш йорт, пулат.

***таштабан*** (ис.) 1. чабата астына куя торган күтәрмә. 2. бала-лар ясап шуа торган тимераяк.

Җ. Вәлиди, бары тик аерым лексик мәгънәгә ия булганда гына, сүзне сүзлеккә теркәргә мөмкин дип басым ясый. Хосусан, *-сыз, -лык, -лы* кушымчалы сүзләрне җентекләп тикшереп, аларга сүзлектә аерым сүз буларак урын алуы өчен тамырыннан үзгә яңа төшенчә белдерү таләбен куя. Фигыльләрнең бирелешенә махсус туктала. Аларның юнәлеш формаларын сүзлектә тулысынча күрсәтеп, төп фигыль аша аңлату кирәклеген әйтә. Кайбер юнәлеш кушымчасы алган фигыльләрнең мөстәкыйль мәгънә белдерүләренә дә игътибар итә. Сүзлектә бу мәгънәләрне аерып күрсәтү кирәклегенә басым ясый. Җ.Вәлиди фигыльләр бирелешендә борынгы *-мак (укымак)* формасыннан баш тартып, сөйләм теленнән алынган *-у (уку)* кушымчалы фигыльләрне сүзлектә күрсәтүнең төп формасы итеп ала (шунда ук). Сүзлектә моны мәс., ***арттыру*** (фг.), ***охшау*** (фг.), ***өртү*** (фг.), ***әрләү*** (фг.) һ.б. барлык фигыльләр бирелешендә күзәтергә мөмкин.

Сүзлек шул чорда кулланышта йөргән яки яңа ясалган терминнарны туплап бирүе белән дә кыйммәтле, мәс., яңа кулланышка кергән сүз буларак, ***ташлама*** (ис. яс.) скидка, уступка рәвешендә бирелә дип күрсәтә.

Фонетика, фәлсәфә, физика, физиология, финанс, химия, грамматика, геология, мантыйк, медицина, ботаника, зоология терминнары махсус тамгалар белән күрсәтелә. Аерым сүзләргә «яңа кереп бара торган» яки «сирәк йөри торган» тамгалары китерелә һәм автор, мондый сүзләрнең, терминнарның аңлатмалары белән генә чикләнмичә, аларның русчага тәрҗемәләрен дә китереп, сүзлекнең информацион эчтәлеген тагын да баета:

***арпа*** (ис.) бодайга охшаган, ләкин аңа караганда кылчыгы зуррак сабан ашлыгы – *ячмень; кибәктән арпаны аера белми* – аңгыра кешегә әйтәләр.

***арпаган*** (ис.) солыга охшашлык бер үсемлек – *ячмень дикий.*

Аерым очракларда сүзне һәм грамматик, һәм стилистик яктан сыйфатлый, һәр сүзнең сүз төркемен билгели, алынма сүзләрнең чыганак телен, кулланыш чикләрен күрсәтә. Мәс.: ***әхлак*** (ис., әд., гар.) 1. асылда холыкның күплеге, ләкин бездә нравственность, мораль мәгънәләрендә йөри. 2. әхлак хакындагы гыйлем – этика.

Сүзлектә игътибарга лаек тагын бер очрак: Җ.Вәлиди, аерым мөстәкыйль фигыльләрнең ярдәмче фигыль функциясенә күчеп, тезмә фигыльләр ясый алу мөмкинлеген дә барлый һәм аларны аерым тел берәмлеге буларак терки. Мәс., ***бирү*** фигыле мисалында карасак, ул аның мөстәкыйль мәгънәләрен күрсәтеп бетергәннән соң аерым мәкалә итеп:

***бирү*** (ярдәм фигыле булып та килә) *үсә бирә, ашый бирә* кебек тезмә фигыльләрдә эш-хәрәкәт бернигә карамый дәвам итә дип күрсәтә һ.б.

Сүзлекнең күпчелек мәддәсе Г. Тукай, Г. Кандалый, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Ф. Бурнаш, К. Насыйри, М. Гафури, Г. Рәхим, Дәрдемәнд, Ш. Бабич, Ш. Камал, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый әсәрләреннән, халык авыз иҗаты – мәкальләр, такмаклар, табышмаклар, халык җырларыннан өзекләр белән иллюстрацияләнә. Сүзлекнең тарихи-лингвистик әһәмиятен билгеләп, андагы иллюстратив материалның күплеген, байлыгын һәм төрлелеген аеруча басым ясап әйтеп китү дә кирәк.

Күренгәнчә, Җ. Вәлиди бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган зур фәнни хезмәт яза. Ул беренче тапкыр татар лексикографиясенең аңлатмалы сүзлекләр төзү өчен төп принципларын эшли. Сүзлек төзү эшен эзлекле фәнни нигезгә кора. Картотека җыю эшен башлап җибәрә. Бүгенге көндә дә Җ. Вәлиди тәкъдим иткән принциплар татар теле сүзлекләре төзүдә нигез булып хезмәт итә. Ни кызганыч, Җамал Вәлиди хаксызга репрессияләнә, сүзлекнең калган материалы кулга алына һәм юкка чыгарыла, шул рәвешле, икенче том чыкмыйча кала һәм эзсез югала.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзү эше 1950 елларда, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалына караган Тел, әдәбият һәм тарих институтында Г.С. Әмиров җитәкчелегендә лексикография бүлеге ачылгач кына, кабат торгызыла. Шул елның урталарында аңлатмалы сүзлек төзү өлкәсендә Н. Исәнбәт, Ф.С. Фасеев тарафыннан яңа кызыклы проектлар тәкъдим ителә. 1958 елда «Татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзүгә сүзләр җыю өчен лексикологик сораулык» эшләнә. Аны тел белгече Ф.С. Фасеев төзи, күренекле галим профессор Л. Җәләй редакцияли. Сораулыкта аңлатмалы сүзлек өчен тупланырга тиешле сүзләр төп зур дүрт тематик төркемгә бүленеп күрсәтелә: «1. Табигать; 2. Кеше; 3. Җәмгыять; 4. Танып белү һәм фәннәр». «Һәрбер бүлек үз нәүбәтендә табигый

системасы буенча – бүлекчәләргә, бүлекчәләр темаларга» (Татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзүгә сүзләр җыю өчен лексикологик сораулык, 1958: 102) бүлеп бирелә. Ул «татар теленең сүз байлыгын тормышның, чынбарлыкның барлык өлкәләре буенча мөмкин кадәр тулырак итеп җыеп алуны тәэмин итү» (шунда ук) максатыннан эшләнә. Сораулыкның ахырында аерым төшенчәләрне атау ягыннан искәрмәләр урнаштырыла. Ф.С. Фасеев аңлатмалы сүзлекне төзү халык соравы белән башкарылуын ассызыклап күрсәтеп үтә.

Бүлектә иң башта аңлатмалы сүзлек төзүдә аеруча мөһим этап булган картотека базасын булдыру максаты куела. Бу эшкә җәмәгатьчелек тәртибендә Татарстан, Башкортстан республикалары, Пермь, Ульяновск, Куйбышев өлкәләре татар мәктәпләренең укучылары һәм укытучылары, студентлар, тел белән кызыксынган аерым кешеләр җәлеп ителә. XIX–XX гасыр татар әдәбияты классикларыннан, иҗтимагый-сәяси әдәбияттан, башка халыкларның классик һәм күренекле язучыларының тәрҗемә әсәрләреннән, кайбер закон, указлар, мәктәп дәреслекләре, сәяси һәм фәнни-популяр китаплардан, татар халык авыз иҗаты әсәрләреннән иллюстратив лексик материал туплау ягыннан зур эш башкарыла. Бу юнәлештәге эш 1958 елдан алып 1963 елга кадәр эзлекле дәвам итә. Нәтиҗәдә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының тел бүлегендә миллионлап сүздән торган картотека туплана. Картотека төзү эше аңлатмалы сүзлекләр төзү барышында да туктамый дәвам итә. «Хәзерге татар әдәби теленең аңлатмалы сүзлеген төзү инструкциясе» 1964 елда басылып чыга һәм анда алда төзеләчәк сүзлекнең төп принциплары эшләнә. Аның соңында турыдан-туры сүзлек төзү эше башланып китә. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең I томы – 1977 елда, II томы –1979 елда, III томы 1981 елда басылып чыга. Ул татар әдәби теленең XIX–XX гасыр эчендә гомумкулланышта йөргән лексик һәм фразеологик байлыгын туплап бирә. Сүзлектә барлыгы 47000 сүз һәм фразеологик берәмлек бар. Баш сүзләргә грамматик һәм стилистик сыйфатлама бирелә, кулланылыш үзенчәлекләре күрсәтелә. Грамматик яктан гамәлдәге классификация нигезендә сүзнең кайсы сүз төркеменә каравы, кирәк урыннарда кайбер грамматик формалары тәкъдим ителә (мәс., **ТАНУ** I *ф.* (таны, таный, таныр, таныячак) ... **ТАНУ** II *ф.* (тан, тана, танар, та-

начак) һ.б.), башка сүз төркеменә күчүе (конверсия күренеше) яки ярдәмче сүз функциясендә кулланылу очраклары китерелә (мәс., **ДУ** 1. *аваз ияр.* ... 2. *рәв. мәгъ. каб. форм.* ... 3. *хәб. функ.* ...). Кулланыш нормаларына нигезләнеп, сүзләр стилистик яктан да сыйфатлана. Кулланыш чикләре (*мәс., кит. диал. махс., гади с., иск.* һ.б.), эмоциональ төсмерләре (*мәс., юг. кимс., мыск., шаяр., шелт., шөбһ.* һ.б.) күрсәтелә. Сүзләрнең мәгънәләре һәм мәгънә төсмерләре өч төрле юл белән аңлатыла: мәгънәне тасвирлап аңлатып бирү (мәс., **ИЯ** *и.* 1. Берәр нәрсәнең, милекнең хуҗасы. ...); сүзнең мәгънәсен ачу өчен, аның синонимнарыннан файдалану (мәс., **БӘЛӘКӘЙ** *с.* 1. Кечкенә. ... 2. Яшь ... 3. Әз...); аерым очракларда, мәгънәне аңлату өчен, алар икесе бергә катнаш та кулланыла (мәс., **ИТЛӘЧ** *с.* 1. Симез, ите күп булган. ...) һәм өченче юл икенче сүзгә җибәрү юлы белән аңлатыла (мәс., **ӘЗ** *рәв. к.* **аз**). Борынгы катлам лексиканың, аеруча фигыльләрнең күп мәгънәлелеген (мәс., ***төшү*** фигыленең 66 мәгънәсе теркәлә, ***тору*** фигыленең 45, ***булу*** фигыленең 39, ***тарту*** фигыленең 37, ***бирү*** фигыленең 36, ***алу*** фигыленең 32, ***утыру*** фигыленең 23 һ.б.), аерым сүзләрнең фразеологизмнар барлыкка китерүдәге активлыгын билгели (мәс., ***баш*** сүзе белән 92 фразеологизм теркәлгән, ***тел*** сүзе белән 88, ***авыз*** сүзе белән 72, ***акыл*** сүзе белән 44, ***бер*** сүзе белән 39, ***аяк*** сүзе белән 35, ***теш, борын*** сүзләре белән 26, ***тын*** сүзе белән 25, ***таш*** сүзе белән 24, ***тәртә, ут*** сүзләре белән 22 һ.б.). Сүзлеккә барлыгы 32 880 баш сүз, 14 010 тезмә сүз һәм фразеологик берәмлек туплап бирелә.

Моңа кадәр чыккан тәрҗемәле һәм аңлатмалы сүзлекләрдә татар теленең күп составлы лексик берәмлекләренең, тезмә фигыльләренең һәм фразеологик әйтелмәләренең бер өлешен баш сүз шәрехләмәсе эчендә аның аерым мәгънәләре аша бирү, ә икенче өлешен ромб билгесеннән соң фразеологизмнар белән бергә аралаштырып бирү күзәтелә, ягъни охшату-чагыштыру юлы белән ясалган күп составлы лексик берәмлекләр фразеологизмнардан аерып каралмый. Өстәвенә «үзәк компонент» принцибы белән теркәлү сәбәпле, бер үк сүзнең берничә урында кабатлану мөмкинлеге дә була. Инструкция төзегәндә үк, бу мәсьәләгә игътибар итеп, күп составлы лексик берәмлекләрне фразеологизмнардан аеру карала. Алар өчтомлыкта беренче сүз принцибы белән баш сүз маддәсендә, төп мәгънәләрне күрсәтеп бетергәннән соң, яңа абзацтан китерелә. Ә фразеология шуннан соң килгән ромб билгесе белән тер-

кәлә. Мәсәлән, ***ат кузгалагы***, ***баш капкачы***, ***дала лачыны***, ***солы чыпчыгы***, ***төпсез бәлеш***, ***тутый кош***, ***уймак чәчәк*** кебек атамалар фразеологиягә хәтле лексик берәмлек буларак аерып бирелә. Төрки лексикография өчен моның шулай хәл ителүе бик мөһим, чөнки төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә дә, аналитик сүз ясалышы – борынгы чорлардан ук килә торган күренеш. Күп составлы терминнардан тыш, фразеологик ояга керми торган исем һәм башка сүз төркемнәренә караган сүзләр + ярдәмче фигыль калыбы белән ясалган тезмә фигыльләр дә (мәс., ***бүләк итү***, ***карар кылу***, ***насыйп булу***, ***ярдәм итү***, ***ду килү***, ***юк итү***) сүз ясалышының бер төре булып тора. Аларны тел берәмлеге буларак аерып күрсәтү сүзлекнең уңышлы ягы булып санала. Кайбер мөстәкыйль фигыльләрнең, башка мөстәкыйль фигыльләр янында, ярдәмче фигыль функциясенә күчеп, тезмә фигыльләр ясау очраклары да, тулысынча булмаса да, сүзлектә күпмедер дәрәҗәдә чагылыш таба (мәс., **БАРУ** *ф.* мәгънәләр аңлатылып беткәннән соң, шул рәвешле ясалган тезмә фигыльләр аңлатмалары белән китерелә: ***барып йөрү*** ...; ***барып кайту*** **(*килү*)** ...; ***барып керү*** ...; ***барып күренү*** ...; ***барып күрү*** ...; ***барып чыгу*** ...; ***барып җитү*** ...). Фигыльләрнең ярдәмче фигыль функциясе баш сүз маддәсендә аерым мәгънә буларак аңлатыла. (мәс., **БАРУ** *ф.* ... 13. *ярд. ф. функ. Хәл фигыльләрнең -ып (-еп) -п формасы белән бәйләнештә килеп, аларның төп мәгънәсенә түбәндәге төсмерләр өсти:* 1) юнәлешле яки нәтиҗәле хәрәкәт төсмере. *Чыгып бару.* ...; 2) эзлеклелек, дәвамлылык төсмере. *Үткәреп бару.* ...; 3) билгеле бер чиккә якынлашу, йөз тоту төсмере. *Кояш баеп бару* h.б.).

Шул рәвешле, үз вакыты өчен саллы, эчтәлеге һәм эшләнеше белән мөкәммәл дип саналырга хаклы бу аңлатмалы сүзлекнең төзелеп басылып чыгуы, гомумән, татар лексикографиясенең яңа зур уңышы, яңа казанышы дип күрсәтергә кирәк. Ул – лексикография бүлеге хезмәткәрләренең зур тырышлыгы, фидакярлеге нәтиҗәсе. Аны эшләүдә танылган тел галимнәре И.А. Абдуллин, Ф.Ә. Ганиев, М.Г. Мөхәммәдиев, Г.Х. Ахунҗанов, Р.Г. Әхмәтьянов, Ш.Р. Ханбикова, К.С. Сабиров, С.Б. Вахитова, Ф.М. Газизова, Л.Р. Гайнановалар катнаша. Сүзлек Л.Т. Мәхмүтова, М.Г. Мөхәммәдиев, К.С. Сабиров һәм Ш.С. Ханбикова редакциясендә дөнья күрә. Әлеге хезмәтнең басылып чыгуы, гомумтюркология күләмендә татар тел белеменең, аеруча татар лексикографиясенең,

үткән гасыр ахырында янә бер югары баскычка күтәрелүенең ачык дәлиле.

Өч томлы аңлатмалы сүзлек фәнни әйләнешкә кертелгәннән соң, җәмгыятьтә татар тел үсешенә тәэсир итәрлек зур вакыйгалар булып уза. Ул республикадагы тел сәясәте, татар теленең Конституциядә дәүләт теле дип беркетелүе белән башланып китә. 1992 елның 8 июлендә Югары Совет Татарстан телләре турындагы законны раслый. Рус һәм татар телләре Татарстанда дәүләт телләре дип игълан ителә. 1994 елның 20 июнендә бу законны тормышка ашыру юлларын билгеләгән «Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча ТР Дәүләт программасы» кабул ителә. Милли мәктәпләр ачу, татар балаларын тулысынча үз туган телләрендә укыту, югары уку йортларында фәннәрне татарча укыту мәсьәләләре күтәрелә, гомумән, милли мәгариф системасында зур үзгәрешләр барлыкка килә. Шул рәвешле, XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы халыкара мәйданда да, ил күләмендә дә кискен сәяси-икътисади, иҗтимагый, мәдәни һ.б. күптөрле вакыйгаларга бай булуы, фән-техниканың сизелерлек алга китүе, халыкара элемтәләр, бәйләнешләр, үзара аралашуларның шактый нык артуы белән аерылып тора. Мондый вазгыять беренче чиратта телгә йогынты ясый. Тормышта булган үзгәрешләр иң элек телнең сүзлек составында, аның лексик системасында чагылыш таба. Нәтиҗәдә бу чорда татар телендә күп кенә яңа сүзләр кулланышка кереп китә. Тел үз мөмкинлекләре исәбенә дә, искергән сүзләрне торгызу һәм диалектизмнар исәбенә дә баеый. Алынмалардан файдалану да телебезнең сүзлек составын киңәйтүдә мөһим бер ысул булып кала. Нәтиҗәдә соңгы чирек гасыр эчендә татар әдәби телендә тагын шактый гына яңа лексик берәмлекләр барлыкка килә, телебезнең лексик системасында башка күпсанлы үзгәрешләр теркәлә. Табигый ки, шул вакыт эчендә телдә, аның лексик системасында барлыкка килгән һәртөрле үзгәрешләрне кабат күз алдыннан үткәреп, яңа сүзлекләрдә чагылдыру бурычы алга килеп баса. Җәмгыять тарафыннан куелган бу бурычларны үтәү максатында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан берничә сүзлек төзелә.

Беренчесе – институтта хезмәт куйган ике буын галимнәрнең уртак тырышлыгы белән төзелеп, 2005 елда нәшер ителгән бер

томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге». Анда тупланган сүзләрнең саны элегрәк дөнья күргән өчтомлыктагы сүзләр саныннан шактыйга артыграк. Чагыштырмача җыйнак булуына карамастан, сүзлеккә татар әдәби телендә актив кулланышта йөргән 58 000 мөстәкыйль сүз һәм фразеологик берәмлек теркәлә. Ул бай эчтәлекле, файдалы һәм уңайлы гамәли кулланма булуы белән аерылып тора. Биредә тел күренешләрен дөрес теркәп тасвирлауга бәйле берничә мөһим мәсьәләне хәл итү юнәлешендә җитди эш башкарыла. Шулардан аеруча әһәмиятлеләре – күп составлы тезмә сүзләр, шулай ук исем һәм башка сүз төркемнәренә караган сүзләр + ярдәмче фигыль калыбы белән ясалган тезмә фигыльләр беренче сүз маддәсендә, аның мәгънәләре күрсәтелеп беткәннән соң, турыпочмаклык тамгасы артыннан, мөстәкыйль тел берәмлекләре буларак, үз аңлатмалары белән урын ала (мәс., **АЮ** *ис.* ... □**Аю баланы** *бот.* Кыргый балан, мәрҗән куагы; *русчасы:* бузина. **Аю балыгы** *зоол. иск.* Тюлень; су эте. **Аю көпшәсе** *бот.* Эре, озын куе яфраклы, юан көпшәле үсемлек; *русчасы:* борец жёлтый. **Аю кырмыска** Эре кырмыска. **Аю табан** Табан асты уентысыз, яссы табанлы кеше; **МӘГЪЛҮМ** *сф. гар.* … □ **Мәгълүм булу** Ачыклану. **Мәгълүм итү** Белдерү, хәбәр итү; ачыклау һ.б.). Икенчедән, кайбер мөстәкыйль фигыльләрнең, ярдәмче фигыль функциясенә күчеп, башка мөстәкыйль фигыльләр белән берлектә барлыкка китергән аналитик фигыль формалары тезмә фигыльләрнең бер төре буларак тәкъдим ителә һәм сүзлектә аерым сүз итеп теркәлә. Биредә аларның иң киң кулланылганнары аңлатмасыз гына үзләре ясалган фигыль оясында китерелә (мәс., **ТАЯНУ** *фг.* .... □ **Таяна төшү. Таянып алу. Таянып кую. Таянып тору. Таянып утыру;** һ.б.). Бу берәмлекләр телебездә һәрдаим кулланылса да, моңа кадәр алар сүзлекләрдән читтә калып килгән. Димәк ки, телебезнең байлыгы да тулысы белән чагылып бетмәгән булып чыга. Конверсия күренеше дә, ягъни бер сүз төркемендәге сүзнең, икенче бер сүз төркеменә күчеп, шул сүз төркеменә хас функция үти алу үзлеге әлеге хезмәттә эзлекле рәвештә һәм киң чагылыш таба (мәс., **ТА́ГЫН** *рәв.* Аның сүзлектә төп мәгънәдән тыш теркәгеч, кисәкчә функциясендә килә алуы бирелә; **ТӘ́МАМ** *хәб. сүз* Исем һәм рәвеш буларак килә алуы күрсәтелә һ.б.). Татар халкы күп гасырлар буе төрле халыклар белән аралашып яшәгәнлектән, телдә алынма сүзләр саны шактый тупланган. Борынгы

чорда үтеп кергән сүзләр татар теле тарафыннан нык үзләшкән, үзгәрешләргә дучар ителгән. Татар телендә рус, рус теле аша европа телләреннән кергән сүзләр бар, дингә бәйле рәвештә гарәп һәм фарсы алынмалары шактый урын алган, шулай ук фин-угор телләреннән кергән сүзләр дә күзәтелә. Мондый сүзләр сүзлектә чыганак телләре күрсәтелеп урын ала (мәс., **КИТАП** *ис. гар.* ...; **ЛӘҮКӘ** *ис. рус.* ...; **ПА́СПОРТ** *ис. фр.* ...; **ПОШИ** *ис. мар.* ...; **САДӘ** *сф. фар.* ... һ.б.). Бу рәвешле эшләү сүзләрнең эчтәлеген тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Эзләнүләр чорында төзелгән сүзлек буларак, орфографиядә аерым үзгәрешләр тәкъдим ителә.

Сүзлек институтта шул чорда эшләгән лексикография бүлеге хезмәткәрләре И.А. Абдуллин, М.Г. Мөхәммәдиев, Р.Г. Әхмәтьянов, С.Б. Вахитова, Ф.М. Газизова, М.Б. Хайруллин, Г.Г. Сабирова, Д.Б. Рамазанова, Р.К. Рәхимова, Ә.Х. Алеева, Л.Г. Габдрахманова, Р.Р. Абдуллина, Л.Р. Мортазина, Ф.И. Таһирова, Ф.Ф. Гаффарова тарафыннан төзелә, ә аны редакцияләү эшен Ф.Ә. Ганиев (баш мөхәррир), К.С. Миннибаев, Ф.М. Газизова, Г.Г. Саберова, Ф.Ф. Гаффарова, А.Р. Рәхимова, Ә.Х. Алиева башкара.

2010 елда ТӘһСИнең лексикография бүлегендә тагын бер зур хезмәт – туган телләре татар теле булган укучыларга аталган «Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге» эшләнеп бетеп, 2013 елда басылып чыга. Бу сүзлек күләме ягыннан кыскарак, куллану өчен уңайлы итеп, мәктәпләр өчен махсус төзелә. Аңа барлыгы 10 000 нән артык лексик берәмлек туплап бирелә. Сүзлеккә мәктәп программасы күләмендә ана телендә материал бирү максаты куела. Бигрәк тә мәктәп программасы күләмендә терминологияне мөмкин кадәр күбрәк чагылдыру зарурияттеннән чыгып эш ителә. Укыту предметларының төп төшенчәләре күләмендә терминнарның киңрәк китерелүе нәкъ менә шул ихтыяҗны күздә тота. Әлбәттә, сүзлеккә ул чорда актив кулланышка кергән сүзләр тупланып бирелә – телнең эчке мөмкинлекләре нигезендә ясалып тәкъдим ителгән яңа сүзләр (мәс., к***үчермә***, ***суыткыч***, ***таныш***, ***тукталыш***, ***ышанмалык*** һ.б.), кабат торгызылып кулланышка кертелгән искергән сүзләр (мәс., ***җепкыр, икътисад, йот, кизү, салым, табиб*** һ.б.), аерым сүзләрнең киңәйтелгән яңа мәгънәләре (мәс., ***бәйге, көндәш, мөнбәр, тугра*** һ.б.). Хәзерге милли яңарыш, гореф-гадәтләребезне барлау, торгызу, динебезгә кире кайту белән бәйле рәвештә активлашкан милли традицияләр, бәйрәм атама-

лары (мәс., ***гает, корбан, нәүрүз, покрау, раштуа, сөрән*** һ.б.), борынгы уен исемнәре (мәс., ***әбәк, йөзек салыш, качышлы, таккаравыл, шамакай уены*** һ.б.), татар халык авыз иҗатына, мифологиягә караган сүзләр (мәс., ***албасты, дию, дөлдөл, җалмавыз, кирәмәт, су анасы*** һ.б.), киң кулланыштан төшеп калган тарихка бәйле сүзләр (мәс., ***айбалта, алпак, йомышлы, корык, лашман, ясаклы*** һ.б.) дини эчтәлектәге атамалар (мәс., ***аять, әбҗәд, бәдәл, рәсүл, сөннәт*** һ.б.) зур урын алган. Шулай ук ул чорда рус теле һәм рус теле аша кергән чит тел алынмаларының активлашуы да сүзлектә чагылыш таба (мәс., ***акция, биржа, девальвация, корпорация, кросс, фермер*** һ.б.). Аз күләмдә булса да гади сөйләм сүзләре (мәс., ***Әндри казнасы, зимагур, кана, килмешәк, тартай*** һ.б.) һәм диалектизмнар (мәс., ***игәч, кактөш, очсыз, пима, рәеш, ырам*** һ.б.) очрый. Ботаника, зоология терминнары үзләренең классификациясе – семьялыклары, отрядлары күрсәтелеп бирелә. Сөйләшләрдә бу атамалар төрлечә әйтелгәнгә, аларның русчага тәрҗемәләре китерелә (**ЗӘРДӘ** ... *русчасы:* **сныть**; **Баба кош** ... *русчасы:* **пеликан**; **БӘРТӘС** ... *русчасы:* **язь**; **БӨГӘЛЧӘН** ... *русчасы: слепень*; **ИЛЕК** ... *русчасы:* **косуля** һ.б.). Татар телендә аерым сүзләрнең дөрес әйтелешен бирү өчен, квадрат җәяләр эчендә транскрипциясе күрсәтелә (мәс., **КАЛЬГА́ [ќальға]** ...; **КАМА́ [ќама]** ...; **КОЙКА́ [ќойќа]** ... һ.б.). Ул, мәктәп программасы күләмендә укучыларга туган телне үзләштерү, белемнәрен тирәнәйтү өчен, ярдәмлек буларак тәкъдим ителә. Сүзлек гамәлдәге орфография кагыйдәләре нигезендә төзелә. «Мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлек» буларак татар телендә укыткан мәктәп программасы белән үрелеп бара. Сүзлектә бирелгән һәр лексик берәмлеккә грамматик яктан күзәтү ясала. Шуның белән ул дәреслеккә файдалы өстәмә була ала. Бирелгән сүзнең сүз төркеме, стилистик белешмәсе китерелә, төрләнгән вакытта сүзләрнең иң актив кушымчалары бирелә. Исемнәрдә кайбер килеш кушымчалары һәм тартым кушымчасы; фигыльләрдә боерык фигыль формасы, хәзерге заман формасы, асыл сыйфатларда һәм кайбер рәвешләрдә чагыштыру дәрәҗәсе кушымчалары күрсәтелә (мәс., **АЛМА** (-га; -дан; -сы) *ис.* 1) Алмагачның витаминнарга, тимергә бай, әчкелтем татлы, сусыл җимеше. ...; 2) *сөйл.* Алмагач. ...; **АЛ** (-рак) *сф.* 1) Аксыл-кызыл төстәге. ...; 2) *күч.* Матур, гүзәл, ямьле. ...; **БА|Ю** (-е; -йый) фг. Бату, офык артына китү. ... һ.б.). Сингармонизм зако-

нына бәйле рәвештә ялганырга тиешле кушымчаларның вариантлары бирелә, авазлар чиратлашу очраклары күрсәтелә (мәс., **ХАЛЫ|К** (-кка; -ктан; халкы) ...; **ЫРЫМ** (-га; -нан; -ы) ...; **Я́У** (-га; -дан; явы) ...; **Я|БУ** (-п; -ба) ...; һ.б.). Татар телендә, кагыйдә буларак, басым сүзнең ахыргы иҗегенә төшә, мондый очракта сүзлектә баш сүздәге басым күрсәтелми, әгәр ул башка иҗеккә төшсә, ул вакытта сүзнең басымы күрсәтеп бирелә (мәс., **ТУГАННА́РЧА** *рәв. ...*; **Ю́ГЫЙСӘ** *терк.* ... һ.б.). Бер сүз төркемендәге сүзнең икенче сүз төркеме функцияләрен үти алу очраклары (конверсия) аерым тамгалар белән билгеләнә (мәс., **ТӨЧЕ** (-рәк) *сф.* **1**. 1) ...; 2) ... **2**. *рәв. мәгъ.* Артык юмакай итеп. *Төче елмаю* һ.б.).

«Мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлек»нең мөһим үзенчәлеге – сүзлектә компонентлары аерым язылган кушма сүзләр һәм тезмә фигыльләр беренче сүз тәртибе белән ояда күпләп күрсәтелә һәм аларга аңлатмалар бирелә (мәс., **КАРАР** ... □ **Карар итү (бирү, кылу)**. Билгеле бер мәсьәлә хакында ныклы фикергә килү; **МҮК** ... □ **Мүк гөмбәсе** *бот.* Болетачалар семьялыгыннан, шул исемдәге ыругны билгеләгән, эшләпәсе сары, караңгы көрән, аксыл коңгырт төсләрдәге, йомшагы ак, сынган урыны зәңгәрләнә торган гөмбә; русчасы: моховик; Мүк җиләге бот. Арчанчалар семьялыгыннан, сазлыклы юеш урыннарда үсә торган нечкә сабаклы, вак яфраклы куак һәм шул куакның кызыл әчкелтем җиләге; *русчасы:* **клюква; ТИБҮ** ... □ **Тибеп алу** Кинәт тибү; **Тибеп кую** Бер тапкыр тибү; **Тибеп тору** Бертуктаусыз тибү һ.б.). Шул рәвешле, «Мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлек»тә тел байлыгының киңлеге тагын да тулырак ачыклана төшә.

Сүзлекне төзүдә Р.Р. Абдуллина, Ә.Х. Алиева, Л.Г. Габдрахманова, Ф.М. Газизова, А.Ф. Гайнетдинова, Ф.Ф. Гаффарова, А.Р. Рәхимова, Г.Р. Самирханова, Г.Г. Саберова, Ф.И. Таһирова, Л.Ш. Шәмсетдинова катнаша. Аны редакцияләү эшен аерым өлешләрен Ф.Ә. Ганиев һәм Г.Г. Саберова, ә тулысынча Ф.Ф. Гаффарова башкара.

Соңгы вакытта басылып чыккан сүзлекләрдән профессор Ф.Ә. Ганиев авторлыгындагы ике кисәктән торган «Тезмә фигыльләрнең аңлатмалы сүзлеге»нә (2009: 375, 2012: 537) татар телендә еш очрый торган якынча 15 000 тезмә фигыль тупланып бирелә. Тюркологиядә аерым галимнәр тарафыннан хәл фигыльгә модификацияләүче (ярдәмче) фигыль кушылып барлыкка килгән

аналитик формаларны тезмә фигыльләрнең бер төре дип санау кабул ителгән. Ф.Ә. Ганиев «Тезмә фигыльләр татар телендә *-ып/-еп, -п* яисә *-а/-ә, -ый/-и кушымчаларына тәмамланган хәл фигыльләргә модификацияләүче (ярдәмче) фигыльләр* кушылып ясала» (2009: 5) дип күрсәтә. Ул андый төр фигыльләрне сүз ясалышына кертеп карый һәм аларны мөстәкыйль лексик берәмлек буларак тәкъдим итә (Татар грамматикасы, 2002: 200–207). Үзенең карашларында автор И. Гиганов, А. Казимбәк, М. Иванов, А. Троянский грамматикаларына, тюркологлардан А.Н. Кононов, В.М. Насилов, Н.А. Баскаков һ.б.ның хезмәтләренә таяна (2009: 5). Тезмә фигыльләрнең табигатен Ф.Ә. Ганиев түбәндәгечә аңлата: «төп мәгънәсе анның беренче компоненты белән бирелә, икенче компоненты – модификацияләүче фигыль – өстәмә лексик мәгънә алып килә, беренче компонентның мәгънәсен ачыклый төшә, конкретлаштыра» (мәс., ***әйтә килү; бөркүләнә төшү; җибәрә бару; җитдиләнеп китү; калтырап тору; кими бару; китеп калу; оялып кую*** һ.б.), «кайбер тезмә фигыльләр компонентларының мәгънәләре суммасын тәшкил итәргә мөмкин: ***укып бетерү*, *ашый башлау***. Ләкин күпчелек тезмә фигыльләрнең мәгънәләрен турыдан-туры компонентларының мәгънәләреннән китереп чыгарып булмый: ***укып чыгу*, *каушап төшү*, *карап алу*** һ.б.» (2009: 9, 10). Тезмә фигыльләрнең мәгънәсен аңлатканда, төп игътибар нигез фигыльнең мәгънәсен ачыклауга түгел, ә модификацияләүче (ярдәмче) фигыльнең нигез фигыльгә нинди мәгънә өстәвен аңлатуга юнәлтелә, мәс., ***кайрап чыгу*** барысын да (бөтенесен дә) рәттән кайрау ...; ***кереп йөрү*** даими яки регуляр рәвештә керү ...; ***кечерәя бару*** торган саен ныграк кечерәю ... һ.б. Галим тезмә фигыльләр ясауда катнаша торган түбәндәге модификацияләүче фигыльләрне күрсәтә: «*алу, ату, бару, бетерү, бетү, бирү, җибәрү, җиткерү, җитү, йөрү, калу, карау, керү, килү, китү, кую, салу, тору, төшү, узу, утыру, чыгару, чыгу, язу, яту*». Бу фигыльләр, тезмә фигыльләр ясауда катнашканда гына, модификацияләүче фигыльләргә әйләнәләр, ә аерым кулланганда, мөстәкыйль фигыль, лексик берәмлек булып калалар (2009: 11). Мондый төр тезмә фигыльләр, сүзлек берәмлеге буларак, татар теленең тәрҗемәле сүзлекләрендә электән дә, төгәлрәк әйткәндә, 1966 һәм шулай ук 1988 елгы «Татарча-русча сүзлек»ләрдә шактый чагылыш тапкан. Алда әйтелгәнчә, аларны аңлатмалы сүзлекләрдә

махсус күрсәтү бер томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ннән (2005: 848) башланып китә.

Бу фигыль формалары тюркология, шул исәптән татар тел белеме өлкәсендә эшләүче галимнәрнең күптәннән килгән бәхәсле тикшерену объекты булып тора һәм галимнәр тарафыннан төрле фәнни яссылыкта карала. Элегрәк чыккан фәнни хезмәтләрдә дә аларның семантик ягына игътибар бирелгән. Күренекле татар галимнәреннән Г.Х. Алпаров ярдәмче фигыльләр төп фигыльгә өстәмә мәгънә бирү өчен кулланыла дип белдерә, В.Н. Хангилдин ярдәмче фигыльләр төп фигыльнең семантикасына йогынты ясый дип күрсәтә. Алда китерелгәнчә, бу төр тезмә фигыльләр, мөстәкыйль тел берәмлеге буларак, Җ. Вәлидинең «Татар теленең тулы сүзлеге»ндә урын алган. Р.С. Газизов та аларны мөстәкыйль фигыль дип саный һәм сүзлекләрдә теркәлергә тиешле мөстәкыйль лексик берәмлек итеп таный. Профессор Ф.М. Хисамова мондый фигыль формаларын «эшнең үтәлү дәрәҗәсен яки юнәлешен белдерә торган лексик-грамматик категория» дип билгели (Хисамова, 2006: 274). Лексик-грамматик категория буларак бу күренеш сүзлектә күрсәтелергә тиеш булмый.

Рус телендә күбесе мәгънәләре белән тәңгәл булган префикслар алган фигыльләр (мәс., читать, вычитать, дочитать, зачитать, перечитать, прочитать, почитать, считать), рус сүзлекләрендә алфавит буенча үз урыннарын алып, аерым лексик берәмлек буларак китерелә. Татар теленең соңгы елларда басылган аңлатмалы сүзлекләрендә тезмә фигыльләрне ныклы алфавит нигезендә тулы хокуклы лексик берәмлек буларак түгел, ә үзе ясалган төп фигыль оясында теркәү кабул ителде. Сүзлекләрдә тезмә фигыльләрне мондый рәвештә күрсәтү, – һичшиксез, уңай күренеш. Бу – модификацияләүче фигыльләрнең төп фигыль семантикасына ясаган йогынтысын күзәтергә, әйтергә теләгән фикерне төгәлрәк тапшыру юлларын ачыкларга, шуның белән татар теленең байлыгын, аның эчке мөмкинлекләрен тулырак ачарга ярдәм итәр дигән максат белән эшләнә.

А. Тимергалинның 2007 елда дөнья күргән «Миллият сүзлеге» (2007: 575) һәм шуның дәвамы буларак соңгы елларда чыккан өч томдагы «Миллият сүзлеге» – (I том, 2016: 743; II том, 2017: 684; III том, 2018: 724) – татар лексикографиясендә олуг казаныш. Аның төзелү тарихын автор «төрле дини төшенчәләрне, аларның

язылыш вариантларын, мәгънәләрен, милләт һәм дин тарихына кагылган әһәмиятле һәм кызыклы фактларны, тормышта эз калдырган күренекле шәхесләр турындагы мәгълүматларны күп еллар буенча көндәлек эш өчен теркәп барган дәфтәрләрдән, аерым кәгазьләрдән һәм картотекадан башланып китте» дип күрсәтә (2007: 3). Автор үзе аны аңлатмалы сүзлек дип атый. Күпьеллык эзләнүләренең нәтиҗәсе буларак барлыкка килгән бу зур фәнни хезмәт, исеменнән күренгәнчә, татар милләте, мәдәнияте һәм дине тарихына, мөселман дөньясына, татарның башка милләтләр белән үзара мөнәсәбәтенә, мәгариф өлкәсенә, фольклорына, мифологиясенә, Татарстан табигатенә, аның географиясенә кагылган әһәмиятле һәм кызыклы фактларны, күренекле шәхесләр турындагы мәгълүматларны, борынгы чорлардан ук килгән һәм әдәби, һәм гыйльми мирасыбызда сакланган, инде онытылып бара торган төрки нигездәге тарихи һәм архаик сүзләрне, төрле төшенчәләрне, гарәп һәм фарсы алынмаларын үз эченә ала. Аңлатмалар төрле чорларда кулланылган хезмәтләрдән алынган мисаллар белән тулыландырыла. Автор, аңлатмалар белән генә чикләнмичә, аерым сүзләрнең чыганак телен барлый, этимологиясен тикшерә. Сүзлекнең үзенә күз салсак, мәс., ***Алык*** Хан заманында халыктан җыелган салым, җыем, алык-салык; ***Әрәпә*** г. Асылда, гарәпчә *гарәфә* сүзеннән 1) керәшеннәрдә Пасха көннәрендә үткәрелә торган үлеләрне искә алу мәҗлесе, поминки. 2) керәшеннәрдә Тройсын (Троица) бәйрәме көнне урамда җырлана торган җырлар; Әрдәнә иск. Казна, тупланган байлык. Элек кызның ата-анасы тарафыннан туй өчен җыелган малны да «әрдәнә» дигәннәр, хәтта кыз үзе дә «әрдәнә» дип аталган // Галимнәрнең сүзеннән әрдәнә кыл. Сүзең – энҗе, нотыгың – хәзинә, бел. Котб; ***Балга*** бор. 1. Төркиләрдә сугыш балтасы, айбалта. 2. Тимерчелектә зур авыр чүкеч, дөлдә [Айдар Хәлимдә очрый] русчасы: *молот*, *кувалда*; ***Буралгы*** Сукбай; русчасы: *бродяга* һ.б. Шул рәвешле, сүзлеккә зур күләмдә татар халкының мәдәни мирасы фәнни әйләнешкә кертелә. Әлеге сүзлек автор үзе билгеләгән «хәзерге заман татар укучысын язма чыганакларга, тарихыбызга һәм иманыбызга якынайтуны, артык вакыт сарыф итмичә генә, күпчелек тарихи, дини, фәлсәфи әдәбиятны зиһенгә алу эшен җиңеләйтү» максатына тулысынча ирешкән (Миллият сүзлеге, 2007: 3).

XXI гасыр башында җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәрабәр басылып чыккан югарыда күрсәтелгән сүзлекләрдә күтәрелгән проблемалар аерым-аерым гына түгел, барысын бергә туплап тасвирлау, телебезнең хәзерге лексик системасының кулланыш сферасын киңрәк күрсәтү ихтыяҗы да туа. Бу бурычны үтәү максатында, татар теленең яңа зур фундаменталь аңлатмалы сүзлеген төзү кирәклеге көн үзәгенә баса. Әлеге хезмәт – гаять күп көч һәм вакыт сарыф итүне сорый торган зур фәнни проект. Сүзлек Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан профессор Ф.Ә. Ганиев әзерләгән инструкция нигезендә төзелә башлый. Бу гаять күләмле һәм үтә җаваплы эш 2002 елда башланып китә. 4 томнан торачак әлеге сүзлекнең күләме якынча 400 табак булыр дип фаразлана. Әлеге яңа зур сүзлекнең бурычы итеп – хәзерге татар әдәби теленең киң кулланышта йөргән лексик байлыгын һәм фразеологиясен мөмкин кадәр тулырак туплап чагылдыру; гомуми кулланышта булган сүзләргә, тотрыклы берәмлекләргә, аларның мәгънәләренә, мәгънә төсмерләренә мөмкин кадәр тулы һәм төгәл аңлатмалар бирү; кулланылышка кереп киткән яңа сүзләрне яки сүзләрнең яңа барлыкка килгән мәгънәләрен ачыклау; аларның грамматик табигатен, стилистик төсмерләрен дөрес билгеләү, кулланылыш үзенчәлекләрен барлау, матур әдәбияттан, иҗтимагый-сәяси, публицистик, фәнни-популяр, фольклор әсәрләреннән, дәреслекләрдән, вакытлы матбугаттан алынган мисаллар белән дәлилләү. Эш барышында чыганакларның даирәсен киңәйтеп, яңадан-яңа тел материалларын анализлау һәм эшкәртү нәтиҗәсендә, сүзлекнең планлаштырылган күләме артканлыгы ачыклана. Шуның белән бергә, теоретик планда аңлатмалы сүзлек төзүгә бәйле кайбер мәсьәләләрне, аерым алганда, конверсия күренешен әтрафлы чагылдыру, тезмә фигыльләрне теркәү рәвеше, аларның мәгънәләрен аңлату ысуллары, татар тел белеме һәм гомуми тюркологиядә ирешелгән башка фәнни уңышларны исәпкә алып эш итү нәтиҗәсендә, инструкциягә шактый үзгәрешләр, өстәмәләр кертелә, аның аерым принциплары үстерелә, камилләштерелә. Шул рәвешле, барлык тупланган тел материаллары 6 том тәшкил итәчәге ачыклана. Бу эшләр проектның гомуми координаторы һәм җитәкчесе А.Ә. Тимерханов җитәкчелегендә алып барыла. Сүзлектә үтә профессиональ сүзләр, жаргоннар, тупас

сүзләр, әдәбиятта очрамый торган җирле сөйләм сүзләре, грамматик формалар бирелми. Сүзлеккә бары тик лексик мәгънәгә ия булган сүзләр генә алына. Татар телендә кулланышта булган алынма сүзләрнең чыганак теле күрсәтелә. Рус һәм рус теле аша кергән алынма сүзләр, үзләшкән борынгы алынмалардан аермалы буларак, рус телендә кабул ителгәнчә теркәлә. Сүзләр гамәлдәге алфавит тәртибендә урнаштырыла. Мәгънәләр аңлатылып беткәннән соң, аерым тамга белән фразеологизмнар китерелә. Сүзлекчәне туплау үтә җентеклелек белән башкарыла. Алдагы сүзлекләрдә теркәлмәгән, әмма соңгы вакытта әдәбиятта шактый еш кулланыла башлаган зур гына төркем сүзләр һәм аерым сүзләрнең өстәмә мәгънәләре исәбенә сүзлек тагын да тулыландырыла. Мәс., тарихи сүзләр (***алай, алапа, алпак, әләмән, багавыл, байса, голуфә, җида*** һ.б.), диалекталь сүзләр (***алгы*** (*2. рәв. мәгъ.*), ***алдавыч*** (*3 мәгъ.*), ***ачамай, әзи, әпә, җалпак, җылу*** һ.б.), кабаттан торгызылган сүзләр (***әйдаман, дивар, җөмһүрият, иләмән*** һ.б.), кулланылышка кереп бара торган яңа сүзләр (***даруханә, җанатар, илбаш, тотык, туңдырма*** һ.б.), алынма сүзләр һәм терминнар (***бартер, бонус, гигабайт, дебат, диджей, дотация, имидж, файл*** һ.б.), чикле күләмдә гади сөйләм сүзләре (***алдак, алмаша, бака*** (*10 мәгъ.*), ***галах, дәмләү, мәй*** һ.б.), жаргон сүзләр (***арчу*** (*6 мәгъ.*), ***вышка*** (*4 мәгъ.*), ***гастролёр*** (*3 мәгъ.*) һ.б.) урын алган. Бер үк сүзнең берничә сүз төркеме функциясендә кулланылуы (конверсия күренеше) сүзлектә эзлекле рәвештә чагылыш таба. Мәс., *булу* фигыленең 37 мәгънәсе күрсәтелә һәм кереш сүз, бәйлек, теркәгеч, кисәкчә функциясендәге кулланылышы китерелә. *Бер* сүзе сан, сыйфат, рәвеш, алмашлык, исем мәгънәсендә һәм кереш сүз, теркәгеч, кисәкчә функциясендә теркәлә. Сүзлектә гомумтөрки сүзләрнең, бигрәк тә фигыльләрнең күп мәгънәгә ия булуы, аерым сүзләрдән ясалган фразеологизмнарның күплеге күзәтелә. Мәс., *аяк* сүзе белән 75, *баш* сүзе белән 162, *бер* сүзе белән 102, *ике* сүзе белән 264, *йөрәк* сүзе белән 189 фразеологизм бирелә, шулай ук сүзлектә рус теленнән калькалаштырылган фразеологизмнар да урын ала: мәс., *алма төшәрлек урын булмау* (яблоку негде упасть), *алсу күзлек аша карау* (смотреть через розовые очки), *диетага утыру* (сесть на диету), *зәңгәр хыял* (голубая мечта), *икенче икмәк* (второй хлеб) һ.б. Алда чыккан аңлатмалы сүзлекләрдән аермалы буларак, татар теленең күп составлы лексик берәмлекләре (мәс.,

***арыш анасы, ат кузгалагы, аю баланы, бүре уы, давыл чәчәге, елак карчыга, Киекказ Юлы*** һ.б.), исем һәм башка сүз төркемнәренә караган сүзләр + ярдәмче фигыль калыбы белән ясалган тезмә фигыльләр (мәс., ***аймыл булу, ант итү, ах-вах килү, бар кылу, җик чигү*** һ.б.) баш сүз оясында түгел, ә компонентлары аерым язылса да, бу сүзлектә, мөстәкыйль тел берәмлеге буларак, алфавит буенча үз урыннарында китерелә, чөнки алар баш сүз мәгънәсе белән һич уртаклыгы булмаган өр-яңа төшенчәне атыйлар. Мондый тип сүзләр – төрки телләргә хас аналитик юл белән ясалган мөстәкыйль лексик берәмлек. Сүз ясалышының аерым бер төрен билгели. Аларны алфавит тәртибендә сүзлекнең мөстәкыйль маддәсе буларак күрсәтү, һичшиксез, тел байлыгыбызны тулырак ачыклауда сүзлекнең уңышлы ягы булып тора. Фигыльләр сүзлектә төп юнәлеш формасында теркәлә, фигыль юнәлешләре телнең грамматик төзелешенә караган булу сәбәпле, алар махсус китерелми. Татар телендә кайбер фигыль юнәлешләре өстәмә лексик мәгънәгә ия. Андый фигыльләрнең юнәлеш формалары сүзлектә китерелә. Аларның беренче грамматик мәгънәсе төп фигыльгә җибәреп күрсәтелә, ә лексик мәгънәләргә аңлатмалар бирелә. Мәс., **Ашалу** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **ашау** (*1 мәгъ.*)...; 2) Кояш, җил, су яки башка нәрсәләр тәэсиреннән бозылу, үзгәрү. ...; 3) Кыршылу, кырылу, ышкылу, тузу. ...; **Кайралу** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **кайрау**. ...; 2) Күп ышкылудан ялтырап тору. ...; 3) Күп ышкылып яки нык кысудан кыршылу. ...; 4) *күч.* Үткенләнү, шомару; күпне күреп тәҗрибә туплау һ.б. Кайбер мөстәкыйль фигыльләрнең, башка мөстәкыйль фигыльләр белән килгәндә, ярдәмче фигыль функциясенә күчеп, тезмә фигыль ясау очраклары төп фигыль маддәсендә аерым-аерым үз аңлатмалары белән ояда күрсәтелә. Бер нигездән ясалган бу тезмә фигыльләр, сүзлектә алфавит тәртибендә китерелмичә, семантик бәйләнешен күздә тотып һәм төп мәгънә уртаклыгын исәпкә алып, үзе ясалган фигыль оясында модификацияләүче фигыльләрнең алфавиты белән теркәлә. Мәс., **ҖИЛЛӘҮ** *ф.* ... мәгънәләренә аңлатма биреп бетергәннән соң, тезмә фигыльләре үзләренең аңлатмалары һәм әдәбияттан алынган мисаллары белән бер ояда урын ала: **Җилләп тору** Бераз җилләү...; **Җилли башлау** Җилләргә тотыну...; **Җилли төшү** Тагын да берникадәр җилләү... һ.б. Тезмә фигыльләрне төп фигыль оясында бирү ярдәмче фигыльләрнең аның семантикасына ясаган йогынтысын төгәлрәк си-

земләргә, татар телен өйрәнүчеләр өчен телнең эчке мөмкинлекләреннән тулырак файдаланырга ярдәм итәр дигән караштан чыгып эшләнә. Сыйфат фигыль һәм хәл фигыль формалары, грамматик категория буларак, сүзлектә аерым китерелми. Әмма кайбер вакытта алар төп фигыльдән үзгә сыйфат һәм рәвеш мәгънәләрен белдерергә мөмкин. Бу очракта төп сүзнең барлык мәгънәләренә аңлатма биргәч, нокталы ярымкалын гарәп цифрыннан соң аерым күрсәтелеп теркәлә һәм лексик мәгънәсе аңлатыла. Мәс., **Егылу** *ф.* **1**. 1) ...; 2) ...; **2. егылган** *с. мәгъ. күч.* Кыерсытылган, авыр хәлдә калган. ...; **3. егылып** *рәв. мәгъ. күч.* 1) Бик нык; көчле. *Егылып көлү;* 2) Мул булып, күкрәп. *Игеннәр егылып уңды* һ.б. Сүзлектә сүзләрнең орфографиясе гамәлдәге традицион кагыйдәләргә нигезләнеп бирелә. Хәзерге вакытта бу сүзлекнең өч томы басылып чыкты. I том – А–В, 2015: 712. Төзүче авторлары – Р.Р. Абдуллина, А.М. Сәгыйтова, Ф.Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова, О.Н. Галимова, А.Ф. Гайнетдинова, Г.Д. Фәтхетдинова, Ф.И. Таһирова, И.И. Сабитова, Э.И. Сафина, Ф.М. Газизова. Томны редакцияләүчеләр: Ф.Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова, Ф.И. Таһирова. II том – Г–Й, 2016: 748. Төзүче авторлары – И.И. Сабитова, Ф.И. Таһирова, А.М. Сәгыйтова, А.Ф. Гайнетдинова, Г.Г. Саберова, Л.Ш. Шәмсетдинова, Г.Р. Сәмирханова, Э.И. Сафина. Томны редакцияләүчеләр: Ф.Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова, Ф.И. Таһирова. III том – К, 2017: 744. Төзүче авторлары – И.И. Сабитова, А.Ф. Гайнетдинова, Ю.Ф. Борһанова, О.Н. Галимова, Г.Г. Саберова, Ф.Ф. Гаффарова, Э.И. Сафина, А.Ә. Тимерханов, Р.Р. Абдуллина, Р.Т. Сәфәров, Ф.И. Таһирова. Томны редакцияләүчеләр: Ф.И. Таһирова, Р.Т. Сәфәров, Ф.Ф. Гаффарова. IV том – Л–Р 2018: 760.

Аңлатмалы сүзлекләр милләт тормышында һәм яшәешендә мөһим роль уйный шул телдә сөйләшүче халыкның белемен арттыруга, сөйләм культурасын үстерүгә хезмәт итә. Шуның өчен дә аны лаеклы рәвештә милләтнең мәдәниятлелек билгесе дип күрсәтәләр. Сүзлекләр – туган телнең бихисап зур хәзинәсе, аның танып белү коралы, милләтнең интеллектуаль үсешендәге күрсәткече. Аңлатмалы сүзлекләр үзенең укучыларын сүзләрне дөрес язарга һәм сөйләмдә урынлы кулланырга өйрәтә, туган телләрен тирәнрәк үзләштерергә ярдәм итә.

## § 13. Ортологик сүзлекләр

Ортологик сүзлекләр татар лексикографиясе системасында аерым урын алып тора. Алар – тел һәм сөйләмне яхшырту, әдәби тел нормаларын ныгыту бурычын үти торган норматив сүзлекләр. Кулланучыда килеп туган сорауларга тиз арада җавап бирү сыйфатына ия булган бу белешмәлекләрне «ашыгыч ярдәм сүзлекләре» дип атыйлар (Козырев, Черняк: 2015, 204).

Әдәби тел үзгәреп тора, аның нормалары да вакыт үтү белән үзгәреш кичерә. Ортологик сүзлекләрнең роле аеруча телнең тотрыксызлыгы, аның нормалары какшаган чорда үсә. Алар, әдәби орфографик нормаларны, сөйләмнең дөреслеген чагылдыра торган махсус сүзлекләр буларак, кулланучыларның төрле төркемнәрен күздә тотып төзелә.

Ортологик сүзлекләргә орфографик, орфоэпик һәм кыенлыклар сүзлекләре керә. Кулланучыларда белешмә-сүзлекләргә һәрдаим сорау булды. Әлеге ихтыяҗга җавап буларак, татар лексикографиясендә төрле типтагы ортологик сүзлекләр басылып чыкты.

**Орфографик сүзлекләр**

Сүзләрне дөрес язуда кабул ителгән кагыйдәләр (имла) орфография дип атала. Сүзләрнең дөрес язылышын, аерым очракларда әйтелеш үзенчәлекләрен дә чагылдыру өчен. орфографик сүзлекләр төзиләр. Бу сүзлекләр җәмгыять тарафыннан киң кулланыла торган лексикографик басмалар санына керә. Алар телдәге, язылыштагы барлык үзгәрешләрне чагылдырырга тиешле сүзлек булганга, «сүзлекләрнең дә сүзлеге» булып санала. Сүзләрнең язылыш кагыйдәләренә нигезләнеп, анда алфавит тәртибендә сүзләр исемлеге бирелә. Гадәттә, мондый белешмәлекләрдә сүзнең вариантлары күрсәтелми. Орфографик сүзлек ул – норматив сүзлек. Бу – аның иң әһәмиятле һәм мөһим сыйфаты. Лөгатьлекләре норматив аңлатмалы сүзлекләргә таянып төзелергә тиеш.

Рус лингвографиясендә орфографик сүзлекләр ике төргә бүленә: гомуми һәм адреслы орфографик сүзлекләр. Адреслы сүзлекләр, үз чиратында өч типка аерыла: 1) мәктәпләр, 2) матбугат эшчеләре өчен, 3) тармак орфографик сүзлекләре [Введенская: 2007, 80–81]. Орфографик сүзлекләр төзү татар лексикографиясен-

дә дә яңа өлкә түгел. Бүгенге көндә ике төр орфографик белешмә-сүзлекләр билгеле: 1) мәктәпләр өчен, 2) гомуми орфографик сүзлекләр. Аларның гомуми саны 21: беренче төр сүзлекләр 4 булса, икенче төргә караганнары – 17.

Татар орфографиясе мәсьәләләре күп еллар көн тәртибендә булса да, орфографик сүзлекләр төзү эше XX гасырның башында гына башлана. Шулардан М. Иманаев тарафыннан төзелеп 1901 елда нәшер ителгән «Русско-татарский (орфографический) словарь к II части учеб. кн. «Русское слово», составленный для русско-татарских, башкирских школ и русских классов при мектебах и медресах» дип аталган кулланма татар теленең беренче орфографик белешмәлеге булып санала [1901-РТ_орфогр_уку]. Шулай ук 1914 елда Казанда «Кыскача татар нәхүе илә орфографический словарь (Татарча авыр сүзләр өчен орфографик сүзлек)» басылып чыга [Т_орфогр].

Язулар алышынуга бәйләнешле рәвештә орфографиягә үзгәрешләр керә бара һәм алар сүзлекләрдә чагыла килә. 1927 елда күренекле тел галиме Г.Х. Алпаров гарәп графикасында төзегән, күләме белән элекке басылып чыккан кулланмалардан күпкә зур булган «Татар теленең имла сүзлеге» 8 000 данә тираж белән дөнья күрә. Шул ук елны сүзлек өч тапкыр һәм 1928 елда тагын бер кат басыла.

1927 елның 3 июлендә Татарстан Республикасы Халык комиссарлары Советы үзенең махсус карары белән латин алфавитын татар теленең рәсми алфавиты дип игълан итә. Кыска вакыт эчендә яңа графикада орфографик сүзлекләр төзү ихтыяҗы туа. 1928 елда И. Рәми «Имла сүзлеге» [1928-Т_орфогр] һәм И. Рәми, И. Кули «Татар теленең орфография сүзлеге» [1930-Т_орфогр] басылып чыга. Тиражы 10 000 данә була. Ә 1933 елда Ш. Абайның «Орфографик сүзлекчә: «о», «е» хәрефләре булган интернациональ һәм халыкара сүзләр» белешмәлеге нәшер ителә [1933-Т_орфогр_алынм]. И. Рәмиев төзегән «Татар әдәби телендәге интернациональ сүзләрнең орфография сүзлеге» дә орфографик белешмә-сүзлекләр арасында үз урынын алып тора [1934-Т_орфогр_алынм]. И. Рәми авторлыгындагы [1928-Т_орфогр], [1934-Т_орфогр_алынм] һәм шулай ук Ш. Абай сүзлегенең дә [1933-Т_орфогр_алынм] тиражы 5 000 данә була.

1939 елның 5 маенда чыккан Татарстан АССР Верховный Советы президиумының «Татар язуын латин алфавитыннан рус графикасы нигезендәге алфавитка күчерү турында»гы указы нигезендә татар язуы кириллицага күчерелә. М. Гыймадиев, Х. Хисмәтуллин, К. Хәмзин, Х. Шамкин, Р. Хәкимовадан торган авторлар коллективы шактый күләмле һәм зур тираж (30 000 данә) белән «Татар әдәби теленең орфография сүзлеге» төзеп бастыралар [1941-Т_орфогр].

1948 елда дөнья күргән кечкенә форматлы «Татар әдәби теленең орфография сүзлеге» (төзүчеләре Х. Хисмәтуллин һәм М. Гыймадиев), шул елларда татар телендә чыга торган матбугат һәм әдәбият практикасына кергән сүзләрнең дөрес язылышын күрсәтү өчен, белешмә ролен уйный [1948-Т_орфогр]. 1939 елда нәшер ителгән сүзлектән аермалы буларак, әлеге кулланма 10 000 данә тираж белән генә басыла.

Сүзлектә тамыр, ясалма, парлы һәм кушма сүзләр белән бер-рәттән шәһәр, район, елга, тау исемнәре дә еш очрый:

каба
кабак – кабагы
кабан дуңгызы
...
кабартма
кабарту – кабартуы
...
Кабул (*ш.*)
...
Казан (*ш.*)
Казанка (*елга*)
...
Казбек (*т.*)
...
Кайбыч (*р.*)
...
кайта-кайта
...
калдык-постык
... *һ.б.*

Кулланмада «Татар әдәби теленең алфавиты һәм орфографиясе» турында бүлеккә дә урын бирелгән. Белешмәдә шул чорда татар әдәби телендә кулланыла торган сүзләрнең, шулай ук русча һәм интернациональ сүзләрнең дә, фонетик, морфологик һәм график үзлекләрен исәпкә алу нигезендә төзелә [1948-Т_орфогр: 10]. Шуннан соң чыккан орфографик сүзлек-белешмәләр барысы да, асылда, сүзләрнең шушы үзлекләренә нигезләнеп эшләнгән. «Сүз башы» өлешендә авторлар ни өчен теге яки бу сүзнең сүзлектә теркәлүен яисә теркәлмәвен болай дип аңлаталар: « ... бу белешмә татар әдәби телендә йөри торган барлык сүзләрне, бигрәк тә язылышлары ягыннан читенлек тудырмый торган сүзләрне, шулай ук аерым фәннәр буенча барлык терминнарны кертеп бетерүне максат итеп алмый» [1948-Т_орфогр: 3].

XX гасырның икенче яртысында – 1968 елда – татар лексикографиясендә А.Х. Нуриева авторлыгында «Татар теленең орфографик сүзлеге. Башлангыч мәктәп укучылары өчен» исемле сүзлекчә басылып чыкты [1968-Т_орфогр_мәк_Нур.]. Белешмә башлангыч мәктәпләрнең ана теле дәресләрендә һәм мөстәкыйль куллану өчен чыгарылган. Анда алфавит тәртибендә, татар теленең үз сүзләре белән бергә, рус теле аша алынган якынча 4 000 берәмлек теркәлгән. Тиражы – 47 000. Алдагы сүзлекләрдән аермалы буларак, кеше исемнәре һәм географик атамалар кулланма ахырында аерым исемлек булып урнаштырылган. Әлеге сүзлекнең дүрт басмасы бар. 1996 елда 40 000 данә тиражда нәшер ителгән соңгы басмада баш сүзләр саны 10 000 гә җиткән [1968-Т_орфогр_мәк_Нур.].

1983 елда чыккан «Татар теленең орфографик сүзлеге» академик орфографик сүзлекләрдән санала [1983-Т_орфогр]. А.Х. Нуриева, Ф.С. Фасеев, М.И. Мәхмүтовтан торган авторлар коллективы төзегән һәм 18 500 данә тиражда басылып чыккан бу белешмәлектә 38 000 гә якын сүз урын алган. Бирелә шул чордагы татар әдәби теленең лексик хәзинәсендә кулланыла торган сүзләр һәм сүз формаларының дөрес язылышы ачыкланган һәм гамәлдәге алфавит һәм орфография кагыйдәләренә нигезләнеп бирелгән. Сүзләрнең язылышын нормалаштыру татар әдәби теленең шул вакыттагы үсеш дәрәҗәсеннән, шул вакыттагы гомуми һәм татар тел белемендәге төп фәнни принциплардан чыгып хәл ителгән. Сүзләр язылышы фонетик, морфологик, график, традицион һәм дифференциаль принципларга нигезләнгән. Сүзлекнең лөгатьле-

ге 1977–1981 елларда басылып чыккан «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ннән алынган. Шул ук вакытта авторларга әлеге басмага һәртөрле фән-техника, сәясәт, мәдәният һ.б. тармакларга кагылышлы атамаларны тулысынча алу бурычы куелмаган. Белешмәлектә көнчыгыш телләреннән кереп үзләшкән алынмаларның да киң таралганнары һәм XIX–XX гасыр классик әдәбиятында еш очраганнары гына бирелгән:

галибанә
…
галип
...
гарби (*иск.*)
гаргарә
... *һ.б.*

Сүзлектә татар теле лексикасының төп ясалыш типлары (тамыр, ясалма, кушма, парлы, кыскартылма сүз) тулы чагылган:

ортоүзәк
...
оста
остабикә
    остазларча
    ...
талаш-ызгыш
... *һ.б.*

Кайбер очракларда вариатив язылыш та тәкъдим ителгән:
казамат һәм каземат
...
казах, -лар һәм казакъ, -лар
... *һ.б.*

Шулай ук сүзләрнең грамматик төрләнеш формалары орфографик яктан кыен булган очракларда гына бирелүе сүзлекнең отышлы ягы булып тора:

абый, -га, -дан;
    -сы(на), абые
...
аять, -кә, -тән
    -те(нә)

...
аңлау, -вы
аңла, аңлыйм, аңлыйк, аңлый, аңлар, аңлаячак
... *һ.б.*

2002 елда Ф.Ә. Ганиев редакциясендә 50 000 тираж белән 140 079 сүз һәм сүз формаларын үз эченә алган «Татар теленең орфография сүзлеге» дөнья күрде [2002-Т_орфогр]. Төзүчеләре – Ф.Ә. Ганиев белән И.И. Сабитова. Әлеге хезмәт басылып чыккан орфографик сүзлекләр арасында иң зур тиражлы сүзлек булып санала. Кулланмага ул чордагы татар тел белеменең үсешенә бәйләнешле кайбер үзгәрешләр кертелгән. «Моңа кадәр орфографиягә булган ихтыяҗны 1983 елда басылып чыккан «Татар теленең орфографик сүзлеге» басмасы үтәп килде. Әмма әдәби телнең бүгенге көнге яшәеше яңа орфография сүзлеген таләп итә», – дип язалар авторлар сүзлекнең «Кереш» өлешендә [2002-Т_орфогр: 3].

Кулланманың яңалыгы – фигыльләрне инфинитивта бирү:
җайлылан|ырга
...
җайлыла|рга, - җайлылый, - җайлылаячак
җайлылат|ырга
... *һ.б.*

Бүгенге көнгә кадәрле татар язма телендә фигыльнең бу формаларын куллану практикасында һәм язылышында бик күп ялгышлыклар яшәп килә.

Барлык сүзлекләрдә диярлек у һәм ү гә тәмамланган исем белән фигыль (бу очракта исем фигыль) аерып бирелми. Әмма язылыштагы ялгышлыклардан качу өчен, инфинитив формаларны аерым бирү, ягъни у һәм ү гә тәмамланган исемнәрне фигыльләрдән аерып алып күрсәтү зарурлыгы көнүзәк мәсьәлә икәне шиксез:
буя|рга, - буйый, - буяячак
...
буя|у, -вы
...
чәчә|ргә, - чәчи, - чәчәячәк I (сулыш юлына берәр нәрсә эләгүдән йөткерергә)
чәч|әргә II (орлык сибәргә)
...

чәчү, -е

*... һ.б.*

Татар телендә инфинитив формаларының язылышы турында кагыйдәләрнең кулланма ахырында кушымта итеп бирелүе һичшиксез, бу хезмәтнең, әһәмиятен арттыра. Бүгенге көнгә кадәр күп кенә инфитивларның ике төрле язылуын күрергә мөмкин: *ябырга – ябарга, үбергә – үбәргә, язырга – язарга, тынырга – тынарга.* Нәтиҗәдә ике вариантлылык барлыкка килә. Абсолют күпчелек очракта кушымтада китерелгән кагыйдәләр инфинитив формаларын дөрес язарга ярдәм итәчәк.

Шулай ук гади фигыльдән ясалган тезмә фигыльләрнең киң кулланыштагылары сүзлектә урын алган. Мәсәлән,

гайгылда|рга, -гайгылдый, -гайгылдаячак

гайгылдап куярга

гайгылдаш|ырга

гайгылдашып торырга

*... һ.б.*

Кушма сүзләр язылышы турында мәгълүмат кулланма ахырында кушымта итеп бирелгән. Төс белдергән кушма сыйфатларның беренче компоненты, аергыч функциясендә килгәндә, нинди? соравына җавап бирә, шуңа да карамастан аергычтан соң сызыкча кую традиция булып киткән. Сүзлектә кушма сыйфатларның әлеге төренең орфографиясен татар теленең грамматик закончалыклары нигезендә язарга тәкъдим ителгән:

аксыл кызыл

...

карасу яшел

...

күксел соры

*... һ.б.*

Авторларның төс белдергән кушма сыйфатларны аерым язуы сүзлекнең тагын бер отышлы ягы булып тора.

2001 елның 1 сентябендә «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы закон үз көченә кергәч, бу Законны гамәлгә ашыру комитеты җитәкчелегендә оешкан комиссия тарафыннан «Татар теленең орфографиясе» әзерләнә. 2003 елда, шул орфографиягә нигезләнгән, якынча 45 000 лексик берәмлекне үз эченә алган «Tatar telenen orfografiə süzlege» (Татар теленең латинда

һәм кириллда орфография сүзлеге) басылып чыга [2003-Т_орфогр_Газ.]. Орфографик сүзлек-белешмәне төзүче – Ф.М. Газизова, фәнни редакторы – М.З. Зәкиев. Латин графикасына нигезләнгән бу сүзлекнең лексик составы әлегә кадәр гамәлдә булган орфография сүзлекләренә һәм өч томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нә таянып эшләнгән. Кулланманың төп үзенчәлеге – сүзләрнең язылышын латин графикасында һәм кириллицада бирү. Авторның максаты – «Сүзлектә латин хәрефләре белән дөрес язу өлгесе генә түгел, бәлки шул яңа өйрәнү этабын җиңеләйтү максаты белән, әлеге сүзләрнең кириллицага нигезләнгән гамәлдәге язылыш нормаларын да бирү» [2003-Т_орфогр_Газ.: 4]. Киң кулланышта булган сүзләр белән беррәттән, сүзлекнең лөгатьлегендә диалекталь сүзләр дә тәшкил итә. Беркадәр алынмалар да урын алган:

awaz аваз

awazdaş, -lık аваздаш, -лык

...

aybagar айбагар

...

cəber-cəfa җәбер-җәфа

... *һ.б.*

Латин графикасы гамәлгә кертелмәү, шулай ук тиражы да 100 данә генә булу сәбәпле, күпсанлы кулланучыларга тәгаенләнгән булуына карамастан, сүзлек-белешмә аларга барып ирешмәде.

2010 елда К.Р. Галиуллин, Р.И. Раскулова авторлыгында «Татар теленең орфографик сүзлеге» нәшер ителде [2010-Т_орфогр]. Анда якынча 43 000 сүз теркәлгән. Тиражы 25 000 данә. Алда басылып чыккан орфографик сүзлекләрдән аермалы буларак, биредә кушымта итеп «Татарстан Республикасындагы торак пунктлар исемлеге» бирелгән. Шулай ук татар һәм рус телләрендә «Морфологик-орфографик белешмәлек» тә урын алган. Белешмәлекнең татар һәм рус телендә булуы, һичшиксез, аның әһәмиятен арттыра, әмма андагы күпсанлы билге-тамгалар биредәге материалдан файдалануны, мәгълүматны кабул итүне катлауландыра.

2002 елда басылып чыккан орфографик сүзлектән аермалы буларак, инфинитив формалар шулай ук *у* һәм *ү* белән бирелгән:

уйландыр|у, -уы

...

уйлан|у, -уы

...

уйланыл|у, -уы

... *һ.б.*

Сыйфат + сыйфат тибында ясалган сыйфатлар тезмә сыйфатлар дип атала һәм алар аерым (сызыкча яки дефис аша түгел) языла. Бу күптән хәл ителгән мәсьәлә булуга карамастан, мондый типтагы сыйфатларны авторлар, ни өчендер, сызыкча аша бирүне дәвам иткәннәр:

аксыл-ал

аксыл-зәңгәр

...

аксыл-сары

... *һ.б.*

Тулыландырылган икенче басмасы 2017 елда «Татар теленең орфографик сүзлеге: Сүзлек. Морфологик-орфографик белешмәлек» исеме астында 5 000 данә тираж белән басылып чыкты [2017-Т_орфогр]. Автор-төзүчеләре – К.Р. Галиуллин, Р.И. Раскулова, фәнни мөхәррире – Г.Р. Галиуллина. Белешмәлектә якынча 46 000 сүз теркәлгән. «Кереш» өлештә «Сүзлек соңгы елларда кулланышка кергән лексик берәмлекләр исәбенә тулыландырылды» дип язылса да, лөгатьлелекнең рус, рус теле аша кергән Европа телләре алынмалары, үтә тар тармак терминнары хисабына тулыландырылганлыгы күренә.

2010 елда нәшер ителгән басмадан аермалы буларак, кушымта итеп «Татарстан Республикасындагы торак пунктлар исемлеге» бирелмәсә дә, «Морфологик-орфографик белешмәлек» урын алган.

Татар орфографиясендәге катлаулы мәсьәләләрнең хәл итеп бетелмәве орфографик сүзлекләрдә ачык күренә: бер үк сүзләрнең төрлечә язылышы, сүзләрнең вариантлылыгы, традиция дип элеккечә язу һ.б. Аеруча гарәп-фарсы алынмалары язылышындагы төгәлсезлекләрнең бер сүзлектән икенчесенә күчеп йөрүе күзгә ташлана. Хәзерге көндә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре һәм Казан федераль университетының Филология белән мәдәниятара багланышлар институтының тел белгечләре коллективы тарафыннан татар теленең академик орфографик сүзлеге эшләнә. Төзүчеләр татар орфографиясенең хәл ителмәгән күп кенә мәсьәләләрен, чишеп, әлеге академик белешмәлек кысаларында чагылдырырлар дип ышанып каласы килә.

**Орфоэпик сүзлекләр**

Дөрес әйтелеш кагыйдәләре, нормалары җыелмасын тел гыйлемендә орфоэпия өйрәнә. Орфоэпик нормалар (сөйләм нормалары) хәзерге әдәби телнең үзәген тәшкил итә. Сүзләрнең әдәби телдә дөрес әйтелеше күрсәтелгән сүзлек орфоэпик сүзлек дип атала. Аның төп максаты булып әйтелеше яки басым куелышы ягыннан кыенлык тудырган сүз турында мәгълүмат бирү тора. Бу төр сүзлекләр сүзне тасвирлау рәвеше белән башкалардан аерыла, аларда сүзләр фәкать орфоэпик аспектта гына ачыклана.

Рус телендә, шулай ук башка телләрдә дә орфоэпик сүзлекләр төзүнең күпьеллык традицияләре булса да, бүгенге көндә татар теленең орфоэпик типтагы өч сүзлеге генә бар.

Беренче орфоэпик сүзлек Х.Х. Сәлимов тарафыннан төзелеп, XX гасыр ахырында, ягъни 1995 елда нәшер ителгән [1995-Т_орфоэп_Сәл.]. Татар лексикографиясендәге әлеге яңа хезмәт телебездә киң кулланышта булган сүзләрне туплап биргән. Автор тәкъдим иткән әлеге сүзлекнең максаты – татар телендәге сүзләрнең дөрес әйтелеш нормаларын (авазларның әйтелеше һәм басым кую), шулай ук төрләнеш вакытында әйтелешнең үзгәргән вариантларын күрсәтү [1995-Т_орфоэп_Сәл. : 3]:

авылча [а$^{o}$wы́лча]
...
алмаз [а$^{o}$лма́с]
...
бавыр [ба$^{o}$wы́р]
...
баш-күз [ба́$^{o}$шкүс]
... *һ.б.*

Сүзләрнең дөрес әйтелеш нормалары фонетик транскрипциядә бирелгән. Төп һәм өстәмә басым вокабулада түгел, җәяләр эчендәге транскрипциядә күрсәтелгән. Баш сүз буларак, бөлешмәлеккә гади лексик берәмлекләр, шулай ук сирәк кенә сүзтезмәләр һәм фразеологик берәмлекләр дә алынган:

игә-чигә килү [игә́чигә килү́$^{w}$]
...
идарә [идәрә́] яки [идарә́]
...

Идел-йорт [иде́лйорт]

... *һ.б.*

Татар теленең үз сүзләре белән беррәттән, гарәп-фарсы алынмаларына да урын бирелгән. Рус, рус теле аша кергән Европа телләре алынмаларының татар телендә үзләшкәннәре дә, үзләшмәгәннәре дә сүзлектә бик аз. Шул алынмаларның әйтелеше, алардагы басымның урыны, күчүкүчмәве еш кына сорау тудырса да, автор аларны сүзлектә чагылдыруны бурыч итеп куймаган:

аванс [ава́нс]

...

газ [гас]

...

орган (музык.) [арга́н]

...

самовар [саᵒмаwа́р] яки [саᵒмаwы́р] ... *һ.б.*

Х.Х. Сәлимовның 2004 елда 3 000 данә тиражда басылып чыккан «Татар теленең орфографикорфоэпик сүзлеге» дә элеккеге сүзлек принциплары нигезендә төзелгән [2004-Т_орфогр_орфоэп_Сәл.]. Белешмәлекнең тулыландырылган лөгатьлеге, алдагы хезмәттән аермалы буларак, яңа алфавит тәртибендә бирелгән һәм сүзләрнең язылышы кириллицада һәм латиницада да тәкъдим ителгән:

абзый abzıy [аᵒбзый: -ла́р, ғá]

...

искечә ıskeçə [иске́чә]

...

ишарәләү işərələw [ишәрәлә́w]

...

лачма яки лычма laçma [ла́ᵒчма] яки [лы́чма]

... *һ.б.*

Сүзлек ахырында рус телендә 3 кушымта урын алган ( Приложение 1. Об орфографическо-орфоэпическом словаре татарского языка. Приложение 2. Звуки татарского языка. Приложение 3. Об ударении в татарском языке).

Якын киләчәктә Р.Т. Сәфәров редакциясендә «Татар теленең орфоэпик сүзлеге» дөнья күрде. Аны Р.Т. Сәфәров, А.Ә. Тимерханов, О.Н. Галимовадан торган авторлар коллективы төзеп басмага

әзерләгән. Яңа төзелгән орфоэпик сүзлектә Х.Х. Сәлимов белешмәлекләре төп ориентир буларак файдаланылган. Алардагы бүгенге татар теленә хас орфоэпик нормаларны чагылдыру ноктасыннан уңышлы дип табылган сыйфатлар әлеге кульязма сүзлектә мөмкин кадәр исәпкә алынган, яңа принциплар нигезендә үстерелгән. Кульязма кулланма алдагы белешмәлекләрдән үзенең күләме белән дә аерыла. Ул, хәзерге татар теленең 4 600 дән артык актив кулланышта йөргән сүзләрдән тыш, әйтелеше язылышына тәңгәл килмәгән, басымын куюда авырлык тудырган, грамматик формалары ясалганда басым гомуми кагыйдәгә күрә соңгы иҗеккә күчмәгән һ. б. лексик берәмлекләрне эченә алган. Төзүчеләр нинди сүзнең лөгатьлеккә керәсен нәкъ менә шушы критерийлардан чыгып сайлаганнар. Шулай ук басымның күчүен я күчмәвен күзәтү, төрләнгән вакытта әйтелештә үзенчәлекле үзгәрешләр барлыкка килү һ. б. мәсьәләләрне күз уңында тотып, сүзләрнең грамматик формалары тутырып язылган рәвешен тәкъдим иткәннәр. Татар теленең башка сүзлекләре кебек үк, бу орфоэпик сүзлек тә гамәлдәге орфографик кагыйдәләр нигезендә төзелгән, лөгатьлектәге сүзләр гамәлдәге алфавит тәртибендә урнаштырылган.

Татар теленең Х.Х. Сәлимов төзегән белешмәлекләрендә транскрипция эзлекле рәвештә һәр сүзгә бирелгән. Яңа басылып чыккан сүзлектә авторлар бу мәсьәләгә яңача килгәннәр: лөгатьлектәге сүзләрнең фонетик транскрипциясе фәкать әйтелеш белән язылышта аерма булган иҗек яки хәрефләр тезмәсендә генә күрсәтелгән:

**абза́р,**
абзары́ , абзарга́, абзарда́н
**абзы́й,**
абзые́ [йы́], абзыйга́, абзыйда́н
...
**авыраю́** [а$^{о}$уы̆райу́$^{у}$],
авыраюы́ [йууы̆́],
авыраюга́, авыраюда́н
**авы́р** [а$^{о}$уы̆ы̆́р],
авырра́к [а$^{о}$уы̆ры̆ра́ķ]
авырлыгы́, авырлыкка́
... *һ.б.*

Рус һәм башка кайбер телләрнең сүзлекләрендә шушы принцип саклана, чөнки грамматик формаларның да, баш сүзләрнең дә әйтелешен күрсәтеп бирү кулланучының белешмәлектән файдалануын, мәгълүматны кабул итүен катлауландыра.

Сүзлектә фонетик транскрипция өчен нигез итеп моңарчы чыккан орфоэпик сүзлекләрдәге билгеләр кулланылган, шулай ук «Советская тюркология» журналы редакциясе тарафыннан кабул ителгән латиница нигезендә халыкара фонетик транскрипциядәге кайбер билгеләр өлге буларак алынган. Яңа берничә билге исә авторларның фикер алышуы нәтиҗәсендә кабул ителгән. Авторлар фикеренчә, кайбер хезмәтләрдә [w] билгесе белән бирелгән өрелмәле иренирен авазы *тау* [та́ᵒw] һәм *дәү* [дә́w] кебек сүзләрдә катылыкйомшаклык нигезендә дифференциацияләнә, әмма транскрипциядә бу күренеш чагылмый. Шул сәбәпле сүзлектә яңа [ў] һәм [ү̆] билгеләре кулланылган:

**дә́ү** [дә́ү̆],
дәүрә́к [дәү̆ᵉ̆рә́к]
...
**та́у** [та́ў],
тавы́ [тауы̆́], таугá, таудáн
... *h. б.*

Бер иҗекле сүзләрдән тыш, басым һәр очракта күрсәтелгән:

**аз,**
азрáк [аᵒзы̆рáқ]
...
**ак,**
агы́ , аккá, актáн
...
**баягы́ча**
...
**бәйлә́м,**
бәйләмé, бәйләмгә́,
бәйләмнә́н, бәйләмнә́р
... *h. б.*

Бүгенге көндә басмага әзер булган «Татар теленең орфоэпик сүзлеге» сөйләмә тел белән бәйле булган белгечләр – филологлар, татар теле укытучылары, лекторлар, радио һәм телевидение дикторлары, актёрлар h. б. өчен, һичшиксез, бик кирәкле кулланма

булып торачак. Татар әдәби теленең нормаларын үзләштерергә теләгән башка укучыларга да ул ышанычлы норматив белешмәлек хезмәтен үтәр дип ышанасы килә. Бер үк вакытта бу сүзлек орфографик сүзлек буларак та кулланыла ала.

**Кыенлыклар сүзлекләре**

Бүгенге көндә иҗтимагый тормышта һәм җәмгыятьтә барган үзгәрешләр телдә чагылмый калмый, әлбәттә. Алар телнең гомуми үсешендә чагыла, көндәлек аралашу телендә, сөйләмдә тискәре процесслар һәм күренешләр барлыкка китерә һәм әдәби тел нормаларына төрле яклап басым ясый. Телче галимнәр әлеге процессларны анализларга һәм чишү юлларын күрсәтергә тиеш, чөнки телнең сафлыгы һәм дөреслеге, югары сөйләм культурасына ирешү турында кайгырту аларның төп бурычы булып санала.

Бу мәсьәләне хәл итүдә махсус сүзлекләрнең әһәмияте зур. Бүгенге көндә рус лингвографиясендә кыен очракларны төрле яктан чагылдырган махсус сүзлекләр шактый: баш хәрефтән яки юл хәрефеннән, кушып яки аерым язу, төрләндерү яки төрләндермәү һ.б. кыен очракларны чагылдырган сүзлекләр.

Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге хезмәткәрләре И.И. Сабитова, Э.И. Сафина, Ф.И. Таһирова төзегән «Татар теленең кыенлыклар сүзлеге» – татар тел белемендә бу өлкәдә беренче тәҗрибә. Чөнки моңа кадәр татар лексикографиясендә аерым сүзлек рәвешендә төзелгән мондый белешмәлек бөтенләй юк иде. Бүгенге көндә сүзлекнең кульъязмасы басмага әзер. Анда 1 400 сүз теркәлгән. «Хәзерге татар телендә күзәтелгән кыенлыклар, әлбәттә, сүзлектә чагылдырылган очраклар белән генә чикләнми, биредә аларның берничә төркеме генә теркәлде һәм аңлатылды», – дип яза кулланманың «Кереш» өлешендә хезмәтнең фәнни редакторы Ф.И. Таһирова. Белешмәлек һәм гамәли кулланма буларак төзелгән бу сүзлек мәктәп укучылары, татар филологиясен өйрәнүче студентлар, татар теле укытучыларына, тел галимнәре, журналистлар һәм язучылар, татар телен өйрәнүче һәм татарча сөйләшүче киң катлам укучыларга тәкъдим ителәчәк. Сүзлек нигезе итеп матур әдәбият, газета-журнал, Интернет челтәре кебек төрле чыганаклардан тупланган ялгыш очраклар алынган, мисаллар системалаштырылган, кыенлык тудырган очракларның асылы, төрләре, сәбәпләре, дөрес вариантлары ки-

терелгән. Һәр очракта хата вариантлар индивидуаль якын килеп анализланган.

Кулъязма сүзлектә мәкаләләр алфавит тәртибендә урнаштырылган, кыенлык тудырган очракларның иң еш кабатланганнары бирелгән. Ялгыш дип табылган очраклар махсус билге-тамга белән күрсәтелгән: ялг. Сүзлек берәмлеге – вокабула (баш сүз) итеп төрле сүз төркеменә караган аерым лексемалар гына алынган:

**АБСТРА́КЦИЯЛӘҮ** *ф. ялг. ...*
**АГИТ-БРИГА́ДА** *и. ялг. ...*
**ДӨ́М-КАРАҢГЫ** *с. ялг. ...*
**ЗАМАНАВИ́ 1.** *с. ялг. ...*
**2.** *рәв. мәгъ. ялг. ...*
**ҺӘ́Р-ДАИМ** *а. ялг. ...*

Ялгыш очракның нидән гыйбарәт булуын аңлауны җиңеләйтү өчен, мисалга аны чагылдырган җөмләләр китерелгән, аларның алынган чыганагы күрсәтелгән:

**ДӘҮЛӘТ-ХОКУКЫ́Й** *с. ялг. Шуңа бәйле рәвештә без ТР Президентының **Дәүләт-хокукый** департаменты белән хезмәттәшлек итәчәкбез.* Ватаным Татарстан. *Безнең парламент эшчәнлеге республикадагы дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен гамәлгә ашыруга, аның **дәүләт-хокукый**, социаль-икътисади һәм рухи-мәдәни үсешен законнар белән тәэмин итүгә юнәлтелгән.* Кызыл таң; ***дөр.:*** **дәүләт-хокук ...-ы/-е, дәүләт һәм хокук ...-ы/-е;** *к.* **либераль-икътисад.**

Белешмәлекнең отышлы ягы – кыенлык тудырган очраклар гомумиләштерелеп, аның барлыкка килү сәбәпләрен һәм башка үзенчәлекләрен чагылдырган кыска һәм конкрет аңлатмалар булуы. Алар иң киң кулланылган бер сүз вокабуласында гына бирелеп һәм шул ук типка караган башка очраклар к. (карагыз) тамгасы белән шуңа җибәрелгән. Мәсәлән:

**ӘЛЛӘ́-КАЙДА** *а. ялг. Җен-пәриләр дә әллә-кайда түгелдер, шушы алабута астында гына утырадыр. Ф. Йосыпов; дөр.:* **әллә кайда.**

***Әллә*** кисәкчәсе, башка сүз төркемнәре белән килеп, аларга билгесезлек төсмере өсти, һәрвакыт аерым языла, чөнки үзе генә дә мөстәкыйль сүз буларак кулланыла. Мәсәлән: ***кайтасыз әллә?*** Шул ук закончалыкка теләсә кем, ***теләсә кайсы, ничек тә, шул хәтле*** кебек конструкцияләр дә буйсына.

**ӘЛЛӘ́-НИШЛӘП** *а. ялг. Алар белән пәрә-пәрә ызгышучы әбиләрне күреп, йөрәгем әллә-нишләп китте.* Безнең гәҗит; *дөр.:* **әллә нишләп;** *к.* **әллә-кайда.**

**ГИБРИ́Д** *и.* Гибридка, гибриды, гибридына, гибридлар; *ялг.:* **гибритка, гибриты, гибритына, гибритлар.** *Өйдә үстерү өчен иртә өлгерә торган, үзлегеннән серкәләнүче сорт һәм* ***гибритлар*** *кулай.* Акчарлак

Рус һәм рус теле аркылы кергән алынмаларның сүз азагындагы **[д]** авазы, сөйләмдә саңгыраулашу кичерсә дә, язылышын үзгәртми, парадигмасының барлык формаларында ***-д*** аркылы языла. Ялгыш язылу очраклары кайбер гарәп алынмаларындагы саңгыраулашу күренеше белән ялган аналогия нигезендә барлыкка килә. Әйтелештәге саңгыраулашуны чагылдыру өчен, кушымчаларның саңгырау варианты ялгана. Шул ук закончалык ***-г*** (гонг, гонгы, гонгына), ***-б*** (клуб, клубы, клубка) хәрефләренең язылышына да кагыла.

**ГИД** *и.* Гидка, гиды, гидына, гидлар; *ялг.:* **гитка, гиты, гитына, гитлар;** *к.* **гибрид.**

Материалны теркәү рәвеше ялгышларның төреннән чыгып хәл ителгәнгә күрә, сүзлек мәкаләләренең структурасы бертөрле түгел икәнлеге күренә.

Кайбер алынмаларның, аеруча гарәп-фарсы алынмаларының язылышы кыенлык тудырган очраклары да теркәлгән:

**ПАКЪ** *с. ялг. Йөзе акның күңеле дә* ***пакъ,*** *диләр.* Кызыл таң. *Аның кешелек кыйбласы һәрвакыт бер максатка – милләтнең яшь буынын аек акыллы, физик сәламәт, рухи камил, әхлакый* ***пакъ*** *һәм эшчән итеп тәрбияләүгә юнәлгән.* Яңарыш; *дөр.:* **пакь.**

**СӘДАКА́** и. ялг. Сәдакага, сәдакасы, сәдакасына. *Ә хәзергә менә хәер –* ***сәдака*** *булыр...* А. Гадел. *Бер елмаю да* ***сәдака*** *диләр.* Идел таңнары; *дөр.:* **садакага, садакасы, садакасына.**

Хәзерге татар телендә күзәтелгән кыенлыклар бу кульязма сүзлектә чагылдырылган очраклар белән генә чикләнми. Биредә аларның берничә төркеме генә теркәлгән һәм аңлатылган. Мондый эш системалы нигездә һәм даими алып барылырга, дәвам ителергә тиеш. Телнең тотрыклылыгын тәэмин иткән ныклы нигез – әдәби тел нормаларының үтәлеше ул. Шуңа күрә игътибарны тел нормаларын бозуга юнәлткән бу сүзлек зур кыйммәткә ия булачак. Һәр кеше үз теленең саф, сөйләменең дөрес булуын тели. «Татар те-

ленең кыенлыклар сүзлеге» кебек кулланмалар исә бу юнәлештә һәрберебез өчен ярдәмлек булып хезмәт итә алачак.

Бүгенге көндә татар лексикографиясенең ортологик сүзлекләр төзү өлкәсендә шактый күп эшләр башкарылган булса да, мондый типтагы сүзлекләрне төзү үзенең актуальлеген югалтмый. Якын киләчәктә тел белгечләре хата-кимчелекләрдән азат орфографик белешмә-сүзлекләр, баш хәрефтән яки юл хәрефеннән, кушып яки аерым язу һ.б. кыен очракларны чагылдырган сүзлекләр төзеп, киң кулланучыларга тәкъдим итәр дип ышанып каласы килә.

## § 14. Диалектологик сүзлекләр

Диалектологик сүзлекләр телебезнең билгеле бер чорга хас җанлы телен чагылдыра, шул чорның тормыш-көнкүреше турында бай мәгълүмат бирә. Диалекталь лексика күренешләр төрлелеге, территориаль вариантлар һәм синонимнар белән бай, анда архаик үзенчәлекләр сакланырга мөмкин. Шул сәбәпле диалектологик сүзлекләр тел белемендә дә, татар телен, татар мәдәниятен тарихи яктан тикшерү өчен дә әһәмиятле чыганак булып тора.

Диалектологик сүзлек ул – билгеле бер диалект яисә бер тел диалектларының лексик составын үз эченә алган аңлатмалы сүзлек.

Лексиканың кайсы төрен туплауга карап, диалектологик сүзлекләр дифферинциаль һәм тулы сүзлекләргә аерылалар. Дифферинциаль сүзлекләр үз эченә үзенчәлекле диалекталь сүзләр һәм семантик диалектизмнарны (әдәби телдәге сүзләрдән мәгънәсе белән аерылып торган лексемаларны) алалар. Тулы диалекталь сүзлекләргә сөйләшләрнең, диалектларның барлык лексикасы, шулай ук әдәби тел һәм диалектлар өчен уртак булган сүзләр теркәлә [Варбот, 1998: 12]. Нигездә, татар теленең диалектологик сүзлекләренең барысы да тулы диалектологик сүзлекләргә карый, чөнки барысында да диярлек диалектларда очрый торган берәмлекләрдән тыш, әдәби тел сүзләре дә урын ала.

Вакыт яссылыгында сүзлекләр синхрон (сөйләшләр лексикасының хәзерге вакыттагы торышын тасвирлый торган) һәм диахрон (диалекталь лексиканы тарихи үсештә тасвирлый торган) төрләргә бүленә. Татар телендәге диалектологик сүзлекләрнең бер өлеше [1948; 1953; 1958, 1969, 1993] синхрон дип карасак, соңгы

чыккан «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге» [2009-Т_диал.] диалекталь лексиканы берникадәр тарихи үсештә тасвирлый, алда нәшер ителгән сүзлекләрдәге материаллар белән беррәттән, даими уздырыла торган экспедицияләр барышында җыелган материаллар да чагыла.

Татар теленең диалекталь лексикасы XVIII гасырдан ук И. Гиганов (Слова коренные, нужнейшие к сведению для обучения татарскому языку, собранные в Тобольской главной школе учителем татарского языка, Софийского собора священником Иосифом Гигановым и Юртовскими муллами свидетельствованные. СПб., 1801. 75 с; көнчыгыш диалекты), Дамаскин (Словарь языков разных народов, в Нижегородской епархии обитающих… – М.,1785; сергач сөйләше), С.Х. Хәлфин (Татарский словарь и краткая татарская грамматика в пользу обучающегося юношества татарскому языку. – 1785; казан татарлары сөйләше), Н.П. Остроумов (Первый опыт словаря народно-татарского языка по выговору крещеных татар Казанской губернии. – Казань, Тип. Казан. ун-та, 1878.) һәм А.А. Воскресенский (Русско-татарский словарь. – Казань. – 1894; казан арты керәшеннәр сөйләше) һ.б. галимнәрнең сүзлекләрендә чагылыш таба. Димәк, татар халык сөйләшләрен сүзлекләрдә теркәү чагыштырмача күптән түгел генә барлыкка килә.

XX гасырның 50 нче елларына кадәр татар диалектологиясе тармагы, нигездә, бер юнәлештә бара: урыннарга экспедицияләр оештырып, сөйләшләрне индивидуаль-монографик ысул белән тасвирлау. 50 нче еллар азагында экспедицияләр дәвамында туплана килгән диалекталь сүзләрне эшкәртү, сүзлекләр төзеп, аларны фәнни әйләнешкә кертү өчен, зур эшләр башкарыла, диалектологик сүзлекләр дөнья күрә [1948; 1953; 1958]. Шулай итеп, диалектология фәненең әһәмиятле юнәлеше – диалекталь лексикография үсеш ала башлый.

Нәтиҗәдә, 3 чыгарылыштан торган татар теленең диалектологик сүзлеге басылып чыга. В.Н. Хангилдин редакциясендә басылган әлеге сүзлеккә материал туплауда Х. Гатина, А. Камский, Х. Шабанов, С. Әмиров, Л.Җ. Җәләй катнашалар; фәнни эшкәртүчеләр – Л.Җ. Җәләй, В.Н. Хангилдин [1948-Т_диал_I]. Күләм ≈ 4000 берәмлек. Бу сүзлекне авторлар «беренче тәҗрибә» дип атый [1948-Т_диал_I: 4]. Чөнки моңа кадәр татар теле буенча аерым китап рәвешендә чыгарылган мондый белешмә бөтенләй булмый.

Әлеге сүзлектә татар теленең аерым диалектына яки сөйләшенә караган фактлар гына бирелми, барлык диалектларны теге яки бу күләмдә күзәтү уңаенда җыелган сүзләр урнаштырыла. Ләкин биредә тәкъдим ителгән сүзләрнең таралышы һәм вариативлыгы тулысынча бирелми, чөнки диалекталь күренешләр ул вакытта әле деталь, җентекле өйрәнелми. Авторлар моны үзләре дә ассызыклый. Мәсәлән, «**аймак** – 1. (Себ.) – кабилә, нәсел, ыру.

– Алар барлык **аймагыман** (бала-чага, нәсел-ыруы белән) килгәннәр;

2. (Минз., Акт.) – төбәк, билгеле чиктәге урын, участок.

– Ул авыл шушы **аймакта**. Колхозчылар шушы **аймакта** эшлиләр.

Әгәрҗәдә шул ук төшенчәдә йөри торган сүзне аумак диләр» [1948-Т_диал_I: 12].

Бу сүзлектә әле фәнни транскрипция кулланылмый. Сүзләрнең диалекталь әйтелеше язуда якынча гына чагыла. Минзәлә сөйләшендәге теш ара спиранты авазы гына язуда аерым билге – «d» белән күрсәтелә. Мәсәлән, «**диңгеd** (Мөс., Акт., Минз.) – 1) нигез, өй нигезе.

– Бу өйнең **диңгеdе** җимерелә башлаган. (Мөс.);

2) (Мөс.) – кыш көне җылы булсын өчен, җирдән ярты метр чамасы биеклектә стенага өелгән тирес, кибәк;

3) (Акт.) – төп йорт.

– Торган **диңгеdеbеd** шушы инде (яши торган төп йортыбыз шушы инде)» [1948-Т_диал_I: 48].

Л. Җәләй редакциясендә чыккан икенче чыгарылыш [1953-Т_диал_II] диалектологик сүзлеккә материал җыйнауда Ш. Байчура, Н.Б. Борһанова, Р. Галимҗанова, С. Рәфыйков, Р. Шамгунов, Г.К. Якупова катнаша. Тупланган материаллар нигезендә сүзлекне Н.Б. Борһанова, Г.К. Якупова төзи. Күләм ≈ 4110 берәмлек. Әлеге сүзлеккә теркәлгән материалларның күпчелеге урта диалектның Татарстан Республикасы территориясендә таралган сөйләшләргә карый. Башка татар диалектларына һәм сөйләшләренә караган сүзләр саны бик аз. Мәсәлән, «**сырга гөл** (Пенз., Шад.) – тамчылы гөл» [1953-Т_диал_II: 169].

Сүзнең мәгънәләрен ачыклау өчен төрле сөйләшләрдәге язып алынган мисаллар яки әдәби әсәрләрдәге мисаллар китерелә. Мәсәлән, «**тымык** (Пенз., Тамб.) – җилсез, тын һава. «Әй-

терлек җил дә юк, һава тымык, тик кисәк кенә өй түбәләрендәге усак яфраклары бер-берсенә бәредлешеп шыпырдашып китәләр» (Шәриф Камал). [1953-Т_диал_II: 192].

Бирелгән сүзләрнең адреслары җәя эчендә кыскартма билге белән күрсәтелә. Авторлар барлык сүзләрнең адресларын үзләре язып алган урын белән билгели. Шул ук лексема башка территорияләрдә, башка сөйләшләрдә таралуы әлеге сүзлектә чагылыш тапмый. Мәсәлән, «**Колак** (*Әг.*) – саңгырау. И колак, бер дә ишетмисең икән син, кеше сөйләгәнне» [1953-Т_диал_II: 108]. Соңрак чыккан сүзлекләрдә сүзнең вариативлыгы һәм таралыш территориясе киңәя: «**қолағы йуқ** *тбл.* чукрак (глухой). Инәм қаты эшмәгәр ите, утала ите, қәйнәм саңқыр, қолағы йуқ ите» [2009-Т_диал.: 409].

«**Күпертмә** 1) (Пенз., Буа, Буд., Тәт.) табаикмәк, кабартма. Әни, күпәртмә пешер әле, ашагым кели; 2) (К.т., Тәм., Ап.) төче камырдан, табада пешерелгән зур коймак. Майга гына салган бодай күпертмәсе әммә тәмле була да соң» [1953-Т_диал_II: 131].

«**Әбәләк** (Сверд., Мол., Тип.) – иркә, авырлыкка чыдамый торган кеше. Синең малаең бигрәк **әбәләк** инде, гел киреләнеп кенә тора» [1953-Т_диал_II: 247].

Икенче чыгарылышның кереш өлешендә Л. Җәләй татар теленең диалектларга, сөйләшләр һәм урынчылыкларга бүленеше һәм аларның бүлү принциплары, лингвистик география турында кыскача мәгълүмат бирә. Л. Җәләй татар теленең диалекталь система мәгънәсендә «гомумтатар теле» сүзтезмәсен куллана, һәм аның өч диалекттан торганын ассызыклый [1953-Т_диал_II: 6]. Диалектларны аеруда өч традицион принципны (географик, тарихи, лингвистик) аңлатып китә һәм тикшеренүләрне, нигездә, лингвистик принципка нигезләнеп алып баруга өстенлек бирү турында яза. Тел үсешендәге эчке закончалыкларны тирәнтен аңларга ярдәм иткән һәм диалектологиянең мәктәпләрдә тел укыту практикасына да, шулай ук тел фәнен баету эшенә дә бәйләнешле булуын ачыклаган күзәтүләр китерә (диалектларда сакланган сүзләр әдәби нормага әверелү һ.б.).

Л.Җ. Җәләй редакциясендәге өченче чыгарылыш [1958-Т_диал_III], нигездә, Н.Б. Борһанова, Л.Т. Мәхмүтова җитәкчелегендә оештырылган экспедицияләр вакытында һәм аерым сөйләшләрне монографик өйрәнүләре процессында тупланган ма-

териалларны үз эченә ала. Күләме ≈ 3392 берәмлек. Сүзлектә XX гасырның 1950 елларында урта һәм көнбатыш диалектлар составындагы сөйләшләрне өйрәнү нәтиҗәсендә җыелган материаллар бирелә. Әлеге сүзлек моңа кадәр билгеле булмаган яңа сүзләрне җыеп бирү ягыннан гына түгел, төзү принциплары белән дә аерыла. Авторлар аны киләчәктә төзеләсе тулы диалектологик сүзлеккә әһәмиятле бер адым, хәтта бу юлда башлангыч тәҗрибә дип саный. Сүзләрнең таралышы алдагы сүзлекләрдәге административ бүленештән чыгып түгел, сөйләш һәм урынчылыкларга нигезләнеп билгеләнә. Кайсы сөйләш таралуы әле ачык билгеле булмаган төбәкләрдән язып алынган сүзләр административ бүленеш белән бирелә.

Мәсәлән, «**Торпа** *Каз. ар. с.*-Малм. (Казан арты сөйләшенең Малмыж урынчылыгы) – дорфа, тупас; *ана кешегә алай торпа булырга җарамас*» [1958-Т_диал_III:157].

Сөйләшләрдән теркәлгән сүзләргә әдәби телдә аңлатма бирү белән беррәттән, сүзнең мәгънәсе күз алдына ачыграк килсен өчен, мөмкин булган урыннарда мисаллар да китерелә.

«**Челлә** – 1. *бөре с., глаз. с., минз. с., т. я. с.* җәйнең иң эссе вакыты; *җәйге челледә камзул, ике шал, алъяпкыч бәйләп салалар иде киленнәр* (глаз. с.); 2. *темн. с.* яхшы, әйбәт; самый челлә төшендә торабыз каланың» [1958-Т_диал_III:181].

Алынма сүзләрнең татар теленә кайсы телләрдән кергәнлеге күрсәтелә. Бу бигрәк тә фонетик үзгәрешләр кичергән сүзләргә карый. Мәсәлән, «**Шытырма** (рус. шторм) *хвал.с.* – өермә, җилдавыл; *Шытырма күтәрелде*» [1958-Т_диал_III: 195].

Сүзлектә беренче һәм икенче чыгарылыш диалектологик сүзлекләрдә билгеле булган сүзләр дә очрарга мөмкин. Ләкин алар, башка төбәкләрдән язылып алынган булу сәбәпле, әлеге сүзлеккә дә кертелә. Бу сүзнең таралышы киңрәк икәнлеген һәм аның икенче сөйләшләр өчен хас булуын күрсәтә. Мәсәлән, **ара** сүзе икенче чыгарылышта *Тәк., Тел., Акташ., Зәй* билгеләре белән бирелгән булса [1953-Т_диал_II: 37], өченче чыгарылышта шул ук сүз *Темн.с.* билгесе белән бирелә [1958-Т_диал_III: 19]. Бу сүзнең таралышы киңрәк икәнлеген һәм аның икенче сөйләшләр өчен дә хас булуын күрсәтә.

Шулай ук бу сүзлек халык телендә кулланыла торган үсемлек һәм бүлмә гөлләре исемнәрен җыйнап, аларны өстәмә бүлек итеп

теркәве белән дә үзенчәлекле. Сүзлектә 200 дән артык үсемлекнең халык арасында билгеле булган атамалары теркәлә. Бу бүлектә сүзлек бөтенләй икенче принциптан чыгып төзелә. Башта үсемлекнең русча фәнни атамасы, җәя эчләрендә латинчасы алынып, шуннан соң гына төрле сөйләшләрдә төрлечә әйтелә торган татарча атамалар бирелә.

Мәсәлән, «**Борщевик** (Heracleum sibiricum L.) – 1. балтырган *а/х. терм. сүзл., Ләмб. с., Бөре с. – Тәт., Т.Я.с.*; 2. җебеш′и *Кас.с.*» [1958-Т_диал_III: 235].

«**Лакрица** 1. татлы тамыр *К.Насыйри*; 2. төче тамыр *а/х. терм. сүзл.*» [1958-Т_диал_III: 242].

Татар диалектологлары XX гасырның икенче яртысыннан барлык татар сөйләшләрен лингвистик география ысулы белән фронталь аспектта өйрәнүгә йөз тота. Шул исәптән «Урта Идел һәм Урал буе татар халык сөйләшләре атласы»на материаллар җыю буенча эшләр башлана. Моның өчен махсус «Программа» төзелә һәм шуның буенча материаллар җыела. Нәтиҗәдә, бик бай фактик материал туплана, җыелган материалны анализлау һәм фәнгә кертү бурычы куела. 1969 елда «Татар теленең диалектологик сүзлеге» дөнья күрә. Сүзлекне төзүчеләр: Л.Т. Мәхмүтова, Н.Б. Борһанова, Г.К. Якупова, З.Р. Садыйкова белән беррәттән Л.Ш. Арсланов, Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Ахметова, Р.Р. Мингулова, Ф.Ю. Юсупов та үз өлешләрен кертәләр [1969-Т_диал].

Әлеге хезмәт тюркологлар арасында югары бәяләнә. Диалектологларның фәнни җитәкчесе, күренекле тюрколог Л.Т. Мәхмүтова тарафыннан сүзлекне төзү өчен оригиналь принциплар аерым ассызыклана. Әлеге принципларда диалекталь сүзнең төгәл билгеләмәсе чагыла, аны әдәби телдәге фонетик вариантлардан аеру критерияләре һәм реестр рәвешендәге сүзләрне сайлау үзенчәлекләре ачыклана. Сүзлекнең тагын бер отышлы ягы аның икетелле булуында, шулай ук мәкаләләр иллюстратив материаллардан, шул исәптән татар халык авыз иҗаты үрнәкләреннән тора.

Сүзлектә сүзләр алфавит тәртибендә бирелә. Мөмкин булган очракларда алынма сүзләрнең чыганагы баш сүздән соң, сүзнең таралышын күрсәтә торган билгеләмәләргә кадәр, квадрат җәяләр эчендә бирелә: [рус.], [морд.], [гар.] һ.б. Сүз тезмәсенең составына кергән сүзләрнең берсе хәзерге көндә аңлашылмый торган булса,

мондый сүз баш сүз итеп кертелә һәм, бу сүздән соң ике нокта куелып, сүз тезмәсе бирелә. Мәсәлән,

«**АЙМАН** *[гар.]:* айман белән *каз.ар.-крш., т.я.-к.т.* иминлек белән, исәнлек белән (с благополучием). Ай күрдем айман белән, Аузым тулы иман белән, Айғa – айлық, мәңа – саулық (яңа туган айны күргәч, картлар әйтә торган сүз) – *каз.ар.-крш.*

**Айман көйөннән** *зәй.-крш.* акрынлыктан, сүлпәнлектән (от медлительности, вялости, нерасторопности). Айман көйөннән тәм тапкан кешедән нидий өмет бусын дий.

**Айман көйөнә** *зәй.-крш.* үз көенә, үз җаена, акрын, сүлпән темпка (на свой лад, на медлительный лад). Бу қәтле айман көйөнә салырсың икән эшне» [1969-Т_диал.: 27].

Сүзнең ике-өч фонетик варианты өтер аша бер мәкалә эчендә бирелсә, аның чыганагы соңгы вариантыннан соң урнаштырыла. Омонимнар аерым мәкаләләрдә рим цифрлары белән билгеләп күрсәтелә. Лексемалар авазларның әйтелеше белән генә аерылса, мондый сүзләр бер мәкалә эчендә бирелә. Мондый сүзләр мәгънәләре белән бер-берсеннән аерылып торса, аерым мәкалә итеп китерелә. Мәсәлән, «**БАҠЧА** каз.ар., т.я. бәрәңге бакчасы (картофельный огород). Баķчам бик әйбәт минем, үзән – каз.ар.-мам.

**баķча алу** *каз.ар.-мам.* бәрәңге алу (рыть картофель). Баķча алыр wахыт та җитте.

**баķча күмү** *каз.ар.-мам.* бәрәңге утырту (сажать картофель). Баķча күмгән wахытта ķайтты.

**баķча сорат** *гәй.* каракчы (пугало в огороде).

**җимеш баķча** *гәй.* яшелчә бакчасы (огород).

**БАҠЧА** 1. *кузн., чст., к.* баķча; **2**. *мәл.* кәбер өсенә тотылган киртә, рәшәткә, чардуган (решетка, изгородь – на могиле)» [1969-Т_диал.: 66].

Башка очракларда диалекталь сүзләрнең фонетик вариантлары үз урыннарында алфавит тәртибендә китерелә.

Басылып чыккан диалектологик сүзлекләрдәге аңлатмалар аерым очракларда яңа редакциядә бирелә. Сүзләрнең дөрес әйтелешен чагылдыру максаты белән сүзлектә кайбер транскрипцион билгеләр кулланыла. Мәсәлән,

«**МУЛ’ I** [*рус.*малёк] *м.-кар.* маймыч (малек).

**МУЛ’ II** *[угор.] минз., гәй.* салга бәйләмичә агызылган агач, бүрәнәләр (лес, сплавляемый не в плотах, а отдельными бревнами). Хәзер инде сал белә түгел, мул’ ага инде — *гәй.*

**мул’ белән агызу** *минз.* агачны, бүрәнәләрне салга бәйләмичә агызу (сплавлять лес отдельными бревнами, не в плотах)» [1969-Т_диал.: 309].

Диалектологик сүзлеккә өстәмә итеп үсемлек атамалары бүлеге бирелә. Әлеге бүлек, нигездә, 250 ләп кыргый үсемлекнең җирле сөйләшләрдә йөртелә торган исемнәре сүзлегеннән тора.

Ахырда татар диалектлары буенча кыскача белешмәлек урнаштырыла. Белешмәнең кереше, «Фонетик үзенчәлекләр» һәм «Лексик үзенчәлекләр» бүлекләре Л.Т. Мәхмүтова, «Морфологик үзенчәлекләр» бүлеге Н.Б. Борһанова тарафыннан язылa. Библиографияне һәм схематик картаны Н.Б. Борһанова төзи. Сүзлеккә теркәлгән схематик картада махсус Программа нигезендә өйрәнелмәгән һәм өйрәнеләчәк территорияләр шартлы билгеләр белән күрсәтелә.

Сүзлектә татар теленең ике төп – урта һәм көнбатыш диалектлары буенча, 1958–1967 елларда җыелган материаллар чагыла. Шулай ук сайланма рәвештә алдан чыккан өч сүзлектәге материаллар да кертелә. Элеге сүзлеккә кергән сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең (күләм ≈ 14000 берәмлек) [1969-Т_диал.: 644] билгеле бер өлеше язучылар тарафыннан, әдәби әсәрләрдә кулланылып, әдәби телгә һәм шуннан татар теленең 3 томлык аңлатмалы сүзлегенә дә кереп китә. Шул рәвешле татар теленең бу диалектологик сүзлеге татар әдәби теленең сүзлек фондын баетуда әһәмиятле роль уйный.

Икенче «Татар теленең диалектологик сүзлеге» 1993 елда басылып чыга [1993-Т_диал.]. Күләм ≈ 10441 берәмлек. Әлеге сүзлек шулай ук Л.Т. Мәхмүтова җитәкчелегендә төзелә. Әлеге хезмәттә, нигездә, Татарстаннан читтә таралган беренче китап чыкканда әле өйрәнелмәгән яки өйрәнү стадиясендә булган урынчылыкларга һәм сөйләшләргә бәйле лексик материаллар чагылган: урта диалектның минзәлә сөйләше, бәләбәй урынчылыгы, Башкортостан территориясендә таралган златоуст сөйләше, тепекәй, турбаслы сөйләшләре, мишәр диалектының стәрлетамак сөйләше, күршә сөйләше, Ульяновск өлкәсе Барыш районындагы (калда сөйләше), Карсун тирәсендәге татар авыллары сөйләшләре татар диалектлары системасында шартлы рәвештә мөстәкыйль берәмлекләр итеп

карала. Атлас төзү барышында төрле төбәкләрдә үткәрелгән контроль экспедиция материалларыннан тыш, сүзлектә 1983–1985 елларда диалектологик сүзлекнең икенче томын төзү максаты белән уздырылган махсус лексикологик экспедицияләрдә җыелган материаллар да чагылыш таба.

Бу диалектологик сүзлектә дә, 1969 елда чыккан сүзлектә кебек, татар теленең ике (урта һәм көнбатыш) диалектына караган лексика урын ала. Ул, башлыча, яңа материал нигезендә төзелә. Шулай да анда беренче китапка кергән сүзләр дә бар, ләкин алар башка куллану территориясендә теркәлгән яисә яңа мәгънә белдерә. Сүзлектә төзүче Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова материалларыннан тыш, Н.Б. Борһанова, Р.У. Әмирханов, М.И. Әхмәтҗанов, Р.Г. Әхмәтьянов, Л.Ш. Җамалетдинов һәм башка галимнәр тарафыннан диалектологлар карамагына тапшырылган материаллар да файдаланыла [1993-Т_диал.: 5].

Сүзлектә, беренче (1969) сүзлектәге кебек үк, урта диалектта һәм мишәр диалектында сүз яки сүз тезмәсе бер үк мәгънәдә йөртелеп тә ғ – г, қ – к, в – w авазларының әйтелеше белән генә аерылса, мондый сүз яки сүз тезмәләре бер мәкалә эчендә бирелә. Мәсәлән, «**ЛАҚША** *кргл.,* **ЛАКША** *клд.,* **ЛАʹША** *кас.* өй токмачы (домашняя лапша). Лақша пешерергәйе – *кргл.* Лакшаны кистем, алып куйым инде мыннан. Мин лакша севә төшәм – *клд.*» [1993-Т_диал.: 211].

Баш сүзләрнең һәм сүз тезмәләренең аерым мәгънәләре гарәп цифрлары белән билгеләнә. Омонимнар кайбер мәкаләләрдә рим цифрлары белән күрсәтелә. Мәсәлән, «**ӘТӘМБАЙ, ӘТӘМБӘЙ** *минз., стрл.* 1. булдыксыз, чирле (неспособный, бездарный, вялый); 2. үсмичә, кечкенә калган бәрән (маленький, недоросший ягненок); 3. к. бәйсәкә; 4. чын түгел, ялган, ясалма (не настоящий, искусственный)» [1993-Т_диал.: 401].

«**СУГУ I** *клд.* төшү (падать). Тенне ай шәүләсе сугамы ызбага?

**СУГУ II** *глз.* к. кагу I. Кукәй сындырып, дыружилар салып, быдай оно былʹан сугып табагай була инды, табага салып пышыралар.

**СУГУ III: май сугу** *карс., клд.* май чыгару (выжимать масло из семян). Киндераштан май сугалар иде – *карс.* Элән майы була иде, суктыралар иде – клд.

**СУГУ IV** *карс.* к. қойу I,2» [1993-Т_диал.: 271].

Диалектологик сүзлекнең икенче китабында да татар диалектлары буенча кыскача очерклар (Д.Б. Рамазанова) һәм татар теленең урта һәм мишәр диалектларына караган библиография (Л.Т. Мәхмүтова) бирелә. Очеркларда татар диалектларына хас үзенчәлекләренең, нигездә, беренче китапка кермәгәннәрен генә күрсәтү максаты куела, диалектологиянең фән буларак формалашуы, лингвистик географиянең куллану киңлеге һәм мөмкинлекләре билгеләнә, Урал тирәсе сөйләшләренең формалашу тарихы чагыла. Әлеге хезмәтнең дә татар әдәби телен баетуда роле зур була, фәнгә яңа фактик материаллар, татар сөйләшләре, шул исәптән, гомумән, милли тел формалашу тарихы буенча яңа материаллар кертелә.

Д.Г. Тумашеваның «Көнбатыш Себер татарлары теле» (1961) дигән хезмәтендә тубыл-иртыш диалектының сүзлеге урын ала. Соңыннан ул аның «Словарь сибирских диалектов» сүзлегенә [1992-Т_диал.] нигез була. Күләме ≈ 6480 берәмлек. Әлеге хезмәттә себер диалектлары (тубыл-иртыш, бараба, том) буенча бай һәм күпкырлы лексика тупланган. Сүзлеккә материаллар автор тарафыннан себер татарлары яшәгән урыннардан җыелган, башка чыганаклардан өстәмәләр белән тулыландырылган. Диалектизмнар татар әдәби теленә, рус теленә тәрҗемә ителгән, шулай ук кирәкле иллюстратив материаллар кулланылган. Баш сүзләр алфавит тәртибендә урнаштырылган. Баш сүздән соң, әлеге сүз язылып алынган торак пункт исеме билгеләнгән. Әгәр дә сүз бер районның берничә торак пунктында таралган булса, аларны санап китү урынына район атамасы бирелә. Себер татар диалектларында киң кулланылыш тапкан сүзләр Себ. билгеләмәсе белән күрсәтелә. Сүзлектә гадиләштерелгән, хәзерге татар графикасына нигезләнгән транскрипция кулланылган. Мәсәлән, «**ҚАЙРАН** *Төм., Тар.* – яхшы, гаҗәп; хороший, удивительный. ..әрпересен йасаты та қуяты, қайран нимә [1992-Т_диал.:114]». Сүзлеккә барлык себер диалектлары буенча материаллар, И. Гигановның «Из словаря российско-татарского... » (1804), В.В. Радловның «Из образцов народной литературы тюркских племён» (1872) хезмәтләреннән дә лексика

кертелгән. Төрле чыганаклардан алынган сүзләр авторга яисә чыганакка күрсәткән өстәмә билге белән бирелә. Мәсәлән, «**АТҚЫУ** 1. *Кукр.* – умырып чеметү; ущипнуть, сильно зажать. Пеләгемне атқыты. 2. *Гиг.* – эләктереп алу; захватывать. 3. *Тоб. Р.* – көчләп алу, кысып тоту; захватить силой, сжимать, крепко держать [1992-Т_диал.: 31]». Бер сүзнең төрле мәгънәләре бер сүзлек мәкаләсе кысаларында һәм гарәп саннары белән бирелә.

2000 елда Д.Г. Тумашева һәм А.Х. Насибуллина тарафыннан төзелгән «Словарь диалектной лексики татарских говоров Тюменской области» басыла [2000-Т_диал.]. Күләм ≈ 4000 берәмлек [2000-Т_диал.: 3]. Әлеге сүзлектә Төмән өлкәсе татар сөйләшләренең дилекталь лексикасы чагыла. Сүзлектәге диалекталь лексика «Словарь сибирских диалектов» [1992-Т_диал.] сүзлегеннән сайлап алына. Шуңа өстәп А.Х. Насибуллина сүзлеккә Төмән өлкәсенең төрле районнарындагы татар авылларыннан җыелган 800 дән артык гомумкулланыш сүзләре һәм тотрыклы сүзтезмәләр кертә. Алар текстта * (йолдыз) билгесе белән аерылалар. Диалектизмнар һәм шулай ук сүзләрнең фонетик вариантлары өч баганда бирелгән: диалектизмнар, аларның әдәби вариантлары (булмаса, аңлатмалары), рус теленә тәрҗемә. Мәсәлән,

| | | |
|---|---|---|
| Айғырцақ | 1. яшь айгыр<br>2. колын | молодой жеребец<br>жеребенок |

[2000-Т_диал.: 9].

| | | |
|---|---|---|
| Ясқану* | кизәнү, селтәнү, кул күтәрү | замахиваться, поднять руку |

[2000-Т_диал.: 169].

Туган телне саклауның аеруча әһәмиятле шартларыннан берсе җирле сөйләшләрне саклау бүгенге көндә бик мөһим мәсьәлә булып тора. Шул исәптән диалектларны, сөйләшләрне өр-яңадан барлау җирле сөйләшләрне өйрәнү-тикшерү аспектларын киңәйтә, татар теленең яңа зур диалектологик сүзлеген төзү ихтыяҗын тудыра. Әлеге максатка ирешүне күздә тотып, 2009 елда «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге» дөнья күрә [2009-Т_диал.]. Бу сүзлек тә диалектология фәнендә танылган һәм камил булып саналган Л.Т. Мәхмүтова принципларына нигезләнеп төзелде. Төзүчеләре – күренекле галимәләр, диалектологлар Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Әлеге сүзлек

татар тел белеме һәм мәдәнияте өлкәсендә эшләүче галимнәргә, массакүләм белгечләргә кирәклеген күздә тотып төзелә. Алда нәшер ителгән диалектологик сүзлекләрдә татар теленең Көнбатыш Себер һәм Әстерхан регионнарында таралган сөйләшләре буенча материаллар чагылмый. Диалектологлар исә төрле төбәкләргә экспедицияләр уздыру барышында өстәмә диалекталь сүзләр дә туплана.

Сүзлектә омонимнар аерым мәкаләләрдә рим цифрлары белән билгеләп бирелә. Сүзнең мәгънәләрен ачыклау өчен, төрле сөйләшләрдән язып алынган мисаллар (шул исәптән фольклор материаллары да) китерелә.

Мәсәлән, «**ЙАЛПАЙУ I 1.** *хвл., злт.* көрәеп китү, рәтләнү, уңайлану (потучнеть, поправиться, стать лучше, здоровее, полнее). Сыйыр көтүдә йөргәч, йалпайған. – *злт.*; **2**. *хвл.* яхшырып, үсеп, уңайланып китү – үсемлек турында (поправиться, стать лучше, похорошеть – о растениях). Үләннәр йаңгырдан соң йалпыйып, яшәреп киткәннәр; **3.** *хвл., злт.* – әйбәтләнү, эше һ.б. уңу (стать лучше, повезти кому-либо). Йакшыга ийәргән йалпайган, йаманга ийәргән картайган (*мәкаль*). – *хвл.* Қыз бала йахшы йергә төшсә, йалпайа, йаман йергә төшсә, қартайа. – (*мәкаль*). – *злт.*

**ЙАЛПАЙУ II** лш. Кыйшаю, янтаю (скособочиться; накрениться на один бок)» [2009-Т_диал.: 229].

Җөмләләрнең төгәл, аңлаешлы булырга тиешлеген күз алдында тотып, төзүчеләр тарафыннан кайбер мисалларга җәяләр эчендә аерым сүзләр өстәлә. Мәсәлән,

«**ҚАТЛАМА 1.** *мам. минз. брб.д.* юка гына җәелгән камырны майлап, өстенә киндер орлыгы сибеп, аны катлы-катлы итеп төреп, кисәкләп мичтә пешерә торган азык (слойка с начинкой из конопляных семян)... **11.** *брб.д.* төче камырдан калын итеп пешерелгән җәймә (не очень тонкая лепешка из пресного теста). Минең пабай йаратайы қатламаны, исе (үзе) қалын, исе цөцө... «[2009-Т_диал.: 397].

Хәзергә кадәр әдәби телгә кереп урнашмаган, ягъни диалекталь булып калган сүзләр, әдәби тел сүзлекләрендә бирелүләренә карамастан, бу сүзлеккә дә кертелә. Мәсәлән,

«**САҚ III** *том. д.*, **САК** *миш.д.* юка пальто (тонкое пальто) ... Сак дип әйткәннәрен беләм әбиләрнең. – *кузн.*» [2009-Т_диал.: 556].

Сүзлек якынча 40 000 сүз һәм сүзтезмәне үз эченә ала. Барлык татар диалектларының лексик байлыгы чагылыш таба. Сүзләрнең мәгънәләре татарча аңлатыла, рус теленә тәрҗемә ителә һәм бай иллюстратив материал белән раслана. Моңа кадәр чыккан сүзлекләрдән тыш, әлеге хезмәттә диалектологларның хәзергә хәтле даими уздырылып килә торган экспедицияләр барышында тупланган материаллар да бирелә. Сүзлек ахырында татар диалектологиясе буенча зур библиография китерелә (төзүчеләре Т.Х. Хәйретдинова, Р.С. Барсукова) [2009-Т_диал.: 6].

Шулай итеп, татар теленең диалекталь лексикографиясе өлкәсендә татар диалектологлары тарафыннан күп, төрле яклы мөһим эшләр башкарыла. Шулай да татар милли телен саклау һәм үстерү өлкәсендә галимнәребез алдында татар теленең җирле лексик байлыгын туплау һәм теркәү бурычы бүгенге көндә дә актуаль булып тора.

## § 15. Этимологик сүзлекләр. Алынмалар сүзлекләре

### Этимологик сүзлекләр

Этимологик сүзлекләрнең төп максаты – сүзләрнең килеп чыгышы турында мәгълүмат бирү. Бу төр сүзлекләр тел белеменең иң катлаулы һәм бәхәсле тармакларыннан берсе булган этимология казанышларын чагылдыра. *Этимология* грекча ἐτυμολογία «сүзнең беренчел, чын мәгънәсен билгеләү, ачыклау фәне» дигәнне белдерә. Мондый типтагы сүзлекләрдә сүзнең билгеле бер телнең үзендә барлыкка килүе яки башка бер телдән алынганлыгы турында хәбәр ителә, еш кына сүзнең нинди тамырдан, кайсы ысул белән ясалуы, аның иң борынгы беренчел мәгънәсе күрсәтелә, мөмкин булса, сүзнең ни өчен нәкъ шулай аталуына нигез булган билге ачыклана. Этимологик сүзлекләрдән укучы татар теленә кереп үзләшкән алынмаларның кайсы телдән һәм нинди юллар белән алынуы турында җавап ала.

Төзелү принциплары, адресатка юнәлтелү һ.б. аерым характеристикаларына карап, этимологик сүзлекләрне берничә төргә аералар. Лөгатьлек күләме һәм куллану даирәсе нигезендә этимологик сүзлекләр *фәнни (академик типтагы)* һәм *фәнни-популяр* төрләргә бүленә. Фәнни этимологик сүзлекләр максималь тулы лөгатьлек, сүзнең килеп чыгышын мөмкин кадәр киң яктырту, җентекле биб-

лиография һәм коры фәнни телдә язылуы белән аерылып тора. Фәнни-популяр этимологик сүзлекләр исә актив кулланышта йөргән сүзләрдән гыйбарәт лөгатьлек, гадиләштерелгән фәнни аппарат, минималь әдәбият һәм укучы өчен аңлаешлы, еш кына мавыктыргыч телдә язылуы белән характерлана.

Тасвирлау теле санына карап, этимологик сүзлекләр *бер тел сүзлекләренә* һәм *берничә тел сүзлекләренә* бүленә. Бер тел сүзлекләре конкрет бер телнең лексик составын тикшерә, башка тел материаллары бары тик тасвирлана торган тел сүзен ачыкларга ярдәм итү өчен генә кулланыла ала. Берничә тел сүзлекләренең объекты буларак, башлыча, кардәш телләр төркеме хезмәт итә. Моңа «Этимологический словарь тюркских языков» яки «Этимологический словарь славянских языков» хезмәтләрен мисал итеп күрсәтергә була.

Тасвирлау берәмлегенә карап та, этимологик сүзлекләр берничә төргә бүленә. Аларның иң киң таралганы – традицион этимологик сүзлекләр. Мондыйларның тасвирлау объекты булып *лексик берәмлек* хезмәт итә. Фәкать *диалекталь сүзләрнең* генә этимологиясен тикшергән сүзлекләр дә бар. Телнең шактый зур өлешен алып торган фразеологик берәмлекләрнең килеп чыгышы *фразеологизмнарның* этимологик сүзлегендә өйрәнелә. *Ономастик берәмлекләрнең* этимологиясе тасвирланган сүзлекләрдә кеше исемнәре, фамилияләр, кушаматлар, томонимнар һ.б. ялгызлык исемнәрнең кайдан чыкканлыгы, ни өчен шулай аталып йөртелгәнлеге ачыклана.

*Тарихи-этимологик сүзлекләр* этимологик сүзлекләрнең аерым бер төре буларак карала. Мондый хезмәтләрдә, сүзләрнең этимологиясе – килеп чыгышы һәм беренчел мәгънәсеннән тыш, аларның биографиясе турында да мәгълүмат бирелә, ягъни барлыкка килүеннән алып бүгенгә кадәр сүз тарихының төп этаплары, фонетик тышчасында, морфологиясендә һәм аеруча семантикасында кичергән үзгәрешләр күзәтелә.

Татар тел белемендә этимология белән телче галим Р.Г. Әхмәтьянов шөгыльләнде. Аның фәнни тикшеренү нәтиҗәләрен чагылдырган берничә этимологик сүзлеге дөнья күрде.

**«Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге»** [2001-ТР_этим] – татар теленең төп сүзлек фондын этимологик позициядән яктырткан беренче тәҗрибә. 3000 гә бераз гына тулмаган

сүзлек мәкаләсендә автор тарафыннан кыска формада татар әдәби теленең лексик нигезләренә этимологик характеристика, кайбер сүзләрнең семантик үзенчәлекләре, аерым берәмлекләр өчен библиографик чыганаклар, этимологияне билгеләүдә төрле гипотезаларга комментарийлар бирелгән. Бу мәгълүмат минималь күләмгә калдырылган. Тасвирлауның җыйнаклыгын, фәнни аппаратның җиңеллеген, библиографик мәгълүматның шактый аз булуын исәпкә алганда, әлеге сүзлек фәнни-популяр хезмәт буларак төзелгән дип нәтиҗә ясарга мөмкин. Белешмәлекнең исеме генә берникадәр гаҗәпләнү уята, анда аның тарихи-этимологик булуы белдерелә. Югыйсә тарихи сүзлекләр билгеле бер телдәге сүзләрнең барлыкка килгәннән алып хәзерге хәленә кадәр яки аларның кулланыштан чыкканчы өзлексез тарихын күзәтергә мөмкинлек бирә. «Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге»ндә Р.Г. Әхмәтьянов исә мондый комментарийлар бирү бурычын куймый (Сафаров, 2017: 399). Сүзлекнең тәрҗемәле булуын да билгеләп үтәргә кирәк: баш сүзләрнең барысына да рус телендәге эквивалентлары бирелгән.

Иллюстрация буларак, әлеге сүзлектән бер-ике үрнәк китерик:

**ЕЛКЫ** «лошадь» – бор. *йал-кы//йал-лык* «яллы (ялын кисмәгән) ат» яки «ял итүче ат» сүзеннән; к. алт. *дылкы* «өйрәтелмәгән ат, бия», госм. *јылкы* «иректә йөрүче атлар», ккк. *җаллык* «ат», чулым. *йалты, ял-тыг ~ йал-лыг* «елкы». К. **Ял** I. [2001-ТР_этим: 65].

**ЗИНДАН** «тюрма» – борынгы Харәзем телендәге *зәминдан* «җирне казып ясалган төрмә» сүзеннән киң таралган. Ирани телләрдәге *зәмин* «җир, җирлек» (татар әдәби телендә дә очрый) рус. *земля* сүзе белән тамырдаш [2001-ТР_этим: 75].

Р.Г. Әхмәтьянов этимологик эзләнүләрен алга таба да дәвам иттерә. Аның максаты татар теленең тулы этимологик сүзлеген төзеп бастыру була. Телнең барлык сүзлек байлыгы бер генә томга сыеп бетмәгәнгә, ул дүрт томлы сүзлек чыгарырга планлаштыра. 2005 елда бу дүртомлыкның беренче томы нәшер ителә. Сүзлекнең икенче, өченче һәм дүртенче томнары автор ниятләгән форматта чыкмый кала. Гомумән алганда, Р.Г. Әхмәтьянов төзегән дүрт томлы **«Татар теленең этимологик сүзлеге»**нең беренче томында [2005-ТР_этим_1] А – Й хәрефләренә башланган 3000 чамасы сүзнең килеп чыгышы тасвирланган. Сүзлек мәкаләсе, кагыйдә буларак, шактый киң мәгълүмат бирерлек итеп оештырылган: баш

сүз, аның рус теленә тәрҗемәсе, төрле стилистик һ.б. тамгалар (мәс., *диал., истор.* һ.б.), этимологик анализ нәтиҗәләре, аерым берәмлекләр өчен башка телләрдән параллельләр, хәтта мәкаль-әйтемнәрдән яки матур әдәбияттан иллюстратив материал, баш сүзнең дериватлары. Бер мисал:

**АВЫШ-У [аwыш-]** «наклоняться; переволить, переходить черту» (к. җырда: *Мәшрикъ тарафыннан чыккан болыт Мәгъриб тарафына авышкай*), диал. (ТТДС:20) «меняться, изменяться; проходить (о болезни, хвори)» < гом. кыпч. *аwыш-* (н. кк. ккк. *ауыс-*, кырг. *оош-*) «авышу; алмашыну; үзгәрү» формасынча **ау-у** фигыленең уртаклык юнәлеше («берьюлы бергә аву»), ләкин соңрак «ава төшү, авуын дәвам итү» мәгъ. алган. К. **Ау-у.**

**Авыш-** тат. теле сөйләшләрендә дә күпмәгънәле һәм продуктив нигез: **авышыл-у, авышын-у, авыштыру** («алмашу, алмаштыру» мәгъ.), диал. авышкан «акылы киткән» һ.б. К. **Авышчан.** [2005-ТР_этим_1: 42]

Р.Г. Әхмәтьяновның ике томлык **«Татар теленең этимологик сүзлеге»** – татар лексикасының килеп чыгышын һәрьяклап чагылдырган сүзлек [2015-ТР_этим_I; 2015-ТР_этим_II]. Аны авторның гомер буе туплаган материалларын чагылдырган хезмәт итеп карый алабыз. Бу белешмәлек телче галимнең үткән елларда нәшер ителгән һәм нәшер ителеп өлгермәгән материалларын үз эченә алган. Күләме ягыннан ул шактый колачлы: лөгатьлеге 10 300 чамасы вокабуладан тора. Абсолют күпчелеге әдәби тел сүзләре булу белән бергә, диалектларда кулланылган, язма чыганакларда теркәлгән җанлы сөйләм теле лексикасы да бу хезмәттә авторның игътибарыннан читтә калмаган. Сүзлек мәкаләсендә лексеманың семантикасы, кардәш һәм кардәш булмаган телләрдәге параллельләре, шактый тулы библиографик мәгълүмат, аерым сүзләрнең этимологиясе тәфсилле итеп тикшерелгән хезмәтләргә сылтамалар һ.б. бирелгән. Кулланылган әдәбият исемлеген 800 дән артык хезмәт тәшкил итә.

Кайбер төгәлсезлекләргә, кайвакыт кирәкле сылтамалар булмавына һәм сүзнең килеп чыгышы турында башка гипотезаларның һәрвакыт күрсәтелеп бетмәвенә һ.б. нечкәлекләргә карамастан, безнеңчә, Р.Г. Әхмәтьяновның ике томлы «Татар теленең этимологик сүзлеге» – бүгенгә академик типтагы иң тулы этимологик сүзлек. Анда татар халкының традицион мәдәнияте, тарихы,

көнкүреше һәм контактлары белән тыгыз бәйләнгән сүзләргә өстенлек бирелгән. Шул ук вакытта сирәк лексемаларга да, профессиональ һәм техник чынбарлык реалияләрен белдергән берәмлекләргә дә игътибар ителгән (Сафаров, 2016: 458).

Сүзлектәге төрки тамырлы берничә сүзгә мисал:

**ИКЕ** «два» > чув. *иккĕ, икĕ* < гом. кыпч. *эки,* кырг. диал., алт. *экки* (Радлов язылышында *äкка*), хак. *ĕккĕ,* уйг. *иги, эги* > тув. *ийи* < бор. төрки (ДТС: 167–168) *eki, iki, ikki* һ.б., к. ЭСТЯ I: 337– 338; Федотов I: 162–163 (бу автор чув. яңгырашы татарчадан икәнлеген әйтми). Сүзнең мәзкүр чыганакларда Г. Рамстедтның (1957: 65) бор. төрки **ek-* < **hek-* < **pek-* «иярү, икенче булу» фигыленнән ясалган дигән фикере китерелә. К. ш. ук **Игез.**

Дерив.: **икеле** (төрле мәгъ.), **икесез** (*сәгать икесез*); **икелек; икелә-ү; икеләнү, икеләт-ү; икеләч; икенче** («бүтән, бүтәнчә» мәгъ. дә кулланыла), диал. **икәм** «икенче» һ.б. К. **Икенде.** [2015-ТР_этим_I: 296]

**ТӘГӘРМӘЧ** «колесо» < **тәгәрмәгәч** (без теркәдек. – *Р.Ә.*) id. < *тәгәрмикәч, *тәгәрмәй-кәч* «кечкенә *тәгәрмәч*» сүзеннән, к. диал. (ТТДС I: 436) **тәгәрмәй, тәгәрми** «тәгәрмәч; арбачык», каз. *тегірмеш* id. һ.б. << бор. төрки (ДТС: 548, 550) *tekermi, tegermi, tegirmä* «түгәрәк, алка» (*-mi, -ma* морфемасы аңлашылып бетми, ихтимал, ул аерым сүздер) > төр. *tegermi, deyirmi* «математик түгәрәк, әйләнә», *degermi* «түгәрәк; хачсыман дүрткел», төркм. *дегирми* «тәгәрмәч» һ.б. күп телләрдә.

Шунысы характерлы ки, *тәгәрмәч, тәгәрмәгәч* яисә *тәгәрмәй* сүзләре, бор. төрки һәм тат. теленнән тыш, бүтән кыпч. телләрендә юк; бу факт башк. *тәгәрмәс, тәңәрмәс* сүзенең тик тат. теленнән генә килә алганын күрсәтә. Тат. *тәгәрмәч* сүзе үзе дә берәр аерым төбәктән (ихтимал, миш. сөйләшләреннән) таралган, чөнки Казан татарларында «тәгәрмәч» мәгъ. **көпчәк** сүзе кулланыла (*арба көпчәге* һ.б.); чув. телендә «тәгәрмәч» урынына *кустăрмач* (тат. *тәгәрмәч* сүзеннән ярымкалька) һ.б.

Диал. (ЗДС: 616–617) **тәгәрмәй, тәкермәч** «тәгәрмәч», әлбәттә, **тәгәр-, тәкәр-* фигыленнән (тик ясалышы ачык түгел); аның исем коррелянты – **тәгәр**, к. аз. *тәкәр*, төр. *teker* «тәгәрмәч», тат. диал. (ТТДС I: 436; Тумашева 1992: 206) **тәгәрцәк, тәгәрцек,** башк. (БТДҺ: 349) *тәңгәрсәк* ~ нуг. *тегершик,* каз. диал. (ҚТДС: 327) *тегершік* «кечкенә тәгәрмәч», госм., чыгт. *тäкäрлäк* id. һ.б.

ясалган. К. **Тәгәр, Тәкернә-ү, Тегермән**. ЭСТЯ III: 172, 178 (төркм. *дегирми-* «тәгәрми» сүзе тур., аз мәгълүматлы).

Дерив.: **тәгәрмәчле, тәгәрмәчсез; тәгәрмәччек; тәгәрмәчлек, тәгәрмәчлә-ү.** [2015-ТР_этим_II: 238-239]

Алынма сүзләрне тасвирлый торган мәкаләләр артык җәенке түгел. Башлыча, анда аерым моментларга гына комментарийлар бирелгән:

**МАНАРА** «минарет» < гар. *мāнāрā, мāнāрāт* «утлы маяк, манара, нурландыргыч», *нwр* «яктыру, нурлану, яктырту, ут, нур» тамырыннан; кайбер мөселман халкы телләрендә (к. ЗДС: 467) *мāнар ~ минар* варианты актив кулланыла. Рус. *минарет* Европа телләре аша кергән. К. **Нур.**

Дерив.: **манаралы, манарасыз; манаралык** [2015-ТР_этим_II: 16].

**ТӘҖЕ,** диал. (шрл.) **тяжы** «тяж» < рус.; шуннан ук чув. *тевӗш, терш, черш* һ.б. id. Рус. сүзе *тяга* «тарту» сүзе белән тамырдаш. [2015-ТР_этим_II: 239]

Татар теленең үз этимологик сүзлекләре шулар белән чикләнә. Ләкин, башка төр сүзлекләрдән аермалы буларак, этимология мәсьәләсендә кардәш һәм хәтта кардәш булмаган телләрнең этимологик сүзлекләре зур ярдәмче була ала. Бу яктан караганда, күп кенә төрки телләрнең этимологик сүзлекләреннән татар теле өчен дә файдалы материал табарга мөмкин. Аерым һәрберсенә тукталып тормыйча, әһәмиятлерәк һәм тулырак дип каралган төрки сүзлекләрне билгеләп үтик: В.Г. Егоровның «Этимологический словарь чувашского языка» (1964), «Қазақ тілінің қысқаша этимологиялық сөздігі» (1966), К. Сейдакматовның «Кыргыз тилинин кыскача этимологиялык сөздүгү» (1988), М. Р. Федотовның «Этимологический словарь чувашского языка» (1996), Х. Әрәннең «Türk dilinin etimoloji sözlüğü» (1999), Б.И. Татаринцевның «Этимологический словарь тувинского языка» (2000, 2002, 2004, 2008), Ш. Рахматуллаевның «Ўзбек тилининг этимологик луғати» (2000, 2003, 2009), Х. М. Акбаевның «Карачаевская военная терминология и оружие: историко-этимологический словарь» (2001), Г. В. Поповның «Этимологический словарь якутского языка» (2003), А. Камалов белән Ф. Камаловларның «Башҡорт теленең тарихи-этимилогик топонимик һүҙлеге» (2007), К.С. Кадыраджиевның «Этимологический словарь кумыкского языка» (басылмаган) һ.б.

Төрки телләр этимологик сүзлекләрнең күбесен чагыштырма-этимологик төргә кертеп карарга мөмкин, һәм андагы чагыштыру элементы, кагыйдә буларак, этимологиядән өстенрәк тора. Төрле сәбәпләр аркасында төрки телләр материалында бүгенгә кадәр тарихи-этимологик сүзлекләр төзелмәгән. Безнең фикеребезчә, Х. Әрән, Б. Татаринцев һәм Р. Әхмәтьяновларның сүзлекләре турыдан-туры этимологик сүзлекләр дип классификацияләнергә мөмкин. Алар эчтәлекләре белән дә, күләмнәре белән дә башка төрки тел сүзлекләреннән аерылып тора.

Болардан тыш, төрки телләр лексикасын бергә туплап, аларның этимологиясен биргән хезмәтләр бар. Хронологик яктан мондыйларның иң әүвәлгесе – Һ. Вамбериның (H. Vámbéry) 1878 елда Лепцигта нәшер ителгән «Etymologisches Wörterbuch der Turko-Tatarischen Sprachen; ein Versuch zur Darstellung des Familienverhältnisses des Turko-Tatarischen Wortschatzes». Сүзлекнең яңа басмалары күп мәртәбә дөнья күрә. 1969 елда Һелсинкида М. Рясяненның (M. Räsänen) «Versuch eines etymologischen Wörterbuchs der Türksprachen», 1972 елда Лондонда Г. Клосонның (G. Clauson) «An etymological dictionary of pre-thirteenth-century Turkish» сүзлекләре чыга. 1974 елдан башлап Э.В. Севортян редакциясендә хәзерге һәм борынгы төрки телләрнең лексикасын киң планда чагылдырган күптомлы «Этимологический словарь тюркских языков» нәшер ителә башлый. Бүген бу сүзлекнең сигез томы һәм А.В. Дыбо авторлыгында өстәмә тугызынчы томы (2013) төзелеп чыкты. Хәзергә бу хезмәт – төрки телләрнең ни дәрәҗәдә бер-берсенә якын, ни дәрәҗәдә бер-берсеннән ерак булуын күрсәтә алган бердәнбер этрафлы һәм фундаменталь сүзлек. Сүзлектә баба төрки лексик фондны барлауга омтылыш ясала һәм бары тик төрки лексика гына тикшерелә. Соңгы гасырларда һәр аерым төрки телгә үтеп кергән күпсанлы алынмалар анда каралмый. Соңгы елларда чыккан төрки лексика сүзлекләреннән Н.Ф. Гил тарафыннан төзелеп, 2013 елда Мәскәүдә басылган «Древнетюркские слова в современных языках: сравнительное языкознание: этимологический словарь» хезмәтен билгеләп үтәргә кирәк.

Бу сүзлекләрдә татар теле лексикасы да шактый урын алган. Этимологик анализ өчен күпчелек очракта алар авторитетлы чыганак булып тора.

Югарыдагы сүзлекләрнең һәммәсенең дә тасвирлау объекты лексик берәмлек иде. Татар фразеологиясен этимологик яктан

тасвирлаган аерым сүзлекләр әлегә юк. Шулай да монда Х. Мәхмүтовның «Гыйбарәләр тарихыннан сәхифәләр» хезмәтен күрсәтеп китмичә булмый (Мәхмүтов, 2008). Махсус этимологик сүзлек дип аталмаса да, анда фәнни-публицистик стильдә 300 дән артык татар идиомасының килеп чыгышы этимологик яктан яктыртылган. Тикшерү объекты итеп алынган берәмлекләрнең алфавит тәртибендә бирелеше дә бу хезмәтне этмологик сүзлек белән якынайта. Автор аеруча хәзерге матур әдәбиятта һәм матбугатта кулланылуын дәвам иткән фразеологизмнарга игътибар биргән, аларның әйләнештә булуын исбатлау өчен, иллюстратив материал да китерә барган. Бер мисалга тукталыйк.

**Пәри башка, җен башка**

Бер-берсенә охшаш, якын ике нәрсәнең (күренешнең) кайбер мөһим сыйфатлары буенча чагыштырганда шактый аерылып торулары искәртелә. Чынлыкта пәри дә, җен дә – мифик затлар. Алай да пәри кызы бик гүзәл, җен кызы бик ямьсез була, имеш. Алар арасында башка үзгәлекләр дә күп икән…

Соңгы елларда гыйбарә әдәби телебездә шактый активлашып китте.

«Әмма безнең бу институт (Татар дәүләт гуманитар институты – *Х. М.*) һич кенә дә милли университет идеясен көн тәртибеннән төшереп калдырырга тиеш түгел. Татар әйтмешли, пәри башка, җен башка» (*Туфан Миңнуллин // «Мәдәни җомга»дагы әңгәмәдән*. – 1997. – 17 гыйнвар).

«Пәри башка, җен башка дигәндәй, шәхсән үзем Республика һәм Шәһәр көннәрен бергә үткәрүне хупламыйм… Әлеге бәйрәмнәр мәгънәләре ягыннан бер-берсеннән нык аерылалар» (*Әгъзам Фәйзрахманов. Мең яшә, дип аңа чорлар дәшә // Мәдәни җомга. – 2002. – 30 август*).

[Ренат Харисның «Чехов базары» поэмасында] «Сюжет кору һәм хикәяләү, уйлануларның нигез тәртибе мәгълүм дәрәҗәдә А. Твардовскийның «Ерактан-еракка» («За далью даль») поэмасын искә төшерә… Ләкин пәри башка, җен башка, ди. Чор башка, тема башка, мәгънәләр башка. Безнең каршыда киң колачлы, реалистик, оригиналь әсәр» (*Нурмөхәммәт Хисамов. Хәтер сагында. – Казан, 2004. – Б. 441–442*).

Бу гыйбарә телебезгә Рәхми Тылмач сүзләре буларак кереп калган. Рәхмәтулла Әмирханов (1805–1876) – әдип, мәгърифәтче,

татарча күп китаплар, календарьлар әзерләп бастырган кеше. Гарәп, фарсы, төрек, рус телләрен яхшы белгән, Казан ратушасында тәрҗемәче булып та эшләгән («Тылмач» кушаматы әнә шуннан килә).

Рәхми Тылмач Казан халкы арасында тапкыр сүз остасы буларак та киң таныла. Аның исеме белән бәйләп мәзәкләр сөйләнүе хакында үзенең «Мөстәфадел-әхбар» әсәрендә Шиһабетдин Мәрҗани дә искә ала.

Нәкый Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре»ндә (Казан, 1963. – Т. 2. – Б. 601–602) әлеге гыйбарәнең «Пәри башка, җен башка, умач булалмый лапша» дигән тулырак варианты да теркәлгән. Шунда ук аның мәзәге дә бирелә:

«Рәхми беркөнне хатынына әйткән:

– Токмач пешер!

Хатыны иренеп тора икән:

– Ярар инде, умач кына пешерик, – дигән.

– Токмач яхшырак бит.

– Умач та тәмләп пешергәч бик яхшы була.

– Мин сиңа әйтәм, токмач пешер. Татарча аңламасаң, урысча әйтәм: лапша!

– Әй, бар да бер камыр түгелмени соң! Токмач ни, умач ни!

Рәхми хатынының юкка тискәреләнүенә эче пошып әйткән, ди:

– Соң, җүләр хатын булмасаң, уйлап кара: пәри башка, җен башка, умач булалмый лапша! – дигән». (Мәхмүтов, 2008: 270–271).

Шулай итеп, татар этимологик сүзлекләрен Р.Г. Әхмәтьяновның төрле елларда чыккан хезмәтләре тәшкил итә. Шул ук вакытта башка төрки телләрнең сүзлекләре, татарлар белән гасырлар буена янәшә яшәгән халыкларның тел материалларын тасвирлаган сүзлекләр дә аерым сүзләрнең килеп чыгышын ачыклау өчен ярдәмче була ала.

**Алынмалар сүзлекләре**

Телдә кулланышта йөргән сүзләр составы генетик яктан үз (яки үзтума) һәм чит тел сүзләре буларак карала. Гомуми планда аерым милләт теленә чит телдән кергән берәмлекләрне алынмалар дип атасалар да, фәкать күптән алынып үзләшеп беткән, гадәттә, алучы телнең фонетикасына буйсындырылган, яңа сүзләр ясауда

нигез хезмәтен үтәгән сүзләрне генә тел белемендә *алынмалар* дип атыйлар. Телдә чагыштырмача соң кулланыла башлаган, үзләшмәгән, чит телнеке икәнлеге тоелып торган сүзләр *чит тел сүзләре* дип атала.

Алынмалар телгә һәр чорда керә торганга, аларның борынгы катлавын ачыклап бетерү дә – шактый кыен мәсьәлә. Шул сәбәп-ле тар мәгънәсендә алынмаларны гына туплап биргән сүзлекләр төзү имкянсыз эш дип карала ала. Алынмалар сүзлеге турында фикер йөрткәндә, кагыйдә буларак, чит тел сүзләре сүзлекләре күз уңында тотыла. Ягъни чит тел сүзләре сүзлекләренең аңлату предметы – стилистик яктан чикле кулланышта йөргән, чыгышы чит телдән булган, ачыктан-ачык чит сүз итеп кабул ителгән сүзләр. Шуңа күрә чит тел сүзләре сүзлекләре, гадәттә, төрле терминнарны аңлата. Көнкүрештә актив кулланылган, үзләшкән алынмалар, гомуми кулланышта йөрү сәбәпле, башлыча, мондый белешмәлекләргә кертелми (Шанский, 2009: 195).

Чит тел сүзләре сүзлекләре, бер яктан, теге яки бу чит тел сүзенең мәгънәсен аңлата (аңлатмалы сүзлек функциясе), икенче яктан, ул сүзнең чыганак телен күрсәтә (этимологик сүзлек функциясе). Кайвакыт шулай ук сүзнең грамматик үзенчәлекләре һәм әйтелеше турында да мәгълүмат бирелә.

Югарыдагы таләпләргә җавап бирә торган сүзлекләр татар телендә әлегә юк. Дөресрәге, мондый төр сүзлекләр XX гасыр башында төзелә башлый, ләкин алар алга таба үсеш алмый. Күпчелек очракта бу сүзлекләр ул чорда татар телендә еш кулланылган, чит сүз булуы тоелган, мәгънәсе аңлашылып бетмәгән гарәп, фарсы, рус, госманлы төрек һәм башка телләрдән кергән сүзләрне туплап бирә, әмма күпчелек вокабулаларны борынгыдан язма чыганакларда кулланылган гарәп алынмалары тәшкил итә.

Бу төр сүзлекләр арасында беренчеләрдән 1911 елда Уфада Сәлимгәрәй Җантуринның «Лөгат»е («لغت») нәшер ителгән [1911-ГФТкТ_алынм_(г)]. Сүзлектә татар әдәбиятында еш очраган «гарәби, фарси һәм бераз госманлы сүзләре» теркәлгән, һәр сүзнең чыганак теле күрсәтелгән. Сүзләр алфавит тәртибендә бирелгән. Күләме – 466 бит. Мәсәлән:

اِجَازَت: ع. رخصت، اذن، ايرك

**иҗазәт**: г. рөхсәт, изен, ирек.

اِجَازَتْنَامَه: عف. اجازت و رخصت يازلغان كاغد، رخصت كاغدى

**иҗазәтнамә**: гф. иҗазәт вә рөхсәт язылган кәгадь, рөхсәт кагаде.

تَرسانَه: ت. پاراخودلر ياصالا طورغان فابريقه.

**тәрсанә**: т. парахудлар ясала торган фабрика.

**فَرشتَه:** ف. مَلَك، ملائكه.

**фәрештә**: ф. мәләк, мәляикә.

С. Җантуринныкы белән бер үк вакытта диярлек төзелеп, 1912 елда Казанда күп кенә сүзлекләр төзүдә актив катнашкан һәм үзе дә берничә сүзлек төзегән Габбас Сәйфуллинның «Кечек лөгать» («كچك لغت») исемле хезмәте басылып чыга [1912-ГФЕвТ_алынм_(г)]. Төзүче, баш сүзләрен алфавит тәртибендә биреп, сүзлекне «әдәбиятымызда мөстәгъмәл гарәби, фарси вә яурупалылар сүзләрене җамигъ лөгать китабыдыр» дип атый. 112 битлек актив кулланышта йөргән авыр аңлаешлы сүзләрнең мәгънәләрен ачыклаган. Сүзлектә «яурупалылар» алынмаларына аерым игътибар бирелгән. Мәсәлән:

**ازدواج** – خاتون آلو، ئويله نو

**издиваҗ** – хатын алу, өйләнү.

**ايلليوستراتسيا** – رسم، صورت، بر اشنى آچق ايتوب كورساتو

**иллюстрация** – рәсем, сурәт, бер эшне ачык итеп күрсәтү.

**ريداكتوْر** – محرر، كتاب ياكه غزيته يازوچى

**редактор** – мөхәррир, китап яки газета язучы.

**كاتيگوْرييا** – درجه، بولم، صنف.

**категория** – дәрәҗә, бүлем, сыйныф.

Шул ук Габбас Сәйфуллинның (Сәйфинең) 1917 елда Казанда нәшер ителгән күләме зур булмаган «Мәктәп лөгате»ндә («مكتب لغتى»), мәктәп дәреслекләрендә очраган, шулай ук гарәп теле дәресләрендә кулланылган сүзләр тупланып бирелгән [1917-ГТ_алынм_(г)]. Бу сүзлектә төп урынны гарәп сүзләре алып торса да, анда төрек һәм фарсы телләреннән кергән берәмлекләр дә очраштыра. Мәсәлән:

اِزار – آلیابقچ. بر نوع كييم.

**изар** – алъяпкыч, бер нәүгъ кием.

**حامِلة** – يوكلى خاتون.

**хамилә** – йөкле хатын.

صِيام – ئورازا طوطمق.

**сыям** – ураза тотмак.

Узган гасыр башында күпләп татар газета-журналлары чыга башлый. Шул ук чорда фән-техника казанышлары, сәяси үзгәрешләр илдәге киң массаларга үтеп керә. Болар барысы да телдә чагылмый калмый. Вакытлы матбугат теле исә мондый үзгәрешләрне аеруча тиз тотып ала. Әмма яңалыкларны белдергән яңа сүзләр истә калдырмаслык дәрәҗәдә артып киткәч, газета укучыларда аларны аңлата торган сүзлекләргә ихтыяҗ туа. М. Гали тарафыннан 1928 елда басылган «Газета укучылар өчен кесә сүзлеге» дә шул ихтыяҗны канәгатьләндерү максаты белән төзелә [1928-Т_алынм_(г)]. Кече форматлы, 203 битлек бу белешмәлектә, башлыча, Совет хакимияте урнашу белән әйләнешкә кергән яңа сүзләрнең мәгънәләре аңлатыла.

Менә «п» хәрефенә берничә мисал:

پرافيسييه هوُنه ر، كه سب.

**прафисия** – һөнәр, кәсеп.

**پرافينتيرين** پرافساسوزلارنڭ بوُتن دوُنيا كوله منده گیُ قزل ئينترناتسييانالیُ، يه عنی ئوُيشمالاریُ.

**прафинтирин** – прафсаюзларның бөтен дөнья күләмендәге кызыл интернационалы, ягъни оешмалары.

**پراكات** پراكاتقا ئالو توُتب توُررعا ياكی ئشله ب توُررعا ئالو.

**пракат** – пракатка алу – тотып торырга яки эшләп торырга алу.

Мисаллардан күренгәнчә, бу сүзлек, һичшиксез, чит тел сүзләре сүзлеге, әмма анда әлеге сүзләрнең чыганак теле күрсәтелмәгән. Кагыйдә буларак, алар барысы да – рус теле аша кергән лексемалар.

1929 елда махсус керәшеннәр өчен әдәби телдә кулланылган гарәп, фарсы сүзләрен һәм хәтта сирәк кенә төрки-татар сүзләрен дә эченә алган «Керәшеннәргә татар-гарәп сүзләрен аңлату өчен сүзлек» дөнья күрә [1929-ТГТ_алынм_(л)]. Бу 31 битлек кечкенә хезмәтнең авторы – Г.Е. Беляев. Сүзлек латин графикасында төзелгән. Берничә мисал:

**Qiraətxanə** – Uqu bylməse, citalnə.

**Məcnyn** – Aqldan şaşqan kşe.

**Məƣdən** – Timer, baqbr, çiz işe çirdən cƣa torƣan mitallar.

**Iƣlan** – Bldery (об’явление).

Югарыдагы сүзлекләр – чын мәгънәсендә чит тел сүзләре сүзлекләре тибында төзелгән белешмәлекләр. Алар татар лекси-

кографиясе тарихында үз урыннарын алып тора. Ләкин графика алмашыну һәм шактый озак вакыт үтү сәбәпле, аларның актуальлекләрен югалтуларын танырга мәҗбүрбез. Мондый типтагы сүзлекләр башка төзелмәгән.

Совет чорында һәм Совет чорыннан соң кабат нәшер ителеп һаман да актуальлеген җуймаган К. Хәмзин, М. Мәхмүтов һәм Г. Сәйфуллиннарның «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»нә (1965, 1993, 2018) XIII гасыр шагыйре Кол Галидән башлап хәзерге чор әдипләренең әсәрләреннән, шулай ук төрле дәреслекләрдән, элекке чор вакытлы матбугат битләреннән тупланган сүзләр алынган [1965-ГФТР_алынм_(1, г, р); 1993-ТР_алынм_I_(2, г, р); 1993-ТР_алынм_II_(2, г, р); 2018-ТР_алынм_(3, г, р)]. Бу шактый тулы белешмәлек гарәп һәм фарсы телләреннән кереп, иске яки хәзерге татар телендә кулланышта йөргән сүзләрне чагылдыра. Сүзлекнең баш сүзләре гамәлдәге язу белән алфавит тәртибендә бирелгән, шул ук вакытта гарәпчә һәм фарсыча язылышлары да күрсәтелгән, сүзнең татарча һәм русча эквивалентлары китерелгән (Сәфәров, 2019: 234). Берничә мисал:

| | |
|---|---|
| **Вөруд** ورود *м. I.* 1) Килү, ирешү, килеп җитү. 2) Терлекләргә су эчерә торган урын. | *м. I.* 1) Прибытие, приход. 2) Водопой. |
| **Казый** قاضی *сф.* Хөкем итүче, судья. | *пр. д.* Судья, кадий. |
| **Тәкәллеф*** تکلف *м. V.* көнкүрештә, эштә табигыйлектән үтеп, күрсәтү өчен көчләнеп эшләү, ясалмалык, кылану, тартыну. *Ул бер дә тәкәллефсез генә үзенең хаҗ җөббәсе белән вокзал идәненә килеп утырды.* (М. Гал.) | *м. V.* Деланность, искусственность, натянутость, стеснение, церемония. |

Җ. Зәйнуллинның күләме ягыннан зур булмаган «Шәрык алынмалары сүзлеге» 1994 елда нәшер ителгән [1994-ГФТ_алынм]. Анда шулай ук татар телендәге гарәп һәм фарсы сүзләре барланган, ләкин сүзләрнең оригинал телдәге язылышы күрсәтелмәгән:

**Гайре рәсми** *г.* Рәсми булмаган, рәсми түгел

**Зир-зөбәр** *ф.* Асты-өскә

**Кабаза** *г.* 1. Кулга төшерү, алу; ия булу; кулдан кысып тоту. 2. Эләктереп алу, хәбес итү, тоткын итү.

Нәтиҗә ясап шуны әйтеп була: хәзерге татар телендәге чит тел берәмлекләрен тулы итеп тасвирлаган чит тел сүзләре сүзлекләре әлегә юк. Татар лексикографиясендә чит тел сүзләре сүзлегенә якын торган чыганакларны алынмалар сүзлеге дип атау практикага кергән. Мондый хезмәтләр арасыннан иң танылган «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»нә авторлар саф алынмаларны да (аларны * билгесе белән күрсәткәннәр), алынма дип әйтерлек булмаган, чит телнеке булуы нык тоелган берәмлекләрне дә кертеп тасвирлаганнар. Бу сүзлекнең гамәлдәге графикада булуы, татар телендә гарәп һәм фарсы сүзләренең һаман да актив кулланылуы мондый төр сүзлекләргә ихтыяҗның зурлыгын күрсәтә. Шул сәбәпле әлеге сүзлек өченче тапкыр кабат басылып чыкты.

## § 16. Ономастик сүзлекләр

Татар теле белемендә ономастик эзләнүләрнең бай тарихы һәм җитди фәнни казанышлары бар. Аларның нәтиҗәсе 2017 елда басылып чыккан «Татар лексикологиясе» хезмәтенең 3 нче томында тирәнтен яктыртылган. Татар телендәге ялгызлык исемнәр теоретик яссылыкта гына өйрәнелеп калмыйча, гамәли яктан да шактый әйләнешкә кертелгәннәр – аларны туплаган сүзлекләрнең булуы моңа дәлил.

Ономастик сүзлекләрдә ялгызлык исемнәрнең мәгънәләре, килеп чыгышлары, норматив кулланылышлары кебек мәгълүматлар теркәлә. Апеллятив лексиканы туплаган сүзлекләрдән аермалы буларак, бу төр сүзлекләр энциклопедик характерда. Ономастик сүзлекләрдә билгеле бер дәрәҗәдә коннотатив һәм лингвомәдәни үзенчәлекләрне берләштергән энциклопедик мәгънә күрсәтерелә. Шулай ук алар лексикографик аппаратның структурасы ягыннан да аерылып торалар. Әлеге сүзлекләрдә лексикографик аппарат гадиләштерелгән формада бирелә, чөнки ялгызлык исемнәрнең барысы да исем сүз төркеменә карый һәм материалның бирелеше дә, күмәклек сүзләрне теркәгән сүзлекләрдән аермалы буларак, нәкъ менә исем сүз төркеменә хас тасвирлаудан гыйбарәт (Сталтмане, 1989:3). Хәзерге лексикографиядә ялгызлык исемнәрне, югарыда атаган үзенчәлекләренә бәйле, гомуми сүзлекләр составына керт-

мәү тенденциясе өстенлек итә. Шуңа карамастан бу төр сүзлекләргә ихтыяҗ гаять дәрәҗәдә зур, чөнки ялгызлык исемнәрнең җәмгыятьтәге урыны һәм әһәмияте бу юнәлештә һәрдаим гамәли ихтыяҗ тудыра.

Татар теленә бәйле ономастик материалны туплап бару тәҗрибәсе күптәннән башлана. Бу җәһәттән махсус циркулярлар, календарь һәм исемлекләрне хасил иткән «Вәгазь намә рисаләсе ирләргә вә хатын-кызларга исемнәре белән бәян ителгәндер» (1846), «Исеме Аллаһе тәгалә әл-хәсәни» (1848), «Аврадии Фәтхия», (1865), «Исем» (1895), Ахун Бендуков «Исем. Балага күркәм исем бирергә киңәш һәм укучы сабыйларга һәдия кылырга муафыйк китап» (1899, 1900), Кәримовлар «Унбер Әхмәт исемнәре» (1914); Шиһабетдин ибне Мелла Габделгазиз ибне Рахматулла «1896 ел календаре», 1897 елда Фәхретдинов тарафыннан төзелгән «Оренбург мөселман диния нәзарәте тарафыннан төрле елларда муллаларга җибәрелгән циркулярлар җыентыгы» кебек материалларны билгеләргә кирәк.

XIX йөз ахырларында И.А. Износков Казан, Лаеш, Мамадыш өязләре авыл исемнәре, татар топонимиясе белән кызыксына башлый. Аның тырышлыгы белән бик күп татар авылларының һәм алар яныннан агып уза торган елга-инешләрнең исемнәре җыелып калган (Износков, 1884; 1885; 1893). И.А. Износков хезмәтләрендә ойконимнарның этимологияләре, төзелеш-ясалыш калыплары анализланган (Татар лексикологиясе, 2017: 172).

Ономастик сүзлекләр төзү тәҗрибәсе К. Насыйри эшчәнлегендә дә урын ала. Аның «Зөя өязе авыллары» хезмәтендә ономастик сүзлекләргә хас булган тәртиптә мәгълүмат тәкъдим ителә: авылларның барлыкка килүе, үсеше, атамаларының килеп чыгышы ачыклана. Һәр авылга бәйле мәгълүмат аерым бер мәкалә буларак формалаштырылган. Авылларга караган эпитафик язмалар, тарихи риваятьләр, кульъязма документлар, шәҗәрә һәм топонимнарны комплексны өйрәнеп, галим 21 авыл тарихына һәм топонимиясенә анализ бирә. Барлык мәкаләләргә хас структура түбәндәгедән гыйбарәт: авыл барлыкка килү вакытына бәйле мәгълүмат, нигез салучы кешегә бәйле мәгълүмат (нигездә, галим анализлаган авылларның зур күпчелеге кеше исеменә нисбәтле барлыкка килгән) һәм аның шәҗәрәсе, географик характеристика, авыл тарихына караган документ, кабер таш язмаларына, башка чыганакларга

күзәтү, кайбер халык авыз иҗаты ядкярләреннән мисаллар китерү, әһәмиятле роль уйнаган микротопонимнар булса, аларны күрсәтү. К. Насыйри тарафыннан тәкъдим ителгән бу алым хәзерге көндә дә ономастик материалны бәян итүдә саклана (Татар лексикологиясе, 2017: 34).

1948 елда Финляндиядә Хәсән Хәмидулланың «Исем көннәре календаре» басылып чыга, автор башка халыкларда булган мондый төр календарьның татарларларда булмавы, яшьләрнең аңа ихтыяҗы зурлыгын ассызыклый. Биредә гарәп һәм латин шрифтында аерым бер көнгә беркетелгән, килеп чыгышлары ягыннан төрки, гарәп һәм фарсы, татар телләренә караган ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре бирелгән (Саттаров, 1970: 64). Бу материал үзенең энциклопедик характерда булуы белән ялгызлык исемнәре сүзлекләренә охшаш.

Тулаем лексикографик кануннарга туры килгән сүзлекләр татар телендә XX гасыр урталарыннан басыла башлый. Татар лексикографиясенә караган мондый сүзлекләр, тасвирлана торган материалның нинди ономастик категориягә каравына бәйле, төп ике төргә бүленә: антропонимик сүзлекләр һәм топонимик сүзлекләр.

**Антропонимик сүзлекләр**

Телнең антропонимнар җыелмасы «антропонимия» (антропонимикон) термины белән атап йөртелә. Антропонимик лексикография антропонимика фәненең гамәли төре кысасында карала һәм ул телдә кулланылган антропонимик берәмлекләрне (кеше исемнәре, ата исеме, фамилия, кушамат, тәхәллүс) туплау, антропонимик сүзлекләр төзү мәсьәләләрен тикшерә.

Татар тел белемендә антропонимик сүзлекләрдән киң таралыш тапканы – кеше исемнәре сүзлекләре. Гадәттә, бу төр сүзлекләр мәкаләсендә кеше исеменең мәгънәсенә аңлатма бирелә, исемнең килеп чыгышы турында мәгълүмат китерелә, якынча кулланылыш чоры, мәсәлән, неологизм, искергән исем һ.б., ир-ат яки хатын-кыз исеме булуы күрсәтелә. Бер төркем берәмлекләрдә исем составындагы морфемалар, кушма исем компонентлары, алар катнашында ясалган исем төрләре билгеләнә. Аерым исемнәрнең синонимы, антонимы бирелә. Икетелле сүзлекләр булса, русча эквиваленты яки язылышы аныклана.

Татар лексикографиясендә бу төр сүзлекләрнең төзелә башлавы күренекле галим Г.Ф. Саттаров эшчәнлеге белән бәйле. Аның

тарафыннан төзелгән беренче антропонимик сүзлек – «Татар исемнәре сүзлеге» [1981-Т_антропон] – 1981 елда басылып чыга. Сүзлек татарлар яшәгән төрле төбәкләрдән, рәсми документлардан, вакытлы матбугат чыганакларыннан, ЗАГС архивларыннан тупланган 50 меңнән артык карточка нигезендә төзелә.

Әлеге сүзлек Ватан ономастика фәнендә һәм тюркологиядә киң таралыш таба һәм югары бәяләүгә ирешә. Сүзлек басылып чыккач, аның турында мәгълүмат күп кенә ономастик белешмәлекләргә кертелә, өземтәләр исә күренекле ономатологларның (мәсәлән, В.Э. Сталтмане, А.В. Суперанская һ.б.) теоретик һәм гамәли аспекттагы хезмәтләрендә урын ала.

Гомуми күләме 256 битне тәшкил иткән әлеге хезмәт 6 өлештән тора: М.З. Зәкиев тарафыннан тәкъдим ителгән кереш сүз («Исеме җисеменә туры килә»); кереш; сүзлекнең төзелеш принциплары; шартлы кыскартылмалар һәм шартлы билгеләр; сүзлек үзе; сүзлектә файдаланылган төп фәнни чыганаклар. Сүзлектә 10 меңгә якын (төрләнешләре белән 15 меңнән артык) кеше исеме тупланган һәм аларның этимологияләре бирелгән. Исемнәргә этимологик аңлатма бирү барышында Г. Саттаров кеше исемнәрен ясый торган кушымчаларның да мәгънәләрен ача, ләкин ул кушымчаларның тулы бер система төзүләрен аерым алып тикшерүне максат итеп куймый. Автор бу сүзлекне ата-аналарга балаларына исем сайлауда, ЗАГС һәм паспорт өстәле хезмәткәрләренә татар исем-фамилияләрен рәсми документларга дөрес теркәүдә файдалы булыр дип искәртеп үтә. Татар исемнәренең килеп чыгышы, лексик мәгънәсе, төзелеш-ясалыш һәм таралыш-кулланылыш үзенчәлекләре, исем кушу мотивлары, йолалары, үсеш тарихы һәм динамикасы һ.б. яклары белән кызыксынучы киң катлам укучылары сүзлектән үзенә күп кенә мәгълүмат таба ала.

Хезмәтнең әһәмиятле ягы булып биредә хәзерге татар исемнәренең борынгыдан алып бүгенгәчә сакланып, тулылынып килгән этнолингвистик катламнары анализлана.

Сүзлек гамәли өлешенең төзелешенә килсәк, биредә ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре алфавит тәртибендә бергә урнаштырылган. Һәр исем зур хәрефләр белән бирелеп, аның янына ир-ат яки хатын-кыз исеме булуы, чыганагы, этимологиясенә аңлатма тәкъдим ителә. Ир-ат исеме генә булып йөри торган исемнән соң *и.-а.* (ир-ат исеме), хатын-кыз исеме генә булып йөри торган исемнән соң

*х.-к.* (хатын-кыз исеме) дигән шартлы кыскартылма билгеләнгән, мәсәлән,

**АЗАЛИЯ** *х.-к. (лат.; бот.)* Эре чәчәкле декоратив үсемлек атамасы.

**ДАБИР** *и.-а. (ф.)* Җитәкче, акыл бирүче, укытучы, тәрбияче.

Әгәр исемнең төрдәше булса, әлеге төрдәш исемгә юнәлтелә. Мәсәлән, **АБАЗ** *и.-а. к.* Габбас.

*Ясалмалары:* Аббаз, Аваз, Абас, Аппас, Апас.

Сүзлектә бер лексик мәгънәгә ия ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре « – » (сызык) аша язылып, бергә теркәлгән: **МАНСУР – МАНСУРА ~МАНСУРИЯ** *и.-а.* һәм *х.-к. (г.)* Җиңүче, өстен чыгучы. Синонимы: Зөфәр.

Автор кушма исемнәр компонентларының килеп чыгышын аерым күрсәтеп бара: **МАҺРУЙБИКӘ** *х.-к. (ф.-төр.-т.)* Ай йөзле бикә.

Г.Ф. Саттаровның әлеге сүзлеге – татар исемнәре турында мөмкин кадәр киң колачлы мәгълүмат бирүгә йөз тотып төзелгән сүзлек. Биредә автор исемнәрнең норматив вариантларын гына түгел, бәлки диалекталь вариантларны да, телебездә яңалардан саналган исемнәрне дә, мәгънәләрен төгәл генә аңлатып булмаганда, мөмкин саналган барлык мәгънәләрне дә җыйнап бирә, исемнең яки аның нигезендә яткан апеллятив сүзнең мәгънәсен аңлатуда төрле карашлар булса, аларга да сылтама китерелә. Иллюстрация буларак, берничә үрнәккә тукталыйк:

**МАРСЕЛЬ – МАРСЕЛӘ** *и.-а.* һәм *х.-к. (гол.-фр.; неол.)* Марска (к.) мөнәсәбәтле. Франция эшчеләр хәрәкәтенең күренекле җитәкчеләреннән берсе Марсель Кашен исеме. Утызынчы еллардан башлап аның хөрмәтенә кушыла торган исемнәр. Д.в.: Марсил – Марсилә.

**ТӘНЗИЛ – ТӘНЗИЛӘ** *и.-а.* һәм *х.-к. (г.)* 1. Югарыдан иңдерү. 2. Зиһен ачылу, рухи ачылыш.

**АБЫЗ** *и.-а. (бор. төр.-т. яки г.)* 1. Тәҗрибәле, дәрәҗәле, өлкән ага; аксакал, нәсел башлыгы; җыен атасы. 2. Абыз исеме гарәп теленнән кергән Хафиз *(к.)* исеменнән барлыкка килгән дигән караш та бар. 3. Т. Жанузаков Абыз исеме гарәби чыгышлы, «саклаучы, яклаучы» мәгънәсен аңлата дип саный. Исем компоненты.

Г.Ф. Саттаровның «Татар исемнәре сүзлеге» татар лексикографиясе өчен зур яңалык буларак кабул ителә һәм, ихтыяҗ зур булу

сәбәпле, алдагы елларда яңартылып, төрле форматларда кабат-кабат бастырыла.

Галимнең икенче сүзлеге – «Раннур» нәшриятында чыккан **«Татар исемнәре ни сөйли? (Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге)»** [1998-ТР_антропон_ аңлат]. Аның төзелеше алдагы сүзлек белән охшаш, ләкин аермалы яклары да бар: исемнәрнең саны 15 меңгә җиткерелү (төрдәшләре белән 20 меңнән артык), ир-ат һәм хатын-кыз исемнәренең аерып бирелүе, һәрбер исемнең русча эквиваленты тәкъдим ителү һ.б. Күзаллау өчен берничә мисал:

ИЛҺАМ *(г.)* | Дәрт, иҗади дәрт, рухлану, илһам. Исем компоненты. | ИЛЬГАМ

ИРЕК *(т.; неол.)* | Азатлык, хөрлек, ирек. | ИРЕК

НАДИРХАН *(г.-төр.-тат.)* | Надир *(к.)* + хан *(к.)*. Тиңдәшсез хан | НАДИРХАН

ГАЙШӘ *(г.)* | Тере, яшәүчән, яшәүче. Д.в.: Гайши, Гайшук, Әйшә, Айшә, Айшук. *Исем компоненты.* | ГАЙША

Сүзлекнең тагын бер үзенчәлекле ягы буларак, редактор Ранис Газизов әзерләгән, өченче бүлек буларак аерып чыгарылган «Татар халкының исем кушуга бәйле гореф-гадәтләре һәм йолалары» бүлеген атарга кирәк.

2006 елда Татарстан китап нәшриятында Г.Ф. Саттаров, Р.Г. Әхмәтьянов, Ф.Ә. Ганиев, И.А. Абдуллин, Г.С. Сабирҗанов, К.Р. Галиуллин, Г.Р. Галиуллиналар авторлыгында **«Татарско-русский словарь личных имен и фамилий» / «Татарча-русча кеше исемнәре һәм фамилияләр сүзлеге»** (375 бит) [2006-ТР_антропон] дөнья күрде. Әйтергә кирәк, әлеге сүзлек – татар тел белемендә антропонимик берәмлекләрне туплаган беренче орфографик сүзлек.

Аңлатмада күрсәтелгәнчә, сүзлек паспорт һәм ЗАГС идарәләре хезмәткәрләренә, төрле дәүләт оешмаларына, массакүләм мәгълүмат чараларына татар кеше исемнәре һәм фамилияләренең орфографиясеннән гамәли кулланма буларак тәкъдим ителә һәм үз эченә якынча 7000 берәмлекне берләштерә.

Сүзлек 7 өлештән тора: кереш, сүзлекне төзү принциплары, рус алфавиты, татар алфавиты, ир-ат исемнәре, хатын-кыз исемнәре, файдаланылган әдәбият исемлеге.

Сүзлек башында авторлар 28 пункттан торган сүзлекнең төзелеш принципларын тәгаенлиләр, татар исемнәрен рус телендә биргәндә күзәтелә торган төрлелекне тәртипкә салу үзенчәлекләрен, транслитерация кагыйдәләрен аңлаталар. Төрлелек тудырган һәрбер хәрефнең рус теленә нинди хәреф белән бирелергә тиешлеген, индивидуаль язылыш очракларын, ата исемен һәм фамилияләр ясый торган кушымчаларның ялгану үзенчәлекләрен, телебездә күптән урнашып, традициягә әверелгән исем вариантларының норма буларак кабул ителгән очракларын күрсәтәләр. Кайберләренә тукталып үтик, мәсәлән, нечкә нигезле татар исемнәренең уртасында, яки ахырында килгән ә хәрефе л хәрефеннән соң я хәрефе белән бирелә: Гөләндәм – Гуляндам, Ләбиб – Лябиб; Фәләх – Фалях, Вәсилә – Василя, Тәнзилә – Танзиля. Исем уртасында килгән ә хәрефе л хәрефеннән соң килеп, ә хәрефеннән соң й хәрефе килсә, ә хәрефе рус телендә е белән белдерелә: Зөләйха – Зулейха, Ләйсән – Лейсан, Ләйлә – Лейля һ.б. [2006-ТР_антропон: 16].

Сүзлекнең 1 нче графасында татарча ир-ат исеме бирелә, 2 нче графада – аның рус телендә бирелеше; 3 нче – 4 нче графаларда русча ирләр һәм хатын-кызлар отчествосы китерелә; 5 – татарча ирләр фамилиясе; 6 – русча ирләр фамилиясе; 7 – татарча хатын-кызлар фамилиясе, 8 нче графада русча хатын-кызлар фамилиясе күрсәтелә.

Мәсәлән,

БӘХТИЯР | Бахтияр | Бахтиярович | Бахтияровна | Бәхтияров | Бахтияров | Бәхтиярова | Бахтиярова

ИЛФАТ | Ильфат | Ильфатович | Ильфатовна | Илфатов | Ильфатов | Илфатова | Ильфатова

Сүзлекнең хатын-кызлар исеменә караган мөстәкыйль бүлегендә 1 нче графада татарча хатын-кыз исеме бирелә, ә 2 нче графада аның рус телендә бирелешә күрсәтелә:

АЛСУ | Алсу

ГӨЛФИЯ | Гульфия

ҖАМАЛ | Джамал

ФӘҺИМӘ | Фагима

Әйтергә кирәк, әлеге сүзлек бүгенге көндә дә антропонимик берәмлекләрне теркәүдә төп норматив сүзлек булып тора. Әлбәттә, мондый төр сүзлек төзүдә тиешле тәҗрибә булмау, татар исемнәренең язылышында киң вариантлылык күзәтелү, исем кушканда

барлыкка килгән индивидуаль үзенчәлекләр (мәсәлән, ата-аналар теләге һ.б.) сүзлекнең камиллегенә дә тәэсир итә. Мисал өчен, сүзлектә татарлар арасында шактый актив кулланылышта йөргән ата исемен улы, кызы сүзләре белән язу калыбы бирелми. Фонетик вариантлардан татар халкы арасында киңрәк кулланылыштагы вариант күрсәтелмичә, сирәгрәк кулланыштагы исем норма буларак тәкъдим ителә, мәсәлән, сүзлектә Нәргизә исеме бирелми, норматив вариант буларак, Наргизә исеме теркәлгән. Җ хәрефен транслитерацияләү буенча да төгәл аңлатма сорала кебек:

Татар исемнәрендәге һәм фамилияләрендәге җ хәрефе рус телендә өч төрле юл белән языла: 1) *дж* хәрефләре белән: *Җәлил – Джалиль, Җәүдәт – Джаудат, Галимҗан – Галимджан, Хуҗа – Ходжа (Ходжа Насретдин), Хаҗи – Хаджи (Хаджимурат)*; 2) хатын-кыз исемнәрендәге җ хәрефе рус телендә ж хәрефе белән дә бирелергә мөмкин: *Мөнҗия – Мунжия, Энҗе – Энже, Хаҗирә – Хажира*; 3) исемнәр ясаганда, *җ* хәрефе рус телендә *з* белән дә күрсәтелергә мөмкин: *Хаҗинур – Хазинур, Галимҗан – Галимзян* [2006-ТР_антропон: 17-18].

Күрсәтелгәннәргә карамастан, «Татарско-русский словарь личных имен и фамилий» / «Татарча-русча кеше исемнәре һәм фамилияләр сүзлеге» татар тел белеме, татар халкы өчен гаять дәрәҗәдә әһәмиятле хезмәт булып тора. Татар телендәге кеше исемнәре һәм фамилияләренең язылышы, аларны рус телендә бирүне мөмкин кадәр тулырак унификацияләү бурычы әлеге хезмәттә хәл ителгән дияргә була.

Татар тел белемендә антропонимик сүзлекләр төзү традициясе дәвам итә. Г.Ф. Саттаровның «**Татар исемнәре: аңлатмалы сүзлек**» дип аталган зур күләмле хезмәте басмага әзерләнә. Әлеге сүзлекне галимнең алдагы еллардагы басмаларының тулыландырылган варианты дип билгеләргә кирәк.

**Топонимик сүзлекләр**

Топонимик сүзлекләрдә географик атамалар турында тарихи-этимологик характеристика, топообъект, аның тарихы турында өстәмә мәгълүмат бирелә (Сталтмане, 1989: 78). Бу төр сүзлекләр өчен материал буларак топографик һәм микротопонимик лексика тупланган төрле реестрлар хезмәт итә. Татар теленә караган топонимик сүзлекләрдә географик реалийлар турында характеристика, теге яки бу атамаларның килеп чыгышы турында мәгълүмат ките-

релә. Татар тел белемендә мондый сүзлекләр XX гасырның икенче яртысында дөнья күрә башлый.

Шундыйлардан Ф.Г. Гарипованың «Татарстан гидронимнары сүзлеге»н [1984-1990-Т_гидрон_I-II] атарга кирәк. Әлеге сүзлек 1984 һәм 1990 елларда ике китап булып нәшер ителде. Соңрак әлеге хезмәт авторның зур күләмле «Татар топонимнары сүзлеге»н әзерләүдә дә җирлек булып тора. Анда 3200 чамасы елга, күл, чишмәләр һәм сазлыклар атамасы теркәлгән. Материал Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәрләренең 1972–1983 елларда Татарстан Республикасы Кама алды һәм Кама аръягы авылларына экспедициясе вакытында җыелган материалларга нигезләнеп эшләнә. Беренче китапның фәнни редакторы – Г.Ф. Саттаров, икенчесенеке – М.З. Зәкиев.

Сүзлектә гидронимик атамалар елгалар, инешләр, чишмәләр, күлләр, сазлыклар, буалар, коелар кебек бүлекләргә берләштерелеп, һәр төркемгә керә торган атамалар гамәлдәге татар алфавиты тәртибендә бирелә. Файдаланылган әдәбият исемлеге белән бергә, информаторлар исемлеге дә теркәлә.

Башта су чыганаклары атамаларының халык телендә кулланылыш формасы күрсәтелә. Атамаларның фонетик вариантлары алдыннан ике авыш сызык // билгесе, вариантлары арасына бер сызык / билгесе куелган. Атамадан соң гидронимик объектларның кайда урнашканлыгы, кечерәк елгаларның кайсы елга бассейнында урнашулары турында мәгълүматлар бирелә. Бер исемдә берничә атама булса, аларның адресларын күрсәткәндә, алларына 1, 2, 3, 4, 5 һ. б. саннары куелган. Адрестан соң атамаларның тарихи чыганакларда күрсәтелгән исеме, вариантлары тәкъдим ителә. Шуннан соң гидронимнарның мәгънәләре яки бирелү мотивлары турында аңлатма китерелә.

Материалны тулырак күзаллау өчен, кайбер мисалларга тукталып үтик:

**Абдулла йылгасы** / Йорт елгасы // Аптулла, Аптылла җылгасы / Җырт җылгасы – *Кесмәс* елг. бассейны (Сеҗе а., Арча р.): к. *Абдулла йылгасы чишмәсе* [1984-1990-Т_гидрон_I: 17].

**Коңгыр күл** – 1. *Олы Чирмешән* елг. бассейны (Киекле а., Октябрь р.). 2. *Ык елг.* бассейны (Яңа Әпсәләм а., Баулы р.) [1984-1990-Т_гидрон_I: 195].

**Айукүдергән йылгасы** // Айукүдергән җылгасы – *Тымбы* суы кушылдыгы (Айукүдергән а., Апас р.). Бу су ярына Аюкүдергән авылы урнашкан. *Кутурган* – елга (Артемьев, 1866, 02) [1984-1990-Т_гидрон_II: 17].

**Дегет базы чишмәсе** – 1. *Шушма* елг. бассейны (Бәркәтә а., Чирмешән р.). 2. *Шөгер* елг. бассейны (Иске Шөгер а., Лениногорск р.) [1984-1990-Т_гидрон_II: 53].

Әлеге сүзлек ономастика фәне өчен генә түгел, диалектология өчен дә гаять әһәмиятле, чөнки материаллар бирелеше халыкның сөйләм теле үзенчәлекләрен саклап тәкъдим ителә, атаманың, әгәр дә сөйләм телендә күзәтелсә, фонетик һәм башка вариантлары да бирелеп барыла.

1992–1993 елларда Ф.Г. Гарипованың ике китап булып **«Татар микротопонимнары сүзлеге»** [1992-1993-Т_ топон] басылып чыга. Биредә 4000 гә якын микротопоним теркәлгән. Сүзлек телчеләр, тарихчылар, географлар, укытучылар, студентлар, укучылар һәм, гомумән, киң катлау җәмәгатьчелек өчен чыгарыла. Сүзлекнең төзелеше түбәндәгедән гыйбарәт: сүзлекнең башында урнаштырылган кереш, сүзлекнең төзелеш принциплары, сүзлектә кулланылган транскрипцион билгеләргә аңлатма, шартлы кыскартылмалар һәм шартлы билгеләр, сүзлек үзе, кушымта һәм сүзлектә файдаланган төп фәнни чыганаклар.

Билгеле булганча, микротопонимнар составына вак географик берәмлек атамалары: урман, алан, тау-калкулык, юл, болын, кыр, урам, кечкенә сазлыклар һәм башка исемнәр керә. Сүзлектә топоним күрсәтелгәннән соң, аның кайда урнашуы, авылы, районы, чыганак авторы (информант) һәм елы күрсәтелгән. Мәсәлән,

Чик чокыры // Чик чыгыры – Бәркәтә а., Чирмешән р. Коры чокыр исеме. Информант – Фәхретдинов Н. Тэ – 1977.

Алан сырнасы – Мөрәле а., Арча р. Алан исеме. Информант – Мөсалим абый. Та – 1972.

Алачык – Тимершык а., Саба р. Урын исеме. Информант – Якупов К. Тэ – 1974.

Әлеге ике китапның төзелеш принциплары ягыннан бер-берсеннән артык аермалары юк. Ике сүзлектә дә топонимик атамалар алфавит тәртибендә бирелгән, ягьни беренче кисәк сүзлекнең башы, икенче кисәк исә ахыры буларак бармый, бәлки икесе дә

тулы сүзлек булып торалар. 1993 елда чыккан икенче китап тулылындырылган вариант хасил итә.

Сүзлектә кулланылган транскрипцион билгеләр арасында да артык зур аермалар юк. *Я, ю, е* хәрефләре урынына *йа, йу, йы/йе* билгеләре алына, сакау *«з»* урынына *d* билгесе кулланыла, техник сәбәпләр аркасында *къ, гъ* авазлары транскрипциядә күрсәтелми. 1993 елгы хезмәттә *w* авазы гына өстәлгән, *аңа ирен-ирен өрелмәле тартык аваз билгесе* дип аңлатма бирелә. Сүзләрне әйтелешкә якынайтып бирү үзенчәлеге Ф.Г. Гарипованың барлык сүзлекләрендә диярлек күзәтелә. Кыскартылмаларда исә, икенче китапта бистәне белдерү өчен *«б»* кыкартылмасы кертелгән.

2010 нчы елда Ф.Г. Гарипова «**Татар топонимнары сүзлеге»**н [2010-Т_ топоним] бастырып чыгара. Гомуми күләме 679 битлек әлеге хезмәттә якынча 19 000 берәмлек теркәлгән. Төзелешенә килсәк, сүзлектә урын алган атамалар татар алфавиты тәртибендә урнаштырыла. Иң беренче географик атамаларның халык телендә кулланылыш формасы бирелә. Атамаларның фонетик вариантлары алдыннан ике авыш сызык (//) билгесе , вариантлары арасына (/) билгесе куела. Атамалардан соң ул географик берәмлекләрнең кайда урнашканлыгы (адреслары), елгаларның кайсы кушылдыклары булулары турында мәгълүматлар китерелә. Бер исемдәге атамалар берничә булса, аларның адресларын күрсәткәндә, алларына 1, 2, 3 һ.б. саннары куела. Адрестан соң атамаларның тарихи чыганакларда күрсәтелгән исеме, исем вариантлары урнаштырыла. Автор искәртүенчә, кайбер авыл атамаларының язылышы халык әйткәнчә бирелә, аерым атамаларның язылышы бердәйләштерелә [2010-Т_ топоним: 14]. Мәсәлән, Авыл йырмагы // **Авыл җырмагы** – *Гөбенә* суы кушылдыгы (Шуширмә а., Апас р.)

**Бикчәнтәй чишмәсе** // Бикчәнтәй шишмәсе – Агыйдел елг. бассейны (Урдалы а., Лениногорск р.)

**Төймә күле** // Тимә күле – 1. *Сәрдә* суы бассейны (Түбән Сәрдә а., Арча р.). 2. *Шәмәк* елг. бассейны (Ташлы Кавал а., Биектау р.).

Автор сирәк очрый торган атамаларны тасвирлаганда, информант турында да мәгълүмат биреп үтә, мәсәлән: **Төкәй тавы** – Иске Байсар а., Актаныш р. Тау атамасы. Информант – Хәйретдин абый [2010-Т_ топон: 546].

**Төпалан аланы** // Төбалан аланы – Бурмәт а., Нурлат р. Алан атамасы. Информант – Галиулла абый [2010-Т_ топон: 547].

Ф.Г. Гарипованың топонимия өлкәсендәге эшчәнлеге, аеруча аның тарафыннан әзерләнгән сүзлекләр татар ономастикасы фәненең җитди казанышларын дәлилли торган иң күренекле күрсәткечләрдән санала.

Топонимик материалны туплап биргән белешмәлекләр дә ономастик сүзлекләр рәтендә каралырга хаклы. Шуларның берничәсенә тукталып үтик.

1997 елда Татарстан Фәннәр академиясе академигы М.Х. Хәсәнов редакторлыгында «Населенные пункты Республики Татарстан. Краткий справочник» [1997-Р_ топон] дөнья күрде. Гомуми күләме – 390 бит. Татар энциклопедик сүзлегенең нигезен тәшкил иткән материаллар буенча эшләнгән әлеге белешмәдә Татарстандагы барлык торак пункт атамалары районлап урын алган, аларга энциклопедик характердагы мәгълүмат китерелгән: административ һәм географик урыны, барлыкка килү вакыты, халык саны, хуҗалык эшчәнлеге һ.б.

Белешмәдә һәр районның картасы, районга бик кыска гына рәвештә гомуми тасвирлама бирелеп, алга таба бирегә кергән торак пункт атамалары алфавит тәртибендә урнаштырылган, татар торак пункт атамаларының татарча атамалары җәяләр эчендә күрсәтелгән:

**БИКТОВО** (Биектау), село, на р. Мувижа (правый приток р. Иж), в 18 км к Ю. от Агрыза. В 1992 – 220 жит. (татары). Основано в 16 в. Родился языковед М.Х. Курбангалиев. Полеводство, мясо-мол. скотоводство [1997-Р_ топон: 11].

Ономастика фәне өчен тагын бер әһәмиятле чыганак – 2016 елда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты коллективы тарафыннан әзерләнгән 320 битлек «Исчезнувшие населенные пункты Республики Татарстан: справочник» хезмәте [2016-Р_ топон]. XX гасырда шактый гына авылларның юкка чыгуы сәбәпле, тарихи яссылыкта гаять әһәмиятле атамалар да әкренләп юкка чыга. Белгәнебезчә, ономастик берәмлекләр үзләрендә тел үзенчәлекләрен генә түгел, халыкның тарихы, мәдәнияте турында да мәгълүмат саклыйлар. Аларны теркәп бару күпкырлы тарихны өйрәнүгә дә этәргеч була. Әлеге хезмәтнең әһәмиятле ягы да шуннан гыйбарәт.

Белешмәлекнең фәнни-редакцион коллегиясе И.А. Гыйләҗев (рәис), Р.В. Шәйдуллин (баш редактор), Л.М. Айнетдинова, Р.Р. Сәләхиев, М.З. Хәбибуллин, Б.Л. Хәмидуллин, Ф.Г. Ялалов. Авторлар коллективы: Р.В. Шәйдуллин, Б.И. Сибгатов, Л.М. Сәхәүова.

Әлеге проектны тормышка ашыру барышында 1930–1970 елларда юкка чыккан 1200 торак пункт ачыклана, аларның урыны, халкы, юкка чыгу сәбәпләре һәм вакыты күрсәтелә. Материаллар – 1930–2010 еллар аралыгына караган архив, статистик-демографик, кануни, нормататив, туган як, картографик чыганаклар. Татарстан Республикасы милли архивы документларына, вакытлы матбугат, фәннибелешмәлекләргә, фәнни-популяр хезмәтләргә нигезләнеп тупланган [2016-Р_ топон: 7].

Белешмәлек алфавит тәртибендә рус телендә төзелгән, атамаларга басым куелган, җәяләр эчендә татарлар яшәгән торак пунктларның татарча атамалары бирелгән, ахырда югалган торак пунктларның районнарга берләштерелгән алфавит тәртибендәге исемлеге китерелгән.

**АПТИКА́Ш** (Әптекәш), населѐнный пункт.

Находился на территории современного Ютазинского района Республики Татарстан, в 23 км от железнодорожной станции Уруссу. С 1930 в составе Байряки–Тамакского сельсовета Тумутукского района, с 1935 –Байряки-Тамакского сельсовета Ютазинского района, с 1963 – Байряки-Тамакского сельсовета Бугульминского района, с 1966 – Байряки-Тамакского сельсовета Бавлинского района. Население – 57 чел. (1930, татары), 213 чел. (1939, татары), 113 чел. (1963, татары). В справочных изданиях с конца 1960-х гг. не упоминается [2016-Р_ топон: 18].

**ТАТА́РСКАЯ АЗМЕ́ТЬ** (Татар Әҗмәте), населѐнный пункт.

Находился на территории современного Актанышского района Республики Татарстан. В справочных изданиях не упоминается [2016-Р_ топон: 251].

Белешмәлекнең бер үзенчәлекле ягы: татарча атамалар булып та, халкы башка милләт вәкилләре булганда яки милли составы күрсәтелмәгәндә, татарча атамалар бирелми, мәсәлән,

**НИ́ЖНИЙ ТАКИРМЕ́Н**, село.

Находилось на территории современного Мензелинского района Республики Татарстан. С 1930 в составе Ямаковского

сельсовета Мензелинского района. Население — 192 чел. (1930, русские), 62 чел. (1939, русские). В справочных изданиях с конца 1940-х гг. не упоминается.

**НИ́ЖНИЙ ТАКТАЛАЧУ́К,** деревня.

Находилась на территории современного Актанышского района Республики Татарстан. Население —213 чел. (1963). Ликвидирована в период борьбы с неперспективными деревнями, население переселено в с.Такталачук Актанышского района [2016-Р_ топон: 165].

Соңгы елларда электрон каталоглар, сүзлекләр төзү эше бик җанланды, ономастик материалларны да бу яктан системалаштыру эше шактый актив бара. Шундыйлардан төзелә башлаган **«Татарстан Республикасы топонимнары каталогы»**н [2016-РТ_ топон] аерым билгеләп үтү кирәк. Географик аатмалар каталогы топонимиканың төрле аспектларын берләштергән комплекслы сүзлек буларак күзаллана. Ул үз эчендә аңлатмалы, энциклопедик, тарихи-этимологик һәм норматив сүзлек үзенчәлекләрен берләштерә (Хисамов, 2018: 259). Төзүчеләр күрсәткәнчә, каталог Татарстан Республикасындагы барлык географик атамаларны (ойконим, гидроним, ороним һәм микротопоним) берләштерәчәк (https://toponym.antat.ru/articles). Топонимнар буенча материаллар сүзлек мәкаләләре формасында тәкъдим ителеп, үз эченә 24 төрле мәгълүматны туплый, биредә топонимның төре, рус һәм татар телләрендә бирелеше, әйтелеше, атаманың вариантлары, торак пунктның урнашу урыны, танылган шәхесләре, географик картасы, координатлары, атаманың этимологиясе, тарихы, атама килеп чыгышына бәйле легендалар һ.б. мәгълүмат бирeләчәк. Эшнең башлангыч этабында алфавит тәртибенә салынган һәм топонимик берәмлекнең төренә аерылган 3200 берәмлек урын алса, алга таба 7000 берәмлекнең сүзлек мәкаләсен күрергә мөмкин булыр дип фаразлана. Хәзергә төп материал рус телендә бирелә, татар телендәге эчтәлеген тулылындыру эше бара. Каталогның төзелеше түбәндәгечә:

**Большая Елга**
**Тип топонима** Топоним
**Вид топонима** Ойконим
**Географический объект** Село
**На русском языке:** Большая Елга

**На татарском языке:** Олы Елга

**Местоположение** Расположена на р. Шуранка, в 21 км к западу от с. Рыбная Слобода.

**Население** Общая численность: 852 (2010 г.). Национальный состав: татары.

**Инфраструктура** В деревне имеется средняя школа, дом культуры, библиотека.

**Достопримечательности** Здание мечети (памятник архитектуры).

**Экономическое значение** Основное занятие населения – полеводство, скотоводство.

**Географическое положение** Расположена на р. Шуранка, в 21 км к западу от с. Рыбная Слобода.

**История** Известна с периода Казанского ханства. В XVIII – первой половине XIX вв. жители относились к категории государственных крестьян. Занимались земледелием, разведением скота, портняжным промыслом. В документах 1859 г. в деревне упоминалась мечеть. В 1879 г. для неё было построено новое здание (памятник архитектуры). В 1908 г. в деревне открылась вторая мечеть. При мечетях имелись мектебы. В начале XX в. в Б.Е. функционировали кузница и 5 мелочных лавок. До 1920 г. деревня входила в Масловскую волость Лаишевского уезда Казанской губернии. С 1920 г. в составе Лаишевского кантона ТАССР. С 14.02.1927 г. в Рыбно-Слободском, с 01.02.1963 г. в Пестречинском, с 12.01.1965 г. в Рыбно-Слободском районах.

**Этимология названия** Топоним произошел от татарского слова «олы» (большой) и гидронимического термина «елга» (река).

**Источники**

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. I том (А – Л). – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. – 543 б. Саттаров Г.Ф. Татар топонимиясе. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1998. – 438 б. Татарская энциклопедия: В 6 т. / Гл. ред. М.Х. Хасанов, отв. ред. Г. С. Сабирзянов. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2002. – Т. 1: А–В. – 672 с. Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз. Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 839 б.

Әлеге электрон каталог тулыландырылып, татар телендә дә эшләнеп беткәч, киң катлам кулланучылар өчен генә түгел, фәнни

эзләнүләр өчен дә кыйммәтле һәм иркен кулланылыштагы хезмәт булачак.

Татар ономастикасы тарихында аерым берәмлекләрне туплаган сүзлекләр белән бергә, теге яки бу төбәкнең тулы ономастик фондын теркәгән хезмәтләр дә бар. Шуларның берсе – 1999 елда ике өлеш булып басылып чыккан Х.Ч. Алишинаның **«Ономастикон сибирских татар»** [1999-Р_I-II_ономас] хезмәте. Фәнни редакторлары – профессорлар Г.Ф. Саттаров (Казан) һәм Н.К. Фролов (Төмән). Беренче өлештә шактый күләмле тарихи, рәсми материаллар нигезендә, Төмән өлкәсе ономастик системасына фәнни күзәтү ясала һәм дүртенче бүлегендә астионим, ойконим, комонимнарның килеп чыгышы, тарихи анализ, урнашу урыны кебек мәгълүматлар китерелә. Атамалар рус телендә бирелеп, бер төркем ономастик берәмлекнең җәяләр эчендә татарча вариантлары да тәкъдим ителә.

Хезмәтнең икенче өлеше, Кушымталар (Приложения) дип аталып, 12 кушымтаны берләштерә. Биредә кыскартылмалар, информантлар исемлеге, архив материаллары исемлеге урын ала. Бишенче – тугызынчы кушымталарда XIX–XX гасырларда себер татарларында кулланылышта йөргән ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре, фамилияләр алфавит тәртибендә урнаштырыла. Унынчы-унберенче кушымталар сүзлек хасил итә. Унынчы кушымтада ойконимнар сүзлеге, унберенче кушымтада исә топонимнар һәм микротопонимнар сүзлеге бирелә. Уникенче кушымтада Төмән өлкәсе көньягы торак пунктлары атамалары исемлеге урын ала. Сүзлектән беркадәр иллюстратив материал:

Старицкие юрты (Үләртеш) – Тм., Тб. р., Бакшеевский с/с [1999-Р_II_ономас: 134]

Цаплыкъ – Тм., Тм. р., Чаплык [1999-Р_II_ономас: 138]

Юршәк – Б. Юршак – Иртышацкие –Тм., Тб. р. [1999-Р_II_ономас: 140]

Кеце Темәкәй оз., Вг., Казанка [1999-Р_II_ономас: 156]

Кызыл цыбык остров, Ял [1999-Р_II_ономас: 160]

Янтыр гүл оз., Ял., Яр [1999-Р_II_ономас: 180]

Сүзлекләрдә этимологик, тарихи, лингвистик тасвирламалар җитеп бетмәсә дә, әлеге хезмәт, себер татарларының тарихи һәм хәзерге ономастиконын күзаллау һәм өйрәнү өчен, кыйммәтле чыганак ролен үти.

Югарыда билгеләгәнчә, күмәклек сүзләрне туплаган төрле типтагы сүзлекләрдә ялгызлык исемнәрен бирергә теләмәү тенденциясе күзәтелсә дә, гамәли максатлардан, аеруча тәрҗемәи сүзлекләрдә ялгызлык исемнәрен ахырга кушымта рәвешендә бирү татар лексикографиясендә шактый еш очрый.

Ялгызлык исемнәренә игътибарның зур булуын күрсәтә торган фактор буларак, телебезнең күмәклек сүзләрен туплаган академик сүзлекләрнең ахырында кушымта буларак урнаштырылган атамаларны да телгә алырга кирәк. Мисал өчен, «Русско-татарский словарь: ок. 47 000 слов = Русча-татарча сүзлек: 47 000 чамасы сүз» хезмәтендә рус һәм татар телләрендә *Географические названия /География атамалар* бүлекчәсе тәкъдим ителә. [1985-РТ_(2): 723-731]

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» ахырында [2005-Т_аңлат] шулай ук *Татарстан Республикасы географик атамалары* исемлеген [2005-Т_аңлат: 812-831] һәм *Татар халкында кеше исемнәре һәм аларның мәгънәләре хакында* бүлекчәсен [2005-Т_аңлат: 832-847] күрергә мөмкин.

Шулай итеп, татар лексикографиясендә ономастик сүзлекләр төзү тарихы чагыштырмача аз вакытны алып торса да, бу берәмлекләрнең төп төрләре буенча билгеле күләмдә лексикографик хезмәтләр инде эшләнгән. Аларның һәм фәнни, һәм гамәли әһәмияте гаять дәрәҗәдә югары. Әмма бу өлкәдә эшлисе эшләрнең дә күп булуын ассызыкларга кирәк. Әйтик, башка төр ономастик берәмлекләр буенча да төрле типтагы сүзлекләр, белешмәлекләр булдыру ихтыяҗы зур. Мондый эшчәнлек алга таба да киң колач алып, татар лексикографиясе тарихында лаеклы урын алыр дигән ышаныч бар.

## § 17. Фразеологик сүзлекләр

Нинди булса да телнең фразеологик сүзлеген төзү иң башта бу тел гыйлемендә фразеология фәненең торышы белән бәйле. Фразеология фәне бүгенге көндә дә күпвакыт сүз барлыгы, аның байлыгы эчендә каралса да, тел тармагы буларак, француз галиме Ш. Балли эшчәнлеге нәтиҗәсендә туа. Татар тел гыйлемендә бу юнәлештәге тикшеренүләрне К. Насыйри исеме белән бәйләргә кирәктер. Фразеология XX гасыр башларында тел гыйлеменең ае-

рым бер тармагы буларак оеша (тулырак *к.*: Татар лексикологиясе I: 192–195).

Фразеологик сүзлекләргә килгәндә, аларны гомуми һәм хосусый төрләргә бүләләр. Гомуми төрдәге фразеологик сүзлекләрдә, нигездә, фразеологик берәмлекләргә аңлатма бирелә һәм кулланылышы күрсәтелә. Хосусый сүзлекләр исә этимологик, синонимик, ике- яки күптелле һ.б. төрдә булырга мөмкиннәр. Татар теленең фразеологик (= әйтелмәләр) сүзлекләре, нигездә, хосусый төргә карый.

**1957 елда** Татарстан китап нәшрияты тарафыннан Л. Җәләй, Н. Борһанова һәм Л. Мәхмүтованың «Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре» дип исемләнгән китабы басылып чыкты; җаваплы мөхәррире – филол. фән. канд. М. Зәкиев [1957-Т_фраз]. Моны, бер дә икеләнмичә, татар теленең беренче фразеологик сүзлеге дип әйтергә мөмкин, чөнки аңарчы чыккан хезмәтләр нигездә мәкаль һәм әйтемнәрнең, канатлы сүзләрнең тупламалары иделәр. Авторлар үзләренең хезмәтләрен сүзлек дип түгел, җыентык дип атаганнар. Чыннан да, сүзлектән битәр, ул җыентык рәвешендә эшләнгән. Китапның «Төзүчеләрдән» дип исемләнгән кереш сүзендә аңа 6 меңгә якын фразеологик, идиоматик әйтелмәләр, әйтем һәм мәкальләр тупланганлыгы хәбәр ителә. Әмма китапта бу төрләр бер-берсеннән берничек тә аерылмый, үрнәкләр алфавит тәртибендә тезелеп куелган. Мәсәлән, «Акыллы аңлар, ахмак тыңлар», «Акыллы баш», «Акылсыз дошман акылсыз дустан яхшырак», «Акыллының аты да арымый, туны да тузмый», «Акыллының теле күңелендә, акылсызның күңеле телендә», «Акылы алтын», «Акылы хәзинә», «Башлы кеше», «Башы ике түгел» һ.б. төзүчеләрнең «фразеология» төшенчәсен шактый киң, ягъни теләсә нинди тотрыклы гыйбарә буларак изаһ итүләрен аңлата кебек. Әйтергә кирәк, тел белемендә андый фикер дә яши.

Кереш сүздә «Төп бүлектә фразеологик берәмлекләр, В. Даль сүзлеге үрнәгендә, тематик бүлекчәләргә салынып бирелделәр» [1957-Т_фраз: 5] дип аңлатып кую, тотрыклы сүзтезмәләрнең югарыда саналып киткән барлык төрләренең дә «фразеологик берәмлек» итеп кабул ителеп, бу төшенчәгә шактый киң мәгънә салынуын раслап тора.

Телгә алынган бу басма ике бүлектән (авторлар аларны төп һәм өстәмә бүлекләр дип күзаллаганнар) тора: беренче бүлек –

«Мәгънәдәш фразеологик берәмлекләр», икенчесе «Аерым сүзләргә нигезләнеп ясалган фразеологик берәмлекләр» дип аталган. Беренче бүлек, тематик принципта төзелеп, 61 төркемчәдән оештырылган. Биредә «Аыллылык-акылсызлык турында», «Алдау, ялганлау, мактанчыклык һәм ышанычсызлык турында», «Ару, талу һәм ял итү турында», <…> «Байлык, ярлылык турында», «Батырлык-куркаклык, кыюлык һәм тәвәккәллек турында» һ.б. төркемчәләр бар. Төзүчеләрнең фикеренчә, сүз байлыгының мондый тәртиптә бирелеше тәрҗемәчеләр һәм укытучылар өчен җайлы.

Сүзлек мәкаләсенә килгәндә, күпчелек очракта баш сүз сыйфатында килгән фразеологик берәмлек грамматик яки стилистик искәрмәсез, аңлатмасыз һәм дәлилли торган микротекстсыз үзе генә тора. Кайбер баш сүзләр янында гына аның кемнән алынганлыгын яки мәгънә үзенчәлеген (бәлки, авторлар, тематик төркемчәнең исеме булгач, шул җиткәндер, дип уйлаганнардыр), яки авторы күрсәтелгән иллюстратив микротекстны күрергә мөмкин, мәсәлән: «Исем китү.

***Исеме киткән*** *аның Зәй буена.* С. Хәким».

Төзүчеләрнең фразеологик берәмлекләрне тема кысаларында төркемләп биргәндә, мәгънәдәш гыйбарәләрне, баш сүздән уңгарак текст эченә кертеп, бер тирәгә укмаштырып куярга тырышулары да күзгә ташлана, *к.*: «Йөзгә бер тулмаган (бу – баш сүз)». «Бер тактасы ким». «Тугыз төймә». «Туксан тугызлы». «Утыз тугызлы – кырыкка бер тулмаган». Ләкин бу уңай күренешне дә һәрвакыт кулланганнар дип әйтеп булмый.

Төзүчеләрнең баш сүз буларак «шаккату», «иңбашы», «аңгыминңге», «дөм – караңгы» (сызыкның ике ягында да ара калдырылган; ихтимал, сызыкча куярга уйлаганнардыр), «имеш-мимеш», «имеш-маныш», «баштан-аяк», «башма-баш» (китапның 1 нче бүлегендә «башма баш» рәвешендә аерым язылган) кебек сүзләрне фразеологик берәмлек дип санаулары, аларның ясалу тарихларына артык игътибар бирүләрен күрсәтә. Сүз уңаенда шуны да әйтергә кирәктер: бүгенге көндә «шаккату», «иңбашы» кебек сүзләр – ике сүзнең янәшә килүеннән ясалган кушма сүз төре итеп, ә сызыкча аша языла торган кушма сүз төре кайвакыт, сызыкчаның яңа сүз ясау вазифасы булганлыгын истән чыгарып, сүз тезмәсе итеп кабул ителә бара.

Хезмәтнең икенче бүлегендә (авторлар аны өстәмә бүлек дип исемләгәннәр) 22 мөстәкыйль сүзгә нигезләнгән фразеологик берәмлекләр алфавит тәртибендә бирелгәннәр. Болар – «авыз», «адәм», «акыл», «ат» (1), «ат» (2), «баш», «йөрәк» һ.б. Бу бүлектә фразологик берәмлекләрнең, төп бүлектән аермалы буларак, мәгънәләре ачыкланган, сирәк кенә дәлилли торган җөмләләр китерелгән. «Бу бүлекнең, – дип язалар төзүчеләр, – фәнни-практик әһәмияте бигрәк тә шунда: мондагы әйтелмәләр бер үк сүзнең күптөрле фразеологик берәмлекләр составына керә алуын ачык күрсәтәләр» [1957-Т_фраз: 5].

Югарыда каралган әйтелмәләр сүзлегендә, мәкальләр һәм әйтемнәр урнаштырылуга да карамастан, татар теленең фразеологик байлыгы күпмедер дәрәҗәдә тупланган һәм системага салынган.

1978 елның ноябрь аенда Башкорт дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире филол. фән. д-ры, проф. Г.Х. Әхәтов татар теленең яңа фразеологик сүзлеген төзү кирәклеге турында чыгыш ясый. Галимнең сүзлек нинди булырга тиешлеге, аның төп принциплары турындагы күзаллавы соңрак аерым брошюра булып басылып та чыга (1979). Югары уку йорты укытучысы буларак, Г.Х. Әхәтов фразеологиянең мәктәп практикасы белән турыдан-туры бәйләнеше булганлыгына, аннан башка яшь буынга тел өйрәтүне, тел культурасын җәелдерүне күз алдына да китерүе авырлыгына басым ясап, сүзлекнең иң әүвәле мәктәп укучыларына, студентларга, укытучыларга, шулай ук язучыларга һәм тәрҗемәчеләргә тәгаенләп әзерләнәчәген белдерә. Күп тә үтми, **1982 елда** бу сүзлек басылып та чыга. Иң әүвәл хезмәтнең исеме «Татар теленең фразеологик сүзлеге»ннән «Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге» итеп үзгәртелә [1982-Т_фраз]. Бу – төзүченең фразеологик әйтелмәләрне мәкаль һәм әйтемнәрдән аерып карарга кирәклеге турындагы ышанычыннан килә.

Авторның искәртүенчә, тәкъдим ителгән «сүзлек татар әдәби телендә актив кулланыла торган 2500 гә якын образлы әйтелмәне эченә ала» [1982 –Т_фраз: 12]. *Образлы әйтелмә* төшенчәсе идиомаларны һәм мәгънәсе буенча бер төшенчә белдереп килгән фразеологик тезмәләрне колачлый. Автор фразеологик әйтелмәләрнең образлы булмаган төрләрен, шулай ук җирле сөйләшләргә, диалектларга хас фразеологизмнарны, фразеологиягә бернинди мөнәсәбәте булмаган мәкальләр һәм әйтемнәрне, табышмакларны, кушма

сүзләрне, фигыльләрнең төрле типтагы аналитик формаларын кертүнең кирәген тапмаган. Бу сүзлекне үз чорында фразеологик сүзлекләргә куелган таләпләргә җавап бирердәй хезмәт дип атарга мөмкин: әйтелмәләр алфавит тәртибендә бирелгән, һәрберсе янында мәгънәләре аңлатылган, күпчелек әйтелмәләр язучыларның әсәрләреннән алынган үрнәк җөмләләр белән ныгытылган. Ләкин язучылардан алынган үрнәкләр булмаган әйтелмәләр «болар фразеологик әйтелмәләрме икән?, әйтелмә булсалар, кайдан алындылар икән? » дигән сорау туа. Мәсәлән «Буй язу» (йөрү), «йөрәк үлү» (бөтен нәрсәгә ваемсыз, салкын карау) һ.б. бүтән чыганакларда очрамадылар; «Разведка ясау», «Рамкадан чыгу», «Расчет ясау», «Резина тарту», «Ризык бетү», «Ризык тарту» кебекләре исә, рус теленнән тәрҗемә ителеп, татарча сәеррәк яңгырыйлар. Кайбер әйтелмәләрнең мәгънәләрен саннар белән күрсәтеп аермау мәгънә үзенчәлекләренең бер-берсенә бәйләнеп китүен китереп чыгара. Мәсәлән, «Ис китү»нең 3 мәгънәсе булса да, алар өтер аша гына саналып киткәннәр (кызыгу, гаҗәпләнү, аптырау); ә инде «Искә килү»нең мәгънәләре нокталы өтер ярдәмендә күрсәтелгәннәр (аңга килү; хәтергә төшү). Мондый системасызлык укучының башында буталчык тудырырга мөмкин.

Еш кына сүзлек төзүдә куе кара төс белән бирелгән баш фразеологик әйтелмә янында берәр сүзнең төрдәше дә китерелә. Бу ысул хезмәтне җыйнакландыра һәм куллану өчен дә уңайлырак итә. Г.Х. Әхәтов та аны бик уңышлы кулланган, *к.*: **Йокы капчыгы (чүлмәге), Кендек береккән (бәйләнгән) булу, Күңелгә сеңү (кереп утыру)** һ.б. Ләкин төзүче файдаланган ике төрле очрак белән килешүе авыр: 1) авторның барлык-юклык мөнәсәбәтен бер үк әйтелмәдә күрсәтүе (*к.*: **Кеше күңеленә керә алу (алмау), Йөрәк җитү (җитмәү), Күңел тарту (тартмау), Күңел утыру (утырмау)** һ.б.) – монда юклыкны язмыйча да, юклыкны белдергән мисал кую җитә. Билгеле булганча, юклык формасы аерым бер мәгънәгә ия булганда яки барлык төре фразеологик берәмлек оештырмаса, юклыгы мөстәкыйль берәмлек итеп күрсәтелә; сүзлектә моның мисаллары бар, *к.*: **Кыл да кыймылдатмау, Кыл да селкетмәү, Мыек та селкетмәү**; 2) беренче сүздән соң җәя эчендә аның төрдәшен бирү: **Йөздән (биттән) кан качу, Күздә (йөздә) нур балку, Күзеннән (күзенә) ут чәчрәү, Кыек (кәкре) атып туры тидерү** – китапта алфавит тәртибе кулланылу сәбәпле, укучы

өчен уңайсыз. Мәсәлән, укучы **Биттән кан качу** әйтелмәсен «б» хәрефеннән эзләячәк һәм таба алмаячак та, ялгыш нәтиҗә ясаячак. **Сабагын (сабакларын) укыту, Йөзен (йөзләрен) ачу** кебек фразеологик әйтелмәләрдә беренче сүздән соң җәя эчендә аның күплек сандагы яки башка килештәге вариантын өстәп куюның да урынсыз икәнлеген күрсәтергә кирәк.

Сүзлек мәкаләсе башында урнаштырылып, өтер аша күрсәтелгән баш сүзләрнең берничә булуы да сүзлекнең алфавит тәртибендә оештырылуына гына түгел, икенче яки өченче урынга куелган әйтелмәне сүзлектә эзләп табуга зыян китерә. **1. Кот ботка җиту, Кот бот тирәсендә йөрү, Кот үкчәгә төшү; 2. Мунча кертү (чабындыру), Мунча кызу булу; 3. Сабыр җебе өзелү, Сабыр савыты тулу, Сабыр казаны шартлау** кебек күренешләрне үзгәртү сорала. Бергә тупланып бирелгән **Кот ботка җиту, Кот бот тирәсендә йөрү, Кот үкчәгә төшү** рәвешендәге тезмәләрне, мәсәлән, **Кот ботка (үкчәгә) төшү** һәм **Кот бот тирәсендә йөрү** дип, 2 мөстәкыйль корылышка үзгәртергә мөмкин.

Беренче карашка бер фразеологик әйтелмә кебек күренгән *Күктән (тәгәрәп) төшү; Кырын (күз белән) карау; Савыт (төбен) ялтырату* кебек тезмәләр 2 берәмлекне берләштерәләр, автор, мондый ысулны кулланып, бик дөрес эшләгән.

Күзгә бәрелеп торган тагын бер техник мәсьәләне телгә алмыйча мөмкин түгел: төзүче, фразеологик әйтелмәләрне берләштереп җыйнакландырганда, фәкать гади җәяләр генә файдалана, аларга нигездә ике вазифаны – төрдәшлекне һәм өстәлмәлекне сиздерү йөкләнгән. *Күктән (тәгәрәп) төшү* мисалында *Күктән төшү* белән *Күктән тәгәрәп төшү* әйтелмәләре берләштерелгәнгә күрә, «тәгәрәп» лексемасы өстәлмә кисәккә әверелгән һәм аны башка төрле – мәсәлән, очлы җәяләр белән күрсәтергә мөмкин: *Күктән <тәгәрәп> төшү;* шулай ук *Йөрәк(не) кисү*, *Чәч бөртекләрең дә (җитмәс)* түгел, *Йөрәк<не> кисү, Чәч бөртекләрең дә <җитмәс>*. Гади җәяләр исә төрдәшлекне белдергән очракта кулланыла алалар.

Сүзлектә «Дагаланып (кайту)», «Кара коелу /көю/» кебек ике үрнәкне без ялгыш куелып, корректура вакытында төзәтелмәгән җәяләр һәм авыш сызыклар дип кабул иттек.

Гомумән алганда, Г.Х. Әхәтовның бу китабы үз чорына хас булган фразеологик сүзлек төзү кагыйдәләрен һәм фразеография фәне таләпләрен дә искә алып төзелгән хезмәт булып саналырга хаклы.

**1989 елда** татар тел гыйлемендә зур вакыйга булып, Н.С.Исәнбәтнең 2 томлык «Татар теленең фразеологик сүзлеге»нең 1 нче томы дөнья күрде [1989-Т_фраз I]. Күләме ≈ 9900 фразеологик берәмлек. 2 нче томы исә 1990 елда басылып чыкты [1990-Т_фраз II]. Күләме ≈ 6300 фразеологик берәмлек; фәнни мөхәррире – филол. фән. д-ры, проф. В.Х. Хаков. Хәзерге көндә бу хезмәтнең татар теленең күпкырлы фразеологик байлыгын чагылдырган һәм аңлаткан иң тулы тупланма икәнлегенә аеруча басым ясарга кирәк.

Иң элек фразеологик берәмлекләрне тасвирлаганда, Н. Исәнбәтнең «әйтем» терминын кулланганлыгын күрсәтергә кирәк һәм ул, кайбер галимнәрнең телдәге бөтен тәгъбир-гыйбарәләрне «әйтем» атамасы астына алырга теләүләре белән риза булмыйча, бу хезмәттә әйтемнәрне үз асылынча тар кысада алу принцибында торып эш иткәнлеген ассызыклый [1989-Т_I: 6].

Сүзлек алфавит тәртибендә төзелгән, ләкин авторның бу тәртипне күзаллавы үзгәрәк (монда сүз 1990 еллар башында татар алфавитына кертелгән үзгәреш турында бармый). Сүзлек төзүчеләрдә кабул ителгән алфавит тәртибе (аны, мәсәлән, Г.Х. Әхәтов сүзлегендә күрергә мөмкин) монда сакланмаган, *к.*: **Елан мөгезе генә юк; Еланның агы да елан, карасы да елан; Елан телен кискән; Елан яшен ялаган; Елан үзәге кебек; Еларга да, көләргә дә белмәссең; Ел арты ел; яки Тегендә китү; Тегеннән кайту; Тегеләй-болай иткәләү; Тегеләй [дә] болай; Тегеләески барырсың; «Тегендә» күрү [типтерү].** Бу исә кирәкле сүзне эзләүне читенләштерә, күбрәк вакыт сарыф итүне таләп итә.

Сүзлеккә кертeләчәк баш сүзләрне (безнең очракта – фразеологик әйтелмәләрне) сайлап алуда авторның фразеология һәм фразеография турындагы фикерләре гамәли эшкә терәлү белән аерылып китә кебек. Иң әүвәле – куе кара төс белән бирелә торган баш сүзләрне сайлап алу мәсьәләсе.

Төзелеше ягыннан гади яки кушма сүз саналган *агай-энеләрчә, алдан-ала, алтынчы, анакай, аткүз, бетте-китте, буеннан-буена, буйдан-буйга, булган-беткән, дару-дәрман,* дименнән кебек берәмлекләр фразеологик сүзлеккә кертелергә тиеш түгелләр.

Сүзтезмә башында өч нокта куеп, ирекле сүзтезмәне тотрыклы итү алымы, ничектер, гайре табигый күренә, чөнки нокталар урынына сүз сөрешен бозмаган теләсә нинди башка сүзне кулланырга мөмкин: *к. ...диген дә бетер инде, ...дигән аты бар, ...дигән*

*белән бер, дигән була, дигән булып, дигәндә генә, ...дигән кебек, ... дигән чакта гына, ...дигәнчә булу, ...димәктән, ...димәсәң хәтере калыр (... дип әйтмәсәң, хәтере корыр (хәтере калыр)), ...дип бару, ...дип торсам, кая..., ...дип әйтеп, ...дип әйтеп булу, ...дип әйтеп әйтү, ...[дип] әйтеп ташлау, ...дисәң дә була.*

Җентекләбрәк караганда, шактый гына сүзләр фразеологик әйтелмә рәтеннән чыгарылырга да мөмкин, *к. абуз өстендә арыш сугу; агар су; аеры сакал; азчылык милләт; акай бизәк; акрын басып, вак-вак атлап; алакай бизәк; Алмаш өркәч; Алпавыт зураты; Арбадан төшеп калырга ярамый; Арт капка; аскы буй; аталарча кайгырту; ахыр заман алдыннан кемне уйласаң, шул үзе алга килә дә тора, ди; ачыклык кертү; ашкын хис; бага-баган төтен; дигән булды; дигән шикелле; дигән төсле; дигән сүз түгел; дин дошманы; дип әйткәннән; диплом корбаны* һ.б.

Кагыйдә буларак, фразеологик берәмлектә шакмаклы җәяле сүз булган очракта, ул өстәлмә буларак кабул ителә, ягъни биредә ике (яки берничә) фразеологик әйтелмә бар һәм алар җыйнаклык максатыннан гына берләштерелгәннәр, дип фараз ителә. *[Акча] вату; [анда] гарасат; [аш] бармый; аз-азлап [кына]; алайсыз-болайсыз [гына]; атлы-туклы [кеше]; даңгыр-даңгыр [килү]; дөбер-дөбер [килү]; ыштын-пыштын эшләү* кебек мисалларда җәянең ялгыш кулланылуын гына бәян итәргә мөмкин, чөнки җәяле сүзне алганда, фразеологик әйтелмә дә юкка чыга. Сүз уңаенан шуны да әйтергә кирәк: Н. Исәнбәткә кадәр, татар фразеологик сүзлекләрендә өстәлмә сүзне белдерү өчен, шакмаклы җәя кулланылмый иде, бу – төзүченең яңалыгы һәм уңышлы яңалыгы, чаг.: *авызы[н] көрәк белән [төртеп] тишкән; Агылы[й] белән Тагылы[й] [йөрү]; ачуы йөзенә [бәреп] чыгу; башыннан [алып] аягынача һ.б., әмма шул ук вакытта авыз күпертеп (сөйләү); авыз күгәртеп (сөйләү); адәм көлкесе (булу); кулы (ут) уйный; аты[м] юк урамда, кайгы[м] юк буранда; теле баллы [татлы]* кебек мисалларда җәя төрләренең ялгыш файдаланылуы аларны куллануда система оешып җитмәвен күрсәтә.

«Төзүчедән» дип аталган бүлекчәдә автор татар тел белемендә фразеологик бөтен, фразеологик ныгыма һәм фразеологик тезмә дип аталган төрләрне, оешу үзенчәлекләреннән чыгып, сүзлеккә исем фигыль калыбында куячагын белдерә [1989-Т_фраз: 7–8.].

Кайбер очракларда сүзлекләргә алынырга тиешле баш сүзләр (фразеологик берәмлекләр) янында аларның төрдәшләрен дә кую үзен акламый дип әйтергә мөмкин. Нокта аркылы янәшә куелган төрдәш фразеологик әйтелмәләрнең беренче сүзләре төрле формада яки төрле сүзләр булганлыктан, укучыга аларны эзләп табу кыенлаша, *чаг. Горбәт чигү. Горбәттә яшәү; Зар булу. Зар-интизар булып; Зур кубып йөрү. Зурдан кубу; Игътибарга алып. Исәпкә алып; Тыгыз җиргә тыгынчык. Тыгын җиргә тана башы* һ.б. Шуңа күрә аларны аерым урыннарда бирү мантыйклырак күренә.

Төзүче әйтелмәләрдә мәгънәләре якын булган сүзләрне гади җәяләр эченә алып тезеп бирү ысулын бик уңышлы файдаланган, *чаг. авырлык күрү (күтәрү); авырткан җиренә кагылу (сугу, тию); авыртмаган ягыңны карыйсың (ягыңа ятасың)* һ.б. Китерелгән үрнәкләрдә ике яки өч әйтелмә бер әйтелмә составында берләштерелгәннәр. Шушы ук ысулны төзүче нокталар аркылы янәшә куйган кайбер әйтелмәләрне гади җәяләр эчендә күрсәтү урынына да куллана алыр иде, ләкин кулланмаган: *чаг. Авыз йому. Авыз йосып калу ~ Авыз йому (йомып калу); Дәүләтең артсын. Дәүләтең белән картай. Дәүләт кошы башыңа кунсын. Дәүләт өстенә дәүләт яусын ~ Дәүләтең артсын (белән картай), ә калган икесе аерым-аерым урын алачак; Зар иңрәде. Зар иңрәп елады ~ Зар иңрәде (иңрәп елады); Зыр түгәрәк. Зыр әйләнә. ~ Зыр түгәрәк (әйләнә); Зыр-зыр килеп. Зыр-зыр әйләнеп ~ Зыр-зыр килеп (әйләнеп); Игә кертү. Игә килү. Игә китерү ~ Игә кертү(килү, китерү)* һ.б.

Алфавит тәртибенә оештырылган сүзлектә укучы үзенә кирәкле сүзне, кагыйдә буларак, куе кара белән язылган баш сүздән эзли башлый. Сүзлектә кайбер очракта кабул ителгән кебек, беренче сүз шакмаклы җәя эченә алынганда, бу әйтелмәдә ике әйтелмә берләштерелеп, икенчесе шакмаклы җәя эченә алынган сүздән башланганлыгын аңлата. Мисал өчен, шакмаклы җәя эчендәге «аңа» сүзе белән 32 («аңар» белән – 2, «аңардан» белән – 2) фразеологик әйтелмә башлана. Үрнәк өчен «Бигрәк тә сәер инде безнең Фирдус, бу яшь егеткә *булды хуш, булмады хуш*» җөмләсен алып карыйк. Сүзлектә булды хуш, булмады хуш әйтелмәсен таба алмассыз, аның каравы [Аңа] булды хуш, булмады хуш фразеологик әйтелмәсе очрый [1989-Т_ фраз: 124]. Димәк, «Б» хәрефендә дә бу әйтелмә кабатланырга тиеш иде (шакмаклы җәя эчендәге сүз белән башланганда шулай эшләнелгән дә), һәм бу вакытта

шакмаклы җәянең кирәге калмый. Баш сүзнең шакмаклы җәягә алынган «аларның», «аның», «анда», «аның», «аның белән» кебек сүзләрдән башланган очраклары да бар.

Күпчелек сүзлекләрдә фигыль кисәкле баш сүз вазифасында килгән әйтелмәдәге фигыльне исем фигыль шәкелендә кую кабул ителгән. Карала торган сүзлек авторы да бу ысулны кулланачагын игълан итә, ләкин кайбер фразеологик берәмлекләр, үзенчәлекләрен саклап калу максатыннан, бу кысаларга кертелмәгәнлеген дә искәртә [1989-Т_фраз: 8]. Бу бик дөрес фикер һәм моның белән килешергә кирәк. *аз азыклы, күп языклы*; *азган-тузган бәрәңге*; *ак эт бәласе кара эткә*; *аның алашасы да колынлый*; *диңгез тубыктан*; *коты култык астында*; *тавык чүпләп бетергесез* һ.б. әйтелмәләр җанлылыклары, тәэсир итү көчләре гаять үтемле калулары белән аерылып торалар. *астан әйтү (әйтеп тору)*, *астан казу (казыну)*, *астан йөртү (йөрү)*, башка [менеп] атлану һ.б. исем фигыль кулланылган әйтелмәләрдә эш-хәрәкәтнең дәвамлылыгы битараф бер төстә сизелсә, *астан бармагы уйный*; *астан кулы уйный*; *астан ут җибәреп ята*; *астан ут йөртә*; *астан эш йөртә*; *колагына тычкан оялаган*; *колагына кереп тә чыкмый*; *колагына да элми* һ.б. кебек исем фигыль файдаланылмаган әйтелмәләрдә конкретлык күбрәк үзен сиздерсә дә, хикәя фигыльнең дәвамлылыкны белдерү үзенчәлеге булганлыгын истән чыгарырга ярамый. Гомумән алганда, ике төркемдә дә образлылыкка зыян тимәгән, күчерелмә мәгънәнең үтемлелеге сакланган, шулай булгач, мөмкин булган очракта баш сүз рәвешендәге фразеологик берәмлекне стандарт исем фигыль калыбында бирү сүзлеккә җыйнаклык кына өстәр иде. *Тавык күз. Тавык күз булу* яки *Адәм зат. Адәм заты*; *Ай-һай салу. Ай-һай салып йөрү* кебек төзелмәләрне, нокта куеп, синонимнар итеп икегә аеру да фразеологик сүзлек төзү принципларына каршы килә.

Гадәттә, сүзлекләрдә фразеологик әйтелмәнең уңай шәкеле янында юклык шәкелен җәя эчендә күрсәтү кулланылмый, тискәре мәгънәле төре мәгънә аермасы булганда гына мөстәкыйль күрсәтелә. Мондый принцип карала торган сүзлектә сакланмаган, *к. андый-мондый хәл булу (булмау); баш[ы] йөрү (йөрмәү); башы эшләү (эшләмәү); вакыт тию (тимәү); гамь йоту (йотмау); гөнаһына керү (керә алмау); дөнья рәтен белү (белмәү); ике башлы булу (булмау); күңел яту (ятмау)* һ.б. Шул ук вакытта *чаг.: абайлап җит-*

*кермәү. авыз ачарга [да] урын калдырмау; авызга сүз төшмәү; авызны җыя алмау; авызына салган майны (салманы) йота белмәү; авызына төшкәнне ашый белмәгән; бетәсе булмады* һ.б.

Сүзлектә чагыштырулы фразеологик берәмлекләрне ничек бирү мәсьәләсе дә уйланып җитмәгән – бер төрне гомуми калып итеп алып, башкалары күз алдында тотылганлыгын искәрмә рәвешендә дә язып үтәргә мөмкин (билгеле, кайбер әйтелмәләр чыгарма буларак калса ярый).

Фразеологик сүзлектә баш сүздә (гыйбарәдә) бик мөһим булмаганда яки сүзтезмәдәге арттарак килгән сүз төрләнеш яисә килеш кушымчаларын кулланууны таләп итмәгәндә, аларны файдаланмау зарури. Бу җәһәттән Н. Исәнбәт сүзлегендә бу кагыйдәне бозу очраклары булуын да телгә алырга кирәк. Мәсәлән, *гайрәт[е] сүнү (кайту)* берәмлегендә, «кайту» синонимын санамаганда, ике фразеологик әйтелмә берләштерелгән: *гайрәт сүнү* (кайту) һәм *гайрәте сүнү (кайту)*. Ни өчен III зат берлек саны шәкеленә өстенлек бирелгән? Әгәр дә *гайрәтем сүнде* (Ф. Яхин), *гайрәтләр сүнгән* (Р. Миңнуллин), *гайрәтләрем (гайрәтең, гайрәтләрең, гайрәтебез* һ.б.*) сүнә* булса, ул фразеологик әйтелмә булмыймы? Шулай ук к.: *балыкның шулпасының шулпасы* аерым *балык шулпасы* бар), *куянның шулпасының шулпасы*, *күзе маңгаена меңгән* һ.б.

Бу фразеологик сүзлекнең уңай яклары итеп, китерелгән һәр фразеологик әйтелмәдән соң аның мәгънәсен (берничә мәгънә булганда, аларны саннар белән аерып) аңлатуын; әйтелмәне яхшырак аңлау максатыннан, әдипләрен күрсәтеп, аларның әсәрләреннән җөмләләр китерүен; җөмлә табылмаганда, үзе оештырып бирүен әйтеп үтәргә кирәк. Шулай да, барлык фразеологик әйтелмәләр дә иллюстратив җөмләләр белән ныгытылмавын да күрсәтми мөмкин түгел. Кайбер очракларда төзүче баш сүзнең мәгънәсен ачыклауны сирәгрәк булса да моңарчы аңлатылган фразеологик әйтелмәгә җибәрү ысулын да файдаланган, мәсәлән, к*араңны чырай бирү* (күрсәтү) *караңгы йөз бирү*гә җибәрелеп, дәлилләүче үрнәк Ф. Әмирханнан алынган. Бу ысулның әлегә ныклап утырып җитмәвен *арыш камыры* белән *арыш салмасы* әйтелмәләренең аерым-аерым рәвештә *арыш боламыгы* белән тәрдәшлеге бәян ителә. Әмма аларның өчесен дә *Арыш боламыгы (камыры, салмасы)* хәлендә бер фразеологик төзелмәдә берләштерергә мөмкин иде.

Н. Исәнбәт сүзлегендә моңарчы күрелмәгән тагын яңалык бар: монда әйтелмәләр янында стилистик билгеләр кулланылган, мәсәлән, «борынгы», «гади сөйләм», «диалекталь әйтем», «тиргәп әйтем», «әкият алымы» һ.б.

Н. Исәнбәтнең «Татар теленең фразеологик сүзлеге»ндә бу төр сүзлекләрдә беренче мәртәбә кайбер әйтелмәләрнең ничек һәм кайдан килеп чыгуларын ачыклаган бай тарихи мәгълүмат бирелгән, бүгенге көн укучысына аңлашылсын өчен, кайбер сүзләрнең этимологиясе, алынмаларның чыганагы күрсәтелгән.

**2000 елда** Яр Чаллының «Идел-йорт» нәшриятында «Татар теленең фразеологик сүзлеге»нең (авторы Н.Исәнбәт) А 5 үлчәмендә 236 битлек кыскартылган варианты басылып чыкты [2000-Т_фраз (1)]. Кыскартулар түбәндәгедән гыйбарәт: 1889 елгы сүзлектәге «Автордан» бүлекчәсенең ахырдагы якынча 1/3 өлеше генә калдырылган; 2 томнан сүзлек мәкаләләре сайланып алынып, бер китап күләмендә калдырылганнар, күләме якынча 2360 фразеологик берәмлек.

**2001 елда** шушы ук сүзлек бернәрсәсе дә үзгәртелмичә шул ук нәшриятта кабаттан басылып чыкты. [2001-Т_фраз (2)]

**2004 елда** «Gumanitarya» нәшриятында Ф. Хәкимҗан белән Д. Хәкимҗан әзерләгән (мөхәррире Э. Кадыйрова) «1001 әйтем» исемле фразеологик сүзлек нәшер ителде [2004-Т_фраз]. Күләме саннар белән күрсәтелгән – 1001 фразеологик берәмлек. Гомуми фразеологик сүзлекләр төренә караган бу хезмәт фәнни-популярлык төсмере белән аерылып тора: кайбер фразеологик әйтелмәләр көлкеле рәсемнәр белән баетылганнар.

Сүзлек алфавит тәртибендә оештырылган, куе кара белән күрсәтелгән баш сүзнең алдына саннар куелган һәм һәр әйтелмәнең мәгънәсе ачыкланган. Аңлатмаларны дәлилләү максатыннан әдәби әсәрләрдән өзекләр китерелгән, андый мисаллар табылмаганда, җанлы сөйләм үрнәге кулланылган. Мәсәлән: **2. Абруй куагын җил селкетү.** Дәрәҗәсе, абруе кими бару. *Хәзер Сәкинә Бариевнаның* ***абруй куагын җил селкетә*** *башлаган иде инде, аның дару сатып көн үткәрүен беләләр иде* (Н.Гыйматдинова). **500. Борчак ату (сибү, чәчү).** Ялганлап, арттырып сөйләү. *Сый-хөрмәт, шөкер, барысы да булды –* ***борчак сибүем*** *түгел* (Ш.Галиев). Тәкъдим ителгән әйтелмәнең сүзлектә төрдәше дә урнаштырылган булса, аңлатма кабатланмый, ул үз урынын алган әйтелмәгә к. билгесе

куеп җибәрелә, мәсәлән: **669. Ике дөнья бер, уртасы камыр** *к.* **ике дөнья – бер кәнди (морҗа).** *Элек колхозда бригадир сыман нәрсә булып йөргән, көн дә сәрхуш Ивановка ике дөнья бер, уртасы камыр* (Т. Мөбәрәков).

Моңарчы билгеле булган татар теленең фразеологик сүзлекләреннән аермалы буларак, ахырында кулланылган фразеологик берәмлекләрнең исемлеге хезмәтнең китерелә.

**Икетелле фразеологик сүзлекләр**

Әдәби әсәрләрне, фәнни популяр очеркларны һәм публицистик мәкаләләрне бер телдән икенче телгә тәрҗемә иткәндә, һәр телнең үзенә генә хас фразеологик берәмлекләре күпләп очрый. Моны искә алып, **1959 елда** Н.Б. Борһанова белән Л.Т. Мәхмүтова тарафыннан бастырылып чыгарылган «Русча-татарча фразеологик сүзлек» бу өлкәдә беренче тәҗрибә булып тора [1959-РТ_фраз]. Сүзлекнең күләме саннар белән күрсәтелгән – 2820 фразеологик берәмлек.

Хезмәтнең «Сүз башы» бүлекчәсендә фразеологиягә хас төп үзенчәлекләр, татар тел белемендә фразеологияне өйрәнүнең торышы, рус теленең өч меңгә якын фразеологик берәмлеге алынып, аңа татар теленнән (әдәби телдән һәм диалектлардан) төгәл эквивалентлар табарга тырышканлыклары хакында язылган. Моннан тыш, сүзлекнең принциплары да аңлатылган.

Сүзлек алфавит тәртибендә төзелгән, ике телнең дә әйтелмәләре янәшә торган баганалар рәвешендә саннар белән күрсәтелеп бирелгәннәр. Рус әйтелмәсенең варианты әйтелеш ягыннан сизелерлек аерылып торса, алфавит тәртибе бозылмыйча, үз урынына куелган, ә татарча тәрҗемәсе урынында әүвәл куелган баш сүзгә ишарә ителеп, аның саны урын алган, мәсәлән: **506. Дать березовой каши.** к. **54**. Ә 54 нче санда болай язылган: **54. Березовой кашей накормить. Тал чыбыгы ашату (кыйнау, суктыру мәгънәсендә). Таяк ашату».** Бу мисалдан күренгәнчә, 1) татарча эквивалентлар буларак төрдәш әйтелмәләр дә куелалар һәм 2) кайбер очракта әйтелмәнең аңлатмасы да бирелә.

Әйтергә кирәк, авторлар рус теленнән алынган фразеологик әйтелмәләр дип файдаланган берәмлекләрнең кайберләре мәкальләрне тәшкил итә, *к. Дальше положишь – ближе возьмешь, Дальше спрячешь – скорее найдешь, Дареному (даровому) коню в зубы не смотрят, Леность наводить на бедность* һ.б. Шуны

ук татар теле кисәгенә дә әйтергә мөмкин, *к. Бер көн ел ашата, Барыбер бер үләсе, Кеше колагын борганда үзеңнеке авыртмый, Күсәккә чыбыркы белән каршы торып булмый, Кылыч белән кергән кылычтан үләр, Чыбыркы белән балта түтәсен сындыра алмассың* һ.б.

Гомумән алганда, бу сүзлек шул чордагы фразеология турындагы белемнең ни дәрәҗәдә булганлыгын күрсәтә, шунлыктан ике тел үрнәкләрендә дә мәкальләр белән фразеологик әйтелмәләр аралашып бирелә, татарча үрнәкләрдә еш кына фигыльле әйтелмәләрдә бердәй фигыль калыбына китерү кулланылмый (мәс., башка йөгерде (китте), баш(ым) әйләнде (әйләнеп китте), кармак салып карау, колакны яра (ерта), юк-барны сөйләү һ.б. янында икәүдән-икәү (сөйләшү), сүзен-сүзгә (күчерү), әйтте-бетте кебек кушма сүзләр фразеологик берәмлек дип кабул ителәләр.

**1991 елда** Татарстан китап нәшрияты Л.К. Бәйрәмованың «Учебный тематический русско-татарский фразеологический словарь» исемле хезмәтен бастырып чыгарды [1991-РТ_фраз], күләме – 694 фразеологик берәмлек. (аннотациядә 700 дән артык дип бирелгән). Бу сүзлек татар мәктәпләрендә рус теленең лексик-фразеологик байлыгын төплерәк үзләштерергә ярдәм итү максатыннан чыгарылганлыктан, төп игътибар рус теленең фразеологик әйтелмәләренә бирелгән.

Хезмәтнең керешендә 1984 елда чыккан «Учебный фразеологический словарь русского языка (для национальной школы)» дигән китап нигез итеп алынып, 95 тема (дулкынлану – тынычлану; ачу, ярсу; рухи газаплану, кызгану; ярату, соклану; үпкәләү; шатлану – моңсулану һ.б.) 14 бүлекчә эчендә каралганлыгы белдерелгән. Билгеле, максатка тугры булып, төп тикшерену рус фразеологик берәмлекләре тирәсендә бара, ягъни баш сүз итеп куелган әйтелмәнең мәгънәсе ачыклана, аннан соң нокталы өтер аркылы татарчадагы тиңдәш булган әйтелмә (яки әйтелмәләр) күрсәтелә. Мәсәлән: БОЛЕТЬ ДУШОЙ (за кого, за что, о ком, о чем) – беспокоиться, волноваться, переживать; йөрәктән кичерү. Безгә калса, биредә русча фразеологик әйтелмә татар телендәге «җан», «бәгырь» белән бәйле эквиваленты куелса, тагын да үтемлерәк чыгар иде, *к. бәгырь кибү; бәгырь киселү (парә-парә килү; өзелү); бәгырь көю; бәгырь парәсен йолку; бәгырь сызла<н>у; бәгырь телгәләнү; бәгырь телү; бәгырь теткәләнү; бәгырь тураклау; бәгырьне авырт-*

*тыру; бәгырьне ашау; бәгырьне бораулау; бәгырьне җидегә телү; бәгырьне игәү; бәгырьне имгәтү; бәгырьне канату; бәгырьне катыру; бәгырьне кимерү; бәгырьне киптерү; бәгырьне кисү; бәгырьне корт ашау; бәгырьне көйдерү; бәгырьне өшетү; бәгырьне пычак белән телү; бәгырьне саву; бәгырьне талау; бәгырьне туравклау; бәгырьне тырнау; бәгырьне утлы тимер көйдерү; бәгырьне үксетү һ.б.; җан әрнү; җан киселү; җан сызу; җан сыкрау; җан сыкрану; җанны ашау; җанны кимерү; җанны куыру.* Кызганыч, бу әйтелмәләр авторның игътибарыннан читтә калганнар.

Автор кайвакыт татар теленнән русчага тиңдәш әйтелмә эзләүне сүзгә-сүз тәрҗемә итү яисә аңлату белән алыштыра: СЕРДЦЕ ЗАМИРАЕТ (у кого, от чего) – кого-либо охватывает волнение, тревога, страх; йөрәк туктап калу; САМ НЕ СВОЙ расстроен, потерял душевное равновесие; кәеф китү, нишләргә белмәү, күңелсезләнү һ.б. Безнең карашка, ике телдән алынган үрнәкләрне янәшә куеп чагыштырганда, нокталы өтер чагыштыру вазифасын берничек тә үти алмый, чөнки бу очракта татар теле үрнәге югалып кала.

Сүзлекнең аерым бер бүлекчәсе кайбер рус фразеологик берәмлекләренә тарихи-этимологик белешмә бирүне үз эченә ала, анда классик язучылардан әйтелмәләрне аңларга ярдәм иткән өземтәләр дә китерелгән. Алфавит тәртибендә китерелгән «Алфавит тәртибендә әйтелмәләр күрсәткече» һәм «Әйтелмәләрнең тематик күрсәткече», һичшиксез, укучыларга рус әдәбиятын яхшырак аңларга ярдәм итәчәк.

**2001 елда** «Мәгариф» нәшриятында Ф.С. Сафиуллинаның «Татарча-русча фразеологик сүзлег»е басылып чыкты (күләме 16 мең чамасы фразеологик берәмлек). «Төзүчедән» дип аталган кереш сүзендә автор сүзлек өчен материалның төрле сүзлекләрдән һәм әсәрләрдән җыйналганлыгын, Н. Исәнбәт сүзлегеннән аермалы буларак, калькаларга шактый урын бирелгәнлеген искәртеп үтә. Гомумән, татар тел белемендә бу – беренче татарча-русча фразеологик сүзлек.

Сүзлектә күпчелек урынны фигыль әйтелмәләр алып торалар һәм алар исем фигыль шәкелендә күрсәтелгәннәр, исемнәр – баш килештә, сыйфат һәм рәвешләр – төп дәрәҗәдә, катып калган гыйбарәләр үзгәртелмичә урын алганнар. Сүзлек алфавит тәртибендә төзелгән.

Татарча өлештә баш сүз куе кара төстә баш хәрефләр белән бирелеп, аның төрдәшләре булган очракта, алар авыш параллельлек билгесеннән соң язылганнар, әйтелмәнең русча эквиваленты ромб билгесеннән соң күрсәтелгән (биредә дә төрдәшләре булган очракта, параллельлек билгесе файдаланылган). Мәсәлән: **АВЫРГА УЗУ (КАЛУ)** // балага узу (калу // корсакка узу (калу) // йөккә узу (калу) // буйга узу (калу) // көмәнгә узу (калу) // бәбәйгә узу // корсак күтәрү ◊ стать беременной // быть на сносях. Шунысы да мөһим: автор мондый корылма эчендәге төрдәш әйтелмәләрне дә, алдына йолдызчык куеп, аерым-аерым баш сүз рәвешендә сүзлеккә кертә, к. * **БАЛАГА УЗУ (КАЛУ)** ◊ быть в положении // быть беременной // быть на сносях // стать беременной. Моннаш тыш, аерым юлда «к. авырга узу (калу)» дип, төп әйтелмәгә дә җибәрә. Мондый ысул татарча сүлекләрдә беренче кат кулланыла һәм укучыга тулаем бер төрдәшлек оясы хасил булганлыгын күзалларга ярдәм итә. Шулай да авторның сүзлек мәкаләсенең русча өлешендә алфавит сакламавының (ул аны үзе дә кисәтә) сәбәбе аңлашылып җитми. Югарыда китерелгән ике мисалда русча өлешләрендә 1) тәңгәллек сакланмавы, 2) *брюхо на нос полезло, в положении, в интересном положении, готовится стать матерью, дохаживает последние дни, на последнем дне беременности, последние дни ходит, скоро должна родить, собирается родить* кебек әйтелмәләрнең китерелмәве сораулар тудыра.

Автор «Төзүчедән» һәм «Сүзлекнең төзелеше» бүлекчәләрендә хезмәтнең барлык үзенчәлекләрен төгәл итеп аңлатып бирергә тырышкан, без монда баш сүзләр янында стилистик төсмер билгеләре күрсәтелмәгәнлеге (берничә лексик күрсәткеч кенә бар), татарча әйтелмәнең төгәл русча эквиваленты булмаганда, аны сүзгә-сүз тәрҗемә итү яки аерым сүз (сүз тезмәсе) белән аңлатылганлыгы белән дә таныша алабыз.

Сүзлектә билгеләрне куллануга килгәндә, фразеологик берәмлеккә аның төрдәш сүзен куйганда да, яңа берәмлек хасил иткән сүз өстәгәндә дә, кайбер очракта аңлатма биргәндә дә гади җәяләрне генә куллану җыйнаклык бирә сыман тоелса да, безнеңчә, мәгънәсен аңлауга хилафлык китерә (мәсәлән, «Эш тормас (калмас)» белән «Ярты юлда (ташлап) калдыру» әйтелмәләрендә гади җәяләрнең вазифалары бер үк түгел). Шулай ук татарча әйтелмәнең русчада берничә төрдәше булуын күрсәткәндә, автор кулланган

ысул таркаулык тудыра, к. («Җан бирү»нең өч мәгънәсен күрсәтү) **ҖАН БИРҮ 1.** ◊ вложить (вкладывать) душу; **ҖАН БИРҮ 2.** // **җан өрү** ◊ дать жизнь // вдохнуть жизнь; **ҖАН БИРҮ 3.** ◊ испустить дух // отдать концы // отдать богу душу һ.б. Фразеологик әйтелмәнең омонимик мәгънәләр биргәнлеген күрсәтергә теләгәндә, моны рим саннары белән белдерү зарури (ягъни I, II, III дип).

Сүзлеккә баш сүз сыйфатында алынган кайбер сүзләр турында ныклабрак уйлап караганда зарар булмас иде кебек, мәсәлән, «Эш узгач, үкенүдән файда юк» мәгънәсендә (не о чем жалеть, все позади, после драки кулаками не машут) «Эш узган, туй тузган» әйтелмәсе китерелгән. Әмма бу тезмә фразеологик берәмлек дип Н.Исәнбәт сүзлегендә китерелсә дә, ул бернинди мисал белән дә дәлилләнмәгән. Мәгънәсендә образлылык күзәтелсә дә, «туз-» фигыленең семасында нәрсәнеңдер бетүе, юкка чыгуы төшенчәсе юк [1981–Т_аңлат III: 153–154] Дөрес, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә «Туй тузгач» фразеологик берәмлеге китерелә, ләкин анда да дәлилле торган мисал юк, аңлатмасы да «соңарып башланган эшнең кирәге калмау, файдасы булмау» дип бирелә [1981–Т_аңлат III:154].

**2006 елда** Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре Ф.Ф. Гаффарова белән Г.Г. Саберова «Татарча-русча идиомалар сүзлеге. Татарско-русский словарь идиом» (фәнни мөхәррире Ф.Н.Таһирова) хезмәтләрен бастырып чыгардылар. Күләме – 3370 фразеологик берәмлек.

Ш.А. Рамазанов, XX йөзнең 50 нче ел башларында фразеологик әйтелмәләр белән идиоматик әйтелмәләрне бер-берсеннән аерып, «фразеологик әйтелмә үз составындагы сүзләрнең көче белән дә, тезмәнең гомуми мәгънәсе белән дә файдалана. Идиома исә кисәкләргә бүлгәләнми торган бөтеннең гомуми мәгънәсен генә саклый», дип язып чыккан иде. (Рамазанов 1954: 131–132) Татар тел гыйлемендә фразеологик ныгымалар белән идиомалар арасында тигезлек билгесе күзгә ташлана (Ахунҗанов 1972; Татар лексикологиясе I, 2015: 224–231).

«Татарча-русча идиомалар сүзлеге» белән танышканнан соң, татар теле белемендә хәл ителмәгән бер сорау – бу төр икетелле сүзлекләр нинди телдә язылырга тиеш? дигән сорау уртага чыга. Ф.С. Сафиуллинаның сүзлеге татарча язылган булса, телгә алынган

идиомалар сүзлеге исә русча язылган. Авторлар «Сүз башы»нда сүзлеккә мәкальләр һәм әйтелмәләр кертелгәнлеген хәбәр итәләр. Баш сүзләр, сан белән күрсәтелеп, куе кара төстәге юл хәрефе белән алфавит тәртибен саклап бирелгәннәр, сүзлек мәкаләсенең үзе гадәти хәрефләр белән язылган (баш сүзнең төрдәше күрсәтелгәндә генә, «см.» кыскартмасы куелып, куе төс кулланылган). Фигыльле әйтелмәләр күпчелек очракта исем фигыль шәкелендә тәкъдим ителгәннәр, кирәк булганда, барлык әйтелмәләр дә гади җөяләр эченә алынып, сүзгә-сүз тәрҗемә ителгәннәр. Сүзлек мәкаләсендә башка төрле җәяләр кулланылмаган.

Авторлар татар материалын русчага тәрҗемә иткәндә, аның мәгънәви ягына зур игътибар биргәннәр, ләкин, үзләре әйтүенчә, эквивалент табылмаганда, аңлатуга да күчкәннәр. Кайвакыт ике ысулны берьюлы куллану гына аңлашылып белми, к. **12. авыз турсайту** надувать губы; обижаться (чаг. Ф.С.Сафиуллина сүзлегендә: **АВЫЗ ТУРСАЙТУ** ◊ ходить недовольным // надуть губы) яки **13. авыз чайкау** (букв. полоскать рот) сплетничать; перемывать косточки *кому-л.* һәм Ф.С. Сафиуллина сүзлегендә: **АВЫЗ ЧАЙКАУ** ◊ лясы точить // разводить сплетни *к. гайбәт сату*.

Кайбер төрки һәм көнбатыш телләреннән азмы-күпме булса да чагыштырма үрнәкләр китерү – бу сүзлекнең яңалыгы.

Сүзлекнең ахырында идиомаларның русча тәрҗемәләре алфавит тәртибендә тезелеп бирелгәннәр.

Тел, бер урында катып калмыйча, даими рәвештә үзгәреш кичергән кебек, сүз байлыгының арта баруы, сүз тезмәләренең калыплашуы фразеологияне җанландыра, аңа образлылык өсти. Телдә яшәгән барлык фразеологик әйтелмәләрне туплап, аларга яңа пәйда булганнарын да өстәп, төрле төрдәге фразеологик сүзлекләрне әзерләп чыгару һаман да көн кадагына суккан мәсьәлә булып кала бирә.

## § 18. Терминологик сүзлекләр

Термин – фән, техника, сәнгать өлкәсенә, рәсми һәм иҗтимагый-сәяси тормышка, шулай ук көнкүрешкә караган төшенчәләрне төгәл, конкрет белдергән сүз яки сүзтезмә. Ул җәмгыять тормышының мәгълүм бер акыл яки физик хезмәт өлкәсенә караган махсус гыйльми төшенчәләрне атый торган тел берәмлеге.

Термин – төгәл фәнни атама, ул – төшенчәнең эчтәлеген мөмкин кадәр тулы, ачык билгеләргә, кыска һәм туры мәгънәле булырга, үз өлкәсендә терминның башка варианты булмаска тиеш. Кайсы да булса өлкәнең аерым бер тармагына яки берничә тармагына караган терминнарны бергә туплап биргән сүзлек терминологик сүзлек була. Соңгы елларда төзелгән терминологик сүзлекләр үзләренең тематикасы буенча күп төрле тармакларга карый. Узган гасырның 90 нчы елларында татар телендә терминологик сүзлекләр төзү эше халык хуҗалыгының төрле юнәлешләренә караган, белгечләр үзләштерергә тиешле иң актив кулланышта булган минимум татар сүзләрен туплаган сүзлек-минимумнардан башланып китте. Алар утызга якын халык хуҗалыгы тармакларына карый. Бу төзелгән сүзлек-минимумнар татарча терминнарның актив кулланылышына, яңа татарча терминнар ясалуга этәргеч ясады. Алга таба төзелгән терминологик сүзлекләрнең нигезе булып хезмәт итте.

Сүзлекнең мәкалә эчтәлеге буенча терминологик сүзлекләрне:

тәрҗемәле [1981-РТ_физич_*Гал.*; 1996-АТР_строит_учеб_*Каф.*; 1996-НТР_строит_учеб_*Каф.*; 1996-АРТ_физич_*Даут.*; 1996-РТ_связь; 1998-ТР_языкозн_*Саф.*; 1999-ЛРТ_анатом_*Гат.*; 2000-РТ_воен_*Мугин.*; 2000-РТ_биохим_*Якуп.*; 2002-РТ_хим_*Миф.*; 2002-ТРЛ_раст; һ.б.],

тәрҗемәле-аңлатмалы [1972-РТ_физич_*Гал.;* 1994-РТ_медиц_*Мин.*; 1995-Р,Т,А_физич/хим_*Сайф.*; 1998-РТ_биол; 2003-РТ_агрохим; 2004-РТ_ветерин; 2004-РТ_хим; 2010-РТ_геогр_*Тайс.*; һ.б.] сүзлекләргә бүлеп карарга мөмкин.

Арада тәрҗемәле һәм «өлешчә аңлатмалы» [1953-РТ_геогр_*Дус.*; 1971-РТ_а/хуж; 2007-РТ_музык; 2008-РТ_хезм/имин; һ.б.] сүзлекләрне дә күзәтергә була. Ул күбрәк рус теленнән тәрҗемә юлы белән ясалган атамаларны туплаган сүзлекләргә карый. Атаманы тәрҗемә иткәндә, ачык аңлаешлы булган, терминның эчтәлеген үзе атаган сүзләр белән ачып биргән аналитик аңлатмалы атамалар барлыкка килә. Шул сәбәпле мондый терминнарга өстәмә аңлатма бирү ихтыяҗы калмый.

Лөгатьлекнең бирелешенә карап, терминологик сүзлекләр алфавит тәртибендә төзелгән сүзлекләргә (күпчелекне тәшкил иткән сүзлекләр), тематик терминологик сүзлекләргә [1995-РТ_культ; 1995-РТ_лес/хоз; 1998-РТ_торг;1999-ЛРТ_анатом; һ.б.], тематик-алфавитлы терминологик сүзлекләргә [1996-РТ_бытов/об-

сл;1996-РТ_связь; 1997-РТ_охр/прир; 2004-РТ_ТР_ветерин; һ.б.] бүленә.

Сүзлек мәкаләсендә терминнарның ничә телдә күрсәтелүенә карап, терминологик сүзлекләр:

икетелле (күпчелекне тәшкил иткән сүзлекләр),

күптелле [1996-АРТ_физич_*Даут.*;1999-РТЛ_ТРЛ_ветерин_*Наб.*; 1999-ЛРТ_анатом;2010-РАТ_менедж_*Гариф.*; 2015-АРТ_компьют; 2018-ТРЛ_орнит_*Саф.*; 2019-ТРЛ_ихтион_*Галим.*; һ.б.],

бертелле [1953-Т_әдәб; 1958-Т_әдәб_*Гыйз.*; 1984-Т_әдәб_*Әхмәд.*; 1995-Р,Т,А_физич/хим_*Сайф.*; 1996-Р,Т_фин/юрид_*Гариф.*; һ.б.] сүзлекләргә бүленә.

Татар телендә тармак терминологиясе үз милли традицияләре нигезендә барлыкка килгән. Татар халкының борынгыдан килгән тормыш-көнкүреше, иткән кәсебе, яшәеш рәвеше үзенә хас милли терминологияне барлыкка китергән. Игенчелек, терлекчелек, тукучылык, тегүчелек, умартачылык, тимерчелек, зәркәнчелек, төзелеш эше, уку-укыту, сату-алу, киез итек басу, шәл бәйләү һ.б. бик күп һөнәрләр татар халкы яшәешенең асылы булып торган һәм һөнәре белән бергә аның терминологиясе дә ясалган. Күпчелек халыкка бу һөнәрләрнең билгеле булуы, аңа караган профессиональ лексиканың аңлаешлылыгы аның терминологиясен гомумхалык лексикасына якынайткан.

Аерым тармакларга караган терминологияне татар телендә булдыру мәсьәләсен беренче булып К. Насыйри күтәрә. Үз чорында бу гаять катлаулы эш булып торган, чөнки бу вакытта фәнни төшенчәләр гарәп, фарсы яки госманлы төрек сүзләре белән генә тәгъбир ителгән. К.Насыйри: «Һәр фәннең үзенең махсус истилахы бардыр вә үзенә махсус теле бардыр. Безнең үз телемездә кадимнән бу фәннәр языла килмәгәнлек сәбәпле, урынына мовафикъ вә килешә торган сүзләрне табуы читен... Лөгать белән истилах арасында бер галәкә кирәктер. Һичбер мөнәсәбәтсез бер сүзне истилах ясап булмый» ди [1894-Т_гөлз/чәм]. К. Насыйри кыю рәвештә, борын-борыннан җимерелмәс закон, үзгәрмәс нормалар рәвешендә урнашкан иске традицияләрне җимереп, татар сүзләрен термин буларак беркетү юлын тота, гарәп терминнарына татарча конкурентлар тудыра. Арифметикада аның тарафыннан кертелгән дүрт гамәлне белдергән атамалар хәзер дә кулланышта йөри. Геометрия терминнарының гарәпчә-татарча параллельләрен күрсәтеп,

гарәпчә терминнарны татарча адекватлары белән аңлатып бирә. Шул ук юл белән география дәреслекләре дә төзи. Татар сүзләрен география терминнары итеп беркетә. К. Насыйри төрле өлкәләргә караган сүзлекләр төзеп, аларны кулланышка тәкъдим итә (Татар лексикологиясе, 2016, Т II: 182).

Игенчелек һәм бакчачылык атамаларын булдыру өчен дә, халыкның җанлы сөйләү телендәге әзер сүзләргә мөрәҗәгать итә. «Гыйльме зирагать» китабында, мәсәлән, «...Европа истилахында суперфосфат аталыр. Сөяк оны дигәнебез ошбудыр» [1882-Т_гыйль/зир] ди. «Гөлзар вә чәмәнзар» китабында тамыр, камыл, көпшә, кабык, кайры, яфрак, чәчәк, җимеш, орлык һ.б. сүзләрне термин буларак күрсәтә [1894-Т_гөлз/чәм]. Татар сүзләрен терминлаштырганда, К.Насыйри татарча-гарәпчә яки гарәпчә-татарча параллельләр китерә: «яфрак димез, – гарәпчә вәрак аталыр, кабык яки кайры гарәпчә кыйшыр аталыр...» дип аңлатып бара.

К.Насыйриның алып килгән иң зур яңалыгы шунда: ул гарәп һәм фарсы телендә белдерелгән терминнарны беренче булып татар теленең җанлы сөйләм теленнән алынган атамаларга алмаштыра, аларны саф татарча атый һәм бу сүзләрне термин буларак тәкъдим итә.

XIX гасыр ахыры XX гасыр башы иҗтимагый-икътисади мөнәсәбәтләрнең үсүе татар милли әдәби теленең барлыкка килүенә этәргеч ясый. Милли әдәби телнең функциональ киңәюе һәм структур үсеше аның лексик составының артуына, тармак термин системасының актив үсүенә китерә. Татар телендә табигать фәннәре атамаларын эшләүдә зур өлеш керткән мәгърифәтче галим, педагог Габдулла Сабир улы Ибраһимов (Шенаси) күренекле урын алып тора. Ул язган «Мохтәсар кимия» – татар телендә беренче мөстәкыйль химия дәреслеге була (Мифтахова, 2005, №3/4: 11). Белгечләр раславынча, бу дәреслек үз чорының камил дәреслекләрнең берсе санала (Рахимкулова, 1998:274). Беренче китабында ул төп химик төшенчәләрне (материя, җисем, элементлар, атом, химия законнары һ.б.) бирсә, икенчесендә металлар турында мәгълүмат китерә, тиешле терминологиясен эшли.

Ул чордагы алдынгы мәдрәсәләрнең эшчәнлеге, беренче чиратта, татар дөньяви мәктәбе өчен киң профильле белгечләр – башлангыч белем бирү укытучылары, урта һәм югары белем бирү белгечләре, шулай ук мәдәният, хуҗалык учреждениеләре өчен

кадрлар әзерләүгә юнәлтелгән була (Шарипов, 2014: 68). Аларда мантыйк, фәлсәфә, фәлсәфә тарихы, мәгълүмате мәдәния, рус, татар, гарәп, фарсы телләре һәм әдәбиятлары, матур язу, арифметика, геометрия (тригонометрия белән), алгебра, физика, химия, астрономия, география, гомуми тарих, Россия тарихы һәм татар тарихы, табигать белеме, зоология һәм ботаника, законнар, политэкономия һәм сату эше, исәп-хисап, сызым һәм рәсем, педагогика һәм дидактика, психология, гигиена һәм медицина белеме нигезләре, гимнастика кебек фәннәр белән бергә, немец, француз телләрен өйрәтүгә дә игътибар бирелә. Әлбәттә, бу дәресләр, аның дәреслекләре һәм терминологиясе дә эшләнгән булуны таләп итә. Г.Ибраһимов-Шенаси татарча физика дәреслеге авторы буларак та билгеле. Аның 1916-1920 елларда урта мәктәпләр һәм педагогия курслары өчен төзегән «Хикмәте табигыя дәреслеге» Уфада берничә тапкыр басылып чыга. Г.Ибраһимов-Шенаси үзенең беренче дәреслекләрендә үк татар телендә фәнни атамалар булдыруга игътибар итә. Мәсәлән, химия дәреслеген язганда, атамалар куллануга карата ул: «Татар шивәсендә язарга тырыштым. Бик мәҗбүрият булганда гарәпчәне керттем. Бу вакытка чаклы үз арамызда билгеле булмаган гонсерләрнең исемнәрен вә кимияви истилахларны госманлыча кабул иттем», – ди (Шәмсетдинова, 2012, № 2: 53). Кирәгенчә рус атамаларын кертү ягында да була, чөнки, «русча белгән шәкертләргә рус телендәге кимия китапларын аңлау җиңел булсын, дидем» (шунда ук). Татарча атамалар ясауда ул аның аңлаешлылыгын, төгәллеген, мәгънә белдерүдәге камиллеген беренче урынга куя. Аның фикеренчә, татар дәреслекләрендә атамалар бары татар телендә генә бирелү шарт түгел, чөнки кайбер очракта, теге яки бу мәгънәне белдерү өчен, бер генә сүз кулланып булмый, катлаулы атамалардагы сүзләр төрле телләрдән алынган булуы мөмкин. «Физика атамалары» һәм «Математика атамалары» китапларының редакторы буларак, ул, иң беренче чиратта, әнә шуларга игътибар итә.

Фән-техника үсеше, акрынлап кул хезмәтенең кысырыклап чыгарылуына, профессияләрнең һәм аларга караган терминнарның гомумхалык лексикасыннан ерагаюына, индивидуальләшүенә китергән. Шул өлкәдә эшләүче белгечләр өчен генә аңлаешлы булган, күп төрле тармакларга караган терминнар системасы барлыкка килүгә сәбәпче булган. Терминнарны белгечләргә җиткерү

өчен теркәү, аларны бердәйләштерү, системага салу бурычы килеп баскан. Әлбәттә, бу бурычның иң зур өлешен терминологик сүзлекләр башкарган.

XX гасыр башында татар милли әдәби теле белән берлектә, атап әйткәндә, 20–30 нчы елларда, милли телдә яңа фән тармагы – терминология бүлеге аерылып чыга. Ул чорда күп кенә терминологик сүзлекләр дөнья күрә. Алар еш кына аерым авторлар, фәнни оешмалар тарафыннан стихиячел рәвештә төзеп бастырыла. Еш кына аларда бер үк терминны белдерү өчен төрле вариантлар, синонимнар куллану очраклары күзәтелә. Аны фәнни нигезгә кую бурычы килеп баса. Г.Ибраһимов-Шенаси бу чордагы ситуацияне анализлап, телдәге юнәлешләр белән җитәкчелек иткән оешманың булмавы сәбәпле стиль һәм терминнарның бик чуар бирелүен, аларның кулланышы һәр очракта һәр авторга бәйле булуын, берәүләрнең термин буларак татар сүзләрен, икенчеләрнең рус сүзләрен, ә кайберләренең гарәп сүзләрен файдалануларын әйтә (Мәгариф, 1921, №10-11: 66-71).

1921 елда Татарстан Мәгариф Халык Комиссариатында Гыйльми үзәк төзелә. Фәнни терминологияне туплап, тәртипкә китерү эшен әйдәп бару өчен, Гыйльми үзәк составында махсус терминологик комиссия оештырыла. Терминологик комиссия татар телендә атамалар ясау турында махсус карарлар кабул итә. Бу карарларда атамалар ясауда татар теленең нигез итеп алынуы, татарча терминнар булмаганда – диалектларга, анда да табылмаса, шәрекъ яки гарәп телләренә мөрәҗәгать итәргә кирәклеге, алыначак сүзләрнең татар теле аһәңенә, табигатенә һәм язуына якын булуына игътибар итәргә тиешлеге әйтелә. Терминология комиссиясе күрсәткән таләпләр нигезендә бик күп фәннәр буенча атамалар төзеп тәкъдим ителә. 20–30 нчы елларда төрле тармакларга караган 15 меңләп атама эшләнә һәм 20 дән артык терминологик сүзлек төзеп таратыла. (Татар лексикологиясе, T II: 182–186). Алар – ана теле, математика, физика, химия, зоология, ботаника, гомуми биология, анатомия-физиология, идарә, хокук һ.б. тармакларга караган терминнар.

Татар терминологиясен булдыру эше сугыш елларында да, сугыштан соңгы елларда да дәвам итә. Бу чорда терминология төзү эше Татарстан дәүләт терминология комиссиясе җитәкчелегендә бара. Мәсәлән, З.С. Дусаев төзегән «Русча-татарча география сүз-

леге»н [1953-РТ_геогр] күздән кичерсәк, аның кереш өлешендә «Сүзлекне төзегәндә, Татарстан хөкүмәт терминология комиссиясе тарафыннан расланган «Татар әдәби теленең гамәлдәге терминологиясен тәртипкә салу, яңа терминнар эшләп чыгару һәм терминологик сүзлекләр төзү эшендә төп принциплар һәм инструкция» һәм «географик сүзлек төзүдә алынган төп принциплар» (1944 е.) күздә тотылды», дип язылган (3 б.). Сүзлекнең турыдан-туры үзенә мөрәҗәгать итсәк, биредә рус атамаларына татарча эквивалентлар, тәрҗемәләр китерелә. Аерым терминнарга җәяләр эчендә атаманың чыганагы, кайсы телдән алынуы, нәрсә аңлатуы күрсәтелә: мәс.,

Кума Кума (ж. хал. Комнан ага торган елга) Төньяк Кавказдагы елга.

Пуна Пуна (исп. – чүлле тау) Анд таулары өстендәге чүл (Көньяк Америкада) һ.б.

Татар телендә фәнни терминологияне эшләү рус терминологиясе нигезендә алып барыла. Тормыш-көнкүрештә, иҗтимагый яшәештә бары рус теленең генә өстенлек итүе татар телендә булган терминологиягә ихтияҗны юкка чыгара, аның үсешен туктата, рус терминологиясеннән күпкә артта калдыра. Шуңа да татар терминологиясен булдыру эше иҗтимагый яшәештә, хуҗалыкның төрле тармакларында, фән-техникада, сәнгатьтә урнашкан рус терминологиясен татарчалаштыру нигезендә эшләнә. Алда китерелгән сүзлектән күренгәнчә, лөгатьлек рус терминологиясен тәшкил итә, татар телендә аның эквивалентлары эзләнә, бу максатта тугандаш төрки халыкларның да теленә мөрәҗәгать ителә, табылмаса, тәрҗемә итү юлы белән яңа сүз-термин ясала яки чит телдән оригиналдагыча кабул ителә.

Күпчелек сүзлекләрдә күрсәтелгән терминнарга татар телендә аңлатмалар китерелә. Информацияне җиткерү ягыннан тәрҗемәдән генә торган сүзлекләрнең аңлатмалары да күрсәтелгән сүзлекләрдән нык калышуы ачык. Аңлатмалар терминның эчтәлеген тулырак ачарга, аны төгәлрәк аңларга ярдәм итә.

Бу чорда татар терминологиясенә үзеннән өлеш керткән хезмәтләрдән түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин: Г.Г. Әхмәтов, М. Гыймадиев «Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге» [1950-РТ_а/хуж]; В. Горохов, А. Касимов, В. Хангилдин «Русча-татарча психология һәм педагогика терминнары сүзлеге»

[1950-РТ_ псих/пед]; А.К. Тимергалин, М.С. Галиев «Русча-татарча техника терминнары сүзлеге» [1963-РТ_техн]; В.З. Закиров, З.Г. Мортазин «Русча-татарча математик терминнар сүзлеге» [1970-РТ_матем]; О.Ж. Курмаев җитәкчелегендәге коллектив төзегән «Русча-татарча биология терминнары сүзлеге» [1972-РТ_биол]; М.С. Галиев, А.К. Тимергалин «Русча-татарча астрономия терминнары сүзлеге» [1974-РТ_астр]; Г.Дистанов «Русча-татарча химия терминнары сүзлеге» [1978-РТ_хим]; М.С. Галиев, А.К. Тимергалин «Русча-татарча физика терминнары сүзлеге» [1981-РТ_физик]; Ф.Г. Ситдиков, Н.А. Бакиева, А.Х. Гарифуллина һ.б. «Русча-татарча биология терминнары сүзлеге» [1985-РТ_биол]; Я.И. Ханбиков, Ш.С. Ханбикова «Русча-татарча педагогика һәм психология терминнары сүзлеге» [1985-РТ_пед/псих] һ.б.

Эшләнгән сүзлекләрдә авторлар, тема буенча өстәмә мәгълүматлар китереп, аларның информацион эчтәлеген баету максатында төрле алымнар кулланалар. Мәс., А.К. Тимергалин, Г.Г. Әхмәтов, Ш.Г. Садыйков төзегән «Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге»нә [1971-РТ_а/хуж] күзәтү ясасак, монда барлыгы 15 мең термин туплап бирелә. Сүзлектә рус атамаларына татарча эквивалентлары, тәрҗемәләр китерелә. Сүзгә сүз тәрҗемә итеп бирү юлы белән ясалган атамаларның күбесе хәзерге телдә аңлаешлы булган, терминның эчтәлеген үзе атаган сүзләр белән ачып биргән аналитик аңлатмалы атамалардан гыйбарәт. Шул сәбәпле аларның барысына да аңлатмалар бирү ихтыяҗы калмаган, сүзлек «өлешчә аңлатмалы» килеп чыккан: мәс.,

| | |
|---|---|
| лузговейка | кабык җилгәргеч |
| лункоделатель | оя ясагыч |

Бирелгән атама төшенчә яки объектны тулысынча күз алдына китереп бетерә алмый икән, җәя эчендә татарча аңлатмалар бирелгән: мәс.,

| | |
|---|---|
| мотовило | әвернә (ургыч кисү аппаратына иген сабакларын авыштыру өчен беркетелгән нурсыман калаклыкүчәр) |

Сүзлекнең тагын бер уңай, үзенчәлекле ягы – терминнарны оялап күрсәтү, ягъни төр атамаларын ыру атамалары оясында бирү: мәс.,

| | |
|---|---|
| орошение | сугару |
| ... затоплением | су бастырып сугару |

| | |
|---|---|
| ... лиманное | лиманлап (кар, яңгыр суларын җыеп, буып) сугару |
| ... органическое | табигый сугару |
| ...паводковое | язгы сулар белән сугару |
| ...подпочвенное | туфрак астыннан сугару |

Сүзлектә төп ыру термин янында аның төр терминнарын ояда җыеп туплау ысулы системалы мәгълүмат бирү, практик уңайлылык ягыннан отышлы һәм күпчелек терминологик сүзлекләрдә бу тәҗрибә киң кулланыла. Хәзерге вакытта да терминологик сүзлекләр төзүдә төп алым булып кала.

Сүзлек ахырында авыл хуҗалыгына караган иллюстрацияләр, тематик төркемнәргә тупланып, аңлатмалары белән кушымта итеп китерелә: культуралы үсемлекләр, чүп үләннәр, үсемлек авырулары һәм корткычлары, хайваннар һәм кошлар, балыклар, авыл хуҗалыгы техникасы, барлыгы 92 рәсем бирелә.

Сүзлекнең информацион эчтәлеген баету максатында, һәр автор үз өлкәсенә бәйле рәвештә үзенчә алымнар куллана. М.С. Галиевнең «Русча-татарча физика терминнары сүзлеге» [1972-РТ_физик], нигездә, урта мәктәп программасында кулланылган терминнарны туплап бирә. Биредә барлыгы 1800 гә якын термин теркәлә. Сүзлек ике бүлектән тора: беренче бүлектә лөгатьлеген рус терминнары билгеләгән русча-татарча сүзлек өлешендә һәр термин татарча шәрехләнә, эквивалентлары, тәрҗемәләре китерелә. Икенче бүлектә тәрҗемәдән генә гыйбарәт татарча-русча терминнар сүзлеге бирелә. Күрсәтелгән тәрҗемәләр татар терминнарына аңлатмаларын тиз һәм җиңел табу мөмкинлеген тудыра. Сүзлек ахырында физика фәнендә кулланылган берәмлекләр системасы кушымта итеп урнаштырыла.

Татар терминологиясен эшләүнең тагын да бер зур күтәрелеше XX гасырның 90 нчы елларыннан башланып китә. Ул беренче чиратта, тел сәясәте, Татарстан Конституциясендә татар теленең дәүләт теле буларак билгеләнүе һәм аның җәмгыятьтә кулланылыш сферасы киңәю, милли үзаң үсеше, җәмгыятьнең демократлашуы, милли мәктәпләр үсү, югары уку йортларында фәннәрне татарча укыта башлау һәм, гомумән, милли мәгариф системасындагы үзгәрешләр белән тыгыз бәйләнгән була. «Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча ТР Дәүләт программасы» кабул ителә. Бу чор халыкара мәйданда

да, ил күләмендә дә кискен сәяси-икътисади, иҗтимагый, мәдәни һ.б. күптөрле вакыйгаларга бай булу, фән-техниканың сизелерлек алга китүе, халыкара элемтәләр, багланышлар, үзара аралашуның шактый нык артуы белән билгеле. Мондый вазгыять беренче чиратта телгә йогынты ясый. Тормышта булган үзгәрешләр иң элек телнең сүзлек составында, аның лексик системасында чагылыш таба. Нәтиҗәдә, татар телендә күп кенә яңа төшенчәләр барлыкка килә, аларны атаган яңа сүзләр кулланышка кереп китә, яки рус теленнән кергән кайбер терминнар татар яисә гарәп, фарсы сүзләре белән алмаштырыла. Ә бу, үз чиратында, яңа сүзлекләр төзүгә этәргеч ясый. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты җитәкчелегендә халык хуҗалыгының төрле юнәлешләренә караган, минимум татар сүзләрен туплаган кыскача русча-татарча сүзлекчәләр эшләнә башлый. Ул билгеләнгән хуҗалык тармагы буенча татар телендә аралаша алу өчен белгечләр үзләштерергә тиешле иң актив кулланышта булган минимум татар сүзләре тупланмасы була. Мондый сүзлек-минимумнар утызга якын фән һәм халык хуҗалыгы тармакларын берләштерә: Г.И. Мустафина «Краткий русско-татарский словарь исторических терминов» [1993-РТ_истор]; Ф.С. Баязитова «Краткий русско-татарский словарь для работников ЗАГСа» [1994-РТ_загс]; М.М. Миннебаев «Краткий русско-татарский толковый словарь медицинских терминов» [1994-РТ_медиц]; И.М. Низамов «Краткий русско-татарский общественно-политический словарь» [1995-РТ_общ/полит]; Д.Б. Рамазанова «Краткий русско-татарский словарь для работников культуры» [1995-РТ_культ]; Т.Х. Хайрутдинова «Краткий русско-татарский словарь для работников общественного питания»[1995-РТ_общепит]; Ф.Ф. Гаффарова, З.Р. Садыкова «Краткий русско-татарский словарь для работников сельского хозяйства» [1995-РТ_с/х]; М.Г. Мухаммадиев «Краткий русско-татарский словарь для работников торговли» [1995-РТ_торг]; Р.Р. Абдуллина «Русско-татарский словарь-минимум для работников предприятий бытового обслуживания» [1995-РТ_бытов/обсл]; А.Г. Гаянов «Русско-татарский словарь-минимум для работников леса» [1995-РТ_лес]; Р.Р. Шәмсетдинова «Сәламәтлек саклау хезмәткәрләре өчен русча-татарча сүзлекчә» [1995-РТ_сәлам/сак]; Р.Г. Гатауллина «Русско-татарский словарь-минимум для работников связи» [1996-РТ_связь]; Д.Б. Рамазанова, Ф.И. Тагирова «Краткий

русско-татарский словарь для работников транспорта» [1996-РТ_трансп]; Р.И. Халиуллин, Н.Ш. Мифтахова «Русско-татарский словарь-минимум для работников химической промышленности» [1996-РТ_хим]; М.Б. Газизов, Р.З. Фахрутдинов «Русско-татарский словарь-минимум для работников нефтяной промышленности» [1996-РТ_нефт]; Р.Г. Ахметьянов, Р.А. Шакирзянов «Русско-татарский словарь-минимум для строителей» [1996-РТ_строит]; К.Р. Галиуллин, Ф.С. Сафиуллина «Краткий русско-татарский словарь для работников народного образования» [1997-РТ_образов]; М.М. Гимадиев, А.И. Щеповских «Краткий русско-татарский словарь для работников охраны природы» [1997-РТ_охр/прир]; Г.Г. Саберова «Русско-татарский словарь-минимум для работников лесной промышленности» [1997-РТ_лес/пром]; А.Г Гараев «Русско-татарский словарь-минимум для работников физического воспитания и спорта» [1998-РТ_физвосп]; С.Ф. Гарифуллин «Краткий русско-татарский словарь для бизнесменов и предпринимателей» [1999-РТ_бизнес]; И.М. Низамов «Русско-татарский словарь-минимум для работников государственно управленческого аппарата и общественных организаций» [2001-РТ_гос.-упр] һ.б.

Сүзлек-минимумнар нигезендә яңа терминологик сүзлекләр төзелә башлый. Терминнарны татарчалаштыруда галимнәр алдында рус атамаларының фәнни нигезен бозмыйча, татар теле грамматикасы нормаларына туры китереп, терминның эчтәлеген кыска һәм дөрес итеп атау бурычы баса. Татар терминологиясен көндәлек тормышка кайтару, гамәлгә кую, гыйльми әйләнешкә кертү татар тел белеме үсешенең әһәмиятле мәсьәләләренең беренчесенә әверелә. Бу мәсьәләнең мөһим өлеше татар тәрҗемә терминологиясен камилләштерүдән, бердәйләштерүдән, аны гыйльми калыплаштырудан гыйбарәт. Теләсә кайсы чорда терминология эшләү барышында бу проблемалар иртәме соңмы килеп баса. Бу мәсьәләдә «Русча-татарча иҗтимагый-сәяси сүзлек» [**1997**-РТ_иҗт/сәяси] игътибарга лаек. 1996 елның декабрендә үткәрелгән «Татар теле терминологиясен камилләштерү мәсьәләләре» дигән фәнни-гамәли конференциядә, матбугатта еш кулланыла торган иҗтимагый-сәяси терминнарны, сүзләрне, гыйбарәләрне бердәйләштерү максатыннан, русча-татарча сүзлек чыгару кирәклеге әйтелә. Шул нигездә югарыда аталган сүзлек басылып чыга. Сүзлеккә иҗтимагый-сәяси тормышта еш кулланыла торган сүзләрне һәм

тезмәләрне теркәп, аларны русчадан татарчага тәрҗемә итеп бирү һәм татар теле белән эш итүчеләр өчен төп кулланмага әйләндереп, терминнарның бердәйлегенә ирешү бурычы куела. Ул шул вакыттагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.М. Харисов җитәкчелегендә эшләнә. Филология фәннәре докторы Ф.Ә. Ганиев, филология фәннәре докторы И.М. Низамов, тәрҗемәчеләр Ф.Г. Тарханова, Н.Г. Хәйруллина тарафыннан төзелә. Сүзлекнең «Сүз башы» авторы – ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин. «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру комитеты бу сүзлектәге русча терминнарның, сүзләрнең һәм гыйбарәләрнең татарчага тәрҗемәләрен канәгатьләнерлек дип таба һәм, татар теле белән эш итү өчен, барлык предприятие, оешма һәм учреждениеләргә аларны файдаланырга тәкъдим итә» (3 б.). Сүзлек төзү тәртибе алда күзәтелгән сүзлекләрдәге принципларны саклый.

Р.Г. Әхмәтьянов редакциясендә Р.Ә. Шакирҗанов төзегән «Русча-татарча төзелеш атамалары сүзлеге» [1992-РТ_төзел] татар телендәге эквивалентлары, тәрҗемәләре, күп төрле синоним вариантлары, шул исәптән гарәп, фарсы алынмалары, борынгы атамалары китерелүе белән аерылып тора: мәс.,

| | |
|---|---|
| открытие | ачу; ачыш, уйлап табу, кәшеф, кәшфия |
| смета | мәстәр, смета |
| яд | агу, ачы, зәһәр һ.б. |

Бер русча терминга, халык сөйләм теленнән һәм диалектлардан да алып, берничә татар сүзе күрсәтүне авторлар телдә булган терминнарны барлап, сайлап алу мөмкинлеген киңрәк булдыру максатында бирүләрен, терминнарның берсе киләчәктә телдә тулы гражданлык хокукы алыр, икенчесе вакыт сынавы белән төшеп калыр дип уйлап эшләүләрен әйтәләр. Гадәттә, аларның беренчесе конкрет төп термин буларак тәкъдим ителә, икенчесе, стиленә карап, популяр язмалар өчен яраклы булыр дип күрсәтелә: мәс.,

| | |
|---|---|
| потоп | туфан, ташкын, су басу |
| рама | рам, кыса эрәтә; йөзлек, яңак... |

Мәгънә аермалары нокталы өтер (;) белән аерымлана.

Сүзлек ыру термин ярдәмендә ясалган төр терминнарны оялап бирү юлы белән төзелә. Бу рәвешле бирү төп терминның эчтәлеген

тулырак ачарга һәм аны тулы бер система буларак күз алдына китерергә ярдәм итә: мәс.,

| | |
|---|---|
| метод | метод, алым, юл, ысул |
| – аналитический | аналитик метод |
| – вырезания узлов | төеннәр кисү методы |
| – графический | график (җәдвәли) метод |
| – графоаналитический | графоаналитик метод һ.б. |

Бу сүзлектә төзелеш эшендә киң кулланылган техник терминнарга зур урын бирелә. Барысы 18500 архитектура, сәнәгый һәм иҗтимагый төзелеш, инженер корылмалар һәм конструкцияләр, төзелеш икътисады һәм аны оештыру, төзелеш эшләрен механикалаштыру, шәһәрләр төзү һәм тору үзәкләрен планлаштыру, авыл хуҗалыгында төзелеш, гидромелиорация һ.б. өлкәләргә караган терминнар теркәлә.

Ул чорда басылган русча-татарча сүзлекләр яшәешнең, фәнни юнәлешләрнең күп төрле тармакларына карый. Х.Г. Шәрипов, М.М. Мәүләтшин «Татар теленең юридик терминнар сүзлеге» [1994-РТ_юрид]; Ф.А. Ганиев редакциясендә К.Ф. Әмировның «Русча-татарча юридик сүзлек» [1996-РТ_юрид]; И.Г. Галәветдинов, Г.Г. Гафуров, В.З. Закиров, М.З. Хөснетдинов «Математикадан русча-татарча белешмә сүзлек» [1997-РТ_матем]; И.Г. Алмазов, Д.Б. Рамазанова «Русско-татарский словарь для работников музыкальных учреждений» [1997-РТ_музык]; Ф.И. Әгъзамов «Русча-татарча журналистика терминнары сүзлеге» [1998-РТ_журн]; Р.А. Мугинов «Русско-татарский словарь военных терминов» [2000-РТ_воен]; А.К. Юлдашев, А.З. Әфләтунов, А.Х. Зимагулов, Р.Г. Нуруллин «Русча-татарча техник терминнар сүзлеге» [2000-РТ_техн]; Н.С. Әхмәтова редакциясендә Н.Ш. Мифтахова төзегән «Русча-татарча химик терминнар сүзлеге» [2002-РТ_хим]; М.М. Гыймадиев, Н.Х. Әмиров, К.Ш. Зыятдинов «Медицинадан русча-татарча аңлатмалы сүзлек» [2003-РТ_медиц]; Ф.С. Хәкимҗанов, Р.А. Шакирҗанов, З.Г. Хәбипова, М.Н. Мингазов «Русча-татарча нефть сәнәгате сүзлеге» [2004-РТ_нефт]; Р.Р. Сафиуллина «Мөселман терминологиясе сүзлеге» [2006-РТ_ислам] һ.б.

Аларның кайберләренә аерым-аерым тукталып үтик:

Ф.Г. Ситдиков, Р.К. Зәкиев, А.Б. Халидов һ.б. төзегән «Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек» [1998-РТ_биол] био-

логиядән фәнни белешмә басма буларак тәкъдим ителә. Алынма сүзләрнең килеп чыгышы җентекле аңлатыла. Атаманың чыганак теле һәм шул телдәге мәгънәсе күрсәтелә: мәс.,

Капсид (лат. capsa сыем, савыт) Капсид – вирусларның аксым сүрүе. К. геометриясе вирусларны классификацияләгәндә төп күрсәткеч булып тора һ.б.

Биологиянең төрле тармакларына, бигрәк тә Кызыл китапка кертелгән Татарстан флорасы һәм фаунасына караган 10 меңләп термин һәм терминологик сүзтезмәләр туплап бирелә. Аларның һәрберсенә татар телендә аңлатмалар китерелә. Татарчага тәрҗемәсендә фәнни терминнар белән генә чикләнмичә, бигрәк тә үсемлекләрнең халык телендә йөргән атамалары да күрсәтелә. Бу – сүзлекнең эчтәлеген тагы да баета, аның лингвистик әһәмиятен арттыра.

Р.У. Измайлова җитәкчелегендә Г.Г. Габдельганиева, Ф.С. Сафиуллина, Г.Г. Шаһиәхмәтова, И.Г. Һадиев, Р.С. Ханнанова, М.Х. Шакирова төзегән «Русско-татарский словарь для работников библиотек, издательств и информационных служб» [1998-РТ_библ/изд] сүзлеге үзендә 3 меңнән артык терминны туплый. Ул китапханә, китап гыйлеме, библиография төзү, информатика, китап басу, полиграфия, китап сәүдәсе һ.б. үз эченә ала. Җәяләр эчендә сүзнең кулланылу даирәсе күрсәтелә: мәс.,

| | |
|---|---|
| заголовок (*полигр.*) | баш исем (*полигр.*) |
| – в подбор с текстом | текст белән бер тигезлектә ... |
| – в разрез с текстом | тексттан аермалы ... |
| – на спуске | буш калган урында ... |

Татарча терминнарның мөмкин булган барлык вариантлары, синонимнары китерелә: мәс.,

Каллиграфия хаттатлык (*хөснехат, каллиграфия*) һ.б.

Бу терминның вакыт дәвамында да, жанрга карап та сайлану мөмкинлеген киңәйтә.

Ф.М. Газизова төзегән «Русча-татарча икътисади атамалар сүзлеге» [1999-РТ_икът] барлыгы 14500 термин, тезмә атамалар, темага караган сүзтезмәләрне үз эченә ала. Алар гомум икътисад, бюджет, финанс, валюта, салым мәсьәләләренә, бухгалтерлык исәбенә, аудит, маркетинг һ.б. шундый өлкәләренә карый. Сүзлек татар алфавитын латин графикасына күчерү мәсьәләсе күтәрелгән

чорда төзелү сәбәпле, автор татарча тәрҗемә өлешне бер үк вакытта латиница белән дә, кириллица белән дә бирүне карар кылган.

Җ.Ш. Сөләйманов, Ә.Ф. Галимҗанов тарафыннан «Информатика буенча русча-татарча сүзнамә»дә [2001-РТ_информ] 2 мең тирәсе термин һәм тәгъбир тәкъдим ителә. Авторларның белдерүенчә, сүзнамәдә русча-татарча терминнарның мөмкин кадәр тулы тупланмасын җыю максаты куела. Информатика өлкәсенә караган татар телендәге терминнарны укучыга җиткерү, кулланышка кертү бурычы йөкләнә. Авторлар, киләчәктә төзеләчәк сүзлек хакында фикер алышу өчен, рус һәм халыкара терминнарга татар теленең үз нигезендә ясалган тәрҗемәләрен тәкъдим итәләр: мәс., компьютер – санак, монитор – күрәк, меню – сайлак, принтер – басак, база данных – тамгасар, клавиатура – төймәсар һ.б.

Ф.С. Хәкимҗанов, Р.А. Шакирҗанов редакциясендә Ф.С. Хәкимҗанов, Р.А. Шакирҗанов, З.Г. Хәбипова, М.Н. Мингазов төзегән «Русча-татарча нефть сәнәгате сүзлеге»ндә [2004-РТ_нефт] геология, нефть һәм газ ятмаларын табу, аларны чыгару сәнәгате, эшкәртү химиясе һәм технологиясе өлкәләрендә кулланылган, скважиналарны бораулау, нефть һәм газ җыю, саклау, транспортлауда файдаланыла торган җиһазлар, кораллар, матдәләр, материаллар белән бәйле 27 меңнән артык термин туплап теркәлгән. Сүзлек рус телендәге терминнарга татарча эквивалентлар күрсәтүдән гыйбарәт икетелле тәрҗемәле сүзлек буларак төзелгән. Аерым терминнарга кыскача аңлатмалар да китерелгән: мәс.,

| | |
|---|---|
| КЛИРЕНС | ара, аралык |
| ~ в вышке | вышка / каланча аралыгы (*бораулау мәйданчыгы белән кронблок мәйданчыгы арасы*) һ.б. |

Кирәк очракларда аерым сүзләрнең кулланылу даирәсе күрсәтелгән: мәс.,

АНТИКЛИНАЛЬ**геол.* калкым

Йолдызчык (*) билгесе сүзнең татар телендә дә шул ук сүз белән үзгәрешсез кулланылуын аңлата.

Сүзлек төзелешендә төр атамаларын ыру атамасы оясында бирү төп алым булып тора: мәс.,

| | |
|---|---|
| НАГНЕТАТЕЛЬ | кудыргыч |
| поршневой ~ | пешкәкле кудыргыч |
| центробежный ~ | үзәктән кудыргыч |

центростремительный ~ үзәккә кудыргыч һ.б

Үз өлкәсендә зур күләмдә татар телендә терминнар туплау буенча әлеге сүзлек – беренче әһәмиятле тәҗрибә.

Р.Р. Шәмсетдинова «Медицина терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге»нә [2004-РТ_медиц] барлыгы 10 мең сүз туплап терки. Терминнарның һәрберсенә татар телендә аңлатмалар китерелгән, аларның тәрҗемәләре, эквивалентлары, диалектларда очраган синонимнары һәм тарихи терминнарда күрсәтелеп тулыландырылган: мәс.,

МИГРЕНЬ мигрень, баш өянәге, баш авырту (гадәттә башның бер яртысында була, артык ару яки дулкынланудан соң күзәтелә).

НЕРВ нерв, сизү тамыры, теңкә.

СЕСАМОВИДНЫЕ КОСТИ бәбер сөякләре (кул чугы һәм табандагы сөякләр, сесам-көнҗет, бу сөякләр формалары белән көнҗет орлыгына охшаган) һ.б.

Төр терминнарын ыру термин янында оялап бирү сүзлек төзелешенең төп алымы булып тора: мәс.,

РЕАКЦИЯ реакция (кеше организмының, психикасының төрле тәэсирләргә җавабы, реакциясе)

| | |
|---|---|
| р. кожная | тире реакциясе |
| р. ответная | җавап реакциясе |
| р. Пирке | Пирке реакциясе |
| р. туберкулиновая | туберкулин реакциясе |

Сүзлек ахырында, беренче кушымта итеп, грек-латин термоэлементларының татар телендә мәгънәләре аңлатылган, икенче кушымта итеп, татарларда медицина фәненең һәм аның теленең барлыкка килүенә, үсүенә рус һәм татар телләрендә күзәтү ясалган.

Ф.Г. Нәбиев, Р.Г. Госманов, Р.И. Ситдиков, М.Ш. Шакуров һ.б.төзегән «Ветеринария медицинасы терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге»нә [2004-РТ_ветерин] барлыгы 6 мең сүз тупланган. Терминнар тематик төркемнәргә бүлеп бирелгән. Ул 16 бүлектән тора: акушерлык, анатомия, биохимия, ботаника, генетика, гистология һ.б. Аларның һәрберсе ветеринария медицинасы фәненә караган 400–500 гә якын терминны үзендә туплый. Сүзлек ахырында һәр бүлектә тупланган терминнарның татарча-русча лөгатьлеге урнаштырылган. Сүзлекне төзегән авторлар турында белешмә бирелгән.

Г.Г. Хисамиев гомуми редакциясендә чыккан, Г.Г. Хисамиев, А.И. Нарбеков, Н.Х. Әмиров, И.А. Абдуллин, А.М. Галеев төзегән «Химиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек» [2004-РТ_хим] хәзерге чорның гомуми, органик, неорганик, физик химияләрдә, коллоидлар химиясендә, экология фәнендә, көнкүрештә, җитештерү өлкәсендә, авыл хуҗалыгында, ветеринариядә, медицинада еш кулланыла торган фәнни атамаларны үз эченә ала. Алынма сүзләрнең чыганак теле, татарча тәрҗемәсе белән шул телдәге язылышы күрсәтелеп, этимологик белешмәсе бирелә: мәс.,

Ингредиент [лат. ingrediens керүче] Ингредиент, тәшкиләт – нинди дә булса катлаулы кушылманың яки катнашманың состав өлеше.

Сапропель [гр. sapros черек + pelos ләм] Черек ләм, сапропель – күл, буа һ.б. сулыклардагы үсемлекләр һәм судагы организм калдыкларыннан торган органик ләм, коры сулыклардагы утырма катлам... Ашлама сыйфатында кулланыла.

Термин белән бәйле кызыклы тарихи мәгълүматлар китерелә: мәс.,

Чугун [төркичәдән] Чуен – домна процессы продукты (тимер белән углерод эретмәсе)... Алтын Урдада XIII гасырда «Шайтан каласы» дигән шәһәрчектә (хәзерге Татарстанда Алабуга шәһәре янында) чуен кою турында мәгълүмат бар. Моны Татарстан җирлегендә 36 домна миче табылу да раслый.

Терминны фәнни әйләнешкә кертеп җибәргән яки термин ясалышында катнашы булган галимнәр күрсәтелә: мәс.,

Реактив Швейцера Швейцер реактивы – икевалентлы бакыр оксидының аммиактагы эремәсе. Анда целлюлоза эри. Немец табибы А.Швейцер (1875–1965) исеме белән бәйле.

Реакция Камая Камай реакциясе – дүртхлорлы углерод белән фосфат кислотасының алкиллы эфирлары тәэсир итешү реакцияләре... Татарлардан беренче химия фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты ректоры Г.Х. Камай (1901–1970) исеме белән аталган.

Реакция Миллона Миллон реакциясе – аксымнарга хас сыйфат реакциясе; нитрит кислотасындагы терекөмеш нитриты тәэсирендә аксымнарның коңгырт кызыл төстәге утырым хасил итүе... Хлор (III) оксидын (1843), хлорат кислотасын ачкан (1842) фран-

цуз химигы, фармацевты Э.Миллон (1812–1867) тарафыннан 1849 елда тәкъдим ителгән.

Мондый тарихи фактларны күрсәтү сүзлекнең мәгълүматлылыгын арттыра, укучы өчен аны тагын да кызыклы итә.

Сүзлек ахырында татарча-русча химия терминнарының аңлатмасыз гына сүзлекчәсе һәм кушымталар урнаштырыла.

Р.Ф. Галләмов «Русча-татарча тарих терминнарының аңлатмалы сүзлеге»нә [2006-РТ_тарих] 6 мең термин туплап бирә. Аларның татарча эквивалентлары, кулланышта булган барлык вариантлары, сүзгә төгәл атама табылмаганда, тәрҗемә сүзтезмәләр китерелгән. Аерым сүзләрнең кулланылыш даирәсе күрсәтелгән: мәс.,

Рында (*ист.*) сарай сакчысы, сарай каравылчысы; җан сакчысы, тән сакчысы (XV–XVII йөзләрдә Мәскәү дәүләте патша сараенда) һ.б.

Сүзлекнең төп өлешеннән соң аерым тематика белән унике кушымта урнаштырылган: Урта һәм Түбән Идел буе археологик культуралары; Урта һәм Түбән Идел буе археологик культуралары кабиләләре; Борынгы халыклар, кабиләләр һәм кабилә берлекләре; Тарихи география төшенчәләре һәм атамалары; Казан шәһәренең тарихи географиясе төшенчәләре һәм атамалары; Тарихи шәһәрләр; Патша, хан, хәлифә, солтан, император династияләре; Тарихи шәхесләр; Урта гасырларда халыкара сәүдә товарлары; Аеруча күп очрый торган археологик табылдыклар; Һөнәрчелек һәм зәркәнчелек сәнагате; Канатлы сүзләр, гыйбарәләр һәм шигарьләр. Кушымталарда укучыга тәкъдим ителгән тарихи фактлар сүзлекнең мәгълүматлылыгын тагын да арттырган һәм кызыклырак иткән.

И.Г. Алмазов, Д.Б. Рамазанова «Русско-татарский музыкальный словарь» [2007-РТ_музык] хезмәтендә авторлар тарафыннан бай күләмдә музыка өлкәсенә караган атамалар тупланган, шул исәптән күпсанлы алынма атамалар, төрле халыкларның уен кораллары һәм аларның аерым өлешләрен билгеләгән терминнар тәкъдим ителгән, татар телендә тәрҗемәләре, эквивалентлары күрсәтелгән. Алынма терминнарның җәяләр эчендә чыганак телдәге тәңгәлләре китерелгән: мәс.,

Пиццикато (итал. *pizzicato* – играть без смычка, т.е. щипком) сызгычсыз, чиртеп-чиртеп.

Атаманың этимологиясен ачыклап күрсәтү аның эчтәлеген ачыграк чагылдыру һәм мәгънәсен тулырак аңлау өчен мөһим. Күпчелек атамаларга җәяләр эчендә аңлатмалар бирелгән: мәс.,

Си – си (1. билге/нота исеме; 2. музыкаль авазлар тәгълиматындагы соңгы, җиденче баскыч).

Эфы – ярык (кыллы уен коралларында тавыш көчәйткеч ярык).

Сүзлектә төрки, татар һәм башка халыкларның уен кораллары атамалары да күрсәтелә: мәс.,

Зурна (тюрк.) сорнай (ике көпшәле, тынлы уен коралы; нигездә, Якын Көнчыгышта таралган)

Кавал (тат.) кәвәл (сыбызгылы агач флейта).

Кубыз (тюрк.) кубыз (татар, башкорт халыкларының үзьяңгырашлы уен коралы); башка исемнәре: кылкубыз, чаңкубыз (тимердән, ә борынгы заманда агачтан яки сөяктән эшләнгән).

Соломенный курай (тат.) камыл курай.

Тар (тюрк.) тар (кыллы музыка уен коралы).

Узъыгумы (удмурт.) узъыгумы (удмурт халкының курайга охшаган буй флейтасы)

Шан (тув.) шан (шаулы бәрмә уен коралы).

Шанзы (тув.) шанзы (чиртмә уен коралы).

Шахлыча, шахлич (чув.) шахлич (чуваш халкының буй флейтасы).

Бу сүзлек музыка өлкәсендә татарча терминнар булдыруның бер зур тәҗрибәсе булып тора. Аны баетуда, камилләштерүдә музыка һәм тел белгечләренең, музыка укытучыларының алга таба да фидакяр хезмәте сорала.

Ф.Ф. Гаффарова редакциясендә А.Х. Зимагулов, Р.Г. Нуруллин, Ф.И. Габдрахманов, Н.Ф. Нигматуллин төзегән «Охрана труда в сельском хозяйстве: русско-татарский словарь» [2008-РТ_охр/тр] хезмәтенә дә тукталып китү урынлы булыр. Сүзлеккә халыкара атамалар, бигрәк тә техник терминнар күпләп теркәлгән. Рус телендә ясалган атамалар да шактый күзәтелә. Тәрҗемәләрдә татар телендә булган атамаларны тулырак күрсәтү максаты куелган. Диалектлардан алынган вариантлар да, кулланыштан чыккан тарихи сүзләр һәм гыйбарәләр дә китерелгән. Татар теленең эчке мөмкинлекләренә нигезләнеп ясалган атамалар, калькалар да бирелә.

Кайбер терминнарның тәрҗемәләре автор-төзүчеләр тарафыннан беренче тапкыр тәкъдим ителә: мәс.,

Водокачка– сукугыч

Капельница – тамызгыч

Кайбер терминнарны үзләштерүне җиңеләйтү максатында, җәяләр эчендә аларга кыскача татарча аңлатмалар китерелгән: мәс.,

Сейсмометр – сейсмометр (*Җир кабыгындагы тирбәлешләрне күзәтү приборы*) һ.б.

Сүзлеккә якынча 4800 термин туплап бирелгән. Ул автор-төзүчеләрнең югары уку йортларында техник һәм хезмәт иминлеге фәннәрен укыту тәҗрибәсенә нигезләнеп эшләнгән.

А.С. Тайсин, Г.В. Сонин, И.А. Уразметов һ.б. тарафыннан төзелгән «Русско-татарский толковый словарь географических терминов» [2010-РТ_геогр] сүзлегендә барлыгы 4 меңгә якын термин тупланып бирелгән. Аларның һәрберсенә татар телендә аңлатмалар китерелгән. Җәяләр эчендә чит телләрдән кергән атамаларның чыганак теле күрсәтелгән, мәгънәләре татарча шәрехләнгән: мәс.,

**Гидрофиты** Гидрофитлар (грек. hydor – су һәм phyton – үсемлек) – аскы өлешләре белән суга күмелеп, тамырлары белән су төбенә береккән үсемлекләр (мәс., дөге, укъяфрак, камыш).

Атаманың телдә кулланылган кыска, төгәл татарча **эквиваленты** булмаган очракта, аның тәрҗемәсе сүзтезмә ярдәмендә тәкъдим ителгән: мәс.,

**Немытые почвы** Юып китерелгән туфраклар – күбесенчә авышлык итәкләрендә, коры елга һәм ерым төпләрендә барган делювиаль процесслар нәтиҗәсендә формалашкан туфраклар һ.б.

Сүзлектә тупланган сүзләрнең күбесе физик географиягә карый. Шулай ук геология, биогеография, картография, атмосфера һәм климат, гидрология, ландшафт белеме, геоэкология, космогония бүлекләреннән дә терминнар теркәлгән.

**Л.И. Галиева, И.Г. Галяутдинов, М.З. Хуснетдинов, И.Б. Гарипов, Ф.Г. Мухлисов** «Математический русско-татарский толковый словарь» [2013-РТ_матем]. Сүзлеккә 2 мең тирәсе термин теркәлгән. Һәр терминга аңлатмалар бирелгән. Ахырда антик чорлардан башлап бүгенге көнгәчә иҗат иткән бөтендөнья күләмендәге мәшһүр математиклар турында биографик белешмә китерелгән, Казан математиклары турында аерым белешмә урнаштырылган.

Р.Т. Сәфәров редакциясендә Ф.Г. Ваһапова төзегән «Тасвири сәнгать, архитектура һәм китап сәнгате атамалары аңлатмалы сүзлеге»ндә [2011-РТ_тасв/сән] бөтен чорларга һәм дөнья халыкларына караган сәнгать белән бәйле атамалар туплап бирелә. Чит телләрдән кергән атамаларның этимологиясе ачыклана. Җәяләр эчендә чыганак теле, язылышы күрсәтелеп, аларның мәгънәсе аңлатыла: мәс.,

**СИНКРЕТИЗМ** [греч. synkretismys соединение] – смешение религиозных систем и культовразнородных элементов культуры.

**СИНКРЕТИЗМ** – дини системалар һәм гыйбадәтләр культурасындагы

төрле элементларның кушылуы.

Күренгәнчә, терминга аңлатмалар рус һәм татар телләрендә бирелгән.

**ГЕММА** [лат. gemma – почка, глазок] – изображение или надпись, вырезанное на драгоценном камне.

Геммы служили главным образом личными печатями.

**ГЕММА** – асылташка сырлап ясалган сурәт яки язу. Башлыча алар шәхси мөһер буларак хезмәт иткән.

Сүзлектә кулланыштан төшеп, хәзерге әдәбиятта күренмәгән тарихи сүзләр дә урын алган: мәс., *әбелһәүл, әһрам, калаф, мигъмарлык, чәмчә* һ.б.

Соңгы елларда басылган сүзлекләрдә рус фәнни терминнарына татар телендәге тәңгәлләрен күрсәтү, яңаларын булдыру, татар телендә аңлатмалар бирү белән чикләнмичә, ике телдә дә термин күрсәтелгән урынны җиңел табу мөмкинлекләре дә кайгыртыла. Аларның төрле юллары билгеләнә. Әлеге сүзлек ахырында кушымта рәвешендә терминнарның аңлатмаларсыз гына алфавит тәртибендәге ике телле татарча-русча сүзлекчәсе китерелә: мәс.,

**Рәсем сәнгате** – живопись

**Рәсемле кулъязма** – лицевая рукопись

**Рәсми басма** – официальное издание һ.б.

Сүзлекчәнең рус телендә күрсәтелгән терминнары нигезендә төп сүзлектән аңлатмаларны да табу, аны ике телдә дә файдалана алу мөмкинлеге барлыкка килә.

Ф.И. Таһирова һәм Ф.Ф. Гаффарова редакциясендә, О.Н. Галимова, И.И. Сабитова, Р.Р. Абдуллина, Ф.Ф Гаффарова, Ф.И. Таһи-

рова, Ф.К. Сагдеева төзегән «**Русско-татарский толковый словарь лингвистических терминов**» [2016-РТ_лингв] сүзлегендә рус телендә ясалган якынча 2250 лингвистик терминның татар телендәге эквивалентлары, тәрҗемә тиңдәшләре, калькалары, телдә булган вариантлары туплап бирелә. Һәр терминга татар телендә аңлатмалар китерелә: мәс.,

**ДЕМАРКАЦИЯ** ДЕМАРКАЦИЯ Иҗек аеру өчен кулланыла торган фонетик чара тамгасы.

**КРАТКИЕ ГЛАСНЫЕ** КЫСКА СУЗЫКЛАР Сөйләм темпы бер үк дәрәҗәдә булганда, озын сузык белән чагыштырганда кыскарак әйтелгән сузыклар.

Әлеге сүзлектә ике телдә дә терминның күрсәтелгән урынын табу өчен икенче төрле юл билгеләнә. Бу максатта сүзлек ахырында татар телендәге терминнарның алфавит тәртибендәге күрсәткече бирелә, терминны табу өчен аның урнашкан бите күрсәтелә: мәс.,

Аңкау гармониясе н, 97

Ягъни бу терминга аңлатма «Н» хәрефендә, 97 биттә.

Бугаз тартыклар г, 37

Җыйма күплек м, 90

Кабатлаулы күптән үткән заман м, 89; м, 90

Алда күрсәтелгән ике төрле алым терминнарны сүзлекләрдән ике телдә дә эзләп таба алу мөмкинлеген барлыкка китерә һәм аның кулланыш сферасын бермә-бер арттыра.

Р.Ә. Шакирҗанов редакциясендә, Р.Ә. Шакирҗанов, М.Б. Һадиев, Р.Г. Галимуллин, Д.Г. Галимов, Р.Ә. Вәлиев, А.И. Нарбеков, Г.М. Мөбәрәкҗанов, Ә.Ф. Галимҗанов төзегән «**Русча-татарча политехника сүзлеге**»ндә [2016-РТ_политех] системалаштырылган 9 меңнән артык халыкара фәнни-техник терминология рус һәм татар телләрендә урын алган. Гамәлдә ул хәзерге чор техник дисциплиналарның терминнарын бергә туплаган сүзлек булып тора. Үзенең күләме белән дә, эчтәлеге белән дә моңа кадәр татар телендә басылган техник сүзлекләрдән бай һәм күп тармаклы булуы белән аерыла. Анда сәнәгатьнең төрле тармаклары – машина төзелеше, энергетика, транспорт, төзелеш, металлургия, элемтә, файдалы казылмаларны табу һәм эшкәртүгә караган терминнар зур урын алган. Фән һәм техниканың өстенлекле юнәлешләре булган электроника, информатика, квант механикасы, төш физикасы, авиация,

космонавтика, радиофизика терминнары да урнаштырылган. Плазма, ультратавыш, электроннар агымы, лазер техникасы, инфракызыл һәм башка төр нурланышлар куллану буенча яңа технологиягә һәм нанотехнологиягә багышланган мәкаләләр дә кертелгән. Шулай ук астрономия, архитектура, геология, медицина, техник эстетика, физика, химия, механика, математика һ.б. фәннәрнең гамәли юнәлешләренә караган терминнар да чагылыш тапкан. Сүзлек хаклы рәвештә политехника сүзлеге атамасын алган.

Авторлар эшне соңгы елларда татар терминологиясендә тупланган тәҗрибә нигезендә алып барган. Сүзлекнең лөгатьлеге рус телендәге терминнардан тора. Алынма сүзләрнең җәяләр эчендә этимологиясе күзәтелә һәм төшенчәгә аңлатма бирелә: мәс.,

**АКСЕЛЕРОГРАФ** [лат. *accelero* тизләтәм + гр. *grapho* язам] тизләнешне автоматик язып бара торган прибор. Авиация, виброметрия, сейсмология һ.б. өлкәләрдә кулланыла.

Терминнарның тәрҗемәләрендә татар теленең борынгыдан килгән үз атамаларына өстенлек бирелә, диалектизмнарга мөрәҗәгать ителә, сүз кулланыштан чыккан пассив лексикадан булса, аның этимологиясе ачыклана: мәс.,

**КОЗЫРЁК** [тат. *кузыр*] КУЗЫР – бина түбәсенең, тышкы ишек өстенең диварны, керү юлын кар-яңгырдан саклый торган чыгынты өлеше.

**КУЗОВ АВТОМОБИЛЯ** [тат. *козау,* әрҗә, тартма] АВТОМОБИЛЬ КУЗАВЫ...

**САНДРИК** [тат. *сәндрә*] СӘНДРӘ – бина ишеге яки тәрәзәсе өстендә зур булмаган кәрниз яки фронтон рәвешендәге бизәгеч деталь; кайчакта колаксага таянырга мөмкин һ.б.

Шул ук вакытта авторлар телдә урнашып, кулланышка кереп бара торган яңа сүзләр – неологизмнарга да мөрәҗәгать итәләр: мәс.,

**БУТОВЫЙ КАМЕНЬ БУТТАШ...**
**ЗАРЯД КОРГЫ, КОРЫЛМА...**
**НАГРУЗКА ЙӨКЛӘМ...**
**ПОРОШОК ОНТА... һ.б.**

Аерым мәкаләләрдә терминны ачыклаган рәсемнәр дә китерелә. Сүзлектә барлыгы 600 дән артык рәсем кулланылган. Сүзлек ахырында 7 таблицада төп, өстәмә һәм чыгарылма берәмлекләр,

кайбер фундаменталь константалар, татарлар элек кулланган үлчәү берәмлекләре һ.б.лар кушымта итеп китерелгән.

Шул рәвешле, сүзлектә татар терминологиясе **авторлар** тарафыннан бөтендөнья табигать һәм техник фәннәр үсешенең хәзерге чоры дәрәҗәсендә системалаштырылган.

Сүзлекнең электрон вариантыннан да файдаланырга мөмкин: www.vk.com/magarifvakyt.

З.А. Хусаинов «Русско-татарский толковый словарь географических терминов» [2017-РТ_геогр]. Сүзлектә барлыгы 4 меңгә якын термин туплап бирелгән. Чит телләрдән кергән атамаларның җәяләр эчендә чыганак теле, язылышы бирелеп, татарча мәгънәләре күрсәтелгән. Терминнарга татарча аңлатмалар китерелгән: мәс.,

**Дрейф** Дрейф (ингл. drijven – куу, йөзү) – судно яки бозның җил яки агым тәэсирендә хәрәкәт итүе.

Монда күп кенә физик-географик, сәяси-хакимият бүленешләренә, геология, геодезия, топография, экология, метеорология һ.б. фәннәргә караган терминнар теркәлгән.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының норматив-хокукый документлары текстларын тәрҗемә итү һәм тәңгәлләштерү бүлеге мөдире Н. Хәйруллина тарафыннан «Русча-татарча иҗтимагый-сәяси сүзлек» [2018-РТ_иҗт/сәяси] төзелгән. Сүзлекнең «Сүз башы»н ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин язган.

Сүз башында: «Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы үз эшчәнлеген татар һәм рус телләрендә гамәлгә ашыра. Әлеге иҗтимагый-сәяси сүзлек Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителгән законнарны һәм норматив хокукый актларны тәрҗемә итү һәм тәңгәлләштерү тәҗрибәсен искә алып төзелде», – диелә. – «Сүзлекнең максаты – киң катлау укучыларга рәсми документлар әйләнешендә аеруча еш кулланыла торган төп төшенчәләрне һәм терминнарны үз эченә алган аңлаешлы, куллану өчен уңайлы белешмә тәкъдим итү», – дип күрсәтелә.

Әлеге сүзлектә телебездә рәсми документлар әйләнешендә еш кулланыла торган терминнар, сүзләр, гыйбарәләр туплап бирелгән. Шулай ук рәсми исемнәр һәм атамаларга, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә, бәйрәмнәргә, һөнәри бәйрәмнәргә һәм истәлекле даталарга, республиканың муниципаль

берәмлекләренең русча һәм татарча әйтелешенә багышланган аерым бүлекләр дә урнаштырылган.

Соңгы елларда тар белгечлек буенча төзелгән терминологик сүзлекләр дә күренә башлады. Мәс., Н.З. Хазипов җитәкчелегендә төзелгән Т.Р. Якуповның «Русча-татарча биохимик атамалар сүзлеге» [2000-РТ_биохим]; М.Ю. Гыйләҗев, С.Г. Мортазина, Ф.Ф. Гаффарова «Агрохимия һәм туфрак белеме терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге» [2003-РТ_агрохим] һ.б. Аларның кайберләренә аерым тукталып үтик: мәс., Л.Ш. Сафиуллова, Л.Ф. Биктимирова «Толковый русско-татарский словарь производственно-экономических терминов в области строительства» [2000-РТ_экон/строит] сүзлегендә инвестиция-төзелеш эшчәнлеге, күчемсез милек, менеджмент, коммерция, икътисад теориясе өлкәләрендә кулланыла торган терминнар туплап бирелә. Бирелгән терминнарга ике телдә дә аңлатмалар китерелә. Сүзлек ахырында бите күрсәтелгән рус терминнарының күрсәткече урнаштырыла.

М.Ю. Гыйләҗев, С.Г. Мортазина, Ф.Ф. Гаффарова, М.Г. Мортазин «Агроэкология терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге» [2008-РТ_агроэкол] өчен терминнар агроэкология буенча гамәли дәресләрдән, лекцияләрдән, терминологик сүзлекләрдән картотекага салып тупланган. Сүзлектә татар телендә булган терминнарны тулырак файдалану максаты куелган, мөмкин булган барлык вариантлар да теркәлгән, шул исәптән диалекталь вариантлар да күрсәтелгән. Аерым очракларда татар теленең эчке мөмкинлекләренә нигезләнеп ясалган яңа атамалар да тәкъдим ителгән: мәс.,

ЖЕЛАТИН ЖЕЛАТИН, СӨЯК ҖИЛЕМЕ – аксымлы матдәләр катнашмасы

ЖЕЛЕ ЖЕЛЕ, ҖИЛЕМ КЕСӘЛЕ, ДЕРЕЛДӘВЕК, КОЙКА

Һәр терминга татар телендә аңлатма бирелә: мәс.,

ИНОЗИТ ИНОЗИТ – туфрак микроорганизмнары бүлеп чыгара торган витаминның бер төре һ.б.

Сүзлек оялап бирү ысулы белән төзелә: мәс.,

| | |
|---|---|
| КАПИЛЛЯРЫ | КАПИЛЛЯРЛАР |
| ... ПОЧВЕННЫЕ | ТУФРАК КАПИЛЛЯРЛАРЫ |
| ... ЧЕТОЧНЫЕ | ДИСБЕСЫМАН КАПИЛЛЯРЛАР |
| | һ.б. |

Татар терминнарын эзләп табуны җиңеләйтү өчен, ахырда татарча термин һәм төшенчәләрнең алфавит күрсәткече китерелеп, аларның теркәлгән битләре күрсәтелә.

Р.Ф. Гайнутдинова «Офтальмология: русско-татарский терминологический словарь» [2011-РТ_офталь]. Сүзлектә шушы өлкәгә нисбәтле күз төзелеше, күз авырулары, диагностикасы, төрле приборлары, хирургия аппаратлары һ.б. атамалар туплап бирелә. Сүзлек төр терминнарны оялап бирү ысулы белән төзелә. Халыкара терминнарның җәяләр эчендә чыганак теле, шул телдәге язылышы, татар теленә тәрҗемәсе күрсәтелә, терминның татар телендәге эквиваленты яки тәрҗемәсе бирелә. Күпчелек терминнарга татарча аңлатмалар китерелә: мәс.,

Зонды [фр. sonde] Зондлар – әгъза эчен тикшерү җайланмалары

З. Боумена Боумензондлары – яшь юлларын тикшергәндә, киңәйткәндә кулланыла.

Төп термин янында кулланышта булган халык атамалары да китерелә: мәс.,

Глаукома [glaucoma; гр. glaukos ачык зәңгәрсу яшел] Глаукома, карасу авыруы – күз (эче) басымының югары булуы белән билгеләнә. Дәваламаганда, тоташ сукырлыкка китерә һ.б.

Сүзлек ахырында татарча-русча сүзлекчә һәм русча-татарча аңлатмалары белән офтальмологиягә караган төсле рәсемнәр китерелә.

Кайбер терминологик сүзлекләр, терминнар белән ике телдә дә эшләү, аларны сүзлектән тиз һәм җиңел табу максатында, русча-татарча, татарча-русча итеп, ике өлештән төзелгән: мәс., Г.Ю. Даутов, З.М. Вәгыйзова төзегән «Русча-татарча, татарча-русча физика терминнары сүзлеге» [1996-РТ,ТР_физик] бер үк төрле терминнарны үз эченә алган русча-татарча һәм татарча-русча ике сүзлектән тора. Бу сүзлеккә якынча 3 мең чамасы термин теркәлә. Аерым бер сүзгә караган төр терминнары ыру термин маддәсе эчендә күрсәтелә: мәс.,

Аномалия аномалия; а. магнитная – магнит аномалиясе; а. силы тяжести – авырлык көче аномалиясе һ.б.

Соңгы елларда өч телле сүзлекләр төзү тәҗрибәсе дә күзәтелә: мәс., З.М. Вагизова, Г.Ю. Даутов, О. Аслан «Англо-русско-татарский словарь физических терминов» [1996-АРТ_физич];

В.И. Кафиатуллина «Англо-татарско-русский учебный словарь общестроительной лексики» [1996-АТР_строит]; В.И. Кафиатуллина «Немецко-татарско-русский учебный словарь общестроительной лексики» [1996-НТР_строит]; Р.М. Гатин «Международная анатомическая номенклатура: Латинско-русско-татарский словарь» [1999-ЛРТ_анатом]; Җ.Ш. Сөләйманов, А.Ф. Галимьянов, М.Х. Вәлиев «Информатика һәм мәгълүмат технологияләре терминнары: инглизчә-татарча-русча аңлатмалы сүзлек» [2006-АТР_информ]. Мондый төр терминологик сүзлекләрдә халыкара терминнар, рус телендәге эквивалентлары белән чагыштырылып, татар теленә тәрҗемә ителә, татар телендәге адекватлары ясала яки тәрҗемә ителмичә тәкъдим ителә: мәс., Җ.Ш. Сөләйманов, Ә.Ф. Галимҗанов «Информатика буенча инглизчә-татарча-русча сүзнамә»дә [2000-АТР_информ] инглиз телендәге терминнарның татарчага тәрҗемәләре тәҗрибә буларак белгечләрнең фикер алышуы өчен бирелә. Информатика өлкәсе мисалында татар телендә термин ясау мөмкинлекләре тәҗрибәсе күзәтелә. Татар теленең яңа сүз ясауда үз эчке мөмкинлекләре нигезендә авторлар халыкара һәм рус терминнарының татарча тәрҗемәләрен тәкъдим итәләр: *компьютер – санак, монитор – күрәк, меню – сайлак, принтер – басак, база данных – тамгасар, клавиатура – төймәсар* һ.б.

А.А. Тимерханов, Ф.И. Тагирова, Р.Т. Сафаров «Англо-русско-татарский словарь компьютерных терминов» [2015-АРТ_компьют]. Сүзлекнең лөгатьлеге инглиз теленнән тупланган һәм аларның русча, татарча эквивалентлары күрсәтелгән. Атамаларның күбесенә татарча аңлатмалар бирелгән.

Өч телле сүзлекләр арасында Н.К. Гарифуллин төзегән «Менеджмент: Русско-англо-татарский толковый словарь» [2010-РАТ_менедж] хезмәтендә, исеменнән үк аңлашылганча, менеджмент өлкәсенә караган русча терминнар инглиз һәм татар телендәге эквивалентлары белән бирелгән. Терминнарның мәгънәсе татар телендә аңлатылган. Сүзлек ахырында татарча термин һәм төшенчәләрнең теркәлгән битләре күрсәтелгән терминологик күрсәткече китерелеп, сүзлектә татар терминнарын эзләп табу уңайлаштырган.

Шул рәвешле, галимнәрнең фидакяр тырышлыгы белән рус фәнни терминологиясе нигезендә татар телендә хуҗалык, фән тармакларына караган күп кенә терминнар барланган, тупланган, тәң-

гәлләре табылмаганда, татар теленең үз мөмкинлекләре нигезендә яңалары ясалган яки тәрҗемә ителгән, күпсанлы терминологик сүзлекләрдә чагылыш тапкан. Шуның белән татар теле үзен фән теле, махсус белгечлек теле буларак мөкәммәл, тәмам формалашкан камил тел булуын дәлилләгән. Әлбәттә, кайбер терминнар, әлегә үз тәңгәлләрен тапмыйча, аңлатмалы сүзтезмәләр аша бирелгән. Шуның өчен дә тупланган терминологиянең актив кулланышта булуы, телгә ярашуы, шомаруы, вакыт сынавы үтүе кирәк.

Татар халкының яшәеш шартларына бәйле рәвештә барлыкка килгән гаять бай борынгы терминологиясенең көннән-көн юкка чыга баруы белән милли терминологияне саклау катлаулана. Халыкта булган бу катлау терминологияне сүзлекләрдә теркәү үтә мөһим һәм катлаулы эшкә әверелә бара. Терминологик сүзлекләр арасында соңгы вакытта лөгатьлеге татар теленең үз нигезендә ясалган терминнардан торган сүзлекләрнең актив төзелә башлавы нәкъ менә шул катлам терминологияне барларга өлгерү, аларны сүзлекләрдә теркәп калу максатын үзәккә куя. Борынгы терминологияне туплау татар халкы өчен теоретик һәм практик әһәмияткә ия. Аларны татар тарихын өйрәнүдә файдаланырга мөмкин. Тупланган материаллар халыкның матди һәм мәдәни тормышы тарихын тулырак күз алдына китерергә ярдәм итә. Бу катлам терминология системасын электән килгән, татар терминологиясенең борынгы калыплары нигезендә ясалган атамалар тәшкил итә. Хәзерге терминология ясалышында алар үрнәк була ала яки терминнарның тәрҗемәләрендә кабат кулланышка кайтырга мөмкин. Лөгатьлеге татар теленең үз нигезендә ясалган терминнардан торган сүзлекләрнең кайберләренә тукталып китик:

Ф.С. Сафиуллина «Татарча-русча тел белеме терминнары сүзлеге»ндә [1998-ТР_языкозн] 4500 татарча термин туплап биргән. Автор терминнарны татар теле дәреслекләреннән, XIX гасырдан алып чыга килгән татарча грамматикалардан җыйган. Сүзлектә гомумкулланыштагы терминологиядән тыш кулланыштан төшкән, искергән терминнар да бирелгән. Термин янында аны беренче кулланган авторлары күрсәтелгән. Сүзлек татар терминнарын русчага тәрҗемә итү юлы белән төзелгән. Зуррак категорияләрне тасвирлаганда, оялау ысулы кулланылган: мәс.,

| | |
|---|---|
| Синтаксис // нәхү | Синтаксис |
| актуаль ... | актуальный ... |

грамматик ... грамматический ...
стилистик ... стилистический ... һ.б.
Тәмамлану төрчәсе (Ханг.) Совершенный вид (-ып +всп. гл.)
Тәмамланган сүз тезмәсе Предикативное словосочетание
(тәркибе тамь) (Нас.) һ.б.

Д.Б. Рамазанова «Термины родства и свойства в татарском языке» [1991-ТР_тер/родст] монографиясендә автор тарафыннан, экспедицияләрдә йөреп, татар халык сөйләшләреннән туплаган һәм иске татар әдәбияты истәлекләреннән җыйган, хәзерге вакытта телебездән югала барган борынгы катлам лексика – туганлык атамалары синхрон һәм диахрон планда анализлана. Иң әһәмиятлесе: монография ахырында татар телендә 280 туганлык атамасының сүзлекчәсе бирелә. Һәр атаманың хезмәттә анализланган битләре күрсәтелә.

Р.К. Рәхимованың «Татар ювелирлык эше лексикасы һәм сүзлеге»ндә [2002-ТР_ювел] озак еллар дәвамында автор тарафыннан, экспедицияләрдә йөреп, татар халык сөйләшләреннән, борынгы әдәбияттан җыйган, хәзерге телдә кулланыштан төшеп барган, искергән тарихи сүзләр туплап бирелә. Һәр сүзнең русчага тәрҗемәсе һәм рус телендә аңлатмасы күрсәтелә. Сүзлек төр терминнарны оялап бирү юлы белән төзелә. Тупланган атамалар тематик төркемнәргә бүлеп карала. Автор алты төркем аерып чыгара: 1) затлы һәм башка металл атамалары; 2) ювелир таш атамалары; 3) ювелир эшләнмәләр һәм аларның детальләре атамалары; 4) эш процессы атамалары; 5) ювелир эшендә белгеч атамалары; 6) ювелир эшендә эш кораллары атамалары.

Сүзләрнең алынган чыганак теле күрсәтелә. Чыганак телдәге яңгырашы, мәгънәсе аңлатыла: мәс.,

**ГӘРӘБӘ** (фар. каһреба: каһ «солома» руба «притягивающий»), кайсы сүзлекләрдә теркәлүе күрсәтелә – ТРС, РТС янтарь (окаменевшая ископаемая смола хвойных деревьев, используется как поделочный материал самоцвет)

**ак гәрәбә** белый янтарь

**алтын (сыман) сары гәрәбә** золотистый желтый янтарь

**балтик гәрәбәсе** балтийский янтарь, сукцинит һ.б.

Атаманы беренче кулланган автор яки экспедиция вакытында язып алган урын күрсәтелә: мәс.,

**БИДӘР** К.Нас., О. Әтн. см. бизәк

**ДӨРРЕ МӘРҖӘН** уст. см. **энҗе-мәрҗән** һ.б.

Әлеге сүзлектә автор тарафыннан зур күләмдә лексик материал китерелә.

Х.Х. Сәлимов «Тел гыйлеме терминнары сүзлеге»ндә [2005-ТР_языкозн] татар тел гыйлемендә киң кулланылган лингвистик терминнарны туплап бирә. Татар телендәге терминнарга русча эквивалентлары, татарча аңлатмасы китерелә.

Казан федераль университеты галимнәре – Р.Р. Җамалетдинов, Ә.Ш. Юсупова, Г.Р. Галиуллина, Р.С. Нурмөхәммәтова, Э.Н. Денмөхәммәтова тарафыннан төзелгән «Татарча-русча-инглизчә тел белеме терминнары сүзлекчәсе» [2014-ТР_языкозн] – соңгы елларда басылып чыккан, хәзерге тел белемендәге мөһим лингвистик терминнарны туплаган әһәмиятле сүзлекләрнең берсе. Сүзлек Татарстан Республикасындагы гомуми белем бирү учреждениеләрендә полилингваль белем бирүне оештыру һәм тәэмин итү максатыннан эшләнгән. Сүзлекнең лөгатьлеге татар телендә булуы татар теленең үз нигезендә ясалган терминнарга киңрәк тукталырга, аларны күбрәк тупларга, укучыга бу терминнарны туган тел аша кабул итәргә мөмкинлек ача. Сүзлектә гомуми тел белеме, фонетика, лексика, морфология, синтаксис, сүз ясалышы, стилистикага караган терминнар тупланган һәм күпчелек терминнарга татарча аңлатмалар бирелгән. Чит телдән кергән атамаларның чыганак теле күрсәтелгән. Матур әдәбияттан, сөйләм теленнән алынган мисаллар белән дәлилләнгән: мәс.,

**АББРЕВИАТУРА** – (лат. abbrevio – кыскарту) ...

**АБСОЛЮТ СИНОНИМ** – бер төшенчә бирү өчен кулланылган, мәгънәләре буенча тулысынча тәңгәл килә торган синонимнар: бегемот – гиппопотам, су айгыры; йөз – гасыр.

**АВАЗ АРТИКУЛЯЦИЯСЕ** – аваз барлыкка китерү барышында, сөйләм аппаратының эшчәнлеге.

Параллель рәвештә һәр мәкаләнең русча һәм инглизчә тәрҗемәләре китерелгән.

Р.Т. Сәфәров төзегән «Татарча-русча хәрби лексика сүзлеге»ндә [2017-ТР_хәрби], нигездә, борынгы тарихи лексика тупланган. Тел материалы урта гасыр әдәбиятыннан, риваятьләрдән, мәкаль-әйтемнәрдән, тарихи романнардан җыелган. Лөгатьлек телебездә күпчелек борынгы заманнарда формалашкан, хәзерге вакытта кулланыштан төшкән тарихи төрки-татар хәрби лексиканы тәшкил

итә. Меңнән артык лексик берәмлекне эченә ала. Җыелган лексиканың тематикасыннан күренгәнчә, татар телендә хәрби лексика тулы система булып формалашкан. Сүзлектә хәрби корал атамалары, аларның аерым өлешләре, детальләре, саклау савытларын белдергән сүзләр, саклану киемнәре, аларның аерым өлешләрен тәкъбирләгән берәмлекләр, хәрби берләшмә атамалары, сугышчылар, гаскәр башлыклары атамалары, сугыш мәйданы эпизодлары, хәрби символларны белдергән сүзләр, әсирлекне тасвирлаган лексика, хәрби өлкәгә караган һ.б. берәмлекләр туплана. Бу сүзләрнең рус телендәге тәрҗемәләре күрсәтелә. Сүзнең тиңдәш эквиваленты табылмаган очракта, рус телендә тасвирлама аңлатма бирелә: мәс.,

**Сакалдырык** подвязка для шлема на подбородке.

Аерым очракларда җәяләр эчендә аңлатмалар китерелә: мәс.,

**Кызылбаш** кизилбаш (тюркский наёмник в персидских войсках).

Төр атамалары ыру атамасы янында ояда туплап бирелгән: мәс.,

**Кылыч** меч, сабля; шашка, палаш, шпага.

**кәкре кылыч** сабля

**кылыч гәүдәсе** клинок меча

**кылыч йөзе** острие меча

**кылыч сабы** эфес, рукоятка меча

**кылыч сырты** тыльная сторана меча

**кылычтан кичерү** предавать/предать мечу

**туры кылыч** меч һ.б.

Күпчелек атамалар матур әдәбияттан, халык авыз иҗатыннан мисаллар белән дәлилләнгән: мәс.,

**Найза** пика, небольшое копьё, дротик. *Касмак бик батыр, куәтле кылыч оргучы, найза тотучы, ук атучы кеше икән, ди.* Риваять

**Нәбәрд** битва, сражение. *Бакты, күрде ул заман, кем ширмәнд, Кемсә килмәс итмәгә аңа нәбәрд.* Мөхәммәд Әмин

**Нөгәр** дружинник, нукер. *Алар артында урыс явыннан исән калган меңләп нөгәр иярgә берегеп үскәндәй тынып калган.* Р. Зәйдулла

Сүзлек татар халкының борынгы чорлардан ук югары хәрби әзерлеккә ия булуын күзалларга ярдәм итә.

О.Н. Галимова редакциясендә Р.К. Рәхимова тарафыннан төзелгән «Татарча-русча тукучылык һәм тегүчелек атамалары сүзлеге» [2018-ТР_тук/тег] авторның 1965–1980 елларда Татарстан республикасының төрле авылларына экспедицияләргә чыгып туплаган, күпчелеге хәзерге вакытта кулланыштан төшкән бай тарихи атамалардан тора. Сүзлеккә тукучылык һәм тегүчелек атамалары – тукыма төрләре, кием-салым һәм аның өлешләре, эрләү, туку, тегү кораллары һәм әсбаплары, аларның өлешләре, тукыма әзерләүдә кулланыла торган үсемлекләр, чималны тукуга әзерләү, бизәкләр, җепләр, аларның төрләре, тегү эшенең төрле стадияләрен атаган халык теленнән җыелган 2844 берәмлек туплап бирелә. Әлеге сүзлектә фәнни терминнар гына түгел, ә халыкта киң таралган, кул хезмәтен белдергән атамалар да теркәлә. Шул сәбәпле аларның фонетик, грамматик вариантлары да шактый чагылыш тапкан, атамаларның таралу ареалы да җентекләп тикшерелгән. Тегүчелек һәм тукучылыкта предметларның вак кына өлеше дә, аларның һәр төре дә исемләнгәнгә күрә, бу тармакларның лексикасы терминологик сүзтезмәләргә бай. Мондый берәмлекләр сүзлектә бик киң бирелә. Рус теленә тәрҗемә ителгән өлеше дә тирәнтен эшләнгән. Татарча атамаларга рус әдәби телендәге төгәл эквивалентлары, рус диалектларындагы атамалар эзләп табып китерелгән, атаманың тиңдәшләрен күрсәтә алмаганда, тасвирый аңлатмалар бирелгән. Сүзлек ике өлештән тора: тукучылык һәм тегүчелек атамалары икесе ике мөстәкыйль сүзлек итеп тәкъдим ителә. Ыру атамалар татар алфавиты тәртибендә күрсәтелгән. Атама янына аның адресы – чыганак урыны бирелгән. Төр атамалары ыру атамасы янында ояда тупланган: мәс.,

**Бизәк** *Каз. ар.* Узор, орнамент.

**Аса бизәк** *к.* **аса**

**Биш калаклы бизәк** Вид простого узора белого полотенца, вытканного браным способом на пяти дощечках һ.б.

Язма чыганаклардан алынган сүзләр янына китапның исеме яки авторы күрсәтелгән: мәс.,

**Кул савыты** *(К.Нас.) к.* **бияләй**

Атаманың чыганак теле күрсәтелгән: мәс.,

**Драп** (*>фр.*)

**Жимпер** (*>ингл.*) һ.б.

Сүзлекнең аерым мәкаләләренә җанлы сөйләм теленнән, халык авыз иҗаты, матур әдәбияттан иллюстратив материал китерелгән. Сүзлек ахырында кушымта итеп туку төрләре, туку станнарының фотолары һәм рәсемнәре бирелгән. Шул рәвешле сүзлектә татар халкының борынгыдан килгән көнкүрешен, аның көн иткән кәсепләреннән булган тукучылык һәм тегүчелек атамалары бай һәм тирән чагылыш тапкан.

И.И. Сабитова, Г.Г. Саберова «Үсемлек атамаларының татарча-русча аңлатмалы сүзлеге»ндә [2020-ТР_үсем] татар теленең 1900 дән артык үсемлек атамалары теркәлгән. Тупланган лексика сигез тематик төркемгә бүлеп күрсәтелгән: үсемлекләр белән бәйле гомуми төшенчәләр; үсемлек анатомиясе, физиологиясе белән бәйле атамалар; агач, куак һәм ярымкуаклар; үсемлекләр; лианалар һәм үрмәләп үсә торган үсемлекләр; суүсемнәр, түбән төзелешле һәм споралы үсемлекләр; гөмбәләр; үсемлек бергәлекләре атамалары. Фәнни терминнар белән бергә халык сөйләшләрендә киң таралган җирле атамалар да теркәлгән. Сүзлектә Урта Идел буе, бигрәк тә Татарстан җирендә үсә торган бай һәм күптөрле үсемлек атамалары зур урын алып тора. Алда басылган сүзлекләрдән аермалы буларак, бу хезмәттә телдә актив кулланылышта булган гөмбә исемнәре һәм аларның төзелешенә караган терминнар теркәлгән. Атамаларның татарча вариантларын мөмкин кадәр киңрәк күрсәтү бурычы куелган булганга, телдәге әлеге катлам лексиканың искергән, кулланылыштан төшкән вариантлары, диалектизмнар һәм фонетик вариантлар да хезмәттә киң чагылыш тапкан. Бу катлам атамаларны теркәү аның сүзлектәге төп атамасына җибәрү юлы белән эшләнгән: мәс.,

**ГОНЧӘ** *иск. к.* **чәчәк бөресе.** *Әй, назнин, сез кайу гөлнең гончәсе, кайу бакчада тәрбиядә булынмыш* (Ф.Ханифи).

**ШЫЛАН** *диал. к.* **наратбаш.** *Ком сибеп шылан белән ышкып юсаң, идән гәрәбәдәй сары төскә керә --- (Әгерҗе таңнары)* һ.б.

Үсемлек атамаларының семьялыклары күрсәтелеп, татарча аңлатмалар бирелгән, русча эквивалентларының да әдәбиятта кулланылган берничә варианты күрсәтелгән. Әдәби әсәрләрдән тупланган иллюстратив материал китерелгән: мәс.,

**КЫНДЫРАК/КОНДЫРАК** КОСТЁР Кыяклылар семьялыгыннан шуышма тамырлы, салам сабаклы, озын тар яфраклы, себеркәчкә тупланган вак чәчәкле күпьеллык үләнчел үсемлек. *Кын-*

*дырак, айравык, солыча, төлкекойрык, болын саруты... заманында авыл табынының хуш исле чәен алыштырган (М.Рәфыйков).*

Сүзлек ахырында кушымта итеп үсемлекләргә бәйләнешле мәкаль-әйтемнәр, сынамыш, ышанулар китерелгән.

**Лөгатьлеге татарча төзелгән сүзлекләр арасында өч телле булганнары да бар.** Фәнни терминнар белән рәттән халык сөйләшләрендәге җирле атамаларны күпләп күрсәткән очракта латинча атамаларын янәшә кую юлы белән терминның бердәнбер төгәл фәнни тәңгәллегенә ирешергә мөмкин. Бу алым ботаника, зоология, анатомия төшенчәләре һәм объектлары өчен зарури эталон хезмәтен үти. Белгеч, җирле сүзләрне латинча атамасы белән чагыштырып, объектны дөрес күзаллый, фәнни атаманы дөрес билгели ала.

**Ф.Ә. Ганиев редакциясендә Г.Г. Саберова төзегән «Татарча-русча-латинча үсемлек атамалары сүзлеге**»ндә [2002-ТРЛ_үсем] сүзләрнең өч телдәге тәрҗемәләре китерелгән. Сүзлек оялау ысулы белән эшләнгән.

Э.И. Сафина **төзегән** «Татарча-русча-латинча кош атамалары сүзлеге»ндә [2018-ТРЛ_орнит] барлыгы 1700 дән артык (1610 әдәби, 113 диалекталь) орнитоним туплап бирелгән. Ыру атамалар татар алфавитында китерелеп, аңа караган төр атамалары ояда күрсәтелгән. Атамаларның диалекталь һәм сөйләм телендәге вариантлары, үзе караган диалектын күрсәтеп урнаштырылган: мәс.,

**Карчыга** *сөйл.* карча, *диал.* ҡарчыға (*перм.*), кыргый (*мәл., чст., чст.-крш.*), кыйгыр (*злт.*), пикцәргә (*тбл.*), карчыган (*м.-кар.*), буйтайак (*твр.*), кагау (*перм.*) Ястреб

Төп орнитонимнан соң семьялык һәм отряд исемнәре күрсәтелгән:

**Карчыга кошлар** Ястребиные *Accipitridae* (семьялык) һ.б.

Орнитонимның русчага тәрҗемәсе китерелгән, ул төр исеме булганда, аның фәндә кабул ителгән латинча термины бирелгән: мәс.,

**ТУНДРА КАЗЫ, казарка** Казарка

**Ак яңаклы тундра казы, ак яңаклы казарка** Казарка белощёкая *Branta Leucopsis*

Сүзлек ахырында татар-рус-латин телләрендә отряд һәм семьялык атамалары исемлеге күрсәтелгән. Татар һәм рус телендә төп орнитонимнар үзләре аерым сүзлек буларак урын алган.

Русча-татарча кош атамаларының алфавит тәртибендәге күрсәткече бирелгән, сүзлектә урнашкан битләре күрсәтелгән. Зур күләмдә «Кошлар белән бәйле сыналмышлар, мәкаль-әйтемнәр, канатлы сүзләр» кушымта буларак тәкъдим ителгән. Бирелгән кушымталар сүзлекнең информацион эчтәлеген арттыра, кирәкле мәгълүматны табу мөмкинлеген җиңелләштерә.

О.Н. Галимова төзегән «Балык атамаларының татарча-русча-латинча аңлатмалы сүзлеге»нең кулязмасы басмага әзер. Анда 1800 дән артык балык атамасы, шул исәптән 166 диалекталь атама тупланып биреләчек.

Сүзлектә, беренче чиратта, Татарстан, Россия сулыкларында яши торган балык атамалары урын алган. Автор аларны мәктәп дәреслекләреннән, фәнни-популяр әдәбияттан, төрле сүзлекләрдән туплаган. Сүзлектә шулай ук аквариумчылар әдәбиятында, балыкчылар, балыкчы спортсменнар форумнарында, ихтиологик әдәбиятта кулланылган океан, диңгез балыклары атамалары теркәлгән. Төп атама итеп ыруг яки семьялык атамасы алынган. Төр атамасы, беркомпонентлы булмаганда, алфавит тәртибендә ояга туплап бирелгән. Һәр балык турында тулы мәгълүмат китерелгән, семьялыгы, яшәү ареалы, төсе, зурлыгы җентекле шәрехләнгән. Атаманың диалекталь вариантлары күрсәтелгән: мәс.,

**(гади) алабуга** ОКУНЬ (ОБЫКНОВЕННЫЙ) *Percafluviatilis* Алабугалар ыругыннан; Европа, Төньяк Азия төче суларында иң киң таралган, койрыгының асты һәм корсак йөзгечләре кызыл төсле, киң яшькелт гәүдәсе биш-тугыз полосалы (шуңа ала булып күренә) ерткыч балык; *диал.* **әлүкін**, **алабога**,**алабыга**, **аламага**, **аламуга**, **бәймәт**

Төп атамадан соң класс, отряд, семьялык, ыруг атамалары күрсәтелгән. Аларга татарча аңлатмалар китерелгән, рус һәм латин телләрендә гомум кабул ителгән терминнары теркәлгән:

> **алабугасыманнар** ОКУНЕОБРАЗНЫЕ *Pereiformes* Нурканатлылар классыннан; 160 лап семьялыкны, шул исәптән алабугалар (*Percidae*), лабиринтлылар, скумбрия балыклар, ташбаш балыклар (*Gobiidae*), цихлид балыкларны берләштергән балыклар отряды.

Төп атамасына карап, бер ояда тупланган балык атамаларының үзләре караган биологик классификациясе күрсәтелгән:

**алтынсу алабуга** ОКУНЬ ЗОЛОТИСТЫЙ *Sebastes marinus* Диңгез алабугалары (*Sebastes*) ыругыннан...

**диңгез алабугалары** ОКУНИ МОРСКИЕ *Sebastes* Скорпен балыклар (*Scorpaenidae*) семьялыгыннан...

**батигобиуслар** БАТИГОБИУСЫ *Bathygobius* Алабугасыманнар отрядыннан тропик балыклар ыругы

**сары батигобиус** БАТИГОБИУС ЖЁЛТЫЙ *Bathygobius fuscus* Батигобиуслар ыругыннан... һ.б.

Диалектизмнарны теркәү аның сүзлектәге төп атамасына җибәрү юлы белән эшләнгән: мәс.,

**бикрә** ОСЁТР *к.* **мәрсин**

Сүзлек ахырында, төп сүзлектәге урыннарын күрсәтеп, русча ихтионимнарның күрсәткече урнаштырылган. Балыклар белән бәйле мәкаль-әйтемнәр китерелгән.

Терминологик сүзлекләр арасында бер телле сүзлекләр дә бар. Р.С. Сайфуллин, Г.Г. Хисамиев **«Толковый словарь-справочник по физике, химии и химической технологии на русском, татарском и английском языках»** [1995-Р,Т,А_физич/хим]. Физика, химия һәм химия технологиясенә караган аңлатмалы сүзлек-белешмә булып тора. Шушы өлкәгә караган 1500 терминны үз эченә ала. Сүзлек рус, татар, инглиз телләрендә аерым-аерым төзелгән. Атамалары бер-берсенә тәңгәл туры килгән бер телле өч мөстәкыйль аңлатмалы сүзлекне берләштерә. Баш сүзләр һәр телнең үз алфавиты нигезендә урнаштырылган. Һәр сүзгә аңлатмалар китерелгән.

К.М. Гарифуллин, К.Г. Хайруллин, Ф.Н. Фаткуллин һ.б. төзегән **«Финансово-экономические и юридические термины: толковый словарь»** [1996-Р,Т_фин/юрид] шулай ук атамалары бер-берсенә тәңгәл туры килгән бер телле ике сүзлектән гыйбарәт. Беренчесе – рус, икенче сүзлек татар телендә бирелгән. Күпчелеге 90 елларда кулланышка кергән 500 дән артык финанс-икътисад һәм юридик терминнарны туплап теркәгән. Бу сүзлекләрдә рус телендәге лөгатьлек төп нигез булып кала. Сүзлек ахырында, терминнарның кайсы биттә урнашкан булуын күрсәтеп, алфавит тәртибендәге күрсәткече китерелә.

Бер телле терминологик сүзлекләрдән татар телендә төзелгәннәрдән Р. Шакирова редакциясендәге **«Тел белеме буенча терминнар һәм әйтелмәләр сүзлеге»** [1953-Т_языкозн]; Н. Гыйззәтуллин

төзегән «Әдәбият белеме сүзлеге» [1958-Т_әдәб]; А.Г. Әхмәдуллин төзегән «Әдәбият белеме сүзлеге» [1984-Т_әдәб] һ.б. урын тота.

Нәтиҗәдә татар теленең терминологик системасын барлыкка китерүдә зур һәм күп эш башкарылган. Белгечләрнең тырышлыгы һәм тәҗрибәсе нигезендә, төрле фәнни һәм хуҗалык тармакларына караган терминнар эшләнгән, татар теленең үз грамматик чаралары нигезендә яңалары ясалган, борынгыдан килгән атамалар барланган. Күпсанлы сүзлекләрдә тупланып кулланышка тәкъдим ителгән. Тармак терминологиясен тәртипкә салуда, аны нормалаштыруда, вариантлыкны булдырмауда сүзлекләр беренче дәрәҗәдәге мөһим роль уйный. Төгәл төшенчә, дөрес информация бирелгәндә генә сүзлекнең фәнни нигезлелегенә, практик максатына ирешүе мөмкин. Шул ук вакытта тәкъдим ителгән терминология, актив кулланышта булып, вакыт сынавын үтүе дә кирәк. Тармак терминнарының унификацияләнгән дөрес әйтелеше, дөрес кулланылышы, сүзлектә норма буларак беркетелүе цивилизацияле җәмгыять өчен гаять мөһим. Алар нигезендә дәреслекләр төзелә, фәнни хезмәтләр языла. Икенче яктан, ул телебезнең күп гасырлар дәвамында кулланышта, үсеш-хәрәкәттә булу нәтиҗәсендә, татар теленең төзек бер система булып формалашкан, тормыш, көнкүрешнең барлык өлкәләрендә дә аралашу, фикер алышу ихтыяҗын тулысы белән һәм нәтиҗәле итеп канәгатьләндерә алырлык дәрәҗәдә һәр яктан эшләнгән булуын күрсәтә. Телебезнең сүзлек составының гаҗәеп дәрәҗәдә бай булып оешканлыгын, аның лексик системасы бүген дә хәрәкәттә, туктаусыз үсештә булуын билгели.

## § 19. Сүзлекләрнең башка төрләре

Татар лексикографиясенең бүгенге көндәге үсеше әлегә кадәр басылган сүзлекләрнең күләмле, җитди һәм шул ук вакытта күптөрле булулары белән билгеләнә. Соңгы йөзьеллыкларда төзелгән сүзлекләр исемлеге татар телендәге лексикографик чыганакларның киңкырлы, киң юнәлешле булуын һәм төрле тармак лексикасын колачлавын күрсәтә. Бер яктан, әлеге хәзинә алдагы бүлекчәләрдә җентекле тасвирланган аңлатмалы, диалектологик, этимологик, ономастик, фразеологик, терминологик һ.б. сүзлекләрдән гыйбарәт булса, икенчедән, болар – икетелле яки берничә телле тәрҗемәле сүзлекләр, татар теленең гаять бай булуын

күрсәтә торган синонимнар, антонимнар, омонимнар сүзлекләре һәм яңа төр лексикографик чыганаклар.

**Тәрҗемәле сүзлекләр**

Гомуми саны, ничә тапкыр басылуы, таралу киңлеге, лөгатьлегенең байлыгы, актуальлеге һ.б. буенча караганда да, киң катлам укучыларга яхшы таныш булуыннан чыгып фикер йөрткәндә дә, иң еш һәм күп файдаланыла торган сүзлекләр булып тәрҗемәле сүзлекләр санала. Татар телендәге мондый төр сүзлекләрнең күпчелеген русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләр тәшкил итә. Билгеле инде, элек-электән сәүдә белән шөгыльләнгән, башка милләтләр белән эшлекле мөнәсәбәтләрдә булган халкыбызда, аралашуны җиңеләйтү, рус телен өйрәнү, татар телен камилләштерү, тәрҗемә итү һ.б. максатларда куллану өчен, икетелле сүзлекләргә ихтыяҗ XVIII гасырларда ук зур булган. С.Хәлфин (1775), И.Гиганов (1804), А.Троянский (1833, 1835), К.Насыйри (1878, 1892) һ.б. шәхесләрнең барыбызга да билгеле тәрҗемәле сүзлекләр татар лексикографиясендә генә түгел, гомумән тюркологиядә күренекле урын алып тора.

Татар теленә өйрәтү киңрәк колач ала башлаган XIX гасырда зур булмаган сүзлекләр яки күп кенә атамаларның татарчадан русчага, русчадан татарчага тәрҗемәләре бирелгән үзөйрәткечләр популяр булса, Октябрь инкыйлабыннан соңгы чорда тәрҗемәле сүзлекләр төзү эше тагын да тирәнрәк фәнни нигездә дәвам итә, XX йөздә элеккеләренә караганда шактый камилләшә төшкән, лөгатьлекләре арткан, баеган тәрҗемәле сүзлекләр алгы планга чыга. Татарча-русча, русча-татарча сүзлекләр төзү юнәлешендә үзенә бертөрле үсеш чоры татар теленең дәүләт теле буларак кулланылышка керүе белән бәйле. 1921 елда Казанда Гыйльми үзәк һәм «Татар телен гамәлгә ашыру» комиссиясе оешу, татар телендә белем бирүнең тагын да киңрәк колач җәюе сүзлекчеләр алдына яңа бурычлар куя. Төрле тармакларга караган терминнарның татарча вариантларын бирү, алынма сүзләрне татарчага тәрҗемә итү максатыннан, русча-татарча, татарча-русча һәм җыйнак кына терминологик сүзлекләр төзелә башлый. Болар барысы да сүзлек төзү эшенең беркайчан да туктап тормавын, сүзлекләрнең һәрдаим төзелеп һәм басылып килүен күрсәтә. Әмма төрле гасырларда, елларда басылган сүзлекләрне бер-берсе белән чагыштырып караган очракта, бик күп аермалар күзәтелә. Мисал өчен, исемнәреннән

күренгәнчә, русча-татарча, татарча-русча сүзлекләрнең максаты – бер телдәге сүз яки терминның икенче телдәге эквивалентын бирү, атаманы тәрҗемә итү. Узган гасырда басылган сүзлекләргә игътибар итсәк, аларның кайберләре тәрҗемә сүзлек булу белән бер үк вакытта, ниндидер дәрәҗәдә орфографик, грамматик сүзлек яисә белешмәлек ролен дә үтәгән. Мисал өчен, С. Рахманкулов белән Г. Карам төзегән «Русча-татарча мөкәммәл лөгать»тә сүзләрнең басымы, кайбер грамматик үзенчәлекләре дә күрсәтелә [1920-РТ_(2)(г)] һ.б.

XX гасырның беренче яртысында төзелгән сүзлекләрнең күбесе русча сүзләрне татарчага тәрҗемә итү белән чикләнмичә, кайбер сүзләргә кыскача аңлатмалар да бирә. Гадәттә, рус телендәге сүзнең тулы мәгънәсен төшендерә алырлык сүз булганда, бер сүз белән генә тәрҗемә ителә. Аерым очракларда, берничә сүз белән якынча мәгънәләре китерелә, халыкка бик үк таныш булмаган алынма сүзләргә, икътисад, сәясәт яки башка өлкәләргә караган яңа интернациональ терминнарга кыскача аңлатмалар тәкъдим ителә. Бу, әлбәттә, татар телендә ул вакытта кайбер тармакларга караган терминологик яисә энциклопедик сүзлекләр булмау белән дә аңлатыла. Мисал өчен: **абдуктор** – абдуктор, читкә тартучы мускул (аяк-кулларны гәүдәдән читкә таба хәрәкәтләндерә торган мускул) [1940-РТ: 3]; **желе**, *нскл ср* – желе (желатин белән җимеш суы кушылып ясалган кесәл) [1940-РТ: 163] һ.б.

Барлык тәрҗемәле сүзлекләрне хронология буенча күзәткән очракта, алар арасындагы иң зур аерма – лөгатьлекләренең, димәк, сүзлекләрнең күләме арта бару. Мисал өчен, үз чоры өчен күләмле сүзлекләрдән саналган 1927 елгы «Татарча-урысча сүзлек» [1927-ТР (г)] 15 000 гә якын сүзнең тәрҗемәсен бирә, 1929 елда басылган «Русча-татарча яңа лөгать» [1929-РТ (г)] һәм 1938 елда төзелгән «Русча-татарча сүзлек»ләрдә инде 32000 гә якын сүз [1938-РТ], 1941 елдагы сүзлектә 40 000 нән артык сүз [1941-РТ], 1971 елгы «Русча-татарча сүзлек»тә [1971-РТ] 50 000 чамасы сүз, ике томлык 2007 елгы «Татарча-русча сүзлек»тә [2007-ТР] 56 000 сүз, 7400 фразеологик берәмлек һ.б.

Чорына бәйле рәвештә, күпмедер дәрәҗәдә сүзлекләрнең лөгатьлекләре дә үзгәреш кичерә барган. Мисал өчен, XIX гасыр сүзлекләрендә дини сүзләр, гарәп алынмалары күп очраса, XX йөз сүзлекләрендә бик иске һәм дини сүзләр төшереп калдырылып,

1917 ел инкыйлабыннан соң актив кулланыла башлаган интернациональ сүзләргә күбрәк урын бирелә. XX–XXI гасыр сүзлекләрендә гарәп-фарсы алынмалары тагын да кими төшеп, чит телдән, бигрәк тә Европа телләреннән кергән терминнарның артуы күзәтелә.

Хезмәт кысаларында барлык тәрҗемәле сүзлекләрне дә бәяләп бетерү мөмкин булмаганлыктан, аларның берничәсенә генә тукталырбыз. Мисал өчен, русча-татарча сүзлекләрдән 1956-1959 елларда төзелгән дүрт томлык «Русча-татарча сүзлек» [1955-1959-РТ_I-IV] аерым игътибарга лаек. Әлеге сүзлек лексик материалының күләме белән дә (38 000 чамасы сүз), сүзлек мәкаләләренең тулырак эшләнеше ягыннан да, моңа кадәр чыккан русча-татарча сүзлекләрдән аерылып тора. Беренче чиратта ул татар теленең совет хакимияте елларындагы үсеш-үзгәрешләрен чагылдыра. Лөгатьлегенең төп өлешен гомумкулланылыш лексикасы тәшкил итә. Шул ук вакытта, кайбер искергән сүзләр һәм диалекталь сүзләр дә кертелгән, рус теленнән кергән алынмаларга, интернациональ сүзләргә шактый урын бирелгән, сүзлек ахырында Ф.С. Фасеев төзегән кыскача грамматик белешмәлек китерелгән. Мисал өчен: **Навсегда** *нареч.* – гомергә, мәңгегә, бөтенләйгә. **Исчертить** *сов.* – сызгалап бетерү, сызыклар белән тутыру; 2. Сыза-сыза тотып бетерү; **исчертить весь мел** – бөтен акбурны сыза-сыза тотып бетерү. **Метель** ж. – буран, кар бураны [1955-1959-РТ_I-IV].

Ф.Ә. Ганиев мөхәррирлегендә 1997 елда дөнья күргән «Русча-татарча сүзлек» [1997-РТ] – әле бүгенге көндә дә бик күпләрнең өстәл китабы. Якынча 47 000 сүзнең татарчага тәрҗемәсен биргән әлеге сүзлек телебезнең шул чордагы үзгәрешләрен чагылдыра һәм аңа кадәр басылган мондый төр сүзлекләрдән лексик материалының күләме белән генә түгел, сүзлек мәкаләләренең тулылыгы белән аерылып тора. Мисал өчен: **закатать** *сов.* **1.** *кого-что во что* төрү, төреп кую, чорнап кую, урап кую; ~ **в полотенце** сөлге белән чорнап кую **2.** *что (заровнять)* каток белән тигезләү **3.** *что, разг.* сызгану; ~ **рукава** җиңнәрне сызгану **4.** *что (герметично закрыть)* ныгытып ябу, капкач белән ябу, һава кермәслек итеп томалау *(мәс, кайнатма савытларын)* [1997-РТ: 161].

2007 елда басылган ике томлык «Татарча-русча сүзлек» – 56 000 сүз һәм 7000 нән артык фразеологизмның русчага тәрҗемәләрен туплаган саллы хезмәт. Ул соңгы дистә елларда басылган

мондый төр сүзлекләр арасында үзенең зурлыгы, мәгълүматлылыгы белән игътибарга лаек. Әлеге сүзлекнең лөгатьлеге, кайбер искәрмәләрдән кала, татар теленең өч томлык аңлатмалы сүзлегендәге барлык сүзләрне дә сыйдырган диярлек. Моннан тыш, хезмәткә шактый неологизмнар, диалекталь сүзләр, гарәп-фарсы алынмалары өстәлгән. Сүзлек мәкаләләре түбәндәгечә: **болан** *сущ.* олень // олений; *тимгелле* ~ пятнистый олень; ~ *көтүе* стадо оленей; оленье стадо; ~ *туны* оленья шуба; *ана* ~ оленуха □ **~ асраучы** оленевод; **~ асраучылык** оленеводство // оленеводческий; **~ баласы** оленёнок; **~ ите** оленина; **~ кәҗә** *зоол.* косуля, козуля; **~ мөгез** *зоол.* оленерог (жук); **~ мүге** *бот.* ягель, олений мох; **~ уты** *бот.* олений язык [2007-ТР_I: 249]. Мисаллардан күренгәнчә, төрле елларда басылган икетелле тәрҗемәле сүзлекләрнең сүзлек составы өзлексез үзгәреп, тулыланып торган. Һәр яңа хезмәт телдә булган актив үзгәрешләрне, яңалыкларны чагылдыру максаты белән эшләнгән.

Тәрҗемәле сүзлекләрнең билгеле бер даирә, өлкә кешеләрен, мисал өчен, укучылар һәм укытучыларны күздә тотып төзелгәннәре дә шактый. Мәсәлән, 1939 елда башлангыч мәктәпләр өчен «Русча-татарча сүзлек» бастырыла (авторлары: Г. Нугайбәк, М. Корбангалиев, М. Гыймадиев). Сүзлектә кайбер грамматик, орфографик үзенчәлекләрне күрсәтеп, зат, сан һ.б. га бәйле тамгалар куелган, чит телдән кергән терминнарга җәя эчендә кыскача аңлатма бирелгән [1939-РТ_мәкт]. 1948 елда дөнья күргән башлангыч мәктәпләр өчен «Русча-татарча сүзлек» шулай ук мәктәп укучыларына кирәкле өстәмә мәгълүматка бай булуы белән аерылып тора [1948-РТ_мәкт]. XXI гасырда басылган мондый сүзлекләрнең, заманча мөмкинлекләрдән, чаралардан файдалану нәтиҗәсендә, практик әһәмияте тагын да арта төшкән. Мисал өчен, Р.Ә. Сабиров редакциясендә 2006 елда басылган «Татарча-русча тулы уку-укыту сүзлеге»ндә сүзләрне хәтта тыңлау мөмкинлеге дә бар. Сүзлеккә өстәмә материал буларак бирелгән СД дискта киң кулланылыштагы 1500 сүзнең татарча яңгырашын тыңлап була [2006-ТР_мәкт].

Тәрҗемәле сүзлекләрнең күбесе икетелле. Мисаллардан күренгәнчә, иң актуальләре – русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләр. Башка телләргә бәйләнешле сүзлекләр бик күп түгел. Мәсәлән, төрле елларга караган унбишләп гарәпчә-татарча һәм татарча-гарәпчә сүзлек булуы мәгълүм һ.б. Татар һәм төрек галимнәренең уртак тырышлыгы белән төзелгән «Татарча-төрекчә сүзлек» (1997) һәм

«Төрекчә-татарча сүзлек»ләр (1998) игътибарга лаек. Аларда тупланган бай материал уртак тарихи тамырларыбызны һәм Татарстан белән Төркия арасындагы социаль-икътисади, мәдәни һ.б. өлкәләргә караган бүгенге хезмәттәшлекнең югары үсеш дәрәҗәсен чагылдыра.

Икетелле тәрҗемәле сүзлекләр белән чагыштырганда, берничә телле сүзлекләрнең саны азрак. Татар телен чит телләргә бәйләп күптелле сүзлекләр эшләүдә, нигездә, фарсы, гарәп, төрек, инглиз һ.б. телләр файдаланылган. Моңа мисал итеп Г. Ишмөхәммәтовның күптелле «Төрки, фарсы, гарәп һәм казахча, татарча-гарәпчә сүзлекчә»сен (1954) китерергә мөмкин. Заманча сүзлекләрдән 1999 елда басылган «Инглизчә-татарча-русча уку-укыту минимумы сүзлеге» инглиз телендәге сүзләрне татарчага һәм русчага тәрҗемә итсә, А.Ә. Тимерхановның 2014 елда дөнья күргән «Татарча-русча-инглизчә мәктәп сүзлеге»ндә, киресенчә, татар сүзләренең, терминнарының рус һәм инглиз телләрендәге вариантлары бирелгән [2014-ТРИ_мәкт]. Әлеге сүзлектә 12 меңгә якын сүз һәм сүзтезмә, шул исәптән 1000 ләп фразеологик берәмлек һәм аларның рус, инглиз телләрендәге төгәл тәңгәлләре яисә тасвирлама вариантлары күрсәтелгән.

Икетелле яки күптелле тәрҗемәле сүзлекләр беркайчан да актуальлекләрен югалтмый, еллар үткән саен яңалары төзелеп-басылып тора торган әһәмиятле лексикографик чыганаклардан санала.

### Энциклопедик сүзлекләр

*Энциклопедик сүзлекнең* алфавит тәртибендә китерелгән төшенчәләргә һәрьяклы тулы мәгълүмат бирә торган җитди хезмәт булуын исәпкә алсак, билгеле инде, мондый төр киң мәгълүматлы, саллы сүзлекләрнең чагыштырмача соң – татар лексикографиясе билгеле бер үсеш этабына җиткәч, ягъни халык көндәлек кулланылыштагы актуаль сүзлекләр белән тәэмин ителгәч кенә, төзелә башлавы үзеннән-үзе аңлашыла.

Шул ук вакытта милли энциклопедия төзү идеясенең татар җәмәгатьчелегендә инде күптән – XIX йөз ахыры – XX йөз башында ук барлыкка килгәнлеген дә онытмаска кирәк. Халкыбызның этник тарихы турындагы мәгълүматларны туплаган белешмә материаллар шул чорда күпләп языла. Бу юнәлештә, билгеле инде, танылган галим, тарихчы Ш.Мәрҗани һәм Р.Фәхретдин эшчәнлекләре бәяләп бетергесез. Аларның халкыбыз тарихын, милләт-

тәшләребез эшчәнлеген яктыртуга багышланган энциклопедик характердагы тарихи-библиографик мәкаләләре, хезмәтләре милли энциклопедиянең нигезен, башлангычын тәшкил итә (Сабирзянов: 2017: 54). Төрле тематик белешмәләр һәм мәкаләләр рәвешендә даими рәвештә басылып килгән бу язмалар татарларның һәм Россия империясендә яшәгән башка халыкларның аң-белем дәрәҗәсен, мәдәнилеген арттырып, офыкларын киңәйтеп кенә калмый, милли үзаңның үсүенә дә искиткеч зур йогынты ясый.

Күренекле тел галиме, җәмәгать эшлеклесе Һ. Максудиның 1927 елда дөнья күргән «Фәнни камус. Русча-гарәпчә һәм төркичә фәнни мәҗмугалар буенча тәгъриф кылынган фәнни, әдәби вә сингый истилахлар камусы» хезмәте татар телендә төзелгән тәүге энциклопедик сүзлек дип санала. XX гасырның беренче яртысына кадәр төзелгән һәм энциклопедик сүзлек буларак тәкъдим ителгән бердәнбер сүзлек һәм беренче тәҗрибә буларак, әлеге хезмәт, һичшиксез, зур игътибарга лаек [1927-РТ_энц (г)]. Фәнни һәм иҗтимагый-сәяси терминнарны үз эченә алган «Фәнни камус» 10 000 терминның аңлатмасын туплаган 4 томлык хезмәт итеп күзаллаган булса да, кызганычка каршы, сүзлекнең беренче томының 2300 терминны үз эченә алган 4 өлеше генә дөнья күргән.

Билгеле инде, сүзлек мәкаләләре бүгенге көндә энциклопе-дик сүзлекләрдәге аңлатмалардан шактый аерыла. Сүзлек төзү принциплары буенча караганда да, ул күбрәк энциклопедик түгел, ә аңлатмалы сүзлекне хәтерләтә: **Мистификация** ميستيفيكاتسييئُ (گر، لات)نەرسە هەم ئشكەحييانەت وەئالداوقاتشدرُو *[**мистификация** (гр, лат.) нәрсә һәм эшкә хыянәт вә алдау катыштыру]* [1927-РТ_энц (г): 45].

1980 ел ахыры – 1990 ел башларында Татарстан Республикасында милли-төбәк энциклопедистикасы үсеш кичерә башлый, рәсми нигездә татар энциклопедиясен төзү эше башланып китә. Шул дәвердән алып бүгенге көнгә кадәр Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты тарафыннан энциклопедияләр һәм күптөрле белешмәлекләр төзү өлкәсендә зур эшләр башкарылып килә, татар һәм рус телләрендә фундаменталь энциклопедик басмалар эшләнә.

Шундый зур хезмәтләрнең беренчесе – 2002 елда М.Х. Хәсәнов мөхәррирлегендә басылган «Татар энциклопедия сүзлеге». Әлеге сүзлек Татарстан Республикасы Президентының «Татар

энциклопедиясе» программасы турындагы Указы (1997 ел, 10 февраль) нигезендә төзелә. «Сүзлектә 17 меңгә якын мәкалә Татарстанның тарихын, дәүләти-сәяси төзелешен, географик-территориаль чикләрдәге җир-суын, үсемлек һәм хайваннар дөньясын, шәһәр һәм авыллары тарихын, республика халыкларының икътисади, фәнни-техник, гыйлем-мәгариф, сәнгать өлкәсендә ирешкән төп казанышларын яктырта» [2002-Т_энц: 5]. Мәкаләләрнең күп өлеше күренекле шәхесләргә багышлана. Сүзлектә күп кенә авыллар һәм башка торак пунктлар турында моңарчы матбугатта басылмаган мәгълүматларны да табарга мөмкин. Биредә беренче тапкыр Татарстан Республикасының физик-географик һәм административ-территориаль бүленеш һәм район карталары татар телендә тәкъдим ителә. Татарстанда очрый торган үсемлекләргә, хайваннарга (*чуртан, чыклы үлән, болынчәй, аю җиләге* һ.б.) тулы аңлатма бирелү сүзлекне тагын да баета, практик яктан әһәмиятен арттыра. Әлеге хезмәт татар телендәге беренче энциклопедик региональ-универсаль басма булуы белән кыйммәтле.

Сүзлек мәкаләләре алфавит тәртибендә бирелә. Мисал өчен:

**ВАҺАПОВ** Рәшит Ваһап улы (1908–1962), җырчы (тенор), ТАССРның халык артисты (1957). 1941–1962 елларда Татар филармониясе солисты, Татар халык җырларын, С. Сәйдәшев, Җ. Фәйзи, М. Мозаффаров һ.б. композиторларның әсәрләрен башкаручы [2002-Т_энц_I: 137].

**ҮТӘМЕШ** авылы, Тәтеш р-нында, р-н үзәгеннән 41 км көньяк-көнбатыштарак, Зөя елгасы бассейнындагы Бидәңге суы буенда. 18 йөздә нигез салына. 1989 елда 253 кеше (татарлар), 2000 елда 236 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. Клуб. [2002-Т_энц_VI: 697].

2008 елда һәр татар кешесе горурланырлык тагын да саллырак басма – алты томлык «Татар энциклопедиясе» басыла башлый. Ул, шулай ук, республика хөкүмәте раслаган программа нигезендә ТР ФАның Татар энциклопедиясе институты тарафыннан төзелә.

Энциклопедия барлыгы 20 меңләп мәкаләне үз эченә ала. Төп урын Татарстанның тарихын, дәүләти-сәяси төзелешен, шәһәр һәм авыллары тарихын, үсемлек һәм хайваннар дөньясын, төрле өлкәләрдәге төп казанышларын яктыртуга бирелә. Мәкаләләрнең 8 меңнән артыгы дәүләт, сәясәт, дин, мәдәният, җәмәгать, мәгариф һәм сәламәтлек саклау эшлеклеләренә, күренекле галимнәргә, сән-

гать, авыл хуҗалыгы, төзелеш, элемтә, транспорт һ.б. өлкәсендә танылган шәхесләргә багышланган. Тәфсилле аңлатмалар бирү белән бер үк вакытта, мәкаләләр эчендә иллюстратив материал, ягъни фоторәсемнәр, карталар китерелү сүзлекне тагын да баета.

Энциклопедия төзүчеләр тарафыннан төрле өлкәләргә караган терминнарны системалаштыруда нәтиҗәле эш башкарылган. Биредә күп кенә топонимнарның һәм төрле өлкәләргә кагылышлы терминнарның татарча язылышы һәм тулы аңлатмаларын табарга мөмкин. Аңлатмалар түбәндәгечә:

**БАШМАКЧӘЧӘК,** кәккүк читеге (Cypripedrum), сәхләбчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 50 ләп төре билгеле, Европа, Азия һәм Төньяк Американың уртача зонасында киң таралган. Тамырчасы калын, үрмәләүче. Туры сабаклы, 3–4 эллиптик формадагы очлы яфраклы. Чәчәкләре ялгыз, эре, төрле төстә, түбәнге аерчасы кабартылган башмак формасында (исеме шуннан). Җимеше – тартмачык. ТРда 3 төре бар. Чын Б. яки Венера Б. (C. calceolus), – бер яки ике, сирәк кенә өч чәчәкле, 20-50 см озынлыктагы үсемлек, кызыл тимгелле ачык сары иренчәле, кызгылт-сары төстәге, ванилин исе килә торган калган яфраклары чәчәклек янында. Көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш р-ннарда очрый. Уңдырышлы, известьле токымнар б-н түшәлгән дымлы туфракларда яхшы үсә. Эре чәчәкле Б. (C. macranthon) – куе кызыл аерчалы аксыл шәмәхә яки шәмәхә-алсу төстәге чәчәге булган 20–40 см озынлыктагы үсемлек. Биектау, Минзәлә һәм Тукай р-ннарында очрый. Тимгелле Б. (C. guttatum) – 15-30 см озынлыкта, чәчәге ак тимгелле куе кызыл төстә. Барлык төрләре дә май уртасы – июльдә чәчәк ата, орлыклары август аенда өлгерә. Орлыклардан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Б. – декоратив үсемлек. Аны үстерү б-н Казан зооботаника бакчасы, ш.у. чәчәк үстерүче һәвәскәрләр шөгыльләнә. 3 төре дә сирәгәеп бара. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Определитель растений Татарской АССР. К., 1979; Красная книга Республики Татарстан. К., 1995 [2008-Т_энц_I: 425].

Халкыбызның иң борынгы заманнардан алып бүгенге көнгә кадәрге катлаулы тарихи юлын бүгенге фәнни күзлектән яктырткан, мәдәниятебез тарихын колачлаган гаять җитди хезмәт булarak, алты томлык «Татар энциклопедиясе» тарихыбызның, мәдәниятебезнең искиткеч бай булуын, Татарстанда күпме талантлы

кешеләр яшәвен, эшләвен күрсәтә, милләтебез белән горурлану хисләре уята.

Соңгы дистә елларда төрле тармакларга, өлкәләргә караган яисә аерым бер шәхескә, темага һ.б. кагылышлы материалларны туплаган энциклопедияләр күп эшләнә. Аерым шәхескә багышланганы – бөек шагыйребез Габдулла Тукай энциклопедиясе. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнгән 864 битле әлеге энциклопедия шагыйрь яшәгән һәм иҗат иткән чорны, аның тирәлеген һәм әсәрләрен аңлауда булышлык итәрлек күп төрле ачышларны һәм фикер-күзәтүләрне бергә туплаган 2358 фәнни мәкалә һәм белешмәне үз эченә алган фундаменталь хезмәт.

Габдулла Тукай энциклопедиясендәге мәкаләләр ТР ФАның Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, ТР ФАның Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты фәнни хезмәткәрләре, Казан шәһәренең югары уку йортлары җәмәгатьчелеге, әдәбият һәм сәнгать әһелләре тарафыннан язылган. Энциклопедиянең гомуми концепциясенә нигезләнеп, алар сигез тематик бүлеккә урнаштырылган. Беренче тематик юнәлештә Габдулла Тукайның бай һәм киңкырлы әдәби иҗаты анализлана, фәнни яктан шәрехләнеп, әдәби әсәрләре, публицистик һәм сатирик мәкаләләре, идеологик басым астында фәнни басмаларына кертелмәгән текстлары, басылмыйча калган кульязмалары бирелә. Икенче бүлектә Тукай иҗаты белән бәйләнешле әдәбият белеме терминнары һәм проблемаларына багышланган язмалар урын алса, өченче бүлек Тукайның «Исемдә калганнар» (1909) автобиографик әсәренә, истәлек-хатирәләргә, шагыйрьнең шәхси хатларына таянып тупланган. Дүртенче бүлек татар поэзиясендә Тукай традицияләре һәм аларның күчемлелеге мәсьәләләренә багышланган. Бишенче бүлектә Тукай рухи мирасының тышкы әдәби-мәдәни бәйләнешләр контекстындагы, ә алтынчы бүлектә «Тукай – музыкада, театрда, рәсем сәнгатендә» исемле тематикадагы мәкаләләр китерелгән. Тукай тормышы һәм иҗаты белән бәйле урыннар хакында белешмә җиденче тематик юнәлештәге мәкаләләрдә бирелә, ә сигезенче бүлектә тукайчы галимнәрнең шагыйрьгә кагылышлы эшчәнлекләре анализланган мәкаләләр урнаштырылган. Әйтергә кирәк, Тукай иҗатына кагылышлы барлык

мәгълүматларны туплап, анализлап язылган әлеге мәкаләләр шактый күләмле. Кыскарак мәкаләләр түбәндәгечә:

**«АВЫЛДА»**, сатирик миниатюра (1906), Китап сатучы һәм алучы арасындагы диалог формасында язылган. Сатучы гади халык мәнфәгатьләрен күздә тоткан китаплар тәкъдим итә. Алучы исә: «Кайсы өяздәге авыл халкы файдасын язган?» – дип, мәгънәсез төпченә башлый, үзебезнең өяз хәлләрен мин болай да беләм, дип йөз чөерә. Миңа «Бәдәвам», «Тәкый гаҗәб» кебек китаплар (борынгы дәвер язмалары) кирәк, ди. Т. биредә наданлыкның халык яшәешенә үтеп кергән типик сыйфатларын фаш итә. Текст беренче тапкыр «Уклар» журналының 1906 елгы 5нче (октябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Кулъязмасы сакланмаган [2016-Т_энц: 21].

**«ДӨНЬЯ КӨЕНӘ»**, шигырь (1906).

XII йөздә иҗат иткән Урта Азия шагыйрьләре Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакыргани әсәрләренә охшатып язылган бу шигырьдә элек-электән үк төрки-татар әдәбияты өчен традицион тема – ялган суфиларны фаш итү үзәккә куелган. Әмма Т. биредә үзенчә эш итә: сөйләм ишәк исеменнән алып барыла. Ахмаклык билгесе булган бу җан иясе образына мөрәҗәгать итү дә ишанның арталыгыннан, наданлыгыннан көлүгә юнәлтелә. Шигырь аерым җырларга (трактир җырларына) хас булган «дөньяда», «вай дөнья» рәдифләре белән бирелә: «…Халыкның каралуына (дөньяда) / Чын күңелдән чалыйшан (вай дөнья)».

Әсәр дүрт юллы 5 строфадан гыйбарәт. Беренче тапкыр «Фикер» газетасының 1906 елгы (45нче) 3 декабрь санында «Вак-төяк» дигән гомуми баш астында имзасыз гына басылган. Кульязмасы сакланмаган.

Әсәр*.: Алты томлы Академик басма. Т.I. Б. 138.*

*Х.Й.Миңнегулов* [2016-Т_энц: 235].

Әлеге саллы, җитди басма Г. Тукайны өйрәнү фәненең йөз елдан артык тарихында зур бер казаныш, бик күп галимнәрнең, белгечләрнең эшләренә нәтиҗә булып тора. Ул татар телендә эшләнгән беренче персональ энциклопедия буларак кыйммәтле.

Энциклопедик характердагы тагын бер үзенчәлекле хезмәт – Ф. Урманче төзегән өч томлык «Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек» [2008-2011-Т_энц_I-III]. Татар гуманитар фәннәре тарихында беренче тәҗрибә буларак, 2008–2011 елларда басылган

әлеге сүзлекләре белән автор «милли мифология белән бәйләнгән төп мифологик төшенчә-категорияләргә тукталып, алар турында мөмкин кадәр киң мәгълүмат бирү, татар милли мифологиясенең, төгәл һәм үзенчәлекле бер система буларак, дөнья мифологиясенең аерылгысыз, табигый һәм мөһим бер өлеше икәнен күрсәтү» [2008-Т_энц_I: 30] максатын тормышка ашырган. Әлеге искиткеч бай энциклопедик сүзлектә саф мифологик сүз-төшенчәләрдән тыш, фольклорның аерым жанрлары, әсәрләре, борынгы һәм урта гасырлар төрки-татар әдәби үрнәкләре турында да кызыклы мәгълүматлар табарга була. Мисал өчен:

**БӘБИ ТУЕ**, сабый баланың дөньяга килүе уңаеннан оештырыла торган катлаулы йолалар, гореф-гадәтләр җыелмасын шартлы рәвештә әнә шулай атарга мөмкин. Элеккерәк заманнарда татар халкында бала туу белән бәйле күп төрле йолалар, ырымнар булган. Бу чараларны оештыру белән махсус кешеләр шөгыльләнгән. Бала тууны билгеләп үтүдә фольклор әсәрләре әһәмиятле урын алып торган. Чөнки бала туу һәр чорда, һәр гаиләдә зур бәхет саналган. Әйтик, Темников татарларында (Мордва республикасы) бәбиләгән хатынның каенанасы авыл буйлап сөенче әйтеп йөргән. Аңа авыл халкы хәергә йомырка бирә торган булган: янәсе, бала йомырка кебек тәгәрәсен... Баланы беренче тапкыр мунчада юындыру зур әһәмияткә ия булган. Бу эшне махсус әзерлеге булган әбиләр башкарган. Баланы юындырганда төрле такмаклар әйтелгән. Мәсәлән: «Атаң кискән утын түгел, Анаң яккан мунча түгел. Имән кебек нык булсын. Каен кебек ак булсын...» Бала туган өйдә шул уңайдан кунак чакыру, төрле мәҗлесләр оештыру шулай ук гадәти бер күренеш саналган. Кайвакыт Б.т. белән бәби мунчасы бер-бере белән үрелеп барган. Бәби яки бишек туена килүчеләр, гадәттә, төрле бүләкләр алып килгәннәр. Балага исем кушу аеруча әһәмияткә ия булган. Чөнки борынгылар ышануы буенча, баланың киләчәге аның исеме белән турыдан-туры бәйләнгән. Кайбер якларда, мәсәлән, Хвалын татарларында, бала тугач та аңа вакытлыча исем – кендек аты кушып торганнар. Бераз вакыт узгач, махсус мәҗлес җыеп, мулла чакыртып, балага чын, яхшы исем кушканнар: сайланган исемне мулла берничә тапкыр баланың колагына кычкырып әйткән, дога кылган, Коръән сүрәләреннән өзекләр укыган. Әгәр бала авырып китсә, аңа миң чыкса яки

балалар еш үлә торган булса, балага яңа, кайвакыт аның «гомерен саклый» торган исемнәр кушканнар [2008-Т_энц_I: 217-218].

Мисаллардан күренгәнчә, республикабыз, милләттәшләребез турында булсынмы, тарихка, гореф-гадәтләргә, йолаларга яисә аерым бер шәхескә багышланган булсынмы, үзенең алдан уйланган максат-бурычларына һәм концепциясенә бәйле рәвештә, татар телендәге һәр энциклопедик сүзлек – үткәнебезне, бүгенгебезне һәм киләчәгебезне билгели торган затлы язма, ягъни Ватан, милләт һәм мәдәният, милли үзаңыбыз энциклопедиясе урын алган.

**Синонимнар сүзлеге**

Татар теленең синонимнарга бай булуыннан чыгып фикер йөрткәндә, барлык мәгънәдәш сүзләрне бер урында туплап биргән сүзлекләрнең актуаль булуы шик тудырмый. Аларның төрле елларда басылганнары бар. Мисал өчен, Ш.С. Ханбикованың 1962 елда нәшер ителгән «Синонимнар сүзлеге» [1962-Т_син_аңлат] сүзләрнең синонимнарын теркәп кенә калмый, синонимик рәттәге сүзләрнең гомуми мәгънәсен, кирәк очракта теге яки бу синонимның мәгънәсен яисә аңа кыскача аңлатма да бирә. Сүзлектә, төп сүз буенча 400 ояга тупланып, 2000 синоним. Барлык синонимик вариантлар доминанта сүз янына тупланып, ояга һәм оядагы һәр сүзгә аңлатма бирелгән, әдәби әсәрләрдән мисал китерелгән. Сүзлек мәкаләләре түбәндәгечә:

таблица → (таблица) → җәдвәл; манзара; табыш → (доход; приход) → файда; керем; килер; килеш; доход; төшем; барыш [1962-Т_син_аңлат*:* 88];

йөз чыту → (хмуриться) → йөз сыту; йөз җыеру; каралу; кара яну; сытыклану; чырай бозу; чырайсызлану; турсаю; томсалану; томсару; төмсәләнү; төмсәрү; төкселәнү; сытылу; йөз бозу [1962-Т_син_аңлат: 48].

Ш.С. Ханбикова һәм Ф.С. Сафиуллинаның 1999 елда дөнья күргән «Синонимнар сүзлеге» татар телендәге 25 меңгә якын синонимик берәмлекне берләштергән 4500 дән артык ояны үз эченә ала. Авторлар фикеренчә, ана теленең шулай синономнарга бай булуы «телебезнең борынгыдан ук яшәп, чарланып килүеннән, халкыбызның мәгълүматлы, укымышлы тарихи халык булуыннан, үз теленә яратып, игътибар белән каравыннандыр» [1999-ТР_син: 3].

Сүзлектә төп сүздән соң җәя эчендә синонимның русчага тәрҗемәсе китерелә һәм охшаш мәгънәдәге барлык сүзләр (си-

нонимнар) санап кителә. Мисал өчен: *сабый (младенец, ребенок, дитя) нарасый; нарасидә; олан; бәби // бәбәй; бәләкәч; бала; яшь бала; кечкенә бала; нәни бала* [1999-Т_син: 81]. Биредә бүгенге көндә актив кулланыла торган сүзләрдән тыш, нарасидә кебек, кулланылыштан төшеп калганнарын да, *бәбәй* кебек, аерым сөйләшләргә хас вариантларны да очратырга мөмкин.

Теге яки бу сүзнең мәгънәдәш сүзләре күп булуын искә төшереп, синонимнар сүзлеге язма һәм сөйләм телебезне тагын да матуррак, баерак, камилрәк итү өчен хезмәт итә.

**Антонимнар сүзлеге**

Татар теленең бер-берсенә каршы мәгънәдәге сүзләрен бер урында туплап биргән сүзлекләр XX гасырның икенче яртысына карый. Беренчесе – Ф.С. Сафиуллина һәм Л.М. Ризванова тарафыннан төзелеп, 1997 елда басылган «Татарча-русча антонимнар сүзлеге» [1997-ТР_антон]. Мәктәп укучыларын күз уңында тотып төзелгән әлеге сүзлек 1000 антонимик парны үз эченә ала. Антонимнарның мәгънәләре аңлатылмый, аерым очракларда кулланылышын күрсәтә торган иллюстратив материал бирелә: Болыт-болыт – облачный. Аяз-аяз – ясный. **Аяз-аяз** көннәрдә җиләк җыяр аппагым, **болыт-болыт** көннәрдә урак урыр аппагым [1997-ТР_антон: 26]; Ару – чистый, пычрак – грязный [1997-ТР_антон: 14]. Икенчесе – 2003 елда басылган «Татарча-русча, русча-татарча антонимнар сүзлеге» дә [2003-ТР_РТ_антон] шул ук типта төзелгән, әмма, алдагысыннан аермалы буларак, әлеге сүзлекнең русча-татарча өлеше дә бар. Һәр ике якта да 1500 гә якын антонимик пар урын алган.

Ф.С. Сафиуллинаның 2005 елда басылган «Антонимнар сүзлеге: (Хәзерге татар поэзиясе һәм мәкальләрдән)» [2005-Т_антон] 2500 гә якын антоним парны үз эченә ала. Исеменнән үк күренгәнчә, ул матур әдәбияттан һәм халык авыз иҗаты әсәрләреннән мисаллар белән баетылган. А.Ш. Рәхмәтуллинаның 2015 елда басылган «Татар теленең омонимнар һәм антонимнар сүзлеге» бер үк вакытта антонимнарны да, омонимнарны да теркәгән сүзлек буларак үзенчәлекле. Биредә аларның татар телендә иң актив кулланыла торганнарына урын бирелгән. Сүзлек мәктәп укучылары, укытучылар өчен аеруча файдалы [2015-*ТР_омон*_антон].

Димәк, *ак – кара, якты – караңгы, матур – ямьсез* кебек күпсанлы антонимнарны теркәгән сүзлекләрдән тыш, бер үк урын-

да антонимнарны һәм омонимнарны туплап биргән хезмәтләр дә була. Алар һәрберсе үзенчә әһәмиятле. Татар телендәге омонимнарның үзләренә генә багышланган сүзлекләр дә бар. Аларны аерым карап үтәрбез.

**Омонимнар сүзлеге**

Татар телендә омонимнарны теркәгән махсус сүзлекләр күп түгел. Беренчесе – 1997 елда басылган «Татар теленең омонимнар сүзлеге» (русчага тәрҗемә белән) (авторлары: Ф.С.Сафиуллина, Л.М.Ризванова) [1997-ТР_омон_мәкт]. Хезмәт 1000 нән артык омоним һәм омоформаны үз эченә ала. Аларның кайберләре янына *диал., полит.* кебек тамгалар куелган. Омонимнарның мәгънәләре рус теленә тәрҗемәләре аша бирелә. Аңлатмалар китерелми, иллюстратив материал бирелми. Мисал өчен:

тукмак I – колотушка

тукмак II – *диал.* цепь

тукмак III – *диал.* мать и мачеха

тукмак IV – *диал.* гиря

тукмак V – *диал.* тукмак юл: тропинка [1997-ТР_омон_ мәкт: 74].

гриф I – гриф (птица)

гриф II – гриф (печать)

гриф III – деревянная или пластмассовая планка для изменения звука инструмента [1997-ТР_омон_ мәкт: 18].

Бу сүзлек омонимнарны туплау, системага салу һәм теркәү максатыннан эшләнгән булса, икенче сүзлек – Ф.С. Хәкимҗан төзегән «Татар теленең аңлатмалы омонимнар сүзлеге», бер үк вакытта аңлатмалы һәм татарча-русча сүзлек булып тора [2004-*ТР_омон*_аңлат]. 2004 елда дөнья күргән әлеге хезмәт шактый мәгълүматлы. Анда якынча 2300 омонимик оя бирелә, омонимнарның төре тәгъдим ителә, санлы индекслар, грамматик һәм стилистик тамгалар ярдәмендә өстәмә мәгълүмат китерелә. Мисал өчен, сүзлектә фигыльләрнең 1) нигезләре (тамырлары) бирелә, 2) омонимнары булган очракта, бу нигездән ясалган форма аерым күрсәтелә, шуннан соң русча тәрҗемәсе һәм аңлатмасы куела. Һәр сүзлек мәкаләсе әдәби әсәрләрдән, сүзлекләрдән мисаллар – иллюстратив материал белән дәлилләнә:

**БУЙЛА- I–IV** * I1, II

**буйла-** I фигыль, урыс. *измерить (длину, глубину)*. «Буй III»тән ясалган.

*Таяк батырабыз – буйламый, колга төшерәбез, төпкә җитми, пылт итеп кире сикереп чыга!* (Ш. Галиев).

**буйла-** II фигыль, урыс. *прошагать, пройти*. Адымларга, буйга үтәргә.

*Малай чагым эзләреннән / Агымсулар буйладым* (Ә.Баянов).

**буйла-** III фигыль (диал), урыс. *заартачиться*. Буйсынмаска.

*Каенсар җирәне буйлаган! Малаен егып калдырган да авылына качкан!..* (Г.Бәширов).

**буйла-** IV фигыль (диал), урыс. *становиться привычным*. Бер гадәтне дәвам иттерергә.

*Буйлады да буйлады шы көwө* (ТТДС II, 60) [2004-*ТР*_омон_ аңлат: 76].

**БУЛДЫК- I–II** * I2, I4

**булдык** I исем, урыс. способность, достоинство. Булдыклылык, сәләтлелек.

*Шушы минутларда ул кыз Гыйzзәтнең бар булдыгын белән алган иде* (Б. Камалов).

**булдык** II фигыль, урыс. *были, посетили, оказались* и т.д. «Бул-I» тамырыннан ясалган билгеле үткән заман хикәя фигыльнең I зат күплеге.

*Тагын берничә адым үтүгә, без бөтенләй ялангач түбә өстендә булдык* (М.Әмир) [2004-*ТР_омон*_аңлат: 77].

Татар телендә бер үк сүзнең күптөрле мәгънәләр белдерә алуын дәлилли торган мондый төр сүзлекләр мәктәп укучылары, укытучылар, тел белгечләре өчен һәрвакыт актуаль булачак.

**Авторлык сүзлекләре**

Татар лексикографиясе соңгы дистә елларда яңа төр заманча сүзлекләргә баеды. Шундыйларның берсе – язучылар теле сүзлеге. Мондый хезмәтләр аерым бер авторның әсәрләрендә кулланылган сүзләрне туплау, анализлау яисә аңлатма бирү максаты белән төзелә. Язучы теле сүзлекләре тел, әдәбият галимнәре, язучының иҗатын, тел үзенчәлекләрен яисә әдәби тел тарихын өйрәнүләр өчен мөһим чыганак булып тора, шагыйрьнең иҗаты белән кызыксынучы һәркем өчен кызыклы, мәгълүматлы хезмәт ролен үти.

Мисал өчен, 1998 елда «Тукай энциклопедиясе»н төзүдә бер этап буларак, «Габдулла Тукай әсәрләре» исемле сүзлек-белеш-

мәлек [1998-Т_Тукай_энц] чыкты. 2006 елда М.Җәлил иҗатына бәйле ике сүзлек дөнья күрде. Беренчесе – патриот шагыйрь Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» шигырьләр циклының телен чагылдыра торган икетелле сүзлек [2006-Т_Җәлил]. Казан университетында оештырылган Җәлил компьютер фонды нигезендә төзелгән хезмәт конкорданс (шигырьләрдән өзекләр китерелгән сүзләр күрсәткече), кулланылу ешлыгын күрсәтә торган сүзләр күрсәткече, квантитатив характеристика кебек өлешләрдән гыйбарәт. Икенчесе – «Муса Җәлил. «Моабит дәфтәрләре» теле» [2006-Т_Җәлил] сүзлеге. Биредә конкорданс һәм сүзләрнең, сүзформаларның кире күрсәткече, сүзләрнең ешлык күрсәткече бирелгән.

2009 елда Казан дәүләт университетының Тукай компьютер фонды нигезендә эшләнгән «Габдулла Тукай. Шигърият теле» сүзлеге дөнья күрде (төзүче-авторлары: К.Р. Галиуллин, Р.Н. Кәримуллина) [2009-Т_Тукай]. Сүзлекнең төп өлешен конкорданс – Тукай шигырьләреннән алынган цитаталар белән бирелгән сүз формалары күрсәткече алып тора. Бу күрсәткеч алфавит тәртибендә китерелгән. Конкорданс сүзнең һәм сүз формасының теге яки бу әсәрдә, шигырь строфасында һәм шигырь юлында нинди контекстта, нинди бәйләнештә, ничә тапкыр очравын күрсәтә, Г.Тукай шигырьләрендә теркәлгән сүз формалары кулланышының барлык очракларын да тасвирлый. Сүзлектә сүз формаларының ешлыгы күрсәтелә һәм кулланылышы чикләнгән (искергән, диалекталь һ.б.) сүзләргә, ялгызлык исемнәргә, кайбер алынма сүзләргә аңлатма бирелә. Конкорданс кысаларында теге яки бу сүзгә тулы аңлатма бирү, сүзнең Габдулла Тукай әсәрләрендә кулланылган тулы мәгънәсен ачу бурычы куелмаган. Кайбер очракларда әлеге аңлатмалар аерым контекстларга гына карый. Мисал өчен, **АКБАЙ** (1)

Әйдәле, Акбай! Өйрән син, арт аягың белән тор ---. 257-1:1 [2009-Т_Тукай_40].

**БОЛЫТ-БОЛЫТ** (1)

Һаваларда кошлар оча болыт-болыт ---. 12-7:2 [2009-Т_Тукай_180].

Сүзләрнең кире күрсәткечендә инверсион алфавит тәртибендә урнашкан сүз формалары бирелә. Сүз формаларының ешлык күрсәткечендә Г.Тукай шигырьләрендә уннан артык кулланылган сүз формалары китерелә. Сүз формалары ешлыклары кимү тәртибендә урнашкан, мисал өчен: *авылда, юлда, аркамда, исламда, урамда,*

*бакчамда, җавабымда, колагымда* һ.б. [2009-Т_Тукай_2: 399]. Әлеге сүзлек Габдулла Тукай шигъриятенә һәм XX гасыр башы татар теленә хас үзенчәлекләрне өйрәнү өчен мөһим чыганак булып тора.

Соңгы елларда мондый төр сүзлекләр төзүгә игътибар тагын да артты. Мисал өчен, З.С. Кәримованың «Аяз Гыйләҗев прозасындагы фразеологизмнар сүзлеге» (2012), Г.С. Әмиревнең «Тукай алынмалар сүзлеге» (2016) һ.б. шундыйлардан. Карап үтелгән һәм мондый типтагы сүзлекләр барысы да күренекле әдипләрнең иҗатына тагын да якынайта, аларның тел үзенчәлекләрен ачыграк күрергә, яратып кулланган чагыштыруларын, образлы гыйбарәләрен күзалларга ярдәм итә торган чыганак ролен үти.

**Сүзьясалыш сүзлекләре**

Татар тел белемендә сүзьясалыш тармагына караган өч сүзлек билгеле. Беренчесе – «Кеше. Кеше тәне (организмы) өлешләре» дигән тематик төркем материаллары буенча төзелеп, 2007 елда дөнья күргән «Русча-татарча тематик сүзьясалышы сүзлеге» (авторлары: А.М. Ямалетдинова һәм И.А. Латыйпова). Биредә кеше организмына кагылышлы лексика түбәндәгечә ике телдә бирелә:

**<u>Бровь</u>**
бров-к-а
бров-н-ый
бров-аст-ый
без-бров-ый
без-бров-н-ый
меж-бров-j-е
над-бров-н-(ый)
    надбровн-иц-а
над-бровь-j-е
бел-о-бров-ый
густ-о-бров-ый
крив-о-бров-ый
рус-о-бров-ый
рыж-е-бров-ый
светл-о-бров-ый
сед-о-бров-ый
сиз-о-бров-ый
темн-о-бров-ый

тонк-о-бров-ый
черн-о-бров(-ый)
чернобров-еньк-ий
чернобров-к-а
широко-о-бров-ый

**Каш**

ак-каш *(белобровик)*
кара-каш *(чернобровик)*
каш-ага *(горизонтально прибитая доска над окном или печью, материя на ней)*
кашага-ла-рга *(повесить ткань на эту доску)*
каш ара-сы *(межбровье)*
каш-бау *(нарядный женский головной убор)*
каш-ка *(особая метка на лбу животных)*
каш-калак *(лысуха)*
каш-кара *(краска для бровей)*
каш-күз *(брови и глаза)*
каш-лак *(возвышенность)*
каш-лан *(поле на возвыш-ти)*
каш-лы *(бровистый, бровастый)*
каш-лык *(небольшая возвышенность)*
каш-сыз *(безбровый)* [2007-РТ_сүзяс: 14].

Икенчесе – шул ук елда төзелгән «Татарча-русча тамырдаш сүзләр сүзлеге» (авторлары: Ф.С. Сафиуллина, З.Н. Кириллова, Ә.Ш. Юсупова, И.Г. Мифтахова) [2007-ТР_ сүзьяс]. Әлеге сүзлектә барлыгы 19 000 сүз һәм якынча 4000 сүзьясалыш оясы бирелгән. Алар түбәндәгечә:

**АҺӘҢ** ● созвучие, благозвучие, гармония, мелодичность
**Аһәң-дәш** ● созвучный
**Аһәң-дәш-лек** ● созвучие, созвучность
**Аһәң-ләш-тер-ү** ● делать (сделать) созвучным
**Аһәң-ле** ● благозвучный, мелодичный, гармоничный
**Аһәң-ле-лек** ● благозвучность, мелодичность [2007-ТР_ сүзяс: 33].

**ОЛПАТ** ● величественный, авторитетный
**Олпат-лык** ● величественность, авторитетность [2007-ТР_ сүзяс: 251].

Өченче сүзлек – И.И. Сабитованың 2015 елда дөнья күргән «Татар теленең сүзьясалыш сүзлеге: «кеше» тематик төркеменә караган лексика». Биредә кеше темасына караган лексик берәмлекләр (барлыгы 3325 сүз) 178 сүзьясалыш оясына туплап бирелгән. Тамыр сүз һәм аның нигезендә барлыкка килгән тамырдаш сүзләрне ояларга бүлү яңа сүзнең кайсы нигезгә нинди сүзьясагыч чаралар кулланып ясалганын ачык күрсәтеп тора. Сүзлектә ясалма сүзләрнең сүзьясалыш структурасы һәм аларның сүзьясалыш потенциалының барлык мөмкинлекләре билгеләнгән. Мисал өчен:

**КҮЗ** и. анат.
күз-**ә** *(ү) ф. диал.*
күз-**әлә** *(ү) ф.*
күз-**әнә** *и.*
күз-**әнәк** *и.* һ.б. [2015-Т_сүзьяс: 65].

**ЯШЬ** III *и.* Ел
яшь-**ле** I *с.*
яшь-**лек** II *с.*
яшь-**тә-ге** *с.*
яшь-**тәш** *и.*
яшьтәш-**лек** *и.* [2015-Т_сүзьяс: 116].

Димәк, сүзьясалыш сүзлекләре барлык сүзьясалыш ояларын күрергә, татар телендәге сүзләрнең күбесенчә нинди чаралар, ясагыч кушымчалар һ.б. ярдәмендә барлыкка килүен күзалларга ярдәм итеп, нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә һәм фәнни хезмәтләр, фәнни анализ өчен мөһим чыганак ролен үти.

**Лингвомәдәни сүзлекләр**

XXI йөз башында дөнья күргән заманча лексикографик хезмәтләрнең тагын бер төре – берәмлекләрнең этномәдәни компонентын аңлату аркасында халыкның мәдәниятен һәм тарихын өйрәнү өчен әһәмиятле чыганак ролен үти алырлык лингвомәдәни сүзлекләр.

Татар телендә беренче этномәдәният сүзлек-белешмәлеге 2003 елда басыла. Р.Р. Җамалетдинов төзегән әлеге хезмәттә аерым лексик берәмлекне теркәп, аңлатып бирү түгел, ә шул тел берәмлеге аша тел һәм мәдәниятнең үзара бәйләнешен дәлилләү максат итеп куела. Сүзлек мәкаләләре милли-мәдәни үзенчәлекләрне ачык чагылдырган, халыкның тарихы һәм матди көнкүреше белән тыгыз

бәйләнгән, һәр татар кешесенә кечкенәдән таныш булган берәмлекләргә багышлана [2003-Т_лингвокульт].

АКЫЛ

(ум // умственный, разум, рассудок // рассудочный; мысль, идея; совет)

Гомумтөрки алынма, гарәп телендәге гакл акыл (гақыйль «акылдар») сүзеннән.

○ □ Кешенең уйлау, фикер йөртү сәләте, аңлылык дәрәҗәсе; иҗтимагый аң, иҗтимагый фикер; киңәш; уйлап эш итү; уй, фикер;

□ сабак

□ акыллы (аңлы, зиһенле; ачык фикерле, уйлап эш итә торган; акылга туры килә торган), акыллылану (акыллыга әйләнү), акыллылык (акыллы булу), акылсыз (уйламыйча эш итъче кеше турында; тәрбиясез, холыксыз), акылсызлану (юләрләнү; холыксызлану, тәрбиясезлек күрсәтү), акылсызлык (акылсыз булу) һ.б.

◊ Акыл алтын икән

Үзен башкалардан өстен кую, акыллырак дип санау һ.б. [2003-Т_лингвокульт].

А.Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә [2007-Т_лингвокульт_аңлат] 12 000 гә якын берәмлек тасвирлана. «Төрле дини төшенчәләрне, аларның язылыш вариантларын, мәгънәләрен, милләт һәм дин тарихына караган әһәмиятле һәм кызыклы фактларны, тормышта эз калдырган күренекле затлар турындагы мәгълүматларны күп еллар буена көндәлек эш өчен теркәп барган дәфтәрләрдән» башланып киткән әлеге сүзлек, автор ассызыклаганча, «үзенең колачы һәм эчтәлеге белән гамәлдә йөри торган күпчелек сүзлек һәм белешмәлекләрдән аерыла» һәм иң элек «хәзерге заман татар укучысын – гади укучыны – язма чыганакларга, тарихыбызга һәм иманыбызга якынайтуны, артык вакыт сарыф итмичә генә күпчелек тарихи, дини, фәлсәфи әдәбиятны зиһенгә алу эшен җиңеләйтүне максат итеп куя» [2007-Т_ лингвокульт_аңлат: 3].

Сүзлектә милләт тарихында эз калдырган шәхесләр, Татарстан, Россия һәм чит илләрдәге байтак кына тарихи һәм хәзерге мәчетләр, мәдрәсәләр турында мәгълүмат табарга була. Шул ук вакытта, сүзлек тарихи ачыклык кертү йөзеннән, Казан шәһәрендәге урам исемнәрен, табигать ядкярләрен, микротопонимнарны теркәп калдыруны, Коръәнне татарчага тәрҗемә итүгә нисбәтле мәсьәләләргә игътибар юнәлтүне дә бурыч итеп куйган. Татар

халкының тарихына, милли мәдәниятенә кагылышлы кыйммәтле мәгълүматларны туплаган бу сүзлек үзенә бер төрле дини-тарихи аңлатмалы сүзлек кебек кабул ителә. Аңлатмалар түбәндәгечә:

**ТӘСБИХ** *г.* – 1. Шул ук *сөбха, дисбе.* Гарәпчә «мактау» мәгънәсендәге сүз. «Сөбхан Аллаһ!» дигән гыйбарәне кабатлау. Риваятьләргә караганда, Идрис галәйһиссәлам һәр көн 12 мең тәсбих әйтә торган булган. Иман Валерия Порохова «Хадисы Пророка» китабында тасбиха язылышын (женский род формасын) куллана. // *Агач башкайлары тәсбих әйтә / Акрын гына искән җил белән.* Җырдан.

Теологлар: «Сөбхан Аллаһ» гыйбарәсе Аллаһның ширеге яки берәр кимчелеге, йомшаклыгы, сәләтсезлеге юк икәнен дә белдерә диләр.

2. Зикерне санау өчен кулланыла торган «тәсбих мәрҗәнен» тәсбих (дисбе) дип йөртәләр (гарәпчә тулы исеме – *әл-мисбат әл-вирдийят*) ---. [2007-Т_ лингвокульт_аңлат: 259-260].

2013 елда татарларның милли-мәдәни кыйммәтләренә багышланган тагын бер хезмәт дөнья күрә. Л.Р. Сәгыйдуллина төзегән «Татар лингвомәдәни концептлар сүзлеге»ндә милләттәшләребезнең милли дөнья картинасын чагылдыруда мөһим урын тоткан лингвомәдәни концептлар тәкъдим ителә [2013-Т_ лингвокульт].

Халкыбызның гореф-гадәтләренә, йолаларына, милли-мәдәни мирасына караган бай мәгълүматны бер урында туплаган хезмәтләрнең яңа төре буларак, мондый сүзлекләр арасында Казан дәүләт университетының татар телен өйрәнүче галимнәре тарафыннан төзелеп, 2015 елдан алып даими басылып килә торган этномәдәният сүзлекләре зур урын алып тора. 2015 елда сүзлекнең беренче томы – «Татар теленең этномәдәният сүзлеге: матди мәдәният лексикасы (ризык һәм савыт-саба атамалары)» дөнья күрде (төзүче авторлар: Р.Р. Җамалетдинов, Ә.Ш. Юсупова, Г.Ф. Җамалетдинова, Р.С. Нурмөхәммәтова, М.Р. Саттарова, Г.Н. Хөснуллина / Тәрҗемәчеләр: А.Х. Әшрәпова, Л.Р. Мөхәммәтҗанова, Л.Р. Мөхәрләмова, Л.Х. Шәяхмәтова). Сүзлектә ризык һәм аны әзерләү белән бәйле төшенчәләрне белдергән 40 сүз карала. Мисал өчен: *бавырсак, бәлеш, бөккән, гөбәдия, гөбе, кабартма, казан, казы (казылык), каймак, каклаган каз, кош теле, күмәч, кымыз, кыстыбый, мичкә, өчпочмак, пәрәмәч, сумса, таба, табак, табикмәк, токмач, умач, чәй, чәкчәк, шулпа* һ.б. Сүзлекнең 2016 елда басылган «Татар те-

ленең этномәдәният сүзлеге: матди мәдәният лексикасы (кием-салым, тукымалар һәм бизәнү әйберләре атамалары)» дип аталган икенче томында кием-салым, тукымалар һәм бизәнү атамаларыннан 45 берәмлек урын ала: *алка, алъяпкыч, балак, балдак, башмак, беләзек, билбау, бишмәт, кәләпүш, муенса, оек / оекбаш, олтан, толып, тун, түбәтәй, ука, хәситә, чабата, чалбар, чалма, чапан, чикмән, читек, чулпы, шәл, ыштан, эшләпә, яка, яулык* һ.б. 2017 елда сүзлекнең өченче томы – «Татар теленең этномәдәният сүзлеге: кешенең интеллектуаль һәм әхлак дөньясы лексикасы» (төзүче авторлар: Р.Р. Җамалетдинов, Р.С. Нурмөхәммәтова, М.Р. Саттарова, Ф.Р. Сибгаева / Тәрҗемәчеләр: А.Х. Әшрәпова, Л.Р. Мөхәрләмова) басыла. Әлеге томда игътибар үзәгендә – татар халкының менталитеты һәм кыйммәтләр системасын чагылдырган *абруйлы, акыллы, атаклы, батыр, бәхетле, дуамал, җор, зирәк, изге, ихлас, көнче, куркак, мактанчык, мәрхәмәтле, моңлы, намуслы, оялчан, сабыр, саран, ягымлы, ялагай* кебек сүзләр. Кешеләргә хас булган хис-кичерешләр, тасвирлаулар, сыйфатлаулар аша тулы бер милләтне, халыкны күзалларга, аңа хас үзенчәлекләрне тирәнрәк ачарга ярдәм итә. Хезмәттә әлеге сүзләр кергән фразеологизмнар, мәкаль-әйтемнәр, матур әдәбият әсәрләреннән алынган күпсанлы мисаллар китерелә, шулар аша бу берәмлекләрнең татарлар тормышында һәм аңында тоткан урыны ачыклана. Алдагы елларда басылган сүзлекләрдән аермалы буларак, биредә материал татар һәм инглиз телләрендә бирелә.

Сүзлек мәкаләләре түбәндәгечә төзелә: баш сүз бирелә, аның этимологиясе ачыклана һәм сүзнең XX–XIX гасырларда чыккан төрле сүзлекләрдәге мәгънәләре китерелә; күчерелмә мәгънәләре, аларны куллану формалары ачыклана; синонимнары, антонимнары бирелә, халык авыз иҗатында, әдәби әсәрләрдә һ.б.да кулланылышыннан мисаллар тәкъдим ителә.

Мисал өчен, **бәхетле** сүзенә лингвомәдәни сүзлектә мондый мәгълүмат таба алабыз:

«**Бәхетле** «бәхет» тамырыннан. Бәхет – гарәп сүзе: 1) язмыш; 2) бәхет, сәгадәт» [2017-Т_ лингвокульт_аңлат: 32]. Шуннан соң әлеге сүзлекнең чуваш, мари, фарсы һ.б. телләрдәге язылышы китерелгән һәм төрле еллардагы (1913, 1927, 1931, 1950, 1966, 1977, 2005, 2007) татар сүзлекләрендәге бирелеше санап үтелгән; синонимнары (*сәгадәтле, котлы, уразлы, талигълы // талигалы,*

*мөбарәк, бәхтеяр*), антонимнары (*бәхетсез, кайгылы, михнәтле), бәхетленең әтәче дә күкәй сала* һ.б. фразеологизмнар, *Бәхетлене сөймиләр, бәхетсезне җәллиләр, Бәхетленең ташы ярылыр,* бәхетсезнең башы ярылыр кебек күпсанлы мәкаль-әйтемнәр һәм Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Г. Бәширов, Ә. Еники һ.б. язучыларның әсәрләреннән *бәхетле* сүзе кулланылган матур җөмләләр китерелгән [2017-Т_лингвокульт_аңлат: 32-37].

Телне мәдәни күренеш буларак өйрәнү юлында яңа тәҗрибә булган әлеге сүзлекләрдәге лексик берәмлекләр татар халкының матди мәдәниятен һәм эчке дөньясын чагылдыра. Милли киемнәр, милли ризыклар яисә кешеләргә хис-кичерешләр, тасвирлаулар милләтебез турында тулы күзаллау булдыруга, татар халкының үзенчәлекле якларын, сыйфатларын тирәнрәк ачарга ярдәм итә.

**Фольклор теле сүзлеге**

XXI гасырда татар лексикографиясе тагын бер яңа төр сүзлеккә – фольклор теле сүзлекләренә баеды. Мисал өчен, 2011 елда басылган «Татарча-русча мәкальләр сүзлеге» (авторлары: Р.Г. Гыйззәтуллина-Старцева, И.Г. Гыйззәтуллин), 2014 елда дөнья күргән «Словарь народных примет в разноструктурных языках (русский, татарский, английский, немецкий» (авторлары: Н.Н. Фәттахова, М.А. Кулькова, С.В. Туганова), 2018 елда басылган «Татар фольклоры теле: мәкальләр, канатлы әйтелмәләр, җор сүзләр һәм әйтемнәр: сүзлек» (авторы: К.Р. Галиуллин) шундыйлардан. Мондый сүзлекләр, исемнәреннән үк күренгәнчә, икетелле яки күптелле тәрҗемә хезмәт булырга яисә халык авыз иҗаты әсәрләренең аерым бер төрен укытучылар, галимнәр һәм гомумән, телебез белән кызыксынучы киң катлам укучылар өчен файдалы булырлык итеп, туплап, системага салып тәкъдим иткән чыганак ролен үтәргә мөмкиннәр.

К.Р. Галиуллин төзегән «Татар фольклоры теле: мәкальләр, канатлы әйтелмәләр, җор сүзләр һәм әйтемнәр» сүзлеге татар паремияләренең дүрт төре (мәкальләр, әйтемнәр, җор сүзләр, канатлы әйтелмәләр) материалларын системалаштырып тасвирлаган белешмәлектән гыйбарәт [2018-Т_фольк]. Аның төп өлешен конкорданс, сүз формаларының кире һәм ешлык сүзлекләре тәшкил итә. Ешлык сүзлегендә татар паремияләрендә ун яки аннан да күбрәк очраган сүз формалары китерелә. Биредә сүз формалары ешлыклары кимү тәртибендә урнашкан [1259 (1230 | 29) дан 10 га кадәр]

1745 сүз формасы бирелгән, татар паремияләренең төп өлешендәге сүз формаларының саны һәм вариантлардагы саны турында мәгълүматлар тәкъдим ителгән. Мәсәлән:

МАКТАМА (10)

МАМЫК (10)

МӘКАЛЬ (10) [2018-Т_фольк: 572].

Конкорданс, ягъни паремияләрдән мисаллар рәвешендә бирелә торган сүз формалары күрсәткече 19 269 берәмлекне (сүз формасын) тасвирлый. Биредә сүз формаларының ешлыгы да күрсәтелә. Мисал өчен:

АКЧАГА (10) ■ Дуслыкны акчага сатмыйлар ○ 5394 ● 7194; 7697; 7698; 7699 (2); 7812; 7828;14851; 16555

АКЧАДАН (3) ■ Вакыт акчадан кадерлерәк ○ 795 ● 5348; 11908

АКЧАДЫР (2) ■ Вакыт акчадыр: гафил булма, качадыр ○ 796 ● 7789

АКЧАЛЫ (3) ■ Акча – санаулы, акчалы – танаулы ○ 7686 ● 7700; 7721 һ.б. [2018-Т_фольк: 27].

Кире сүзлектә ахыргы хәрефләре буенча алфавит тәртибендә урнашкан 19 269 сүз формасы исемлеге урын алган. Мәсәлән:

(1) ▪ ЙОРТЫМ

(1) ▪ БАСТЫМ

2/2°(1) ▪ ДУСТЫМ

(2) ▪ АТТЫМ һ.б. [2018-Т_фольк: 518].

Хезмәттә статистик мәгълүмат бик күп. Сүзлек ахырында татар паремияләренең тематик классификация планы урнаштырыла, үсемлекләр, хайваннар, кием-салым һ.б. турындагы паремияләрнең кайсы битләрдә китерелүе турында мәгълүмат бирелә.

Мондый төр сүзлекләр халык авыз иҗатын өйрәнү, куллану өчен әһәмиятле чыганак ролен үтәп кенә калмый, фольклор әсәрләрен фәнни нигездә тикшерүчеләр өчен зур ярдәмлек булып тора.

**Кире сүзлекләр**

Кире (инверсион) сүзлекләрдә сүзләр соңгы хәрефе буенча алфавитка салынып урнаштырыла. Беренче чиратта алар төрле дәрәҗәдәге фәнни тикшеренүләрдә (сүзьясалышы, фонетика, текстны компьютер программалары ярдәмендә эшкәртү һ.б.) файдалану өчен кирәк.

Татар теле материалы нигезендә төзелгән мондый типтагы беренче һәм бердәнбер сүзлек – М.Х.Әхтәмовның 1999 елда басылган «Татар теленең кире сүзлеге» [1999-Т_кире]. Ул ахыргы хәрефләре буенча алфавит тәртибендә урнаштырылган 32 000 сүзне үз эченә ала. Һәр сүзгә грамматик тамгалар куелган. Сүзлектә билгеле бер хәрефкә тәмамлана торган сүзләр, сүзләрнең грамматик билгеләре турында һ.б. статистик мәгълүматлар китерелә. Статистиканы күрсәткән таблицалардан татар сүзләренең грамматик төзелеше турында бик күп мәгълүмат алырга мөмкин. Хезмәт тулысынча яки өлешчә татар теленең грамматик сүзлек ролен үти ала.

Бүгенге көндә төзелә торган кайбер заманча сүзлекләрдә (мәсәлән, Муса Җәлил һәм Тукай шигърияте сүзлекләре) дә инверсион белешмәлек бар. Алар – аеруча галимнәр, тел белгечләре өчен мөһим чыганак.

**Грамматик сүзлекләр**

Грамматик сүзлекләр сүзнең морфологик һәм синтаксик үзлекләрен чагылдыра. Татар телендәге мондый төр сүзлек 2004 елда дөнья күрде. М.Х. Әхтәмов төзегән «Татар теленең грамматика сүзлеге: Сүз төрләнеше: Уку кулланмасы» шундыйлардан. Сүзлек укучыларга, укытучыларга, студентларга ярдәмлек буларак тәкъдим ителә [2004-Т_грам].

**Кыскартылмалар сүзлеге**

Күпмедер дәрәҗәдә сүзьясалышы сүзлекләре белән янәшә тора торган кыскартылмалар (аббревиатуралар) сүзлегенә мисал итеп Ф.Г. Миңнуллинның 2005 елда басылган «Татар теленең кыскартылмалар сүзлеге»н китерергә мөмкин [2005-РТ_Т_кыс-карт]. Аның русча-татарча өлешендә якынча 3500, татарча-русча өлешендә – 850 берәмлек. Бу сүзлектә шулай ук кыскартылмаларның әйтелеше ничек булуы да билгеләнгән, кайберләренә кыскача аңлатма бирелгән. Тарихи-этимологик мәгълүматлар белән баетылган аббревиатуралар да бар. Ул татар телендәге кыскартылмаларны чагыштырмача тулы теркәгән бердәнбер сүзлек булып тора.

Алда сүз алып барылган хезмәтләрдән тыш, татар лексикографиясендә соңгы елларда гына төзелә һәм басыла башлаган яңа төр сүзлекләр дә бар. Мисал өчен, И.Ф. Зарипованың 2012–2013 елларда басылган «Татар телендә сүзләр бәйләнеше сүзлеге» [2012-2013-Т_бәйл], халык үзаңында, этномәдәни системасында иң ачык

чагылган образларны яктырткан хезмәт – 2016 елда дөнья күргән «Ассоциативный словарь башкирского и татарского языков» (төзүчеләре: Газизова Л.В., Хөснетдинова А.В., Чертыкова Д.Р., Ишбердина М.Ф., Кочетова Г.Р., Габдуллина В.Р.) [2016-*БТ*_ассоц] һ.б. шундыйлардан.

Татар лексикографиясенең соңгы еллардагы тагын бер зур казанышы – алда сүз алып барылган күп кенә сүзлекләрнең электрон фондын. Бу юнәлештәге зур проектларның берсе – «TATZET» платформасы. Ул ТР ФАның Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Гамәли семиотика институты һәм башка фәнни оешмалар тарафыннан төрле елларда эшләнгән 20 проектны үз эченә ала. Проектның төп һәм иң мөһим үзенчәлеге – бер урында, татар теле сүзлекләренең күп функцияле электрон тупланмасын булдыру. Аңлатмалы, икетелле, күптелле, терминологик, аерым билгеләргә багышлап төзелгән, төрле аспектларны яктырткан һ.б. сүзлекләр урын алган электрон фонд даими рәвештә яңа сүзлекләр белән тулыландырылып тора. Биредә сүзнең дөрес язылышын, аңлатмасын, килеп чыгышын, басымын, тәрҗемәсен, грамматик үзенчәлекләрен, диалекталь сүзләрнең мәгънәсен, синонимнарын һ.б.ны белеп була.

«TATZET» платформасы беренче чиратта фәнни эшчәнлек алып баручы тел һәм әдәбият галимнәре өчен заманча инструментарийлар булдыру, тел, әдәбият, сәнгать белән бәйле материалларны интернет челтәре аша киң җәмәгатьчелеккә җиткерү, татар телен популярлаштыру мөмкинлекләрен киңәйтү максатыннан эшләнгән.

Сүзлекләрнең күптөрлелеге һәм аларны электрон форматта да куллану мөмкинлеге булу татар лексикографиясенең байлыгын һәм үсештә булуын күрсәтә. Һәр яңа сүзлек татар әдәби теленең үзгәрешен чагылдырып кына калмый, сүзләрне һәм сүзформаларны, терминнарны теркәп, аларны системага салу эшен башкара. Күп гасырлар дәвамында сүзлекләр төзүдә тупланган зур тәҗрибә лексикография өлкәсендә алга таба тагын да күләмлерәк проектларны гамәлгә ашыруга төпле нигез булып тора.

## ЙОМГАК

Соңгы берничә дистә ел дәвамында лексикографиянең көчле үсеше күзәтелә. Әлеге өлкәдә төрле төрдәге сүзлекләр шактый күп төзелде һәм төзелә дә. Бу исә җәмгыятьтәге күптөрле тел белешмәлекләренә ихтыяҗ арту белән бәйле. Сүзлекләрнең саны, аларның төрләре генә түгел, ә традицион белешмә китапларның мәгълүмат бирү потенциал дәрәҗәсе дә сизелерлек күләмдә арта. Җәмгыять үскән саен, сүзлекләрнең формалары, мәгълүмат туплау киңлеге дә арта, үзгәреш кичерә бара. Сүзлекләрдә тупланган тел байлыгы берничә гасыр дәвамында телебездә барган үзгәрешләрне, үсеш юнәлешләрен тулаем күзаллау мөмкинлеге бирә. Шунлыктан сүзлекләрне өйрәнү фәнни күзлектән генә түгел, бәлки тел, милләт яшәешен өйрәнү өчен дә гаять әһәмиятле санала.

*Татар лексикологиясе* дип аталган шактый күләмле һәм телнең иң катлаулы, күпкатламлы өлкәсен колачлаган хезмәтнең бу томы (III том, икенче кисәк) махсус рәвештә татар теленең сүзлекләрен өйрәнүгә багышланды.

Татар лексикографиясе бай тарихы белән генә түгел, сүзлек фондының бик күләмле булуы белән дә аерылып тора. Моңарчы татар теле белемендә лексикографик мирасны бергә туплап, комплекслы якын килеп, тирәнтен анализлаган хезмәтләр юк иде әле. «Татар лексикографиясе» китабы – бу юнәлештә беренче тәҗрибә. Хезмәтнең төзелешен билгеләгәндә, авторлар алдында татар лексикографиясенең үсеш этапларын, бай тарихын, сүзлек төрләрен мөмкин кадәр тулы күрсәтү максаты торды. Шуның белән бергә, лексикография фәненә кагылышлы теоретик мәгълүматны да күзаллау зарури иде. Әлеге максаттан чыгып, хезмәт өч гомуми

өлешкә бүленде: татар лексикографиясенә кереш, татар лексикографиясе тарихы һәм татар сүзлекләренең төрләре.

Анализ барышында татар лексикографиясенә багышланган шактый монографик хезмәтләр инде дөнья күргән, шуңа карамастан әле теоретик планда хәл итәсе мәсьәләләр дә кала баруы ачыкланды. Моның сәбәпләре гомуми лексикография фәнендәге тенденцияләргә, шулай ук татар лексикографиясенең эчке факторларына да бәйле. Шулай ук термин мәсьәләсе дә ачык кала бирә, чөнки *лексикография* һәм татар теле белемендә әйләнешкә кергән *лингвография* терминнарының эчтәлек ягыннан тәңгәл булмавы үз чиратында соңгы елларда басылган сүзлекләрнең лексиканы гына түгел, телнең башка берәмлекләрен тасвирлауга йөз тотканлыгы да шуны исбатлый.

Татар лексикографиясенең тарихын өйрәнү нәтиҗәсендә лексикографиянең башлангычы XI–XIII гасырлардагы борынгы төрки сүзлекләргә барып тоташып, соңрак XIV–XV гасырлардагы кыпчак-коман сүзлекләре традицияләре белән баетылып, XVI–XVIII гасырларда төзелгән русча-татарча (яки татарча-русча) сүзлекләрдә максатчан юнәлеш алуын күрдек. XIX гасырда гамәли максаттан чыгып төзелгән сүзлекләр белән беррәттән, фәнни яссылыкта эшләнгән сүзлекләр дә басыла. Бу чор сүзлекләрендә татар теленең лингвистик табигатенә караган материаллар, әдәби тел сүзләре, алынмалар, диалект һәм халыкның җанлы сөйләм теле үрнәкләре, татар һәм рус телләрен өйрәнүгә бәйле киңәшләр дә урын ала. Татар лексикографиясендә бу чорда Каюм Насыйриның «Ләһҗәи татари» беренче аңлатмалы сүзлеге басылу сүзлекләр төзү фәненең ныклы традицияләре урнашып җитүе турында сөйли. Әлеге традицияләр XX гасыр башында төрле төрдәге сүзлекләрдә дәвам иттерелә һәм татар лексикографиясе яңа төр сүзлекләр белән тулылана. Сүзлекләр бер-берсеннән төрләре, принциплары, лөгатьлекләре белән аерылса да, сүзлекләргә куелган гомуми таләпләрнең беркадәр формалашуы күзгә ташлана.

XX гасырның 20 нче елларыннан татар лексикографиясе үсеше яңа баскычка күтәрелә. Беренчедән, бу өлкәдә урнашкан традицияләр дәвам итә. Без аны тәрҗемә, аңлатмалы сүзлекләрдә

күрәбез. Икенчедән, моңарчы басылмаган сүзлекләр төзү эше башлана, мәсәлән, терминнар сүзлеге, энциклопедик сүзлек, орфографик, диалектологик сүзлекләр шундыйлардан. Бу чордан башлап татар сүзлекләренең график бирелеше дә үзгәрә.

XX гасырның 50 нче елларыннан сүзлекләр төзү эшчәнлегенең комплекслы характер алуы беренче чиратта Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында лексикография бүлеге ачылу белән бәйле. Сүзлек төзү принципларына фәнни якын килү, телнең төрле катламнарыннан фактик материал туплау һәм аны фәнни анализлау, татар теленең сүз байлыгын туплаган җитмешкә якын сүзлек дөнья күрүгә мөмкинлек бирә. Алар арасында инде традицион саналган сүзлекләр белән беррәттән, яңа төрләре дә (фразеологик, ономастик һәм синонимик сүзлекләр) басыла.

XX гасыр ахырыннан хәзергәчә чор – татар лексикографиясенең һәм сан, һәм сыйфат ягыннан үсеш-үзгәреш кичергән чоры. Лексикография фонды яңа төр сүзлекләр белән тулылану, бай традицияле филологик сүзлекләрнең даими яңа материал белән баетылуы, теоретик лексикографиянең фәнни югарылыкта системалы эшләнүе, «Сүзлекләрнең электрон фонды» булдырылу татар лексикографиясенең хәзерге яшәешен күрсәткән билгеләрдән санала. Шуның нәтиҗәсендә төрле типтагы 200 тирәсе сүзлек ике форматта: һәм кәгазь, һәм электрон вариантта эшләнә. Бу үз чиратында милли лексикографиянең заман таләпләренә яраклашып үсүе, төрле электрон лексиконнар, интерактив сүзлекләр һәм башка төр фәнни хезмәтләр эшләү өчен зур мөмкинлекләр булуын күрсәтә торган фактор.

«Татар лексикографиясе» хезмәтенең өченче өлеше татар сүзлекләренең төрләрен анализлауга багышланды. Беренче карашка, биредә тәкъдим ителгән мәгълүмат алдагы бүлек белән аваздаш дигән тәэсир калдырырга мөмкин. Әмма материалның бу төрдә бирелешенең үз максаты бар. Алдагы бүлектә татар лексикографиясенең үсешен, сүзлек төрләренең эшләнешен, аларда тарихи чорлар кысасында материал бирелешенә игътибар юнәлтелсә, әлеге бүлектә исә һәр сүзлек төренең үзенчәлегенә,

күләменә, лөгатьлеккә тирәнтен анализ ясау күздә тотыла. Һәр сүзлек төренең төзелеше, сүзлек мәкаләләренең эчтәлеге татар лексикографиясе фәненең үсешен, камилләшүен ачык күрсәтә. Шулай ук бу өлкәдәге эзләнүләр, сүзлек төзү принципларының эшләнеше һәм эзләнүләр, материалларны тәкъдим итүдәге җитешсезлекләр дә, татар лексикографиясендә ачыкланасы мәсьәләләр дә өченче бүлектә шактый игътибарга алынды.

Хезмәт ахырындагы татар сүзлекләренең хронологик белешмәлеге исә татар лексикографик фондын тулаем күзаллау мөмкинлеге тудыра.

Татар теленең сүзлек фондын комплексны өйрәнүгә багышланган әлеге тәҗрибә лексикография фәненең үсеш дәрәҗәсен билгеләүдә төп күрсәткечләрдән саналырга хаклы. Ул хәзерге татар тел белеме казанышлары рәтендә лаеклы урынын табар дигән өметтә калабыз.

## ТАТАР СҮЗЛЕКЛӘРЕНЕҢ ХРОНОЛОГИК БЕЛЕШМӘЛЕГЕ

### 1801

Гиганов И. Слова коренные, нужнейшие к сведению для обучения татарскому языку, собранные в Тобольской главной школе, учителем татарского языка Софийского собора, священником Иосифом Гигановым и юртовскими муллами свидетельствованные. – СПб.: Императорская Академия Наук, 1801. – 75 с.

### 1804

Гиганов И. Словарь российско-татарский, собранный в Тобольском главном народном училище учителем татарского языка священником Иосифом Гигановым и муллами юртовскими свидетельствованный. – СПб.: Тип. АН, 1804. – 682 с.

### 1833

Троянский А. Словарь татарского языка и некоторых употребительных в нем речений арабских и персидских, собранный трудами и тщанием учителя татарского языка в Казанской семинарии, священника Александра Троянского и напечатанный с дозволения комиссии духовных училищ. Т. I. – Казань: Тип. ун-та, 1833. – 629 с. +IV с.

### 1835

Троянский А. Словарь татарского языка и некоторых употребительных в нем речений арабских и персидских, собранный трудами и тщанием учителя татарского языка в Казанской семинарии, священника Александра Троянского и напечатанный с дозволения комиссии духовных училищ: Т. II. – Казань: Тип. ун-та, 1835. – 340 с.

**1859**

Кукляшев С. Словарь к татарской хрестоматии / Сост. С. Кукляшев. – Казань: Тип. ун-та, 1859. – 106 с.

**1869**

Сравнительный словарь турецко-татарских наречий, со включением употребительнейших слов арабских и персидских и с переводом на русский язык / Составил Лазарь Будагов, – Т. I (ا – ف). – СПб.: Тип. Имп. Акад. наук, 1869. – X, 810, 6, 3 с.

**1871**

Будагов Л. З. Сравнительный словарь турецко-татарских наречий, со включением употребительнейших слов арабских и персидских и с переводом на русский язык: В двух т.: Т. 2. – СПб.: Тип. АН, 1871. – 415 с.

**1876**

Остроумов Н. П. Первый опыт словаря народно-татарского языка по выговору крещенных татар Казанской губернии. – Казань: Тип. ун-та, 1876. – 145 с.

**1878**

Насыйри К. Татарча-русча лөгать китабы. = Татарско-русский словарь. – Казань: Тип. Казан, унта, 1878. – 120 с.

**1880**

Краткий татарско-русский словарь с прибавлением некоторых славянских слов с татарским переводом. – Изд. 1-е. – Казань: Тип. М. А. Гладышевой и др., 1880. – 55 с.

**1882**

Краткий татарско-русский словарь с прибавлением некоторых славянских слов с татарским переводом. – Изд. 2-е. – Казань: Тип. М. А. Гладышевой и др., 1882. – 55 с.

Насыйри К. Гыйльме зирагать (игенчелек һәм бакчачылык эше). – Казан: Типография Императорского Университета, 1882. – 24 б.

**1884**

Радлов В. В. О языке куманов: По поводу издания куманского словаря / В. В. Радлов. – СПб.: Тип. Имп. Рос. АН, 1884. – 53 с.

Насыйри К. Гөлзар вә чәмәнзар (үсемлек һәм чәчәклек). – Казан: Типография Императорского Университета, 1894. – 110 б.

## 1886

Краткий татарско-русский словарь с прибавлением некоторых славянских слов с татарским переводом. – Изд. 3-е. – Казань: Тип. М. А. Чирковой, 1886. – 96 с.

Өч йөз җитмешләп дәва үләннәренең исемнәре русча, латинча, мөселманча. = Татарско-русско-латинский терминологический словарь лекарственных трав, содержащий 370 названий. – Казань, 1886. – 52 с.

## 1888

Краткий татарско-русский словарь с прибавлением некоторых славянских слов с татарским переводом. – Изд. 4-е. – Казань, 1888. – 96 с.

## 1891

Краткий татарско-русский словарь с прибавлением некоторых славянских слов с татарским переводом. – Изд. 5-е. – Казань, 1891. – 96+11 с.

## 1892

Насыйри К. Рус хоруфы һиҗасы үзрә мөрәттәб лөгать китабы. = Полный русско-татарский словарь с дополнением из иностранных слов, употребляемых в русском языке как научные термины. Около 20000 слов. – Казан: Ун-т тип., 1892. – 263 б.

Остроумов Н. П. Татарско-русский словарь Н. Остроумова. – Изд-е правосл. мисс. об-ва. – Казань: Тип. ун-та, 1892. – 1У+246 с.

## 1893

Баруди Г. Лөгать сәляссә зөбән өч тел. – 1 басма. = Трехъязычный (арабско-персидско-татарский) словарь. – Изд. 1-е. – Казан, 1893. – 41 б.

Габделгазиз Ш. Татар теленнән урысчага һәм урыс теленнән татарчага тәрҗемә-лөгать яки словарь. = Перевод с татарского на русский язык с русского на татарский или словарь. – Казан: Ун-т типолитогр., 1893. – 72 б.

## 1894

